«ЯР ЧАЛЛЫ ДӘҮЛӘТ ПЕДАГОГИКА УНИВЕРСИТЕТЫ»
ФЕДЕРАЛЬ БЮДЖЕТ ЮГАРЫ БЕЛЕМ БИРҮ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ МӘГАРИФ ИДАРӘСЕ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ МУСА
ҖӘЛИЛ ИСЕМЕНДӘГЕ “1 НЧЕ ГИМНАЗИЯ” МУНИЦИПАЛЬ БЮДЖЕТ ГОМУМИ
БЕЛЕМ БИРҮ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ

# «Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын»
# Бөтенрәсәй форумы материаллары

Түбән Кама
2022

УДК 37.01

Федераль бюджет югары белем бирү учреждениесенең «Яр Чаллы дәүләт педагогика университеты» психолого-педагогик һәм мәхсус дефектологик белем бирү кафедрасы, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы башкарма комитеты мәгариф идарәсе, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Муса Җәлил исемендәге “1 нче гимназия” муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе карарлары белән басыла

Төзүчеләр:

1. Мухаметшин Азат Габдулхакович, педагогика фәннәре докторы, профессор, Федераль бюджет югары белем бирү учреждениесенең «Яр Чаллы дәүләт педагогика университеты» беренче проректоры
2. Хәзрәтова Фирүзә Вакильевна, педагогика фәннәре кандидаты, Федераль бюджет югары белем бирү учреждениесенең «Яр Чаллы дәүләт педагогика университеты» психолого-педагогик һәм мәхсус дефектологик белем бирү кафедрасы мөдире
3. Хөснетдинова Резидә Рөстәмовна, психология фәннәре кандидаты, Федераль бюджет югары белем бирү учреждениесенең «Яр Чаллы дәүләт педагогика университеты» психолого-педагогик һәм мәхсус дефектологик белем бирү кафедрасы доценты
4. Шәрәфетдинова Зимфира Габдрахмановна, филология фәннәре кандидаты, Федераль бюджет югары белем бирү учреждениесенең «Яр Чаллы дәүләт педагогика университеты» башлангыч һәм мәктәпкәчә белем бирү теориясе һәм методикасы кафедрасы доценты
5. Хабибуллин Ильнур Ильдарович, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Муса Җәлил исемендәге “1 нче гимназия” муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең директоры
6. Хайруллина Гульназ Рашитовна, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Муса Җәлил исемендәге “1 нче гимназия” муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы
7. Хайруллина Гульнара Илсуровна, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Муса Җәлил исемендәге “1 нче гимназия” муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең информатика укытучысы
8. Сөнгатуллина Ләйлә Мөхәмәтовна, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Муса Җәлил исемендәге “1 нче гимназия” муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы

9. Галимова Гөлфинә Салихҗановна, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Муса Җәлил исемендәге “1 нче гимназия” муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы

**Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын** = Жизнь люби, люби отчизну, всё, чем жив родной народ: (Укытучылар һәм укучыларның эзләнү-тикшеренү, проект һәм иҗади эшләре Бөтенрәсәй Форумы материаллары=Материалы всероссийского форума) - Түбән Кама, 2022. – 340 б.

Җыентыкта “Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын” Бөтенроссия форумында катнашучы укытучы һәм укучыларның  доклад тезислары урын алды.

Җыентык материаллары гомуми белем бирү укытучысының инновацион эшчәнлегендәге төп аспектларны үз эченә ала: мәгарифкә  яңалык өстәү, яңа педагогик технологияләр һәм методикалар кертү,  укучыларның интеллектуаль-иҗади эшчәнлеген оештыру, инновацион педагогик проектларны һәм программаларны тормышка ашыру, мәктәп имиджын булдыру һәм уңай тәрбия мохите тудыру өстендә эшләү. Искәрмә: язмаларда автор орфографиясе һәм пунктуациясе сакланды.

Автор редакциясендә басыла

**УДК 37.01**

Эчтәлек


**Беренче бүлек. Укытучылар чыгышы.** 5

Әминова Эльмира Зөфәр кызы. Мәктәптә милли тәрбия бирү юнәлешләре 5

Әхмәтова Резеда Илдус кызы. Математика һәм физика фәннәрен өйрәтүдә яңа таләпләр 7

Вәгыйзов Фәрит Яхъя улы. Дәресләрдә туган телне өйрәтүдә мотивлаштыруның кайбер алымнары 10

Вәлиева Рузалия Сәед кызы. Математика укытучысы уйланулары 13

Галимова Гөлфинә Сәлихҗан кызы. Башлангыч сыйныфларда туган тел дәресендә уен технологиясен куллану 23

Ганиева Рузилә Фәвәдис кызы, Фокеева Елизавета Павел кызы. Дәресләрдә яңа педагогик технологияләр куллану 26

Гарипова Лилия Рәүф кызы. Гыйлем тарату, халыкка ярдәм бирү өчен тырышу, иң гүзәл гайрәттер 28

Гарифуллина Ләйсән Әнәс кызы. Функциональ белемлелек иҗтимагый иминлекнең мөһим индикаторы 35

Гиздатуллина Эльмира Мирзаһит кызы, Фәләхиева Ильмира Ризатдин кызы. Дәресләрдә мәгънәле уку стратегиясен формалаштыру 38

Гыймалетдинова Нурзия Минәхмәт кызы. ФДББС тормышка ашыру шартларында татар әдәбияты дәресләрендә яңа технологияләр. Тәнкыйди фикерләү технологиясе ысулларын куллану 40

Җәләлова Венера Иршат кызы. Сәләтле балалар. Кем алар? 47

Зарипова Әнисә Газизулла кызы. Сәнгатьле сөйләм эшчәнлеген оештыру процессында укучыларның иҗади сәләтен үстерү 48

Кәримова Марина Николай кызы. Татар телен чит тел буларак укытуда проект методының әһәмияте 51

Колмәхәммәтова Зөлфия Эдуард кызы, Хәйруллина Гөлназ Рәшит кызы. Укыдым димә, аңладым диген 52

Куряева Людмила Петр кызы, Маслова Ирина Евгений кызы. Татар әдәбияты һәм җәмгыять белеме дәресләрендә текстны уку һәм аңлау буенча функциональ грамоталылыкны үстерү 58

Масаллимова Мәүлия Минвәли кызы. Сәләтле балалар белән эшләү алымнары 62

Миннегалиева Гөлназ Сәләхетдин кызы, Шаһиева Энҗе Рафаил кызы. Башлангыч классларда проект эшчәнлеге 64

Минегалиева Ләйсән Ризат кызы. Дәрестә тәрбия потенциалын күтәрү - укыту-тәрбия процессын оештыруның мөһим шарты 67

Мөбарәкшина Рузилә Рәшит кызы. Башлангыч сыйныфларда туган (татар) тел һәм әдәби уку дәресләрендә фәнни-эзләнү эшен оештыру 69

Мулламөхәммәтова Рәсимә Риф кызы. Кеше химия мохитендә 73

Нурмиева Резидә Равил кызы. Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә проект методын куллану 75

Пахомова Гөлшат Әсхәт кызы, Чевачина Розалия Вакыйф кызы. Нәтиҗәлелеккә ирешү юллары 78

Солтанов Радик Ибраһим улы. Тарихны укытуда укучыларның иҗади сәләтләрен үстерү өчен мәсьәләләр куллану 82

Степанова Роза Александр кызы. Балаларны татар халкының гореф – гадәтләре, йолалары, бәйрәмнәре үрнәгендә тәрбияләү 86

Сөнгатуллина Ләйлә Мөхәмәт кызы. Әбиемнең күңел сандыгы 91

Хәйруллина Гөлнара Илсур кызы. Информацион технологияләр 93

Хәйруллина Лилия Миннефаяз кызы. Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә инновацион технологияләр куллану 95

Шәймөхәммәтова Фәнзилә Мирзанур кызы, Муратова Лариса Миншәех кызы. Туган тел һәм 105

әдәбият дәресләрендә уңай мотивация тудыру

**Икенче бүлек. Укучылар эшләре.** 113
Абзалутдинова Эльза. Фитонцидларның азык-төлек сакланышына йогынтысы 112
Афанасьева Лиана. Иске Комазан авылы тарихы 116
Әхмәтҗанова Иделия. Габдулла Кариев- олуг шәхес 120
Вәлиев Реваль. Нәселебез эзләре буйлап... 129
Вәлиуллина Гүзәл. Халкыбызның туй йолалары: үткәне һәм бүгенгесе 133
Гайнетдинова Айсылу, Хабиров Салих. Кышлаучы кошларны тукландырыгыз 153
Галиева Зәринә. Исемнәрдә-кеше язмышы 160
Галимова Айсылу. Шинельсез солдатлар 169
Галимов Зиннур, Хәлимов Рәмис. Татар халкында кунакчыллыкның милли-мәдәни үзенчәлекләре 172
Галиуллина Адилә. Тел – бакча, сүз - чәчәк 177
Ганиева Нәзилә. «Муса Җәлилнең гражданлык батырлыгы» 194
Гасимова Алинә. Татар халык мәзәк текстларының милли-мәдәни үзенчәлекләре 202
Гатауллин Рәмис. «Муса Җәлилнең фронт лирикасында үзенчәлекләр» 207
Гиззатуллина Мәрьям, Фәсхетдинова Диләрә. Чәй табыны: татарча һәм инглизчә 212
Гыйлемханова Язилә. Йолаларда һәм халык авыз иҗаты әсәрләрендә саннарның вазифалары 220
Гыйләҗетдинова Зилә. Мөхәммәт Мәһдиев әсәрләрендә авыл кешеләренә хас сөйләм үзенчәлекләре 226
Имамиева Сәмирә. Батырлыкта – матурлык 234
Кәлимуллин Ильяс. Төбәк сөйләмендә кушаматлар 243
Кашапова Илүзә. *Мин Тукайның дәвамчысы* 250
Колмөхәммәтов Әлфис. Гасырлар кичкән телем 257
Макаров Әмир. Муса Җәлил 259
Мәрданшина Әмилә. Җәлил эзләре буйлап... 261
Мәхмүтова Диана. Көз 297
Мөбәрәкшин Илгиз. Әниемә 268
Низамова Ясминә. Венераны терраформалаштыру һәм колонизация ысуллары 272
Разетдинова Рузилә. Мамадыш районы Югары Ушмы төбәге татар авылларының кыскача тарихы һәм микротопонимиясе 278
Сафин Алмаз. М.Җәлил иҗатында кеше һәм табигать күренешләренең үзара мөнәсәбәте 284
Ситдиков Булат. Якын дуслар! 290
Солтанова Эльвина. Без яшь чакта 288
Фаррахов Ислам. Туган авылым топонимнары 289
Фёдорова Милена. Авылым язмышы-халкым язмышы 294
Феткуллова Динара. Чувашстан татарлары тормышында Яңа Торын кабер ташлары 305
Хабибуллин Давид. XVI-XVII гасырларда Казан бистәләре. Татар бистәсе 309
Хайруллина Ясминә. Мәктәбем - белем учагы 317
Шәрифуллин Данир. Милләтемнең энҗе бөртекләре 322
Юнысова Ралия. Иске Комазан авылы тарихы, ономастикасы, топонимикасы 329
Якупов Ислам. Туган җирем, туган ягым! 334

## Кереш сүз

Һәр милләттә исеме телгә алынуга ихтирам уята торган шәхесләр була. Муса Җәлил әнә шундый исемнәрнең берсе. Юк, ул исем генә түгел, бәлки тирән мәгънәле символ да. Чөнки бу исемнең синонимнары булып батырлык, кыюлык, каһарманлык, талантлылык, ватанпәрвәрлек,тугрылык кебек тирән мәгънәле сүзләр тора. Шагыйрь Муса Җәлил үзенең бөтен гомерен туган иленә, туган халкына багышлаган. Аның бөтен тормышы — героик тормыш ул. Муса Җәлил шигырьләрендә туган халкының азатлыгы өчен көрәштә үзен корбан итәргә әзер торган көрәшче образы тудыра, үзе дә халык эше өчен соңгы сулышына кадәр аяусыз көрәшә. Ул халык эше өчен көрәшергә биргән антын тиңдәшсез батырлык, искиткеч ныклык белән үти, үз халкының азатлыгы өчен гомерен бирә.

Республикабызда бу герой исемебелән аталучы урамнар, мәдәният үзәкләре бар. Түбән Камада урнашкан безнең 1-нче номерлы Гимназия дә Муса Җәлил исемен горур йөртә. Федераль бюджет югары белем бирү учреждениесенең «Яр Чаллы дәүләт педагогика университеты» психолого-педагогик һәм мәхсус дефектологик белем бирү кафедрасы, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы башкарма комитеты мәгариф идарәсе, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Муса Җәлил исемендәге “1 нче Гимназия” муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе тарафыннан 2022 елнын 15 февралендә Муса Җәлилнең тууына 116 ел уңаеннан, “Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын” Бөтенрәсәй Форумы үткәрелде. Форумның максаты укытучылар һәм укучыларның фәнни-тикшерү эшчәнлегенә кызыксыну уяту. Мәктәп укытучылары һәм укучыларны үзләренең эзләнү-тикшеренү, проект һәм иҗади эшләрен тәгъдим иттеләр. Конкурс эшләре 7 юнәлеш буенча кабул ителде һәм эксперт комиссиясе тарафыннан бәяләнде. Чыгыш ясау нәтиҗәләре буенча җиңүчеләр диплом, сертификатлар белән бүләкләнде һәм аларның эшләре әлеге җыентыкка кертелде. Беренче бүлектә укытучыларның хезмәтләре, ә икенче бүлектә мәктәп укучыларының проектлары урын алды. Тәгъдим ителгән эзләнү-тикшеренү, проект һәм иҗади эшләр төрле көнүзәк проблемаларны күтәрәләр: анда туган тел проблемасы да, тарихны өйрәнү үзенчәлеге дә, патриотик тәрбия дә, химия, биология, физика фәннәре сораулары да, милли тәрбия дә чагылыш тапты. Бу яшь буынның битараф булмавын, киләчәгебезнен өметле булуын, безнең чорда да “җәлилчеләр” булуын тагын бер кат исбатлый.

Халык тормышы турында кирәген генә белеп иҗат итүче Җәлил гомере җырга әверелде. Ул җыр безгә тыныч кына яшәргә, хуш күңелле, битараф булырга ирек бирми; безне янарга, дөрләргә өйрәтә, халыклар бәхете өчен көрәшкә өнди.

## Беренче бүлек. Укытучылар чыгышлары.

*Әминова Эльмира Зөфәр кызы,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы "22нче гимназия" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең беренче категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

### Мәктәптә милли тәрбия бирү юнәлешләре

***«Хәзерге мәктәпнең вазифасы безнең киләчәк буыныбызны аңлы, укымышлы бер татар ясап чыгарудыр» (Гаяз Исхакый)***

Баланы үз милләтенең лаеклы вәкиле һәм камил шәхес буларак тәрбияләү өчен, аңа туган телен өйрәтү генә аз. Без, укучыларга белем бирү белән беррәттән, милли тәрбия бирүне гамәлгә ашырабыз, милли үзаңны үстерү юнәлешендә максатчан эш алып барабыз. Баланы үз милләтенең лаеклы вәкиле һәм камил шәхес буларак тәрбияләү өчен, аңа туган телен өйрәнү генә аз.Аның өчен тел милли гореф-гадәтләрне аңга сеңдерү, саклау, киләчәк буыннарга тапшыру чарасына әверелергә тиеш. Туган тел аралашу һәм тирә-юньне танып белү чарасыннан – милли-мәдәни традицияләрне аңга сеңдерү, саклау һәм киләчәк буыннарга тапшыру чарасына әверелергә тиеш. Шул очракта гына тел өйрәнү нәтиҗәле була.

Без яшәгән заман - тирән үзгәрешләр чорына туры килә. Заманнан артка калмас өчен мәктәпләрдә тәрбия бирү эшен ФГОС таләпләренә туры килерлек итеп, балаларны сәләтле, белемле, әдәпле тәрбияләүгә зур игътибар сорала.

Хәзерге чорда радио һәм телевидение, урам йогынтысы балаларның аңына, рухына әдәпсезлек үрнәкләрен сеңдергән заманда, милләтнең гасырлар буе формалашкан тәҗрибәсе, әхлак кагыйдәләре югала бара. Менә шуның өчен мәктәпләрдә халкыбыз хәзинәләре нигезендә милли үзаң тәрбияләүгә аеруча зур игътибар бирү безнең максат булып тора.

Мәктәптә милли тәрбия процессы – гаҗәеп катлаулы, кешелек җәмгыятенең иҗтимагый, икътисадый, сәяси, педагогик һәм психологик шартларына бәйле күренеш. Милли тәрбия бирү нигездә дүрт юнәлештә алып барыла:

1.Укучыларны кешелек җәмгыятенең әхлакый нигезләре булган гомумкешелек кыйммәтләре белән таныштыру, аларның асылын аңлату, таныту.

2.Укучыларда җәмгыятьтә мөнәсәбәт нормалары булган гомумкешелек сыйфатларын формалаштыру.

3.Укучыларда милләт буларак яшәүнең төп шарты булган милли үзаң формалаштыру.

4.Укучыларның үз милләтенә хас уңай сыйфатларга ия булуы.

Дәресләрдән тыш тәрбия эшләре алып бару — балаларга төп белем бирүнең, аларны шәхес буларак үстерүнең аерылгысыз бер өлеше. Мәктәп яшь буынга белем һәм тәрбия бирүдә халыкның милли традицияләренә нигезләнгәндә генә үзенең тәрбияви һәм белем бирү бурычларын уңышлы хәл итә ала.

Тәрбия бирүнең төп максаты — тормышка һәр яктан әзерлекле, камил, үз милләтенең, матди һәм рухи байлыкларын арттыручы, туган халкының киләчәген кайгыртучы шәхес тәрбияләү.

Бурычлары:

1.Халкыбызның милли үзенчәлекләрен, күркәм сыйфатларын, йола-гадәтләрен, гаилә этикасын кече яшьтән үк төшендереп, укучыларны өлкәннәр үрнәгендә тәрбияләү, буыннар бәйләнешен тәэмин итү;

2.Әхлакый сыйфатлар тәрбияләү, балаларны кешеләр белән аралашу кагыйдәләренә өйрәтү, югары әдәп, әхлак сыйфатлары булдыру; иҗади сәләт һәм милли үзаң формалаштыру;

3.Туган телебез, мәдәниятебез үсеше өчен җаваплылык хисе булдыру;

йолалар нигезендә сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау.

Бүген без укучыларны туган телдә укырга һәм язарга өйрәтү белән генә чикләнмичә, һәр яклап камил шәхес тәрбияләүнең бер юнәлеше булган милли культура формалаштыру, халкыбызның милли-мәдәни рухын сеңдерү юнәлешендә эшлибез.

Әдәплелек, тыйнаклык, намуслылык, башкаларга хөрмәт белән карау кебек әхлакый сыйфатлар һәт милләт кешесенә дә хас. Милли культура формалаштыруда иң мөһиме – халык традицияләренә, гореф-гадәтләренә нигезләнеп, әхлаклылык сыйфатлары тәрбияләү.

Укучыларда милли мәдәният турында бербөтен күзаллау булдыру – туган телеңне белү һәм шул телдә аралашу; халык авыз иҗатын – әкиятләр, мәкаль-әйтемнәр, табышмаклар, бишек җырларын белү; шигырьләр, җырлар өйрәнү; халыкка хас әдәп кагыйдәләрен, туган як табигатен, милли халык уеннарын белү дигән сүз. Укучыларны татар теле дәресләрендә генә дөрес һәм матур итеп сөйләшергә, татарча аралашырга өйрәтеп бетереп булмый. Шуңа күрә телебезгә мәхәббәт тәрбияләү, халкыбызның гореф-гадәтләре, йола-бәйрәмнәре белән таныштыру, сәнгатьле уку күнекмәләрен үстерү һәм, иң әһәмиятлесе, аралаша белергә өйрәтү максатыннан дәрестән тыш төрле чаралар үткәрүгә зур әһәмият бирелә. Шундый чараларның берсе – ел саен үткәрелеп, матур традициягә әйләнгән «Туган телем- иркә гөлем әдәби» музыкаль кичәсе. Бу чарада башлангыч һәм югары сыйныф укучылары да бик актив катнаша. Шулай ук укучылар белән берлектә «Йолдызлы сәгать», «Телләр белгән- илләр гизгән», «Тамчы –шоу» кебек чаралар

үткәрелә. Күренекле әдипләребезнең дә туган көннәре билгеләп үтелә. Г.Тукайга, М.Җәлилгә, А.Алишка һәм башка шагыйрь, язучыларга багышланган әдәби-музыкаль кичәләр үткәрелә. Укучылар аларның әсәрләрен сәхнәләштерәләр, шигырь конкурсларында катнашалар, стенгазеталар чыгаралар. Шәһәребезнең 6 нчы балалар китапханәсе белән тыгыз элемтәдә торабыз.

Балаларга дөрес тәрбия бирүдә ата-ананың абруе көчле. Аларның шәхси үрнәге генә балаларның мәхәббәтен яулый ала. Яшь буынга дөрес тәрбия бирү вазыйфасына һәр ата-ана җитди һәм җаваплы карарга тиеш. Бу юнәлештә әти-әниләр белән берлектә бик күп чаралар үткәрелә.Укучларыбыз төрле фәнни-гамәли конференцияләрдә, конкурсларда катнашалар һәм җиңүләр яулыйлар.

Ихтирамлы (толерант) шәхес тәрбияләү – ул укучыларда башка милләт кешеләренә, аларның мәдәниятенә уңай мөнәсәбәт булдыру дигән сүз. Без балаларда үз халкыбызга, үз илебезгә мәхәббәт тәрбияләү белән генә чикләнмичә, кайда яшәүләренә һәм нинди милләт кешеләре булуга карамастан – барлык халыкларны, аларның мәдәниятен, гореф-гадәт, традицияләрен хөрмәт итәргә, табигатьне яратырга өйрәтәбез, гомумкешелек кыйммәтләре белән таныштырабыз. Үз мәдәниятләре белән беррәттән, укучылар башка халыкларның да мәдәниятен, телен белергә тиеш.

*Әхмәтова Резеда Илдус кызы,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы «19нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе” муниципаль бюджет белем бирү учреждениесенең югары категорияле математика укытучысы*

**Математика һәм физика фәннәрен өйрәтүдә яңа таләпләр**

Тормышта билгеле бер белемгә ия булу гына түгел, аларны куллана белү дә мөһим. Бу бигрәк тә математика һәм физика кебек төгәл фәннәр өчен актуаль. Хәзерге мәктәп укучыларының дәресләрдә өйрәнелә торган формулалар һәм теоремалар, мондый белемнәрне тормышта куллануның конкрет ысулларын һәрвакытта да күреп булмый. Бу еш кына укуга кызыксынуны югалту сәбәбе булып тора. Шуңа күрә математик белем бирүнең төп максатларының берсе – укучыларның математик грамоталылыгын - аларның математика ярдәмендә тормыш бурычларын хәл итәргә әзерлекләрен һәм сәләтләрен тәэмин итү. Бу хакта халыкара мониторинг тикшеренүләре, аерым алганда, PISA һәм TIMSS та сөйли.

Математика яки физика белән шөгыльләнү бер генә кеше сәләтенә һәм көченә түгел, эмоция яки интеллект булсынмы, ә гомумән, кешегә дә туры килә. Математика интеллектуаль, әхлакый җайланмалар системасын формалаштыра, бүлемнәрне,

җитештерелгән әйберне исәпләргә, пөхтә сызымнар ясарга өйрәтә. Математика һәм физика буенча PISA һәм TIMSS тикшеренүләре нәтиҗәләре буенча мәктәпләрдә билгеле бер җитешсезлекләр ачыкланды, аерым алганда, коммуникатив һәм гомуми белем һәм осталыкның, мәгълүмат чыганаклары белән эшли белүнең түбән дәрәҗәсе билгеле булды.

Безнең укучылар мәктәптә алган белем системасы белән үз тормыш тәҗрибәсен "бәйли" алмый. Стандарт булмаган ситуацияләрдә математик закончалыкка юлыгып, укучылар еш кына таныш төшенчәләрне "белми". Математика укытучылары балага еш кына бурычны үзгәртеп кору, аны "математик" телгә күчерү, математик бурычларны билгеләү, математик объектларны билгеләү авыр икәнлеген белә.

Математика укытуда компетентлы якын килү-ул гомуми принциплар җыелмасы: математик белем бирү максатларын билгеләү, белем бирү эчтәлеген сайлап алу, белем бирү процессын оештыру һәм белем бирү нәтиҗәләрен бәяләү. Математик белем бирүнең мәгънәсе укучыларның социаль тәҗрибәдән файдалану нигезендә төрле эшчәнлек төрләрендәге проблемаларны мөстәкыйль рәвештә хәл итү сәләтен үстерүдән гыйбарәт. Математик белем бирү процессын оештыру белем бирүнең эчтәлеген тәшкил итүче танып-белү, коммуникатив, оештыру, әхлакый һәм башка проблемаларны мөстәкыйль хәл итү тәҗрибәсен формалаштыру өчен шартлар тудырудан гыйбарәт. Белем бирү нәтиҗәләрен бәяләү укучыларның билгеле бер этапта ирешкән белем дәрәҗәсен анализлауга нигезләнә.

**Менә төп компетенцияләр исемлеге**

**Өйрәнергә:**

- үз белемнәрен тәртипкә салуны оештыру;
- үз өйрәнү алымнарын оештырырга;
- проблемаларны хәл итә белү;
- үз укуың белән мөстәкыйль рәвештә шөгыльләнү.
- тәҗрибәдән файданы күрә белү;

**Эзләргә:**

- төрле мәгълүматлар базасын табу;
- тирә-юньдәгеләрне сораштыру;
- эксперттан консультацияләр алу;
- Мәгълүмат алу;
- документлар белән эшли һәм аларны классификацияли белү.

**Уйларга:**

- узган һәм хәзерге вакыйгаларның үзара бәйләнешен оештыру;
- җәмгыятьләребез үсешенең теге яки бу аспектына тәнкыйть белән карарга;

- ышанычсызлыкка һәм кыенлыкларга каршы тора белү;
- дискуссияләрдә үз урыныңны һәм фиреңне таба белү;
- укыту һәм тәрбия эше бара торган өлкәдә сәяси һәм икътисади округның әһәмиятен күрү;
- социаль гадәтләр белән бәйле сәламәтлек, куллану, шулай ук әйләнә-тирә мохитне бәяләү;
- сәнгать һәм әдәбият әсәрләрен бәяли белү.

**Хезмәттәшлек:**

- хезмәттәшлек итә һәм төркемдә эшли белү;
- карарлар кабул итү — каршылыкларны һәм конфликтларны җайга салу;
- килешә белү;
- контрактларны эшли һәм башкара белү.

**Эшкә керешү:**

- Проектка керешү;
- Җаваплылык тою;
- Группага яки клективка керү һәм үз өлешеңне кертү;
- Бердәмлекне исбатлау;
- Үз эшеңне оештыра белү;
- исәпләү һәм модельләштерү приборлары белән куллана белү.

**Җайлашу:**

- яңа технологияләр,  мәгълүмат һәм коммуникацияләр куллана белү;
- -тиз үзгәрүчәнлек алдында сыгылмалыкны исбатлау;
- авырлыклар алдында ныклыкны күрсәтү;
- яңа карарлар таба белү.

Компетентлы алымны гамәлгә ашыру конкурс имтиханына чыдамыйча, яхшы өлгергән укучы тормышта уңышсызга әверелә, ә кайвакыт алган белемнәре һәм осталыклары бөтенләй кулланылмый торган ситуацияләрдән котылырга ярдәм итәчәк. Математиканы укытуда компетентлы якын килү укучыларның белем дәрәҗәсен арттыруга китерә һәм белем бирүнең яңа сыйфатына ирешүне аңлата, аңа аны модернизацияләү программасын юнәлдерелә.Яңа белем бирү сыйфаты мәктәпне тәмамлаучыларның яңа мөмкинлекләреннән гыйбарәт, аларның алдагы буын чыгарылыш сыйныф укучылары хәл итмәгән проблемаларны хәл итү сәләте булуда.

**Кулланылган әдәбият исемлеге:**

1. Башарина А.В. Влияние процессов глобализации на образовательное пространство России [Электронный ресурс]. - Режим доступа:http://www.naukapro.ru/konf2008/bash.htm.

2. Бермус А. Г. Проблемы и перспективы реализации компетентностного подхода в образования [Электронный ресурс]. - Режим доступа: http://www.bestreferat.ru/referat-78164.html.

*Вәгыйзов Фәрит Яхъя улы,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы “Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүле 11нче урта гомуми белем бирү мәктәбе” муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең I категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

**Дәресләрдә туган телне өйрәтүдә мотивлаштыруның кайбер алымнары**

Яхшы укытучы һәр дәресне заманча проектлаштырып, нәтиҗәле эшләргә тиеш. Шул очракта гына без үзебезнең эшебезнең татлы җимешләрен күрербез. Ә моның өчен укытучыларга иҗади эшләргә, һәрчак югарыга омтылып, зур тырышлык куярга кирәк. Чөнки безнең төп бурыч - иҗади фикерләүче; толерант булган; югары әхлаклы һәм белемле; көндәшлеккә сәләтле укучылар үстереп күпкырлы шәхесләр тәрбияләү. Андый шәхес формалаштырыр өчен без катлаулы, сикәлтәле юл үтәбез. Балалар белән янәшә барып, аларга юнәлеш күрсәтәбез. Бу процессны уңышлы рәвештә тормышка ашыру өчен төрле укыту технологияләре кулланабыз: үстерешле укыту; коммуникатив; компьютер; шәхескә юнәлтелгән; уен һәм башка технологияләр кулланабыз.

Һәрбер укытучының дәресләр алып барганда мотивлаштыру этабында кулланыла торган кызыклы алымнары бар.Федераль дәүләт белем бирү стандартлары кысаларында дәрескә әзерләнгәндә дәрес структурасын күзаллау, төзү укытучыдан зур әзерлек таләп итә. Укучыга нәтиҗәле белем алу өчен эффектив ысуллар кулланып, уңай шартлар булдыру бар укытучының көндәлек максаты. Мотивлаштыру – ориентлаштыру этабы дәреснең иң мөһим өлешләреннән берсе. Бу этапның максаты: дәрестә укучылар белән уңай психологик халәт булдыру, укучыларны уку эшчәнлегенә җәлеп итү, кызыксыну уяту.

Әлеге этапта укучылар белән индивидуаль эш тә, парларда һәм төркемнәрдә эш тә оештырылырга мөмкин. Укытучы укучыларда алган белем һәм күнекмәләргә таянып, яңаларын кабул итәргә җирлек әзерли, махсус биремнәр тәкъдим итә, ягъни эзләү, проблемалы ситуация тудыра. Шул биремнәр нәтиҗәсендә укучы әкренләп гамәлләр башкара, нәтиҗә ясый бара. Укучыда логик фикер йөртү, танып-белү, коммуникатив күнекмәләр формалаша. Ә мотивлаштыру – ориентлаштыру этабында төрле алымнар кулланырга мөмкин .

Мин сезгә шуларның берничәсе тәкъдим итеп китәм:

1.дәресне шигъри юллар белән башлау;

2.дәрес эчтәлегенә туры килгән видео, мультфильм карау;

3.җыр тыңлау, музыкаль сәламләү;

4. мәкаль-әйтемнәр, табышмаклар әйтү һәм башкалар.

Шәхсән үзем кайбер дәресләрне башлаганда тактага тема буенча бер мәкальнең баш өлешен язып, икенче кисәген укучыларның үзләре дәвам итү мөмкинчелеген бирәм. Бик кызыклы булып дәреснең темасын башваткыч (кроссворд) чишү белән ачыклау алымы тора. Хәзер компьютерда кроссвордларны төзү программалары да, электрон такталарда аларны чишү процессында бергәләп эшләү мөмкинчелеге дә бар. Үземнең компьютерда географик атамаларга (Рәсәй һәм Татарстан шәһәрләре, елгалары, урам исемнәре), әдәби-тарихи шәхесләргә яки вакыйгаларга башланган (Герой-якташлар, язучылар һ.б.) темаларына багышланган 20 дән артык башваткыч бар.

Ә башлангыч сыйныфларда электрон тактада төрле уеннар (мәсәлән,“Нәрсә артык?”) уйнау шулай ук балаларның игътибарын җәлеп итә. Өлкән сыйныф укучыларын хат белән яки притча (мәсәл) сөйләү алымнары ярдәмендә дәресне башлап җибәргәндә кызыксындыру уята. Шулай ук билгеле бер темага укучыларга алдагы дәрестән соң өй эше итеп ребус, анаграмма яки тавтаграммалар төзеп алып килеп, аларны яңа дәрес алдыннан уртаклап чишү-тикшерү уңай халәт тудыра. Кече сыйныфларда дәресләрне төркемнәргә бүленеп уен формасында үткәрү укучыларны тапкырлыкта һәм зирәклектә ярыштырып, туган теллләрен өйрәнүгә уңай караш тәрбияләүгә ярдәм итә.

Дәрес уздыру вакытында укытучы бик күп максатлар куя: телдән һәм язма бәйләнешле сөйләм күнекмәләрен камлләштерү, күңел байлыгын үстерү, белемнәрне гомумиләштереп кабатлау, туган телнең матурлыгын тоярга өйрәтү; лексика бүлеге буенча күнекмәләрне ныгыту, сөйләм телен үстерү; туган тел турында белемнәрен тирәнәйтү, телгә мәхәббәт , тәрбияләү. Иң татлы тел-туган тел, анаң сөйләп торган тел,”-ди халык. Менә шушы туган телнең серләренә, матурлыгына, байлыгына төшенү өчен, иң беренче чиратта укучы балаларда татар теле белән кызыксыну теләге тудыру кирәк. Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә туган телне өйрәтүдә мотивлаштыруның актив алымнарын куллану безгә бу мәсьәләне чишүдә зур ярдәм булып тора.

Кушымта

**<u>«Буыннардан буыннарга күчә батырлык бәйгесе…”</u>**

(Ватан батырлары көненә багышланган дәрес планы)

Тема: “Батырлык дәресе”

Максат: Укучыларның бәйләнешле сөйләм телен,эзлекле фикерләү сәләтен үстерү; сугыш ветераннарына карата хөрмәт,ихтирам хисләре уяту, патриотик тәрбия бирү.

Җиһазлау: Сыйныфта китап күргәзмәсе, М.Җәлилнең 115 еллыгына багышланган музей экспозициясе, стенгазета материаллары...

Дәрес барышы.I.Уңай психологик халәт тудыру.

Укытучы. Хәерле көн,укучылар! Балалар, бүгенге татар теле дәресе гади генә дәрес түгел. Сезгә бүген тырышып эшләргә, ни дәрәҗәдә белемле икәнлегегезне күрсәтергә кирәк булачак. Бүген нинди бәйрәм?(Россия геройлары көне). Сез бу бәйрәм турында нәрсә беләсез?: А.Конюхова, В.Улыбин, В. Лисов. (3 орден-3 җөмлә)

Әйдәгез, хәзер берничә мәкаль белән танышып узыйк әле. / Алдан тактага язылган: Ир - яуда, батыр – мәйданда сыналыр, Батырлыкта – матурлык, Батыр ярасыз булмый./Бу мәкальләр нәрсә турында? Аларны нәрсә берләштерә? .... Бәлкем, сезгә кроссворд ярдәм итәр?.. Такта әйләндерелә, тиз җаваплар табу конкурсы.

Димәк, безнең дәресебезнең темасы ничек дип аталачак? (Батырлык) Белемнәре актуальләштерү. Нәрсә соң ул батырлык? Әйдәгез, шигъри юллар белән танышып китик әле:

1-нче укучы:

Беләм, егет, синең җырында
Күп иленә сөю, якынлык.
Тик әйт: авыр сугыш елында
Син күрсәттең нинди батырлык?

2 нче укучы: Бу шигырьнең ничек дип атала һәм аның авторы кем? ( “Батырлык турында”, 1943 ел, М.Җәлил, )Бу шигъри юлларда нәрсә һәм кемнәр турында сүз бара? Әйдәгез, бераз уйлыйк әле – кемнәр соң ул батырлар ?/Укучылар белән әңгәмә: батыр – сабантуйда көрәштә җиңүче, батыр – сугыш һәм хезмәт герое/...

1 нче укучы: Күгебез аяз, көннәребез имин булса, җирдә икмәк тә игелә, җаннарыбыз тыныч, табыннарыбыз да мул була. Ә безнең иминлигебезне саклап, Ватаныбыз сагында кыю йөрәкле, лачындай ир-атларыбыз тора. Узган ел без Бөек Җиңүнең 75 еллыгын билгеләп уздык. Халкыбызның батырлыгын һәм нык рухлылыгын сугыш елларында 10 меңнән артык кеше Советлар Союзы Герое исеменә лаек булу факты раслый. Шулар арасында – 300 артык Татарстан вәкиле. Барыбызга да герой- шагыйрь Муса Җәлил исеме таныш. Дошманга каршы ул утлы корал белән генә түгел, ә шигырьләре белән дә көрәшә.

2 нче укучы: Әйдәгез, аның иҗатында аеруча зур урын алып торган “Моабит дәфтәрләре” китабыннан өзекләр белән танышып узыйк әле: /М. Җәлилнең “Батырлык турында”, “Чулпанга”, “Кызыл ромашка” шигырьләреннән өзекләр уку/.

Укучыларга сораулар: М.Җәлилнең туган көне кайчан? Туган төбәге? Кызының исеме? Ничек һәлак була?

Укытучы: -Тагы кемнәрне кем герой-җәлилчеләр дип йөртәләр? /Абдулла Алиш, Рәхим Саттар, Әхмәт Симаев, Гайнан Курмашев, Фоат Сәйфелмөлеков, Гариф Шабаев, Зиннәт Хәсәнов, Абдулла Батталов, Сәлим Бухаров, Әхәт Әтнәшев һәм Фуат Булатов./2. Кайсы шәһәрләрдә аларга һәйкәлләр бар? Мәскәү, Санкт-Петербург, Казан, Түбән Кама)

1-укучы: Миллионнарча корбаннар таләп иткән Бөек Ватан сугышында бүгенге Түбән Кама районына керә торган авыллардан 20 меңнән артык кеше катнаша, аларның күбесе сугыш кырларында һәлак була. Прости авылыннан Никита Кайманов, Елантау авылыннан орудие командиры Григорий Абызов, Иске Чишмә поселогыннан укчы сержант Иван Болодурин Һәм Буденновецтан разведчик Дмитрий Приваловлар Ватанның иң зур бүләге – Советлар Союзы Герое исеменә лаек булалар.

2-укучы:. Шулай ук безнең районнан тагы батыр 3 ир-ат бу югары исемгә тәкъдим ителәләр, ләкин теге-яки бу сәбәпләр аркасында алар орден-медальләр беләгн генә бүләкләнеп калалар. Тубән Кама шәһәре урамнарының берсе тагы бер герой - Дан орденының тулы кавалеры Рифкат Гайнуллин исемен йөртә.

1-укучы: Бүген бездә кунакта – запастагы майор, 20 дән артык орден һәм медальләр кавалеры, 29 ел армиядә хезмәт иткән Николай Гаврилович Журавлев: -Николай Гаврилович, сүзне Сезгә бирәбез – Сез ничәнче елны армия сафларына чакырылдыгыз? Кайда хезмәт иттегез, нинди сугышчан бүләкләрегез бар? Укучыларга нинди теләкләрегез бар?

2 укучы:. Безнең икенче кунагыбыз – Ленинград блокадасында булган, авыр сугыш елларыннан соң хәрби заводларда эшләгән, илле елдан артык хезмәт стажы булган Рукия Гатият кызы Сәхәбетдинов**а**. Укучыларның сезгә сораулары күп булыр дип уйлыйбыз... (Сез ничек блокадага эләктегез? Сугыштан соң кайда эшләдегез? Нинди бүләкләрегез бар? Сезнең теләкләр?)

Укытучы: Кадерле ветераннарга сугыш елы истәлекләре өчен зур рәхмәт. Димәк, “Батырлыкка һәрчак урын бар”. Гади хезмәт кешеләре дә зур тырышлык куеп, фидакарь эшчәнлекләре белән тыныч тормышта да батыр була алалалар. Түбән Кама җирендә яшәгән 4 кеше Социалистик Хезмәт Герое исеменә лаек булган. Алар Түбән Кама экономикасының төрле тармакларында фидакарь хезмәт куйганнар. ( Евгений Королев- төзелеш башлыгы – начальник “Татэнергостроя”, Николай Лемаев- директор “Нижнекамскнефтехим”, Клавдия Малышева – птицевод фабрики Кр.Ключ, Ганҗә Әхмәдиева –төзүче-маляр).

Бу геройларга “Җәлил” кинотеатры, техник колледж янында бюстлар урнаштырылган. Йомгаклау(рефлексия).Укучылар, әйдәгез тагы бер кат кем соң ул батырлар сорауына җавап бирегез. Сезнең фикерләрегез үзгәрмәдеме?

Җавап вариантлары: /-Патриотлар, кыю кешеләр, үз илен яратучылар, Ватанына тугры хезмәт итүчеләр,туган җире абруен яклаучылар.../ Чын батыр ул – Ватанын, Туган илен яратучы кеше. Батырлыкка бүгендә урын бар!

Өй эше бирү: 1.(батырлык турында мәкальләр язып килергә – “4” билгесенә, шушы темага иҗади язма эш “5”-гә бәяләнәчәк )2. Интернет материаллары нигезендә Советлар Союзы Геройларнына багышланган презентация әзерләргә /Дәрес азагында укучылар үзләре өйдә ясап килгән рәсемнәренә үзбәя бирсәләр булса- Георгий кавалеры, Алтын Йолдыз һәм Ватан Герое медальләренең рәсемнәре/.

*Вәлиева Рузалия Сәед кызы,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Муса Җәлил исемендәге “1 нче гимназия” муниципаль бюджет белем бирү учреждениесенең беренче категорияле математика укытучысы*

## Математика укытучысы уйланулары

«Балаларыгызны үзегез яшәгән заманга һәм башка
заман өчен дә яраклы итеп укытыгыз»
Ризаэддин Фәхреддин

Кеше дөньяга бәхетле булу өчен килә. Мәктәптә белем алырга өйрәнгән бала алдагы тормышында да югалып калмый, бәхетле була белә. Математика, физика дәресләрен алып баручы укытучылар икеләтә җаваплылык тоеп эш итәргә тиешләр. Көнкүреш техникасы, элемтә чаралары бик нык алга киткән, зур тизлектә үзгәреп торган XXI гасырда яшәргә сәләтле шәхес тәрбияләүдә аларның роле бигрәк тә зур.

Бөек ачышлар ясаган шәхесләрнең күпчелеге төгәл фәннәрне яхшы белгән. Рәссам, архитектор, галим, инженер Леонардо да Винчи, полководец Суворов, галим һәм шагыйрь Ломоносов – шундыйлардан. Үзебезнең татарлар арасында да андыйлар җитәрлек. Татарстаныбызның элеккеге һәм хәзерге президентлары инженер һөнәренә ия кешеләр икәнлеген искәртеп китү дә җитә торгандыр дип беләм. Аларның зирәк акыллы, оештыру сәләтенә ия булулары аркасында республикабызда яшәүче күпмилләтле халык үзара дус-тату яши. Мәгариф өлкәсендә дә уңышлар зур. «Иннополис» кебек белем бирү үзәкләре ачылу республикада төгәл фәннәргә игътибарның зур булуын тагын бер тапкыр раслый.

Белем һәм тәрбия алу процессы кеше тормышында әһәмиятле урын алып тора. Ләкин аның нәтиҗәләре еллар узгач кына күренергә мөмкин. Элеккеге укучыларының

тормыш юлындагы уңышлары һәм ялгышлары өчен һәр укытучы гомере буе «имтихан» тота. Әнә, узган уку елында мәктәпне тәмамлап киткән, инженер һөнәрен сайлаучы укучым югары уку йортының I курсын гел «5»ле билгеләренә генә тәмамлавы уңаеннан шатлыгы белән уртаклаша. Димәк, мин ялгышмаганмын. Фәнни эш белән дә шөгыльләнә башлаган икән инде. Моннан кырык ел элек бала өчен укытучының һәр сүзе яңалык булса, бүген хөрмәт, ышаныч казану өчен укытучы көн-төн укырга, белемен арттырырга мәҗбүр.

Укытучы профессиясен мәңгелек профессия дип атыйлар. Укытучы – иң катлаулы процесс , ул шәхес формалаштыру процессы белән идарә итә. Бу процессның катлаулылыгы тәрбияләнүче шәхеснең даими үзгәреп торуы һәм аңа күп санлы һәм күптөрле факторның тәэсир итуе билгеләнә. Укытучының төп эше – укыту һәм тәрбия процессында барлыкка килә торган мөнәсәббәтләр белән идарә итү.

Безнең укучыларыбыз, алар безнең киләчәгебез. Шуңа күрә һәр укытучы укучыга шәхес итеп карарга тиеш. Ул укучының үз-үзенә ышаныч тудыра, кылган эш гамәлләренә, үзенең мөмкинлегенә һәм сәләтенә бәя бирергә өйрәтә.

Укытучы укытуның сыйфаты , укучыларның белем һәм тәрбия дәрәҗәсе өчен җавап бирә. Укутуның сыйфатын яхшырту өстендә эшләү укытучы өчен иң төп бурыч. Шуларны күздә тотып , без укытучылар , һәрдаим үз өстебездә эшләргә тырышабыз.

Мин “Математика укытуда укучыларның мөстәкыйльлелеген үстерү” дигән методик тема өстендә эшлим. Дәресләрне шушы методик темага туры килерлек итеп үткәрергә тырышам.

Математика укытучысы белем һәм тәрбия бирү процессында төрле алымнарны кулланып , дәресләрне фәнне укытуда укучыларда кызыксыну уята алырлык итеп үткәрә алырга тиеш. Шул максатларны күздә тотып мин җанлы һәм кызыклы итеп үткәрү өстендә эшлим , дәресләрдә укучыларга индивидуаль якын килергә тырышам.

Дәресләрдә мөстәкыйль эшләр үткәрүнең роле искиткеч зур, чөнки ул эшләр укучыларның логик фикерләү сәләтләрен үстерә, акыл эшчәнлеген активлаштыра, дикъкат тәрбияли, өйрәнелә торган материалның тирәнрәк һәм ныграк үзләштерелүенә булыша, белем дәрәҗәсен күрсәтә. Шуларны истә тотып һәр дәрестә индивидуаль биремнәрдән торган карточкалар ясарга тырышам.

Укучыларда мөстәкыйльлелекне дәреснең барлык этапларында да тәрбияләргә була . Белемнәрне актуальләштерү этабында математика дәресләрендә зирәклеккә мәсьәләләр, башваткычлар, математик кроссворд, арифметик табышмаклар, арифметик диктантлар, бер яктан укучыларның логик фикерләү сәләтен үстерсә , икенче яктан фәнгә мәхәббәт , кызыксыну уята. Өйрәнелгән материалны актуальләштерү максатыннан мөстәкыйль

эшләр куллану да уңай нәтиҗә бирә.Әгәр укытучы үз укучыларының мөмкинлекләрен дөрес билгеләсә , теге яки бу эшне ничек башкарачагын алдан белсә, мөстәкыйль эшләрен яңа белем бирү этабында да кулланырга мөмкин. Чөнки каршылыклар аша үтеп, эзләнеп үзләштерелгән материал әзер килеш тәкъдим ителгән материалга караганда ныграк үзләштерелә. Мөстәкыйль эшләү вакытында һәр укучы үзләштереләчәк материал белән очраша, үзенең игътибарын шуңа юнәлтә.Белемнәрне ныгыту вакытында тестлар, индивидуаль карточкалар, төрле дәрәҗәдәге карточкалар, карточка-белешмәләр белән эшләү уңайлы.

Мөстәкыйль эшләр үз белеменә таянып эшләргә, вакытны сарыф итмәскә, һәр укучыга индивидуаль якын килергә булыша.

Күнегүләрнең куптөрлелеге, укучыларның мөстәкыйль эшли алу дәрәҗәсенең артуы һәм аңлылыгының үсүе, укучыларның һәрбер яңа очракта гомумиләштерүне куллана белергә өйрәтә һәм күнектерә. Барлык укучыларның да аң дәрәҗәсе бер төрле булмый . Шуның өчен мөстәкыйльлек тәрбияләүкүнегүләрнең катлаулана баруы күләме буенча да төрле булуы әйбәт. Бу вакыттаһәр укучыга үз фикерен әйтергә мөмкинлек тудырыла. Яңа материалны өйрәнгәндә кайбер укучыларга тиз үзләштерә , ә кайбер укучылар авырдан үзләштерергә мөмкин. Мондый очракта төрле дәрәҗәдәге биремнәр куллану уңай нәтиҗә бирә.

Һәр яңа теманы өйрәнгәннән соң һәр укучыга индивидуаль карточкалар ярдәмендә мөстәкыйль эш алырга тырышам. Ә гадәти үткәрелә торган мөстәкыйль эшне 2 вариантта тәкъдим итәм.

Төрле дәрәҗәдәге карточкалар белән эшләгәндә төсле кәгазьләр кулланып, өч төрле дәрәҗәдәге( Җиңел, уртача, авыр) карточкалар ясыйм. Бу карточкаларны укучыларның үзләренә сайлап алу мөмкинлеге бирәм. Кем нинди дәрәҗәдәгене эшли алам дип уйлый, шундыйны сайлап ала. Билгене дә карточкаларның авырлыгына карап куям. Шунысы уңай, һәр укучының белем дәрәҗәсе күренә.

Укучылар яңа теманы бер дәрәҗәдә үзләштермиләр. Укучыларның әзерлек дәрәҗәсен һәм шәхси үзенчәлекләрен искә алып , авыр кайбер дәресләрдә карточка-белешмәләр кулланам. Мөстәкыйль эшләр вакытында кайбер укучыларның алдында тора. Бу карточкаларны өйдә дәрес хәзерләү өчен укучыларның өйләренә дә биреп кайтарырга мөмкин. Дәрес калдырган укучыга иптәшләрен куып җитәргә ярдәм итә. Бу карточка-белешмәләрнең берничә төрен булдырдым.. Шулар ярдәмендә укучы кечкенә генә булса дә җиңү шатлыгы татый.

Төрле темалар буенча эшләгән берничә төрле карточканыкарап китик. Карточкалар исеменнән күренгәнчә темага кыскача аңлатуны , шул тема буенча кирәкле формуларны һәм биремнәрне эченә ала.

Авыр үзләштерү укучылар өчен эшләнгән карточкаларның берничә төре.

**Квадрат тигезләмәләр чишү.**

$ax^2 + bx + c = 0$ (a,b,c- нindidер саннар, $a \neq 0$, ә x үзгәрешле) рәвешендәге һәр тигезләмә квадрат тигезләмә дип атала.

1. *$ax^2 + bx + c = 0$ квадрат тигезләмәсенең тамырын* $x = \frac{-b \pm \sqrt{D}}{2a}$ *, биредә* $D = b^2 - 4ac$ *формуласы буенча табарга мөмкин.*

Искәрмә: Гадәттә b җөп сан булганда, $\frac{b}{2}$ бөтен сан булганда $x = \frac{-\frac{b}{2} \pm \sqrt{\frac{D}{4}}}{a}$ формуласы кулланыла.

2. *Дискриминантны исәплибез* $D = b^2 - 4ac$.

*Искәрмә:* Дискриминант тамгасына карап, өч очрак тикшерелә:

D<0 булса, тигезләмәнең тамыры булмый;

D=0 булса, тигезләмәнең бер тамыры;

D>0 булса, тигезләмәнең ике тамыры бар.

3.*Үрнәк өчен:*

$12x^2+7x+1=0$

a=12, b=7,c=1

Дискриминантны табыйк: $D = b^2 - 4ac = 7^2 - 4\ 12\ 1 = 1$

D>0 тигезләмәнең тамыры ике.

$x_{1,2} = \frac{-7 \pm \sqrt{D}}{24}$ . $x_1 = -\frac{1}{3}$; $x_2 = -\frac{1}{4}$.

4. *Тигезләмәне чишегез*:

1) $3x^2-14x+16=0$

2) $5x^2-6x+1=0$

3) $x^2+2x+80=0$

4) $8x^2-4x+0,5=0$

5) $4x^2+x-3=0$

**Бер үзгәрешле сызыкча тигезсезлекләр чишү.**

**ax+b>0** яки **ax+b<0** рәвешендәге тигезсезлекләр **сызыкчы тигезсезлекләр** дип атала.

1. Җәяләр булса, җәяләрне ачачрга.

2. Тигезсезлекнең берягына үзгәрешле кергән, ә икенче ягына узгәрешле кермәгәнкушылучыларны җыярга.

*Искәрмә:* Кушылучыларны тигезсезлекнең бер ягыннан икенче ягына күчергәндә тамга капма – каршыга алышына.

3. Охшаш буыннарны берләштерегә.

4. Тигезсезлекнең ике кисәгендә үзгәрешле алдында торган коэффициентка бүләбез.

*Искәрмә:* Тигезсезлекнең ике кисәгендә уңай санга бүлсәк, тигезсезлек тамгасы саклана. Тигезсезлекнең ике кисәген дә тискәре санга бүлсәк , тигезсезлек тамгасы капма-каршыга алышына.

5. Чишелешләр күплеген санлы турыда күрсәтергә.

6. Җавапны язарга.

*Үрнәк өчен:*

$$2\cdot(x+3)-3\cdot(4-2x)>10x$$
$$2x+6-12+6x>10x$$
$$2x+6x-10x>-6+12$$

Җавап : (-∞; 3)

$$-2x>6$$
$$x<-3$$

*Тигезсезлекләрне чишәргә:*

1. 4(x+1)<5(x-3)+14
2. 7(a-2)+22<a-4
3. $y(y-4)-y^2>12-6y$
4. 4(a+8)-7(a-1)<12
5. 2x-5< 8(x+4)-7
6. 5(x-1)+7 ≤ 1-3(x+2)
7. 8(x-7)+2 ≤ 6(x+3)-5
8. -4(x+5)+12>

9 $a^2$- a(a-5)> 2a-10

**Тигезләмәләр чишү.**

*Тигезләмә чишүнең гомуми схемасы:*

1. Мөмкин кадәр тигезләмәне гадиләштерәбез, җәяләрне ачабыз, охшаш буыннарны берләштерәбез.

2. Билгесез кушылучыларны, тамгаларын капма-каршыга үзгәртеп, тигезләмәнең бер кисәгенә , әкалган кушылучыларны тигезләмәнең икенче кисәгенә күчерәбез.

3. Охшаш кушылучыларны берләштерәбез.

4. Тигезләмәнең тамырын табабыз.

5. Дөреслеген тикшерәбез.

*Тигезләмәне чишү үрнәге:*

3(x+3)=5-2x тигезләмәсен чишик

3x+9=5-2x (җәяләрне ачтык)

3x+2x=5-9 ( тамгаларны үзгәртеп,-2x кушылучысын уң кисәктән сул кисәккә, ә 9 кушылучысын сул кисәктән уң кисәккә күчердек)

5x=-4 ( охшаш кушылучыларны берләштердек)

x=-4 : 8

x=-0,8 ( билгесез тапкырлаучыны таптык.)

*Дөреслеген тикшерү:*

Сул кисәге: 3(-0,8+3)=3· 2,2=6,6

Уң кисәге: 5—2(-0,8)=5+1,6=6,6

Тигезләмә дөрес чишелгән.

*Тигезләмәләрне чишәргә:*

1. 3(2x-1)+7=5(x-1)+7

2. 0,8(0,5-2y)=2y+0,4

3. –2(x+5)+3=2-3(x+1)

4.0,6(x-3)-0,5(x+4)=-1,8

5. O,2(4-3y)-0,5(3y-5)=2,5-11y

6. –3(2x+1)=-33-3x

7. –5(3a+1)-11=-16

8.14,48-4,3x=14,9-5,7x

9.5(x-3)-12= 6(x-9)

Авыр үзләштерү укучылар белән эшләү өчен мин тагы шундый типтагы карточкалар белән дә кулланам.

Укучыларга бирем язылган карточка өләшәм һәм аларга эшләр өчен вакыт бирәм, ә бераздан биремнәр эшләнгән карточка таратам һәм укучылар дөреслеген шулкарточкалар ярдәмендә үзләре тикшерәләр. Бу карточкалар тигезләмәләр темасын үткәндә барлык

укучылар белән эшләргә дә уңайлы. Һәр укучыга индивидуаль якын килергә дә мөмкин . Шулай ук тиз үзләштергән укучы шул билетлар ярдәмендә авырырак биремнәр дә эшли ала.

**Билет №1 (бирем карточкасы).**

1. 0,4(y+5)-0,3(y-2)=3
2. 0,6(3-4y)-0,9(y-1)=1,9-2,3y
3. 3,7(x-2,5)=-186,85
4. 4(x-3)-16=5(x-5)
5. 2(3,6x-1,6)=3,2x

**Билет №1 ( Җавап карточкасы) .**

1) 0,4(y+5-0,3(y-2)=3

0,4y+2-0,3y+0,6=3

0,4y-0,3=3-0,6-2

0,1y=0,4

y=0,4:0,1

y=4

2) 0,6(3-4y)-0,9(y-1)=1,9-2,3y

1,8-2,4y-0,9y-0,9=1,9-2,3y

-2,4y-0,9y+2,3y=1,9-0,9-1,8

-1y=-0,8

y=-0,8: (-1)

y=0,8

3) 37(x-25)=-186,85

37x-9,25=-186,85

37x=-186,85+9,25

37x=-177,60

x=-177,60:37

x=-48

4) 4(x-3)-16=15(x-5)

4x-12-16=5x-25

4x-5x=-25+16+12

-x=3

x=3: (-1)

x=-3

5) 2(3,6x-1,6)=3,2x

7,2x-3,2x=3,2

4x=3,2

x=3,2: 4

x=0,8

Тригонометрия темасын үткәндә бик күп формуларар үтелә, һәм шуларны укучылардан белү сорала. Ләкин бу формулаларны, почмакның кыйммәтләрен белсәләр дә, укучылар мисаллар эшләгәндә онытып җибәрәләр. Мин шуларны истә тотып белешмә карточкалар ясадым. Аларны целофан белән тышлап , мөстәкыйль эшләрне эшләргә урын калдырам , шулай эшләгәндә, укучылар шул карточкадагы буш урынга эшләп бирәләр, тикшергәч, сөртеп алырга уңайлы була.

| Карточка № 2 |
|---|

***Тригонометрик формуалар*.**

Cos 2a = $\cos^2 a - \sin^2 a$ (1)

Sin 2a = 2 sin a cos a (2)

Cos 2a =2 $\cos^2 a$ –1 (3)

Cos 2a =1- 2$\sin^2 a$ (4)

(3) тән $\cos^2 a = \frac{1+\cos 2a}{2}$ (5)

(4) тән $\sin^2 a = \frac{1-\cos 2a}{2}$ (6)

$$tg\,2a = \frac{2tga}{1-tg^2 a} \quad (7)$$

*Үрнәк:*

$$\frac{2tg15^\circ}{1-tg^2 15^\circ} = tg\,2\cdot 15^\circ = tg30^\circ = \frac{\sqrt{3}}{2}$$

1-2 $\sin^2$+cos 2a= cos 2a + cos 2a = 2 cos 2a

$$2\cdot\sin 30^\circ\cdot\cos 30^\circ = \sin 2\cdot 30^\circ = \sin 60^\circ = \frac{\sqrt{3}}{2}$$

*Мөстәкыйль эш:*

$$\frac{2tg30^\circ}{1-tg^2 30^\circ} =$$


2 $\cos^2$ a - 1+ 2 cos 2a=

$$\cos^2 45^\circ - \sin^2 45^\circ =$$


Геометрия дәресләрендә дә күбрәк карточкалар эшләү уңайлы. Чөнки бу фән укучыларга югары класска барган саен авырдан үзләштерелә . Мин аывр үзләштерүче укучылар өчен түбәндәге рәвештәге карточкалар ясыйм. Карточкалардагы сызымнар ярдәмендә укучылар мәсьәләләр чишәргә дә, фигуралар белән дә эшләргә өйрәнәләр. Һәр тема саен һәр теореманы куллана алуларына ирешү өчен дә мондый карточкалар уңайлы диа саныйм.

***Параллелограмм темасы буенча билет №1.***

Периметры 24 см га тигез булган ABCD параллелограммның якларын табарга:



AB-AD=3см AB:DC=1:2 MC-MB=3см




Информатика фәне математика , физика фәне белән тыгыз элемтәдә тора. Информатикадан да һәр темана үткәч, мөстәкыйль эш эшләр өчен билетлар эшлим. Монда күбрәк төрле дәрәҗәдәге (авыр, уртача, җиңел) билетлар төзим.

***I дәрәҗәдәге билетлар.***

1. Бер үлчәмле массивның һәр элементын ике тапкыр зурайтырга.

2. Ике үлчәмле массивның суммасын табарга.

3. Бер үлчәмле массивта 100 дән зур элементларны чыгарырга.

***II дәрәҗәдәге билетлар***

1.Ике үлчәмле массивның иң кечкенә һәм иң зур элементын табарга.

2. Квадрат матрицаның төп диагональ элементларын квадратка күтәреп, суммасын табарга.

3. Ике үлчәмле массивта ничә тискәре, ничә уңай, ничә нольгә тигез сан бар икәнен санарга.

***III дәрәҗәдәге мисаллар.***

1. Ике үлчәмле массивта беренче юлны ахыргы юл белән, икенче юлны ахырдан икенче юл белән һәм шулай дәвам итеп ...... алыштырырга.

2. Ике үлчәмле массивта юл элементларын багана элементлары итәргә.

3. Ике үлчәмле массивта һәр багананың суммасын табып, сумманы бер үлчәмле массив рәвешендә чыгарырга.

Сәләтле укучылар белән дә өстәмә эш алып барырга тырышым . Программадан тыш модудульле , параметрлы тигезләмәләр, тигезсезлекләр чишүгә игътибар итәм. Мондый укучыларга аерым эшкәртмәләр төзеп, шуларны файдаланам. 9 нчы класста

тиргонометрия темасы үтелмәгәч,программага модудульле, параметрлы тигезләмәләр, тигезсезлекләрне керттем. Алар өчен төзелгән аерым билетларым бар.

Билет №1

Тигезләмәне чишәргә һәм x=0, x>0,x<0 булганда параметрның кыйммәтен табарга.

1. $(a+4)x=a^2+6a+8$

2. $a^2x+30x-a^2=4a-11ax$

3. $\frac{x}{a-2}=\frac{1}{a+2}+\frac{3(x+1)}{a^2-4}$

4. $\frac{a}{(a+2)x}-\frac{2}{x^2-1}=\frac{3x^2+2}{(x^3-x)(a+2)}$

**Билет № 2**

Тигезләмәләрне чишәргә :

1. $\left|(x+1)|x|-x\right|=1$

2. $\sqrt{x^2-6x+9}+\sqrt{25+10x+x^2}=8$

3. $\left||x+1|-|x-3|\right|=|x|$

4 $\sqrt{x^2+2\sqrt{x^2-1}}-\sqrt{x^2-2\sqrt{x^2}-1}=1$

5. $0{,}5^{\left|\frac{x-1}{x-3}\right|}=0{,}25$

Сәләтле укучылар белән олимпиада мәсьәләләре эшлибез. Аерым өстәмә әдәбияттан файдаланабыз. Бигрәк тә С.Л.Евсюкның “ Решение задач повышенной сложности “ , “1 сентября” газетасының математика кушымтасы, математика в школе журналы, олимпиада мәсьәләләре җыентыгы, техникум һәм училищелар өчен информатика китабы, бердәм дәүләт имтиханы өчен тест китаплары белән эшлибез.

Шулай ук 11 нче класс укучыларым математикадан төрле ВУЗларның читтән торып һәм көндезге әзерлек курсларына язылалар. Без бергәләп шул әзерлек курсларының мисал- мәсьәләләрне эшлибез.

Дәрестә системалы мөстәкыйль эш эшләү һәр укучының белем дәрәҗәсен белү өчен уңайлы. Дәрестә инливидуаль якын килү алымы – укучыларның сәләтен истә тотып белем бирүнең нәтиҗәле шарты. Бу алымнарны тормышка ашырганда, кыенлыклар да очрый. Беренчедән, укучыларның белем дәрәҗәсенә диагностика ясарга, икенчедән, дәрестә төрле төркемдәге ( белем дәрәҗәсе буенча) балаларның эшчәнлегенә җитәкчелек итәргә, өченчедән, укытучыга эзләнү - күпсанлы дидиктик материал әзерләргә кирәк.

Укыту процессында укучыларның белем һәм күнекмәләрен тикшерү- укытучы эшчәнлегенең мөһим этабы. Укытучы укучының тема буенча нәрсәне үзләштергәнен яисә нәрсәне үзләштермәгәнен, нинди хаталар җибәргәнен ачыкларга тиеш. Болар барысы да укучыларның белемендәге җитешсезлекләрне бетерү юнәлешендә эзлекле эш алып бару өчен кирәк.

*Галимова Гөлфинә Сәлихҗан кызы,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Муса Җәлил исемендәге “1 нче гимназия” муниципаль бюджет белем учреждениесенең беренче категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

**Башлангыч сыйныфларда туган тел дәресендә уен технологиясен куллану**

Хәзерге заман укытучыларыннан укучыны укырга-язарга өйрәтү генә таләп ителми,ә заман таләпләренә туры килә торган белем биреп, шәхесне җәмгыятьтәге төрле үзгәрешләргә, тормыш ситуацияләренә, фән нигезләрен ныклы үзләштерүгә әзерләүне күздә тота. Укучының иҗади мөмкинлекләрен тулырак ачу, алган белемнәрен тирәнәйтү, аралашу вакытында үзара ярдәмләшү мохите тудыру инициативасын үстерә. Башлангыч сыйныфлардан укучыларда туган тел фәненә кызыксыну уяту,шәхеснең танып белү активлыгын арттыру, тел өйрәнү өчен уңайлы шартлар булдыру заманча технологияләрне файдалануга мөһим бурыч булып санала. Педагогик технологияләрнең берсе булган уен технологиясе укучының эшчәнлеген активлаштыру һәм интенсивлаштыруга нигезләнгән. Башлангыч сыйныфта уку процессын активлаштыруга корылган уен технологиясе түбәндәге очракларда кулланыла:

-төшенчәләрне,темаларны, дәреслекнең кайбер бүлекләрен мөстәкыйль үзләштергәндә;

-дәрес структурасының кайбер элементлары буларак(кереш өлеше,аңлату, ныгыту, актуальләштерү);

-сыйныфтан тыш эшчәнлек технологиясе итеп.

Укучыларның яшь үзенчәлекләренә карап, уенга укытучы дәрес темасына туры килерлек төрле мавыктыргыч биремнәр, гамәлләр кертә. Кайбер укучылар өчен туган тел дәресләрен үзләштергәндә авырлыклар килеп чыгарга һәм дәрес материалы үзләштерелмичә калырга мөмкин. Бу уңайдан төрле ребуслар, кроссвордлар чишү, табышмакларның җавапларын табу, сүзләрнең мәгънәви билгеләрен күрсәтү укучыларның логик фикерләвен, гаделлек,күмәклекне тәрбияли, зирәклекне, тапкырлыкны, җитезлекне булдыра. Сүзләр уены укучыларның сүз байлыгын арттыра, кирәкле төшенчәләрне тиз табарга этәрә, пассив сүзләр куллануны активлаштыра.

Мондый уеннарны башкарганда, укучыларга билгеле бер вакыт биреп оештыру отышлы була, уенга ярыш мотивын кертә һәм дәрескә кызыксыну уята. Туган тел дәресләрендә укучыларның күзаллавын һәм иҗадилыгын үстергәндә рәсем буенча төрле хикәяләр төзү, дидактик формадагы биремнәр, уенның нәтиҗәсе буларак, уңышлы булып санала.

Туган тел дәресләрендә кулланылган кайбер дидактик уеннарына мисаллар:

**“Рәсем буенча хикәя”.** Укучыларга берничә рәсем биреп хикәя төзергә. Биремне катлауландыруга юнәлткәндә,төрле темага караган рәсемнәр бирергә мөмкин.

**“Тел шомарткыч”:** тизәйткечләр укырга өйрәнү.Укучыларга сүздәге авазларның дөрес әйтелешен истә калдыру өчен тизәйткечләр булыша. Башта аларны әкрен һәм кычкырып , аннан тиз һәм тыныч кына укып өйрәнергә мөмкин. Тизәйткеч укучы сөйләмендәге авазларны дөрес һәм ачык, төгәл әйтергә өйрәтә, сөйләм тизлеген яхшырта.

**“Сүзләрдән сүзтезмә яса” :** ике сүз бирелә, шулардан сүзтезмә ясарга.

Җәй, яңгыр;

Тәртип, бала;

Мәктәп, бару;

Ашыга, кайту.

**“Хәрефләрен алыштыр”** Бирелгән сүзләрнең бер сузык хәрефен алыштырып, яңа сүз ясарга.

Кыр - ...../кер жыр -...../җир

Бал - ..../бил чор - ...../чир

Тал - ..../тел саз - ...../сүз

**“Иҗекләрдән- сүз”** Бирелгән иҗекләрдән сүзләр төзе: *кар-,чи-, ак-,ба-,кур-, бал-.*

**“Мәкальләрне җый”.** Бирелгән сүзләрдән мәкаль җыярга: *белемле,***беләге***, берне, юан, егар, меңне,егар.*

*Агач, эше белән, җимеше белән, кеше, матур.*

**“Анаграммалар уйлап тап”.** Анаграмманың нәрсә икәне аңлатыла.Бер хәрефне үзгәртеп, анаграмма ясарга: *йөрәк- көрәк, тарак-карак, болын- колын, торма- тырма.* Һәм киресенчә*:ит- бит,ат- шат,ай –тай,аш – таш,итек-читек.*

**“Кем тизрәк таба?”** Җөмләдән фигыльләрне кем тизрәк таба:

Эссе һавада мин суда коенам, йөзәм, чәчрәтәм, уйныйм,башым белән суны сөзәм.

И чабам мин, и чабам, ашыгам, тирлим, пешәм һәм кып-кызу утта янам.

**“Нәрсә ничек кычкыра?”** Исемнәр бирелә, алар янына фигыльләрне язып куярга. Кайсы команда беренче?

Сыер - (мөгри) бака-

Ат - тавык -

Үрдәк - тычкан –

Кәҗә - песи –

**“Кем нәрсә эшли?”** Бирелгән исемнәргә фигыльләр табарга.

Пешекче- (пешерә) сатучы –

Төзүче - тегүче -

Сатучы- комбайнчы

Уен технологиясе укучыларның танып белү активлыгын үстерә, акыл үсешен активлаштыра, аларда яңа сыйфатлар булдыруга ярдәм итә. Уен вакытында фән белән кызыксыну көчәя, мөстәкыйльлек, ихтыяр көче, игътибарлылык арта, хәтер яхшыра, уйлау күнекмәләре камилләшә. Уен аша укытучы укыту һәм тәрбия бурычларын уңайлы хәл итеп кенә калмый, ә укучы белән аралашуны да җайга сала. Балалар коллективын берләштерүдә, туплауда, дусларча мөгамәлә урнаштыруда да уенның әһәмияте зур.

**Файдаланылган әдәбият.**


1.Хуҗиәхмәтов Ә.Н. Тәрбия дәресләре. Казан, “Матбугат йорты” нәшр., 1998

2. « Мәгариф» журналлары, №5 2004, №6 2004, №2 2006

3. Халиков Х. Сакчы күркә. Казан. “Татарстан- китап” нәшрияты, 2000



*Ганиева Рузилә Фәвәдис кызы, Фокеева Елизавета Павел кызы,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүле 31 нче гомуми урта белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе укытучылары*


## Дәресләрдә яңа педагогик технологияләр куллану

Кызганычка каршы, соңгы вакытта туган тел һәм әдәбият укытучылары үз предметларына карата укучыларның кызыксынуы кимүен күзәтәләр һәм сөйләмгә өйрәтүнең нәтиҗәлерәк юлларын эзлиләр. Балаларны татар теленә өйрәтү өчен, иң беренче чиратта, фәнне өйрәнүгә карата укучыларда уңай мотивация тудырырга кирәк. Укытучының төп бурычы – шушы мотивацияне булдыру һәм саклау, белем бирү процессында шәхескә мәдәни-әхлакый тәрбия бирү, шәхси мөмкинлекләрен үстерү чарасы буларак файдалану.

Хәзерге көндә әзер белем биреп чыгару уку процессында төп бурыч булудан туктады, укытуны традицион формада оештыру актуальлеген югалтты. Без дәресләрдә, шул исәптән туган тел дәресләрендә дә укучыларны мөстәкыйль эшләүгә, үзбелем алуга, мәгълүматларны анализлый белү күнекмәләре булдыруга, җаваплылык һәм актив

эшчәнлек тудыруга юнәлдерелгән укыту технологияләрен һәм методларын кулланырга кирәклеген ачык беләбез. Заман таләбе укытучыларга яңа мәгълүмати технологияләр белән хәбәрдар булуны, аларны гамәлдә нәтиҗәле куллана белүне сорый. Белем бирүнең нәтиҗәлелеген күтәрү укыту процессының яңа, тагын да нәтиҗәлерәк технологияләрен эзләүне, дәресләрдә куллануны таләп итә. Яңа технологияләр ярдәмендә телне өйрәнү укучыны тагын да активлаштыра, фәнне югары дәрәҗәдә үзләштерү, максатка омтылучанлык, информацион технологияләр дөньясында яңалыклар белән кызыксыну теләге уята.

Минемчә, бүгенге укыту процессында иң әһәмиятле урынны заманча технологияләрнең берсе булган компьютер технологиясе алып тора.

Шуңа да татар теле дәресләрендә укучыларны кызыксындыру, дәресне мавыктыргыч итеп үткәрү өчен компьютер куллану бик отышлыдип саныйм мин. Компьютер – укучы белән белемнәр системасы арасында арадашчы, белем алу чарасы. Компьютердан файдалану укыту эшчәнлеген баета, укыту процессын кызыклы, нәтиҗәле һәм иҗади итеп оештырырга мөмкинлек бирә. Ул сыйныф тактасын да, тарату материалын да, дәреслекләрне дә алыштыра ала, дәреснең нәтиҗәлелеген арттыруга ярдәм итә. Шулай ук бу метод укучыларны компьютер белән эшли белергә, текст процессоры ярдәмендә төрле документлар, график программалар, иллюстрацияләр әзерләргә, электрон таблицалар, гади программалар төзергә, интернеттан файдаланырга өйрәтә. Шулай ук татар теле дәресләрендә интернет - ресурсларны куллану уку, язу күнекмәләрен булдыру һәм үстерү, кирәкле материал табу, укучыларның сүзлек запасын баету, татар телен өйрәнүгә мотив формалаштыру кебек дидактик бурычларны үтәргә мөмкинлек бирә.

Интерактив такта куллану да дәресләрне мавыктыргыч, нәтиҗәле итәргә ярдәм итә. Интерактив такта белән эшләгәндә, укытучы һәрвакыт укучыларның игътибар үзәгендә, сыйныф белән элемтәдә тора. Бу алым укучыларның белем сыйфатын үстерергә, яңа материалны һәр балага җиңел, аңлаешлы итеп җиткерергә дә ярдәм итә.

Шулай ук тел дәресләрендә проектлар методын куллану отышлы дип саныйм. Проектлар методы укучы шәхесенең белем алуга иҗади якын килүенә юнәлтелгән. Укучы күзлегеннән караганда, проект ул – үзең яисә төркем белән кызыклы нәрсә дә булса эшләп карау мөмкинлеге. Мәсәлән, татар һәм рус язучылары, аларның әсәрләре, халык авыз иҗаты жанрлары, ел фасыллары турында, көндәлек режим, юлда йөрү кагыйдәләре буенча проект эшләре башкару материалны йомшак үзләштерүче укучыларда да кызыксыну тудырды, алар бу эшләрне бик теләп башкардылар.

Шул рәвешле, татар телен укытканда, заманча технологияләргә таяну укытучының да эшен җиңеләйтә, укучыларның белем дәрәҗәсен арттыруда да мөһим чара булып тора.

Укучыларның белем һәм күнекмәләрен арттыруда, аларның үз фикерләрен язмача яки сөйләмә рәвештә формалаштыра белергә өйрәтүдә, укыту һәм тәрбиянең бердәмлегенә ирешүдә, шулай ук балаларны тел фәне белән кызыксындыруда уеннарның әһәмияте зур.

Алда әйтелгәнчә, уеннар тәрбия һәм өйрәтүнең төрле мәсьәләләрен чишәргә, билгеле бер программа таләпләрен үзләштерергә, тәртип кагыйдәләренә өйрәнергә ярдәм итә. Уеннарны сайлый белү дә зур әһәмияткә ия. Интеллектуаль уеннарны сайлаганда, укытучы балаларның шәхси мөмкинлекләрен, яшь үзенчәлекләрен, уен белән ни дәрәҗәдә кызыксынуларын, балаларның уен алдындагы халәтен, кәефен истә тотып эшли. Уен вакытында туган шатлыклы кичерешләр уенны көчле тәрбия чарасына әйләндерә. Интеллектуаль уеннар ярдәмендә оялчан, үз эченә бикләнгән балаларны да "уятырга" мөмкин. Мәсәлән, кушма сүзләрне өйрәнгәндә "Сүз эчендә сүз" уенын уйнаганда бар бала да бик актив катнаша.
(Мондый уеннарга "Кызыклы сүзләр уйла" , "Кем? яки Нәрсә?", "Исемнәр уйла!" "Нинди сүз артык?", "Мәкальнең (фразеологик әйтелмәнең) ахырын тап!" һ.б.уеннар керә).

Татар телен (туган тел яки чит тел буларак) өйрәнергә теләгән балалар өчен рольле уеннар диалогик сөйләмне үстерүдә бик нәтиҗәле чара булып тора. Аеруча башлангыч сыйныфларда бу алымны актив кулланырга мөмкин. Рольле уенда парлап һәм төркем составында да катнашырга була. Төркем белән эшләгәндә, экиятләрне үзгәртеп, тулыландырып, өстәмә сораулар ярдәмендә коммуникатив максатка ирешергә мөмкин. Мәсәлән, 1 нче сыйныфта "Шалкан", "Теремкәй" әкияте мисалында лексик һәм грамматик материал ныгытыла. Әкиятне сәхнәләштерүдә катнашучы һәр бала үз исеменнән әлеге геройга характеристика биреп китә. Мәсәлән, "Шалкан" әкиятендәге шалкан үзе турында түбәндәгечә сөйләргә мөмкин: "Мин – шалкан. Мин сары, зур, тәмле". Шул рәвешчә, һәр герой үзе турында сөйләп китә. Укучылар бу уенда бик теләп катнашалар, бер-берсенә ярдәм итәләр.

Болардан тыш төрле уен элементларын кулланырга мөмкин. Бөтен дәресне ситуацияле уенга кормыйча, аның билгеле бер этабында гына да уен элементы кертеп җибәреп була. Мәсәлән, "Мин чисталык яратам", "Кибеттә", "Базарда", "Туган көнгә чакыру" , "Ашханәдә" кебек рольле уеннар бик кызыклы. Аны, гадәттә, шушы темаларга караган лексика һәм репликаларны өйрәнгәндә куллану уңай нәтиҗә бирә. Диалогик сөйләмне үстерүдә дә әһәмиятле чара булып тора. Телне авыр үзләштергән балаларда да кызыксыну уяна.

Ребуслар һәм кроссвордлар да, уен алымы буларак, дәресне җанландырып җибәрә. Моңа өстәп, укучыларның сүзлек составы арта, коммуникатив күнекмәләре, логик фикер йөртү сәләтләре үсә. Башваткычларны иҗади өй эше буларак та кулланырга мөмкин.

Шуны да әйтергә кирәк, дәресләрдә уен алымнарын куллану укучыларның белем дәрәҗәсен генә күтәреп калмый, телебезгә тирән мәхәббәт тә тәрбияли.

Алда язылганнардан нәтиҗә ясап, шуны әйтергә була: педагогика фәнендә укыту-тәрбия процессы сыйфатын үстерергә булышлык итүче технологияләр шактый. Укытучының бурычы – яңалыклар агымында югалып калмыйча, дөрес юнәлеш алу, укытучының һәр этабы өчен уку материалын аңлатуның иң уңышлы вариантын табу. Шул ук вакытта аларның бер-берсе белән ярашырга тиешлеген дә онытмау зарури.

Файдаланылган әдәбият:

1.Газизуллина Р. Мәгълүмати технологияләрдән файдаланып.// “Мәгариф” журналы / 2007, № 12.

2.Камаева Р. Б. Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә яңа педагогик алымнар. – Алабуга: АДПУ нәшрияты, 2010. – 103 б.

3.Волкова Р., Гарәфетдинова Р. Башлангыч мәктәптә татар телен чит тел буларак өйрәтүдә уен алымнарын һәм методларын куллану. – Казан: Мәгариф, 2014. – 128 б

*Гарипова Лилия Рәүф кызы,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы “Каенлы урта гомуми белем бирү мәктәбе” муниципаль бюджет урта белем бирү учреждениесенең беренче категорияле татар теле укытучысы*

**Гыйлем тарату, халыкка ярдәм бирү өчен тырышу, иң гүзәл гайрәттер**

**I Кереш**

Мәңгелектән дәшә сыман
Безгә Риза Фәхреддин:
“Яшик әдәп- әхлак белән,
Көнебез үтәр имин”.
Мәгърифәтле, азат татар илен
Күрер өчен янды, көйде ул.
Әсәрләре белән күңелләргә
Мәңгелеккә килеп керде ул.

Халкыбызның мәшһүр галиме, мөгаллим, журналист, җәмәгать эшлеклесе, мәгърифәтче Ризаэддин Фәхреддиннең тәрбия, тарих, дин гыйлемен яктырткан 148

китабы дөнья күргән.Галимнең гыйбрәтле сүзләрдән төзелгән хезмәтләре бүгенге көндә дә бик актуаль.

Мин Р. Фәхреддиннең алтын бәһасенә тиңләшерлек - “Гыйлем тарату, халыкка ярдәм бирү өчен тырышу, иң гүзәл гайрәттер”[ 1:7] фикерен ачыклап китү максатыннан уку-укыту һәм тәрбия-әхлак мәсьәләләренә багышлап язылган китапларын барлап чыктым. Алар арасында безгә, укытучыларга, иң кирәкле булып саналган “Адәбе тәгълим” (“Укыту кагыйдәләре”) хезмәтен өйрәнеп, аның өстендә тикшеренү алып бардым.

Эшемнең **максаты:**

– укыту-тәрбия бирүдә укытучыларга йөкләнә торган вазифаларны барлау; - дәрескә әзерләнүнең ундүрт кагыйдәсен исәпкә алу;

-укучының наданлыгыннан, бозыклыгыннан котылуга өйрәтү юнәлешләрен хәзерге вакытта укыту-тәрбия процессында куллану.

- хезмәтнең һәр мөгаллим өчен иң кирәкле өстәл китабы булу теләгенә ирешү.

Максаттан чыгып, эшне башкарганда түбәндәге **бурычларны** чишү өстендә эшләдем:

-галимнең китабы белән танышу;

-уку-укыту һәм тәрбия бирү ысул-алымнарын тану;

- укытучыга хас сыйфатларны табу;

- мәгърифәтченең башка дәреслек-әсбабларыннан табылган гыйбәрәләр белән фикерләрне дәлилләү.

Максатка ирешү юлында мин эзләнү, тикшерү, анализлау **алымнары** кулландым.

## II төп өлеш

1.Ризаэддин Фәхреддин Кизләү мәдрәсәсенең югары сыйныфында укыган шәкертлек елларында башлангыч сыйныф балаларын укыта башлый. Бу хәл турында ул: “Мөхтәрәм остазыбыз үзенең Габдерәүф исемле угылы илә кыз карендәшенең углын укытыр өчен миңа тапшырды...Ничек булса да, мин боларга мөгаллим булган хәлдә, һәр көнне үз- үземнән дәресне хәзерләп укыта башладым...Күп еллардан соң белдем ки, “Гыйльме тәрбия”(педагогика) иң бөек бер фән икән. Ул исә сабак укыту юлларын вә, гомумән, шәкертләр тәрбия итү кагыйдәләрен белдерә икән”, дип искә ала [2:27].

2.Ризаэддин Фәхреддин укыту барышында дөньяви фәннәргә өстенлек бирүе, укыту тәрбия эшендә яңа алымнар куллануы белән бик тиз танылып өлгерә. Шәкерт вакытында сайлаган әлеге һөнәренә ул гомере буена тугырылыклы булып кала. Р. Фәхреддин яшь буынны яхшы сыйфатлы мәдрәсәләрдә укытып һәм югары әхлакка ия булган мәдәниятле кешеләр итеп тәрбияләп олы тормыш юлына әзерләү эшчәнлеге белән

шөгыльләнә. Ул, шактый зур укыту һәм фәнни тәҗрибә туплаган педагог һәм галим буларак, уку-укыту һәм тәрбия-әхлак мәсьәләләренә багышлап китаплар яза."Гыйлем әхлак ("Әхлак гыйлеме-этика") сериясеннән ун исемдә булган дәреслек-китаплар бастыра. Бу – "Гаилә" (1902-1916); "Нәсыйхәт I" (1903-1919); "Нәсыйхәт II" (1903-1913); "Нәсыйхәт III" (1898-1909); "Тәрбияле хатын" (1899-1910); "Тәрбияле ата" (1898); "Шәкертлек әдәпләре" (1899-1914); "Тәрбияле ана"(1898-1910); "Адәбе тәгълим" (1902-1908); "Әхле гыяль"("Өй җәмәгате" (1908-1910)[4:5].

3.Китап-дәреслекләрнең тугызынчысы "Адәбе тәгълим" ("Укыту кагыйдәләре")нең иң беренче битенә, бүлек башына, иң беренче сүз итеп «Гыйлем» дип куя. Аннан соң «Мөгаллим. Тәрбия», дип яза. Аның фикеренчә, гыйлемнән дә артык байлык, наданлыктан да артык фәкыйрьлек юктыр.

Гыйлем өйрәтүче, дәрес укытучы, балаларның җаннарын тәрбияләүче кешенең мөгаллим-укытучы дип аталуын искәртә. Укытучының иң беренче эше-шәкертләрне гыйлем белән тәрбияләү, күркәм холыклар белән таныштыру һәм аларга гадәтләндерү икәнлеген аңлатып бирә. Хезмәтләре–саваплы, вазифалары–авыр, мактаулы булган укытучыларның шәкертләре өчен җаваплы булуын да белдерә. Укытучыларның олы хезмәтләрен лаеклы бәяләп: "Укытучылык- иң бөек һәм иң изге бер хезмәт урыныдыр ки: бу юлда никадәр мәшәкать тартылса да, аларның барысы да рәхәтлеккә хисапланылса да-урынлыдыр..."- дип яза. [3:11].

Укытучыларның һәм шул исәптән мәктәпләрнең дә эшчәнлегенә-гыйлем өйрәтү, укыту белән генә чикләнмичә, балаларның күңелләренә яхшы гадәтләр, тырышлык, гүзәл холык, тугрылык, гайрәтлелек, активлык кебек яхшы холыклылык орлыкларын игътибар белән чәчү һәм тәрбияләү вазифалары да йөкләнә. Ризаэддин Фәхреддин укытучы нинди булырга тиеш; ул нинди сыйфатларга ия булырга тиеш; дәресләрен ничек укытырга тиеш; аның вазифалары нәрсәдән гыйбарәт булуын тәфсилләп аңлата.

4.Галим укытучыларга йөкләнә торган унөч вазифаны төшендерә.

Беренче вазифа – укытучы холкы һәм гамәле белән шәкертләренә үрнәк –күчергеч булырга тиеш. Балалар укытучының гүзәл холкы һәм яхшы гамәле үрнәгендә тәрбияләвенә мохтаҗ. Әгәр укытучы һәр укучыны бертигез күреп хөрмәт итсә, һәркайсына шәфкатьле эндәшсә, шәхес итеп күрсә, үзенә дә кадер-хөрмәт булачак икәнлекне онытмаска тиеш. Бу урында Р. Фәхреддиннең түбәндәге гыйбарәсен китерү урынлыдыр: "Язылган китап нөсхәсен күреп, язучының гыйлем һәм акылда булган дәрәҗәсен тәкъдир итү мөмкин булган кебек, шәкертен күреп, укытучысының кем икәнен белү дә авыр булмас."[3:16].

Икенче вазифа -укытучы булып эшләү өчен белем , булдыклылык, сәләтлелек булу фарыз. Әгәр укытучы белемле булып та, күңелендә булган гыйлемне бала күңеленә ачык итеп салмаса, бернинди нәтиҗәгә дә ирешә алмас.Галим булу-бер нәрсә, ә укытучы булу- икенче нәрсә. Бу урында: "Баланың күңеленә дәрескә мәхәббәт салу һәм бу мәхәббәтне киметмәү, һәм һәр көнне арттыру мөгаллимнең осталыгыннан, тәрбия ысулларының камил куллануыннан тора",-дигән фикере белән нәтиҗә ясарга була [1:9].

"Укытучы тәрбиясеннән күреләчәк файда, фәкать гыйлем булдыклылыгыннан гына булмыйча, бәлки болар белән бәрабәр, аның шәфкатьле һәм мәрхәмәтле булуыннан да күренеп тора."[1:7]гыйбәрәсе аркылы өченче вазифаны күрәсең. Өченче вазифа - укытучы шәфкатьле, мәрхәмәтле булырга тиеш. Бу хисләр булмаса, андый кешенең укыту- тәрбия эше белән шөгыльләнмәве үзе өчен дә, балалар өчен дә хәерле. Риза Фәхерддин укытучыларның сабыр булуларын да тели.

Укытучының дүртенче вазифасы- ихласлылык, дикъкатьлелек, тырышлык сыйфатларын күрсәтә. Галим фикеренчә, укытучы һәрвакыт укыту-тәрбия үткәрү чараларын билгеләнгән вакытта башкарырга тиеш. Һәр эшне үз вакытында үтәү-дикъкатьле булу билгесе.

Бишенче вазифа- балаларны сынап карау юлы белән, гыйлемгә карата мәхәббәт уяту, белем алырга кызыксыну тудыру, түземлелек сыйфатлары тәрбияләү. Укучының җәмгыять өчен кирәкле һәм һәрьяктан камил шәхес булып җитешүе өчен укытучы җаваплы.

Алтынчы вазифа -укытучы баланы яхшылыкка өндәп үгет-нәсыйхәт бирергә тиеш. Нәсыйхәт сүз белән генә түгел, ә үзеңнең гамәлең һәм холкың белән укучыларга күчергеч-үрнәк булып торуда күренә. Әгәр укытучы тырышып укытып һәм тәрбия биреп тә нәтиҗә күренмәсә, бала үзе теләсә, башка укытучыдан белем алуга каршы килмәскә кирәк.

Җиденче вазифа- укытучының укучыны битәрләргә хакы юк. Ул дөрес гыйлем өйрәтүче, милләтне кайгыртучы,барлык кешеләр белән яхшы мөгамәләдә булып, булдыра алганча файда китерүче генә булырга тиеш.

Укытучының гыйлемгә һәм галимнәргә олы хөрмәт һәм мәхәббәт күрсәтүе-сигезенче вазифа була. Тәкәбберлек, көнчелек, комсызлык, үч алучанлык, үзен генә яратучылык, канәгатьсезлек, дөнья малына кирәгеннән артык кызыгу, явызлык кебек сыйфатларга ия булу укытучы өчен гаеп санала.

Тугызынчы вазифа- укытучы һәрдаим дөреслеккә өйрәтергә тиеш. "Балаларга дөреслек өйрәтегез, дөреслек аларга барлык яхшылыкны өйрәтер!" дигән изге сүзләр, Р. Фәхреддин фикеренчә, тәрбия мәсьәләсендә эзлекле, чагылыш тапкан һәм гәүдәләнгән бер

кагыйдә булып торалар. Шулай ук укытучы үз укучыларын һәр нәрсәдә дөреслеккә гадәтләндерергә, моны үзенең эш кагыйдәсе итеп кулланырга һәм беркайчан да игътибарсызлык күрсәтмәскә тиешлеген аңлатырга тиеш.

Унынчы вазифа-укытучы дәрес укыту ысулына игътибар итәргә бурычлы. Гыйлем бирү, укыту ысулының төп өлеше бер төрле булса, укыту ысулы тармаклары һәм бүлекләре заман, мәгърифәт һәм мәдәният таләп иткәнчә тулылана, камилләшә, үсә баруын укытучы онытмаска тиеш.

Мөгаллим дәрес бирүгә әзерләнгәндә ундүрт кагыйдәне исәпкә алырга кирәк.

-Дәрес галимнәр язган китапка таянып уздырыла.

-Уздырылачак дәрес кыска һәм файдалы, тирән эчтәлекле булырга тиеш. Укытучы дәресне китапка карап үткәрми.

-Һәр үткәргән дәресне укучылар аңлау-аңламавы төрле ысуллар белән тикшерелә.

-Бүгенге дәрес кичә үткәне белән бәйләнеп алып барыла.

-Дәрес үткәргәндә ятлау ысулын ешрак куллану. Ятлыйсы һәр нәрсәнең сүзләре, гыйбарәләре-сүзтезмәләре һәм җөмләләре төзек һәм камил булырга тиеш.

-Укытучының дәрес өйрәтүдән тыш һәрвакытта да динлелекнең һәм әхлакның күркәмлекләре хакында да сүз алып барырга тиеш. Дин ул- әдәп, әхлакның нигезе буларак, аны өйрәнү мәсьәләсенә аеруча нык игътибар итәргә тиеш.

- Һәр дәрес зур җаваплылык белән әзерләнеп үткәрелергә тиеш.

- Дәрестә укытучы аңлаешлы итеп, бөтен көчен , тырышлыгын куеп, үткен тел белән, чиста итеп, фикерләрен һәм сүзләрен кабатламыйча сөйләргә тиеш.

- Әгәр укытучының укучыларына биргән гыйлеменә караганда , тәрбия мәсьәләсендәге файдасы азрак булса, ул укытучы-бик камил укытучы була алмый.

-Дәрес укучыларның сәләтләренә яраклаштырып,сыйныфта иң көчсез укучыга йөз тотып, аңлаешлы тел белән ачык һәм кыска итеп аңлатылырга тиеш.

-Өйрәнелә торган фән белән укучыларда кызыксындыру булдыру максатыннан, ялкау һәм тырыш укучыларны билгеләү; тырышларның хезмәтен бәяләү алымнары да куллана.

-Дәрес вакытында яки дәрестән соң укучыларны ял иттерергә кирәк. Башлангыч сыйныф балаларын саф һавага алып чыгу сорала. Мәктәптә сәламәтлек саклау кагыйдәләре һичшиксез үтәлергә тиеш.

-Тиешле бүлекне өйрәнгәннән соң һәр бала имтихан тапшырыга тиеш. Укытучының имтихан ала белүе- укыту кебек авыр эш. Мондый бик нечкә һәм җаваплы эшкә һәркем сәләтле түгел.

-Укытучы дәрестә, укучылары нинди яшьтә булуларына карамастан, укытуның төп максаты булган аңлату эше белән шөгыльләнергә тиеш. Аңлату эше дәрестә үткәннәрне чагыштырып карау, тәҗрибәләр үткәреп белү юлы белән алып барыла.

Укытучының һәр дәресе менә шундый ысуллар белән уздырылса, нәтиҗәсе яхшы була.

Укытучының унберенче вазифасы булып, ул гыйлемне сайлап алырга өйрәтә. Балаларны укытканда аларның киләчәген күздә тотып, үсеп буй җиткәч тормыш итәр өчен кирәклк гыйлемнәр өйрәтергә кирәк. Укытучы наданлыктан, бозык холыклардан котылу өчен түбәндәге юнәлешләр белән укытырга һәм тәрбияләргә тиеш:

-Дин гыйлеме укыту.

-Тырышлык тәрбияләү.

-Сакчыл булырга өйрәтү.

-Яхшы холыклы булырга өйрәтү.

-Аралашу кагыйдәләрен өйрәтү.

- Аңны тәрбияләү.

Уникенче вазифа- укытучы мәктәпнең һәм укучыларның хәлен даими күзәтергә тиеш. Мәктәпнең эче һәм тышы күркәм , чиста, җыйнак булып, читтән килгән кешегә бер бик хөрмәтле гыйлем өйрәнү йорты икәнлеге күренеп торсын, халык өчен үрнәк күчергеч булсын.

Гыйлем өйрәтүдән тыш, укучыларның сәламәтлекләре турында да кайгыртып, тәнәфесләрдә хәрәкәтле уеннар оештыру кирәк. Киләчәккә сайланасы һөнәрләре турында да белемнәр бирү.

Укытучылар азгынлык, бозыклык белән шөгыльләнүче кешеләрне мәктәпкә эшкә алуларына юл куймаска тиеш.Әхлак бозыклыгына китерә торган әдәби әсәрләр укуга рөхсәт бирмәскә тиеш.

Укучының өй әгъзалары белән таныш булырга тиеш. Дәрескә килмәсә, тиз арада сәбәбен ачыклау да укытучы өстендә була.

Укытучының төп эш вазифаларына өстәп, камиллекне арттыра торган унөченче вазифасы түбәндәге кагыйдәләрне үз эченә ала.

1.Укытучы матур һәм килешле итеп сөйли белергә тиеш. Моның өчен даими рәвештә үзенең сөйләү осталыгын камилләштерү өстендә эшләү сорала. Укучылар үзләренең укытучыларыннан үрнәк алып, аның кебек сөйли, язганда, укыган грамматик ялгышлардан саклана.

2. Укытучыдан язу сәнгатенә оста булу һәм үзлегеннән иҗат итү сәләтенә ия булу сорала. Укытучы кеше сөйләргә яраман нәрсәне кәгазьгә язмаска тиеш.

3. Укытучының хәтер дәфтәре булып, анда үзе өчен кирәкле мәгълүматлар туплану фарыз.

4. Укытучы тарих, география фәннәре белән таныш булырга тиеш. Нинди фәнне аңлатканда да тарихи материалларга таяну кирәк була. Мондый укытучыда белем алган укучылар да тирән белемле була.

5. Укытучы укучы балаларга да барлык кешеләргә карата да гадел булырга тиеш. Укучыларына да дөреслекне танып белергә, гаделлекне танырга өйрәтә.

### III Йомгаклау

Әйе, Ризаэддин Фәхреддин үзенең "Укыту кагыйдәләре" исемле дәреслек-китабында җәмгыятьтә шәхес тәрбияләүнең никадәр авыр, катлаулы һәм дәвамлы эш икәнлеген ассызыклады һәм яшь баланы укытучы-мөгаллимнең, шәхес, гакыл, рух һәм гүзәл холык тәрбияләүче кеше буларак, һәрвакыт гадел булырга тиешлеген аңлатып бирде.Мин аның укытучы нинди сыйфатларга ия булырга тиеш; дәресләрне ничек укытырга кирәклекне; аның вазифалары нәрсәдән гыйбарәт булуын остазларча җиткерергә теләвен күрдем. Әлеге китап XXI гасыр мөгаллимнәренә дә түбәндәге фикерне җиткерә кебек: "Гыйлем бирү, укыту ысулының төп өлеше бер төрле булса, укыту ысулы тармаклары һәм бүлекләре заман, мәгърифәт һәм мәдәният таләп иткәнчә тулылана, камилләшә, үсә баруын укытучы онытмаска тиеш."

Чыгышымны Ризаэддин Фәхреддиннең тагын бер кыйммәтле гыйбарәсе тәмамларга булдым: "Гыйлем юлы-бер кадерле юлдыр, ләкин бик мәшәкатьле һәм авырдыр. Шулай булса да, очы бәхеткә, ахыры камиллеккә барып туктыйдыр"[1:36].

**Әдәбият**

1.Гимранова Д. Ризаэддин Фәхреддин " Сүзләрнең кыйммәтлесе-заман үтү белән онытылмый торганы"- с. Кичучатово: Мемориальный музей Р. Фахреддина, 2014.- 7б.,9б., 36б.

2.Мәрданов Р, Миңнуллин Р., Рәхимов С. "Р. Фәхретдин Фәнни-биографик җыентык"- Казан: Рухият 1999, 27 б.

3.Ризаэддин Фәхреддин "Адәбе тәгълим" - Казан: 2006, 11б., 16б

4.Хайри А. Ризаэддин Фәхреддин "Нәсыйхәт" -Казан: Мәгариф, 2005, 5

*Гарифуллина Ләйсән Әнәс кызы,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының "20нче урта гомуми белем бирү мәктәбе" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең югары квалификацияле туган тел һәм әдәбият укытучысы*

## Функциональ белемлелек иҗтимагый иминлекнең мөһим индикаторы

Бүгенге ил таләпләре һәм мәгълүмати җәмгыятьнең тиз темплар белән формалашуы мәгариф системасы алдында яшь буынга белем бирү максатын һәм бурычларын, форма һәм эчтәлеген тамырыннан үзгәртү мәсьәләсен куйды. Россия педагоглары, заман таләпләрен искә алып, беренче мәртәбә буларак, укучы шәхесен формалаштыруда белем бирүне мәгънәле һәм максатлы булырга тиеш дигән фикергә килделәр. Мәгариф системасындагы шушы яңалыкларны гамәлгә ашыруда төп көч вазифасын үтәү өчен дәүләт стандарлары төзелде. Гамәлдәгесеннән аермасы өйрәнү өчен мәҗбүри булган материаллар җыелмасында гына түгел, ә бала шәхесенең игътибар үзәгенә куелуында. Ул белем бирүнең нәтиҗәлелегенә йөз тота - укучы конкрет дисциплиналар буенча белем алып кына калмый, ә аларны көндәлек тормышта, алга таба укуында файдаланырга да өйрәтә.

Билгеле булуынча, уку предметының реаль тормыш белән бәйле булуын да аерым игътибарга ала. Мәсәлән, уку дәресенең төп максаты минутына ничә сүз уку түгел, ә текстны аңлап уку һәм аңа анализ ясый белү. Баланың алган белеме тупланып кына калырга тиеш түгел. Укучы бала алган белемнәрен тормышта иркен куллана белергә, килеп туган мәсьәләләрнең чишелешен эзли, таба белергә тиеш.

“Кешегә бетмәс –төкәнмәс иҗат чыганагы салынган. Менә шул чыганакны ачарга, иреккә чыгарырга, кешегә иҗтимагый тормышта урынын табарга булышырга, аңа үсү өчен тиешле шартлар тудырырга кирәк”, - дип язган моннан күп еллар элек Л.Н.Толстой. Бүгенгесе көндә бу фикерләр белән килешми булмый: гомуми белем алган укучылар аралашу һәм социаль мөнәсәбәтләрнең киң диапазонын хәл итү өчен кирәкле белем, күнекмәләргә ия булырга тиеш. Без укучыларга әзер белем бирү белән шөгыльләнмичә, белемне укучыларның үзләреннән таптыру адымнарын күздә тотып эшләргә, алган белемнәрен тормышта куллана белергә өйрәтергә тиеш. Шул очракта гына безнең укучылар яңа тормыш шартларына яраклашкан, гомуми мәдәни үсешкә ирешкән, үз фикере булган һәм җәмгыятькә файдалы шәхесләр булып үсәчәкләр. Бу максатка ирешү өчен балаларда функциональ грамоталылык формалашырга тиеш.

Функциональ грамоталылык – кешенең әйләнә-тирә мохит белән мөнәсәбәтләргә керү, гомер дәвамында белемнәрен куллана белү сәләте.

Бу бурычларны туган тел һәм әдәбияты укытучысы нинди юллар белән тормышка ашыра ала соң? Педагогика фәнендә укуыту- тәрбия процессы сыйфатын үстерүгә булышлык итүче технологияләр шактый. Укытучының бурычы - яңалыклар агымында югалып калмыйча, укытуның һәр этабы өчен уку материалын үзләштерүнең иң уңышлы вариантын кулланып эшләү, укучыларга алган белемнәрен тормышта куллана белергә өйрәтү.

Педагогик стажы булган һәр укытучы үзенә генә хас булган эш алымнарын кулланып, иҗади рәвештә эшли. Педагогик технологияләрнең төрлесен кулланп карыйбыз, аларга үзгәрешләр кертәбез, кечкенә генә ачышлар ясыйбыз. Шулар нәтиҗәсендә, һәрберебезнең “Үз технологиясе туа”.

Шундый алымнарның берсе, мәсәлән, дәрестә проблемалы ситуация куллану. Ни өчен кирәк соң ул ситуация? Беренчедән, ситуация укучыларның дәрестә эшчәнлекләренә кызыксыну уята. Икенчедән, дөрес уйланылган ситуация укучыларның үз уку бурычларын билгели аламы- юкмы икәнлеген аңларга ярдәм итә.

Үземнең чыгышымда кайбер алымнарга тукталып үтәм:

1. *Капма-каршылыклы ситуция*. Бу алымны әдәби әсәрләр, текстлар өстендә эшләгәндә отышлы, дип саныйм. Бу алым укучы тарафыннан “бәхәстә дөреслек табыла” принцибын үзләштерүгә ярдәм итә, “аргумент һәм контраргумент” белән эш итәргә, бәхәсләшү культурасын үстерүгә булышлык итә. Бәхәс итү юллары аша укучы үз фикерен аңлатырга һәм расларга өйрәнә.Әгәр ялгышлары булса, төзәтү юлларын бергәләп эзлибез. Фикер тирәнлеге һәм төзеклеге дә бу очракта зур роль уйный. Укучының, коммуниктивлык сәләтен үстерү аша, үз фикерен аңлата һәм раслый белү бик әһәмиятле.
2. *Ярашмаучанлык ситуациясе.* Укучылар игътибарына түбәндәге сүзләр бирелә. Бер сүз белән әйт:

Авыз ачу - уразадан кич ашау

Авыз да ачтырмау - сүз әйттермичә үзеңчә эшләтү

Адәм рәтле - ярарлык кимәлдә

Ай күрде, кояш алды - кыска булып кинәт беткән нәрсә турында

“... Ак сакаллы карт булыр идем” - эшем уңар иде

Баш бирмәү - буйсынмау

Борчак чәчү - мактану

Каты колак - саңгырау

Кул арасына керү - булышу

Баш вату – уйлау.

Анализлау барышында шундый бурычларны ассызыклау, белү кирәклеге туа: бу сүзләрнең мәгънә үзенчәлеге; алар ничек атала; аларның сөйләмдәге роле.

Бу ысул укучының иҗади фикерләү сәләтен, аларга тормыш куренешләрен “төрле төсләрдә” кабул итү, киңәйтеп сөйләү сәләтен үстерергә ярдәм итә.

*Көтелмәгәнлек ситуациясе.*

Ул булачак вакыйгага үз фаразыңны белдерү.Сезнең алдыгызда әдәби әсәрләр исемлеге. Бирелгән әсәр атамасын ачыклау максатыннан: “Бу әсәр нәрсә турында булыр?”

, - дигән сорау куела. Яки әсәрнең бер өлеше укылганнан соң, “Укучылар, вакыйгалар ничек үстерелер?”,

- дип сорап була. Кайбер әсәрләрләрдә, фильмнарда “ачык финал” алымы кулланыла. Монда да укучылар финалны төрлечә фаразларга мөмкин. Бу алым уйлау, күзаллау сәләтен арттырырга, үзеңнең фаразларыңны дәлилләргә өйрәнергә ярдәм итә. Укучыга тормышта очрый торган көтелмәгән очракларда югалып калмау кебек сыйфатларны формалаштырырга булыша.

*Ассоциацияләр ботагы яки “Ассоциацияләр”, “сүз болыты” алымы* (критик фикерләүне үстерү технологиясе) образлы фикерләүне, аналитик фикерләүне, хәтерне, сөйләмне үстерә. Укучыларга ассоциацияне тактада яки карточкада язылган сүз буенча атарга, язылган ассоциацияләрдән сүз болыты ясау тәкъдим ителә. Шул ук вакытта аларга әсәрнең сюжетын, идеясен, темасын, геройларын билгеләргә тырышырга кирәк. Шулай ук укучыларга әсәр исеменә ассоциацияләр табарга тәкъдим итеп була. Сүз болыты күбрәк булган саен, аларның логик чылбырлары катлаулана бара. Эш нәтиҗәләре буенча укучының әсәрне ни дәрәҗәдә тирәнтен укуын һәм аңлавын күрергә мөмкин.

*Цифрлы онлайн - сервис LearningApps куллану.*

Яңа гасыр узган гасырны алмаштыра, социаль кыйммәтләр, идеаллар алмаша. Бүгенге конне без акыллы пылесостан, смартфон, айпад, айфон, “текә-текә” гаджетлардан башка күз алдына да китерә алмыйбыз. Кайвакыт без бик борчылып та куябыз, чөнки кечкенә генә балалар да телефоннан күзен ала алмый кнопларына басып уйный, шома экраннан нәни бармакларын шудыра. Ә ничек соң ул гаджетларны укучыларга файдалы итеп кулланырга? Укытучы ничек моны оештыра ала? Дәресләремдә мин цифры онлайн-сервис LearningApps куллана башладым. Бу сервис белән бушка кулланырга мөмкин. Биредәге Сервисны Германиядә уйлап тапканнар. LearningApps сервисына кереп мин 20-ләп бирем төзи алам. Бик уңышлы дип, йомгаклау күнегүләрен таптым. Теманы үткәч, укучы гаджетындагы кюаркод программасын кулланып, LearningApps ка керә, һәм онлайн (укытучы алдан төзеп керткән биремнәрне) эшли башлый. Сервис тиз арада гына биремнәрне тикшереп укучыга билге дә куя. Сервисның мөмкинлекләре бик күп, уңайлы. Тиз арада тикшерү уңайлылыгы укытучының кыйммәтле вакытын саклап кала, укучыларда кызыксыну уята.

Шулай итеп, дөнья яңалыклары агымында укучыларның позициясен ныгыту өчен, без, һичшиксез, аларга функциональ грамоталылыкны өйрәтергә бурычлы. Алар үзгәрүчән әйлән- тирә дөнья белән уңышлы хезмәттәшлек итәргә әзер булу, төрле (шул исәптән стандарт булмаган) уку һәм тормыш бурычларын хәл итү, социаль мөнәсәбәтләр төзи алу, үз грамоталылыгын бәяләү һәм алга таба белем алуга омтылыш тәэмин итә

торган осталыкларга ия булырга тиеш. Шулай итеп, бүгенге көндә функциональ белемлелек иҗтимагый иминлекнең мөһим индикаторы булып тора, ә укучыларның функциональ грамоталылыгы - белем бирү сыйфатының мөһим күрсәткече.

*Гиздатуллина Эльмира Мирзаһит кызы, Фәләхиева Ильмира Ризатдин кызы, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Муса Җәлил исемендәге «1нче гимназия» муниципаль бюджет белем бирү учреждениесенең югары категорияле укытучылары*

**Дәресләрдә мәгънәле уку стратегиясен формалаштыру**

Укучыларның тар фикерләү дайрәсе мөстәкыйль укуда ОГЭга һәм ЕГЭга әзерләгәндә проблема тудыра. Мәктәп укучылары күбесенчә фәнни-танып белү әдәбиятын аз укыйлар һәм тиешле яшьтә сүзлекләр, белешмәлекләр, энциклопедияләр, предмет буенча белешмә әдәбиятында ориентлаша алмыйлар. Һәр укучы тексттан, аның ихтыяҗларына һәм сәләтләренә карап, хәзерге вакытта алырга сәләтле булган кадәр алачак. Шуның өчен дәрестә өйрәнелә торган материалны кабул итүдә аерыла да. Укытучы - үз предметы кысаларында мәгънәле уку күнекмәләрен үстерү һәм камилләштерү буенча эш алып барырга тиеш.

Мәгънәле уку укучының төп төшенчәләргә ия булуын күздә тота, беренче чиратта терминнар шундый. Беренче төп сүзләрне табарга, ә аннары - аларның төгәл мәгънәсен шушы текстта билгеләргә өйрәнергә кирәк. Төп сүзләр, кагыйдә буларак, күп мәгънәгә ия булганга, аны автор нинди мәгънәдә куллануын аңларга кирәк. Гадәттә, төп сүзне очратканда, укучы аның мәгънәсен һәм мөһимлеген аңлавында кыенлык кичерә. Бу сүзләр өйрәнүне таләп итә, алар өчен текст языла да инде. Авторның төп сүзләрне аерып чыгару ысуллары күп. Аларны белергә һәм укыганда куллана белергә кирәк. Мәгънәсе һәм әһәмияте текстта ук каралырга мөмкин. Автор бу сүзне ассызыклау яки шрифт аша әйтә ала, аңа үзенең конкрет билгеләмәсен бирә. Бу очракта, бигрәк тә өлкән сыйныфларда, башка авторларның төшенчәләрен интерпретацияләүгә мөрәҗәгать итү файдалы. Моның өчен шулай ук сүзлекләр, энциклопедияләр, белешмә әдәбият кулланырга мөмкин. Күзәтүләр күрсәткәнчә, мәктәп укучылары аңлаешсыз сүзләргә берничек тә реакция бирми. Яңалык алар яныннан үтеп китә, аның нәрсә икәнен белү теләге тумый, уйларга да, сүзлеккә күз салырга да, өлкәннәргә сораулар белән мөрәҗәгать итәргә дә мәҗбүр итми.

Уку хаталарының берсе - сүзләргә игътибар итмәү. Укучылар еш кына сүзләргә игътибар итмиләр, аларны аңлаешлы һәм аңлаешсыз сүзләргә бүлмиләр. Күпләр барлык сүзләрнең мәгънәсен аңлыйлар дип ышана, бигрәк тә китаптан төп сүзләр сөйләм сүзләре

белән туры килсә. Шуңа күрә укытучыга сүзнең мәгънәсе өстендә генә түгел, ә әһәмиятен ачыкларга кирәк булган төп сүзләрне эзләү өстендә дә эш оештырырга кирәк.

Мәгънәле уку күнекмәләрен формалаштыру этаплары:

1.Мәгънәле-ориентлаштыру- әлеге этапта төп осталык булып текстта ачыктан-ачык бирелгән мәгълүматны алу, терминнарның мәгънәсен текстыннан билгеләү, текстның төрле өлешләреннән мәгълүматны чагыштыру, текстта эзлекле гамәлләр билгеләү тора. Нәтиҗә: текстта гомуми ориентлашу.

2.Эчтәлектән мәгънә табу- төп осталык булып текстның аерым өлешләренең төп фикерен аерып күрсәтү, тексттан мәгълүмат нигезендә нәтиҗәләр ясау, мәгълүматны тексттан графикка яки киресенчә графиктан текстка үзгәртү тора. Нәтиҗә: текстны тирән аңлау.

3.Шәхси рефлексия - төп осталык булып яңа ситуацияне анализлау һәм аңлату өчен тиешле мәгълүмат блокларыннан алынган белемнәрне куллану, нечкә һәм юан сораулар табу:

«Нечкә» сораулар - бер сүзле җавап, репродуктив план мәсьәләләре:

Нәрсә?

Кем?

Кайчан?

Ни атлы?

Булдымы?

«Юан» сораулар - уйлануны, өстәмә белем бирүне җәлеп итүне, анализлауны таләп итә торган мәсьәләләр:

Ни өчен дип өч аңлатма бирегез?

Ни өчен икәнен аңлатыгыз...

Ни өчен дип уйлыйсыз?..

Ни өчен сез...

Нинди аерма бар?

Нәрсә, әгәр ...

Бәлки...

Булырмы?

Булган идеме?

Ризамы сез?

Дөресме?

Булса ни булыр?

Нәтиҗә: алынган мәгълүматны практик эшчәнлектә куллану.

Мәгънәле укуның максаты - текстның эчтәлеген максималь төгәл һәм тулы итеп аңлау, барлык детальләрне отып алырга һәм алынган мәгълүматны аңларга . Чөнки уку мәгънәле булсын өчен, укучыларга текстның мәгънәсен төгәл һәм тулысынча аңларга, мәгълүматнын эчтәлегенә төшенергә кирәк.

Укытучының бурычы - балаларның тирән төп мәнфәгатьләрен формалаштыру һәм ныгыту, бер үк вакытта төрле яклап укуга ирешү. Теләсә кайсы тематиканы уку белән

кызыксыну хисен кичергән кешенең яңа белемнәрне кертү юлы белән тикшерергә, тәҗрибәсен киңәйтергә һәм яңа белемнәр белән баетудан канәгатьләнү алырга теләге бар.

*Гыймалетдинова Нурзия Минәхмәт кызы, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы "Кизләү төп гомуми белем мәктәбе" муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

**ФДББС тормышка ашыру шартларында татар әдәбияты дәресләрендә яңа технологияләр. Тәнкыйди фикерләү технологиясе ысулларын куллану**

Күп белдерүгә караганда эзләнү орлыгын салу һәм
эзләнгәнен табарга юллар күрсәтү – мөгаллим бирә торган
хезмәтләрнең иң кадерлесе, иң зурысыдыр”
Галимҗан Ибраһимов

Җәмгыять алга барган саен, белем бирү системасында да үзгәрешләр арта бара. Укытучы һәр яклап тирән белемле һәм профессиональ компетенцияле, киң мәгълүматлы булганда гына, заманга лаеклы, мөстәкыйль фикерләүче, Функциональ грамоталы,зәвыклы шәхес тәрбияли ала.

Белем бирүнең төп максаты – укучыга белем һәм тәрбия бирү генә түгел, ә мөстәкыйль рәвештә белем алырга теләк уяту һәм бу белемнәрне тормышта иҗади кулланырга өйрәтү. Шәхес тәрбияләүдә әдәбият дәресләре иң алдынгы урында тора. Укучы әсәрне бәяләргә, үз фикерен төрле дәлилләр кулланып расларга, геройларның эш-хәрәкәтләренә мөнәсәбәтен белдерергә тиеш. Мин укыту-тәрбия эшендә ярдәм итүче инновацион технологияләр куллануны алгы планга куям. Шуларның берсе – критик фикерләү технологиясе.

Тәнкыйди фикерләүне үстерү технологиясенең төп максаты:

1)укучыны мөстәкыйль рәвештә, әлбәттә укытучы ярдәме белән, белемнәрне үзләштерергә өйрәтү тора;

2) укучыларның интеллектуаль фикерләү сәләтләрен үстерү;

3) танып-белү эшчәнлеген үстерүгә юнәлтелгән күнекмәләр булдыру.

Бурычлары:

1) укучы һәм укытучы арасында иҗади хезмәттәшлек булдыру, укучыны креатив эшчәнлеккә тарту;

2) белем бирү процессын оптимальләштерү, белем алуга уңай омтылыш (мотивация) булдыру.

Критик фикерләү технологиясенә корылган дәрес өч этаптан тора:

- өйрәнелә торган темага кызыксыну уяту,

- төшенү,

- рефлексия.

1. Кызыксыну этабына бәяләмә бирик. Кызыксыну уяту һәр дәрестә була. Бу өйрәнелә торган тема яки проблема буенча укучының элекке белемнәрен актуальләштерү һәм гомумиләштерү һәм актив эшчәнлеккә (уку эшчәнлегенә) ныклы кызыксыну уяту өчен кирәк.

2. Аңлау этабында укучы өйрәнелә торган материал буенча яңа мәгълүмат ала, төшенчәләрне, фактларны аңлап, элегрәк алган белемнәрен яңалары белән бәйли, тулыландыра.

3. Рефлексия этабында укучы өйрәнгәннәрне бербөтен итеп күзаллый, аңлап гомумиләштерә, яңа мәгълүматны тулысынча үзләштерә, иҗади фикер йөртә һәм өйрәнелә торган материалга карата аның шәхси мөнәсәбәте формалаша..

Критик фикерләү технологиясенең төрле ысуллары бар: “кәрзин” ысулы, инсерт, синквейн, “алты эшләпә” ысулы, кластер, фишбоун, дидактик уен, төркемнәрдә дискуссия оештыру, терәк конспект, паузалар ясап уку. Шундыйларның берничәсе белән танышып китик.

Бу технологиянең яңалыгы аның ысулларында, ягъни иҗади шәхес тәрбияләү өчен шартлар тудыруында. Әдәбият дәресләрендә кластер, синквейн, “алты эшләпә”, инсерт һәм “кәрзин” ысулларын кулландым. Алар мисаллар белән нигезләнеп, докладымда урын алдылар. Бу ысулларның һәрберсен дә бер дәрестә кулланырга кирәк икән дип уйларга ярамый. Һәр дәреснең үз үзенчәлеге бар, шуңа күрә укытучы аларның иң отышлыларын гына сайлап ала. “Кәрзин” ысулы. Бу ысул төшенчәләрне, фактларны тупларга һәм алар арасында бәйләнеш тудырырга ярдәм итә. Иң әһәмиятлесе: ул язма сөйләмне камилләштерү һәм укучыларның парлап һәм төркемнәрдә эшләүләрен оештыру мөмкинлеген бирә. 5 нче сыйныфта Нәби Дәүлинең “Кар нинди җылы...” хикәясен өйрәнгәндә бу ысулны куллану “бәхет” һәм “кайгы” төшенчәләре турында тирәнтен фикер йөртергә ярдәм итә. Укучыларның бер төркеме – “Бәхет нәрсә ул?”, икенчесе “Нәрсә ул кайгы?” соравы буенча эшли. Һәр укучы 1-2 минут эчендә кәгазьдә үз фикерен язып куя. Соңыннан парлап, аннан соң төркемнәрдә җаваплар тикшерелә, ягъни мәгълүмат алмашу үткәрелә: һәр укучы үзе уйлаганны төркемдәгеләргә сөйли. Укучыларның дөрес җаваплары да, дөрес булмаганнары да кәрзингә салына. Ике төркемнең укучылары бергәләшеп һәр фикерне тикшерәләр. Балалар үз фикерләрен расларга тырышалар, хаталар төзәтелә. Укучылар төп нәтиҗәне ясыйлар. Эш тәҗрибәсе шуны күрсәтә: дәрес

вакытында битараф укучылар булмый, чөнки һәр укучыга үз фикерен яклап чыгыш ясарга туры килә.




Инсерт ысулы.

Ул катлаулы түгел. Бу ысулны икенче төрле “текстны тамгалау” дип атыйлар. Укучыларны тамга кую билгеләре белән таныштырып чыгарга кирәк, чөнки текстның кырыена тамгалар куеп барырга туры киләчәк.

∨ (галочка) тамгасын укучы текстагы мәгълүмат белән күптәннән таныш булган очракта куя. Ул моны белә.

+ (плюс) тамгасын укучы үзенә таныш булмаган яңа мәгълүматны очратканда куеп бара.

– (минус) тамгасын укучы текстта очраган мәгълүматның үзе моңарчы беләм дип йөргән фикер белән туры килмәвен күргәч куя.

? (сорау) тамгасы белән укучы таныш булмаган мәгълүматны билгели. Ул моны белергә теләвен күрсәтә.

Бу ысулны куллануның уңышлы ягы шунда, укучы текстны ә белергә, аңларга теләп, игътибар белән кат-кат укый. Мин үзем бу ысулны изложение һәм сочинение-фикерләмә язарга өйрәткәндә кулланам һәм болай эшләү уңай нәтиҗәләр бирә дип уйлыйм.

Г. Бәшировның 5 нче сыйныф әдәбияты дәреслегендә урнашкан “Нинди ул Татарстан?” текстын өйрәнгәндә, укучылар аның кырыена шул тамгаларны куеп

бардылар. Текстны тамгалап укыганнан соң, дүрт бүлектән торган Инсерт таблицасы тутырылды. Бүлекләр дә шул тамгалар белән билгеләнде. Таблицага тексттагы мәгълүматлар кыскача гына язып куелды. Соңыннан язмалар тикшереп анализланды. Инсерт ысулы текстны җентекләп анализларга, кирәкле фикерне аерып алырга, иң катлаулы мәгълүматны да җиңел һәм яхшы итеп хәтердә калдырырга ярдәм итә.

“Синквейн язу” ысулы.

“Синквейн” сүзе французча шигырь дигәнне аңлата. Бу билгеле бер кагыйдәләргә нигезләнгән иҗади эш формасы. Ул кыска төшенчәләр кулланып, укыган материал буенча нәтиҗә – резюме чыгарырга ярдәм итә. Синквейн укучыда төгәллек, күзәтүчәнлек, игътибарлылык сыйфатлары тәрбияләүдә дә әһәмиятле чара булып тора. Бу ысулның кабул ителгән кагыйдәләре бар.

Укучылар өчен ул кызык, чөнки эзләнәләр, уңышларын күреп шатланалар.

Менә шул кагыйдәләргә нигезләнгән синквейннарны без хәзер тыңлап узыйк.

Матурлык

Ягымлы, игелекле.

Шатландыра,кызыктыра, күңелгә рәхәт бирә.

Адым саен бездә матурлык!

Гүзәллек.

Матурлык

Сылу, файдалы.

Явызлыктан саклый, коткара кара уйлардан.

Бай безнең заман матурлыкка!

Ямьлелек.

Шулай, Матурлык – бик тирән мәгънәле төшенчә ул. Сез дә аны һәрберегез үзенчә аңлый.

Матурлыкны табигатьтә күрәбез, кеше күңеленең матурлыгы, беренче мәхәббәт һәм, кайберегез матурлыкны шушы тыныч тормышта, илнең иминлегендә, эти-әниләрегезнең җылы кочагында иркәләнеп, үз туган телендә белем алуда күрә. Көн саен шушы дөньяның якты кояш нурларын күреп тормыш итү - үзе зур матурлык.

Матурлык һәркайда, аны күрә, тоя белергә генә кирәк.

Бу мисаллар аша укучыларның иҗади фикер йөртүен; бирелгән теманы ачыклап, аңа бәя биреп, нәтиҗә чыгарырга тырышуларын күрергә була. Минемчә, синквейн тел чарлау һәм зиһенне үстерерүдә ярдәм итә.

“Алты эшләпә” ысулы. Бу ысул ярдәмендә фикерләүнең алты ысулын күрсәтергә телим. Укучыларны өч төркемгә бүләбез. Аларның һәрберсенә төрле төстәге икешәр эшләпә бирәбез *(кечкенә эшләпәләр кәгазьдән ясала).* Татар халык әкияте “Шалкан”ны

өйрәнгәндә бик уңышлы кулланам. Бу шактый кызыклы иҗади эш һәм аны дәреснең өченче этабында кулланырга була. Бу ысулның асылын аңлату өчен, Фатих Хөснинең “Сөйләнмәгән хикәя” әсәренә таянырбыз. Төрле төстәге эшләпәләр түбәндәге мәгънәгә ия.

*Ак эшләпә.* Укучы бары тик фактлар белән генә эшли. Хисләр, субъектив бәяләр бирүнең кирәге юк. Мәсәлән, укучылар “Сөйләнмәгән хикәя”нең төп вакыйгаларын санап чыгалар, нинди персонажлар булуын әйтәләр һәм аларга кыскача бәя бирәләр. Төркемдәге һәр укучы үз фикерен әйтә. Мисал китерәбез. Чабатачы Әхми гаиләсе бик ярлы булган, хәтта коймак пешерү өчен дә, таба эзләп, күршегә чаба торган булалар.

*Сары эшләпә.* Бары тик уңай фикерләр генә әйтелә. Һәр вакыйганың, образның позитив яклары турында сөйләнә. Ни өчен шулай уйлаулары турында аңлаталар. Мәсәлән, “Сөйләнмәгән хикәя”нең төп герое Биктимер тыңлаучан. Ул әнисе эш кушуга ук чыгып йөгерә. Акыллы. Үскәч инженер булган, димәк, башлы, яхшы укыган. Хыялый, уйлап табучан. Табага утырып, таудан шуу кемнең башына килер иде икән? Таудан шуганда ул бәхетле минутлар кичерә. Канатлы кошка охшап кала. Бар да аңа кызыгып карыйлар. Минем дә аның кебек табага утырып шуасым килеп китте, дигән җавапларны ишетергә була.

*Кара эшләпә.* Бу эшләпәне алган төркем нәкъ киресен, ягъни вакыйгаларның тискәре якларын гына сөйлиләр. Килеп чыккан проблемаларга бәя бирәләр. Мәсәлән, коймак ашап, рәхәт кичерергә әзерләнгән Әхми гаиләсенең хыялы тормышка ашмый. Кем гаепле? Биктимер әнисе кушканны онытып, көн буе тауда шуды, шуңа күрә коймак пешмәде, гаилә бәхетле мизгелләр кичермәде. Үзен бәхетле тойган Биктимер ата-анасы турында онытты. Ул дөрес эшләмәде. Өйгә кайткач, әнисе аны кыйнарга теләде. Бу минутта малай да бәхетсез иде.

*Кызыл эшләпә.* Бу эшләпә эмоциональ фикерләүне таләп итә. Мисал китерәбез. Рәхәтләнеп тау шуучы малайларны күргәч, Биктимер югалып калмады, табасына утырып шуа башлады. Миңа аның бу сыйфаты бик ошады. Әнисе Биктимерне орыша башлагач, миндә аны кызгану хисләре уянды. Әтисе аны кыйнатмады, чөнки ул улын аңлый, аның улы әллә нигә бер рәхәтлек кичергән икән, моннан бернинди дә зыян юк. Әтисе шулай уйлагандыр. Минемчә, аның да бәхетле булырга хакы бар.

*Яшел эшләпә.* Бу эшләпәне алган төркем башкалардан иҗади булуы белән аерылып торырга тиеш. Биктимер – тыңлаучан малай. Әгәр таба алып кайтасы көнне дә шулай булган булса, аларның гаиләсе бәхетле булыр иде. Сирәк кенә булса да, аларның да бәхетле буласы, тәмле ашыйсы килә. Биктимер табаны вакытында алып кайткан булса, бу кызыклы хикәя дә булмас иде. Без кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрнең, хисләрнең

катлаулы булуын да күрмәс идек. Мин Биктимер урынында булсам, нәкъ шуның кебек эшләр идем. Бу да укучылар фикере.

*Зәңгәр эшләпә.* Бу эшләпә фәлсәфи фикер йөртү турында. Ул дәрескә йомгак ясарга ярдәм итә. Гомуми нәтиҗәләр чыгарыла. Бу эшләпә “хуҗалары” башкаларның фикерләрен игътибар белән тыңларга тиешләр, чөнки алар алдында иң җаваплы бурыч – барлык төркемнәрнең җавапларын берләштереп, нәтиҗә чыгару тора: ата-ананы тыңлау кирәк.

Кластер ысулы.

Бу инглизчә “тәлгәш”, “бер үзәктә туплану”, ягъни тексттагы фикерләрне, төшенчәләрне аерып алу һәм аларның мәгънәви бәйләнешен график сурәттә күрсәтү дигән сүзне аңлата. Бу ысулның өстенлеге шунда, монда чикләүләр юк, укучылар барлык фикерләрен яза алалар. 5 нче сыйныфта Ә.Фәйзинең “Тукай” романыннан “Габдулланың Җаек мәдрәсәсендә укуы” өзеген дә өйрәндек, чөнки ул булачак шагыйрьнең характеры формалашуга бәйле сурәтләүләргә бай. Бу өзек дәреслектә булмау сәбәпле, укучыларга текст әзерләп бирелде һәм аны өйдә укып килделәр. Текстны укыганнан соң, анализ ясала. Кәгазь яки такта уртасында дәреснең темасын һәм идеясен ачарга ярдәм итүче төп (ачкыч) фикер язып куела. Аның тирәсендә фактлар, образлар һәм аларның эш-хәрәкәтләренә бәйле фикерләр, җөмләләр языла. Бу җөмләләр уртада урнашкан төп җөмләгә сызыклар ярдәмендә тоташтырылалар, бәйләнеш саклана. Нәтиҗәдә, укучыларның уй-фикерләрен, геройларга мөнәсәбәтләрен чагылдырган график сурәт барлыкка килә. Кластер (график сурәт) *рәсемен* карагыз.

Язучының тормыш юлы, иҗатын өйрәнгәндә кулланам. “Җомга көн кич белән” әсәрендә Бибинур образына бик уңайлы тәлгәш хасил булды.




Шулай итеп, критик фикер йөртү технологиясе баланы мөстәкыйль фикерләргә өйрәтә. Бу технологиянең нигезендә стандарт булмаган фикерләү, ирекле күзаллау, катлаулы проблемаларның яңа чишелешен табу һәм иҗади эшләү ята.

*Җәләлова Венера Иршат кызы,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Муса Җәлил исемендәге "1 нче гимназия" муниципаль бюджет белем бирү учреждениесенең югары категорияле рус теле һәм әдәбияты укытучысы*

## Сәләтле балалар. Кем алар?

Минем педагогик эшчәнлегем Алабуга дәүләт педагогика университетын кызыл диплом белән тәмамлагач, 2000 елда Муса Җәлил исемендәге «1 нче гимназия» дә рус теле һәм әдәбияты укытучысы буларак башланды. Үземнең методик темам буларак, мәҗбүри нәтиҗәләр нигезендә укытуның дәрәҗәсен дифференциацияләүне сайладым, аның авторы - В.В. Фирсов. Ул педагогика фәннәре кандидаты, «Мәгариф- барыбыз өчен дә» дигән үзәкнең җитәкчесе (Мәскәү шәһәре). Әлеге технологиягә ике стандарт кертү тәкъдим ителә: мәҗбүри гомуми белем бирү әзерлеге стандарты (аның дәрәҗәсенә һәркем ирешергә тиеш) һәм белем бирү стандартлары (мәктәпне кызыксынучан, хезмәт сөючән укучы белән тиешле дәрәҗәдә тәэмин итәргә). Мин сәләтле балалар белән шөгыльләнеп, төрле конкурсларда, конференцияләрдә, муниципаль һәм республика олимпиадаларында катнашам, икенче стандартка өстенлек бирәм.

Сәләтле балалар... Кем алар? Нинди алар? Укытучылардан еш кына аларның нәтиҗәлелеге юк дип ишеткән идек, чөнки аларның мәктәбендә (сыйныфта) сәләтле

укучылар юк. Мин моның белән катгый рәвештә килешмим, чөнки кешенең гениальлеге һәм таланты тумыштан килгән сыйфатларга бәйле түгел дип саныйм. Сәләтлелекне әйләнә-тирә формалаштыра. Әлбәттә, һәр бала үз сәләте белән туа, әмма аларны югары дәрәҗәдә үстерергә мөмкин. Башка сүзләр белән әйткәндә, дөрес яктан килгән очракта, теләсә кайсы баладан талант үстерергә мөмкин. Нәрсә ул талант? Бу сүз үзе дә хәзинә, бүләк һәм байлык турындагы күзаллауларга бәйле. Борынгы заманнарда талант дип бик югары бәяле чара, үзенең колоссаль зурлыгы аркасында гади кеше өчен файдасыз дип саналган. Бүгенге көндә психика һәм характер сыйфатларының серле ярашуы талант дип атала, алар кешене бик уңышлы күрсәтә, димәк, иҗади эшчәнлекнең нинди дә булса өлкәсендә актив итә.

Минем уйлавымча, чын тәрбия табигать биргән сәләтләрне үстерергә тиеш. Өлкәннәрнең ярдәме белән балаларның талантлары кешеләргә шатлык-сөенечләр китерә, яисә "җиргә күмелгән" була. Талантларны тәрбияләүдә иң мөһиме-үз көчеңә ышаныч, үзеңдә Хәзинә эзләргә теләк тудыру, һәм Ходай биргән сәләткә юл салу. Баланы тыюлардан азат итәргә һәм канатларын җәер өчен мөмкинлек бирергә кирәк. Канатлар һәр кешедә бар, тик аларны ачып җибәрмәсәң, алар сынарга мөмкин - балалар бөрешә, тоныклана. Баланы ешрак мактарга, мөстәкыйльлелеген хупларга, аның чиксез талантлы булуын бертуктаусыз искә төшереп торырга кирәк.

Минем җитәкчелегем астында бик күп укучыларымның дипломнар, грамоталар, югары дәрәҗәдәге таныклыклар алулары белән, муниципаль район, республика, Россия һәм халыкара конкурсларда, олимпиадаларда, конференцияләрдә чыгыш ясаулары белән бик горурланам. Һәм ышанызгыз, бу медалистлар һәм отличниклар гына түгел, алар арасында хәтта «3»ле билгесенә укучылар да бар. “Уртача укучы” һәм «артта калучылар» өчен мин бигрәк тә шатланам, чөнки аларга иң кирәге– авыр эштә кечкенә генә уңыш. Уңыш, шәхси казанышлар гына үз-үзеңә ышанычны ныгыта. Бер эшчәнлектәге уңыш, башка юнәлештә эзсез калмый. Минем фәннәрдә бирелгән уңышлар башка фәннәрдә дә ышаныч уята. Минем өчле билгесенә укыган укучым “4”леләргә тартыла, ә дүртлегә укыган кыз- медаль алырга тырыша. Бер уңыш икенчесен алыштыра алмый, ул үзе турында күзаллауны яхшырта һәм яңа уңышларга китерә.

Фән олимпиадалары иң сәләтле балаларны ача. Олимпиаданың төп максатлары һәм бурычлары-фәнни белемнәрне пропагандалау һәм мәктәп укучыларында фәнни эшчәнлеккә кызыксыну уяту, сәләтле һәм талантлы укучыларны ачыклау өчен оптималь шартлар тудыру, аларның киләчәктә интеллектуаль үсеше һәм һөнәри юнәлеш алуы.

*Зарипова Әнисә Газизулла кызы,*

*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Бакый Урманче исемендәге “2 нче гимназия” муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесенең югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

**Сәнгатьле сөйләм эшчәнлеген оештыру процессында укучыларның иҗади сәләтен үстерү**

Укучының иҗади сәләтен үстерү – бүгенге мәгариф системасндa иң мөһим юнәлешләрнең берсе булып тора. Чөнки иҗади фикерли белү, иҗадилык - шәхес өчен иң кирәкле һәм бүгенге җәмгыятьтә иң кыйммәт бәяләнә торган сыйфатларның берсе. Иҗади үзләштерелгән белемнәр генә бала шәхесен формалаштыруга йогынты ясый.

Ә.З.Рәхимов: ”Иҗади шәхес - милләт һәм Ватан байлыгы,”- ди. Чөнки иҗади шәхес башкалардан үзенең әхлаклы, кешелекле, хисле һәм ихтыярлы булуы белән аерылып тора.

Сүз — кешеләр аралашуы өчен иң кирәкле чараларның берсе. Фикерне аңлаешлы, күңелдәге хисне матур итеп әйтеп бирә белү һәрбер зыялы кеше өчен зарури. Бу күнекмәләр мәктәптә бирелергә тиеш һәм аны формалаштыруда татар теле һәм әдәбияты укытучыларының роле әйтеп бетергесез зур. Туган тел һәм әдәбияты дәресләрендә һәм дәрестән тыш чараларда укучыларның иҗади сәләтен ачу юнәлешендә төп максатларымның берсе: укучыларны сәнгатьле шигырь сөйләргә өйрәтү. “Җанлы уку – тасвири уку. Монда укылган әсәрдәге хис – кайгымы, көенеч вә шатлыкмы, башкамы – укучының йөрәгенә керә, йөрәгеннән тавышына килә: аның тавышы күз яшьсез елый, кылычсыз кисә. Икенче төрле әйткәндә, тасвири уку — әсәрдән алынган тәэсирнең тавыш белән бирелүе димәктер”,-дип язып калдырган Г. Ибраһимов

Әдәбият – мәктәптә шәхес формалаштыручы төп фәннәрнең берсе. Фән буларак, әдәбият – укучыга әдәбиятны сүз сәнгате итеп аңларга, аның әдәби культурасын, зәвыгын, сөйләмен, иҗади мөмкинлеген үстерергә ярдәм итүче белем, күнекмә һәм мәгълүматлар системасы, ягъни әдәбиятны сүз сәнгате буларак өйрәтү аша без укучыларның иҗади сәләтен, интеллектуаль мөмкинлеген, дөньяви күзаллавын үстерү хакында сүз алып бара алабыз.

Укучыларны сәнгатьле сөйләргә өйрәтү юнәлешендә түбәндәге эшчәнлек алып бару отышлы:

- татар сәнгатендә нәфис сөйләүче атаклы драматург Галиәсгар Камал, артистлардан Габдулла Кариев, Мөхтәр Мутин, С.Гыйззәтуллина-Волжскаяның иҗатын өйрәнү, граммофон тәлинкәсе язмаларын алар укуында Габдулла Тукай, Сәгыйть Рәмиев, Дәрдмәнд шигырьләрен тыңлау;

- язмалардан Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе Айрат Арслановның сөйләмен тыңлау;
- Татарстан китап нәшрияты А. Арсланов иҗатына багышлап 1998 нче елда “Сүз тәме” дигән китап чыгарды. Әлеге китапны өйрәнү;
- нәфис сүз сәнгатен халыкка җиткерүдә радио, телевидение, һичшиксез, зур роль уйный. Эльмира Хамматова, Лия Заһидуллина, Фәридә Мәсгуть, Миләүшә Насыйбуллиналарның чыгышларын тыңлау;
- укучыларның сөйләм үзенчәлекләрен өйрәнү;
- тавыш- сөйләм аппаратын көйләү;
- дикция;
- текст тикшерү (сүз белән йогынты ясау, текстны мәгънәви анализлау);
- тавыш (тавыш куюның башлангычы- резонаторларда яңгырау нигезләрен, сөйләм мелодикасының типларын өйрәнү, сонор тартыклардан һәм сузыклардан торган күнегүләр ясау, тавыш диапазонын үстерү);
- мәгънәви басымны билгеләү;
- сөйләм темпын ачыклау;
- дөрес әйтелеш кануннарын үзләштерү һәм ныгыту (хәзерге әдәби тел әйтелеш кануннары кагыйдәләре, сузыклар, тартыклар орфоэпиясе);
- шигырьне сәнгатьле уку;
- яттан сөйләү.

Сүз сәнгатенә төшенүне, аны аңлау мизгелен ике яклы күренеш итеп карарга кирәк. Беренчесе: сүз әдипнең уен, хисен тәгаен билгеләргә, тыңлаучының аңына тәэсир итәргә тиеш. Сөйләм сәнгатен тулысынча үзләштерүнең бер шарты булып, сүзнең бөтен төсмерләрен тоемлау тора. Шуңа күрә сүз тоемлауның өч билге-авазлар җыелмасы буларак, мәгънәлелек, образлык буенча аерым-аерым күнектерәбез.

Билгеле бер эш белән җитди һәм эзлекле шөгыльләнгән баланың сәләте тиз ачыла, кызыксынучанлыгы арта. Бәйге-ярышларда катнашу тырышлык, максатка омтылучанлык, мөстәкыйль фикер йөртә белү кебек мөһим шәхси сыйфатлар тәрбияләргә дә булыша. Укучылар Татарстан республикасының халык шагыйре Р. Вәлиевның 70 еллыгына багышланган «Дулкыннар”, «Театр театр ул», «Сандугач сайрар илем” исемле балалар иҗаты фестивальләрендә, “Теле барның- иле бар”, “Туган телем- серле тел”, “Без талантлар эзлибез”, «Яттан сөйлә Тукай шигырьләрен, шушы булыр иң зур бүләгең», “Сөмбелә - талантлылар ярминкәсе”, “Бәхет йолдызы” исемле бөтенрәсәй, республика, район күләмендә оештырылган сәнгатьле шигырь сөйләү бәйгеләрендә катнашып ике

Гран-при, ун Җиңүче, унбишләп лауреат диломнарына ия булдылар, призлы урыннар яуладылар.

Кешегә бетмәс-төкәнмәс иҗат чыганагы салынган. Менә шул чыганакны ачарга, иреккә чыгарырга, иҗтимагый тормышта урынын табарга ярдәм итәргә, аңа үсү өчен тиешле шартлар тудырырга кирәк.

Файдаланган әдәбият

1. Хәйруллина А.Х. Дөрес сөйләргә өйрәнегез.- Казан:Казан нәшр.,1992.-96б.

2. Рәүф Нуриев Сәнгатьле уку. Методик ярдәмлек. -Казан.-2000.-152б.

3. Курбатов Х.Р. Сүз сәнгате: Татар теленең лингвистик стилистикасы һәм поэтикасы. -Казан: Мәгариф, 2002.-199б.

4. Галимуллин Ф. Г. Укучыларны сәнгатьле укырга өйрәтү.-Казан:Тат. кит. нәшр.,1988.-86б.

5.Галимуллин Т.Н.Хәзерге шигърият// Мирас-1996.-№7-8

*Кәримова Марина Николай кызы,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының "Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүле 27нче урта гомуми белем бирү мәктәбе" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

**Татар телен чит тел буларак укытуда проект методының әһәмияте**

Татар телен чит тел буларак өйрәтүнең инновацион технологияләр арасында проектлар методы әһәмиятле урын алып тора.

Проект яисә эзләнү-тикшеренү эшчәнлеге – укучыларда проектлаштыру һәм тикшеренү үзенчәлекле күнекмәләрен һәм осталыкларын барлыккак китерә торган интегратив дидактив үстерү, белем һәм тәрбия бирү чарасы. Бу төр эшчәнлектә иң әһәмиятлесе – кызыклы бер проблеманы чишәргә алынып һәм укучылар тарафыннан бурычлар рәвешендә формалаштырылып, чишелеш ысуллары аша нинди дә булса бер нәтиҗәгә килү.

**Проект эшенең төп максаты** – укучыларның шәхси үсешенә, уңышлы аралашуларына ирешү, аларны һәртөрле эшчәнлеккә иҗади якын килергә өйрәтү.

**Проект эшчәнлегенең нигезе** – тикшеренү эше. Тикшеренү характерында башкарыла торган проект эшчәнлеге генә уку программасына ярашлы рәвештә яңа белемнәр алу мөмкинлеге бирә.

**Проект эшчәнлегенең бурычлары**:

- укучыларда интеллектуаль һәм гомумхезмәт белемнәрен булдыру, аларның хезмәт нәтиҗәсен күз алдына китереп эшләрлек күнегүләр, осталык булдыру;
- иҗади фикерләү, мөстәкыйльлек һәм башлап эш итү сәләтен үстерү.

**Проект эшләүнең берничә шарты бар:**

1. Укучыларны тема белән таныштыру,
2. Уку фәннәренең төрен сайлау,
3. Мәгълүмат җыю,
4. Проект белән эшләү,
5. Проектларны тәкъдим итү,
6. Проект әзер продукт (сайт, белешмә, кушымта, китап, сүзлекчә, видеофильм, модель, җиһаз һ.б) буларак тәкъдим ителә. Аны Интернетка урнаштыру яки әзер килеш тарату, гамәлдә куллану мөмкин булырга тиеш.
7. Проектның гамәли файдасы, кулланучысы булуы шарт,
8. Проектның теге яки бу проблеманы (әйтик, татар телендә берәр төрле продуктның, булмавын) тулыландырырлык, хәл итәрлек максаты, актуальлеге булуы зарур.

Проект өчен тема сайлаганда, укучылар фикерен искә алу әһәмиятле. Моның өчен аларның кызыксынуларына (хоббиларына) игътибар итәргә кирәк. Мәсәлән, укучы дөнья кинематографы белән кызыксына икән, аңа фильмнар турында сайт яки яраткан фильмының тәрҗемәсен эшләргә тәкъдим итеп була. Химияне яратса, татар телендә химиядән берәр белешмәлек яки видеоязма ясарга мөмкин.

Фәнни эшкә әзерлек дәресләрдә башлана. Хәзерге заман таләпләренә җавап бирә торган дәрес нинди булырга тиеш? Аны проектлаштырганда укытучыга нәрсәләргә игътибар итү сорала?

Иң беренче чиратта педагогка шуны истә тоту мөһим – дәрестә никадәр дәрәҗәдә мөстәкыйль эшчәнлеккә күбрәк урын бирелсә, шулкадәр яхшырак.

Эш барышында сәләтле укучылар да барлана. Алар дәрес кысаларында гына эшләп калмыйлар, дәрестән тыш та бу эшне дәвам итәләр.

Татар телен чит тел буларак укыту дәресләрендә проектлар методын куллану – балаларның сәләтен үстерүгә этәргеч булып тора:

- укучыларда яңа проектлар эшләү теләге туа һәм фәнгә карата кызыксыну уяна. Иҗади эшчәнлек тәҗрибәсенә ия булган саен укучыларның белем сыйфаты да үсә.
- Аларның төрле сүзлекләр, тәнкыйди материаллар белән эшләү күнекмәсе арта. Чыганакларны ничек эзләп табасың, алардан иң кирәкле мәгълүматларны ничек туплыйсын, аннан соң гомумиләштереп, нәтиҗәләрне ни рәвешле ясыйсын өйрәнәләр.

Укучыларның уңышлары һәм уңышсызлыклары да дәрестә ачык күренә. Үзлектән эш башкарганда балаларрның аны теләк белән яки теләксез башкаруы ачыклана. Укучы эшне кызыксынып, теләп башкарганда гына нәтиҗә була. Укытучы моны исәпкә алырга тиеш.

**Алда язылганнардан нәтиҗә ясап**, шуны әйтергә була: педагогика фәнендә укыту-тәрбия процессы сыйфатын үстерергә булышлык итүче технологияләр шактый. Укытучының бурычы – яңалыклар агымында югалып калмыйча, дөрес юнәлеш алу, укытуның һәр этабы өчен уку материаларын аңлатуның иң уңышлы вариантын табу. Шул ук вакытта аларның бер-берсе белән ярашырга тиешлеген дә онытмау зарури.

Кулланылган әдәбият

1. Сәмигуллин Г.Х., Баһавиев И.И. Мәктәптә фәнни тикшеренүләр белән идарә итү. II китап. Яр Чаллы, ИНПО. – 2004.
2. Белых С.Л. Управление исследовательской активностью ученика: методичекое пособие для педагогов средних школ, гимназий, лицеев – М.: Зимородок, 2007.

*Колмәхәммәтова Зөлфия Эдуард кызы, Хәйруллина Гөлназ Рәшит кызы, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Муса Җәлил исемендәге “1 нче гимназия” муниципаль бюджет белем бирү учреждениесе укытучылары*

**Укыдым димә, аңладым диген**

(текст белән эшләү буенча мастер-класс)

Хәерле көн, хөрмәтле хезмәттәшләр! Без, башлангыч сыйныф укытучысы Колмәхәммәтова Зөлфия Эдуард кызы, туган тел укытучысы Хәйруллина Гөлназ Рәшит кызы, Сезне үзебезнең укытучы остаханәсендә сәламлибез.

Ике укытучы бергә туры килсә, аларның укучылар турында сөйләшүен көт тә тор. Иртән очрашсалар - соңга калмадыლармы икән, кич очрашсалар - исән-имин кайтып җиттеләрме икән барысы да дип борчылабыз. Кичә дә дәресләрдән соң балалар өйләренә таралышты. Аларның кайтып җитүләрен белгертеп Ватсапка әти-әниләрнең хәбәрләре килә торды. Бер әнидән килгән хәбәр үзенчәлекле иде. Игътибар экранга! (Федор Решетниковның “Тагын икеле” картинасы). Мөгаен, бу картина Сезгә таныштыр. Сезнеңчә, бала ни өчен икеле алган? (карточкалар белән эш)

*Фикерләр тыңлана:*

- *Өй эшен эшләмәгән*
- *Теманы аңламаган*
- *Дәфтәре өйдә калган*
- *Диктантны начар язган*

- *Мәсьәләне дөрес чишмәгән*

- *Параграфны укымаган*

Әйе, без Сезнең белән килешәбез. Ә икеле алмыйча калып була идеме? Фикерләрегезне тыңлап карыйк. (2 группага бүлү: укучы-укытучы) укучы һәм укытучы буларак фикерләр тыңлана.

| укучы | укытучы |
|---|---|
| -шпаргалка ясарга мөмкин<br>-сөйләгәндә карап алырга<br>-күчерергә | -өй эшен яхшылап әзерләргә<br>-кагыйдәләрне камил белергә<br>-текстны кат-кат укырга |

Чыннан да, без Сезнең белән килешәбез. Икеле алуның төп сәбәбе – укучыларда тескт белән эшләү күнекмәләренең тиешенчә формалашмавы. Шуннан чыгып, мастер-классыбызның темасын ничек дип тәкъдим итәр идегез? (фикерләрләр тыңлана)

Рәхмәт, сезнең тәкъдимнәрегез безнең фикер белән туры килә. “Укыдым димә, аңладым диген” исемле остаханә үз эшен башлый.

Компьютерлар, гаджетлар өстенлек иткән заманда уку ник кирәк дип уйлаучылар да шактый. Сезнеңчә, уку кирәкме? (Гипотеза, фикерләр тыңлана, гомумиләштерелә).

Әйе, текст белән эшли белү күнекмәләре мәктәптә барлык фәннәрдә дә төп бурыч булып кала бирә. Остаханәбез башындагы картинага кабат кайтсак, без малай текст белән эшли белсә, “икеле” алмаган булыр иде дип фаразлыйбыз. Һәр укытучының методик сандыгында сыналган эш алымнары тупланган. Әйдәгез бергәләп, текст белән эшләү алымнарын гамәли яктан кулланып карыйк. Моның өчен Сезгә төсле рәсемле битләрне алырга кирәк. (1нче кушымта)

Үзегезгә бирелгән битләрдәге рәсемнәргә игътибар итегез. Һәркайсыгызның саргылт яшел кәгазьләрне алып, андагы сорауга җавап әзерләвегез сорала. Әлеге рәсемнәр ни турында сөйли? Рәсемдәге җанлы табигать турында нәрсә белербез дип уйлыйсыз? Рәсемнәрдә нәрсә дә булса сәер тоелмыймы? Укыячак текстыбыз нәрсә турында булыр дип фаразлыйсыз? Текстның атамасы ни турында сөйли? Иртә яз, табигать, үзгәреш, яңарыш сүзләре Сездә нинди фикерләр уята? (уйларга вакыт бирелә)

Текст белән эшләү 3 этаптан тора.

**1 этап** – текстны укуга әзерлек дип атала. Әлеге этапның максаты – укучының антиципация осталыгын, ягъни текстның атамасы, авторы, текстка карата бирелгән терәк сүзләр, рәсемнәр ярдәмендә тәкъдим ителгән текстның эчтәлеген фаразлау. Этапның төп бурычы – укучыда әлеге текстны укуга теләк-мотивация булдыру.

- Хөрмәтле остаханә кунаклары, әйдәгез бергәләп, Сезнең эшкә күз салыйк.

Текстка карата бирелгән сурәтләр сезгә ни турында сөйли?

Аның атамасы безгә текст эчтәлеген фаразларга мөмкинлек бирәме?

Текст нәрсә турында булыр дип уйлыйсыз? (фикерләр тыңлана)

- Рәхмәт, фикерләрегез бик кызыклы. Инде эшебезне дәвам итик. Барыгызны да текстның төп эчтәлеге кызыксындырадыр (2нче кушымта). Сез хәзер текстны укыйсыз, уку бурышында поляларга махсус тамгалар куя барырга кирәк була. Әлеге тамгаларны Сез слайдта яки өстәлдәге карточкаларда күрә аласыз. (*слайд, карточкалар)*

+ — мин моны беләм

! — бу - минем өчен яңалык

- — башкача уйлый идем

? — аңлашылмады

***2 этап-*** текстны уку барышында эш. Әлеге этапның максаты – бу текстны аңлау һәм аны интерпретацияләү, ягъни аңлатма бирү, үзеңнең тексттагы мәгълүматны ни дәрәҗәдә белүеңне бәяләү. Этапның бурычы - укучының текстны тулысынча кабул итүен тәэмин итү.

Бу уңайдан "Инсерт" алымы бик отышлы.

Инсерт ул — текстны уку, яңа мәгълүмат белән эшләү барышында тәнкыйди фикерләүне уку һәм язу ярдәмендә үстерергә мөмкинлек бирүче алым. Методикада аны нәтиҗәле уку технологиясе дип тә атыйлар. Маркировканы, китап-дәреслекләрне буямас өчен, махсус кәгазь ленталарда тамгаларга була.

- Хөрмәтле коллегалар, әйдәгез, Сезнең эшкә күз салыйк. Бу бирем катлаулы булмадымы?

+ тамгасы белән билгеләнгән укыгыз әле.

үзегез өчен яңа булган мәгълүмат белән уртаклашыгыз әле.

Сез нәрсә турында башкача уйлый идегез?

текстта ? тамгасы белән тамгаланган, аңлашылмаган өлеш булдымы?

Бик зур рәхмәт, бу биремне бик җайлы эшләдегез.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтәсе килә: әлеге алым, беренчедән, Сезне моңа кадәр билгеле булган мәгълүматны искә төшерергә, икенчедән, текст эченнән яңа булганнарын бүлеп алырга, өченчедән, мәгълүматны мөстәкыйль рәвештә анализларга мөмкинлек бирде. Текст белән эшләү моның белән тәмамланмый әле. Сезгә алсу төстәге кәгазьләрне алырга кирәк. Чираттагы алым - "Сайлап уку" дип атала. Сез үзегезгә бирелгән сорауларга тексттан җавап табарга һәм җавапны укып күрсәтергә тиеш.

Тексттан табыгыз һәм укып күрсәтегез:

- март ахырында беренче зур яңалык нинди?

- кычыткан күбәлге нинди?

- үрмәкүч иртән һәм кичен нинди халәттә була?

- аларны ни өчен сукбай дип атыйлар?

- ата һәм ана сыерчыкның аермасы нәрсәдә?

-иртә яз дигәндә, язның кайсы ае күз алдында тотыла?

Сайлап уку – тиз укуның бер төре. Аның барышында текстның аерым бүлекләре сайлап укыла. Бу алым белән эшләгәндә, укучы текстны тулы көе күрә, бернәрсәне дә төшереп калдырмый, әмма игътибарын үзенә кирәкле өлешкә, үзенә кирәкле мәгълүматка гына юнәлтә. Бу алым, гадәттә, текстны икенче кат уку барышында отышлы. Икенчел укыганда инде укучының уку тизлеге дә югарырак була, ул үз соравына җавап булган өлешне тәфсилләбрәк өйрәнергә мөмкинлек бирә. Шулай ук уку-карап чыгу, уку-эзләнү алымнарын да файдаланырга мөмкин. Алар турында мәгълүматны эзләп табу кыен түгел. Текстны аңлап уку күнекмәләре никадәр югары булса, укучыларның Бөтенрәсәй тикшерү эшләре, бердәм һәм төп дәүләт имтиханнары нәтиҗәләре дә шул дәрәҗәдә уңай булуына беркем шикләнми.

-Укучылар өчен бик кызыклы һәм шул ук вакытта катлаулы биремнәрнең берсе булып, укылган текстка карата сораулар төзү. Хәзер мин Сезгә шушы текст буенча сораулар төзергә тәкъдим итәм. Моның өчен игътибарыгызны экраннарга юнәлтүегезне сорыйм (нәзек һәм калын сораулар төзү).

3 этап – текстны укыганнан соң эш. Бу этапта тәнкыйди фикерләүне үстерү технологиясеннән Синквейн, Алты эшләпә, Нәзек һәм калын сораулар алымнары отышлы

| ... ? | ... ? |
|---|---|
| • кем...<br>• нәрсә...<br>• кайчан...<br>• ... булырмы<br>• ... исеме ничек<br>• ... бар идеме<br>• ... белән килешәсеңме<br>• ... дөреме | • аңлатып кит, ни өчен...<br>• ни өчен ... дип уйлыйсың<br>• аерма нидә ...<br>• әгәр башкача булса, ...<br>• әгәр ... |

Әйдәгез бергәләп экранга карыйк. Анда Сезгә сорауның башлам өлеше тәкъдим ителгән. Безгә, беренчедән, әлеге сорауларның кайсы “нәзек”, кайсы “калын” булуын билгеләргә; икенчедән шул үрнәк нигезендә сораулар төзергә кирәк булыр.

- Хөрмәтле коллегалар, әйдәгез, сез төзегән сорауларга әйләнеп кайтыйк. «Нәзек һәм калын сораулар».

- Үзегез төзегән сорауны укыгыз әле. Сезнеңчә, бу нинди сорау?

Аны ничек билгеләдегез? (нәзек- сорау репродуктив җавап таләп итә. Җавап текстта өстә ята)

- Сезнең сорауны тыңлыйк. Бу нинди сорау? (калын) Аның калын булуын ничек билгеләдегез? (сорау тирәнтен фикерләүне, өстәмә мәгълүматлы булуны, синтез һәм анализ ясый белүне, чагыштыруны таләп итә).

- Бик дөрес, рәхмәт Сезгә!

Шулай ук укучыларга өй эше итеп чагыштырма таблица төзү, текстка план төзеп, аның нигезендә эчтәлек сөйләргә дигән эшләр бирү дә нәтиҗәле.

Очрашуыбыз ахырына якынлаша, хөрмәтле коллегалар, остаханә эшчәнлеге барышында хәтерегездә калган мәгълүматны кабат искә төшереп, нәтиҗә ясарга безгә Фишбоун алымы ярдәмгә килер.

"Фишбоун" ("Балык скелеты") — тәкъдим ителгән мәгълүматны сурәтле итеп күрсәтергә мөмкинлек бирүче график алым. Схемада нинди дә булса күренешнең проблемасы, сәбәпләре, фактлары һәм дә нәтиҗәсе чагылыш таба. Бүгенге фишбоун укучыларда аңлап уку күнекмәләре формалаштыруга багышланды. Фишбоун әзер, фокус группаның нәтиҗәсен тыңлап карыйк (фикерләр тыңлыны).

-Рәхмәт, димәк, бүгенге очрашудан һәркем үзенең алдагы һөнәри эшчәнлеге өчен файдалы мәгълүматны алып китә. Остаханә эшчәнлегенең истәлеге итеп, без Сезгә буклетлар бүләк итәбез. Рәхим итеп алыгыз, файдаланыгыз. Нәтиҗәле хезмәтегез өчен фокус группадагы һәркемгә рәхмәт белдерәбез. Мәктәптәге төп эшчәнлек төре буларак, укучычыларда текст белән эшләү өчен махсус уку күнекмәләре формалашкан булырга тиеш. Тәнкыйди фикерләү технологиясеннән Без тәкъдим иткән һәм аңлап уку күнекмәләре формалаштыруга ярдәм итүче алымнар Сезнең өчен файдалы булсын иде дигән теләктә остаханә үз эшен тәмамлый.

1нче кушымта







2нче кушымта

**Табигатьтә яңалыклар**

Март ахыры якынлашкач, беренче зур яңалык шул булды: кычыткан күбәләге оча башлады. Кирпеч төсле кызыл күбәләк. Шул кызыл өстендә вак кара таплар күренә. Юка канатлары читеннән кара кайма киткән, ә каймага зәңгәр таплар тезелгән. Күбәләк суыкны агач ярыгында уздырган һәм яз җиткәч уянган.

Бераздан үрмәкүчләр уянды, кайберләре кар өстендә сәяхәт итә башлады. Иртән кояш күренә — үрмәкүч терелә, кичен суыта — ул тагы үлеп куя. Бу төр үрмәкүчләрне сукбай дип йөртәләр, чөнки алар бөҗәкләрне ятьмәсез аулыйлар.

Март үтте дигәндә, сыерчыклар кайтты. Иң башта ата сыерчык күренде. Томшыгы сары, туны кара. Ул, туган яклар белән күрешеп, җир-суларны, урман-тугайларны сәламләп йөрде-йөрде дә, ана сыерчык килгәч, ояга парлашып кайтып төштеләр. Ана сыерчык исә бүтәнрәк: томшыгы кап-кара, тик оч тирәсендә бераз сарылык бар, каурыйлары шактый тимгеллерәк. Кояш күк битеннән төшәргә ашыкмый, чөнки җиргә яз хуҗа, һәм бөтен табигать үзгәреш, яңарыш кичерә.

**Сүзлек:**

| Чыганак сүз | Тәрҗемәсе | Аңлатмалы сүзлек |
|---|---|---|
| Кайма | 1.Кайм**а**<br>2.Окантовка | Нинди дә булса әйбернең, тукыманың һ.б. төсе, бизәге яки тукымасы белән аерылып торган чите, кырые. |
| Сукбай | Бродяга | Билгеле бер эше, кәсебе булмыйча, теләсә кайда йөри торган |
| Тимгелле | Пятнистый, крапчатый | Тимгеле булган, тимгелләр төшкән, таплы-таплы |
| Томшык | клюв | Кош авызының мөгез матдәле, очлаеп торган алгы өлеше, борыны |
| Ятьмә | Сеть | Җепләрне аркылы-торкылы итеп үреп, челтәрләп эшләнгән, балык, кош һ.б.ш. аулау өчен махсус җайланма |

*Куряева Людмила Петр кызы, Маслова Ирина Евгений кызы, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы «19нчы мәктәп» муниципаль бюджет белем бирү учреждениесе укытучылары*

**Татар әдәбияты һәм җәмгыять белеме дәресләрендә текстны уку һәм аңлау буенча функциональ грамоталылыкны үстерү**

Заманча мәктәпнең иң мөһим бурычларыннан берсе - функциональ белемле шәхесләр формалаштыру.

Нәрсә ул «функциональ грамоталылык"?

Функциональ грамоталылык– кешенең тышкы мохит белән мөнәсәбәтләргә керүе, анда тиз җайлашуы һәм эшләү сәләте. Функциональ грамоталылык нигезләре башлангыч сыйныфларда салына, анда сөйләм эшчәнлегенең төрле төрләренә – язуга, укуга, сөйләшүгә һәм тыңлауга интенсив өйрәтү бара.

Бүгенге көндә мәктәптә укуга һәм язуга өйрәтү академик максатлар белән генә чикләнә алмый, ул көндәлек тормыш һәм хезмәт эшчәнлеге белән бәйле функциональ һәм операцион максатларны да үз эченә алырга тиеш. Яңа дәүләт программасы укытучыларны укучыларның функциональ грамоталылыгын үстерүгә юнәлдерә. Туган телне өйрәткәндә текстны белүгә басым ясала, коммуникатив якын килү актуальләшә һәм мультикультура мохитенең үзенчәлекләре исәпкә алына.

Безнең алда тормыш өчен мөһим булган бурычлар тора:

1) "татар теле" фәнен өйрәнүгә карата уңай омтылышта булу, татар теле белән даими кызыксыну һәм шулар нигезендә белем алуның алдагы баскычларында татар телен уңышлы үзләштерү.;
2) төрле чыганаклардан мәгълүмат ала белү;
3) интернет челтәреннән белешмә таба һәм аны тәнкыйтьли белә алу;
4) чыганаклардан файдалана һәм аларга таяна белү;
5) таблицаларны, диаграммаларны, схемаларны, шартлы билгеләрне укый белү һәм аларны үз текстларыңны әзерләгәндә куллану;
6) текст белән эшләгәндә укуның төрле стратегияләрен тормышка ашыру.

Мәктәп үз укучыларын алган белемнәрен көндәлек тормышта кулланырга өйрәтергә тиеш.

**Текст белән эшләүнең нәтиҗәле алымнары**

Бүгенге шартларда текст белән эшләүнең бик күп метод һәм алымнары бар. Мәсәлән, үз алдыңа максат куя белүне формалаштырганда, башта укучылар укытучы җитәкчелегендә дәресләрдә максатчан эшләү тәҗрибәсен алалар. Аннары аларны мотивацияләү, эшчәнлекнең максат төшенчәсе һәм максатчанлык алгоритмы белән танышу оештырыла. Алга таба укучылар дәресләрдә һәм дәрестән тыш эшчәнлектә уку максатын куюның өйрәнелгән ысулын мөстәкыйль рәвештә куллана башлыйлар, килешенгән гомуми ысулларга нигезләнеп, үз гамәлләрен аныклый һәм төзәтә, үз-үзен

контрольдә тота белә башлый. Монда укучыларның функциональ грамоталылыгы формалаша, таләп ителә торган белеме ныгытыла, шуннан соң әлеге күнекмәләрнең оешканлык дәрәҗәсен укытучы контрольдә тота.

Мәсәлән, дискуссияләр, дебатлар методын мин 5 нче сыйныф укучылары белән эшләү практикасына кертә башлыйм. Өлкән яшьтә тәкъдим ителгән метод аеруча кызыклы, чөнки әңгәмәдәшнең теләсә кайсы төре белән элемтәгә керә белү, аралашу өчен элемтә булдыру, нормалар һәм кагыйдәләрне үтәп, әңгәмә тыңлау, әңгәмә коруны дәвам итү, кирәк булганда үз-үзләрен үзгәртү билгеле. Мондый метод укучыларга үз фикерләрен, карашларын иректе итеп чагылдырырга, шулай ук тормыш белән элемтә урнаштырырга мөмкинлек бирә.

Дәресләрдә мин шулай ук проектлар методын кулланам, презентацияләрне яклау, компьютер презентацияләрен булдыру һәм күрсәтү, шәхси кичерешләр, күңелсезлекләр, ышанычсызлык хисе белән бәйле кыенлыкларны җиңәргә ярдәм итәргә тырышам.

Шулай ук үз дәресләремдә укучыларның функциональ грамоталылыгын үстерү өчен түбәндәге биремнәр һәм сорауларны кулланам:

Аяз Гыйләҗев “Җомга көн кич белән”

- Дәресебез бер сулышта үтсен өчен нишлибез?

- Төп героойның ярдәмче геройлар белән мөнәсәбәте нинди?

- Әсәрне ничә өлешкә бүлдегез? Ярдәмче геройлар кемнәр?

- Бибинур кем ул? Бибинур ни өчен Габдуллаҗанга кияүгә чыга? Балаларны ничек тәрбияли? Гбдуллаҗанга кияүгә чыгып, Бибинур дөрес эшләдеме?

- Балаларның үсеп, кеше булгач, әниләренә мөнәсәбәтләре нинди? Бибинурны гаепле дип саныйсызмы? Бибинур карчык бу балаларга үги булмаса, хәл үзгәрер идеме? Гомере буе кешеләргә яхшылык эшләгән Бибинур “бәхет” сүзен ничек аңлый?

- Җиһангир кем ул? Нигә Бибинур аны хөрмәт итә? Ничек уйлыйсыз ут, буа тавышы нинди образлар?

- Аксыргак авылы сабан туена кемнәр кайта? Әби нинди тавыш ишетә? Авыл кешеләре әбине яратамы? Зәкиянең олы улы ни өчен Бибинурга мәк чәчәге төшерелгән күлмәклек бүләк итә? Ничек уйлыйсыз: бүгенге дәреснең темасы ничек яңгырар?

- Кемнәр алар маңкортлар? Бибинурның балаларын маңкортлар дип әйтеп буламы? Карабай нинди символ?

- Ни өчен Бибинурның балалары аналарын ташлыйлар? Моңа кем гаепле? Бибинурның изгелеге, шәфкатьлелеге нәрсәләрдә чагыла?

- Әсәрдә бәхетле кешеләр бармы? Бибинурны бәхетле дип әйтә алабызмы?

- Әсәрдә автор төп игътибарны кайсы геройга юнәлтә?

- Автор әсәрдә нинди шартлы-метафорик образ сурәтләр куллана?

- Аяз Гыйләҗевнең “Җомга көн, кич белән...” әсәрендә нинди проблемалар күтәрелә? Алар хәзерге заманда актуальме?

- Автор әсәрен ни өчен шулай атаган? Җомга сүзе нәрсәне аңлата?

- Әсәрдә фәлсәфи яссылыктагы нинди каршылыклар бар?

- Бибинур гәҗиттә язылачак мәкаләне ничек күзаллый? Сюжетта үзәк каршылык кемнәр арасында чыга? Илдә бу чорда урнашкан идеологик кануннар нәрсә китереп чыгарды?

9 нчы сыйныфта “Җомга көн кич белән» әсәре буенча дәресләрдә төрле бирем төрләрен кулланам:

1) ошаган цитатаны әсәр геройлары сөйләменнән сайлагыз һәм аның турында тезмә һәм иярченле кушма җөмләлр кулланып, кечкенә генә фикер языгыз.

2) геройларга характеристика бирергә, әсәрне укучы аңладымы икән? Нәрсә турында сүз бара?

3) Сиңа нинди характердагы сыйфатлар якын? Нинди геройларның кылган эшләрен беркайчан да эшләмәс идең? Ни өчен?

Мондый биремнәрне файдаланып, укучылар бу әсәрне яхшырак аңларлар һәм өйрәнгәнне үз тормышларында да куллана алырлар, дип уйлыйм.

Минем уйлавымча, күп кенә укытучылар текстлар белән эшләүгә үз карашларын үзгәрттеләр, текстларны һәм биремнәрне дөрес сайларга өйрәнделәр, алар укучыларда белемнәрне үстерүгә ярдәм итәчәк, аларны практикада, тормышта куллана алачак.

Хәзер мин бу эшнең бездә шул кадәр сыйфатлы һәм яхшырак башкарылуын аңлыйм.

Без күпчелек дәрәҗәдә берьяклы эшләдек: текстны укып, сөйләргә, гади сорауларга җавап бирергә. Хәзер мин филологларның гына түгел, башка коллегаларының да укучыларда функциональ грамоталылыкны үстерергә тиешлеген аңлыйм.

Хәзерге вакытта Россиядә финанс секторы икътисадның иң тиз үсүче тармакларыннан берсен тәшкил итә.

Яңа икътисадый фикерләүне формалаштыру - мәктәпнең иң мөһим бурычы.

Шуны истә тотарга кирәк, бүгенге балалар-булачак финанс базарында катнашучылар, салым түләүчеләр, вкладчылар һәм заемчылар.

Менә ни өчен укыту финанс грамоталылыгын иртә яшьтә башларга кирәк. Төп финанс төшенчәләрен белү һәм аларны практикада куллана белү кешегә грамоталы идарә итү, үз акчалата чаралары кулланырга ярдәм итә.

Шулай итеп, җәмгыять белеме дәресләрендә финанс грамоталылыгын формалаштыру өчен «икътисад» блогы буенча темаларны өйрәнүдә практик әһәмияткә ия булуны өстәргә һәм икътисадый бурычларны актив кулланырга кирәк.

Мәсьәләләрдә гаилә бюджетын төзү һәм исәпләү кебек мөһим темалар каралырга тиеш; банкларда һәм башка структураларда акчалата операцияләр; алыш-бирешләр белән бәйле куркыныч акчалата бүләкләр; финанс хезмәтләре өчен җаваплы органнар булу; кредит һәм депозитларның нечкәлекләре; акча агымнары белән идарә итү, банкларның агрессив сәясәте; актив һәм пассив керем һәм чыгымнар; иминиятләштерү һәм пенсия түләү; пластик карталар булу һәм аларны куркынычсыз куллану һ. б.

Уку процессында укучыларны әзер белемнәрне җиткерүгә юнәлдерелгән актив укыту формалары кулланырга мөмкин, аларны истә калдырырга, тыңлаучыга җиткерергә.

Укучыларның финанс грамоталылыгын формалаштыру ысуллары булып шәхси - эшчәнлек, интегратив, практик юнәлешле, компетентлы, субъектив, контекстлы тора.

Интеграцион метод эшкуарлык җәмәгатьчелеге, иҗтимагый оешмалар, 28 банк системасы, массакүләм мәгълүмат чаралары, ата-аналар җәмәгатьчелеге вәкилләренең укучыларның финанс грамоталылыгы күнекмәләрен формалаштыруда катнашуын күз алдында тота.

Практик юнәлешле алым мөһим мәсьәләләрне һәм килеп туган проблемаларны хәл иткәндә тәҗрибәне формалаштыруны һәм куллануны күз алдында тота, финанс белемнәре һәм җәмгыятьнең көндәлек тормышы арасындагы элемтәләрне ача.

Компетентлы караш реаль тормыш һәм уку процессын интеграцияләүгә юнәлдерелгән. Башка фән өлкәләрендә белем һәм эшчәнлек алымнарын куллану өчен нигез булып тора.

Субъектив якын килү укучыларның шәхси үсеше өчен шартлар тудыруны, аларның активлыгын һәм мөстәкыйльлеген күрсәтүне, тормышыңны һәм белемеңне практик үзгәртеп коруга һәм камилләштерүгә әверелдерүне күздә тота.

Контекстлы якын килү белем бирү процессының реаль тормыш белән якынаюын тәэмин итә, финанс контекстын Башка фән өлкәләреннән белем, осталык һәм күнекмәләрне куллану өчен эчтәлекле нигез буларак кулланырга өйрәтә.

Мәктәпнең төп бурычы - даими үзгәреп торучы дөньяда уңышлы булырга сәләтле баланы әзерләргә омтылу.

*Масаллимова Мәүлия Минвәли кызы,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы “32 нче гимназия” муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

**Сәләтле балалар белән эшләү алымнары**

Татар теле һәм әдәбияты укытучысы буларак, мин үземнең эш дәверемдә иҗатка сәләтле укучылар белән эшләү программасы төзедем. Үз эшемнең максат һәм бурычларын, принципларын билгеләдем. Хәзерге заман таләбе - баланың табигать тарафыннан бирелгән сәләтен үстереп, аны иҗади шәхес итеп тәрбияләү. Белгәнебезчә, укыту өлкәсендә сәләтле балаларны табу һәм аларның эшчәнлеген үстерү - хәзерге көндә төп бурычларның берсе булып тора. Без баланың сәләтен никадәр тизрәк күреп алабыз, үстерәбез, уңай шартлар тудырабыз, шул очракта гына көтелгән уңышларга ирешә алабыз. Хәзерге заман шартларында сәләтле балалар белән эшләү системасы зур җаваплылык сорый дип әйтергә кирәк. Ни өчен дигәндә, һәрбер кеше үзенең мөмкинлекләреннән, үз кызыксынуларыннан чыгып, киләчәк һөнәр сайлый, олы тормыш юлына аяк баса.

Олимпиада — ул башкалар белән көч сынашып, җиңү яулау гына түгел, ә күп өйрәнү, күп белү һәм шул белемеңне дөрес итеп куллана алу. Аңа әзерлек укытучыдан һәм укучыдан күп көч, түземлелек сорый. Бертуктаусыз эзләнергә, укырга, тел һәм әдәбият яңалыклары белән танышып барырга кирәк була. Олимпиадаларга юл гадәти дәресләрдән башлана. Әлбәттә, җиңүләр җиңел генә бирелми. Үземнең эш тәҗрибәмнән чыгып, олимпиадаларга ничек әзерләнүем турында кайбер фикерләрем белән уртаклашасым килә.

Олимпиадага әзерләнүдә беренче мөһим әйбер — ул ТЕЛӘК! Әгәр дә укучыда телне өйрәнү теләге юк икән, аның белән бушка вакыт уздырмаска тырышам.Сәләтле балалар белән эшләгәндә түбәндәге бурычларны куям:

- программа материалын бик яхшы белү;
- өстәмә  чыганаклардан мәгълумат алу;
- бөтен төр анализ үрнәкләрен белү;
- халкыбызның үткәне, бүгенгесе турындагы материалларны өйрәнү,  вакытлы матбугат белән кызыксыну, радио,телевидениедән татарча тапшыруларны карап бару;
- фикерләү сәләтен үстерү;
- мөстәкыйль  эшләргә өйрәтү.

Олимпиада биремнәренең төзелешенә килгәндә, гадәттә, беренче өлешне тестлар тәшкил итә. Җавапларны сайлап алу зур кыенлык тудырмаса да  аларны эшләү зур игътибарлылык сорый. Шуңа күрә бу өлештә ялгышлык җибәрмәс өчен биремне дөрес, аңлаганчы, кат-кат уку кирәклеген укучыларыма төшендерәм. Теоретик биремнәрне эшләп чыгар өчен, әлбәттә, укучыда теоретик белем дә булырга тиеш. Бу биремне эшләгәндә, терминнарны бутамау, сүзләргә дөрес билгеләмә бирү зарур. Кагыйдәләрне яттан белү дә комачауламый, шул ук вакытта «коры кагыйдә» язып кую укучының белемен күрсәтми, аларны мисаллар белән дәлилләп бирү дә кирәк.

Гамәли биремне үтәү өчен дә теорияне белү мөһим. Моны уңышлы башкарып чыгуны олимпиадага әзерлек вакытында һәрбер өйрәнгән теманы гамәли биремнәр белән ныгытып барырга кирәк. Монда анализлар турында да онытмаска (фонетик, морфологик, лексик, синтаксик анализлар). Олимпиада биремнәрен дә мондый төренә дә зур игътибар бирелә.

Кагыйдәләрне язып бару өчен аерым дәфтәр башлана. Кирәкле мәгълүматны язып бару — истә калдыруның бер ысулы булып тора, бу дәфтәр икенче уку елында да дәвам ителә. Кагыйдәләрдән тыш бу дәфтәрдә бик күп материаллар тупланып барыла. Иҗади биремгә туры килгән төрле темага иншалар да шул дәфтәрдә урын ала. Укучылар белән төрле платформаларда да эшне алып барабыз. Бигрәк тә ZOOM, LearningApps.org платформаларында эшләү бик отышлы.

Тырышып, үз эшеңне чын күңелдән яратып, вакытыңны кызганмыйча эшләсәң, иҗатка сәләтле балалар тагын да зур уңышларга ирешәчәк һәм калган укучылар арасында сәләтле балалар саны һичшиксез артачак, әлбәттә.

Начар мөгаллим хакыйкатьне бирә, ә яхшысы аны табарга өйрәтә», - дигән Дистервег. Безгә әзер белемне генә бирергә түгел, ә аны эзләп табарга өйрәтергә кирәк. Шул чакта гына укучыларыбыз *югары нәтиҗәләргә ирешер.*

*Миннегалиева Гөлназ Сәләхетдин кызы, Шаһиева Энҗе Рафаил кызы, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы 1 нче номерлы гомуми белем бирү мәктәбе муниципаль бюджет белем учреждениесенең югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучылары*

## Башлангыч классларда проект эшчәнлеге

Федераль дәүләт белем бирү стандартларына күчү шартларында укытучы эшчәнлегенең нәтиҗәле юнәлешләреннән берсе булып проектлар методы санала. Бу метод укучыларның өйрәнгән белемнәрен гамәли куллана белүләренә, мәгълүмати тирәлектә ориентлашу осталыкларына, иҗади фикерләү сәләтләренә нигезләнә.

Проектлар методы – укучы шәхесенең белем алуга иҗади якын килүенә юнәлтелгән укыту системасы ул. Ул мәктәптә укытучы җитәкчелегендә эшләнә торган мөстәкыйль иҗади эш. Проект эшчәнлеге – төпле фикере булган балалар тәрбияләү технологияләреннән берсе. Аның нигезе - тикшеренү эше.

Максаты: укучыларның шәхси үсешенә, уңышлы аралашуларына ирешү, аларны һәртөрле эшчәнлеккә иҗади якын килергә өйрәтү.

Проект эшчәнлеге укучыларда да, укытучыда да зур кызыксыну тудыра. Ул фикерләүне, сөйләмне, үз уйларыңны формалаштыра белү сәләтен үстерә. Проект

эшчәнлеге барышында укучы коллективта эшләргә, үзенә бирелгән эшкә җаваплы карарга, куелган сорауларга җавап табарга өйрәнә.

Башлангыч сыйныф укучысы өчен проект эшчәнлеге шактый катлаулы. Балада көтелгән нәтиҗәгә ирешүгә кызыксыну булганда гына, проблеманы чишүдә уңай мотивация тудырып, аның эшкә дәртен, мөстәкыйльлеген үстерергә мөмкин. Кече яшьтәге мәктәп балалары белән проект-эзләнү эше алып барганда, аларның белем дәрәҗәсенең югары булмавын, дөньяны күзаллауларының, мөстәкыйль анализлау һәм игътибар туплау сәләтенең тиешенчә формалашып җитмәвен истә тотарга кирәк. Шуңа күрә укытучы башлангыч сыйныф укучыларын эзләнү эшчәнлегенең беренче адымнары һәм алгоритмнары белән таныштыра. Проект методының төп өстенлеге, минемчә, укучыларның яңа белем туплап кына калмыйча, белем туплауның, бердәм хезмәтнең нәтиҗәсен булдыруда.

Башлангыч сыйныфларда түбәндәге төрдәге проектларны кулланып була:

тикшеренү (проблемалы ситуацияләрдән чыгу юлларын эзләү, көндәлек тормышта кирәк булырдай программалар тәкъдим итү); иҗади (бәйрәмнәр яки конкурслар өчен презентация, музыкаль бизәлеш, фото коллаж, видеоклип һ.б.);

мәгълүмати (темага караган мәгълүматларны җыю, аларны катнашучыларга тәкъдим итү, фикер алышу, нәтиҗә ясау); уен-проектлар.

Проект эшләүнең түбәндәге этапларын билгеләп үтәргә мөмкин.

1. Әзерлек этабы, аны “кереш өлеш” яки “проектка кереп китү” дип тә атарга мөмкин:

-проектның темасын, максатын һәм проблемасын билгеләү;

-проблеманың әһәмиятен нигезләү;

-проект башкару өчен укучыларның шәхси теләкләрен искә алып, төркемнәргә бүлү.

Укытучы бу этапта укучыларга проект өчен төрле темалар тәкъдим итә. Укучылар үзләре тәкъдим иткән темалар карала. Бу этап проектның иң демократик өлеше булып тора.Теге яки башка теманы сайлату өчен укучыга басым ясау, укучы башкарырга теләгән проектны кире кагу рөхсәт ителми.Укытучы ярдәме белән, укучылар үзләре кабул иткән проектның проблемасын, сюжетын, максат һәм бурычларын билгелиләр, куелган максатны тормышка ашыру юлларын эзлиләр.

2.Эшчәнлекне планлаштыру һәм проблемаларны чишү этабы яки “эшчәнлекне оештыру” дип тә атасак була (информация эзләү да шушында керә ала):

-мәгълүмат чыганакларын барлау, аны җыю һәм туплау;

-проблемалы ситуацияләрдән чыгу юлларын эзләү;

-киләчәк нәтиҗәне презентацияләү формасын һәм алымын сайлау.

Укучылар бу этапта мәгълүмат эзлиләр, җыялар, тәртипкә китереп анализлыйлар, эшне планлаштыралар; укытучы белән киңәшләшеп, киләчәк нәтиҗәне презентацияләү формасын һәм алымын сайлыйлар; әзерлек һәм планлаштыру эшенә үзбәя бирәләр.

3.Проектны тормышка ашыру:

-анализ юлы белән табылган мәгълүматларны бер бөтенгә берләштерү, нәтиҗәне дәлилле аңлату. Укучылар үзләре башкарган эшкә анализ ясыйлар, уңышларын һәм кимчелекле якларын ачыклыйлар, нәтиҗә чыгаралар.

4.Проектны яклау, проект эшчәнлегенең нәтиҗәләрен бәяләү этабы.

Укучылар проектны презентациялиләр, башкаларны эш нәтиҗәләре белән таныштыралар, сорауларга җавап бирәләр, эшчәнлекләренә үзбәя бирәләр.Бу этап бигрәк тә әһәмиятле булып тора.Һәрбер проект уңышлы тәмамланырга тиеш. Проект эшенә ата-аналарны да җәлеп итү бик отышлы, ата-ана бала тормышында актив катнаша башлый.

Укытучы: киңәшче, юнәлеш бирүче, төзәтмәләр кертүче, рухландыручы,

илһам өстәүче.

Укучы: эзләнүче, идеяне тормышка ашыручы, мәгълүмат җыючы, фикерләүче,күзәтүләр нигезендә модель төзүче, барлыкка килгән нәтиҗәләрне анализлаучы, тәҗрибәләр үткәрүче, интернет материалларын кулланучы, проектны яклаучы.

Ата- ана: укучыга кирәкле мәгълүматны табарга ярдәм итүче, идеяләрне тулыландыручы, иҗади бала белән бергә кызыксынучы, бала белән көндәлек аралашучы ролен үтәүче.

Балалар эшенең күрсәткече: 1-4 классларда рәсем, инша,табышмак, шигырь, сүзлек һәм башкалар булырга мөмкин.

Проект эшенең нәтиҗәсе: 1-2 классларда мәгълүмат тупланган китап яисә альбом, 3-4 классларда проект эше презентация, сценарий, фильм, каталог һ.б ярдәмендә башкарылырга мөмкин.

Укучыларга проект эшчәнлегенә йомгак ясаганда:

1.Проект эшендә нәрсә кызыклы булды?

2.Аеруча нәрсә ошады?

3.Нинди яңалыклар белдең?

4.Бу теманы өйрәнүне дәвам итәр идеңме?

5.Киләчәктә нинди проект эшен дәвам итәр идең? -кебек сораулар бирергә була.

Йомгаклап шуны әйтәсебез килә: проект методын кулланганда уйлау мөмкинлекләре киң ачыла, логик фикерләү дәрәҗәсе үсә, төрле чыганаклар белән мөстәкыйль эшләргә,

төрле чыгышлар ясарга өйрәтә. Ә иң кыйммәте - аларда үз нәтиҗәләрен күргәннән соң иҗат дәрте кабынуы.

*Минегалиева Ләйсән Ризат кызы,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Муса Җәлил исемендәге “1 нче гимназия” муниципаль бюджет белем бирү учреждениесенең беренче категорияле башлангыч сыйныф укытучысы*

## Дәрестә тәрбия потенциалын күтәрү - укыту-тәрбия процессын оештыруның мөһим шарты

Һәр сабый тумыштан килә торган үзенчәлекләргә ия, әмма аның нинди булып үсүе тәрбиягә бәйле. Бала мәктәпкә йөри, белем һәм тәрбия ала. Бу вакыт аның гомерендә иң катлаулы, иң күңелле чор. Мәктәпне тәмамлагач, баланың кем булуы, кешеләр арасында ничек яшәве мәктәп елларының ничек узуына бәйле. Белем алу – авыр хезмәт. Ул зур тырышлык, түземлек һәм киеренке эш таләп итә. Шуңа күрә балада ихтыяр көче тәрбияләү бик мөһим. Андый тәрбия үз алдыңа максат куярга һәм аңа ирешергә бөтен көчне, сәләтне, игътибарны тупларга өйрәнүдән башлана.

Барлык әсәрләрдә дә рәхимлелек, гаделлек, яхшылык,матурлык бар. "Яхшылыкка яхшылык белән җавап бирерләр”, "начарлык эшләсәң, җәзасын алырсың” , "кешеләрне хөрмәт итсәң, үзеңне дә хөрмәт итәрләр” кебек тәрбияви моментларга зур урын бирелә. Бу исә эзлекле фикер йөртергә өйрәтә, укучының сөйләм телен үстерә.Уку дәресләрендә класстан тыш уку дәресләре үткәрелә. Укучы бирелгән тема буенча әзерләнә, укый, рәсемнәр ясый. Шулай итеп тырышлык тәрбияләүдә әдәбиятның да әһәмияте зур. Класстан тыш уку баланың гомуми культурасын үстереп кенә калмый, ә аның танып белү активлыгын стимуллаштыра, шәхси мәнфәгатьләрен канәгатьләндерә, кызыксынуын арттыра.

Укучы үзен кызыксындыра торган һәм уен кебек мавыктыргыч эшләрне генә ихлас күңел белән башкара. Шулай булмаганда, ул бик арый, игътибарын туплый алмыйча, як-ягына карана яисә бөтенләй башка нәрсә белән шөгыльләнергә керешә. Шуңа күрә дәрес планын кызыклы һәм тәрбияви яктан уйлап төзергә кирәк.Тәрбияви моментны аерым түгел, ә дәреснең һәрбер этабында бергә бәйләп алып барыла. Алар бер-берсен тулыландырып торалар һәм шәхес формалаштыруда, тәрбияләүдә, үстерүдә зур роль уйныйлар. Дәрестә экиятләр, төрле темадагы хикәяләр укыганда укучы персонажлар урынына үзен куеп карый, уңай һәм тискәре сыйфатларны анализлый. Дәрестә план төзиләр, аның буенча сөйлиләр һәм рольләргә бүлеп укыйлар. Шул рольгә үзләрен куеп карыйлар һәм үзләрендә кайсы сыйфатларны булдырырга, кайсыларын бетерергә

уйланалар. Укытучы "шулай булырга кирәк,болай ярамый” дип түгел, ә укучы үзе аңлап үзендә уңай сыйфатлар тәрбияли белергә тиеш. Татар теле дәресләрендә һәрбер теманы үткәндә темага бәйләп табышмаклар, мәкальләр, төрле шигырьләр укыла, җаваплар табыла. Бу да тәрбияви чара булып тора,чөнки халык авыз иҗаты балада уңай хисләр тәрбияли, кызыксыну уята.

Укытучының сәләте дәресне үткәрүдә генә түгел, ә аны ничек итеп оештырудан да тора. Үзенең предметын чын күңелдән яратып,тәрбия потенциалын күтәрү өстендә эшләргә тиеш. Бары тик төпле белемле, әхлаклы укытучы гына шәхес тәрбияли ала. Укытучының шәхси сыйфатлары һәм һөнәри осталыгы яшь буынны тәрбияләүгә зур йогынты ясый. Укучыларда үзенә карата хөрмәт, ышаныч һәм ярату хисләре тәрбияли алса гына, укытучы иң абруйлы, дәрәҗәле шәхес була ала. Укытучының үз-үзен тотышы, тәртибе аралашуы дәрес атмосферасына, укучыларның укуына тәэсир итә. Чыннан да укытучы матур итеп, күңелгә үтеп кererлек итеп сөйли белгәндә генә дәрес җанлы рәвештә бара. Һәр дәрестә укучыга үзенең иҗади потенциалын, үзаңын,үзтәрбиясен үстерергә мөмкинлек бирергә кирәк. Дәреснең нәтиҗәлеге аңа ничек әзерләнүгә, дәреснең планына, укыту методларының ничек сайлап алынуына бәйле.Укыту методларын дөрес сайлап алу һәм оста чиратлаштыру, тәрбия методларыннан уңышлы файдалану,йомшак өлгерүчеләргә теләсә кайсы моментта ярдәм итәргә әзер булу,аларда үз көчләренә ышаныч тудыру,эшкә дәрт уяту – болар барысы да дәреснең яхшы сыйфатлы булуы өчен мәһим шарт булып тора.

"Мөмкинлекләре һәм сәламәтлекләре чикләнгән укучыларны киләчәк тормышка әзерләү” не истә тотып дәрес планын төзергә,укучылар белән эшләгәндә моны онытып бетермәскә тиешбез. Укучыларның кайберләре аз аралашучан, класстагы иптәшләре белән дә уртак тел таба алмыйлар. Андыйларга алдагы тормышта кешеләр белән аралашырга бик авыр була. Шуңа күрә дәрестә генә түгел, ә класс сәгатьләрендә дә бу эшне дәвам итәргә кирәк. Мәсәлән: "Үз-үзеңне дөрес тота белү”, "Кешеләр белән аралаша беләсеңме?”,”Мин кунакта” кебек темаларга сөйләшкәндә укучыларда кешелеклелек,миһербанлылык, дустанә мөнәсәбәт тәрбияләнә.Дәрес планын төзегәндә мөһим тәрбияви моментларны билгеләү, укучыларда ата-аналарга, иптәшләренә карата миһербанлылык, яхшы мөнәсәбәт, милләтара дуслык,хөрмәт, ярдәмчеллек хисләрен тәрбияләү,иҗади фикер йөртү сәләтен үстерүне максат итеп куям. Ярдәмгә карточкалар, аңлатмалы сүзлекләр, мәкальләр, табышмаклар алына.

Укытучы укучыда шәхес күрә белергә, аңа индивидуаль якын килә белергә тиеш. Көчле укучылар дәрес материалын бик тиз үзләштерә һәм уңай җавап бирә.Алар мактала, үрнәк итеп куела. Ләкин класста көчлеләр генә түгел, ә көчсез укучылар да була. Аларга

җиңелрәк биремнәр биреп ирешелгән уңышларын күреп мактарга була. Шуңа күрә дәресләрдә укучыларның мөмкинлекләреннән чыгып аларны группаларга бүләбез һәм төрле авырлыктагы биремнәр бирәбез. Кирәк булганда көчлерәк укучылар 2, 3 группага ярдәм итә. Бу вакытта бер-берсенә карата игътибарлылык, кешелеклелек сыйфатлары тәрбияләнә.

Тәрбия эшендә җибәргән ялгышларын мәктәптән эзләргә тырышучы ата-аналар да очрый. "Безнең бурыч – баланы ашатып – эчертү, киендерү, ә аны тәрбияләү – мәктәп эше",-диләр андыйлар. Чынбарлыкта исә баланың холкы, үз-үзен тотышы, әхлакый сыйфатлары иң элек гаиләдә формалаша. Мәктәп белән гаиләнең бәйләнеше ныгый барган саен, балаларыбыз тәрбиялерәк, уңышларыбыз да зуррак булыр.

Йомгак ясап шуны әйтергә була: укытучы үзенең предметын чын күңелдән яратып, тәрбия потенциалын күтәрү өстендә эшләгәндә генә аның дәресләре кызыклы һәм үтемле, балалар да тәрбияле булыр.

*Мөбарәкшина Рузилә Рәшит кызы,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «32 нче гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең беренче категорияле туган тел һәм әдәбияты укытучысы*

**Башлангыч сыйныфларда туган (татар) тел һәм әдәби уку дәресләрендә фәнни-эзләнү эшен оештыру**

Укучыларны фәнни-эзләнү эшенә әкренләп 1 нче сыйныфтан ук җәлеп итәргә кирәк. Балаларның уңышлары бу төр эшчәнлекнең югары нәтиҗәле булуын дәлилли. Укучылар фәнни-гамәли конференцияләрдә, конкурсларда катнашып призлы урыннар яулыйлар. Иң мөһиме фәнни конференцияләргә әзерләнү укучыларның иҗади һәм танып белү сәләтен, логик фикерләвен үстерә.

Фәнни-эзләнү эшен оештыру этаплары

| Фәнни-эзләнү эшенең эчтәлеге | Укучы эшчәнлеге | Укытучы эшчәнлеге |
|---|---|---|
| **I этап: әзерлек** | | |
| Фәнни эш турында беренчел күзаллау булдыру, темага карата кызыксындыру уяту максатыннан кереш әңгәмә үткәрү. | | |
| **II этап: фәнни-эзләнү эшчәнлеген оештыру** | | |
| Белемнәрне актуальләштерү | | |
| 1. Фәнни хезмәтнең темасын, | Тема буенча укытучы белән | Һәр укучыга |

| | | |
|---|---|---|
| структурасын, эчтәлеген сайлау, максат-бурычларын билгеләү.<br>2. Эштә катнашучылар санын билгеләү. | фикер алышу, максат кую. | алдан ук әзерләнгән карточка, белешмәлек тапшыру. Максат-бурычларны билгеләргә ярдәм итү. |
| План буенча эшләр | | |
| 1. Мәгълүмат чыганакларын билгеләү.<br>2. Мәгълүматны җыю һәм анализлау алымнарын планлаштыру.<br>3. Фәнни-эзләнү эшен тәкъдим итү, яклау формаларын уйлау. Мәсәлән:<br>- сәяхәт, реклама һ.б.<br>- фильм, макет, җыентык һ.б.<br>-конференция, бәйрәм һ.б.<br>4. Эш нәтиҗәләрен бәяләү критерийларын эшләү.<br>5. Катнашучыларның вазифаларын билгеләү. | Төп алымнарны билгеләү:<br>- китаптан уку;<br>- күзәтү;<br>- интернеттан карау;<br>- әти-әниләрдән, белгечтән сорау;<br>- үзлектән фикер йөртү;<br>- телевизордан карау һ.б.<br>Проблеманы ачу өчен сораулар уйлау. (Без моны ни өчен эшлибез? Нинди проблеманы хәл итү максатыннан эшлибез?) | Идеяләр тәкъдим итү, гипотезаны чыгару, эшнең вакытын билгеләү. |
| Эзләнү эшчәнлеге | | |
| Мәгълүмат җыю, проблеманы тикшерү, ачу, аны чишүдә дөрес вариантны сайлау, эшне бизәү. Эшнең төп формалары: сораштыру, күзәтү, тәҗрибә, фәнни һәм әдәби чыганакларны өйрәнү һ.б. Экскурсияләр оештыру, экспериментлар үткәрү һ.б. | Эзләнүләр үткәрү, бурычларны чишү, фәнни хезмәтләрне укып анализлау эше башкарыла. Укучылар тиешле урыннарны билгеләп баралар, аларның кайберләрен язып та алалар. | Күзәтү, киңәшләр бирү, тиешле фикерләрне җиткерү. |

| Нәтиҗәләр | | |
|---|---|---|
| Мәгълүматны анализлау. Нәтиҗәләр чыгару. | Мәгълүматны анализлыйлар, нәтиҗәләр чыгаралар | Күзәтү, киңәшләр бирү |
| **III этап: әзер эшне тәкъдим итү (презентацияләү)** | | |
| Төрле формада эш нәтиҗәләрен тәкъдим итү. | Укучылар үз фикерләрен яклый белергә, аны яклау өчен, дәлилләр, фактлар китерергә, сорауларга җаваплар таба белергә тиешләр. | Әзер эш белән танышу, эшкә карата сораулар бирү. |
| **IV этап: эш нәтиҗәләрен бәяләү** | | |
| | Эшне бәяләүдә коллектив фикер алышу һәм үзбәя. | Берничә номинация тәкьдим итеп һәм һәр проект нинди дә булса бер номинациядә җиңәрлек итеп оештыру отышлы. |

2020 нче елда мин үземнең укучыларыма Бөек Ватан сугышының 75 еллыгы уңаеннан, “Сугыш чоры икмәге” темасына фәнни-эзләнү эше язарга тәкъдим иттем. 1 нче сыйныф укучылары Мөбарәкшин Илгиз, Юнысова Ралия бик теләп риза булдылар. Алар үзалларына “Сугыш чоры икмәге нинди булган?” дигән проблемалы сорау куеп, шул сорауга җавап эзләргә керештеләр. Хезмәтебезнең максат-бурычларын билгеләдек. Кирәкле мәгълүматны без шәһәребезнең Габдулла Тукай исемендәге үзәк китапханәдән, авылда сугыш чорында яшәгән әби-бабайлардан сорашып табарга булдык. Китапханәдә Алмазов Б. А. «Наш хлеб», Дзенискевич А.Р. «Непокоренный Ленинград», Ходза «Дорога Жизни» китаплары белән таныштык. Әлеге әсәрләрне укыгач укучыларда хезмәтебезгә карата кызыксыну тагын да артты. Авылда яшәүче тыл ветераннарыннан сугыш чорында нинди икмәк белән тукланганнары турында белештек. Темага карата мәгълүматны туплаганнан соң, эш планын төзедек. Эш нәтиҗәсен сугыш чоры икмәгенең рецептлары язылган буклет формасында тәкъдим итәргә булдык.

Алга таба укучылар үзләренең сыйныфташлары белән “Безнең буын икмәк кадерен беләме?” дигән темага сораштыру үткәрделәр, нәтиҗәләр чыгардылар.

Мәгълүматны туплап, анализлап, фәнни һәм әдәби чыганакларны өйрәнеп, күзәтү, сораштырулар үткәргәннән соң, "сугыш чоры икмәген" укучылар үзләре пешереп, тәмен татып караганнан соң, без хезмәтебезнең нәтиҗәсе итеп, сугыш чоры икмәге рецептларыннан торган буклет чыгардык.

Әлеге һәм башка хезмәтләр белән без күп кенә конференция һәм конкурсларда катнашып призлы урыннар яуладык.

| Конференциянең исеме | Эшнең темасы | Укучы | Сыйныф | Нәтиҗә |
|---|---|---|---|---|
| IV Региональная научно-практическая конференция «Мы – будущее XXI века» | «Сугыш чоры икмәге» | Мөбарәкшин Илгиз, Юнысова Ралия | 1 д | 1 нче урын |
| V Региональная научно-практическая конференция «Создание историко-культурного и духовного наследия России» | «Иске Комазан мәктәбе тарихы» | Мөбарәкшин Илгиз, Святова Ксения | 1 д | 2 нче урын |
| XVIII Республиканская юношеская научно-исследовательская конференция имени С.С. Молодцова | "Сугыш чоры икмәге" | Мөбарәкшин Илгиз, Юнысова Ралия | 1 д | 3 нче урын |
| Региональный этап всероссийского фестиваля творческих открытий и инициатив «Леонардо» Республики Татарстан | "Сугыш чоры икмәге" | Мөбарәкшин Илгиз, Юнысова Ралия | 1 д | 2 нче урын |
| Региональный этап всероссийского фестиваля творческих открытий и инициатив «Леонардо» Республики Татарстан | "Иске Комазан мәктәбе тарихы" | Мөбарәкшин Илгиз, Святова Ксения | 1 д | 3 нче урын |
| XI Республиканский конкурс исследовательских работ и проектов школьников «Дебют в науке» | "Иске Комазан авылы топонимикасы" | Мөбарәкшин Илгиз | 2 д | 1 нче урын |
| V Региональная научно- | "Иске Комазан | Мөбарәкшин | 3 д | 1 нче |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| практическая конференция «Создание историко-культурного и духовного наследия России» | авылы топонимикасы” | Илгиз | | урын |

Гомумән, фәнни-тикшеренү конференцияләрендә катнашу сәләтле балаларның характерын тәрбияли, иҗади хезмәттәшлеккә этәрә, максатка ирешү юлында ныклыкка әзерли, укучы үзенә һәм үзенең эшләгән эшләренә таләпчән мөнәсәбәт булдыра.

*Мулламөхәммәтова Рәсимә Риф кызы,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Муса Җәлил исемендәге “1 нче гимназия” муниципаль бюджет белем бирү учреждениесенең югары категорияле химия укытучысы*

**Кеше химия мохитендә**

Укучылар эшчәнлеген оештыруның бер формасы булып тикшеренү эше тора, ул укучыларның иҗади эшчәнлеген үстерә. Балалар нинди дә булса мәгълүмат алып, аны үзләре дә тормышта куллана алалар.

Әгәр дә балачак дөньясына әйләнеп кайтсак, элек без кызыксынучан булдык, нинди булса да тәҗрибәләр уздырырга теләдек. Чөнки тәҗрибә балага ниндидер яңалык, мәгълүмат өчен ишек ача. Шулай итеп бала үзе нәрсәдер уйлап чыгарса, уйлап тапса, гомер буе ул аны онытмаячак. Монда Сухомлинскийның сүзләрен искә төшерү урынлы булыр: «Парта артында эшсез булу- иң куркынычы; көн саен 6 сәгать эшсезлек, айлар, еллар буе эшсез булу - бу кешенең рухын сындыра, фикер йөртү сәләтен, эшчәнлеген юкка чыгара».

Укытучының бурычы-баланы фикер йөртергә өйрәтү. Моның өчен эшне кызыксындырырлык, уйланырлык итеп төзергә, укырга этәргеч бирергә кирәк. Укыганда, уйлаганда, фикер йөрткәндә кеше мәгълүматны биш сенсор канал аша кабул итә: ишетү, күрү, ис һәм тәм сизү, тоемлау. Психологлар 4 төп үзләштерү төрләрен аерып күрсәтә: аудиаллар, визуаллар, кинестетиклар, һәм дигиталлар.

**Аудиаллар**- мәгълүматны ишетү каналы аша кабул итә.

**Визуаллар**- мәгълүматны күбесенчә күз күреме белән кабул итә торган кешеләр.

**Кинестетиклар**- мәгълүматның күп өлешен башка тойгылар – тоемлау, хәрәкәтләр, сизү аша үзләштерәләр.

**Дигиталлар**- мәгълүматны, күбесенчә, логик фикерләү, тамгалар, саннар, логик дәлилләр аша кабул итүче кешеләр.

Укытучы дәрескә әзерләнгән очракта сыйныфта үзләштерү ягыннан шушындый төр укучылар барлыгын истә тотарга тиеш. Мин дәресләрдә химик тәҗрибәләр ярдәмендә

укучыларны күрү, ишетү, сизү, тоемлау сәләтләрен үстерүне максат итеп куям. Дәреснең бу этабында укучылар төркемнәргә бүленәләр: визуаллар, аудиаллар, кинестетиклар, дигиталлар.

Химик тәҗрибәләр үткәрү сәбәпле, куркынычсызлык кагыйдәләрен искә төшереп китү зарури.

Кинестетиклар-тәҗрибә үткәрү өчен кирәк булган матдәләр белән таныштыралар һәм тәҗрибә үткәрәләр. Визуаллар тәҗрибә турында аңлатма бирәләр, үзгәрешләрне билгелиләр. Аудиаллар тәҗрибәнең химик реакцияләрен язалар. Дигиталлар шушы тәҗрибә турында реклама рәвешендәме, шигырь форматындамы, тормышта кулланылу дәрәҗәсендәме сөйлиләр.

Тәҗрибә үрнәкләрен китерик: беренчесе: кинестетиклар тәкъдим ителгән матдәләрне (тимер(III)хлориды эремәсе, калий роданиды эремәсе)бергә кушалар. Визуаллар реакциянең барышына аңлатма бирәләр һәм реакциядә килеп чыккан матдәнең кан кебек кызыл төскә үзгәрүен күзәтәләр.

Аудиаллар тигезләмә язалар: $FeCI_3+3KCNS \rightarrow Fe(CNS)_3+3KCI$

Дигиталлар фикерләрен реклама рәвешендә тәкъдим итәләр: үзгәрүчән, төсе кызгылт – куе, туендырылган була, яңа төс барлыкка килә.

Икенчесе: кинестетиклар тәкъдим ителгән матдәләрне (бакыр (II) сульфаты эремәсе, натрий гидроксиды эремәсе) бергә кушалар.

Визуаллар реакциянең барышына аңлатма бирәләр һәм реакциядә килеп чыккан матдәнең зәңгәр төстәге утырым булуын күзәтәләр.

Аудиаллар тигезләмә язалар: $CuSO_4+2NaOH \rightarrow Cu(OH)_2+Na_2SO$

Дигиталлар фикерләрен реклама рәвешендә тәкъдим итәләр: утырым зәңгәр күк төсендә барлыкка килә, каплый, мөһим эш башкара.

Дәреснең икенче этабында төркемнәрне урыннары белән алмаштырырга мөмкин.

Өченчесе: кинестетиклар тәкъдим ителгән матдәләрне ( натрий карбонаты, хлорид кислотасы эремәсе) бергә кушалар.

Визуаллар реакциянең барышына аңлатма бирәләр һәм реакциядә газ барлыкка килүен күзәтәләр.

Аудиаллар тигезләмә язалар: $Na_2CO_3+2HCl \rightarrow 2NaCl+H_2O+CO_2\uparrow$

Дигиталлар фикерләрен реклама рәвешендә тәкъдим итәләр: газ төссез, чыҗлый, тавыш чыгара, өскә менә.

Дүртенчесе: кинестетиклар тәкъдим ителгән матдәләрне( коры ягулык, магний порошогы) бергә кушалар.

Визуаллар реакциянең барышына аңлатма бирәләр һәм реакциядә якты очкыннар барлыкка килүен күзәтәләр.

Аудиаллар тигезләмә язалар: $2Mg+O_2 \rightarrow 2MgO$

Дигиталлар фикерләрен реклама рәвешендә тәкъдим итәләр: якты төсле очкыннар ялтырый. Монда шигырь дә төзеп була: реакция ахырга хәтле бара, әгәр дә утырым барлыкка килсә, газ аерылып чыкса, төсе үзгәрсә, яисә җылыну бүленеп чыкса. Ягъни сизү, күрү, тоем органнары аша реакцияне билгеләп була.

Нәтиҗә ясап шуны әйтәсем килә: балалар белән эшне төзегәндә, укучылар дәрес буе информацияне барлык сенсор каналлар буенча кабул итәрлек итеп төзергә кирәк. Дәрес ахырына укучылар күреп кенә калмыйлар, сөйләп тә күрсәтәләр, нәтиҗә дә ясыйлар, анализлыйлар, тормыштан кулланырга, сизгерлеккә өйрәнәләр. Аларга укырга да җиңел һәм кызык булачак, һәм әйләнә-тирәне дә тулы бер бөтен дөнья итеп кабул итәчәкләр.

*Нурмиева Резидә Равил кызы,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы «10нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең беренче категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

**Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә проект методын куллану**

Бүгенге көн белем бирү системасы заман белән бергә атлый. Укытуда яңа технологияләр куллану хәзерге заман мәктәбенең таләпләренә туры килә. Бүген үк инде белем бирү системасын камилләштерү, белем сыйфатын үстерү юллары эзләнелә. Җәмгыятькә иҗади фикерли белүче, аралашучан, талантлы кешеләр сорала. Мәктәпләрдә шундый һәр яктан килгән шәхесләр тәрбияләүгә укучы шәхесенә юнәлдерелгән яңа педагогик технологияләр куллану ярдәмгә килә.

Укыту процессында яңа педагогик технологияләрне куллану - яңа метод һәм алымнарны үстерергә, яңача эшләргә ярдәм итә. Мин, татар теле һәм әдәбияты укытучысы –Нурмиева Резидә Равил кызы, дәрестә өйрәнгән теманы җиңел юл белән үзләштерә торган, белем сыйфатын күтәрүгә файдалы булган проектлар технологиясен дәрестә куллану уңай күренеш дип саныйм.

Проект методы эшчәнлегенең эпиграфы итеп түбәндәге юлларны кулланыр идем: "Сөйлә миңа - мин онытырмын, күрсәт - истә калдырырмын, кызыксындыр - өйрәнермен."

Проект эшчәнлеге укучы шәхесенең белем алуга иҗади якын килүенә юнәлтелгән. Бу метод белән эшләгәндә, укучылар актив рәвештә уйлау, фикерләү эшчәнлегенә тартылалар.

Гомумән, проект методы - баланың интеллектын, иҗади сәләтен, логик фикерләвен үстерүдә нәтиҗәле алымнарның берсе булып тора дип уйлыйм мин.

Проект эшчәнлегенең нигезе - эзләнү-тикшеренү эше. Эшнең уңышлы килеп чыгуы - аның дөрес планлаштырыуына бәйле. Монда укытучы, укучы һәм ата-ана хезмәттәшлеге бик әһәмиятле. Проект методы укытучы һәм укучыларның яхшы әзерлеген, сыйныфның һәм иҗади төркемнәрнең үзара килешеп эшләүләрен таләп итә. Проект турында сөйләшүдә катнашып, укытучы да тигез хокуклы фикердәшкә, ярдәмчегә әйләнә. Проектны гамәлгә ашыру барышында укучылар әйләнә-тирәдәгеләр белән уртак тел табып эшләргә, фикерләрен дәлилләргә өйрәнә.

Проект эшенең нәтиҗәсе булып, мәгълүмат тупланган китап, буклет, брошюра, реклама, плакат, альбом, сценарий, фильм, ярдәмлекләр, доклад, презентация торырга мөмкин.

**Проект эшчәнлеген оештыруда эшне планлаштыру этаплары:**

1.Проектның темасын, структурасын, эчтәлеген сайлау.

2. Проблеманы ачу өчен сораулар уйлау. (Без моны ничек эшлибез? дигән сораудан түгел, ә ни өчен эшлибез? Нинди проблеманы хәл итү максатыннан эшлибез? дигән сорауларга җавап эзләүдән башлана.)

3.Тиешле мәгълүматны табу юлларын ачыклау. Катнашучыларның вазифаларын билгеләү ( бала эшчәнлеге, укытучы эшчәнлеге)

4.Проект туплау( мәгълүмат җыю, проблеманы тикшерү, ачу, аны чишүдә дөрес варианты сайлау).

5. Проектны тәкъдим итү, яклау формаларын уйлау. Төрле формада эшләргә була.

6. Проектны бәяләү. Урыннар билгеләп, ярышка әйләндерү киңәш ителми. Берничә номинация тәкъдим итеп һәм һәр проект нинди дә булса бер номинациядә җиңәрлек итеп оештыру отышлы була. Мәсәлән, истәлекле, бизәлешле, оригиналь, дус, кызыклы, файдалы, үрнәк проект.

7. Проектның перспективасын билгеләү. Иң мөһиме - игътибарсыз калмаска тиеш. Иң әһәмиятле фактор - балалар үз эшләренең кирәклегенә төшенсеннәр һәм аның башка кешеләргә шатлык, рәхәтлек китерүен күрсеннәр.

Проект дәресләрне башлангыч сыйныфларда ук үткәрә башларга кирәк. Әлбәттә, 1-2 нче сыйныф укучылары, яшь үзенчәлекләреннән чыгып караганда, проект эшчәнлеген тулысынча башкара алмыйлар. Башлангыч сыйныфларда татар теленә өйрәтү уен

формасында алып барыла. Әлеге алымны проект методына кертеп, инде кечкенәдән үк бу эшчәнлеккә әзерли башларга була. 1-2 нче сыйныфлар проект дәресләрне үти алмасалар да, бу әле мини-проектлар үткәреп булмый дигән сүз түгел. Моның өчен мин укучылаврграна билгеле бер алгоритм бирәм, ә укучылар үзләренең эшчәнлеген шуның буенча төзиләр. Башлангыч сыйныфларда шундыйрак темалар тәкъдим итәргә була:

- “Минем гаиләм”
- “Көндәлек режим”
- “Ел фасыллары” һ.б.

Мәсәлән, беренче сыйныфларда гаилә темасын өйрәнгән вакытта мин сыйныфны берничә төркемгә бүлеп, һәр балага аерым бер гаилә әгъзасы турында сөйләргә һәм аның рәсемен ясарга, дигән бирем бирәм. Мини-проектның максатын гаилә темасын өйрәнә башланда ук әйтәм. Шуңа балалар бик кызыксынып, һәр сүзне истә калдырырга тырышып эшлиләр.

Эшләренең нәтиҗәсе күп очракта рәсемнәр була. Алар үз фикерләрен рәсемнәрдә чагылдырырга тырышалар, кыска җөмләләр яки сүзләр ярдәмендә аңлатма кертәләр. Иң яратып башкарган эш формалары- коллажлар төзү.

Үз эшемдә бу методны урта сыйныфларда еш кулланам. Рус телле балаларга татар телен өйрәтүдә әлеге методны уңышлы дип саныйм.

Проект методын беренче тапкыр кулланганда, миндә икеләнү хисе көчле иде. ”Мондый дәрес барлык укучыларга да ошармы? Куелган проблемалар алдында югалып калмасលармы? Үзләре генә мөстәкыйль рәвештә эшли алырлармы? Нәтиҗәсе ничегрәк килеп чыгар? “ - дигән сораулар борчыды. Шуларны уйлап, мин җиңелрәк проблемалар, гадирәк темалар сайларга тырыштым. Эшне башлап җибәргәндә үк инде, укучыларның күзләрендә очкыннар кабынды. Проектның этаплары аңлатылу белән алар кызыксынып эшкә тотындылар. Шуннан соң узган проект дәресләр бик теләп кабул ителде, укучылар парларда да, төркемләп тә проект эшләрен башкардылар.

Укытуда проектлаштыру уку процессының сыйфатын үстерүгә ярдәм итә. Укучылар мәгълүмат алу өчен өстәмә чыганаклар эзлиләр, табылган материалны анализлыйлар, төп һәм кызыклы булганнарын аерып чыгаралар, сүзлекләр белән эшлиләр, тәкъдим итү формасын сайлыйлар. Хәзерге заман укучылары бигрәк тә заманча технологияләр кулланып эшләргә яраталар, шуның өчен презентациягә өстенлек бирәләр.

Үз эшебездә укучыларга кызыклы булган темалар сайларга, милли төбәк компонентына күбрәк игътибар бирергә тырышабыз. Бу алар күңелендә туган яклары белән горурлану хисләре уята, яңа мәгълүмат белән танышырга ярдәм итә. Проект дәресләр өчен кызыклы булган бик күп темалар тәкъдим итәргә була: 7нче сыйныфта

Татарстан табигате бүлеген өйрәнгән вакытта, “Шәһәребез тирәсендә нинди елгалар ага”, “Түбән Камада нинди чишмәләр бар, аларның тарихы”. 9нчы сыйныфта Һөнәрләр бүлеген үзләштергән вакытта, 1 төркемгә -“Тәбән Кама Шин заводында нинди һөнәр ияләре эшли”, 2нче төркемгә – Түбән Кама нефть һәм химия заводында нинди һөнәр ияләре эшли”

Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә проект методын куллану зур әһәмияткә ия. Чөнки укучылар татар телендә генә аралашырга тырышалар, төрле яклы фикер йөртергә өйрәнәләр, эзләнү вакытында төрле кызыклы мәгълүматларга юлыгалар, шуны башкаларга җиткерергә ашыгалар .

*Пахомова Гөлшат Әсхәт кызы, Чевачина Розалия Вакыйф кызы, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы «29 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучылары*

## Нәтиҗәлелеккә ирешү юллары

Бүгенге көндә җәмгыятьтә бара торган үзгәрешләр уку - укыту системасының барлык өлкәләренә дә яңача якын килүне таләп итә. Укучыларны хезмәткә, тормышка әзерләү, аларга сыйфатлы белем бирү - дәүләтнең мәгариф учреждениеләре алдына куйган мөһим бурычы. Гамәлгә кертелгән яңа буын стандартлары моңа кадәр яшәп килгән гадәти дәресләр, тәрбия чаралары белән генә чикләнеп калмыйча, яңача эш итүне таләп итә. Укучыларга белем бирүне генә түгел, ә аларны белем алырга, алган белемнәрен тормышта кулланырга өйрәтүне төп максат итеп куя. Бу исә бездән белем бирүнең яңа алымнарын һәм методларын кулланып эш итүне, бүгенге көн таләпләренә җавап биргән дәресләр оештыруны таләп итә.

Бүгенге көнне мәктәпләрдә туган телләрне өйрәнү төркемнәре ата-аналар язган гаризалар нигезендә туплана. Кызганычка каршы, беренче сыйныфларга килгән татар балалары арасында татар телендә иркен сөйләшә, аралаша белә торган балалар юк диярлек, шуңа күрә ата-аналар аларны рус телле укучылар программасы нигезендә укытырга бирәләр.

Рус телле балаларны татар теленә өйрәтүнең төп максаты - аларны бу телдә сөйләшергә өйрәтү. Шуңа күрә дәресне оештыруның төрле алымнарын кулланып, балаларны мөмкин кадәр активрак сөйләмгә тартырга тырышырга, чөнки балаларның татар теле дәресләренә йөрүе, кызыксынуы шуңа бәйле.

Дәреснең беренче минутларыннан ук сүзнең нинди тавыш белән әйтелүе, йөзнең нинди кыяфәттә булуы бик тә мөһим. Дәреснең башыннан ук укучыларның игътибарын дәрескә юнәлтергә һәм иркен сөйләшү теләге уятырга кирәк.

Шушы максатта һәр дәрестә акрынлап оештыру моменты өчен кирәкле булган фразалар кертелә бара.

- Бүген сыйныфта кем дежур?
- Бүген сыйныфта мин дежур.
- Ничәнче число?
- Беренче февраль.
- Атнаның нинди көне?
- Дүшәмбе көне.
- Бүген көн нинди?
- Бүген көн җылы (салкын, җылы, җилле, кояшлы, яңгырлы...).
- Бүген тышта ничә градус салкын (җылы)? Һ.б. сораулар.

Алдагы дәресләрдә дежур укучылар бу сорауларны сыйныфташларына бирәләр, дөрес җавап алуга ирешәләр.

Шулай итеп бу оештыру өлеше дәреснең фоны булып тора. Дәрес оешкан рәвештә, тыныч кына башланса, шулай узып та китә.

Төрле темалар өйрәнгәндә дежур укучылар дәрес темасы белән бәйләнешле сораулар бирәләр:

“Гаилә” темасына -

1. Синең әниеңнең (әтиеңнең) исеме ничек?
2. Әниеңә (әниеңә) ничә яшь?
3. Ул кайда эшли?
4. Әниең (әтиең) кем булып эшли?

Гади эчтәлекле мондый әңгәмәнең үзенчәлеге шунда: ул бик тиз үткәрелергә тиеш.

Укучылар белән аерым зур дәфтәр башлыйбыз, башка сыйныфларда ул тулыландырып барыла. Бу дәфтәргә җырлар, текстлар, табышмаклар, такмаклар, тизәйткечләр, фразеологик әйтемнәр, шигырьләр, мәкальләр һ.б. языла. Бу дәфтәрне “Тылсымлы дәфтәр” дип атыйбыз! Ни өчен? Чөнки ул балаларга “5”ле алырга да ярдәм итә. Һәр дәрестә диярлек “Кемнең “5”ле аласы килә?” дигән рубрика үткәрелә. Мәсәлән: Бүген “5”ле аласы өчен, сезгә Габдулла Тукайның “И туган тел, и матур тел” шигырен сөйләргә (я: “Сәлам!”, “Безнең мәктәп” һ.б. җырларны искә төшерергә, дуслык турында мәкальләр, санамышлар, табышмаклар, такмаклар, тизәйткечләр һ.б. әйтергә). Шулай итеп дәрестә уңышка ирешү ситуациясе тудырыла! Бу алым дәрестә үткән темаларны истә

тотарга, онытмаска ярдәм итә. Билгеле, укучыларның бу биремнәрне үтәгәндә хаталары була. Аерым билге хаталар тапкан балаларга куела. (Бу укучылар игътибар белән тыңласыннар өчен кирәк).

Дәрес - бала тормышының дәвамы, бер мизгеле. Заманча дәрес - баланың урамдагы, өйдәге, елга буендагы һ.б. тормышының дәвамы, бала шәхесе үсү тарихының бер өлеше. Ел дәвамында дәрестә укучыларның туган көннәрен билгеләп үтәбез. Дәрестә туган көннәре белән котлау – тормышларының дәвамы.  Бу күп вакыт алмый, ләкин файдасы зур. Такта янына чыгып, кулларга кул тотынып, “Ак калач “ җырын җырлыйбыз. Шуннан соң теләкләр әйтәбез. Сыйныфта уңай халәт тудырыла. Һәрбер дәреснең үзенә хас социаль - психологик климаты була. Туган көне булган дәресләрдә бигрәк тә укучыларның бер - берсе турында кайгыртучанлыгы, ягымлылыгы күренә. Бу шартларда балалар уңышка ирешәләр.

Сөйләргә өйрәтү алымнарының иң киң таралганы - диалог. Сөйләшү күнекмәләрен үстерү өчен укучыларны парлап эшләтү уңышлы. Укучы сорау бирергә тиеш! Җавап бирергә тиеш! Диалогсыз бер дәрес тә узмый.

Иң беренче чиратта балаларга аралашырга кирәкле ситуацияләр сайлап  алына. Аралашуның максаты һәм мотивы була. Укучы өйрәнелгән диалогны кирәклеген аңлый, шунда гына балаларда телне өйрәнү теләге барлыкка килә һәм үсә. Ел буена диалоглар күп җыела, һәм алар дәресләрдә еш кабатлана. “Мәктәптә”, “Дәрестә”, “Ашханәдә”, “Китапханәдә”, “Азык - төлек кибетендә”, “Билет кассалары янында”, “Чәчтарашханәдә” һ.б.

Диалогларда саннарны да кулланырга өйрәтәбез, чөнки кешенең бөтен тормышы саннар белән бәйле.

Мәсәлән, диалог “Азык - төлек кибетендә”.

- Исәнмесез!
- Исәнмесез!
- Сездә нинди ашамлыклар бар?
- Бездә ипи, сөт, май  бар. Сезгә нинди ашамлыклар кирәк?
- Миңа ипи кирәк. Бер ипи ничә сум тора?
- Бер ипи утыз сум тора.
- Ничә ипи кирәк?
- Ике ипи кирәк!
- Мәгез, алыгыз!
- Рәхмәт, сау булыгыз!

Телдә аралашуга өйрәтүнең башлангыч этабында төп чара булып уен тора. Уен-тел үзләштерү өчен мотив та, бер үк вакытта чара да. Дәрестә куллану өчен уен төрләре бик күп: сюжетлы-рольле уеннар, табышмаклар, кроссвордлар чишү, экиятләр сәхнәләштерү.

Әкиятләр сәхнәләштерү барысына да бик ошый. Үзләренә таныш һәм яраткан экиятләрне алабыз. (“Шалкан”, “Теремкәй”, “Төлке белән Торна”, “Йомры икмәк” һ.б.). Башта әкиятнең эчтәлеге белән танышабыз, геройлар турында фикер алышабыз. Сәхнәләштерү дәресендә балаларның сәләтләрен истә тотып, рольләрне бүләбез, бер укучы да читтә калмый. Мондый уен рус телле балаларга татар телен кызыксынып үзләштерү өчен яхшы стимул булып тора.

Рус телле балаларны сөйләшергә өйрәтүнең берничә алымына гына тукталып үттек. Туктаусыз эзләнеп, эшнең яңа алымнарын табып, татар телен киң рәвештә куллану, аны саклап үстерү - безнең беренче максатыбыз.

Ләкин нинди генә алымнар, заманча технологияләр, дәреслекләр, методик әсбаплар кулланылмасын, тирән акыллы, дәресне артист дәрәҗәсендә оста бирә торган укытучыдан башка телне өйрәнү авыр.

Һәр милләт өчен иң моңлы көй - милли көй, иң матур тел - милли тел. Әнә шуны тоеп, ләззәтләнеп яшәгәндә кеше эшләргә һәм укырга сәләтлерәк, бәхетлерәк була. Шундый бәхетне югалтмас өчен генә дә без ана телен белергә һәм сакларга тиешбез.

Бөек шәхесебез Ризаэтдин Фәхретдин әйткәнчә, һәрбер кеше үз кулыннан килгән кадәр эш эшләргә, байлык вә һөнәр һәм дә сәнәгать өлкәләрендә милләтнең күтәрелүенә ярдәм кылырга тиеш. Бу фикер бүген дә үз көчендә кала.

**Файдаланылган әдәбият.**

1. Хайдарова Р.З. Научно-педагогические аспекты билингвального образования в Республике Татарстан - Набережные Челны, 2006.–197 с.
2. Махмутов М.И. Современный урок и педагогические технологии развития мышления /Составитель Д.М.Шакирова/ – К.: Магариф-Вакыт, 2016. - 375 с.
3. Шәкүрова М.М., Гыйниятуллина Л.М. Башлангыч сыйныфларда «Туган тел» предметын укыту: яңартылган эчтәлек һәм перспективалар. Методик ярдәмлек.- Казан, 2018. - 40 б.
4. Шәкүрова М.М., Гыйниятуллина Л.М. 5-9 нчы сыйныфларда «Туган тел» предметын яңача укыту. Методик ярдәмлек.- Казан, 2018. -36 б.
5. Сафиуллина И.Н. Коммуникативная игра как средство реализации проблемного подхода в обучении // Магариф, 2000. - №10. – С.69-70
6. Козлова Р.Б. Язык как основа развития коммуникативных способностей // Магариф. - 2010. - №2. – С.30-32.

*Солтанов Радик Ибраһим улы,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Муса Җәлил исемендәге “1 нче гимназия” муниципаль бюджет белем бирү учреждениесенең беренче категорияле тарих һәм җәмгыять белеме укытучысы*

**Тарихны укытуда укучыларның иҗади сәләтләрен үстерү өчен мәсьәләләр куллану**

Бүген, кызганычка каршы, яшь буынның тарихны өйрәнүгә карашы тиешле баскычка күтәрелде диеп әйтеп булмый әле. Моның сәбәпләре бик күп төрле. Ләкин төп сәбәп – битарафлык, предмет белән кызыксынуның түбән булуы.

Минемчә, тарихны өйрәтүдә отышлы чараларның берсе – укучыларның иҗади фикерләү сәләтен үстерү. Соңгы вакытта, яңа федераль дәүләт белем бирү стандартларына күчү сәбәпле, бу бигрәк тә актуаль. Яңача белем таләп-ләренә нигезләнеп, укучыларның иҗади активлыгын үстерү, белемнәрне мөстәкыйль рәвештә куллана белүче, заманга яраклашкан шәхесләр тәрбияләү –укытучылар алдында торган төп бурычларның берсе.

Иҗади эшләүче укытучы беркайчан да дәреслектәге күнегүләр белән генә чикләнми, ул үз укучыларының сәләтенә һәм мөмкинлекләренә туры килә торган биремнәрне, методик алымнарны башка дәреслек һәм кулланмалар-дан да сайлап ала. Мин кемнеңдер эш системасын яки ул куллана торган технологияне алу кыен дип уйлыйм. Һәр педагог, үзенең мөмкинлегенә, иҗади карашларына, укучыларның ихтыяҗына карап , үз эш алымнарын булдырырга тиеш. Иң мөһиме - белем сыйфаты, эшнең нәтиҗәлелеге. Шул очракта гына укучының фән белән кызыксынуы арта, ул дәрестә алган белемне төрле ситуцияләрдә кулланырга өйрәнә, кыскасы, иҗади фикерләүче шәхес формалаша.

Тарихны өйрәнү өчен укучыларның иҗади фикерләү сәләтен үстерүдә төп ысул булып тикшеренү эшчәнлеге тора. Укучы эзләгәндә, чагыштырганда аның акыл үсешендә алга китеш була. Моңа балаларга продуктив биремнәрне системалы эшләү нәтиҗәсендә ирешеп була.

Мин үземнең эшемдә Россия тарихына караган мәсьәләләр кулланам. Алар тормышчан, шул ук вакытта катлаулы теоретик материалны үзләштерүдә гамәли якын да, актуаль да. Дәресләрдә балаларның игътибарын, күзәтү-чәнлеген , иҗади күзаллавын, логик фикер йөртүен үстерү өчен шартлар булдырырга кирәк. Шулай эшләгәндә, укучы теләсә нинди очракта да, әйтик читенрәк мәсьәләләрне чишкәндә дә югалып калмый. Тарих фәнен өйрәнүдә иҗади фикер йөртергә һәр укучыны да өйрәтеп була, әмма фикерләүнең дәрәҗәсе тигез була алмый. Шуның өчен дә бу төр күнегү-ләрнең катлаулана

баруы, күләме буенча да төрле булуы шарт. Дәрес җитди дә, кыен да, шатлыклы да булырга тиеш.

Мәсьәләләр балаларда тарих белән кызыксыну уята, аларның битарафлыгын бетерергә булыша. Алар укучы белән укытучы арасын якынайта, иҗади хезмәттәшлеккә этәрә, балага тарих фәненә мәхәббәт уятырга ярдәм итә.

Сезнең игътибарга берничә шундый тарихи мәсьәлә тәкъдим итәм:

1 нче мәсьәлә

Рус дәүләте күпмилләтле ил буларак формалаша. Кайбер халыклар бу дәүләткә я үзләре теләп кушылалар, яисә яулап алыналар (Кавказ, Урта Идел, Урал алды, Себер, Урта Азия һ.б.). Көнчыгыш Европа тигезлегендә славян-нарга кадәр үк яшәп яткан кабиләләр булган, алар бу территориянең төп халкы - аборигеннар булып торалар. Рус милләтен барлыкка китерүдә бу кабиләләрнең өлеше зур. Кемнәр алар?

2 нче мәсьәлә

860 еллар тирәсендә Византия патриархы Фотий Константинополь диварлары янындагы хәлне күзәтеп, болай дип яза: «Тупас һәм рәхимсез халык шәһәр яны бистәләрен талый, барысын да юк итә, кылычы белән һәлак итә! ... Кем соң бу ... Әйтеп бетергесез байлыкка һәм гүзәл югарылыкка ирешкән халык ... Үзләре бездән әллә кайларда еракта яшиләр ... кораллары белән горурланалар?» Сүз кемнәр турында бара?

3 нче мәсьәлә

Бу кенәзнең кушаматы «Карт» («Старый»). Ул 33 ел буе Рус җирендә кенәз була. Елъязмаларда ул куркак, ялкау һәм ихтыярсыз идарәче буларак сурәтләнә. Дружинасы да аңардан риза булмый: «ярым ялан-өс йөрибез», дип зарлана. Бу кенәзне ясак түләүче халыклар «ач бүре» дип тә йөрткәннәр. Кем ул?

4 нче мәсьәлә

«Әсирләрне карадым, - диде Добрыня воевода Владимир кенәзгә, — аларның аякларында күн итекләр. Болардан без ясак түләтә алмыйбыз, байлар буылып үлсәләр дә түләмиләр инде алар. Безгә үзебез кебек чабаталыларны эзләргә кирәк». Нинди вакыйга турында сүз бара?

5 нче мәсьәлә

1030 елда Чуд күленең көнбатыш яр буенда төзелгән бу шәһәрне төзетүче кенәзнең исеме белән Юрьев дип атыйлар. Соңрак бу шәһәрне немецлар Дерпт дип, XX гасырда эстонлар Тарту дип атаганнар. Шәһәрне кем һәм ни өчен төзеткән?

6 нче мәсьәлә

Рус җиренең көньягында яшәүче җир эшкәртүчеләр авыр сабан кулланганнар, төньяк территорияләрдә исә җирне гади җиңел сука белән эшкәрткәннәр. Төрле җир эшкәртү коралларын куллану сәбәбе нәрсәдә?

7 нче мәсьәлә

IX-XI гасырларда община вервь дип йөртелгән. Эшләгән җинаяте өчен гаепле кеше штраф-вира түләгән. Мәсәлән, огнищанинны (кенәз идарәчесе, вотчина башы) үтергән өчен 80 гривна (4 кг көмеш) штраф каралган. Ә кыргый вира нәрсә ул?

8 нче мәсьәлә

XIV-XV гасырларда җирбиләүчелекнең төп, привилегияле төре булып вотчина тора. Кайсыбер очракта аны дедина дип тә йөрткәннәр. Шул ук вакытта шартлы җирбиләү барлыкка килә, ул билгеле бер хезмәтләр, бурычлар, йөкләмәләр башкарган өчен бирелгән. XII гасырда шартлы җирбиләү хуҗасын милостник - рәхимлелек иясе дип атаганнар. Сүз нинди җирбиләүчелек турында бара?

9 нчы мәсьәлә

1327 елда Тверь шәһәрендә шундый хәл була. Базарның кызган чагында Чолхан исемле татар (ул баскак буларак билгеле) рус дьяконының атын тартып ала. Дьякон дусларын, танышларын ярдәмгә чакыра. Чиркәүләр чаң кагып шәһәр халкын вечега чакыралар. Җыелган халык татарларга каршы баш күтәрергә карар кабул итә. Баш күтәрүчеләр татарларны, кенәз түрәләрен үтерәләр. Чолхан һәм аның якыннары кенәз йортына кереп качалар, тик аны баш күтәргән халык ут төртеп яндыра. Чолхан иптәшләре белән шунда һәлак була. Бик аз гына исән калучылар Урдага качып китәләр.

Шушы вакыйганың нәтиҗәсе Тверьның көндәше Мәскәү кенәзе Иван I өчен генә түгел, ә барлык Рус җире өчен уңай булып чыга. Ни өчен?

10 нчы мәсьәлә

Дмитрий Донскойның улы Василий I хан кулыннан ярлыкны Мәскәү кенәзлеген идарә итү өчен генә түгел, ә шуңа өстәп Түбән Новгород, Мещера, Тарту һәм Муром җирләрен дә ала. 1385нче елда Аксак Тимер (Тимур, Тамерлан, Тимерләнк) гаскәре Алтын Урдага каршы походка юнәлә. Татар гаскәре Үкә елгасы буендагы Елец шәһәре тирәсенә килеп җитә. Митрополит Киприан дәһшәтле Аксак Тимернең басып керүен булдырмас өчен Владимир анасы иконасын дошманга каршы алып чыгарга киңәш бирә. Чыннан да, Елецка килеп җиткән Урта Азия хакиме гаскәрләре Рус җиренә басып керми. Бу хәлне православие руханилары иконаның могҗизалы булуы белән аңлаталар. Сез ничек аңлатырсыз?

Җаваплар:

1. Фин-угор кабиләләре.

2. Сүз славяннар турында бара. Киев Русе барлыкка килгәнче үк славян кенәзләре Царьградка (Константинопольгә) һөҗүмнәр оештырганнар.

3. Игорь кенәз, Рюрикның улы. Хакимияткә 912 елда, Олег кенәз үлгәннән сон килә. Древляннар тарафыннан җәзалап үтерелгәндә (945 ел) Игорьга 70 яшь тирәсе була.

4. 985 елда булган рус-болгар сугышы турында. Бу сугышта көмеш болгарлар җиңеләләр; руслар җиңүдән табышланмыйлар - Добрыня тәкъдиме белән алар һәм болгарлар арасында «мәңгелек» килешү төзелә.

5. Ярослав Мудрый; чудь кабиләсенә үзенең хакимиятен урнаштыру өчен.

6. Көньякта туфракның уңдырышлы катламы тирән; төньякка киткән саен уңдырышлы катлам юкара, шуңа күрә монда тирән сөрә торган сабан кулланып булмаган.

7. Кыргый вира ул - бердәм җаваплылык. Җинаятьче ачыкланмаган очракта штрафны шушы округта яшәгән барлык кешеләрдән түләткәннәр.

8.Поместье – алпавыт җирбиләүчелеге.

9. Иван I Калита, форсаттан файдаланып, Мәскәүнең күптәнге көндәше Тверь кенәзлеген ут һәм кылыч белән үтеп аны көчсезләндерә; Урда тарафыннан рус җиренә көчләп тагылган, халыкларда нәфрәт тудырган баскаклык системасы бетерелә; Үзбәк хан ясак җыю вазифасын Иван Калитага тапшыра.

10. Тимурның төп максаты - аңа хыянәт иткән Туктамышны юк итү була. Аны эзәрлекләп ул чигенүче дошманы артыннан куа бара. Рус җирендә сугышлар алып бару Аксак Тимернең уенда да булмый.

Чит ил һәм үзебезнең ил галимнәре тикшерү нәтиҗәләре күрсәткәнчә, эшчәнлекнең теге яки бу төре белән җитди шөгыльләнгәндә, теләсә нинди кеше иҗат сәләте ачылуга билгеле бер көч, юнәлеш ала.

Укучы фикерен кискен тәнкыйтьләргә ярамый, ә бәлки үз фикереңне тәкъдим, киңәш рәвешендә әйтү зарур. Чамасын белмичә тәнкыйтьләү, кисәтүләр ясау баланың мөстәкыйльлеген, иҗади сәләтен үстерергә комачаулый.

Иҗади сәләтне үстерүдә хыяллана белү дә зур әһәмияткә ия. Бу сыйфатка ия булучыларны хупларга һәм аларны күңелдә «образ», «ачышлар» булдырырга өйрәтергә, моның өчен балаларда хыяллана, күз алдына китерә белү күнекмәсе тәрбияләргә, төрле көтелмәгән хәлләр туганда аптырап калмаска өйрәтергә, хыялны үстерү өчен төрле күнегүләр үткәрергә кирәк.

Балаларның үзләренчә фикер йөртүен, мөстәкыйльлеген, яңа фикер әйтүләрен хупларга, үз фикерләрен яклый белү күнекмәсе булдырырга кирәк. Балалар үзләрен иркен тотканда, үз көчләренә ышанганда, теге яки бу мәсьәләне көтелмәгәнчә, үзләренчә хәл итәләр.

Иҗади сәләтне үстерүдә укучыларның «дивергентлы» фикерләвен (латинчадан тәрҗемә иткәндә, төрле юнәлештә фикерләү дигән мәгънәне белдерә) камилләштерү дә мөһим шарт булып

тора. Чит ил галимнәре билгеләп үткәнчә, дивергентлы фикерләүгә 4 төп сыйфат хас. Алар түбәндәгеләр: тизлек, төрлелек, төгәллек, шәхеснең үзенчә фикерләве. Тиз фикерләү дигәндә, укучының күп санда идея, фикерләр әйтүен истә тотарга кирәк. Бу очракта аларның сыйфаты түгел, саны истә тотыла. Мәсәлән, мондый сораулар биреп, баланы рухландырырга мөмкин: «Әйдә үзеңне сынап кара әле: син сорауга ничә төрле җавап бирер идең икән?», «Тагын нәрсә эшләргә була?» һ. б. ш.

Иҗади сәләт үстерүне үзагымына куярга ярамый, чөнки кызыксынучанлык, яңалыкка омтылу, мөстәкыйльлек кебек сыйфатлар балачакта формалаша.

**Әдәбият исемлеге**

1. Бакулина Г. Укучыларның интеллектуаль сәләтләрен үстерү. - Казан, Мәгариф нәшр., 2001.

2. "Мәгариф" журналлары, №5, 1998; №5, 2006; №8, 2006; №12, 2006.

3. Хуҗиәхмәтов Ә. Н. Педагогика.- Казан, Матбугат йорты нәшр., 2000.

4. Хуҗиәхмәтов Ә. Н. Тәрбия дәресләре. - Казан, Матбугат йорты нәшр., 1998.

*Степанова Роза Александр кызы,*
*Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы “Кызыл Тау “Аленушка” балалар бакчасы”ның беренче квалификацияле тәрбиячесе*

## Балаларны татар халкының гореф – гадәтләре, йолалары, бәйрәмнәре үрнәгендә тәрбияләү

Соңгы елларда халкыбызның гореф-гадәтләренә, йолаларына һәм бәйрәмнәренә игътибар арта башлады. Шул уңайдан күп кенә бәйрәмнәребез яңадан халык арасына кереп бара. Татар халкының йола-бәйрәмнәрен, гореф-гадәтләрен торгызу һәм яңарту безнең “Кызыл тау “Аленушка” балалар бакчасында да актив алып барыла. Рус балалар бакчасы булуга карамастан, милли бәйрәмнәр һәм гореф-гадәтләр, балаларыбызны халык культурасы белән таныштыру, монда зур урын алып тора. Ниһаять, безнең бабаларыбызның онытыла барган бәйрәмнәре, аларның гореф-гадәтләре, яңадан әйләнеп кайта башлады. Безнең бурычыбыз, шушы милли бәйрәмнәрне, уеннарны һәм йолалаларны киләсе буынга, балаларга өйрәтеп калдыру.

Татар халкының уй, холкы, фикере, барлык йолалары, гореф-гадәтләре, традицияләре үзебер тәрбия ысулы булуын күрсәтә. Аларны өйрәтү балаларның рухи үсешенә этәргеч була. Баланың гаиләдә, коллективтагы тәрбияви нормалары, кагыйдәләре халык педагогикасына салынган. Һәр халыкның милли мәдәнияте - ул табигать көчләренә баш ию дигән сүз.

Кечкенә балаларны милли тәрбия һәм мәдәнияте белән таныштыру төрле тәрбия алымнарына нигезләнеп башкарыла. Иң киң таралган ярдәмче чыганагыбыз булып балалар фолькларын әйтергә була. Ул –тән хәрәкәтләрен ритмга, көйгә салучы үзенә бер төр иҗат. Аларның нәфислек тойгыларын, зиһен һәм хыял йөгреклеген, зәвыкларын үстерү һәм шуларның барысы бергә бала шәхесе өчен тәрбияви әһәмияткә ия. Бармак уеннары, санамышлар, алдавыч әкиятләр, җырлы-биюле уеннар - болар барысы да бала өчен кызык.

Нәкъ менә шушы алымнар, безнең балар бакчасында да балаларны тәрбияләүдә һәм белем бирүдә зур урын алып тора.

Бу юнәлештә балаларга белем бирүдә торган бурычлар:

1.Балаларны уеннар, җырлар, шигырьләр, җырлы-биюле уеннар, бәйрәмнәр аша татар халкының гореф-гадәтләре, йолалар белән таныштыру.

2.Халык авыз иҗатына, бизәкләргә, кул эшләренә кызыксыну уяту. Аларны танып әйтә белергә өйрәтү.

3.Татар халкының бай мирасына мәхәббәт тәрбияләү.

Үз халкының телен, мәдәниятен өйрәткәндә балаларны башка халыкларның тарихы, мәдәнияте белән таныштыру бик мөһим. Бәйрәм иртәләре балаларда туган телгә һәм татар сәнгатенә ихтирам тәрбияләү, халкыбыз гореф-гадәтләрен, йолаларын торгызу максаты белән үткәрелә. Бәйрәмнәр балаларда әдәп-әхлак сыйфатлары тәрбияли, шәфкатьле, игелекле, миһербанлы кеше итеп үстерүдә ярдәм итә.

Халык бәйрәмнәре ул халыкны милләт итеп берләштерә торган чараларның берсе. Һәр милләтнең үзенә генә хас бәйрәмнәре була.Татар халкының Балалар бакчаларындаүткәрелә торган бәйрәмнәр балаларда күркәм сыйфатлар тәрбияләргә ярдәм итә.

Төп өлеш

Иң кече яшьтәге баллар белән без татар халык уеннарыннан – бармак уеннары һәм бишек җырлары өйрәнүдән башлыйбыз. Кече яшьтәге балаларһәр нәрсәне уен аша җиңел үзләштерә.Бармак уеннарында мәсәлән,авазларның яттан әйтү күнекмәләре ныгый,сәнгатьле әйтелеш үстерелә. Шулай ук мимика, пластик хәрәкәтләр барлыкка килә, бармак, кул мускуллары ныгый. Кечкенә балаларга белем һәм тәрбия бирүдә бишек җырлары бик зур роль уйный. Алар сабыйның тыныч холыклы булып үсүенә ярдәм итә. Әнисенең җырлары аша ул туган телендә сүзләр әйтергә, тирә-якны танып белергә, фикерләү сәләтен, сөйләмен үстерергә өйрәнә. Игътибар иткәнегез бардыр, балалар, бигрәк кызлар, курчаклы уйнаганда, аларны «ә-ә-ә итә» дип, үзләренчә йоклаткандай итәләр. Димәк, бишек җырлары балага тулысынча аңлашылып бетмәсә дә, беркадәресе

аның зиһенендә, күңелендә барыбер сакланып кала. Бишек җырлары - баланы ничек яшәргә, кешеләргә ихтирамлы, мәрхәмәтле булырга, ата-ананы, туганнарын хөрмәт итәргә өйрәтә, туган теленә, милләтенә мәхәббәт тәрбияли.

Ел саен без үзебезнең балалар бакчасында татар халык бәйрәмнәрен үткәрәбез: “Аулак өй”, “Сөмбелә”, “Каз өмәсе”, “Нәүрүз”, “Карга боткасы”, “Сабантуй”. Балалар халкыбызның бәйрәмнәре, гореф-гадәтләре белән танышалар, яңа җырлар, биюләр, такмаклар өйрәнәләр. Татар халык ашлары, киемнәре белән танышалар. Балалар татар халык уеннарында бик кызыксынып катнашалар.

Яңа уку елына аяк басу белән,безнең балалар бакчасында уңыш бәйрәме, алтын көзне каршылау “Сөмбелә” бәйрәме белән башланып китә. Елның сихри фасылында, көн белән төн тигезләшкән мәлдә, татар халкы Сөмбелә бәйрәмен үткәргән.

Өлкәннәр көненә безнең балалар бакчасында күп еллар хезмәт иткән өлкәннәребезгә күмәк, җырлы- биюле “Аулак өй” исемле театр-тамаша әзерлибез.

«Аулак өй»нең нәрсә икәнен мөгаен һәр кеше дә беләдер, чөнки бу гореф гадәт бик борынгыдан килә. Элек, олылар туганнарына яисә эшләре буенча киткәч, кызлар үзләре генә калганнар һәм кунакка дус кызларын чакырганнар. Озакламый аларга егетләр дә килеп кушылган. Зур һәм шаян төркемдә бию һәм җыр, мәзәкләр сөйләү башланган. Егетләр һәм кызлар милли татар уеннары уйнаганнар. Нәкъ менә шул «Аулак өй» татарларның гореф гадәте булып киткән. «Аулак өй» бәйрәмен үткәргәндә без балалар белән төрле халык уеннарын өйрәнәбез . Мәсәлән, «Йөзек салыш», «Түбәтәй», «Ефәк элдем читәнгә» - бу уенда ике сафка бүленеп бер якта егетләр, бер якта кызлар такмаклар җырлыйлар. Бер - берсен биергә чакыралар. «Аулак өй» бәйрәмендә татар халык биюләре, җырлары, табышмаклар, мәкальләр, такмаклар кертелә.

Декабрь аенда без «Каз өмәсе» бәйрәмен үткәрәбез. «Каз өмәсе» бәйрәмендә балаларга шундый җырлар өйрәтәбез: «Канат сату», «Каз өмәсе», «Каз канаты» һәм татар халык уеннарын да бу бәйрәмгә кертәбез. «Гармунчыга», «Алтын - капка», «Чума үрдәк – чума каз» уеннарын уйныйбыз. Безнең әби-бабаларыбызның гореф-гадәтләрен без бәйрәм аша балаларга аңлатабыз.

«Нәүрүз» бәйрәмендә без балалар белән кышны озатабыз, язны каршы алабыз. Ул 21 нче мартта үткәрелә. Бәйрәмдә без «Нәүрүз» турында җырлыйбыз, «Язгы – әйләнбәйлән» уеннарын өйрәнәбез. «Нәүрүз» - ул яз дигәнне аңлата. Бу бәйрәмнәрнең барысы да зурлар, әзерлек төркемендәге балалар белән үткәрелә. Балалар бәйрәмнәрдә бик теләп һәм яратып катнашалар. «Нәүрүз» бәйрәмендә кыш белән яз үзара көч сынашалар, аркан тартышалар, биюдә ярышалар, мәкальләр әйтешәләр.

«Сабантуй» бәйрәмен без мәйданда июнь аенда үткәрәбез. Ул иң кызыклы бәйрәм булып үтә, чөнки балалар төрле уеннар уйныйлар, ярышларда катнашалар (көянтә-чиләк белән су ташу, капчык киеп йөгерү, капчык сугышы, чүлмәк вату, аркан тартышу, йомырка салынган кашык кабып йөгерү) һәм көрәш үткәрелә, җиңүче балага ясалган сарык бүләккә бирелә, ясалган атларда ат чабышы үткәрәбез. Мәйданда балалар үзләренең яраткан җырларын, биюләрен, шигырьләрен башкалар. Бу бәйрәмгә ата - аналарны чакырабыз, алар балалары белән бергә күңел ачалар. Бәйрәм үткәрелә торган мәйданыбызны без шарлар, милли бизәкләр белән һ. б. татар халык сөлгеләре белән бизибез. Шулай итеп, балаларыбыз бу бәйрәмнәрдә катнашып үзләре дә сизмәстән үзара бер-берсе белән аралашалар, үз-үзләрен тоту гадәтләрен үзләштерәләр, халкыбызның гореф-гадәтләре, йолалары, бәйрәмнәре белән якыннан танышалар.

Татар халкының уеннарын балалар бик тиз өйрәнәләр һәм бик теләп уйныйлар. Балаларга уен тәкъдим иткәндә, аларның иң яхшы үзләштерә торганнарын сайларга кирәк.

Балалар хәрәкәтле уеннарга өстенләк бирәләр һәм без алар белән күбрәк “Мәче һәм тычкан”, “Ябалак”, “Йоклаган песи”, “Очты, очты...”, “Аю-бүре”, “Күрсәт әле үскәнем”, “Милүшә-дилбегә” кебек уеннар уйныйбыз.Уеннардан балалар уңай тәэсир алалар, шулай ук тел байлыгын арттыралар.

Төркемдә балалар белән “Серле капчык”, “Әбием сандыгы”, “Танып бел”, “Мәликә”, “Йөзек салышлы”, “Ватык телефон” кебек уеннар алына.

Сюжетлы-рольле уеннарга да бик зур урын бирелә. Бу балаларга бер-берсенә хөрмәт, әдәплелек хисен үстерергә ярдәм итә. Шулай ук дидактик уеннарга да зур урын бирелә. Бу уеннар “Нәрсә артык?”, “Читекнең парын тап”, “Савыт-сабаны бизә”, “Милли киемнәрне бизәү” һ. б. баланың дөрес фикерләү, уйлап табу сәләтен үстерә. Шөгыльләрне уздырганда физминуткалар өчен кызыклы, хәрәкәтле күнекмәләр алабыз. Бу “Кәҗә мәкәрҗә” – үртәвеч, “Үчти-үчти, үчтеки”, “Әти биштә”. Балалар бик теләп катнашалар, үртәвечләрне бик тиз отып алалар.

Безнең «Аленушка» балалар бакчасында милли хис тәрбияләү түбәндәге юнәлешләрдән чыгып оештырыла:

- балаларга республика, туган як турында мәгълүмат бирү;
- халкыбызның гореф-гадәтләре белән тирәнтен таныштыру;
- әдәби һәм мәдәни байлыгыбыз турында кузаллау булдыру;
- туган телдә сөйләшергә теләк уяту, аны хөрмәт итү;
- төбәктә яшәүче язучылар, сәнгать кешеләре белән танышу;
-милли бәйрәмнәрнең тарихы белән таныштыру, аларда катнашу;
-халыклар, милләтләр арасындагы дуслык төшенчәсе барлыгын җиткерү.

Һәрбер төркемдә милли почмаклар бар. Без аларны һәрдаим баетып, тулыландырып торабыз. Балаларга халкыбызнын үткәнен, гореф-гадәтләрен күзаллау өчен күп төрле альбомнар әзерләдек. Аларга керәләр:

Татар халык уеннары

Милли орнаментлар

Татар халык ашлары

Татар халык табышмаклары

Татар халык бәйрәмнәре һ.б.

Үзебезнең бакчада фольклор элементларын туплап, эш барышында киң кулланабыз. Нинди генә тәрбия чарасы әкият, сынамыш, санамыш, җырлы-биюле яисә хәрәкәтле уеннардан башка үтә икән?!

Йомгаклау

Соңгы елларда татар халкының теле, мәдәнияте һәм гореф-гадәтләре белән кызыксыну балаларда да, ата-аналарда да күзгә күренеп артты. Балаларның урамда әти-әниләре белән яки үзара татар телендә сөйләшкәнен ишетсәң, сөенеп куясың, димәк хезмәтебезнең нәтиҗәсе бар.Үз телендә матур итеп сөйләшә белгән баланың киләчәктә дә үз милләте белән горурланып яшәвенә ышанам. Безнең рухи байлыгыбыз, милли традицияләребез исән булыр. Алар безгә бүгенге һәм киләчәк өчен кирәк.

Халык бәйрәмнәре һәм йолалары кешене тормыш тәртипләренә һәм таләпләренә күнектерергә ярдәм итә. Бу бәйрәмнәрне халыкның олысы-кечесе бергәләп уздыра. Яшьләр бәйрәмнәрнең тәртибен, йоласын кечкендән үк белеп, күреп, өйрәнеп үсәргә тиеш. Балаларга кечкнәдән үк әдәплелек, инсафлык, мәрхәмәтлелек тәрбияләүдә әти-әниләр, тәрбиячеләр зур эш алып барырга тиеш. Балаларга үз-үзен тота белү, аралаша белү күнекмәләрен балалар бакчасында һәм гаиләдә өйрәтергә кирәк. Әгәрдә без балаларны шушы тәртиптә тәрбияләсәк, шул чагында гына милләт, халык өчен тәрбияле балалар үстеребез .

Кулланган әдәбият

Балалар бакчасында тәрбия һәм белем бирү программасы /Төзүчеләре: К.В. Закирова, Р.Г. Борһанова. — Казан: Хәтер, 2000.

“Мәгариф” журналлары

“Салават күпере” нурналлары

Татар календарьлары.

Татар халык уеннары. Р.Ягъфаров, Мәгариф-2001,№9.

Татар халкының уен фольклоры. Р.Ягъфаров-Казан, Иман,2002.

Балам багалмам. Татар халык иҗаты. 1997.

*Сөнгатуллина Ләйлә Мөхәмәт кызы,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Муса Җәлил исемендәге “1 нче гимназия” муниципаль бюджет белем бирү учреждениесенең югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

**Әбиемнең күңел сандыгы**

*Әби җеп эрли, балалар “Без- без” уйныйлар. Кытыклашалар, уйныйлар.*

**Әби:** Әй, балакайлар, бигрәк матур чагыгыз! Безнең яшь чаклар да шулай, уйнап-көлеп, бик тиз генә узды да китте.

**Нәргизә:** Әби, бу нәрсә?

**Әби:** Без килен булып сандык белән килә идек. Өй түрендә тора иде алар! Аның өстенә чигүле япма, күпертелеп куелган йомшак чигүле мендәрләр куела иде. Ә сандык эчендә иң кадерле, затлы әйберләрне генә саклаганнар яңага тотыла торган киемнәр, сөлге-тастымаллар, сабыннар, истәлекләр. Ул сандыкны ачып җибәрүгә борынга иң элек сабын исе килеп бәрелә иде?

**Давыт:**

Әбиемнең күңел сандыгы!
Нинди серләр саклый икән ул?
Гомер буе җыйган хәзинәме,
Әллә инде күңел бизәгеме,
Нинди серләр саклый икән ул?

**Зәринә:**

Әбиемнең күңел сандыгын
Бер ачасы иде, ачасы…
Әби-бабам белгән йолаларны,
Халкыбызның күңел җәүһәрләрен
Бер ачасы иде, ачасы.

**Нәргизә:**

Әбиемнең күңел сандыгы
Кызыктыра инде күптәннән.
Ач, әбием, безгә күңелеңне,
Яшь буынга мирас булып калсын,
Бер хәзинә калсын үткәннән.

**Әби:** Сандыкта ниләр барын беләсегез киләме, балалар? Әйдәгез әле бергәләп ачыйк сандыкны.

**Балалар:** Беләсебез кил...Ачыйк, әбекәй! (Шатланышалар)

*Әби сандыкны ачып җибәрә, Камил курайны ала.*

**Камил:** Әбием, кемнең курае бу? Мин дә курайда уйный беләм бит!(уйный башлый).

**Әби:** Бабаң истәлеге бу, улым! Өздереп уйнап җибәрер иде! (Уйга кала, әкрен генә кереп китәләр, **курайчылар** чыга).

**Камилә:** Әбием, бу нинди кәгазьләр? (Өчпочмаклы хатларны алып).

**Әби:** Балакайларым, тормыш гел уйнап- көлеп кенә узмады шул. Кайгы- хәсрәтле, борчулы вакытлары да булды. Сугыш китергән афәтләрнең тамгасы болар. Бабагызның фронттан язган хатлары. Мәңгегә сугыш кырларында калучылар да күп булды, хәбәрсез югалучыларны көтүче апа- әбиләрегез хәзер дә бар әле.

***Әдилә Апсагитова** чыга, калганнар әкрен генә кереп китәләр.*

**Давыт:** Әбием, син гармунда уйный беләсеңме әллә? (Гармунны тота, гармунны тартып карый).

**Әби:** Бабагызның гармуны, үзе уйнап җырлап җибәрә торган иде. Ул уйнаганда тик торып кара син! Үзеннән-үзе биеп китәсең.(Гармун турында сөйләшә- сөйләшә кереп китәләр, **"Кама таңнары"** биюе башлана).

**Камил:** Әбием, мин бер кәкре таяк таптым, миңа булсын әле?!

**Әби:** Көянтә бит бу, нишлисең аның белән?

**Камил:** Нәрсә соң ул көянтә?

**Әби:** Аның белән чишмәдән су ташый идек без, хәзерге кебек кран суы эчмәдек. Ике ягына чиләкләреңне асасың да китәсең матур атлап... Менә шул чишмә юлында очраттым да инде бабагызны... (Уйга кала, китәләр, **җыр**).

**Җырлаучы** *кереп китә, әби балаларны үзе янына җыя.*

**Әби:** Карагыз әле нинди матур сөлгеләр?

Бүген матур итеп чигелгән затлы сөлгеләр әбиләрнең сандыгында гына саклана. Әбиләр аларны кадерләп саклый. Яшь кызлар үз куллары белән чигеп, сугып сөлгеләр әзерләгәннәр. Сөлгеләрнең матурлыгына карап яшь кызларның уңганлыгы, пөхтәлеге, булдыклылыгы бәяләнгән.

**Зәринә:**

Татар хатын –кызларыбыз

Эшнең серен белгәннәр.

Кич утырып, җырлар җырлап

Оста чигү чиккәннәр.

**Нәргизә:**

Бу сөлгеләр, эскәтерләр,

Тамбур белән чигелгән.

Әллә инде өсләренә

Чын чәчәкләр чигелгән?

**Әби:** Бу сөлгеләр Сабан туеның чын бизәкләре була иде. (**САБАНТУЙ** биюе башлангач кына сәхнәдән чыгып китәләр).

**Әби:** Балалар, сез инде сандыкта нәрсәләр ятканын күрдегез, алар безнең үткәнебез, ә үткәнне онытырга ярамый, аны сакларга кирәк. Аны саклау- сезнең изге бурычыгыз. Әйдәгез, матур итеп урынына салыйк бу истәлекләрне.(Бик кадерләп кенә бергәләп кире тутыралар, әби сандыкны яба).

Хәтерләүдән курыкма син!

Үткәнеңне онытма син.

Бел син ерак бабаларның

Ничек итеп көн иткәнен.

Ни иккәнен, ни чиккәнен,

Нинди җырлар, нинди моңнар

Безгә калдырып киткәнен!

**Давыт:** Без үткәнебезне саклarбыз, әбекәй! Сүз бирәбез!

**Балалар:** Сүз бирәбез!(*Әби һәм балалар алга килеп баш иятәр.)*

*Хайруллина Гөлнара Илсур кызы,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Муса Җәлил исемендәге «1нче гимназия» муниципаль бюджет белем бирү учреждениесе югары категорияле информатика укытучысы*

## Информацион технологияләр

Соңгы елларда мәктәптә яңа педагогик технологияләр көннән-көн активрак кулланыла бара.

Бүгенге уку-укыту процессы укытучылар алдына педагогик технологияләрнең принципларына таянып эшләү, уку-укыту эшендә әлегә кадәр булган технологияләрнең барсын да теге яки бу дәрәҗәдә куллану максатларын куя. Шулар белән бергә, заман алга барган саен, бүгенге уку-укыту процессында иң әһәмиятле урынны заманча технологияләрнең берсе булган компьютер технологиясе алып тора. Хәзер әлеге технология кеше эшчәнлегенең барлык өлкәләренә дә нык үтеп керде. Бер генә белгечлекне, профессияне дә аңардан башка күз алдына китереп булмый. Мәгариф оешмаларын компьютерлаштыру – мәгариф үсешендәге өстенлекле юнәлешләрнең

берсе. Шунлыктан мәктәпләр интерактив такталар, мультимедиа проектлары белән җиһазлана, дәресләрдә компьютерлар кулланыла. Башка күп кенә һөнәрләр кебек үк, укытучы һөнәре дә компьютер технологияләрен нәтиҗәле куллануны күз алдында тота. Компьютер технологиясеннән нәтиҗәле файдалану – хәзерге көндә укыту методикасының мөһим бурычы. Яңа төр эшчәнлек, компьютерны "йөгәнли белү" гә кызыксыну булдыру бәрабәренә укытуның сыйфатын күтәрүгә ирешү - әлеге технологиянең иң өстенлекле ягы. Технологик алгарыштагы һәр яңалыкка балалар сокланып карый, һәм, әлбәттә, аларның кызыксынучанлыгын һәм танып-белү активлыгын үз шәхесләренең максатчан үсешенә юнәлдерү мөһим. Нәкъ менә дәрестә укучылар укытучылары җитәкчелегендә үз интеллектларын һәрьяклап үстерү, белем алу һәм тормыш мәсьәләләрен хәл итү өчен мәгълүмат туплау максатында компьютер технологияләрен кулланырга өйрәнә.

Дәрес – уку-укыту эшчәнлегенең иң төп урыны. Нәкъ менә дәрестә укучылар укытучылары җитәкчелегендә үз интеллектларын һәрьяклап үстерү, белем алу һәм тормыш мәсьәләләрен хәл итү өчен мәгълүмат туплау максатында компьютер технологияләрен кулланырга өйрәнә. Компьютер – бүгенге заманда белем алу өлкәсендәге максатларга ирешү, укыту процессын баету, бала шәхесе һәм укытучының һөнәри осталыгы үсешенә йогынты ясау чарасы ул. Моның өчен мөгаллимгә:

- компьютердан файдалануның үзенә хас үзенчәлекләрен педагогик әсбап буларак аңлау, аның мөмкинлекләрен һәм җитешсез якларын билгели белү;
- уку материалын аңлата алу һм укучылар белемен тикшерүнең бер ысулы буларак веб-ресурслардан файдалана белү тәбрибәсенә ия булу;
- үзең укыта торган фән укытучылары өчен тәкъдим ителгән кулланма программа һәм ярдәмлекләр белән эш итә белү алымнарын үзләштерү кирәк.
- Әлеге технологияләр яңа материалны өйрәнү дәресләрендә, осталык һәм күнекмәләрне үзләштергәндә, шулай ук практик дәресләрдә яхшы нәтиҗәләр бирә.

Дәресләрдә мәгълүмати технологияләрне куллануның өстенлеге бәхәссез. Барыннан да элек, әлеге технология – шәхескә юнәлтелгән, ныклы һәм вариатив булуы белән аерылып тора. Компьютер, күрсәтмәлелекне һәм контрольлекне тәэмин итеп, күп мәгълүмат биреп, укытуның сыйфатын күтәрергә ярдәм итә, этәргеч бирә. Дәресләрдә компьютер куллануның юллары һәм ысуллары күптөрле. Шуларның берсе – электрон презентацияләр. Дәрестә кулланылган теләсә нинди визуаль мәгълүматның уңай нәтиҗәсе бар. Һәрбер укыту чарасы дәрес материалын үзләштерүгә этәргеч бирә. Шулай да мондый чаралар кулланып үткәрелгән дәресләр гадәти, укучы өчен дә, укытучы өчен дә кулай булырга, тышкы бизәкләре белән укучы дикъкатен читкә юнәлдермәскә тиеш. Кайбер

дәресләрдә кәгазьдән ясалган берничә таблица яки схема күрсәтү дә җитә. Әгәр дә инде алар искергән дә булса,  ул чакта электрон презентация - әлеге мәсьәләне хәл итүнең заманча һәм кулай юлы.  Аны куллану урынлы, чөнки ул балаларның игътибарын читкә юнәлдертми.  Электрон презентация бары даими кулланылган очракта гына  уңай нәтиҗә бирәчәк, шул ук вакытта аны  һәр дәрестә куллану белән дә артык мавыкмаска кирәк.

Әлеге технологияләрдә уңышлы файдалану дәреснең нәтиҗәлелеген күтәрә, укучыларның кызыксынучанлыгын арттыра, аларны белем дөньясына җәлеп итә, өлгереш күрсәткечен һәм уку сыйфатын яхшырта.

*Хәйруллина Лилия Миннефаяз кызы,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүле 27 нче гомуми урта белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең беренче категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

## Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә инновацион технологияләр куллану

Инновация турында төшенчә

Мәгариф системасы гомер-гомергә традицион укыту методикасына нигезләнеп үсте. Әлбәттә инде, гасырлар буена тупланган тәҗрибәгә таянмыйча мөмкин түгел. Шулай да, тормыш бер урында тормый, заманалар үзгәрә бара. Димәк, яңалыкларны да исәпкә алмыйча эш итәргә ярамый. Бүген без техника зур тизлек белән үсеш алган инновацияләр чорында яшибез. Мәгълүмати технологияләр тормышның барлык өлкәләренә үтеп керде. Белем бирү өлкәсе дә моннан читтә калмады – заманча техника белән җиһазландырылган мәктәпләр барлыкка килде, укытуда яңа методик алымнар, технологияләр кулланыла,укучыларның белемнәрен тиз генә тикшерергә мөмкинлек бирә торган күнегүләр һәм мәсьәләләр файдаланыла. Мәгарифне инновацион үстерү-республикабыз һәм илебез киләчәгенең нигезе. Шуңа күрә белем бирүдә инновацион юнәлешне үстерү-төп бурычларның берсе. «Инновация» (яңа, заманча) термины XIX гасырдан ук кулланылышта йөри. Фәнни әдәбиятта «яңалык» һәм «инновация» төшенчәләре төрлечә аңлатыла. Яңалык-укыту процессына караган яңа чара (метод, методика, технология һ.б.). Әлеге чараны үзләштерү процессын инновация дип йөртәләр. Инновацион технологияләрне укыту процессында файдалану-белем бирү сыйфатын күтәрүдә бик нәтиҗәле чара ул. Чөнки алар укуга кызыксыну тудыра, уку материалын тирәнрәк үзләштерү теләге булдыра, укучыларның иҗади сәләтен үстерү мөмкинлеген бирә. Теләп башкарылган эш кенә истә кала, баланың сәләтен, аңын үстерә. Әгәр материалны үзләштерү авыр, бертөрле икән, укучының күңеле суына, телне өйрәнергә булган теләге

бөтенләй сүнергә дә мөмкин. Әйе, бүгенге җәмгыятьтә күнегелгән күп мөннәсәбәтләр,традицияләр үзгәрә. Мәктәптәге укучы белән укытучы мөнәсәбәтләре дә бөтенләй икенчегә әйләнде: укытучы да, укучы да иҗатчыга әверелә бара. Яңа нәтиҗәләргә ирешү, конкурентлыкка сәләтле, җаваплы, инициативалы һәм компетентлы гражданнар тәрбияләү- инновацион белем бирүнең төп бурычлары шулар.

Заманча технологияләр белән эшләү, укытучының үз эшенә иҗади якын килүен дә таләп итә. Ул инде укытучы буларак кына түгел, режиссер, укучы, яки башка рольгә кереп. укыту процессын оештыра. Инновацион технология эчтәлеген ачуда эшчәнлек, ирек, бербөтен шәхес, өйрәнүченең ихтыяҗлары, кызыксыну һәм башка шундый төшенчәләр файдаланыла.

Без, татар теле укытучылары, бары тик яхшы әзерлекле укытучы гынабелем бирүне югары дәрәҗәдә алып барырга, укучыларда тыңлап аңлау,сөйләү, уку, язу өлкәсендә ныклы белем һәм күнекмәләр булдырырга сәләтле икәнлеген аңлыйбыз. Шулай итеп, инновацион технология төп максаты итеп укучының белем алу эшчәнлеген активлаштыруны күздә тота дип әйтү дөрестер. Элегрәк укытучы яңа теманы бик матур итеп сөйли, ә укучы бары гади үзләштерүче ролен үти иде: бүген исә, укучы яңа теманы үзе эзләүче, тикшеренүче сыйфатында үзләштерергә тиеш дип карала. Укытучы бу очракта укучыларның актив фикерләү эшчәнлеген, акылын, зиһенен үстерү өчен юнәлеш бирүче, әйдәп баручы ролен үти. Хәзерге шартларда, мәгълүматның күләме тиз үскән вакытта, кирәген сайлап ала белергә, тәртипкә китерергә, бәләкәй генә ачыш ясап куана белергә өйрәтү, юл күрсәтү- уку - укыту өчен авыр эш. Укучы теманы уйлап, фикерләп, эзләнеп аңлый икән, әлбәттә, аның белеме ныклырак, төплерәк була. Мәктәптәге традицион, бер төрле үткәрелгән дәресләр арасында, гадәти булмаган дәресләр үткәрү укучыларның хәтерендә ныграк кала. Ялкыткыч эш төрләрен һәр дәрестә кат-кат башкаруга караганда кызыклы ачышлар булганы укучының күңеленә тәэсир итә, аң-белемен киңәйтә, иҗади эзләнүгә теләк тудыра. Шуңа да соңгы вакытта укучының белем сыйфатын күтәрүдә, иҗади сәләтләрен үстерүдә яңа технологияләрне өйрәнү һәм дәрестә куллану турында күп сөйләнелә, языла. Хәзер татар теле һәм әдәбиятын укыту күпкә катлауланды. Укытучы алдында җаваплылык артты: мәктәптә укытылган дистәләгән фәннәр арасында балага татар телен абруйлы итеп өйрәтү, балада шушы фәнгә карата гомер буена җитәрлек горурлык хисе тәрбияләү, туган тел матурлыгын онытылмаслык итеп күңеленә сеңдерү. Дәрес шәхес күңелен кузгатырлык булырга тиеш. Заманча технологияләр белән эшләү укытучының үз эшенә иҗади якын килүен дә таләп итә. Ул инде укытучы буларак кына түгел, режиссер, укучы, нинди дә булса эшкә (мәсәлән, уенга) җитәкчелек итә, консультант яки башка рольгә кереп, укыту процессын яңача оештыра.

Башта бу юнәлеш буенча төгәл фәннәр эшли башлаган. Хәзер исә татар теле укытучылары да башка фән укытучылары белән рәттән заманча технологияләрне файдаланып белем бирәләр. Бүгенгесе көндә татар теле һәм әдәбиятын укыту күпкә катлауланды. Хәзер укытучыдан бик күп нәрсә таләп ителә: мәктәптә укытылган дистәләгән фәннәр арасында балага татар телен абруйлы итеп өйрәтү, шушы фәнгә карата кызыксыну, горурлык хисе тәрбияләү, үз фәнеңне бик яхшы белү, балаларны яратудан тыш, аларның фикерләү сәләтен үстерү, уку-танып белү эшчәнлеген оештыру, рухи һәм физик үсешен тәэмин итү. Ә моның өчен мөгалимнән үз шәхесенә тәнкыйть күзлегеннән карау, яңалыкка омтылу, заман сулышын тоеп эшләү сорала. Бүгенге балалар мәгълүмати технологияләр белән бик иртә таныша. Хәзер балалар бакчасында ук заманча технологияләрне үзләштерү мөмкинлеге тудырылган. Әгәр дә элек мәктәп баласы өчен мәгълүмат чыганагы булып китап һәм мөгаллим торса, бүген ул барлык кызыксындырган сорауларга җавапны интернет челтәре аша да таба ала. Шуңа да хәзерге педагоглар үсмерләрне үз фәне белән кызыксындыру, аларның игътибарын җәлеп итү өчен төрле хәйләләр уйлап табарга — шул ук мәгълүмати технологияләрне үзләштерергә һәм аларны укыту процессында кулланырга тиеш. Уку-укыту процессына яңа технологияләрне кертеп җибәрү бүген көн тәртибенә куелган мәсьәлә.

Хәзерге көндә мәгълүмати белем чыганаклары уку-укыту системасында аерылгысыз бер тармак булып тора. Нәрсә соң ул мәгълүмати белем чыганаклары? Мәгълүмати белем чыганаклары - укыту процессын оештыруда мөһим булган фотосурәтләр, видеоматериаллар, динамик модельләр, тавыш язмалары һәм башка укыту материаллары ул . Шунлыктан мәктәпләр интерактив такталар, мультимедиа проектлары белән җиһазлана, дәресләрдә компьютерлар кулланыла. Заманча технологияләрнең түбәндәге төрләрен күрсәтеп була: 1) шәхескә юнәлтелгән технологияләр;. 2) укучылар эшчәнлеген активлаштыру һәм интенсивлаштыруга нигезләнгән педагогик технологияләр; а) уен технологиясе; б) проблемалы укыту; в) аралашуга өйрәтү технологиясе. 3)уку процессын оештыру һәм идарә итүнең нәтиҗәлелегенә нигезләнгән педагогик технологияләр. а) терәк схемаларны кулланып, алга китеп укыту технологиясе; б) белем бирүнең компьютер технологияләре; в) интенсив белем бирү технологиясе.

**Заманча технологияләрне татар телен чит тел буларак укытканда куллану.**

Мин үземнең эш тәҗрибәмдә түбәндәге заманча технологоияләргә мөрәҗәгать итәм: 1) уен технологиясе; 2) компьютер технологиясе, проблемалы укыту технологиясе.

Уеннар файдалану укучыны белем алуга, укуга дәртләндерә, анда фән белән кызыксыну уята. Уен технологиясен яңа материалны аңлатканда һәм ныгытканда, сөйләм телен үстергәндә кулланырга мөмкин. Әлеге технология балаларның иҗади сәләтен

үстерә, фикерләү дәрәҗәсен арттыра, дәресне җанландыра, кызыклы итә. Уйный-уйный белем алганда, телдән үзләштерә торган материал җиңел ныгытыла һәм мавыктыргыч була, балаларның күзәтүчәнлеге арта. Тик әлеге эш төрен оештырганда, мин укучыларның яшь үзенчәлеген истә тотып, аны дәрестә урынлы кулланырга тырышам. Мәсәлән, 1нче сыйныфта фигыльләрне өйрәнгәндә укучылар "Ватык телевизор" уенын кызыксынып уйныйлар. Телевизор ватылган, тавышы юк. Бер укучы такта янына чыга. Мин аның колагына фигыльнең беренче формасын пышылдап әйтәм, укучы моны хәрәкәт белән күрсәтә. Калган укучылар фигыльне хәзерге заман формасында әйтеп бирәләр. Һава торышын тасвирлаганда, төрле ситуацияләр бирәм, "Синоптиклар" уенын үткәрәм. Уеннарда шулай ук күрсәтмәлелек файдалану (киемнәр, уенчыклар, муляжлар, маскалар) яхшы нәтиҗә бирә. Аларны кулланып, кибеттә әйберләр алу, бүлмәне җиһазлау, өстәл әзерләү турында сөйләшергә, киңәшләшергә мөмкин. Рольле уеннарның ситуацияләрен укучылар үзләре дә тәкъдим итә. Иң кызык уеннарның берсе — курчак театры оештыру, әкиятләрне сәхнәләштерү. Сәхнәләштерелгән уеннар иҗади хыялны, уйлау сәләтен үстерә. Алар уку эшен җанландыра, төрләндерә, сөйләм телен үстерүгә уңай йогынты ясый. Г.К.Селевко, үткәрү максатыннан чыгып, уеннарны берничә төркемгә бүлә:

-дидактик уеннар;

-тәрбияви уеннар;

-үстерешле уеннар;

-социальләштерүче уеннар.

Дидактик уеннарны укучыларның белем дәрәҗәсен, танып белү эшчәнлеген камилләштерү өчен кулланабыз. Тәрбияви уеннарны әхлак тәрбиясе бирү, рухи сыйфатлар, сәламәт яшәү рәвеше тәрбияләү максатыннан үткәрәбез. Укучыларның сөйләм телен үстерүдә, эзлекле фикер йөртү сәләтләрен формалаштыруда үстерешле уеннар ярдәм итә. Укучылар бигрәк тә рольле уеннарны яраталар.Рольле уеннар укучыларның коммуникатив эшчәнлеген активлаштыра, үзара ярдәмләшү теләге тудыра.

Рольле уеннар диалогик сөйләмне үстерүдә бик нәтиҗәле чара булып тора. Мәсәлән, "Ашханәдә", "Кибеттә", "Базарда", "Туган көнгә чакыру" кебек рольле уеннар бик кызыклы. Башлангыч сыйныфларда, мин бу алымны аеруча яратып кулланам. Рольле уенда парлап һәм төркем составында да катнашырга була. Төркем белән эшләгәндә, әкиятләрне үзгәртеп, тулыландырып, өстәмә сораулар ярдәмендә коммуникатив максатка ирешәм.

Проблемалы укыту технологиясе XIX гасыр ахырында кулланылышка керә. Ул Америка галиме Дж.Дьюн теориясенә нигезләнә. Проблемалы укыту-укытучының укучылар белән берлектә проблемалы ситуацияне хәл итү юлларын эзләү процессы.

Балаларның фикерләү сәләте камилләштерелә, ныклы белем һәм күнекмәләр формалаша.Проблемалы укыту технологиясен кулланып укыткан укытучылар саны көннән-көн арта. Укучыларда интеллектуаль көч яңа вакыйга, төшенчәләрне аңларга Һәм фикер аша үткәрергә тырышкан вакытта кыенлыкларга очраганда барлыкка килә һәм ул проблемалы ситуациянең тудырылуын, тема белән тирәнтен кызыксынуны, аны хисси кабул итүне һәм укучының ихтыяр көченә ия булуын таләп итә. Проблемалы укыту процессында укытучы уку-танып-белү эшчәнлеген фактларны анализлау нигезендә укучылар нәтиҗә Һәм гомумиләштерүләр ясарлык итеп оештыра. Эчке (логик-психологик) үзенчәлектән чыгып караганда укытучы аңлы рәвештә проблеманы ситуация тудыра торган дәресне проблемалы дәрес дип атыйлар.

Шунысы да әһәмиятле: әгәр укытучы дәрестә уңай психологик халәт тудыра алса, уңышка китерәчәк ситуация уйлап таба алса, үз эшен яратса, укучыларны хөрмәт итсә, ул һичшиксез зур уңышларга ирешәчәк . Балалар үзләренә булган игътибарны күреп үзләрен яратуларын, үзләренә ышануларын тоеп яшәргә тиеш. Бүгенге балалар мәгълүмати технологияләр белән бик иртә таныша. Хәзер балалар бакчасында ук заманча технологияләрне үзләштерү мөмкинлеге тудырылган. Әгәр дә элек мәктәп баласы өчен мәгълүмат чыганагы булып китап һәм мөгаллим торса, бүген ул барлык кызыксындырган сорауларга җавапны интернет челтәре аша да таба ала. Шуңа да хәзерге педагоглар үсмерләрне үз фәне белән кызыксындыру, аларның игътибарын җәлеп итү өчен төрле хәйләләр уйлап табарга — шул ук мәгълүмати технологияләрне үзләштерергә һәм аларны укыту процессында кулланырга тиеш. Уку-укыту процессына яңа технологияләрне кертеп җибәрү бүген көн тәртибенә куелган мәсьәлә. Хәзерге көндә мәгълүмати белем чыганаклары уку-укыту системасында аерылгысыз бер тармак булып тора. Нәрсә соң ул мәгълүмати белем чыганаклары? Мәгълүмати белем чыганаклары - укыту процессын оештыруда мөһим булган фотосурәтләр, видеоматериаллар, динамик модельләр, тавыш язмалары һәм башка укыту материаллары ул . Шунлыктан мәктәпләр интерактив закталар, мультимедиа проектлары белән җиһазлана, дәресләрдә компьютерлар кулланыла.

Компьютер – укучы белән белемнәр системасы арасында арадашчы, белем алу чарасы. Компьютердан файдалану укыту эшчәнлеген баета, укыту процессын кызыклы, нәтиҗәле һәм иҗади итеп оештырырга мөмкинлек бирә. Компьютер сыйныф тактасын да, тарату материалын да, дәреслекләрне дә алыштыра ала. Аны куллану дәреснең нәтиҗәлелеген арттыруга ярдәм итә. Һәр укучының белем үзләштерүгә сәләте төрлечә була. Кайбер укучыларның ишетеп истә калдыру дәрәҗәсе өстенлек алса, күпчелек укучыларда күреп истә калдыруы өстен чыга. Менә шушы вакытта компьютер ярдәмгә килә. Чөнки мониторда барлык биремнәр матур, эстетик яктан камил эшләнә. Үзем эшли

торган 3 нче гимназиядә дә барлык шартлар тудырылган. Татар теле һәм әдәбияты кабинетлары компьютер, интерактив такталар , мультипроектор белән җиһазландырылган. Һәр дәрестә яңа технологияләр куллану мөмкинлеге бар. Презентацияләр төзегәндә, мин аның эченә бик күп материал: төрле схемалар, рәсемнәр, фотосурәтләр кертергә тырышам. Мин үз дәресләремдә бик еш интерактив тактага мөрәҗәгать итәм, чөнки интерактив такта куллану дәресләрне тагы да мавыктыргыч, нәтиҗәле итәргә ярдәм итә. Мин рус төркемнәрендә эшлим. Әдәбият дәресләрендә без язучылар, шагыйрьләр турында прензентацияләр төзибез. Укучылар мөстәкыйль рәвештә фотосурәтләр, төрле схемалар, рәсемнәр белән прензентацияләр әзерлиләр. Биремнәрне матур итеп,эстетик яктан камил итеп башкарырыга тырышалар. Мәсәлән, 5 нче сыйныфта Г. Тукай, Ф. Кәримнең тормыш һәм иҗатлары турында укучылар прензентацияләр әзерләп килделәр. Укучылар бу биремнәрне теләп, авырсынмыйча башкардылар. Әлбәттә, нинди дер аңлашылмаучанлык булганда минем ярдәм дә кирәк була. Күпчелек укучылар материалны күреп истә калдыра, ә әлеге чараны куллану кирәкле мәгълүматны хәтердә калдырырга нык ярдәм итә. Шулай ук башка сыйныфларда да компьютер технологияләрен кулланабыз, бу инде беркем өчен дә яңалык түгел дип уйлыйм. Укытуны интенсивлаштыру өчен тестларны нәтиҗәле дип саныйм. Укучыларның теманы үзләштерү дәрәҗәсен тикшерү, белемнәрен бәяләү, ялгышларын ачыклау, аларны анализлау һәм төзәтү юлларын билгеләү өчен тестлар бик уңайлы. Компьютер технологияләре ярдәмен түбәндәге эш төрләрендә дә кулланам:Текст белән эшләү. Презентация ярдәмендә сүзлек, тикшерү диктантларын яки контроль күчереп язуларны тикшерергә уңайлы. Моның өчен мин бер слайдта хәрефләре төшеп калган яки хаталы текстлар бирәм. Эшне башкаргач, укучылар бер-берсе белән дәфтәрләрен алмашалар һәм алдагы слайд ярдәмендә тикшерәләр. Төшеп калган хәрефләр, хаталар башка төс белән бирәм. Киләсе слайдта бәяләү критерияләре күрсәтелә. Укучылар билгеләрне үзләре куялар. Биредә укучыга җавап вариантларын сайлап алу гына түгел, аларның дөреслеген тикшерү мөмкинлеге дә тудырыла. Бер- берсен мактыйлар, хаталарны төзәтергә киңәшләр бирәләр. Төрле темага күрсәтмә материаллар һәм укыту ресурсларын бик күп табарга һәм аларны кабат-кабат файдаланырга мөмкин. Бу алым укучыларның белем сыйфатын үстерергә ярдәм итә. Укучылар интерактив тактага бик тиз күнегәләр. Зур экран бергәләп эшләргә мөмкинлек бирә. Сыйныфта интерактив тактаның барлыкка килүе хәтта иң проблемалы укучыларга да укуга карата карашларын үзгәртергә этәргеч ясый. Соңгы парта артында утырган бала кинәт активлаша һәм иҗади фикер йөртә башлый. Шулай итеп интерактив такта укучыларда эшләү активлыгын гына арттырып калмый, ә яңа материалны һәр укучыга җиңел, аңлаешлы итеп җиткерергә дә ярдәм итә. Шулай ук дәресләрдә Интернет ресурсларны куллану гаять зур

мөмкинлекләр бирә. Интернет челтәре укучыга һәм укытучыга кирәкле мәгълүматны җир шарының төрле ноктасыннан эзләп табу шартларын тудыра. Татар теле дәресендә Интернет ярдәмендә уку, язу күнекмәләрен булдыру һәм үстерү, кирәкле материал табу, укучыларның сүзлек запасын баету, татар телен өйрәнүгә мотив формалаштыру кебек дидактик бурычларны үтәргә мөмкин. Укучылар Интернет челтәрендә үткәрелә торган тестларда, викториналарда, конкурсларда, олимпиадаларда катнаша, яшьтәшләре белән аралаша алалар. Соңгы вакытта шулай ук дәресләребездә сингапур структураларын куллана башладык. Сингапур методикасының максаты булып түбәндәгеләр билгеләнә ала:

- дәресләрдә, «өйрәтү структурасы»н кулланып, үзенчәлекле мохит булдыру;
- пассив, ваемсыз укучыларны кызыксынучан, бер-берсе белән эшлекле формада аралаша белүчеләргә, актив хезмәттәшлек итүчеләргә, кискен фикер йөртүчеләргә әйләндерү;
- укучының критик һәм креатив фикерләвен булдыру;
- укучыны кирәкле мәгълүматны мөстәкыйль эзләргә һәм табарга өйрәтү.

Әлеге методика биш модульне үз эченә ала: “Критик фикерләүне үстерү”, “Үзара хезмәттәшлектә белем бирү”, “XXI гасырда белем бирүнең үсеш тенденциясе”, “Проблемалы укыту”, “Инновацион төркемнәр булдыру”. Әлбәттә, һәр модульне ныклап өйрәнергә, аның асылына төшенергә кирәк. Максатыма ирешү өчен, әлегә түбәндәге модульләрне өйрәнәм: «Үзара хезмәттәшлектә белем бирү» һәм «Критик фикерләүне үстерү». «Үзара хезмәттәшлектә белем бирү» модуленең хасиятләре:

- укытучы тәкъдим иткән биремне укучылар парлап яки төркемләп эшлиләр;
- сыйныфтагы һәр укучы бер-берсе белән фикерләшә;
- укытучы тарафыннан җиткерелгән һәр мәгълүмат баланың хәтерендә кала һәм аны уйлау, фикер йөртүгә этәрә;
- сыйныфта һәр укучының актив эшчәнлеге күзәтелә.

«Үзара хезмәттәшлектә белем бирү» модуленә караган түбәндәге структураларны татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә кулланам:
«Таймд пэа шэа» (Татар теле (5 нче сыйныф): «Эшли ала» конструкциясе)
“Микс-Фриз-Груп”(Башлангыч сыйныфларда физминуткалар үткәргәндә)
“Джот-Тотс” , “Тик-Тэк-Тоу”(4 сыйныф, татар теле, “Сыйфат”)
“Раунд-Робин”(5 нче сыйныф, “Фигыльнең хәзерге заман формасы”,татар теле)
“Намбэ-Ап”(физминуткалар, төрле сыйныф укучылары өчен)
Шул рәвешле, әлеге структураларны татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә файдалану, укучыларны хезмәттәшлек итәргә, үз фикереңне җиткерә, башкаларныкын тыңлый белергә өйрәтә, төркемдә эшли белү күнекмәләрен үстерә, дәрестә һәр укучының

эшчәнлеген активлаштыра. Тагын бер үзенчәлекле модуль - «Критик фикерләүне үстерү» модуле. Аның төп сыйфатлары:

- укучының критик һәм креатив фикерләве арта; - белем алучы теге яисә бу тема, проблемага кагылышлы фикер төрлелеге булуы мөмкинлеге хакында белә;
- укучы кирәкле мәгълүматны мөстәкыйль эзләргә һәм табарга өйрәнә.
Сер түгел, укучылар матур әдәбият әсәрләрен бик аз укый.ләкин бер техник чара, иң яңа буын компьютер да тере җанлы әдәби әсәрнең үзен, аның телен, моңын, фикер тирәнлеген алыштыра алмый. Бигрәк тә-укытучының үзен, аның белем бирү процессын.

Баланы үзе теләп, мавыгып әдәби әсәр укырга укытучы өйрәтә. Моңа бары тик баланы яратып, аңа күңел җылыңны биреп , аның белән бергәләп рухи хезмәт башкарып кына ирешеп була! Җанлы аралашуны бер техник чара да алыштыра алмый.Педагогика фәнендә укыту-тәрбия процессы сыйфатын үстерергә булышлык итүче технологияләр бик күп. Укытуның һәр этабы өчен уку материалын аңлатуның иң уңышлы вариантын табу-укытучының бурычы.

Информацион технологияләр – укучыларның гомуми эрудициясен киңәйтүдә зур роль уйный.

Татар теле дәрес буларак укытыла башлаганнан бирле (XVIII гасырда Сәгыйть Хәлфин эшчәнлеге белән бәйле) һәр чор укытучылары һәм методистлары укытуны камилләштерү ысул һәм алымнарын булдырырга тырышканнар. 21 нче гасырда укытучы һәм укучы арасындагы уңай эмоциональ халәт, укучыларда белем алуга мотивация булдыру, балаларга төпле теоретик белем бирү белән беррәттән аларның сөйләм телен үстерүгә дә урын бирүне үз эченә ала. Бүгенге информацион технологияләр үсеше һәм техника алгарышы заманында исә татар теле һәм әдәбияты укытучысы алдына укучыларның гомуми эрудициясен киңәйтү максаты да килеп баса.

Әхмәт Зәки улы Рәхимовның “Укучыларның иҗади фикерләвен үстерү технологиясе”, Ф.Г.Казыйханова, В.С.Казыйхановларның “Иҗади үстерелешле технология”ләренә нигезләнеп, гомуми эрудицияне киңәйтү татар теле дәресенең коммуникатив һәм тәрбияви максатларын тормышка ашыру белән бергә үрелеп барырга, шул ук вакытта бирелгән теоретик белемне ныгытуга да хезмәт итәргә тиешлеге күз уңында тотыла. Татар теле дәресләрендә татар халкы этнографиясе һәм тарихы турында мәгълүмат бирү укучыларның гомуми эрудициясен киңәйтүгә йөз тота торган мәгълүматлар тупланмасын тәкъдим итү чарасы булып тора. ФГОС таләпләре буенча укучы дәреслектә эшчәнлекнең нәтиҗәсен, материалны үзләштерү дәрәҗәсен бәяләп барсын иде: “бусы - үземнеке, бусы - иптәшемнеке”. Бала мөстәкыйль тикшерү алып бара, йомгаклый, нәтиҗә чыгара, үзен-үзе бәяли. Укучылардан әледән-әле “Хаталы сүзне

төзәтү", "Махсус хата ясау", "Мин нәрсәне беләм һәм нәрсә белмим?", "Нәрсә эшләнде?", "Эш ничек башкарылды?" кебек регулятив эш төрләренә җаваплар эзләтергә кирәк.

Мондый төр мәгълүматны презентацияләр, видеороликлар ярдәмендә тәкъдим итәргә мөмкин. Әлбәттә, аларны әзерләү һәм дәрес тукымасына кертеп җибәрү укытучыдан зур әзерлек таләп итә. Әзерлек барышында татар халкының этнографиясе һәм киенү рәвеше турында язылган күпләгән монографияләрне кулланырга мөмкин. Күрсәтмәлелек принцибын тормышка ашыру максатыннан татар халкының милли киемнәре, бизәнү әйберләре, эш кораллары, йорт-җире фоторәсемнәрен, әлбәттә, интернет сайтларыннан алырга мөмкин. Тик, минем күзәтүләремә караганда, андагы материал бик бай түгел, шуңа күрә укытучы үзе күпсанлы музейларда булырга, аларның экспонатлары белән якыннанрак танышырга һәм фотога төшереп, әлеге фотосурәтләрне үз презентацияләрендә куллана алырга тиеш.

Дәрестә әлеге төр мәгълүматны бирүне системалы итеп оештырырга була. Әйтик, 5 нче сыйныф укучыларына күбрәк рәсемнәр кулланылган, җиңел формадагы информация бирү кулайрак булса, шул ук вакытта уен элементлары белән аралаштыру да укучыларның информацияне кабул итү һәм белем алуга мотивация булдыру файдасына. Тора-бара, югары сыйныфларга якынлашкан саен, материалны катлауландыра барырга мөмкин, югары сыйныф укучылары фәнни-тикшеренү эше алып барып, үзләре дә аерым бер темага доклад, реферат, презентация әзерли ала.

Мондый төр дәресләр үткәрүнең актуальлеге бәхәссез. Беренчедән, бүгенге көндә мәктәпләрдә татар халкы тарихы бик аз күләмдә укытыла яисә бөтенләй укытылмый. Шуңа күрә татар теле дәресләрендә, коммуникатив һәм тәрбияви максатларны күздә тотып, кызыклы этнографик-тарихи темаларны яктырту укучыларга үз халкының үткәне турында күпмедер күләмдә мәгълүмат биреп, аларда татар тарихын өйрәнүгә мотивация булдыра. Икенчедән, бүгенге көн укучыларында татар халкының гореф-гадәтләре, традицияләре турында күзаллау бик шартлы. Бигрәк тә зур шәһәрләрдә яшәүче балалар өлкән буын вәкилләре – әби-бабаларыннан читтә яши, шуңа күрә аларда татар халкының гасырлар дәвамында формалашкан гореф-гадәтләре турында хәбәрсез булып калуы ихтимал: "Әбиләрегез яшь чакта кульяулыклар чиккәндер, күргәнегез, сораганыгыз бармы?" - дип сорагач, балалар "без әби белән яшәмибез, ул аерым яши" яки "әби-бабай үлгән, йортлары сатылган инде", диләр. Өченчедән, мондый тип информация укучыларда милли музейларга һәм аларның экспонатларына кызыксыну уята, укучылар музейга барыр алдыннан да күпмедер күләмдә мәгълүмат ала. Гомумән, социомәдәни компетенцияне тел материалы белән бергә үреп, диалогик яки монологик сөйләм итеп үткәргәч, укытучы үзе укучыларны музейга алып бара ала, музейга барырга теләк белдерүчеләр саны бермә-бер

арта. Дүртенчедән, укучыларда татар халкының дөнья цивилизациясенең бер өлеше булуын, аның үз милли киенү рәвеше, күзаллаулары, гореф-гадәтләре, рухи һәм материаль байлыгы барлыгы турында фикер урнаша.

Ә тәрбияви максаты татар милли бизәкләре, татар халкының киенү үзенчәлекләре, гореф-гадәтләре, аш-су осталыгы, кулдан эшләнгән эш кораллары турында мәгълүмат бирү, укучыларда үз халкының гореф-гадәтләренә, этнографик үзенчәлекләренә ихтирам-хөрмәт уяту, горурлык хисе тәрбияләү булган дәресләр комплекслы тәкъдим ителсә, укучыларыбызда үз халкы мәдәнияте турында тулы күзаллау булдырырга мөмкин. Шул рәвешле бүгенге заман 21 нче гасыр укытучысы татар телен һәм әдәбиятын өйрәтү белән беррәттән, укучыларда, ягъни киләчәк буын вәкилләрендә, үз үткәненә, тарихына, мәдәни мирасына ихтирам-хөрмәт тәрбияли, димәк, һәр бала үз-үзен яратырга, әби-бабасын, әти-әнисен хөрмәтләргә өйрәнә.

Йомгак.

Хәзерге шатрларда татар телен дәүләт теле дәрәҗәсендә гамәлгә кертү өчен, объектив шартлар җитәрлек. Ә татар телен дәүләт теле дәрәҗәсенә күтәрү, иң беренче чиратта, мәктәпләр эшчәнлеге белән бәйле. Шунлыктан, татар телен чит аудиториядә укытуны мөмкин кадәр нәтиҗәлерәк итү – бүгенге көн педагогикасының мөһим бурычларыннан берсе. Ә уңай нәтиҗәләргә ирешүдә заманча технологияләргә таяну ярдәм итә ала.

Белем бирүдә заманча технологияләрне куллану ул - әхлаклы кеше тәрбияләү, педагогик технологияләр булдыруда фәннең роле арту, өйрәнгәнне тормышта куллана белү һәм башкалар.

Инновацион технология буенча татар теленә өйрәтү – уку-укыту процессын яңача оештыруны аңлата. Бу вакытта укыту процессы төп нәтиҗәгә - укучының актив коммуникатив эшчәнлеккә омтылуын алдан сизүгә, баланың хисси һәм интелектуаль мөмкинлекләрен файдаланып аралашуга юнәлтелә.

Дәресләремдә заманча технологияләрне кулланып мин түбәндәге нәтиҗәләргә ирешә алдым дип уйлыйм:

- укучыларның сөйләм теле яхшырды, сүзлек запасы баеды;

- татар мәдәнияте, сәнгате, әдәбияты турында күзаллаулары үсте;

- башлангыч сыйныфлар һәрбер укучыга иҗади эшләр портфолиосы булдырылды. Анда укучыларның иҗади эшләре тупланып бара. Укучылар мондый эшләрне бик кызыксынып һәм теләп башкаралар.

- компьютер технлогияләре куллану уку эшчәнлеген тагын да баетты;

- укучыларның иҗади эшчәнлеге артты.

Менә шундый юллар белән мин үземнең укучылармның сөйләм телен үстерү һәм камилләштерү өстендә эшлим. Эшемнең нәтиҗәсе буларак укыткан укучыларым ачык дәресләрдә, төрле конкурсларда, призлы урыннар алалар.

Алда язылганнардан нәтиҗә ясап, шуны әйтергә була: педагогика фәнендә укыту-тәрбия процессы сыйфатын үстерергә булышлык итүче технологияләр байтак. Укытучының бурычы – яңалыклар агымында югалып калмыйча, дөрес юнәлеш алу, һәр этап өчен уку материалын аңлатуның иң уңышлы вариантын табу. Иң мөһиме шул: заманча технологияләрне куллану алынган мәгълүматның 85%ка якынын, ә традицион технологияләр – 40% белемне хәтердә озак сакларга ярдәм итә.

**Кулланылган әдәбият**

1. Р.З.Хәйдәрова, Л.Ә.Гыйниятуллина. Рус телендә сөйләшүче балаларга татар теле укыту- Казан “Татармультфильм” 2013.
2. Әсәдуллин А.Ш., Юсупов Р.А. Рус телендә сөйләшүче балаларга татар телен укыту методикасы нигезләре. – Казан: Мәгариф, 1998.
3. Харисов Ф.Ф., Ч.М. Харисова, В.А. Гарипова.Рус телендә урта(тулы) гомуми белем бирү мәктәпләре өчен татар теле һәм әдәбиятыннан үрнәк программалар: 1-11 сыйныфлар; Казан: Татарстан китап нәшрияты,2011.
4. Сафиуллина Ф.С., Фәтхуллова К.С. Татарский язык. Интенсивный курс. – Казан: Хәтер, 1998; 1999.
5. Харисов Ф.Ф. Научные основы начального обучения татарскому языку как неродному. – Казань: Изд-во ТАРИХ, 2000. – 479 с.
6. Харисов Ф.Ф. Татар телен чит тел буларак өйрәтүнең фәнни-методик нигезләре / Русчадан Н.К.Нотфуллина тәрж. – Казан: Мәгариф, 2002.

Харисов Ф.Ф. Основы методики обучения татарскому языку как неродному. – СПб: филиал издательства «Просвещение», 2001.

*Шәймөхәммәтова Фәнзилә Мирзанур кызы, Муратова Лариса Миншәех кызы, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Бакый Урманче исемендәге «2нче гимназия» муниципаль бюджет белем бирү учреждениесенең югары категорияле укытучылары*

## Туган тел һәм әдәбият дәресләрендә уңай мотивация тудыру

**1. Мотивация** барлык укытучылар өчен дә катлаулы проблема булып тора. Укучының укуга иң югары мотивациясе – фәнгә карата ихтыяҗы, кызыксынучанлыгы. Россия психологларның әйтүләре буенча, укучының интеллектуаль активлыгына аның кызыксынучанлыгы юнәлеш бирә, чөнки ул игътибарлылык һәм фикерләү дәрәҗәсенә

йогынты ясый. Безнең проект эшенең төп төшенчәсе булган мотив төшенчәсенә аңлатма бирик. **Мотив** (француз сүзе - motif) – теләк тудыру, сәбәп булу; латин телендә – хәрәкәткә китерү, этәрү. **Мотивация** – кешене төп эшчәнлеккә этәрүче мотивлар җыелмасы.

Педагогика фәне бу төшенчәгә түбәндәгечә аңлатма бирә:

**Мотивация** – укучыларны танып белү эшчәнлегенә, белем эчтәлеген актив үзләштерүгә этәрә торган эшчәнлек төрләре, ысуллары һәм чаралары

**Укуга мотивация** – укучылар тарафыннан укуда максатка ирешү өчен күрсәтелә торган активлык. Укучылар өчен түбәндәге мотивлар (ихтыяҗлар) әһәмиятле һәм кирәкле исәпләнә:

- танып - белү;
- коммуникатив;
- эмоциональ;
- үзүсеш;
- укучы позициясе;
- уңышка ирешү;
    - тышкы (мактау, шелтә).

Белемгә мотивациянең үзенчәлеге шунда, эшчәнлек процессында укучы белемнәр үзләштерә һәм шәхес булаларк формалаша. Уңышлы белем бирүнең төп шартларының берсе укуга ихтыяҗ тудыру икәнлеге дә дәлилләнгән.

Уңай мотивация тудыру һәм аның белән идарә итү өчен диагностикалау әһәмиятле. Бу диагностика үз эченә түбәндәгеләрне ала:

- башлангыч сыйныф укучыларының укуга мотивациясен өйрәнү һәм дәрәҗәсен билгеләү – югары, уртача, түбән;
- урта сыйныф укучылар арасында анкета үткәрү һәм укучы өчен әһәмиятле уку мотивларын билгеләү;
    - укучылар өчен уңай мотивацион өлкә булдыруда укытучының эшен анализлау.

Бу эштә укытучы тарафыннан түбәндәгеләрне исәпкә алынуы кирәк:

- укучыларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алу;
- укучыларның мөмкинлекләрен исәпкә алган эш төрләре куллану;
- максатка ирешүдә эш алымнарын укучы белән бергәләп сайлау;
- парларда,төркемнәрдә эшләү эш алымнарын куллану;
- мультимедиа, электрон ресурслар, презентацияләр һ.б. файдалану;
- уен элементларын кертү;

- дәрес бирүнең традицион булмаган формаларын куллану;
- үзара хезмәттәшлек һәм аңлашу атмосферасы тудыру;
- уңышка ирешү ситуациясе тудыру;
- укытучының укучы мөмкинлекләренә ышануы;
- укучыны кечкенә генә уңышлары өчен дә мактау;
- укучыларны үз эшчәнлекләрен дөрес бәяли белергә өйрәтү;
- укытучының эмоциональ сөйләме.

Белем бирүне модернизацияциләү Стратегиясендә белем бирүнең укучыларны мөстәкыйль эшләүгә, үзбелем алуга, мәгълүматларны анализлый белү күнекмәләре булдыруга, җаваплылык һәм актив эшчәнлек тудыруга юнәлдерелгән укыту технологияләрен һәм методларын кулланырга кирәклеге ассызыклана. Безнең алга шәхескә юнәлдерелгән белем бирү принципларын тормышка ашыручы, заманча информацион технологияләргә нигезләнгән яңача белем бирү моделен булдыру мәҗбүрилеге килеп басты.

**2. Дәрестә уңай мотивация тудыру юллары**

Мәктәпнең төп укыту формасы - дәрес. Дәрес, аны планлаштыру һәм үткәрү - бу укытуның һәр көнне аңлап, уйлап башкара торган эше. Дәрес - ул укытучының шәхси һәм һөнәри “көзгесе”, иҗади остаханәсе. Һәрбер дәрестә укытучының педагогик системасын һәм нәтиҗәләрен күрергә була. Дәрестә яңача ачышлар туа, экспериментлар үткәрелә, проблемалар чишелә, хаталар ачыклана, иҗади эзләнүләр алып барыла, уңышлы нәтиҗәләр ясала. Дәрес ул - укучы өчен үсеш вакыты: кызыклы һәм мавыктыргыч “Белем дөньясына” сәяхәт итү, фән баскычларыннан биеклекләргә менү, аның серле һәм таныш булмаган сукмакларыннан бару. Укытучы һәр дәресенә зур әзерлек белән керә, кечкенә шәхесләрнең интеллектуаль, социаль, психик, физик һәм рухи сфераларын үстерүгә зур көч куя һәм махсус шартлар булдыра. Дәрес ул шәхси һәм социаль тормышның бер мизгеле һәм күренеше. Дәрес процесс буларак, ул – диалог, аралашу, шәхесара төрле мөнәсәбәтләргә керү, эшчәнлек башкару. Дәрес никадәр җанлы һәм кызыклы – укучыда фәнгә карата уңай мотивация шулкадәр югары.

Татар теле курсының төп бурычы – аңлап дөрес укырга, сөйләргә, грамоталы язарга һәм дәреслек белән эшләргә өйрәтү. Ә бу күнекмәләр укучының әдәби тел нормаларына туры килгән сөйләмендә, фикерен телдән һәм язма әйтеп бирә алуында күренә.

Татар теленнән укыту-методик комплектларының концептуаль нигезе аның коммуникатив һәм танып-белү юнәлеше. Телне, аның төп төшенчәләрен һәм кагыйдәләрен үзләштерү сөйләмдәге коммуникатив белем һәм күнекмәгә бәйле, һәм инде шул аларга гамәли һәм функциональ юнәлеш өсти дә. Укытуның коммуникатив юнәлеше

укучыларга телне аралашу чарасы буларак үстерү, кирәкле мәгълүматлар туплау, телдән һәм язма сөйләмне камилләштерү мөмкинчелеге бирә. Укытуның танып-белү юнәлеше, телнең танып-белү чарасы буларак, белем формалаштыру, логик һәм образлы фикерләүне үстерүне күздә тота. Бу дәреслеккә кертелгән текстларны күп максатта куллануны таләп итә.

Дәрес структурасын күзаллау, төзү бу очракта укытучыдан шактый иҗадилык таләп итә. Укытучыга дәрес структурасы буенча төгәл күрсәтмә юк. Ул Федераль дәүләт гомуми белем бирү стандартында күтәрелгән мөһим таләпләрне исәпкә алып, дәрес стуктурасын үзе төзи. Әмма бер дәрес кысасында укытучы нинди нәтиҗәләргә ничек ирешәсен ачык күзалларга тиеш. Укучыга нәтиҗәле белем алу өчен эффектив ысуллар кулланып, уңай шартлар булдыру - укытучының бурычы һәм шул ук вакытта һөнәри осталыгын күрсәтү мөмкинлеген бирүче чара.

Укучыларның танып - белү эшчәнлеген активлаштыру һәм укучыларда уңай мотивация булдыру дәреснең һәр этабында тормышка ашырылырга тиеш. Укучыларны кызыксындыруны тәэмин итә торган кайбер нәтиҗәле алымнарга күзәтү ясап китик.

1. Оештыру, ягъни мотивлаштыру өлеше. Дәресне төрле мотивацион чаралар ярдәмендә башлап җибәрү. Мәсәлән, уңай халәт тудырырга ярдәм итә торган шигырь сөйләү, табышмаклар әйтү, бер-береңә комплиментлар әйтешү, теләкләр, яхшы кәеф теләү, укучыларга исемнәре белән эндәшү, мактау сүзләре

2. Уку материалын аңлатканда:

- сүз белән эшләү алымнары (сөйләү, сүзлек эше, әңгәмә, һ.б.);

- практик алымнар (күнегүләр, буклетлар , презентацияләр эшләү, электрон дәреслекләр куллану).

3. Фикерләү, уку эшчәнлеге белән идарә иткәндә: проблемалы эзләнү методы (проблемалы сорау кую, проблемалы ситуация тудыру, парлы, группаларда эшләү, фәнни-тикшеренү эшләре) .

Дәрестә дә, өй эше итеп тә эзләнү, тикшеренү, уйлану таләп иткән эшләр бирү нәтиҗәле.

4. Уку эшчәнлеген активлаштыру өчен дәресләрдә эмоциональлеккә ирешү, танып-белү уеннары, уңыш ситуациясе булдыру, үзара ярдәм оештыру бик отышлы алым була.

5. Өйгә эш бирү индивидуаль яки дифференциаль якын килүне сорый. Мәктәп баласы мәҗбүри итеп бирелгән өй эшен бик яратмый. Кимендә өч вариантта бирелгән һәм сайлап алу мөмкинлеге булган эш теләп башкарыла. Бигрәк тә иҗади биремнәргә укучы җаваплырак карый.

Укыту формаларын һәм ысулларын төрләндерү дәрес эчтәлеген баерак һәм кызыграк итә. Моннан берничә еллар элек уку - укыту процессында укытучының төп эш коралы булып такта белән акбур торса, хәзер инде хәл бөтенләй башкача.

Татар теле дәресләрендә укучыларны кызыксындыру, дәресне мавыктыргыч итеп үткәрү өчен компьютер куллану бик отышлы. Компьютер – укучы белән белемнәр системасы арасында арадашчы, белем алу чарасы. Компьютердан файдалану укыту эшчәнлеген баета, укыту процессын кызыклы, нәтиҗәле һәм иҗади итеп оештырырга мөмкинлек бирә. Ул сыйныф тактасын да, тарату материалын да, дәреслекләрне дә алыштыра ала, дәреснең нәтиҗәлелеген арттыруга ярдәм итә. Һәр укучының белем үзләштерүгә сәләте төрлечә була. Кайбер укучыларның ишетеп истә калдыру дәрәҗәсе өстенлек алса, күпчелек укучыларда күреп истә калдыруы өстен чыга. Менә шушы вакытта компьютер ярдәмгә килә. Чөнки мониторда барлык биремнәр матур, эстетик яктан камил эшләнә. Презентацион программаларны төзегәндә, аның эченә бик күп материал салына: төрле схемалар, рәсемнәр, фотосурәтләр.

Белем бирүдә компьютер технологияләрен куллануның нәтиҗәләре:

- белем бирүнең эффективлыгын күтәрү (укучының интеллектын һәм информация эзләүдә мөстәкыйль эшләү күнекмәләре булдыру; дәрестә төрле укыту алымнарын кулану); белемнәрне киңәйтүгә мөмкинлекләрнең артуы;
- уку процессы белән идарә итүдә сыгылмалылык (эшнең барышын һәм нәтиҗәсен күзәтеп бару мөмкинлеге);
- дәресне оештыруның сыйфаты яхшыру (дидактик материалларның җитәрлек күләмдә һәм һәрвакыт кул астында булуы);
- укучыларның белемнәрен контрольдә тотуның сыйфаты күтәрелү һәм аның күптөрле формалары барлыкка килү;
- укучыларны парларда, төркемнәрдә эшләүгә тарту;
- баланың фәнне өйрәнүгә теләге арту, белем сыйфаты күтәрелү, укучыларның иҗади потенциалы активлашу;
- укучыларның һәм укытучыларның заманча мәгълүмати тирәлеккә керешеп китүләре, укучы шәхесенең үзреализациясе һәм үзүсеше.

Интерактив такта куллану дәресләрне тагы да мавыктыргыч, нәтиҗәле итәргә ярдәм итә. Интерактив такта белән эшләүче укытучы һәрвакыт укучыларның игътибар үзәгендә, сыйныф белән элемтәдә тора. Бу алым укучыларның белем сыйфатын үстерергә, яңа материалны һәр балага җиңел, аңлаешлы итеп җиткерергә дә ярдәм итә.

Шулай ук татар теле дәресләрендә интернет - ресурсларны куллану уку, язу күнекмәләрен булдыру һәм үстерү, кирәкле материал табу, укучыларның сүзлек запасын

баету, татар телен өйрәнүгә мотив формалаштыру кебек дидактик бурычларны үтәргә мөмкинлек бирә.

Яңа технологияләр ярдәмендә телне өйрәнү укучыны тагын да активлаштыра, мөстәкыйльлек тәрбияли, фәнне югары дәрәҗәдә үзләштерү, максатка омтылучанлык, информацион технологияләр дөньясында яңалыклар белән кызыксыну теләге уята.

Дәрестә куелган бурычлар башка чараларга этәргеч булып торалар: укучылар эзләнүләр алып баралар, аларга ярдәм йөзеннән экскурсияләр оештырыла, укучылар үзләренең эзләнүләреннән чыгып иҗади эшләр башкаралар. Шушы эшләргә йомгак ясау өчен, сыйныфтан тыш чаралар үткәрелә. Дәреснең төрле этапларында һәм төрле типтагы дәресләрдә халык педагогикасына мөрәҗәгать итү бу бөтенлекне сакларга, үстерергә ярдәм итә.

Шулай ук бу метод укучыларны компьютер белән эшли белергә, текст процессоры ярдәмендә төрле документлар, график программалар, иллюстрацияләр әзерләргә, электрон таблицаларда гамәлләр үтәргә, гади программалар төзергә, интернеттан файдаланырга өйрәтә.

Тел дәресләрендә проектлар методын куллану отышлы, чөнки проект эше – улниндидер идея, фикер өстендә, җентекле планлаштырылып, эзлекле эшләү һәм эш азагында күзгә күренерлек нәтиҗә чыгару, билгеле бер тема буенча информацияне бер схемада күрсәтү. Проектлар методы укучы шәхесенең белем алуга иҗади якын килүенә юнәлтелгән. Ул, теге яки бу проблеманы тирәнтен өйрәнү максатында, укытучы җитәкчелегендә эшләнә торган мөстәкыйль иҗади эш. Укучы күзлегеннән караганда, проект ул – үзең яисә төркем белән кызыклы нәрсә дә булса эшләп карау мөмкинлеге. Татар теле дәресләрендә укучылар проектлар эшлиләр: “Сүзлекләр” темасын өйрәнгәндә, сүзлекләр тарихы, сүзлекләр төзүче галимнәр турында, схемалар, сүзләр тарихыннан чыгыш әзерләү, лингвистик темаларга сочинениеләр язу, фразеологизмнарның әдәби әсәрләрдә кулланылышы турында фәнни эшләр һ.б. Кроссвордлар, ребуслар, иллюстрацияләр, тестлар дәрескә карата кызыксыну уята; дәресләрне тагын да кызыклырак итә. Проекттагы информация һәр дәрестә укучының күз алдында була, кирәк вакытта ул аңа мөрәҗәгать итә ала. Бу исә материалның хәтта йомшак укучылар тарафыннан да үзләштерелүен тәэмин итә.

Проектлар методының нәтиҗәләре:

- тел һәм әдәбият буенча материалны бәйләнештә карау, өйрәнү;

- укучының дәресләрдә төп белем алуы, эш төрләре, кагыйдәләр белән танышуы;

- метод кызыксынучанлыкны, һәр яңа эш төрен ихлас, дәртле итеп башкару теләген уятуы;

- проекттагы информациянең һәр дәрестә укучының күз алдында булуы ( кирәк вакытта ул аңа мөрәҗәгать итә ала).

Нәтиҗәләрнең яхшы сыйфатына ирешүдә татар теле дәресләрендә уен технологиясе алымнарын куллануның роле зур дип әйтә алабыз, чөнки мәктәп балаларының укуга, белем алуга омтылышын, кызыксынуын ныгытуда, аларның күзәтүчәнлеген арттыруда һәм иҗади фикер йөртү сәләтен үстерүдә уеннар гаять зур әһәмияткә ия. Ә моның өчен мөмкинлекләр җитәрлек. Әйтик, дәреснең аерым этапларында төрле уен элементлары кертергә була. Дәресләрдә уен технологиясе уенга корылган төрле ситуацияләр аша тормышка ашырыла һәм уку эшчәнлегендә кызыксындыру, эшкә дәртләндерү чарасы буларак файдаланыла.

Дәресләрдә презентацияләр, “Электрон белем бирү” сайтындагы татарча мультфильмнарны карап фикер алышабыз, “Цифрлы белем бирү ресурслары”на (ЦОР) куелган тематик күнегүләрне башкарабыз, “Ана теле” порталындагы видеоязмаларны, УМК га кушымта булып барган дисктагы текстларны тыңлыйбыз. Мультфильмнарны тавышсыз гына тыңлап, балаларга аларны үзләренчә “тавышландырырга” (персонаж булып сөйләргә) кушкан биремнәр дә бик кызыклы килеп чыга.

Мультимедиа технологиясе слайд – иллюстрацияләр күрсәтергә, читтән торып экскурсия үткәрергә мөмкинлек бирә. Әдәбият дәресләрендә иллюстрацияләр, сәнгатьле уку күнекмәләрен бирү һәм шагыйрьләрнең көйгә салынган җырларын тыңларга мөмкин. Дәреснең төрле этапларында материал мультимедиа аша бирелә.

Уңышка ирешү ситуациясе тудыру укучыларда үз мөмкинлекләренә ышанычны арттыра һәм белем алуга уңай мотивация булдыра. Күп кенә танылган педагоглар да уен методына зур игътибар биргәннәр. В.А.Сухомлинский : « Бала - үзенең табигате белән эзләнүче, дөнья ачучы. Шулай булгач, аның алдында тылсымлы дөнья бөтен төсләре белән ачылсын. Бу төсләр ачык һәм дулкынландыргыч тавышларда, әкиятләрдә, уеннарда, баланың үз иҗатында... Әкиятләр, фантазия, уен , баланың кабатланмас иҗаты - болар барысы да бала йөрәгенә дөрес юл...”,- дигән. Телдән кулланыла торган уен элементлары язуда кыенлыклар кичерә торган укучы өчен уңышка ирешү юлы. Уенлы биремнәр акыл, йөгерек уй , хәтер үсешенә уңай йогынты ясый. Күп кенә уеннар белем белән беррәттән ихтыяр көче, түземлелек, уен кагыйдәләрен үтәүне таләп итә. Иң мөһиме: уен укучы алырга тиешле белемне бирә торган, аны актив белем алу эшчәнлегеннән игътибарын читкә юнәлтми торган булсын, киресенчә, укучыны актив акыл эшчәнлегенә китерсен.

**Икенче бүлек. Укучылар эшләре.**

*Абзалутдинова Эльза Вәсил кызы, 7 нче сыйныф,*
*Татарстан Республикасы Тукай муниципаль*
*районы Сәмәкәй төп гомуми белем бирү мәктәбе*
*Җитәкчесе: Сәгыйтова Ләйсән*
*Рәхим кызы, биология укытучысы*

**Фитонцидларның азык-төлек сакланышына йогынтысы**

Кешелек дөньясы физик, җылылык һәм биологик эшкәртү ысулларына мөрәҗәгать итеп, микроорганизмнар һәм аларның агулы калдыклары продуктларын нейтральләштерергә өйрәнде. Озак вакыт саклау өчен, продуктларны җылылык белән эшкәртү еш кулланыла, бу аларның туклану кыйммәтен һәм тәмен киметә. Микроорганизмнар һәм фитонцидлар турында белмәгән ата-бабаларыбызның тәҗрибәсен исәпкә алып, алар үсемлекләрне азык саклау өчен кулланганнар. Моның өчен фитонцид үзлекләренә ия булган төрле кыргый үсемлекләр кулланыла.

Фитонцидлар - бактерия, түбән төзелешле гөмбәләр һәм иң гади төзелешле организмнар үсешенә тискәре йогынты ясый торган, югары төзелешле үсемлекләр бүлеп чыгарган матдә. Төрле үсемлекләр җитештергән фитонцидларны продуктларны озаграк саклау өчен кулланырга мөмкин.

**Фитонцидлар, аларның азыкны саклау процессындагы роле**

Кешеләр күптән инде кайбер үсемлекләрнең антимикроб үзенчәлекләргә ия булуын сизәләр. Борынгы заманнардан ук аучылар киекне үләннәр белән төргәннәр. Галимнәр үсемлекләрнең, аларның тукымаларының яки махсус үзгәрүчән фракцияләрнең күп микроорганизмнарны үтерә алуын билгеләделәр. Ләкин моның өчен фәнни аңлатма юк.Бу искиткеч табышмакны совет галиме Б.П.Токин 1928 елда ачкан. Очучан матдәләр микроорганизмнар белән аяусыз эш итәләр, тикшерүче аларны фитонцидлар дип атый: грек "phyton" (үсемлек) һәм латинча "caedo" (мин үтерәм).

Борис Петрович көнчыгыш базарларында, санитар булмаган шартларда әзерләнгән азык-төлек продуктларының йогышлы авырулар китереп чыгармавына игътибар итә. Ул көнчыгыш тәмләткечләренең күпчелеге ничектер ризыкның бозылуына комачаулый. Токин тәмләткечләрдәге матдәләрне тикшерде һәм үзгәрүчән компонентларның антисептик эффект биргәнен ачыклады. Ул бу "үзгәрүчән үсемлек агуларын" фитонцидлар дип атарга тәкъдим итте. Фитонцидлар ачылганнан бирле, үсемлекләрнең антимикроблы һәм вируслы матдәләре турында бик күп фактик материал тупланган. Фитонцидаль эшчәнлекнең бөтен үсемлек дөньясына хас булуы исбатланды.

Фитонцидларның иң мөһим үзенчәлекләренең берсе - аларның эш үзенчәлеге. Хәтта микроскопик дозаларда да алар кайбер микроорганизмнарның үсешен һәм үрчүен

тоткарлый, башкаларның үсешен стимуллаштыра һәм һава, туфрак һәм су микрофлорасы составын көйләүдә мөһим роль уйный ала.

Барлык үсемлекләр дә үзләрен саклау өчен фитонцидлар эшләп чыгаралар. Алар вирусларга, бактерияләргә, бер күзәнәкле һәм кайбер күп күзәнәкле организмнарга зарарлы йогынты ясыйлар. Бу очучан матдәләр үсемлекләрне генә түгел, хайваннарны да, кешеләрне дә саклый.

Теләсә нинди үсемлек – бактерияләрдән алып чәчәкле үсемлекләргә кадәр - фитонцидлар бүлеп чыгара, һәм бу матдәләр химик табигате буенча бик күп төрле. Очучы фитонцидларның эш механизмы шунда: алар микробиаль күзәнәктә төрле үзгәрешләр тудыралар: сулышны кысалар, цитоплазманың өслек катламнарын һәм компонентларын (ферментлар һ.б.) эретәләр һәм юк итәләр. Фитонцидлар микроорганизмнарга үз оборона механизмнарын булдырырга рөхсәт итмиләр.

**Төрле үсемлек фитонцидларының үзлекләрен өйрәнү**

Фитонцидлар - үсемлек дөньясында универсаль күренеш. Югарытөзелешле үсемлекләрнең якынча 85% югары фитонцид активлыгына ия. Аерым алганда, бик актив фитонцидлар сарымсак, суган, лимон, кара карлыган, башлы кәбестә, каен, имән, артыш, чыршы, нарат, шомыртта очрый

Тикшеренүнең эксперименталь өлешендә кулланылган үсемлекләрнең фитонцидүзлекләрен карап үтәбез.

<u>Чыршының фитонцид үзлекләре</u>

Нарат һәм чыршы популяр үсемлекләр, аларның фитонцид үзлекләре организмның саклану көчен арттыра, шулай ук төрле авыруларның патогеннарына зарарлы тәэсир итә. Юкка гына, күпчелек санаторийлар һәм больницалар ылыслы урманнарда төзелгәннәр, наратның очучан фитонцидлары үпкә һәм тире аша кеше организмына үтеп керә ала. Алар патогеннар үсешен тоткарлый, аны йогышлы авырулардан саклый. Урманлы җирләрдә яшәүче кешеләрнең югары сулыш юллары авыруларына шәһәр кешеләренә караганда азрак бирешүе очраклы түгел.

<u>Сарымсакның фитонцид үзлекләре</u>

Кытай медицинасында сарымсак ашкайнату системасы, сулыш алу, ару, ревматизм һәм тире авыруларында тоник эффект белән бәяләнде. XVII гасыр азагында Лондондагы чума эпидемиясе вакытында Британия табиблары сарымсакны чумадан саклап калу чарасы итеп пропагандаладылар.

Күпчелек халыклар суган һәм сарымсак җеннәр җибәргән авыруларны дәвалый һәм алардан саклый дип саный. Көнчыгыш Европада сарымсак вампирларны җиңәр өчен ышанычлы ысул булып саналды. Моның өчен алар белән ишек тоткалары һәм тәрәзә

рамнары сөртелде, түшәмгә сарымсак лампаларының бөтен гирляндалары эленде. Болгария, Венгрия, Румыниядә яшәүчеләр өчен сарымсак талисманның бер төре иде, алар аны тормышның мөһим мизгелләрендә янәшәдә сакларга тырыштылар.

XIX гасырда Франция микробиологы Луи Пастер сарымсакның "тылсымлы" эффектын аңлатты. Берничә эксперименттан соң, галим сарымсак согының антисептик үзлекләрен ачты. Соңрак, сарымсак фитонцидлары тикшерелде, ләкин аларның химик составы билгеләнә алмады. Билгеле булганча, сарымсакның антибактерия эшчәнлегенә зур өлеш, аллисин, аның исе өчен җаваплы матдә. Хәтта меңләгән тапкыр сыегайтылган, аллисин бактерияләрнең үсүен һәм үсешен тоткарлый ала. Сарымсак фитонцидлары грамм-уңай һәм грамм-тискәре бактерияләрне, шулай ук төрле гөмбәләрне үтерәләр.

<u>Лимон фитонцидлары</u>

Мең ярым ел элек Кытай китапларында лимон белән чәй ясау рецепты бирелгән. XVII гасырда Кытайда лимон яраларны һәм үпкә авыруларын дәвалау өчен кулланылган. Кытайлар лимонның йөзләрчә ел элек файдасын билгеләделәр.

Лимоннын яфрагыһәм кабыгы эфир маена бай. Бактерицид көче ягыннан, аның фитонцидларын сарымсак һәм суган фитонцидлары белән чагыштырып була: алар менингококкны 15 минутта, бер сәгать эчендә тиф бактерияләрен, пневмококкларны 3-12 сәгать эчендә нейтральләштерәләр.

<u>Горчица фитонцидлары</u>

Горчица - составында аллил мае бар. Горчица фитонцидларының бактерицид һәм антифунгал үзлекләре бик көчле. Plantсемлек авыруларын һәм аларның спораларын китереп чыгаручы бик нык зарарлы гөмбәләр  алты сәгать очучан фитонцидлардан соң үлә, һәм күп бактерияләр беренче минутларда үлә! Әгәр дә бу литрга 25 мг бу май кушылса, сок озак вакыт үз сыйфатын саклый һәм начарланмый. Горчица яфракларында һәм орлыкларында күп күләмдә фитонцидлар бар.

**Эшнең практик өлеше**

Фитонцидларның азыкны саклау процессына тәэсирен өйрәнү

<u>Тикшеренүнең максаты:</u> фитонцидларның азыкның саклану вакытына тәэсир итү дәрәҗәсен билгеләү

<u>Практик нигез:</u>күгәрек гөмбәләренең үсешенә продукт табигатенә бәйләнешен ачыклау

Җиһазлар:

• пыяла савытлар;

• ризык үрнәкләре: ипи, сыр, лимон;

• блокнот, ручка.

Эксперимент барышы:

Тикшеренү өчен: арыш ипи кисәкләре, сыр һәм лимон. Үрнәкләр пыяла савытларда нарат һәм чыршы үсемлекләре, сарымсак һәм изелгән горчица салынды. Контроль үрнәк аерым урнаштырылды. Күзәтүләр 14 көн дәвамында үткәрелде. Күзәтүләр таблицага кертелде.

| Үрнәк | Күгәрек барлыкка килү | Күгәрекнең үсеше |
|---|---|---|
| Ипи, сыр, лимон | 3 нче көн | актив үсеш |
| Ипи, сыр, лимон + чыршы | 4 нче көн | лимон - күп, икмәк һәм сыр - бераз |
| Ипи, сыр, лимон + нарат | 6 нчы көн | лимон, икмәк - күп, сыр - үсеш әкрен |
| Ипи, сыр, лимон + сарымсак | 5 нче көн | лимон - күбрәк, сыр һәм икмәк - әкрен үсеш |
| Ипи, сыр, лимон + горчица | юк | юк |

Контроль үрнәктә күгәрек 3-нче көнне барлыкка килде һәм актив үсә башлады. Чыршы һәм сарымсак продуктларында күгәрек 4-нче көнне барлыкка килде. Чыршы тирәсендә икмәк һәм сыр лимонга караганда азрак күгәргән. Сарымсаклы продуктлар тигез диярлек күгәрек белән капланган, ләкин лимонның күгәреге күбрәк. Нарат продуктларда күгәрек үсешен 6 көнгә кадәр тоткарларга булышты. Лимонда күбрәк, бераз сыр, икмәк үсүдә күренми диярлек. Горчица салынган савытта күгәрек барлыкка килмәде.

Тикшерү нәтиҗәләре буенча: барлык кулланылган үсемлек үрнәкләрендә дә фитонцидлар бар, ләкин аларның характеристикалары төрле. Чыршы иң аз фитонцид активлыгына ия. Горчица фитонцидның иң көчле үзенчәлекләренә ия. 10 көн эчендә күгәрек гөмбә бөтенләй барлыкка килмәде.

Шулай итеп, горчица фитонцидлары азык продуктларының саклану срогын арттырырга мөмкин, чөнки ул күгәрек гөмбәләренең таралу дәрәҗәсенә тәэсир итә.

Фитонцидлар - бактерияләргә, күгәрек гөмбәләргә һәм протозоага зарарлы югары үсемлекләр матдәләре. Барлык үсемлекләр дә фитонцидлар чыгара. Фитонцидларның иң зур күләме горчицада очрый.

Кайбер үсемлекләрнең фитонцидлары микробларны үтерәләр (мәсәлән, аларда бактерицид үзлекләре бар), калганнары микроорганизмнарның үсүен һәм үрчүен тоткарлыйлар (ягъни, алар бактериостатик эффектка ия). Фитонцидлар җитештерүче үсемлекләр ит, балык, җиләк-җимеш һәм башка продуктларны саклауда кулланылырга мөмкин. Фитонцидлар күп авыруларны дәвалау һәм профилактикалау өчен уңышлы кулланыла (фитонцидотерапия).

**Әдәбият исемлеге:**

1. Аксенова М. Балалар өчен энциклопедия. Биология: Аванта, 2007

2. Батурицкая И.В., Фенчук Т. Р. Үсемлекләр белән гаҗәп экспериментлар / Нәшрият йорты китабы, 1991

3. Бинас А.В. һ.б. Мәктәптә биологик эксперимент / А.В. Бинас - М. Мәгърифәтчелек, 1990

4. Блинкин С.А., Рудницкая Т.В. Фитонцидлар безнең тирәдә. М., 1981. 185 б.

5. Гольшенков П.П. Дару үләннәре һәм аларны куллану. - Саранск. Мордовия китап нәшрияты, 1990. - С.29-30.

6. Токин Б.П. Фитонцидлар турында повесть . - Л .: Университет нәшрияты, 1980.

*Афанасьева Лиана, 7 нче сыйныф, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Муса Җәлил исемендәге "1 нче гимназия" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*

*Житәкчесе: Фәләхиева Ильмира Ризатдин кызы, биология һәм география укытучысы, Миннегалиева Гөлназ Сәләхетдин кызы, татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

## Иске Комазан авылы тарихы

Хәзер балаларда милли үзаң тәрбияләү, татар теленә, халкына, тарихына, туган ягына мәхәббәт уяту, рухи яктан бай ,физик яктан камил шәхес тәрбияләү аеруча игътибарга лаеклы проблемаларның берсе булып тора.

Үзенең үткәненә һәм тарихына хөрмәт һәм ышаныч белән караган халыкның гына киләчәге бар. Шуңа күрә без олы шәхесләребез, бөек халкыбыз, үткән олы тарихыбыз белән горурланырга, алар рухы белән яшәргә тиешбез.

**Максат:**

Туган ягым – Комазан авылының бай тарихы турында күбрәк белү, башкаларга да җиткерү. Авылыбыздан чыккан күренекле һәм талантлы якташларыбызның күркәм эшләре белән таныштыру.

Минем туган авылым Иске Комазан. Русча исеме - Старый Кумазан. Авылның исеме үзгәрмәгән, официаль булмаган исеме юк. Хәзерге вакытта Иске Комазан авылы Мамадыш районы Дүсмәт жирле үзидарә составына керә. Элек Казан губернасы, Мамадыш кантонына кергән.

Авылдашларыбыз арасында күренекле сәнгать әһелләре, атказанган төзүчеләр, урманчылар, табиблар, укытучылар, орден-медальләргә лаек булган механизаторларыбыз, терлекчеләребезнең дә булуы белән мин чын күңелдән горурланам

**Иске Комазан атамасы каян килеп чыккан?**

Минем туган авылым Иске Комазан. Русча исеме - Старый Кумазан. Авылның исеме үзгәрмәгән, официаль булмаган исеме юк. Хәзерге вакытта Иске Комазан авылы Мамадыш районы Дүсмәт жирле үзидарә составына керә. Элек Казан губернасы, Мамадыш кантонына кергән.

Иске Комазан авылы район үзәге Мамадыштан 15 чакрым ераклыкта, Мамадыш - Кукмара юлы өстендә кала. Авыл чокырда, кечкенә таучыклар арасында урнашкан. Тирә-ягын катнаш урманнар чолгап алган. Нократ елгасына таба 7-8 чакрым ераклыкта Яңа Комазан авылы бар. Шуңа күрә, исемнәреннән чыгып, Иске Комазан авылына беренче нигез салганнар, дип уйларга була. Авылның нигезләнү вакыты билгеле түгел. Ләкин авылның исеме килеп чыгуы турында ике легенда бар.Мамадыштан Кукмарага баручылар чиста комлы урында Азан әйтеп китәләр. " Комда азан " дигәннән Комазан килеп чыккан. Элек авыл янында ком чыгару урыны булган. Бу урынны "Ком Казаны " дип йөрткәннәр. " Ком казаны " кыскарып, авыл исеме Комазан килеп чыккан.

Авылыбызда чын бай нәселләре юк. Тырыш хезмәт белән мул тормышта ̇ яшәүче нәсел Әгъләмнекеләр. Хәзерге көндә Иске Комазанда аның алтынчы буын вәкилләре туган. Әгъләмнекеләр – җирне үз итүчеләр, алдынгы механизаторлар.

Иске Комазанда татар һәм керәшен татарлары бүленеше юк. Ләкин, байтак кына татар һәм керәшен кушылган яшь гаиләләр бар.

Иске Комазан авылында истәлекле урыннар да юк түгел. "Кызыл йорт", "Бакыр ширбе", "Крестьян йөрәге", "Биге юлы", "Морза очы" кебек атамалар авылыбызның тарихына бәйле рәвештә килеп чыкканнар.

Авылыбызда туып-үскән, бүгенге көндә илебезнең терле почмакларында яшәп, Туган илебезгә армый-талмый хезмәт итүче күренекле шәхесләребезне дә атап китү урынлы булыр. Вахит ага Галиев – ТРның атказанган мәдәният хезмәткәре, шагыйрь, 9 китап авторы, Мамадыш районының Аксакаллар шурасы рәисе, сугыш һәм хезмәт ветераны. Гарәфи ага Әгъләмов - шагыйрь, 2 китап авторы, Алабуга шәһәрендә яшәп ижат итә. Мингол Галиев - Татарстанның, халык артисты, җырчы, КДПУ доценты, татар моңнарын бөтен дөнья халкына ишеттергән шәхес. Дусил Касыймов - Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театрында эшли, Татарстанның атказанган артисты. Иске Комазан авылы – районда ҺӘМ республикада билгеле булган шәхесләрне биргән авыл. Мәдәният өлкәсендә үзләреннән зур өлешфән өлкәсендә үзләреннән зур өлеш керткән, химия фәннәре кандидаты, доцент Мансур Хәсәнов, техник фәннәр кандидаты, доцент Әхмәтгаяз Гыйләҗевларны әйтеп үтәргә мөмкин.

Авылдашларыбыз арасында күренекле сәнгать әһелләре, атказанган төзүчеләр, урманчылар, табиблар, укытучылар, орден-медальләргә лаек булган механизаторларыбыз, терлекчеләребезнең дә булуы белән мин чын күңелдән горурланам.

Төбәктә яшәүче халык татар милләтеннән булып, Комазан башы, Дүсмәт авылларында яшәүче керәшен татарлары православие диненә карый. Сотый һәм Участок авылларында яшәүчеләрне катнаш- керәшен татарлары һәм татарлар тәшкил итә.

Торак пунктлардан Иске Комазан авылы иң зурлардан санала. Хәзерге вакытта152 хуҗалык булып, авылда 525 кеше яши. Авыл Комазан елгасы буйлап 1,5 км га сузылган.

Авылда төп гомуми белем бирү мәктәбе, медпункт, 4 кибет, Мәдәният йорты, китапханә, балалар бакчасы бар. Безнең Иске Комазан авылында да чишмәләр бик күп.

Изгеләр чишмәсе текә яр астыннан агып чыга. Чишмә тирәсе табигатьнең гаҗәеп матур урыны: өске өлешендә бик матур урман сузылып киткән, кояш чыгышына агучы "Изгеләр чишмәсе" бу урында кинәт бормалы-бормалы агышы белән дәвам итә. Ерак түгел наратлык әйләндереп алган. Гомумән, бу чишмә белән безнең авыл кешеләре озак еллар файдаланганнар һәм сокланып туя алмаганнар. Хәзер дә, әби-бабайлар изге чишмәнең суын эчеп, бит-кулларын юып, тәннәренә сафлык, чисталык алалар. Коръән укып хәер-сәдакаларын калдырып китәләр. Чишмә янындагы хәтфәдәй яшел чирәмгә утырып үзләренең матур теләкләрен телиләр. Төрле авырулар белән авырганда, изгеләр чишмәсеннән ераклардан килгән кешеләр саф чишмә суын алып китәләр. Изгеләр чишмәсе күп санлы : чишмәләрдән, суының салкынлыгы һәм тәме белән аерылып тора. Урманнан, яки басудан арып-талып эштән кайтучы авыл халкыбыз, җәйге көннәрдә чишмә янында хәл җыярга тукталалар, суын эчәләр. Җәйләрен кызарып кояш батканда изгеләр чишмәсе өстенә кып-кызыл булып кояш нурлары төшә, су өстендә үзенә бер сихри дөнья ачыла. Бер карап сокланып торган әби-бабайларның исләренә күп еллар булган тарихи көннәр исләренә төшәдер кебек, чөнки изгеләр чишмәсе ага башлавына күп гасырлар үткән.

**" Сәетбабай " чишмәсе**

Чишмә авыл башында, су буенда, тау астыннан агып чыга. Сәет бабай матурлыкны, табигатьне яраткандыр, ул анда ике яшь каен утырткан. Бу яшь каеннар шаулап үсеп киткәннәр. Хәзер бу каеннар зур булып үскәннәр. Сәет бабай каеннар турында күршеләренә болай ди: "Менә бу каенның берсе мин, берсе минем хәләл хатыным", дигән дә, мыек астыннан гына елмаеп куйган. Чынлап та, чишмәгә карап торсаң, андагы ике каенның берсе кыз, берсе егет кебек Сәет бабай чишмәсенең татлы суын эчеп үскән Гарафетдинабый да үзенең чишмәгә карата күңелендәге хисләрен ачып салган. Аның бу шигырь юллары күңелгә якын:

Барладым барып юлларын,
Үлән юк сукмагында.
Тыңладым җанып моң-зарын,
Янында туктадым да.
" Куяр җан тапмыйм бу җанны
Янәшәмдә пар каен.

Сагынам соңгы хуҗамны,

Каен шаулаган саен".

Бу шигырендә Гарәфи абый үзенең табигатькә һәм чишмәләргә карата мәхәббәтен ачып салган. Зур шигъри җанлы кеше ул, шуңардырмы, күңеле канатлы атлардай матурлыкка җилкенә.

**" Газизҗамал әби " чишмәсе**

Чишмәләр күбесенчә су буйларына урнашып ага. Чишмәләр бик күп, алар төрлесе-төрлечә. Онытылып, аны белгән кешеләр күптәннән дөньяда булмасалар да чишмәләрнең әкияттәй серле тарихы җәелеп ята. Һәр чишмәнең үз исеме, үз тарихы, аны төзегән кешесе була. АвылыбызныңЧаллы очы су буенда бер кечкенә генә тарихлы кое бар. Аны кое дип тә, чишмә дип тә йөртәләр. Чөнки ул казылган. Кое кебекбик тирән дә түгел. Бу чишмәне Газизҗамал чишмәсе дип йөртәләр.

1900 нче елларда бу чишмә янында бер Газизҗамал исемле әби торган, ире белән. Якын тирәдә чишмә булмаганлыктан, алар өйләре янына бер чишмә казып чыгаралар. Бучишмәне Газизҗамал әби үзе казыткан һәм чишмәне гомере өзелгәнче үзе чистартып, карап торган. Аннан соң аның Мөхәлисә, оныгы Шарифуллин Әлфир әбинең эшен дәвам иткәннәр.

Хәзерге көндә дә чишмә сакланып калган.

Бу чишмәдән башлап өскә таба, урманга кадәр 18 чишмә бар. Бу чишмәләр Чаллы очына керәләр. Бу 18 чишмәнең беренче чишмә төзүчесе Сәет бабай, икенчесе Газизҗамал әби. Юкка чыкканнары да күптер. Шушы 18 чишмәнең барлыкка килгән боргаланып агучы инеш төпләрендә ничәмә-ничә еллар су төбендә шомарып, ялтырап торучы ташлар борынгы болгар татарларының тарихын искә төшерә кебек.

**" Мәсер әби " чишмәсе**

Мәсер әби чишмәсенең дә килеп чыгышы Газизҗамал әби чишмәсенең тарихы белән туры килә. Мәсер әби чишмәне үзе карый, соңгы көннәренә кадәр чистартып тора. Хәзер чишмә үзгәртелеп яңартылды.

Кайсы милләт төсен алсагыз да,

Булсагыз да кайсы як, илдә,

Онытмагыз таныш туфрак барын,

Онытмагыз гүзәл телнең барын –

Җанга җылы туган Җирнең барын

Иксез – чиксез сәйярә – Җирдә!

Минем туган авылым - Иске Комазан. Русча исеме - Старый Кумазан. Авылның исеме үзгәрмәгән, официаль булмаган исеме юк. Хәзерге вакытта Иске Комазан авылы

Авылыбызда туып-үскән, бүгенге көндә илебезнең терле почмакларында яшәп, Туган илебезгә армый-талмый хезмәт итүче күренекле шәхесләребез:

Вахит ага Галиев – ТРның атказанган мәдәният хезмәткәре, шагыйрь, 9 китап авторы, Мамадыш районының Аксакаллар шурасы рәисе, сугыш һәм хезмәт ветераны;

Гарәфи ага Әгъләмов - шагыйрь, 2 китап авторы, Алабуга шәһәрендә яшәп иҗат итә; Мингол Галиев - Татарстанның, халык артисты, җырчы, КДПУ доценты, татар моңнарын бөтен дөнья халкына ишеттергән шәхес;

Дусил Касыймов - Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театрында эшли, Татарстанның атказанган артисты

Мансур Хәсәнов химия фәннәре кандидаты, доцент;

Әхмәтгаяз Гыйләҗев- техник фәннәр кандидаты, доцент.

**Эш әдәбият исемлеге:**


- Мамадышым – язмышым. Р. Газизов 2005г.

- Авылдашлар, сугыш һәм тыл ветераннары сөйләвеннән:

- Мөхәммәдиева Зәйтүнә апа истәлекләре

- Билалова Рәсүлә апа истәлекләре

- Шәяхмәтова Гөлзәрифә әби истәлекләре

-Хаҗиева Мәлиха истәлекләре

Мөбәрәкшина Газизәбикә истәлекләре

- Хөснетдинов Хаммат истәлекләре

- Сәгыйтов Хатыйп истәлекләре

3. Мамадыш – яңарышта И. Әхмәтҗанов 1989г.

4. “ Иске Комазан мәктәбенең 70 еллыгына багышлана”

Р.Гобәй 6 август 2005г.

5. “ Авылым мәктәбенә” В. Галиев 2005г.

6. “ Авылым аның кешеләре һәм эшләре” А.З.Хадиуллина

язмаларыннан.



*Әхмәтҗанова Иделия, 9 нчы сыйныф, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Бакый Урманче исемендәге “2 нче гимназия” муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*

*Җитәкчесе: Зарипова Әнисә Газизулла кызы, татар теле һәм әдәбияты укытучысы*


## Габдулла Кариев- олуг шәхес

Халыкның талантын, рухи дөньясын, дәрәҗәсен билгели торган театр сәнгате - милләтебезнең казанышы һәм горурлыгы ул. Рус драматургы А. Н. Островский фикеренчә, театр оешу - милләтнең камиллеген, өлгереп җиткәнлеген раслаучы зур тарихи вакыйга. Россиядә театр сәнгатенең XVIII гасыр урталарында мәйданга чыгуын искә алсак, милли театр өчен 110 елдан артык вакыт аз тарих түгел.

Ил тарихы, халык язмышы белән бергә үрелеп барган театр биографиясендә җиңүләр һәм фаҗигаләр дә, казанышлар һәм югалтулар да җитәрлек. Бу иҗади эшчәнлектә дистәләгән, йөзләгән фидакарь, талантлы режиссер, драматург, артист, рәссам, музыкант һәм театр сәнгатен тудыручы башка һөнәр ияләре катнашкан. Бүгенге татар театрының дөньядагы зур тарихлы мәшһүр театрлардан калышмый гына түгел, ә бәлки алар дәрәҗәсендә иҗат итүе бәхәссез.

Татар театр сәнгате – XX гасыр дөнья мәдәниятенең тирән игътибарга лаеклы аерым өлеше. 1906 елның 15 маенда Казанда беренче мәртәбә татарча ачык спектакль күрсәтелә. «Новый клуб» бинасында тамашачыларга Г. Камалның төрекчәдән тәрҗемә ителгән «Кызганыч бала» драмасы һәм Г. Кәрамның тәрҗемә әсәре — «Гыйшык бәласе» комедиясе тәкъдим ителә. Шул ук елның 22 декабрендә әлеге әсәрләр кабат куела. Бу көн тарихка татар театры туган көн буларак кереп кала.

Төрки телле халыклар сәнгатендә беренчеләрдән барлыкка килгән бу театрның бүген инде бай тарихы, зур казанышлары, дөньякүләм танылу алган олуг шәхесләре бар. Бу уңышларда, һичшиксез, татар театрының атасы, режиссер һәм актер Габдулла Каривның да роле гаять зур.

Ул тормышын тулысы белән татар халкының мәдәниятен, сәнгатен үстерүгә багышлый һәм милли театрның нигез ташын салучыларның берсе булып танылa. Ул үзенең актерлык мәктәбен тудыра. Бу мәктәпне Касыйм Шамил, Гөлсем Болгарская, Зәйни Солтанов, Фатыйма Ильская, Шакир Шамильский, Хәлил Әбҗәлилов һәм башка күренекле татар актерлары үтте. Кариев мәктәбе хәзерге чорда иҗат итүче талантлы татар яшьләренең сәнгатендә дә яши.

Ирексездән шундый сорау туа: без татар теленең киләчәгенә зур йогынты ясаган татар театрының яшәвен телибезме, юкмы? Яшик дисәк, театр өлкәсенең тарихи нигезләрен һәръяклап өйрәнергә тиешбез һәм, XXI гасыр вәкилләре буларак, киләчәк буыннарга тапшырырга бурычлыбыз. Ә аның өчен илебезгә театр, татар театры өчен җан аткан Кариевлар кирәк. Безнең фәнни хезмәтебезнең **актуальлеге** шуның белән билгеләнә.

Шулардан чыгып, **максатыбыз** түбәндәгечә билгеләнде: Габдулла Кариевның тормыш һәм иҗат юлын өйрәнү аша театр үсеше процессындагы тоткан урынын билгеләү.

Эшебезнең максатыннан чыгып төп **бурычлар** билгеләнде:

1. Г.Кариевның шәхесе һәм аның театр өлкәседәге эшчәнлеге турында мәгълүмат туплау;

2. Г. Кариевның иҗади мирасын барлау;

3. Г. Кариев исемен мәңгеләштерүгә башкарылган эшләрне туплау.

Югарыдагы бурычларны тормышка ашыру өчен, Г.Кариевның туган ягында эшләп килүче музейга бардым, анда авылдашлары белән аралаштым. Музейда тупланган экспонатларны өйрәндем. Аның турында замандашларының язмалары, документлар һәм матбугатта интернет басылып чыккан материаллардан файдаландым.

**Өйрәнү объекты:** фәнни хезмәтебездәге бүлекләрдә Г.Кариевның татар театры өлкәсендәге эшчәнлегенә чагыштырма планда күзәтү ясалды. Төп тикшеренү объекты буларак, олуг шәхесебезнең иҗатын өйрәнү һәм аның исемен мәңгеләштерүгә башкарылган эшләрне туплау булды.

Фәнни-тикшеренү нәтиҗәләре татар һәм башка төрки халыкларның театр тарихын өйрәнүдә кулланылырга мөмкин. Г.Кариевның татар театры өлкәсендәге эшчәнлеге турында мәктәп дәреслекләренә киңрәк кертүнең әһәмияте зур булыр иде.

## I бүлек. Габдулла Кариевның тормышы һәм иҗаты

Габдулла Хәйрулла улы Кариев (Миңлебай Хәйруллин) 1886 нчы елның 8 нче маенда (яңа стиль белән 20 нче май) элеккеге Чистай өязе Колбай Мораса авылында туган. 12 яшенә кадәр туган авылында белем ала. Әтисе Хәйрулла ага солдаттан өйрәнеп кайткан итекчелек һөнәре белән үзенең зур гаиләсен асырап килгән.

Гаиләнең фәкыйрьлеге балаларны укытырга мөмкинлек бирә алмаган. 1894 нчы елда авылга Зариф мулла Камалов килеп, Миңлебайны укырга бирәләр. Зариф мулла, 30-40 шәкерт арасыннан ике малайны сайлап алып, Коръән – хафиз итәргә уйлый.

Алар арасында Миңлебай да була. Сәләтле малай тиз арада мулланы сөендереп, зирәклеге белән яшьтәшләрен шаккаттыра башлый. Зариф мулла Коръән – хафиз буласы кешегә мужик исеме бер дә килешми дип, аңа Габдулла дип яңа исем игълан итә. Шушы чордан Миңлебай гомеренең ахырынача Габдулла булып китә.

1899 нчы елда Зариф мулла Такталы авылына күчә һәм Габдулланы шул авыл мәдрәсәсенә алдыра. Ярлылыкка чыдый алмыйча, ул 1902 нче елда бәхет эзләп Җаек (Уральск) шәһәренә юнәлә.

Ул 1904 нче елда “Мотыйгия” мәдрәсәсенә укырга керә, яшьләр кичәләрендә әдәби чараларда җырчы, декламатор буларак актив чыгышлар ясый. Мәдрәсә аны Габдулла Тукай, Камил Мотыйги кебек яшь талант ияләре белән дуслаштыра. 1905 нче елда шәкертләр хәрәкәтендә катнашучыларның берсе дип Габдулланы полиция эзәрлекли

башлый һәм ул авылында яшеренергә мәҗбүр була. Әмма ирекнең һәм актив тормышның тәмен татып караган Габдуллага инде авыл тар була һәм фамилиясен алмаштырган егет янә Уральскига китә. 1907 нче елда ул Түбән Новгородта булачак “Сәйяр” артистлары белән очраша, һәм бу очрашу аның киләчәк язмышын хәл итә: ул татар профессиональ театрына нигез салучы, аның беренче артисты, режиссеры булып тарихка кереп кала.

1918 елда театр беразга эшен туктатып тора. Г. Кариев Уфага, соңрак, контрразведка күзеннән качып, Петропавелга китә. 1919 елда Казанга кире кайта. Военкомиссия каршындагы татар театрына эшкә керә. Драматург Кәрим Тинчурин аңа махсус яңа роль бирә.

Колбай Морасада туган Миңлебай атлы малайның киләчәктә татар профессиональ театрына нигез салучыларның иң күренеклесе, театрыбызның атасы булып китәчәген, балачактан зирәк, җыр егетне калага сәфәргә озатып калган авылдашлардан кем генә башына китерә алды икән? Тик язмыш аңа бик кырыс була, ул тынычлап кына эшли алмый, тиф авыруы Г. Кариевны аяктан ега. Егет бу мәкерле чирне җиңеп чыга, терелә. Каты авырудан хәлсезләнгән организмын чыныктырам дип, көн саен 2—3 стакан ат мае эчә башлый. Дуслары ничек кенә каршы төшмәсеннәр, бу эшне ташламый. Майның артык күплеге артистның бавырын эштән чыгара. Ул 1920 нче елның 28 нче гыйнварендә, Казан шәһәрендә, иртәнге сәгать дүртендә 34 яшендәге Г.Кариев мәңгелеккә күзләрен йома.

Татар әдәбиятында Г.Тукайның вафаты олы фаҗига булган шикелле үк, Г.Кариевның да бу дөньядан яшьли китүе бик авыр кабул ителә. Татар сәнгате каһарманының якты дөньядан бик яшьли китеп баруы, якты көндә кояш яктылыгын югалтуына тиң була. Казан халкы мәрхүмне бик хөрмәтләп соңгы юлга озата.

«Син кояш идең, ләкин вакытсыз сүндең, шулай да синең җылың белән тәрбияләнеп үскән орлыклар көннән-көн артачаклар. Синең хезмәтең, гайрәтең җимешләре исемеңне мәңге оныттырмаячаклар», дип язды «Эш» газетасы.

Гомеренең һәм иҗатының чәчәк аткан чорында дөньядан китсә дә, ул кыска гына, ләкин давыллы еллар эчендә зур юл үткән, халкы күңелендә мәңге саклана торган эз калдырган.

## II бүлек

### 1.1. Г.Кариевның иҗади мирасын барлау

1907 еллар тирәсендә Уральскидан китеп, Түбән Новгородта булачак «Сәйяр» артистлары белән очраша. Бу очрашу аның киләчәк язмышын да хәл итә. Г.Кариев татар профессиональ театрына нигез салучы, аның беренче артисты, режиссеры, Г.Тукайның аерылмас дусты булып тарихка кереп кала.

1912 елда «Сәйяр» труппагсына Г. Кариев рәссам Сабит Яхшыбаевны чакыра. Шул чордан сәхнәдә декорация, сурәтләү чаралары, костюмнар бик яхшы дәрәҗәдә хәл ителә башлый. Бүген Колбай Морасада Г. Кариев исемендәге музейда саклaнган Кариев портреты нәкъ әнә шул рәссам тарафыннан ясалган.

Чистай өязенең Колбай Мораса авылы малае Мәскәү, Түбән Новгород, Җаек, Уфа, Тифлис, Ташкент, Баку, Оренбургларга барып чыга. Сәхнәләрдән төшми уйнап, артист буларак та, режиссер буларак та остара. Үз тормышларының кызганыч та, көлкеле дә күренешләрен сурәтләп язган «Артист» дигән пьесасы да бар Г. Кариевның.

Татар профессиональ театрының үсү чоры Столыпин реакциясе елларына туры килә. “Сәйяр” труппасы бу елларда каты эзәрлекләүләргә, реакцион буржуазия һәм дин әһелләренең төрле янауларына, кисәтүләренә карамастан, үз бурычларын намус белән үтиләр. Алар яңадан- яңа әсәрләр белән республикабызның төрле шәһәрләрендә гострольләрдә йөриләр. Хәтта артистларның билет алырга да акчалары булмый, алар товарный поезд вагоннарында кача-поса баралар. Кайсыдыр шәһәргә барганда Г.Кариевның колаклары өши башлый, ул бер дә аптырап тормый, кесәсендәге носкиларны алып колагына киеп куя. Алда әйтелгәнчә, аларны бик эзәрлеклиләр. Алдагы станциянең берсендә артистларны кулга алалар һәм станция начальнигы янына алып керәләр. Начальник язып утыра торган була, тавышка башын күтәреп карый да көләргә тотына. Артистлар югалып калалар. Кариев колагындагы носкиларны исенә төшерә, ул тиз генә аларны ала да гаепле кеше шикелле басып торуын дәвам итә. Начальник көлеп туйганнан соң, боларның кем икәнлеген аңлап, аларга кайнар чәйләр эчереп, хөрмәтләп озатып җибәрә, Габдулла Кариев искиткеч киң күңелле кеше була. Ул театрга бөтен барлыгы белән бирелә.

Моңа мисал булып тагын бер вакыйгага тукталып үтәсем килә. Әстерхан шәһәренә барырга чыккач, артистларның берсенә билет алырга акчалары җитми. Кариев бер дә югалып калмый, өстенә кигән пальтосын сатып билет ала һәм юлларын дәвам итәләр.

Кариевның хезмәте аркасында, татар театрының мирасы барлыкка килде, ул җитлеккән кадрлары тәрбияләнде һәм татар совет театрын оештырырга мөмкинлек бирде.

Әйе, Г.Кариевның татар мәдәнияты тарихында тоткан урыны һичшиксез зур. Татар халкының Габдулла Тукай, Х.Ямашев, М.Вахитов, Ф.Әмирхан, Г.Коләхметов, Г.Камал, Г.Ибраһимов кебек атаклы шәхесләрнең турыдан-туры йогынтысында дөньяга карашы формалашкан, җитлеккән һәм авыр юл үткән Г.Кариев үзе дә алар белән беррәттән торырга лаеклы.

**Габдулла Кариев рольләре**

Татар театрының актерлары һәм режиссерлары биш дистә еллардан артык "Кариев мәктәбе" турында сөйләделәр. "Сәйяр" труппасының күренекле актеры Габдулла Кариев безнең милли театрның төп сәнгати юнәлешен билгеләүче әлеге сәхнә осталыгы мәктәбен тудыручы. Нигездә шул мәктәп аркасында безнең театрыбыз профессиональ театр булып китә дә инде.

Кариевның иҗади эзләнүләренең башы Уральск белән бәйләнгән. Бу шәһәрдә ул яңа дуслар таба, алар арасында яшь шагыйрь Габдулла Тукай да була. Кариев белән Тукай шәкертләрнең яшерен кичәләренә йөриләр. Кариев шулай ук шәкертләрнең "шәкертләр театры" исеме алган театрлаштырылган тамашаларында катнаша. Ул шигырь укый яки нинди дә булса кызыклы хәлләр турында сөйли, тыңлаучыларны укыган пьесаларының эчтәлеге белән таныштыра.

Габдулла Кариев "Сәйяр" труппасының рәсми җитәкчесе булып китә. Ул үзенең юлын алга таба аңа актерлык сәнгатен тирәнтен үзләштерергә ярдәм иткән Гусейн Араблинский җитәкчелегендәге Азәрбәйҗан труппасы белән үтә.

Араблинскийның Кариев белән Нариман Нариманов пьесасы буенча куелган **"Надир шаһ"** спектаклендәге **Җәвад карт** роле өстендә ничек эшләве турында артист Касыйм Шамилнең хатирәләре сакланган:

"Хәлсезләнгән картка охшарга тырышып, Кариев берничә тапкыр сәхнәгә чыга. Аның кул-аяклары калтырый. Әмма бу Араблинскийга бөтенлай ошамый. Ул актерга кулына таяк алырга куша. Кариев шулай эшли, ләкин бу юлы да режиссер канәгатьләнми.

— Сез артист түгел, ә һәвәскәр! — дип кычкыра ул һәм: "Менә ничек кирәк!" — дип, хәлсез картның ничек чыгарга тиешлеген күрсәтә. Ул таякка ныклап тотына, аңа ятыбрак, әгәр таяк булмаса, хәзер аварга тиешле калтырап торган кешене сурәтли. Бу актерлык осталыгы дәресе татар актерлары хәтерендә мәңге саклана".

Кариев белән Араблинскийның бергә эшләве репертуар формалаштыру һәм бигрәк тә сәхнә сәнгатен камилләштерү өчен зур әһәмияткә ия була. Кариев-актер турында уңай бәяләмәләр күренә башлый. **"Хуҗа һәм приказчик"** пьесасын икенче мәртәбә куйганда аның ничек уйнавы турында Тукай: "**Галимҗан** ролендә Кариевның гамәлләре һәм үзен тотышы тормышчанлыгы белән автор тәкъдим иткән шартларда тулаем урынлы булды һәм күптөрле интонацияле сөйләме белән очраклы рәвештә базар урынына сәхнәгә килеп эләккән татар баена бик охшаган иде", — дип яза.

Габдулла Кариевның Галиәсгар Камал белән дуслыгы легендага охшаш. Ул Г. Камалның барлык пьесаларын куя һәм күбесендә төп рольләрне бик яхшылап үзе уйный. Аларның берсе - **"Безнең шәһәрнең серләре"** комедиясендә **Мөхәммәтҗан Хафиз.** Кариев икейөзле һәм карагруһчы образын фаш итте. Әмма сәхнәдә Хафиз образын

тудыру, актер фикеренчә, аның прототибы белән танышканнан соң гына мөмкин булыр иде.

Аның холкын, кыланышларын, гадәтләрен яхшы өйрәнү таләп ителә, ә артистның моңа мөмкинлеге юк диярлек. Кариев шулчак Хафизның ышанычын казанырга һәм аның "якын дусты" булырга карар кыла. Ул мәдрәсәнең мәңгелек шәкерте кыяфәтен алып, тиешенчә киенеп, Печән базарына Хафизның "оясына" килә.

Ул тудырган образ тамашачыларны үзенең тормышчан булуы белән таңга калдыра, күпләр Мөхәммәтҗан Хафиз сәхнәгә чыгып, үзен үзе уйнады, дип фараз кылалар.

Актерлык профессиясе Кариевка авырлык белән бирелә. Уңыш уңышсызлык белән чиратлаша, һәр яңа рольдә киртәләр туып тора. Шулай, **Галиәсгар Камалның "Беренче театр"** спектаклендә Кариевка **Хәмзә бай** ролен уйнарга туры килә. Бу рольне башкару шуның белән катлаулы була: кечкенә генә күренештә актерга байның ачуы бик нык кабарган мизгелен күрсәтергә кирәк. Халәтне кешеләргә гамәлсез күрсәтеп булмый, шуңа күрә уйнау ясалма килеп чыга.

Бу мәсьәлә көтмәгәндә хәл ителә. Спектакльнең премьерасы көнендә Кариев, роль турындагы уйларына тулысынча бирелеп, сәхнәгә чыгарга чакырганнарын ишетми һәм икенче тапкыр әйткәннән соң гына сәхнәгә атылып барып керә дә, нәрсәгәдер абынып егыла. Башта югалып кала һәм бер сүз дә әйтә алмый. Тамаша залыннан көлү ишетелә. Шунда гына ул аңына килеп, сәхнәдә икәнен һәм аңа хәрәкәт итәргә кирәклеген исенә төшерә. Егылу ялгыш булмаган шикелле итеп, ухылдап тора: эчендә давыл. Бик нык гарьләнгән хәлдә, Кариев Хәмзә байның беренче фаразларын әйтә, һәм бик табигый килеп чыга. Роль тулысынча дулкынланып һәм илһамланып уйнала. Актер сәхнәдә моңа кадәр булмаган ләззәт ала.

Кариевка кирәкле дулкынлануга һәм үз-үзен дөрес хис итүгә ирешергә нәрсә ярдәм итте соң? Ул бу сорауга җавап таба алмый. Җавапны соңрак, актерның сәхнәдә психо-физик эш итү законын ачкач, К.С. Станиславский бирә. Әмма талантлы актер-реалист интуиция белән сәхнәдә холыкны дөрес итеп бирә, гәрчә үзенең ни эшләгәнен теоретик яктан нигезли алмаса да.

Кариевның классик образларыннан берсе — Г. Камалның 1912 елда куелган **"Банкрот"** сатирик комедиясеннән сәүдәгәр **Сираҗетдин Туктагаев.**

Бу катлаулы роль яхшы актерлык техникасын таләп итә. Кариев хәйләкәрне шундый оста, үзенчәлекле итеп уйный ки, тамашачылар үз алларында тулаем тормышчан һәм шуңа күрә куркыныч образ күрәләр. Кәкерәйгән куллары, юмакайлап йөреше —

образның тышкы күренешенә өстәмә. Кариев Сиражетдинның акылдан язганлыгын бик дөрес итеп охшата. Ул тулысынча хискә бирелеп, илһам белән уйный.

Кариев аңлый, бер үк артист уйнаган һәр яңа образ тышкы кыяфәте һәм эчке эчтәлеге белән аның алдагы эшләреннән аерылырга тиеш. Ә моның өчен тормышны өйрәнергә кирәк. Ул образга шул кадәр ышанычлы итеп керә белә, хәтта башка артистлар вакыты белән кайда актер, ә кайда персонаж икәнен аера алмыйлар.

Мәскәү Художество театры сәнгатен өйрәнеп, Кариев шундый фикергә килә: тормышны тирәнтен өйрәнү генә актер өчен сәхнә дөреслегенең, психологик яктан төгәл образ тудыруның нигезе була ала. Шул чакта гына сәхнәдә табигыйлекне юкка чыгаручы театр штампларыннан котылырга мөмкин. Кариев, шулай, асылда актерлык кичерешләре мәктәбе булып киткән үз мәктәбен тудыра. Бу мәктәпне Касыйм Шамил, Гөлсем Болгарская, Зәйни Солтанов, Фатыйма Ильская, Шакир Шамильский, Хәлил Әбҗәлилов һәм башка күренекле татар актерлары үтте. Кариев мәктәбе хәзерге чорда иҗат итүче талантлы яшьләребезнең сәнгатендә дә яши.

**III бүлек Исеме театр сәнгатендә мәңгегә истә калган шәхес**

1988 нче елның 22 нче апрелендә, Колбай Мораса авылында Габдулла Кариевка багышланган музей ачу тантанасы була. Музейга нигезне тарих укытучысы Садретдинов Харис Камалетдинов улы сала.

Тарихка тирән эз калдырган кешеләрне без һәракыт хәтеребездә, күңелебездә сакларга тиешбез. Шул уңайдан татар халкының горурлыгы булган Кариевның юбилеен Колбай Мораса авылында үткәрү матур традициягә әйләнеп бара.

Бу бәйрәм беренче тапкыр 1981 нче елда Г.Кариевның 95 еллыгы уңаеннан оештырылган. Анда килгән кунаклар арасында СССР ның халык артисты, легендар Габдулла Шамуков, сәнгать белгече, Г.Кариевның тормышын һәм иҗатын җентекләп өйрәнгән һәм җыентык чыгарган Хәсән Гобәйдуллин һәм Г.Кариевның С.Яхшыбаев ясаган портретын реставрацияләүче Марат Рахманкулов булган.

1986 нчы елда Г.Кариевның бер гасырлык юбилее Колбай Морасага янә аның иң асыл дәвамчыларын җыя. Театрның ул чактагы баш режиссеры, СССРның халык артисты, РСФСРның К.С.Станиславский исемендәге дәүләт премиясе лауреаты М.Х.Сәлимҗанов бу көнне авыл халкы өчен аеруча кадерле кешегә әверелә. 1996 нчы елда Кариевның 110 еллыгын билгеләп үтү шулай ук Колбай Морасада була. 2001 нче ел. Г.Кариевның 115 еллык юбилеенда олуг режиссер, сәхнә ветераны Марсель ага Сәлимҗанов сүзен матур чагыштырудан башлый: “Татар әдәбияты – Тукайдан, татар музыка сәнгате - Сәйдәштән, татарның рәсем сәнгате Урманчедән башланса, театрның чишмә башы – Кариевтан”, -

диде ул. Бу зур чара шулай ук Колбай Мораса авылында Габдулла Кариев исемедәге мәдәният йортында үткәрелә.

Башкалабыз Казанда да Г.Кариев исемен мәңгеләштерү буенча бик күп эшләр башкарыла. 2007 нче елның 16 нчы февралендә Казан татар дәүләт яшь тамашачылар театрына профессиональ татар театр сәнгатенә нигез салучы, режиссер, артист Габдулла Кариев исеме бирелде. Ә 2018 нче елның 26 нчы апрелендә тамашачыларга яңа бина ишекләрен ача. Казандагы Париж Коммунасы урамын Габдулла Кариев урамы итеп үзгәрттеләр.

Гомумән, әдәбият һәм сәнгать бәйрәме татар зыялыларына, татар сәнгатенә багышланган чын тантаналар, чаралар булган, булып тора. Үзе башында торган татар театр сәнгатенең бүген нинди биеклеккә ирешүен, үз җирендә исеменә баш ияргә күпме талантлар килүен тоеп, илебезнең халкы күңелендә аның исеме уелып калуын күреп рухы шатланадыр Кариебызның.

## Йомгаклау

Театр – сәнгатьнең иң гүзәл төре, дияр идем мин. Ул кешеләрне көлдерә дә, елата да, уйландыра да... Без бүгенге тормышыбызны театрдан башка күз алдына да китерә алмыйбыз. Чөнки театр – тормышның көзгесе.

Театр башка сәнгать төрләре белән чагыштырганда кеше күңеленең иң нечкә кылларына килеп кагыла ала торган көчкә ия. Театрда гына тамашачы образ тудыручы белән күзгә күз очраша. Театрда гына тамашачы иҗат процессында актив катнаша ала. К. С.Станиславский әйтүенчә, тамашачы нәрсә булганын “бүген, биредә, хәзер” күрә ала.

Безнең Республикабыз да театрларга, Кариев кебек аны башлап, оештырып йөрүче шәхесләргә бик бай.

Г.Кариев – татар теартының атасы булган кешенең әйтеп калдырган сүзе, амәнәте бүгенге көндә онытылмый. Олы шәхесебезнең татар милләте, татар халкы, татар мәдәниятына, гомумән, театр ярдәмендә татар телен саклауган зур өлеш керткән кешенең исемен мәңгеләштерү эше бүгенге көндә бик актив алып барыла.

Бүгенге көндә татар теленә бәйле булган авыр чорда әдәбият, рәсем сәнгате генә түгел, театр сәнгате дә телне коткарып калаучы бер фактор. Театр сәнгате булмаган халык, үзен зур, бай итеп саный алмый. Ул ярлы, мескен кешегә әйләнә, рухи яктан да сула.

Бүгенге көндә татар театр сәнгате бик бай. Г.Кариев күрсәткән юнәлештә эшләүче шәхесләр, яшьләр булганда, аның киләчәге дә өметле булыр.

## Файдаланылган әдәбият

1.Г.Кариев исемендәге музей. Казан. 2006. “Идел – Пресс”нәшрияты.

2.Г. Кариев Татарстан китап нәшрияты. 1976 ел

3. “Туган җире Кари Габдулланың”, Казан 1996 ел.

4.“Г.Кариев турында истәлекләр” Татарстан китап нәшрияты. Казан 1967 ел.

5.“Дуслык” газетасы. “Идел-Пресс” нәшрияты: 10 февраль 2006 ел; 21 февраль 2006 ел; №134. 31 октябрь 2006 ел; ноябрь 2006 ел.

6."Казан мөхбире" газетасы, № 304, 12 ноябрь 1908 ел.

7.“Артист Г.Кариев” Казан. 1924 ел.

8.Г.Кариев исемендәге музейдан язмалар файдаланылды.

*Вәлиев Реваль, 7 нче сыйныф,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы “10 нчы мәктәп” муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчесе: Гәрәева Гөлнара Риан кызы, татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

Нәселебез эзләре буйлап...

Халкыбызның элек - электән, якыннарга, кардәш - ыруга хөрмәт, кайгыртучан мөнәсәбәт, туган илгә мәхәббәт яшәгән. Бу сыйфатлар борынгылар тарафыннан югары бәяләнгән.

«Жиде буыныңны бел!» дигән гади, ләкин искеткеч нәсыйхәткә халкыбызның тирән тарихы салынган. Юкка гына балалар шагыйре Ш.Галиев: «Исәннәрнең кадерен бел, үлгәннәрнең каберен бел»- дип язмаган.

Гаилә, нәсел киләчәгең , токым... Әлеге сүзләр безгә бик кечкенә вакыттан таныш. Гомер дәвамында кешеләр күренми торган җепләр, туганлык белән бәйле. Ә безне, бер-беребез белән нәрсә берләштерүе турында уйланып караганыбыз бар микән? Мөгаен, юктыр. Әйе, «илен белмәгән - игелексез», «халкын белмәгән - холыксыз», «нәселен белмәгән - нәсәпсез» дип, юкка гына әйтмәгән халкыбыз. Кеше туган иленең, туган төбәгенең, туган йортының үткәнен, үз халкының,гаиләсенең чыгышын белергә тиеш.

Борынгы заманда һәр кеше үзенең җиде буын бабасын белергә тиеш булган, үз нәселен белгән кеше абруйлылардан саналган. Безнеңчә, гаиләңнең тарихын өйрәнү кызыклы һәм файдалы. Гаилә әгъзалары кем булган, ничек яшәгән һәм нәрсә белән шөгыльләнгән, кешеләр өчен файдалы эшләр башкарганнармы, әллә киресенчәме? Безнең уйлавыбызча, безнең бабаларның яшәү рәвеше безнең тормышта да уз урынын алган, үз нәселеңне белергә һәм хәтерләргә тиешбез.

Бүгенге көндә буыннар арасында тарихи бәйләнеш юк дисәң дә була. Балалар өлкән буын кешеләреннән үрнәк алу мөмкинлегеннән мәхрүм. Шуңа күрә һәр кеше үз

гаиләсендә буыннан буынга килгән истәлекләрне белеп, аларны саклап, киләчәк буынга тапшырырга тиеш.

Сайлап алган темамның **актуальлеге** шик тудырмый. Бүгенге көндә гаиләнең,булган вакыйгаларның тарихын өйрәнү проблемасы иң мөһим проблемаларның берсе булып тора.Үз нәселе белән кызыксынмаган кешене киләчәктә ни көтә, буыннар бәйләнешен, туганлыкны өзгән кешедән ни көтәргә? Гаилә тарихын өйрәнүне һәм белүне мин бик мөһим дип саныйм. Фәнни эзләнү эшемнең **максаты**:нәселебезнең тарихын барлау, әби-бабайларыбызның тамырын өйрәнү. Шушы максатка ирешү өчен мин үземнең алда түбәндәге **бурычларны** куйдым:

1) Үзебезнең гаиләдәге истәлекләргә таянып, сугышның гаиләбездә нинди эз калдыруын ачыклау
2) Әби-бабамнарның үткән тормыш юлларын өйрәнү

**II Әбием истәлекләре**

“Нәселемнең шаҗәрәсе кулда,
Чал тарихның гүя кисәге,
Илем минем бары тынычлыкта
Була алыр дөнья бизәге.
Бу тормышның рәхәт михнәтләре,
Уртак язмышларда чагыла,
Сокланырлык гаилә учаклары,
Туган җирдә генә кабына. “- дип яза авылдашыбыз Назилә апа Шагаева.

Мин - Вәлиев Реваль, 5 нче сыйныфта белем алам. Әтием- Марс, әнием-Венера.Түбән Кама шәһәрендә яшибез. Энем Риназ белән икебез дә шушы шәһәрдә дөньяга аваз салганбыз.Гаиләбездә яхшы күңеллелек , өлкәннәргә хөрмәт, үткәннәр белән кызыксыну кебек сыйфатлар беренче урында тора. Шуңа күрә без әтием ягыннан да, әниемнең дә нәсел җепләрен саклыйбыз, аны өйрәнәбез. Бу язмамда мин әнием ягыннан булган нәсел тамырына мөрәҗәгать итәм. Әбиемнең күңел сандыгын, аның тормыш хатирәләрен барлыйсым килә.

Әниемнең кыз фамилиясе- Мияссарова, ул гаиләдә 7нче бала булып дөньяга килә. Әйе, әнием Венера минем туганнарга бик бай. Аның ике бертуган апасы, ике энесе, һәм бертуган дурт абыйсы бар. Бу байлык аның горурлыгы. Алар барысы да тату, бердәм булып, гаиләдә дөрес тәрбия алып үскәннәр. Бүгенгесе көндә алар үз гаиләләре белән төрле шәһәрләрдә яшиләр. Тик мин сүземне төптәнрәк , яраткан әби-бабамнан башлыйсым килә.

Әбием Сәрия 1941 елның 1нче сентяберендә Азнакай районы Кәкре елга авылында Шарипов Харис һәм Ибраһимова Салиха гаиләсендэ икенче бала булып туа. Әбиемнең бала чагы сугыш чорына туры килә. «И, улым, ул елларның әчесен дә, төчесен дә күреп, татып үстек без,»- дип искә төшереп сөйли әбием. Аның күңел сандыгы хатирәләргә бик бай. Ачлы – туклы ялангач кыз һәм дә аның кебекләр ул елларны уз башларыннанниләр генә кичермәгәннәр бит. Кечкенәдән әтисез калган әбиемнең бала йөрәгенә дә күпме яра салган бит ул сугыш еллары. Ул туган елны әтисе Харис бабайны сугышка алып китәләр. Карт әбием Салиха алты айлык кыз бала һәм яшь ярымлык ир бала белән авылда кайнана янында кала. Бик авыр була ул чакларда карт әбиемә. Карт бабам Харис яу кырыннан кайтмый. Хәбәрсез югала. Салиха әбиемнең үз әтисе Ибраһим бабай да сугыштан кире әйләнеп кайтмый. Бүгенгесе көндә алар хәбәрсез югалганнар исемлегендә. Яшьли тол калган карт әбием Салиха, ике кечкенә баланы җитәкләп, Чубар Абдул дигән күрше авылга үз әнисе Гыйльмениса әби янына күченеп килергә мәҗбүр була. Сәрия әбиемнең бала чагы шушы авылда үтә. Шушы авылның сукмаклары аның яшьлек эзләрен саклый.

«Ә сез үскәндә матур күлмәкләр бар идеме, нинди тәмле ашлар ашый идегез, нинди уеннар уйный идегез, әбием?»-дип кызыксынам мин аның янына кунакка кайткач.. «И, балакаем, без үскәндә ни булса шуны кидек, җүнле башлы киемебез дә юк иде бит, аякта агач күтәртмәле чабата, хәтта уйнарга да вакыт калмый иде безнең » - дип искә төшереп сүзен башлый әбием, ә күз яшьләре төер булып тыгыла…Әйе, кечкенәдән әтисез үскән бу ике баланың җилкәсенә зур йөк салынган бит. Ул чорларда карт әбием Салиха авыл фермасына маллар карарга эшкә йөргән. Йортта сыер булмау сәбәпле, карт әбием я кәҗә, я сарык савып, качырып кына сөт алып кайта торган булган..Шул сөтне шулпага кушып, балаларына эчерткән..Әбием Сәрия абыйсы Әнис белән инде әзрәк эшкә ярый башлагач, карт әбиемә булышырга фермага маллар карашырга ияреп чыга торган булганнар. «И, ул кәлҗимә.[1] ашаган ачлы-туклы еллар.Чөгендер, кычыткан турап, он булса , әзрәк он кушып аш пешерә иде карт әбиегез, менә шул иде инде безнең бала чактагы иң тәмле ашлар,»- дип күз яшьләре аша елмая әбием…

Әбием авыл мәктәбендә 7 сыйныф белем ала. Абыйсы Әнис 16 яше тулуга атлар караучысы, ә Сәрия әбием үзе авыл фермасына савымчы булып эшкә йөри. Гаиләнең тоткасы булган, бердәнбер ир туганыннан аерылуны да әбием бик авыр кичерә. Әнис абыйны армия сафларына алалар, анда 3 ел хезмәт итеп кайткач ,ул йөргән кызы артыннан Үзбәкстан якларына чыгып китә, шунда тормыш корып, Зарафшан шәһәрендә яшәп кала. Башта әтисез, аннан абыйсыз калган әбием, әнисе Салиха белән тормыш йөген икәүләп тарта башлыйлар.

Ә инде 1963нче елда әбием шул ук авылда туып үскән , әле генә армиядан кайткан яшь, чибәр егеткә - Жәүдәт бабама кияүгә чыга. Күрше Уфа урамына, Мияссаровлар гаиләсенә, алты почмаклы бура йортка килен булып төшә…

Җәүдәт бабам 1939нчы елны карт бабам Мансур һәм карт әбием Шәмсенур гаиләсендә дүртенче бала булып дөньяга килә. Сәрия әбием килен булып төшкән елларда, карт әбием Шәмсенур каты авыру белән урын өстендә сырхау булып ята. Бу гаиләнең дә бар авырлыклары белән бергә, тормыш дилбегәсен әбием янә үз кулына ала. Карт бабам Мансур - гаилә башлыгы, ул елларда мәчеттә мулла булып йөри , бабам Жәүдәт колхоз эшендә тракторист, соңрак авыл фермасында сарык караучысы булып эшен дәвам итә. Сәрия әбием яшь кыз булуына карамастан, бабамнар белән бергә печән чабарга да, урманга агач кисәргә дә йөри. Кул пычкысы белән хәтта утын да тураша.

Еллар үткән саен бер- бер артлы бала тавышына күмелә төп йорт.. «И, замана, кайлардан көч алганмындыр, узем дә хәзер шаклар катам, -дип авыр сулап куя әбием, хатирәләр уена чумып..Урын өстендә яткан кайнанамны гына тугел, эткәйне дә, балаларны да карарга кирәк иде бит, уз әнием дә ялгыз, аны да ярдәмемнән ташларга ярамый.. Җитмәсә, колхоз эше дә көтә, хуҗалыкта да эшнең бетәсе юк, мал-туар, үрдәк-чебеш, бакча, кыр эшләре дисеңме… Зарланмадык, зарланырга вакыт юк иде,»- ди әбием.

Еллар үтә, тормыш бара. Минем әнием Венера туган елны(1980) карт әбием Шамсенурны, ә берничә елдан соң карт бабам Мансурны соңгы юлга озаталар. Төп йортның куанычы да, юанычы да булып бер-бер артлы дөньяга килгән тугыз бала нәсел агачын дәвам итә. Бугенгесе көндә Жәүдәт бабам юк инде, ә Сәрия әбием әле дә  авылда төп йортта яши. Безне  тәмле чәйләре белән каршы ала, җылы теләкләре белән озатып кала..Әбиемнең тормыш китабы безне дә көчле рухлы, әдәпле, олыларга ихтирамлы булырга өйрәтә. Хәзерге көндә әбиемнең инде 14 оныгы, 5 онықчыгы бар..Безнең нәсел агачы үскәннән- үсә бара. Мин шундый зур гаилә агачының бер яфрагы булуыма әби - бабама, әти - әниемә бурычлы да, рәхмәтле дә, чиксез бәхетле дә…

Мин бу эзләнү эшемдә әнием ягыннан  әби-бабайларымның тормыш юлларын барлап,аларның истәлекләре белән уртаклаштым.Бу эшемдә миңа әбием һәм бабам сөйләгән хатирәләр ярдәм итте.Алар янына авылга кайткач,мин иске фоторәсемнәрне карарга яратам.Шул чордагы йөзләргә карагач,миңа аларның:”Сез,улым, рәхәт,тыныч тормышта яшисез.Ә бу матур тормышны төзү безгә бик җиңел бирелмәде,шуңа күрә гомерләрегезне бушка уздырмагыз,бүгенге якты,рәхәт дөньяның кадерен белеп яшәгез!”- дия кебек алар.Үзенең үткәнен белгән кеше генә киләчәген төзи ала. Шуңа күрә дә гаиләбез тарихын, нәселелебез шәҗәрәсен өйрәнү безнең алга куелган иң беренче бурычларның берсе булып торырга тиеш.  Туган җиргә мәхәббәт, анда яшәгән халыкка

хөрмәт, гаиләбезгә ихтирам белән карасак, әби-бабаларыбызга, әти-әниләребезгә игътибарлы булсак, без чын кешеләр булып үсәрбез.

Киләчәктә мин бу эзләнү эшемне дәвам итеп, әтием ягыннан булган әби-бабаларымның тормыш юлларын өйрәнүне максат итеп куям.

Кулланылган әдәбият

1.Ш.Галиев «Сайланма әсәрләр» Татарстан китап нәширияты . Казан: 1987

2. “Милли тәрбия нигезләре”( Ш.Ш.Җәләлиев, Казан, “Мәгари” нәшрияты, 2003 ).

3. “Балалар фольклоры” (Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1984)

*Вәлиуллина Гүзәл, 10нчы сыйныф,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүче Кама Аланы 2нче гомуми белем бирү мәктәбе*
*Җитәкче: Хәйруллина Лилия Аркадий кызы, татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

## Халкыбызның туй йолалары: үткәне һәм бүгенгесе

### Кереш

Соңгы елларда халкыбызның рухи мирасын барлауга һәм өйрәтүгә игътибар бик нык артты. Туган телне саклау, үстерү белән бергә, халык йолалары, бәйрәмнәре, гореф-гадәтләрен дә җыю һеркәү, халыкка кире кайтару зур эш итеп карала башлады.

Татар халкы һәм аның теле дигәндә без беренче чиратта телне һәм гореф- гадәтләрне саклауда иң ныклы тотка булган авылны һәм авыл халкының телен күз алдында тотабыз. Авыл- шәһәрнең анасы, диләр. Авылларда сакланып калган җирле сөйләшләр безгә халыкның үзенә генә хас булган тормыш чынбарлыгын, борынгы атамалар, сөйләм үрнәкләрен китереп җиткергәннәр.

Борынгы язма истәлекләрдә халкыбызның рухи мәдәнияте, гореф- гадәтләре, йолалары турында җентекле мәгълүматлар бик аз. Шуңа күрә рухи һәм матди мәдәниятнең борынгырагын торгызу, күз алдына китерү җирле сөйләшләрне, диалектларны тирәнтен өйрәнү юлы белән генә хәл ителергә мөмкин. Халык йолаларын яңарту, торгызу өчен, беренче чиратта, халкыбыз күңелендә нәрсәләр сакланганын белергә кирәк. Ләкин аларның күпчелеге өлкән буын вәкилләрнең телендә генә саклана. Күп нәрсәләрне хәзер без халык хәтеренә нигезләнеп, аңа таянып кына күз алдына китерәбез. Татар халкы шактый ерак араларга сибелеп утырган, халыкның формалашу тарихы катлаулы. Шул катлаулылык телдә һәм гореф- гадәтләрдә, йолаларда чагылыш таба. Халыкның теле, аның җирле үзенчәлекләре сакланган төбәкләрдә гореф- гадәт, йолаларның да борынгы үрнәкләре сакланган. Татар халкының төрле этнографик төркемнәре, бигрәк тә татар- мишәрләр, керәшен татарлары, нократ, әстерхан татарларында барлык татар халкы өчен хас булган уртак йолалар, аларның һәрберсенең

формалашу тарихы, башка халыклар белән бәйләнешен ачыклый торган йолалар һәм йола атамалары бар.

## 1.БҮЛЕК. “Туй тарихы "

Борынгыдан бүгенге көннәргәчә килеп җиткән йолаларны фәндә традицион йолалар дип атыйлар.Традицион йолаларны икегә бүлеп карыйар: гаилә- көнкүреш йолалары һәм календарь йолалар, ягъни елның төрле фасыллары белән бәйле йолалар. Гаилә йолалары арасында иң катлаулысы-туй йолалары. Без югалып баручы йолаларны барлауны максат итеп куйдык.

Халкыбыз өйләнешү, гаилә коруга үтә җаваплы караган, аның ил, җәмгыять каршында үтәлергә тиешле гадәт һәм әхлак нормалары, йолалары калыплашкан. Йолалар белән бергә, аларга караган бик күп сүз-атамалар, гыйбарәләр йола белән бергә үрелеп яшиләр, шулай ук туй йолаларының һәр этабында кара- каршы сөйләшү, җырлашу, үткен, зирәк сүзләр уйнату бу йолаларның бизәге булып торалар һәм аның аерылмас бер өлешен тәшкил итәләр.

Татарларның туй йоласы үзенчәлекле булуы белән аерылып торган. Борынгы туй йолалары серле, борылмалы булулары, гомергә истә калырлык мизгелләре белән бездә кызыксыну уятты.

### Туй тарихы

Татарларда туй йолалары төбәгенә - социаль катламына һ.б. бәйле рәвештә төрлечә булган. Хәтта, әйтергә мөмкин ки, туе ничә булса, төре дә шунча. Ләкин татар туеның тотрыклы һәм үзенчәлекле схемасы бар. Җентекләп караганда татар "классик туенда" борынгы бер "хәрби" сюжет ята һәм һәр җирдә дә шул сюжет саклана. Ул болай: ике як бар - би ягы (егет) һәм хан ягы (кыз). Би ягы хан ягына яучы("яулаучы") җибәрә. Шуннан, эш уңса, үзенең гвардиясе - нәгәрләре белән би ягы кызны алып китә. Кыз артыннан "хан кызының" сакчылары - арчыйлар (арчилар) куа чыгалар. Би йортында бик зур хөрмәт белән каршы алгач, кыз шунда калырга риза була. Шуннан би йортында "җиңү уңае белән" тантаналы хәрби мәҗлес - шыйлык үткәрелә. Егет шунда "хан" булып утыра, кәләш "ханым" була ("-ым" биредә "бием" сүзендәге "-ем" кебек үк, тартым кушымчасы түгел, ә борынгы мөәннәс - женский род кушымчасы). Егет сүзе дә төптә "би углы, хан углы" мәгънәсендәге "дэгин, тэгин" сүзенең күплек формасыннан (дэгинт) килә.

Мәсьәлә өйләнешүгә килеп терәлгәндә, эш һәрвакыт диярлек яучылардан башланган. Кайбер халыкларда (һәм, ихтимал, бездә дә) яучының кулында махсус уклы җәя булган һәм ул, һавага атып, угы гүяки "очраклы рәвештә" килеп төшкән йорт ихатасына кергән. Моның белән ул үзен кыз ата-анасы алдында "битараф" кеше итеп күрсәткән. Бу ук ату йоласында шулай ук "өйләнешү асылда очраклылыкка нигезләнгән; кемне генә алсаң да,

кемгә генә барсаң да, аны хөрмәт итәргә кирәк", дигән фәлсәфә чагыла. Бу борынгы фәлсәфә хәзерге көндә дә актуальлеген югалтмаган.

Яучы уңай җавап белән кайтса, егет ягы кыз ягына кунакка килгән (кече туй). Шуннан соң егет кыз йортына килеп йөрергә хокук алган. Бу чорда кияу гадәттә сынау үткән. Мәсәлән, кыз энесе аркылы кияүгә каткан ипи һәм үтмәс пычак җибәрә. Кияү, ипине үз пәкесе белән телеп, аны каенишенә бирә (җизни пәкесе), теге үтмәс пычакны үткерли. Шулай ук кияү утырасы мендәр астына утын пүләне яисе шартлап ярыла торган үгез куыгы салу, кияүгә "менә сиңа суык су" дип, кап- кайнар су эчертүләр һ.б. шуклыклар аның холкын сынар өчен эшләнәләр. Кече туйның соңгы төнендә кыз, ахирәтләре-тиңнәре белән кич утырып, соңгы хәзерлекләр күргән, кызлык дәверен баштанаяк хәтерләгән. Таң беленгәч, барлык җыелган кызлар хор белән яки берәм-берәм таңкучат җырларын җырлаганнар.

Борынгырак заманда шул кичәдә ***"чәчне чәчкә бәйләү"*** церемониясе үткәрелгән, ягъни егет белән кызның чәчләрен бер-берсенә бәйләгәннәр дә (шуның өчен егетнең баш түбәсендә бер учлап чәч - "кәкел чәче" яки "айдар" калдырылган) чәчләрнең очларын үзләренә күрсәткәннәр һәм үз чәчеңне танырга кушканнар. Үз чәчен таныганы начарга юралган - димәк, үзен күбрәк ярата. Үз чәче дип сөеклесенең чәчен күрсәтсә, димәк, аны үзеннән күбрәк ярата дип исәпләнгән.

Татарларда туйның кульминацион моменты - "дуены" булып килен төшерү хисапланган. Олы туйны оештыру эшләре белән махсус чакырылган тәҗрибәле кеше - туй башы җитәкчелек итә. Аның ике урынбасары була: ир-ат белән командалык итүче - чавыш, хатын-кыз җәмәгатенең башлыгы - аргышчы. Чавыш кул астында агалар (ишек агасы - кунаклар каршылаучы, йөгәнче ага - кунакларның атын караучы һ.б.) һәм нәгәрләр; ә аргышчы командасында җиңгиләр эш йөртә. Кыз озату өчен кияү белән киленгә махсус көймәле экипаж- мәгәлдәк хәзерлиләр. Аргыш (туй процессиясе) башында туй башы, чавыш һәм нәгәләр, аннан соң би ягы утырган экипажлар, уртадарак - мәгәлдәк (кияүнең сул ягында - килен, кучерда - кияү егете), мәгәлдәктән артта - аргыш командасы һәм хан ягыннан озатучылар - арчыйлар бара. Элегрәк иң соңгы экипажда күнтәйләр (туйны таныклаучылар) барган. Кияү йортына керү белән аргышны һавага мылтык атып тәбрик итәләр. Мәгәлдәк болдыр ишеге турысына туктый, аннан кияү һәм кияү егете сикереп төшәләр. Килен исә төшмичә ялындырырга тиеш. Ул арада мәгәлдәк ишегеннән өй ишегенәчә палас җәелә, килен төшәсе урынга мендәр (яки кашма - махсус киез) куела. Җыелган тамашачылар, кияү һәм кияү егете киленне төшергә өндәп, "Хан кызы, хан кызы, ач ишегең" җырын җырлыйлар. Әгәр тавышы булса һәм кыюлыгы җитсә, "хан кызы" серенада җырлаучылар белән кара-каршы җырлаша.("Хан кызы" сүзе биредә киленне

олылау, аның хан кызлары кебек кадерле икәнен белдерү өчен кулланыла. )**Килен төшәргә** булгач, кияү белән кияү егете аңарга булышалар. Элегрәк " килен өйгә керү озын бер церемония булган, аның "кулын юдырганнар", "яңа төймә такканнар"(Яңа төймә тагып бирүче җиңги төкләче дип аталган. Ул килennең кияү йортындагы бәхете өчен җаваплы булган). Шуннан соң яки берничә көн үткәч, өйдәге кунакларга "килennең йөзен күрсәтү" церемониясе башкарыла: ике бала махсус эшләнгән таяк(очына туп сыман ипи беркетелгән ук - тукмак) белән ике яктан килеп, килennең бөркәнчеген ача. Килен тез чүгеп, " кунакларны тәбрикли hем бүләкләр бирә.Аннары тагын киленгә "су юлы күрсәтү", "килен токмачы пешерү", "кыз елату" йолалары үтәлгән. Кунаклар алдында кияү белән киленне үбештерү-кочыштыру гадәтләре аларда булмаган. Кияү һәм җыелган ир-ат бу вакытта җырлы-биюле, шау-шулы мәҗлестә - шыйлыкта күңел ачкан: анда кияүне - егетне кашмага утыртып, кашманың дүрт почмагыннан дүрт " кеше тотып, "хан күтәргәннәр" (һавага чөйгәннәр).

**КЫЗ ЕЛАТУ ЙОЛАСЫ**

Татар халкының "кыз елату" йоласы хәзерге вакытта онытылган гореф- гадәтләрнең берсе. Ул кыз елату аталса да, бу хактагы җырлар кыз исеменнән иҗат ителгән булсалар да, аны кияүгә бирелгән кыз үзе түгел, башкалар утәгән. Йоланы төрле җирдә төрлечә, әйтик, бер урында кызның якыннары, икенче урында аны яхшы белгән карчыклар башкарган. Кызларга, билгеле ,өйләрен ташлап китүләре авыр булган. Кемгә генә бирмәгәннәр элек буй җиткән кыз баланы. һич тә кызганып тормаганнар. Үзе аны күрмәгән-белмәгән егеткә, үзеннән ничәмә-ничә яшькә олырак картка, икенче яки өченче хатынлыкка - көндәш өстенә ярәшкәннәр мескенемне - бик еракка, күз күрмәгән, колак ишетмәгән җирләргә биреп җибәргәннәр. Менә ни өчен кыз елату борынгы заманнарда бик тә урынлы йола булган. Туган йортын, авылын, ата-анасын, туганнарын, якыннарын калдырып китүче кыз:

Мәскәүләрдән алган ак җепне

Тетүеннән авыр сүтүе;

Әткәй кәбәмнең өеннән

Әҗәлләрдән авыр китүе, - дип офтана торган булган.

Өстәвенә кем кулына эләгә бит әле кыз бала.

Булачак киленнәр:

Әтиемнең мин өендә

Урыным иде түрдә;

Ят кешеләрнең өендә

Булырмын ишек төбендә, - дип җырлаганнар.

Кыз елатуның бигрәк тә мишәрләрдә, керәшеннәрдә һәм Себер татарларында аеруча нык таралган булуы мәгълүм."

Йоланың барышы түбәндәгечә булган: кызның якын әбисе "түр урындыкка", тиңдәш кызларны эскәмияләргә утыртты. Әзерләп куйган ак чаршауны киленнең башына ябып бүлмәдән алып чыкты. Идән уртасына туктап, моңлы тавыш белән җырлый башлады.

"Әгүзе белән башладым… унып ташладым:

Кече яшьтән җыйган яшемне " Әле генә түгә башладым."

Аннан анасы каршына туктап: "Әгүзе белән бисмилла, ул иманнарның башы икән.

Карадым анакай йөзенә,

Ике күзе тулы яшь икән.

Атҡынаем борган китәргә

Килдем күңелеңне бәхил итәргә!

Синнән аерылуга вакты җитте,

Инде миңа нихәл итәргә?"

Әбинең җыерчыкланган бите буенча яшьләре ага, агасы да елый, кызларның да күзләреннән мөлдер-мөлдер яшьләр коела. Чаршау белән капланган кызның йөзе күренмәсә дә иңбашлары калтыранганга, чиксез елавы сизелә. Тутай эшенә кимчелек кылмый җырлый:

"Мин анакайга барырмын

Ап- ак кына чатыр ябынып,

Алда анай кәбәмне күрдең,

Баксаң елар идең сагынып.

Китмә, анай кәбәм, күреп кал!

Тагы да килә алмам- юлым тар.

Чыбылдыккынам чуп- чуар,

Чебенләр үк кунса, кем куар?

Туган илемне сагынып еглаганда

Еламачы диеп кем тыяр?

Тар урындыкларның буена

Куш чыбыллар корылган.

Минем буем гынам борылган анакай

Кәбәмнең югыннан.

Китәм, анай, китәм, күреп кал.

Тагы да килә алмам, юлым тар!"

Бик каты елаган киленне аяк өстендә көчкә торуын тутай сизеп, тотыгыз дип, кызларга ишарә кылды. Башыннан чаршауны ачып карасалар, йөзе ап- ак булып, һушы китәрлек дәрәҗәгә җиткән. Тиңдәш кызларның һәммәсенең дә елаудан йөзләре, күзләре шешенеп беткән иде. Кыз елатудан өч- дүрт көннән соң никах мәҗлесе була.

" "Кыз елату" йоласы безнең көннәрдә кулланылмый гына түгел, бөтенләй диярлек онытылган.

## 2. БҮЛЕК. Килен төшерү һәм яшь киленне каршы алу йолалары

**Туй атларына карата тылсымлы йолалар:**

Туй атлары кияү капкасына җиткәндә көнчыгыш яктан, кояш чыгышы ягыннан әйләндереп алып керәләр.

Атның башын кияү капкасыннан кыйблага таба каратып кертәләр.

Яшь килен алашасын ут өстеннән уздыралар, алашаны ут өстендә биетәләр (Пенза өлкәсе).

• Кыз утырган көймә капка алдына җиткәч, ут ягып, атны өстеннән уздыралар (Себер татарлары).

Егет йортының капкасын ачып, капка алдына камыштан ут ягалар, атлар ут алдыннан әйләнеп керә.(Әстерхан татарлары).

**Киленне кияү өендә каршы алу:**

• Ат килеп туктый, мендәр салалар, килен төшә, мендәргә баса. Уң яктан төшеп, ат алдыннан әйләнеп керә.

Чигелгән ак бүз тышлы мендәрне аяк астына салалар.

Килен мендәргә төшеп баса да егет артыннан калмыйча, араларына кеше кертмичә, бергәләп өйгә кереп утыралар.

Төкле аягы белән килсен дип, тун җәеп киленне бастыралар(Казан арты - Лаеш).

• Килен кергәндә бусага төбенә ак яулык җәяләр. Килен ак яулыкка уң аягы басып, кайнана кулын үбеп керә. "Ак юллы булсын", - дип, ак яулыкка бастыралар(Әстерхан татарлары).

• Килен басып кергән ак яулыкны барлык туй кунакларына тоттырып чыгалар:

Синең малаеңа да юаш булсын,

Синең кызыңа да юаш булсын,

синең оныгыңа да юаш булсын, - дип.

• Кыз әнисендә туй булса - кыз кардәшләре, егет әнисендә туй булса - егет кардәшләре йөртә ак яулыкны. Ак яулыксыз туй башланмый, ул туйның башы була.

**Гаиләгә бәхет, байлык китерү теләге белән үтәлә торган тылсымлы йолалар:**

Гомер буе ашлык белән булсын, туклык булсын дип, табак белән ашлык алып чыгып, яшь килennнең өстенә сибәләр. Кызның эрпәге (бөркәнчеге) була, шуңа сибәләр.

Кайнана алъяпкычка салып, конфет, тары әзерләп тора. "Ризыклы булыгыз", - дип яшьләргә сибәләр.

Килен чигелдәк (вак бавырсаклар) сибеп җибәрә, оланннар узыша- узыша җыялар.

• Килен төшкәндә җимеш сибәләр. " Татлы гына, тату гына торыгыз", - дип. Килен капкадан кергәндә, кешенең күзе киленгә төшмәсен, әйбергә төшсен дип, бавырсак чәчеп җибәрәләр. Капка бавырсагы бүл үл.

Капка төбендәге кешеләр шул әйберләрне җыеп, киленгә күзләре төшми дә кала. Егет йортына төшкәч, яшь киленгә беренче мәртәбә азык, бал-май каптыру - "***авызландыру"*** йоласы башкарыла:

**Май кебек йомшак булсын,**
**Бал кебек татлы булсын теле",** - ди кайнана.

Килен авызландырырга керә кайнана.

Чәйнектә ширбәт, баллы су. " "Йортлы-җирле, ризыклы, тәмле телле бул", - дип өч мәртәбә каптыра. "Сезгә дә йоксын, сез дә бәхетле булыгыз", - ди килен.Әстерхан татарлары кыз авызландырганда, ак яулыкка бастырып, кызга " Ак юллы , ак күңелле бул, сөт эчертәләр.»- диләр

Авызың белән аш килсен,
Аягың белән бәхет килсен,
Бәхетле булыгыз", - дип авызландыра егет анасы.

## 3.БҮЛЕК.Туй киеменә бәйле йолалар

**Баш бәйләтү, биткүрәм һәм туй киеменә бәйле башка йолалар.**

Туйларда бигрәк тә яшь киленнәрнең баш киемнәренә зур әһәмият биргәннәр. Кыз кеше килен булып кияү йортына төшкәч, аның инде кыз чакта киеп йөргән баш киемнәрен салдырып, хатыннар кия торган баш киемнәре белән алмаштырганнар. Ул йоланы мишәрләрдә һәм керәшеннәрдә әле дә хәтерлиләр. Мишәрләрдә ул тастар сару, керәшеннәрдә - баш бәйләтү дип атала. Тастар - мишәр хатын-кызлары бәйли торган озынча яулык яки сәлге сыман ак тукыма, аның баш-башлары чигүле була. Тастарны кыз кеше әле кияүгә бармас борын ук үзе чигеп әзерләп куйган һәм егет йорты белән ике арада

башкодалар йөреп, үзара килешенгәч, вәгъдә бүләге итеп, ышанмаклыкка егет ягына җиреп җибәргән. "Тастар алырга килү, тастар алу" дигән йолалар һәм йола сүзләре дә шуннан калган. "Тастар алу - кызны бөтенләйгә килешү бүла инде үл. Сүз " өзелмәскә тиешлеген раслап, ышанычлы булсын, дип, тастар бирәләр." Кияv йортына килен булып төшкәннән соң, ул тастарны яшь киленнең башына чорнап куялар. Аның инде килен кеше икәнлеге, тормышның яңа баскычына атлаган хатын-кыз икәнлеге күренеп тора. Ак юкәгачсуйдыгыз,

Кабыгын кайда куйдыгыз?

Ап-ак тастар сардыгыз,

Яулыгым кая куйдыгыз?- дип җырлаганнар яшь киленнәр.

Керәшеннәрдә кияүгә китә торган кызга "баш бәйләтү" йоласын кыяматлык әни итеп билгеләп куелган хатын-кыз башкара. Кызлар кия торган баш киемнәре: калфак-чачак, маңгай ука, кашбауларны салдырып, чәчләрен икегә аерып үрә һәм хатын-кызлар кия торган баш киемнәре:мәләнчек, сүрәкә, чигәчә киертә, өстән түгәрәк яулык дип атала торган, уртасы эре бизәкләр белән күпертеп чигелгән, дүрт кырлы чачаклы калын яулык ябындыра. Мәләнчек белән башны кысып бәйләп куялар, чәчләр күренеп торырга тиеш түгел. Ука җепләр белән чигелеп эшләнгән сүрәкәләр дә бик затлы.

Сүрәкә һәм түгәрәк яулык чигучеләр авылларда бик кадерле. Билгеле кешеләр генә булган, аларның осталыгы буыннан-буынга тапшырылып килгән.

Баш бәйләнгән, тастар сарылган яшь киленнәргә иң өстән бөркәнчек бөркәндерәләр(йөзен беркем дә күрмәсен). Бөркәнчекне кыз алрга килгәндә егет ягыннан китергәннәр.

Туй кунаклары алдында яшь киленнең бөркәнчеген ачып йөзен халыкка күрсәтү, күрендерү йоласы башкарыла. Керәшеннәрдә туй кунаклары табынга утырганнан соң, кызның эти-әниләре шундый җыр әйтәләр:

Биекәй тауларның башында

Яшь үләннәр ята яшәреп

Безнең бәбекәйләр сезнең кулда,

Кайда тотасыз аны яшереп.

Яшь киленнәр киеменә киенгән, бөркәнчек бөркәнгән, башы бәйләнгән кызны туй кунаклары алдына чыгаралар. Ике яктан ике малай килеп уклау белән кызның бөркәнчеген ачалар. Бу вакытта кияү егете йөгән чылтыратып торырга тиеш. Яшь килен беркәнчек ачучыларга янчык бүләк итә.

Мишәрләрдә яшь киленнең йөзен ачу,күрендерү йоласы шулай ук туй кунаклары алдында башкарыла;

Тыпыр-тыпыр биергә
Идәнеңнең уе бар.
Чыгарыгыз яшь киленне,
Ничә карыш буе бар?

Яшь киленнең беркәнчек ачу йоласы башкарылса да, ул олы кешеләр, кайнаталары алдында шәльяулык яки кушъяулык бөргәнеп, озын күлмәк, камзул яки аркалык киеп йөргән. Хәтта урак урганда да шул киемнәрен салмаганнар. Киров өлкәсе Нократ авылында Бибиҗамал апа сөйләгән бер истәлек бик гыйбрәтле. "Бер килен урак урганда, эссегә түзмәгәч, камзулын салып куйган икән, аны кайнанасына чакканнар. "Ник салдың? Кешедән оя", дигән кайнанасы.

Гомумән, яшь киленнәр матур итеп киенеп, төрле бизәнү әйберләрү тагып йөрергә тырышканнар. Мәсәлән, чәч толымнарына көмеш тәңкәләр яки чулпырлар такканнар.

" Чылтырап торган чулпырлар атлаган саен , бас, бас, атла дип торырлар ые, дәттләндереп торырлар ые", - дип сөйлиләр әбиләр, килен чакларын искә төшереп. Әмма яшь киленнәр, өлкән кешеләр яныннан үзганда яки кайнана- кайната янына кергәндә, чәч чулпыларын, чылтырый күрмәсеннәр дип, кулларына учлап тотып кергәннәр.

### 4. БҮЛЕК. Эзләнү өлеше:

### 1. "Яшь киленгә су юлы күрсәтү" йоласының Татарстан районнарында саклануы һәм үтүе.

Туйларның иң матур күренеше килен төшерү булса, икенчесе матуры- яшь киленгә су юлы күрсәтү йоласы.

Килен төшкәннән соң, аңа су юлы күрсәтелә. Бу йола татар халкының борынгыдан килгән йолаларының берсе. Бу йоланың эчтәлеге гаять бай һәм кызыклы.

Без түгәрәккә йөрүче балалар белән татар халкының милли йолалары һәм традицияләре белән һәрдаим танышабыз, материаллар туплыйбыз. Аеруча безгә кызыклы һәм мавыктыргыч булган туй йолаларын балалар бирелеп тыңлыйлар һәм бу йолаларны тирәнтен өйрәнү теләкләре туа. Менә шуңа без укучылар белән өлкән буын кешеләреннән үз төбәкләребездә бу йолаларның үтәлешен кызыксынып өйрәндек. Һәр укучы үзенең әби-бабайларының, туган-тумачаларының авылларына кунакка баргач бу йолаларның үтәлешен язып алдылар. Түбән Кама районы яны авылларыннан, Азнакай районы Сәпәй авылы, Актаныш районы Ахун авылы, Чистай районы Мөслим,Керәшен елтаны авылларыннан мәгълүмат тупланды. Бу йоланың үтәлешендә һәр якның үзенең үзенчәлеге

бар. Түбән Кама районында бөтенләй сакланмаган.Ә Азнакай һәм Актаныш районындагы авылларда эле хэзерге заманда да бик яратып үткәрәләр.Тупланган материалларга нигезләнеп йоланың үтәлешен белдек.

Яшь киленне суга барганда кияү егетенең сеңлесе яки туганнарыннан берәр яшь кыз озата.

Керәшен татарларында су юлын печкәчәм, ягъни киявенең сеңлесе күрсәтә. Килен үзенең узорлы, бизәкле көянтә-чиләкләрен иңенә салып озатучы белән су буена таба китә. Озатучы каен сеңел шулай ук көянтә- чиләкләр белән. Калган яшьләр озата баралар, ә Азнакай районы Сәпәй авылында, яшь киленгә су юлын килендәше күрсәтә.

Кайбер төбәкләрдә су юлын тоту күренеше бар.Я әбиләр, я апалар юлга бау сузып тоталар, яшь киленнән бүләк сорыйлар. Яшьләр биешеп, су юлын тотучыларга бүләкләр биреп юлларын дәвам иттерәләр. Чишмәгә төшкәч анда да сакчылар бар икән. Чишмә сакчысы:

Буш чиләкләр юлларыңа
Каршы килә күрмәсен.
Тулы булсын бәхетегез
Тормышыгыз гөрләсен.

Яшь килен чишмә сакчыларына үзенең бүләкләрен бирә. Азнакай районында су буена килен пешереп алып килгән икмәкне алып төшәләр. Икмәктән кечкенә телем кисеп алып чишмә суына агызалар һәм:«Яшь килен ашлы-сулы булсын, ризыгы белән килсен,» - диләр. Калганнарны килен күмәче белән сыйлыйлар. Аннары су юлын күрсәтүче үзенең чиләкләрен мөлдерәмә тутырып су ала. Килен шулай ук чиләкләрен мөлдерәмә тутырып су ала. Яшь килен түкмичә, чайпалдырмыйча алып кайтып җиткерсә, тормышы мул, иркен булыр.

Актаныш районы авылларында киленнең чиләгендәге суга көмеш тәңкәләр " салалар. Ә кайбер төбәкләрдә тәңкә акчаны чишмә суына салалар. "Яшь килен белән кияү көмеш кебек ялтырап, парлап яшәсеннәр",- диләр.

Кайбер төбәкләрдә килен өйгә кайтып җиткәч суыннан чәй кайнатып эчерәләр. Ә Чистай районының авылларында чиләктәге суларны кайтып җиткәч түгеп " тагы алып кайттыралар. "Юлны үзе белергә тиеш хәзер,"- диеп. Шулай итеп, яшь киленне суга озатучы яшьләр килен чәе эчәргә керәләр. Без, укучылар белән бу йоланы сәхнәләштерү өчен сценарий яздык һәм фольклор фестивальда күрсәттек. Тамашачылар килеп рәхмәтләрен белдерделәр.

**2.Түбән Кама районында яшәүче керәшен татарларының туй җырларын туплау**

Туй җырлары туй барышында үтәлә торган йолалар белән тыгыз бәйләнештә торалар, аның аерылгысыз бер өлешен тәшкил итәләр. Аеруча керәшен татарларындагы җырулар үзенең үзенчәлекле көе, моңы белән күңелләрне җәлеп итәләр. Хәзерге вакытта да керәшен татарларының туйлары бу җырларсыз үтми. Эзләнү барышында Түбән Кама районы Шәңгәлче авылында яшәүче Денисова Разима Әнвәр кызы һәм Балчыклы авылынында яшәүче Никитина Пелогия түти белән очраштык.Рәзимә апа безгә үзенең Келәтле авылында гомер иткән каенанасы Васильева Мариядан (театр артисты Аграфена Васильеваның әнисе) отып, язып куйган туй җырлары белән таныштырды һәм безгә дә язып алырга рөхсәт итте.Пелогия түти үз авылларында үткәрелгән туйларны, үз авылының җыруларын җырлап күрсәтте. “Бу җырларны элек-электән безнең туганнарыбыз җырлаган,әле 15-20 ел элек кенә сеңелләрнең туенда җырланган җырлар бу,”- диде Рәзимә Әнвәр кызы. Рәзимә апаның татар кызы булып та керәшен җырларын җырлавы, сокланып сөйләве, туй җыруларын саклавы безне сокландырды.Эзләнү барышында җыелган җыруларны районыбызның керәшен ансамбленә бирергә карар кылдык.

## III. Йомгак

Шулай итеп, йолалар халыкнын тарихы белән үтә тыгыз бәйләнештә. Телдә диалекталь үзенчәлекләрбулган кебек, халыкның рухи культурасы да җирле үзенчәлекләр белән баетыла, ул җирле үзенчәлекләр шул төбәктә яшәүче халыкның җанына якын, кадерле һәм изге була.

Соңгы вакытта туган телебезгә дә, борынгыдан килгән йолаларга да игътибарыбыз артты, чөнки башка халыклар кебек үк, татар халкы даүзенең тарихы, югалган рухи байлыклары белән кызыксына һәм аларны кире кайтарырга тырыша. Борынгы философ һәм тарихның атасы дип танылган Геродот түбәндәге фикерне әйткән: "Әгәр дәньядагы халыкларга иң яхшы йолаларны һәм гореф- гадәтләрне сайлап алырга кушсаң, игътибар белән караганнан соң, һәрхалык үзенекен сайлар иде, чөнки барысы да үз халыкларының яшәү рәвеше иң яхшысы дип исәпли". Моннан 25 гасыр элек әйтелгән бу фикер әле бүгенге көндә дә үзенең тирәнлеге һәм дөреслеге белән таң калдыра, һәрбер халыкның борынгы йолалары һәм борынгы ышануларына хөрмәт белән карарга кирәклеге кисәтелә кебек.

Менә шуңа күрә без дә үзебезнең төбәктәге татар һәм керәшен халкының милли йолалары, җырлары белән кызыксынып материаллар тупладык. Аеруча « Яшь киленгә су юлы күрсәтү йоласы” белән кызыксындык.Түгәрәккә йөрүчеукучылар белән өлкән буын кешеләреннән үз төбәкләребездә бу йолаларның үтәлешен кызыксынып өйрәндек. Һәр укучы үзенең әби- бабайларының, туган-тумачаларының авылларына кунакка баргач бу йолаларның үтәлешен язып алдылар. Түбән Кама районы яны авылларыннан, Азнакай

районы Сәпәй авылы, Актаныш районы Ахун авылы, Чистай районы Мөслим авылларыннан мәгълүмат тупланды. Бу йоланың үтәлешендә һәр якның үзенең үзенчәлеге бар икәне исбатланды. Кызганычка каршы, Түбән Кама районында бөтенләй бу йола сакланмаган.Ә Азнакай һәм Актаныш районындагы авылларда эле хэзерге заманда да бик яратып үткәрәлә.

Тупланган материалларга нигезләнеп йоланың үтәлешен , һәр төбәкнең сөйләмен кулланып .“ Яшь киленгә су йоласы күрсәтү” йоласын укучылар һәм гомумән татар халкы онытмасын дип, сәхнә өчен сценарий яздык. Түгәрәккә йөрүчеләр белән фольклор фестивалендә сәхнәдә уйнадык.

Эзләнү барышында җыелган керәшен татарларының туй җырларын Түбән Кама районында актив эшләүче “ Сүрәкә” ансамбленең җитәкчесенә тапшырырга максат итеп куябыз.

Сүземне йомгаклап, әйтәсем килә: “ Милләт язмышын, телебезне, гореф-гадәтләребезне, мирасыбызны саклау -барлык татар кешеләренең дә уртак бурычы ул”.

**IV. Кулланылган әдәбият**


1. Ф.Баязитова “ Гомернең өч туе”.
2. Уразманова Р. Татар халкының йолалары һәм бәйрәмнәре. – Казан:Татар кит.нәшр., 1992, -69б.
3. Шәңгәлче авылында яшәүче Денисова Рәзимә Әнвәр кызының куен дәфтәре язмасы. 1995 елда язылган.


# Кушымта

### Керәшен татарларының туй җырлары

**Агылай агым су.**

Бүгенгедәй күргием төшләремдәй
Бүлмә эчләремдә йоклыйсыз, шул
Агылай агым су.
Агылай агым су
Каршы йөзәлмим шул
Сагынам түзәлмим.

Сәгатьләрдәй түгел, бер минуттай
һич тә исләремнән чыкмыйсыз, шул
Агылай агым су

Агылай агым су
Каршы йөзәлмим шул
Сагынам түзәлмим.

Алма бакчасына керер идем
Алмалары тия җилкәмә.
Агылай агым су.
Агылай агым су
Каршы йөзәлмим шул
Сагынам түзәлмим.

Сагынганнар саен килер идем
Җыраклыгың тия теңкәмә, шул
Агылай агым су
Агылай агым су
Каршы йөзәлмим шул
Сагынам түзәлмим.

**Туй җырлары**.
Атларыңны җигеп юлга чыксаң
Арбасында булыр кормысы
Әйдәгез, кодалар җырлашаек
Шушы булыр туйның формысы
Йөзегемнең буйлары талчыбык
Утыралар микән талчыгып
Сездәй кодаларны без дә көттек
Тал чыбыклар кебек талчыгып
Башкайларыңдагы яулыгыңны
Кайсы елгаларда юдың син.
Бер битләрең айдыр, берсе-кояш
Кайсы әүлиядән тудың син

Башкайларыңдагы яулыгыңның
Бер почмаккайлары шәл түгел
Синдәй кодагыйым хакларына

Җыруым түгел җаным жәл түгел.

Агыйделкәйләрдән болгап калдым
Аклы гына яулыкларымны.
Син сау булсаң , мин дә хур булмамын
Телим синең саулыкларыңны.

Җырларга кушсаң мин җырлыем
Берне генә түгел икене.
Җырламасласлар идем мин икене
Килгән кодачалар сөйкемле.

Түшләреңә таккан тәңкәңнең
Ничек итеп чутын алыем.
Кодагыйкайларым җан гынаем
Ничек итеп күңелең алыем.
Ишек алларына аллар элдем
Алыемнар диеп үрелдем.

Ишекләрне ачып кергән чакта
Мәк чәчәге кебек күрендең
Башкайларыңдагы яулыкларың
Очыпкайлар барган кош кебек.

Уң битләрең белән сул битләрең
Карап торсаң тутый кош кебек
Башкайларыңдагы яулыгыңгның
Чигелмәгән җире калмаган.

Килгәннәрдән бирле карап торам һ
Һич килмәгән җире калмаган.
Бу да яулыгыңны кемнәр чикте
Бормагына борма бормалап.
Бу да буйларыңны кайда үстердең
Тутый кошлар кебек юргалап.

**Авыл җыруы**.

Алтын гына балдак мин койдырдым
Йөз тәңкәгә төште бер кашы.
Чәркәләрдә тоткан бу кодабыз
Йөз кешегә тора бер башы.
Биеккәй ташларның башларында
Алтын үлчи диләр бер җегет.
Алтын үлчәсә дә гадел үлчи
Бардыр ул җегеттә бер өмет.
Көндә генә басма кияр идем
Безне илдә басма басмыйлар
Сөйләшерләр сүзгә күрер күзгә
Безнең илдә сезне мактыйлар.
Кара урманнарны үтәрләргә
Козгыннардан кара ат кирәк
Сез кодалар белән сөйләшергә
Ефәкләрдән йомшак тел кирәк.

Әй, җегет син әле, җегет син
Сүда йөзә торган сөлек син.
Суда йөзә торган сөлек түгел
Миргә ярый торган җегет син.

Башларыңа кигән бүрегеңнең
Бөрчек кенә бөрчек агы бар
Бай баласы дигән исемең бар
Гаделлеккәйләрең тагын бар.

Өсләреңә кигән киемеңнең
Запунка урынын кем уйган.
И, атларың нәфис үзең күпис
Синең исемнәрең кем куйган.

Өйнең буйларында гөлем бар
Гел араларында юлым бар

Сиңа җырламыйча кемгә җырлыйм
Синнән бүтән минем кемем бар.

Өйнең буйларында алмагач
Ботаклары саен сандугач
 Синеңнәрдә кебек булса булыр
 Сатта сайрый торган сандугач.

Атның өсләрендә ыңгырчак
Тирбәнчеккәй арба йомышак.
Бу ашаганнарны, бу эчкәнне
Кайтарырбыз микән бер- бер чак.

Алачалар күлмәк аллар булмас
Бер акчалар безгә мал булмас.
Бер- беребезне кадерләшсәк
Газиз башларыбыз хур булмас.

И, ал чәчәк әле ,ал чәчәк,
Ал чәчәк эчләре гөл чәчәк.
Безнең сөюебез артыгырак
Үлчәүләргә салып үлчәсәк.
Иртәләрдә торып бит сөртергә
Чөйдәге бистәрең ак булсын.
Кичке йокыларың татлы булсын
Иртәнге йокыларың сак булсын.

Минем алъяпкычым икәү генә
Берсе сатин, берсе клинкүр.
Инеде генә бездән аерылдың
Ямансылап йөрмә көнең күр.

Кулларыңа кигән пирчәткәңне
Артларыңа куеп алдырма.
Кешенең ярлары чибәр диеп

Үз ярыңның хәтерен калдырма.

Ак Иделкәйләргә сал килгән
Борылыр җирләре тар килгән.
Юклар да Казанда, юк Мәскәүдә
Сезнең генә кебек пар килгән.

Һаваларда оча тилегән
Канат очкайларын көйдергән
Синең генә кебек барлар микән
Күз карашың белән сөйдергән.

Кодачакайларым син килгәнсең
Сөйләшеркәйләргә маза юк.
Сөйләшәләр куйсам сүзем арта
Аерата җаным ярата.

Байның балалары бай кебек
Яңа гына туган ай кебек.
Байның баласының әйткән сүзе
Тәнгә сеңә сары май кебек.

Җылыкай, җылыкай итәдер
Икәү мәллә синең дәветең.
Килгәннәрдән бирле кадерлисең
Бик күп мәллә синең өметең
Җефәк унды мәллә илегездә

Җефәк билбау синең билеңдә
Синеңнәрдә кебек асыл кеше
Тагын бармы җөргән җиреңдә

Түгәрәккәй куак башы уак
Мәк чәчәккәенә ошаулы.
йөзләргә берәү меңгә икәү

Безнең кодаларга ошаулы.

**Татар халкының гореф-гадәтләренә таянып язылган «Яшь киленгә су юлы күрсәтү» йоласы.**

**«Килен төшкәндә» җырының 1 куплеты сәхнә артыннан яңгырый**.

Магнитофон тасмасыннан яңгыратсан да ярый.

Мамык мендәрләргә төренеп
Килен төшә бүген авылга
Борынгыдан калган гадәт ул –
Халык чыга каршы алырга
Яшь кәләшне күреп калырга.

***1 укучы сәхнәгә чыгып***:

Килен төшә, ап-ак бәхет төшә
Капкаларны ачып куегыз!
Бары шатлыкларга күмелегез,
Котлы булсын, дуслар туегыз.

***«Су буйлап» җырының (халык җыры) көе яңгырый.***

Шул вакытта көй астында

**2нче укучы сөйли:**

Борынгыдан калган киленнәрнең
Чишмәләргә суга баруы
Авыл халкы чыгып яшь кәләшкә
Изге теләк теләп калуы.

Сәхнәгә килен, аны озатучы яшьләр һәм егетнең сеңлесе яки апасы чыга. Егетнең апасы һәм яшь килен көянтә чиләкләр белән.

***Егетнең сеңлесе:***

Әйдә килен, чишмә буйларына
Үзем күрсәтермен юлларны.
Тормышыгыз сезнең гөрләп үтсен,
Бәхетләрне юрыйк уйларны.

Киленне чишмә юлына озатучы яшьләр һәм яшь килен бара-бара җырлыйлар.

1. Су буйларына төшәм мин
Көянтә-чиләкләрем

Тулган чиләгемдә бәхет

Телисе теләкләрем.

Кушымта: Барам, барам чишмәләргә

Тутырам чиләкләрем

Чиләгемдәге тулган су

Бәхетләр алып килсен.

2. Су юлларына төшкән юл

Изге юлларым булсын

Чишмә суларыдай керсез

Бәхетләр ташып тулсын.

Килен каршысына чыгучылар, су юлын тотучылар (я ике әби, я яшь кызлар су юлын юлга бау сузып тоталар, бүләк көтәләр).

Ике әби бер-берсенә:

-Төшеп киләләр!

-Киләләр!

Яшьләр арасыннан берсе:

-Карагыз әле, яшь киленнең су юлын тотканнар икән

. **1 әби**: Килен төшә су буена

Каршына килик әле

Нурлы йөзен, зифа буен

Әйдәгез күрик әле.

**2 әби:**

Йөзләреңнән нур чагыла

Битләрең алма микән

Зифа гәүдәләрең белән

Биеп күрсәтсәң икән.

Яшьләр арасыннан 1 кыз яки егет киленне биергә чакыра һәм татарча бииләр. Биюдән соң яшь килен әбиләргә бүләген тапшыра.

1 әби:-Менә хәзер, кызым, су юлы сиңа инде.

2 әби:-Бәхетләр сиңа! (Әбиләр яшьләргә кушылалар).

Җырның 3 куплеты дәвам итә.

Чайпалмасын чиләкләрем

Суларым түгелмәсен.

Шул сулардай саф хисләрем

Сөюләр сүрелмәсен.

**Кушымта:** Барам, барам чишмәләргә

Тутырам чиләкләрем

Чиләгемдәге тулган су

Бәхетләр алып килсен.

Яшьләр чишмә буена якынлашалар. Чишмә күренеше күрсәткәндә чишмә макеты кирәк.

Чишмә буенда 2 сакчы бар. ( 1 кечкенә малай, 1 кыз).

Яшьләр һәм килен чишмәгә якынлашкач чишмә сакчысы:

**1 малай:** Без саклыйбыз чишмә буен

Аның борма юлларын

Иң беренче чиләк тутырып

Килен алсын суларын.

**1 кыз**: Буш чиләкләр юлларыңа

Каршы килә күрмәсен

. Тулы булсын бәхетегез

Тормышыгыз гөрләсен.

**Килен**: Рәхмәт, энем, рәхмәт, сеңлем. Менә чишмәне саклаган өчен минем сезгә бүләгем.

Арадан бер кыз йөгереп чыга кулында сөлге белән икмәк: Күмәч! Күмәч! Килен күмәче! (Икмәктән кечкенә телем алып чишмә суына агыза).

-Яшь килен ашлы-сулы булсын, ризыгы белән килсен.

Әйдәгез, сездә килен күмәченнән авыз итегез. (Яшьләргә күмәчне бүлеп бирә).

**Яшьләрдән берсе:**Бигрәк тәмле булган

**Икенчесе:.**Ничек уңып пешкән, киленебез дә шулай уңган булыр.

Су буена озата төшүче (егетнең сеңлесе) киленгә карап үзе чишмәдән су ала.

Бигрәк ямьле чишмә буе

Сафтыр аның сулары

Шул суларга шифа өсти

Яшь киленнең коллары.

Безнең чишмә бал гына

Кил келеп ал гына

Учларыңнан авыз итсәм

Йөрәгемә ял була.

Яшь килен үзенең матур, бизәкле чиләкләренә су ала.

**Яшьләрдән бер кыз:** (Кулында көмеш тәңкәләр). Киленнең чиләгенә көмеш тәңкәләр салып:

-Яшь килен белән кияү көмеш кебек ялтырап, парлап яшәсеннәр.

Тормышлары мул булсын, гөрләп торсын.

***Су буеннан кайту*.**

(Килен белән озатучы алдан баралар).

1.Бәллүр чишмә буйлары ла

Безнең чишмә юллары

Изгелектә генә булсын

Яшь киленнең уйлары.

2.Пар чиләге иңләрендә

Килен төшә суларга

Теләк телик бүген аңа

Гөлләр сибик юлларга

. 3.Ап-ак күлмәкләрен киеп

Күбәләктәй яшь килен

Аның белән бергәләшеп

Су юлын йөрдек бүген.

Капка төбендә каршы алучылар:

-Кайталар! Кайталар!

*Гайнетдинова Айсылу, Хабиров Салих, 7 нче сыйныф, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Муса Җәлил исемендәге "1 нче гимназия" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*

*Җитәкчесе: Фәләхиева Ильмира Ризатдин кызы, югары категорияле биология һәм география укытучысы*

## Кышлаучы кошларны тукландырыгыз

1.1. Тикшеренү темасының актуальлеген нигезләү.

Без кошларны көн саен күрәбез, аларга ияләштек, еш кына аларга игътибар итмибез һәм аларның табигатьтә нинди роль уйнавы турында уйламыйбыз. Ә бит яз көне бакчаларыбыз һәм паркларыбыз яшелләнерме, бу күп очракта кошларга бәйле. Тукраннар һәм песнәкләр бик күп зарарлы бөҗәкләрне юкка чыгаралар. Кош балаларын ашатканда, бер песнәк тәүлегенә үзе авырлыгы нинди булса,шулкадәр бөҗәкләрне җыя. Кыш көне дә песнәкләр, бөҗәкләрне һәм аларның личинкаларын агач кабыгы ярыкларында эзләп табалар.

Безнең тугры дусларыбыз - ел әйләнәсендә бер урында яшәгән утрак кошлар,алар көньякка очып китмиләр.

Көчле салкыннарда алар азык эзләп кеше торагына якынрак күченәләр, бездән ярдәм көтәләр.

Кошлар өчен иң куркыныч вакыт - кышның ахыры һәм яз башы, ул вакытта һәркем файдалана алырлык җимешләр, җиләк-җимешләр, орлыклар һәм башка азыклар инде ашалган яки вакыт һәм һава начарлыгыннан бозга әверелгән.

Хәзер һәр җимлек, кар җебегәнче һәм беренче яшеллек барлыкка килгәнче, уннарча кош тормышы... Орнитологлар раславынча, кыш чыгарга насыйп булмаган песнәкләрнең 70% ка кадәре нәкъ менә февраль-апрельдә һәлак була... Кошлар салкыннан түгел, ачлыктан үлә. Ә бит безнең һәрберебез авыр сәгатьтә канатлы дусларга ярдәм итә ала.

1.2. Максат һәм бурычлар. Тикшеренү методлары

**Максат:** Җимлекләрдә тукланучы кышлаучы кошларны тикшерү.

**Бурычлар:**

1. Җимлекләрне әзерләргә һәм мәктәп яны участогында урнаштырырга.
2. Җимлекләргә килүче кош төрләрен билгеләргә.
3. Исәпкә алу мәйданчыкларында кошларны күзәтү һәм җимлекләрдә тукланучы еошларны исәпкә алырга.
4. Кошлар нинди җимлекләрне  яратуын билгеләргә.

**Фараз:** Шәһәрдә кышлаучы барлык кошлар җимлекләрдә туклана һәм җимлек материалы кошларның туклануына йогынты ясый.

**Тикшеренү объекты:** безнең якларда кышлаучы кошлар.

**Тикшеренү предметы**: төр составы, җимлекләрдә кошларның күплеге һәм төрле материаллардан ясалган җимлекләрдә кошларнын туклануы.

**Тикшеренү методлары:** Тикшеренүләр 2021 елның февраль-мартында үткәрелде.

Җимлекләргә көнгә ике тапкыр азык тутырылды. Күзәтүләр көн саен алып барылды.  Күзәтү 2021 елның февраль һәм март айларында бер сәгать - 4, 11, 18 сәгать дәвамында контроль көннәрдә үткәрелде. Күзәтүләр мәктәп тәрәзәсеннән җимлекләр һәм

биология кабинетындагы агачларда кошлар артыннан үткәрелде. Күзәтүләр нәтиҗәсендә алынган барлык мәгълүматлар таблицаларга кертелде.

**2 бүлек. Төп өлеше. Теоретик өлеш.**

2.1. Кышлаучы кошларның төрләре.

Төрле мәгълүмат чыганакларын өйрәнгәндә, кышлаучы кошларга түбәндәгеләр керә:

**Йорт чыпчыгы** - чын чыпчыкларның иң киң таралган төре. Бу - кешенең торак белән янәшә яшәүче иң танылган кошларның берсе (аның «йорт» атамасы шуннан алынган) һәм тышкы күренеше белән дә, характерлы чирикалары белән дә яхшы таныш. Тәннең озынлыгы 16 см га кадәр, массасы 23-35 г. Кошның гомуми төсе - өстән коңгырт-көрән, кара таплы күгәргән, астан аксыл яисә соры төстәге. Ак, колак өлкәсе ак, соры. Сары-ак аркылы сызыклы канатлар. Ата ана ана коштан томшыгын, бугазын, зобын һәм күкрәгенең өске өлешен, шулай ук караңгы соры (караңгы көрән түгел) өске өлешен колачлаган зур кара тап булуы белән аерылып тора. Ана затның башы да, тамагы асты да соры, ә күз өстендә аксыл-сары тасма. Йорт чыпчыгы утрак яшәү рәвеше алып бара, шуңа күрә оя кору һәм кеше җирлекләрендә мул азык туплау шартлары да уңай. Нигездә үсемлек азыгы белән туклана, бары тик язда гына өлешчә бөҗәкләр белән туклана, алар белән кошчыкларны ашата.

Чыпчык рационына авыл хуҗалыгы культуралары орлыклары, кеше җирлекләрендә җыйган төрле азык-төлекнең калдыгы, кырларда икмәк кыяклары, чия җиләкләре, карлыган, бакчаларда виноград, яз көне чәчәк бөреләре керә. Якын-тирәдә басулар булмаганда болында, урман буйларында һәм далада, кыргый үсемлек үләннәре һәм бөҗәкләр орлыкларын җыя торган болында тукланырга туры килә.

**Зур песнәк** - безнең илнең иң зур песнәге; аның зурлыгы чыпчык хәтле генә, һәм ул шактый якты каурыйлыкка ия. Башы, бугазы, күкрәк турысында буй-буй булып кара сызык, канатлары һәм койрыгы зәңгәр төстә, аркасы саргылт яшел яки зәңгәр төстә, корсагы ешрак сары төстә, ә яңаклары һәм баш артындагы таплар ак. Катнаш һәм яфраклы урманнарда, паркларда һәм бакчаларда зур песнәк киң таралган. Гадәттән тыш җитезлеге белән аерылып тора. Бу песнәк - утрак кош, урыны белән генә күченеп йөри. Урманның күп кенә корткычларын юкка чыгарып, табигатькә һичшиксез файда китерә. Кышын башка кошлар белән бергә кушылып, азык эзләп йөри. Җимлекләртә көнбагыш, тозсыз май, сөт пакетларыннан сөт өсте каймаклары белән туклана.

**Урман чыпчыгы** - җырчы кош. Тәннең озынлыгы 18-23 см, массасы - 60-67 граммга кадәр. Шактый зур хохолок бар. Төсе алсу-соры, канатлары саргылт һәм ак сызыклар белән капланган, койрыгы, бугазы һәм күз төпләре кап-кара. Икенчел

дәрәҗәдәге  каурыйларының очы якында гына сизелә торган кечкенә җете кызыл пластинкаларга әверелгән. Койрык читендә сары сызык, канатта тар гына ак сызык. Урман чыпчыгы  җыры - свирели яңгырашына охшаган "сви-ри-ри-ри-ри-ри-ри" чытырдавы. Тиз һәм туры сызыклы очып китә. Кошлар зур көтүләр булып торалар. Җаен бөҗәкләр белән туклананалар, аларны еш кына җәйгә, личинкалар, төрле җиләк һәм үсемлекләрнең яшь үсентеләре белән тоталар. Башка вакытта күбесенчә җиләк һәм җимешләр, мәсәлән, брусник, калина белән туклана. Кышын Россиянең урта полосасы шәһәрләрендә еш очрый, анда күбесенчә миләш белән туклананалар. Әгәр дә миләш уңышы зур булса, урман чыпчыклары безнең якларда озак вакытка тоткарлана ала, ә иген уңмаган елларда көньякка таба хәрәкәт итә.

**Гади үрмәләч** - озынлыгы 12-14,5 см булган, канатлары киңлеге 22,5-27 см һәм авырлыгы 20-25 г булган кечерәк хәрәкәтчән кош; тыгыз тәнле, зур башлы һәм күзгә чалынмый торган кыска муенлы. Каурыйчыгы йомшак, куе. Тәрәзә яшәү районына бәйле рәвештә нык үзгәреп тора, шул ук вакытта гәүдәнең өске өлеше һәрвакыт зәңгәрсу-соры төстәге төрле төсләргә ия. Озын, туры һәм очлы томшык; соры төстәге. Канатлары кыска, бөкләнгән. Койрык кыска, туры. Аяклары соры, көчле, озын чылбырлы. Агачлар арасыннан җитез генә шуышып үтә дә югарыга таба, башы белән аска төшө. Хайван белән дә, үсемлек азыгы белән дә туклана. Көз көне, урман бүләкләре өлгерү сезоны җиткәч, бу тынгысыз кошчыклар бу урыннарга бай булган бөтен нәрсәне җыя һәм запас кабыгын ярыкларына тарата башлый. Урта полосада бу урман чикләвеге һәм улак. Кышын еш кына песнәкләр өеренә кушыла.

**Гади карабүрек** - җырчы кош. Вак кошлар, чыпчыклардан бераз зуррак. Өстән һәм күз тирәсендә башы - кара. Канат кагучы һәм руль каурыйлары да кара, зәңгәр металл кою белән. Бил дә, койрыклар да - ак. Әтиләренең җилкәләре, иңбашлары соры. Калтырак, муен, корсак һәм ян-яклар - кызыл. Муены һәм иңбашлары соры. Арка көрән төстә. Калтырак, муен, корсак һәм ян - соры-коңгырт. Орлыклар, бөреләр, кайбер үрмәкүчсыманнар һәм җиләкләр белән туклана. Җиләк-җимешләр белән тукланып, шулардан орлыкларын ала да кибәк йомшагы калдыра.

**Миләш чыпчыгы** - бу Россия территориясендәге, бигрәк тә аның төньяк һәм урта полосасында, дроздларның иң киң таралган якты вәкиле. Тәне озынлыгы 26 см чамасы булган бу кош башка чыпчыклардан үзенең тышкы кыяфәте белән аерылып тора. Миләш чыпчыгының башы һәм койрыгы көл-соры төстә. Моннан тыш, корсагының ак өлешендә муенның ике ягында да зур күләмдә тупланган таплар тулысынча юк, шуңа күрә бу тирәдә миләш шәүләсе дөм караңгы булып күренә. Миләш чыпчыгы өчен азык җитәрлек

булганда, аны еш кына кышын да очратырга була. Уңышлы миләш елларында, кыш урталарында, шау-шулы көтүләр булып йөргән чакларда бу бигрәк тә еш була.

**Тукран** зурлыгында. 22-27 см озынлыктагы канатлар киңлеге 42-47 см, 60-100 г. Күбесенчә кара һәм ак төсләр өстенлек итә, алар кып-кызыл (аерым төркемнәрдә - алсу) койрык белән тоташкан һәм кошка үткен төс бирәләр. Баш өсте, аркасы һәм койрыгы күгелҗем ялтыравык кара төстә. Маңгае, битләре, иңбашлары һәм корсагы коңгырт-ак; соңгысы яшәү районына бәйле рәвештә, аксымнан алып көрән төскә кадәр яки шоколадлы диярлек, каралырак булырга мөмкин. Җилкәсендә зур ак басулар үсеш алган, алар арасында арка тасмасы уза. Киң ак таплы кара таплар бөкләнгән канатта биш аркылы якты полоса барлыкка китерәләр. Ак төстәге ике руль каурыйларыннан тыш кара койрыклы. Терлек азыгын сайлап алу, сезонга карап, хайван яисә үсемлек азыгы ягына авышкан. Язын һәм җәен туклыклылар күп санда төрле бөҗәкләрне һәм аларның кортларын ашыйлар. Кышын һәм көзен аксымга бай үсемлек азыклары күбрәк, беренче чиратта, ылыслы агач токымнарының, чикләвек һәм сарымнарның орлыклары. Бу вакытта бөҗәкләр, мөгаен, искәрмәдер.

Тукран урман экологиясендә мөһим роль уйный, чөнки урман корткычларын һәм агач белән тукланучы бөҗәкләрне күп ашый.

**Гади купшы чыпчык** җырчы кош. Тәннең озынлыгы 130-157 мм. Канатлар озын, ата затларда 80-85 мм чамасы, аналарда - 75-80 мм; ата затларда канат киңлеге 230-270 мм, аналарда - 240-289 мм. Томшыгы озын, очлы. Койрык озын түгел - 50 мм чамасы. Ата-аналарның авырлыгы 16-20 грамм. Бу кошка табигать күркәм каурыйлык бүләк иткән. Ачык кызыл төстәге башның алгы өлеше кара төстә, артка таба кап-кара, яңаклары ак, канатлары саргылт, арткы кырыйда кап-кара һәм ак таплар күзәтелә. Ахырында ак таплы кара күкрәк һәм кызыл-көрән төстәге корсак, койрык ак. Бөҗәкләр, үлән орлыклары ашыйлар. Җәйге чорда ярыклар зур булмаган стайкаларга җыела. Көз көне бу стайкалар акрынлап көньякка таба хәрәкәт итә, ләкин аларның күбесе кышларга кала.

2.2. Кошларны кышкы тукландыру өчен кулланыла торган азык төрләре

Кошларны кышкы тукландыру өчен түбәндәгеләрне кулланырга мөмкин:

1. Тары, солы, бодай, кукуруз орлыгы.
2. Көнбагыш орлыклары (кыздырылмаган).
3. Сало (эчке май), ит (пешмәгән,тозсыз).
4. Кипкән миләш һәм камыр агачы жимешләре.
5. өрәнге һәм корыч-агач орлыклары.
6. Карбыз, кабак, кавын орлыклары.
7. Куркә, чикләвекләр.

Кайбер азыклар кошлар өчен зарарлы, ә еш кына үлем куркынычы да зур. Беренче чиратта, болар барысы да кыздырылган һәм тозлы азык. Тозлы азык ашаганда, тоз кошлар организмында кирәгеннән артык туплана, ә аларны чыгаручы система имезүчеләрнекенә караганда нәтиҗәлерәк түгел һәм организмның агулануы күзәтелә. Эссе вакытта майлар үзләренең структурасын үзгәртәләр һәм бавырга көчле зыян китерәләр. Шулай ук бозылган ризыкны, кушылган бөртекне, күгәргән, басылган азык-төлекне дә кулланырга ярамый. Алар көчле токсиннар тота. Хәтта агулану кошның тиз үлеменә китермәсә дә, ул организмны көчсезләндерә, кош авырый һәм ахыр чиктә һәлак була.

Кошларга ярдырылган бодай да бирергә ярамый. Тарыдан аермалы буларак, тышы юк, бу аның өслегендә майлар оксидлашуга, токсик матдәләр, авыру организмнары барлыкка килүгә китерә. Кошлар өчен кара икмәк тә куркыныч. Арыш крахмалы кош организмы тарафыннан начар үзләштерелә, кара икмәк ак ипигә караганда һәрвакыт дымлырак, югары кислоталы, бу еш кына эчәкләрне әйләндереп алганчы ук көчле әчешүгә китерә.

Димәк, кошларга һичбер очракта да нәрсә бирергә ярамый? Кыздырылган һәм тозлы көнбагыш, тозлы май, тары ярмасы, кара икмәк һәм тәмсез исле яисә күгәрекле бозылган продуктлар.

2.3. Кошларны тукландыруның төп кагыйдәләре.

Кошларны еш ашатырга ярамый, аз-азлап ашатырга гына була! Азык җимлектә гел булырга тиеш түгел. Ашау вакытында көндәлек рационны җимлектән генә алалар, ә тукландырганда, алар кирәкле азыкның бер өлешен генә кешедән алалар, һәм үз рационының калган өлешен табигатьтә табарга мәҗбүр булалар. Табигатьтә кошлар рационы бик төрле. Урманда күченеп йөргәндә, песнәкләр кабык ярыкларын кышлаучы бөҗәкләр, аларның личинкалары һәм курчаклары эзләп тикшерәләр, төрле үсемлекләрнең орлыкларын сайлап алалар, ә җимлектә бары тик көнбагыш һәм сало гына ашыйлар. Орлыклар даими булганда, җимлектә песнәкләр башка азык эзләүдән туктыйлар.

Кошлар рационы төрлечә булырга тиеш. Бертөрле рацион канатлылар өчен зарарлы. Кошлар үзләре берьяклы туклану куркынычын аңламыйлар, хәтта азыкны төрле азык итеп сайлап алганда да, азыкның туклыклы төре буларак, көнбагыш ашауны артыграк күрәләр. Майларның артык күп булуы бавыр авыруына һәм кошның тиз үлүенә китерә. Файда урынына без кошларга төзәтеп булмаслык зыян сала алабыз булып чыга.

Кошларны бер үк урында, бер үк вакытта ашатырга кирәк. Көн саен ашатырга, вакыт-вакыт ашатырга ярамый. Үзеңне һәм кошларны билгеле бер режимга өйрәт, тәүлегенә бер-ике тапкыр җимлекләр тутыр, иртән яки иртән һәм кич бер үк вакытта. Әгәр

ныклап тотсаң, кошлар билгеле бер вакытта кормушкада азык табарга исәп тота алуларына тиз күнегәләр, ә калган вакытта башка урыннарда азык эзләргә китәчәкләр.

Тукландыру вакытында полиэтилен пакетлар, калай банкалар, тартмалар һ.б. калдырырга ярамый

2.4. Җимлекләр әзерләү һәм урнаштыру буенча төп кагыйдәләр.

Җимлекнең иң гади варианты - ул, азыкны җил өрдермәсен өчен, кырыйларына бортлар белән беркетелгән такта. Кошлар өчен җимлекне үз кулларың белән агачтан, фанерадан, пластик шешәләрдән, сөт, соклар һәм ярмалар пакетларыннан, кабактан, буш кокослардан, иске автомобиль фараларыннан һәм башка кул астындагы материаллардан ясарга мөмкин.

Җимлекләрне урнаштырганда, артык катлаулы һәм гаҗәп конструкцияләр артыннан куарга кирәкми.  Гадирәк итәргә һәм күбрәк кош ашатырга кирәк. Тик җимлектә, мөмкин булганча, азыкны һава торышыннан саклау мөһим. Кышын кошларга рәхәт түгел - исән калу өчен кирәк. Яклау өчен төрле капкачлар, ян стеналар ясыйлар.

Җимлек киң булырга тиеш, кош җимлек эченә тыныч кына үтеп, аны ташлап китсен өчен.

Җимлек элү иң яхшысы - 1,5-2 метр биеклектә көньяк якта. Шулай итеп, без аны җил һәм кардан саклыйбыз, кояшлы көннәрдә азык җылына һәм эри (әгәр дә аңа дым килеп керсә), зур биеклек кимерүчеләргә азык янына барып җитәргә мөмкинлек бирмәячәк.

Йомгак

Тикшеренү барышында түбәндәге бурычлар хәл ителде:

1. Мәктәп яны участогында җимлекләр әзерләнде һәм урнаштырылды.

2. Кышлаучы кошларның күптөрлелеге өйрәнелде.

3. Кошларны кышкы тукландыру нигезләре, җимлекләр әзерләү һәм урнаштыру кагыйдәләре, азык составы өйрәнелде.

4. Кошларга йөрүче кошларны күзәтү һәм исәпкә алу үткәрелде.

5. Тикшерү барышында алынган нәтиҗәләр анализланды.

Эшнең максаты ирешелгән:

иң катлаулы чорда (февраль - апрель) кошларны даими тукландыру оештырылды.

Киләчәк эш планы:

1. Беренче яшеллек барлыкка килгәнче, кошларны тукландыруны дәвам итәргә.

2. Көз көне өстәмә тукландыру өчен азык әзерли башлау (2022-2023 ел кышы).

3. Киләсе сезоннарда кошлар турында кайгыртуны дәвам итәргә.

**Эш әдәбият исемлеге**

1. Внеклассная работа по экологии. Сборник методических разработк, составленной методистами АОУ ДОД РА «Республиканский ЦДОД», Соломоновой Е.В., Солодиловой Г.И.,Малковой А.Н., Горно-Алтайск-2012.
2. « Книга природы» под редакцией Ю.Дмитриева, Москва «Детская литература» 1990.
3. П.П.Костенков «Экологическое воспитание школьников», Барнаул, Алтайское книжное издательство,1990.
4. Интернет – сайт «Птицы Алтая» http://birds-altay.ru/
5. Птицы. Полная энциклопедия. /Юлия Школьник. – М., Эксмо, 2006
6. Энциклопедия для детей. Птицы и звери. / под ред. В. Володина. – М., Аванта+, 2004 г.

*Галиева Зәринә, 5 нче сыйныф, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы “Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүле 10 нчы гомуми урта белем бирү мәктәбе”муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчесе: Хәкимова Рәмзия Риф кызы, татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

## Исемнәрдә-кеше язмышы

Дөньяда һәр нәрсәнең, һәр кешенең исеме бар. Бала туу белән, аңа исем бирелә. Балага нинди исем кушарга дигән **проблема** һәр заманда актуаль булган. Бүгенге көндә дә ят түгел бу проблема. Димәк, эшнең темасы актуаль.

Проблемага ачыклык кертеп, кешенең исеме тормышына һәм язмышына йогынты ясавы турында аңлату **максаты**н куйдым.

**I бүлек. Исемнәрдә-кеше язмышы**

Ата - ана, баласына исем кушканда, теләсә нинди очраган исемне битараф рәвештә алмый. Үзенең зәвыгы, уй һәм фикерләреннән чыгып сайлый ала, мөмкин кадәр яңгырашлырак исем эзли.

Татар халкы элек-электән яңа туган сабыйга исем кушуга зур җаваплылык белән караган. Исеме җисеменә туры килә торган матур эчтәлекле, җиңел әйтелешле исемнәр бирергә тырышкан. Менә шуңа кытай халык мәкалендә хаклы рәвештә: “Начар язмыш белән туу куркыныч түгел әле ул, ә менә начар исем алу- коточкыч” диелә.

**II бүлек. Исемнәрнең мәгънәсе.**

**§ 2.1. Нәрсә соң ул исем?**

Без гадәттә исемнәрнең мәгънәсе турында уйланып тормыйбыз, күнеккәнчә сөйли бирәбез. Уйлап карасаң, аларда кызык нәрсәләр ачыла. Кеше мәсәлән, үзенең нигә Рәмзил булуын аңлый алмый. Аның галилегенең сәбәбе нәрсәдә соң?

Әллә исем, бер кешене икенчесеннән аерып тану өчен, ясалма рәвештә төзелгән авазлар тезмәсеме? Яки тамга кебегрәк бернәрсәме? Әйе, исемнәр- нигездә кешеләрне бер-берсеннән аеру- тану өчен хезмәт итә торган тамга. Ләкин гаҗәеп тамга... Чөнки авазлардан тезеп кенә исем ясап булмый бит.

Һәр кешегә матур исем кирәк,
Аның булсын тирән мәгънәсе.
Шушы исем аңа гомерлеккә!
Истә тотсын әткә-әнкәсе.
Шушы исем белән яшәп кеше,
Үрләр яулый, таный, таныла,
Исем мөһим кеше язмышында,
Һәркем салсын моны аңына.

### § 2.2. Исем кешегә гомерлеккә бирелә.

Балага бирелгән исем матур булып, аның мәгънәсе тирән булырга тиеш. Ата-ана баласының исеме белән горурланырлык булсын. Матур эчтәлекле, тыйнак, җыйнак исемнәр һәрвакыт кешеләр күңеленә хуш килә. Исеме матур кеше үзе дә матур була. Үсеп җиткәч, иләмсез, ят исемнәре аркасында балалары уңайсыз хәлгә калмасын өчен, ата-ана исем кушканда сак эш итсеннәр иде диясе килә. (Исем кушу йоласы!)

## 3 бүлек. Актаныш районында кулланыла торган исемнәр.

Минем укытучым Рәмзия Риф кызы. Ул Актаныш авылы кызы. Ул якларда борынгы исемнәр ,кызыклы исемнәр куп дип,мине бу эзләнү эшенә кызыксындырды. Мин,укытучым белән бергә “Актаныш таңнары” газетасындагы исемнәрне “чүпли”-эзли башладык. Газетаны укыгын саен укыйсы килә башлады.

1. Әнис, Диләрис, Фарис, Динәес, Фидә**ес**,Фидә**и**с, Фикус, Гавис, Илфар, Фәрхәд, Фәнүс, Иршат, Ралиф, Нәсим, Дилүс, Глүс, Лирон, Хавил, Флүн.

( “Актаныш таңнары” газетасының 2021 нче елның 30 нчы апрель санындагы “Механизаторларның 28 нче апрельгә эш күрсәткече” )

2. Гөлүзә, Люция.

( “Актаныш таңнары” газетасының 2021 нче елның 30 нчы апрель санындагы “Кишер чәчү серләре”)

3. Лүзия Гыйлҗманова.

( “Актаныш таңнары” газетасының 2021 нче елның 30 нчы апрель санындагы “Җирле үзидарәгә”)

4. Кифарис Салихов.

( “Актаныш таңнары” газетасының 2021 нче елның 30 нчы апрель санындагы “Яшьлегем хатирәсендә”)

5. Әлфрит, Әхнәф, Рим, Риф улы, Гаптелхәй кызы, Мирзаян улы, Раминә оныгы, Әнвәр, Айдар+Айгиз.

( “Актаныш таңнары” газетасының 2021 нче елның 30 нчы апрель санындагы “Котлауларда –күңел җылысы”)

6. Энгель Фаттахов.

( “Актаныш таңнары” газетасының 2021 нче елның 2 нче апрель санындагы “Замана баласы Һөнәрле булып үсә”)

7.Джон Мусин, Илгинә Фәтхиева, Ленар**а** Шарипова.

( “Актаныш таңнары” газетасының 2021 нче елның 2 нче апрель санындагы “Мәдәният хезмәткәрләре уңаеннан”)

8. Рәйхан Галимҗанов .

( “Актаныш таңнары” газетасының 2021 нче елның 2 нче апрель санындагы “Саннарда –язмышлар” )

9. Әбүгали Шакиров.

( “Актаныш таңнары” газетасының 2021 нче елның 2 нче апрель санындагы

“Андый шәхесләр бик сирәк,әмма бик кирәк”)

10. Кадрия Идрисова.

( “Актаныш таңнары” газетасының 2021 нче елның 2 нче апрель санындагы “Татар кызчыгы бәйгесендә”)

11. Индия Шәймәрдан кызы, Финат Шәрип улы, оныклары- Элис, кодагые-Данил**ә**, Билүс кызы, Рәзүл.

( “Актаныш таңнары” газетасының 2021 нче елның 2 нче апрель санындагы “Котлауларда –күңел җылысы”)

12. Хәнис Төхватуллин.

( “Актаныш таңнары” газетасының 2021 нче елның 12 нче март санындагы “Хәбәрләр”)

13. Марс Бәдретдинов.

( “Актаныш таңнары” газетасының 2021 нче елның 12 нче март санындагы “Без капчыкта ятмый”)

14. Гөлназ **Баянова.**

( “Актаныш таңнары” газетасының 2021 нче елның 12 нче март санындагы “Язны каршы алу”)

15. Гатуф Бәдрәшитов .

( “Актаныш таңнары” газетасының 2021 нче елның 12 нче март санындагы Сәламәтлегеңне үзең кайгырт”)

16. Гөлфидә Хәбирова .

( “Актаныш таңнары” газетасының 2021 нче елның 12 нче март санындагы “Тәмле телле ,якты йөзле”)

17. Даимә, Әнис, Әнәс, Әфкатъ,Голфәния, **Дөбирә** Имамгали кызы, Сирена, Сиринә,**Әнҗүдә**.

( “Актаныш таңнары” газетасының 2021 нче елның 12 нче март санындагы “Котлауларда- күңел җылысы”)

18. Тәфкил, Тимер, Вазыйх, **Нурфика** Абдуллина, Шаһтимер.

( “Актаныш таңнары” газетасының 2021 нче елның 12 нче май санындагы “Оныттылар дип уйламагыз”)

19. Физилия Дәүләтгәраева .

( “Актаныш таңнары” газетасының 2021 нче елның 12 нче май санындагы “Интернат” мәкалендә)

**4 бүлек. Сыйныфымда исемнәр хәзинәсе.**

Ә минем сыйныфымда нинди исемнәр бар икән? Шул максаттан, мин кечкенә генә тикшерүләр үткәрергә булдым. Рус мәктәбе булганга күрә, билгеле, бездә рус милләтеннән булган укучылар да бар. Ләкин минем сыйныфымда гел татар исемнәре генә кулланылган!

| Язылышы, кайсы тел сүзе булуы | Исемнең мәгънәсе, нәрсә аңлатуы |
|---|---|
| Адылгареев Тимур Рамилевич | туры сүзле,гадел. Тимур-Тимер-ныклы. |
| Афзалов Камиль Ильгизарович | КАМИЛ (г.) Тулы, бөтен, мөкәммәл килгән; һәрьяктан җитешкән, камил. Исем компоненты. |
| Ахмедшин Булат Ильшатович | БУЛАТ (г.; й. ис.) Гарәп телендә булат сүзе «яхшы корыч» дигән мәгънә белдерә. Дәмәшкъта коелган иң шәп сортлы корычка булат дигәннәр. Булат исеме ир бала яхшы корыч кебек нык булсын, дошманнарга бирешмәсен дигән теләктән |

| | |
|---|---|
| | чыгып кушылган. Исем компоненты. |
| Ахметова Аиша Рамилевна | Аишә-Гәйшә-гарәп. Иптәш,әңгәмәдәш. |
| Валеева Самира Раилевна | САМИРӘ (г.) Әңгәмәдәш, гәптәш. |
| Валиахметов Мурат Ирекович | Мурат-Марат(г.) Ышанычлы,таяныч. |
| Валиева Айнель Айнуровна | Айнель-(тат.,рус)-Ай-луна. Сөйкемле. |
| Гайфиев Азат Ильдарович | АЗАТ (ф.) Ирек; хөр, ирекле, азат. |
| Галеева Зарина Ренатовна | үзем турында тулырак әйтеп китәчәкмен!<br>**V бүлек. Минем гаиләдәге исемнәр.** |
| Гамирова Арина Ильнуровна | -Арина- |
| Гибадуллина Адиля Ирековна | Гадел, тугрылыклы, намуслы. Д. в.: Адилә, Әзилә, Әдилә. АДИЛӘ (г.) |
| Мубаракшин Амир Айратович | -Әмир(г.) Әмир-приказ,указ бирүче,сүзендә торучы |
| Назипова Аделина Ильдаровна | АДЕЛИНА (бор. герм.) Намуслы, вөжданлы. |
| Сунгатова Азалия Ваисовна | АЗАЛИЯ (лат.; бот.; неол.) Азалия гөле; эре чәчәкле үсемлек атамасыннан. |
| Талипова Малика Рамилевна | МӘЛИКӘ (г.) Патша хатыны, ханбикә. |
| Фазлетдинова Малика Ниязовна | МӘЛИКӘ (г.) Патша хатыны, ханбикә. |
| Хайбуллин Марсель Ильшатович | МАРСЕЛЬ (гол.-фр.; неол.) Марска (к.) мөнәсәбәтле. Франция эшчеләр хәрәкәтенең күренекле җитәкчеләреннән берсе Марсель Кашен исеме. Утызынчы еллардан башлап аның хөрмәтенә кушыла торган исем. Д. в.: Марсил. |
| Хикматуллин Ислам Шамилевич | ИСЛАМ (г.) 1. Буйсыну, Аллаһыга буйсыну, күндәмлек. 2. Мөслим, мөселман. 3. Сәламәт, сау, төзек. Д. в.: Ислай, Ислакай, Слам. Исем компоненты. |
| Чурсина Валерия | -Валерия-рус теленнән алынган. Матурлык, |

| | |
|---|---|
| Сергеевна | күркәмлек. |
| Шайдуллин Ислам Ильдарович | ИСЛАМ (г.) 1. Буйсыну, Аллаһыга буйсыну, күндәмлек. 2. Мөслим, мөселман. 3. Сәламәт, сау, төзек. Д. в.: Ислай, Ислакай, Слам. Исем компоненты. |
| Шаймурзин Амир Динарович | -Әмир(г.) Әмир-приказ,указ бирүче,сүзендә торучы |
| Шакуров Фидан Ильнарович | ФИДАН (г.) Коткаручы, җанын фида итәргә әзер булучы. |
| Шамсегалиева Наира Алмазовна | НАИРӘ (г.) Яктыртучы, балкучы, нур чәчүче. |

Күркәм исемнәребез бик күп, һәрбер ата-ана шулар арасыннан үзенә ошаганын, зәвыгына туры, күңеленә хуш килгәнен, әлбәттә, заман таләпләренә җавап бирә торганын сайлый.

**V бүлек. Минем гаиләдәге исемнәр.**

Әти-әнием миңа да бик матур исем биргәннәр. Минем исемем–Зарина-

1)Зарина – с золотыми украшениями, узорами.(https://nameology.ru/nacionalnye-imena/zhenskie-tatarskie-imena)

2) Имя Зарина имеет несколько версий своего происхождения, перевода:

славянская – означает «заря», «красота рассвета»

арийская – переводится как «золотоносящая», «златая»

тюркская – обозначает «украшенная золотом»

кавказское – значится как «жрица храма огня»

еврейская – считатаеся как «княгиня» (от имени Сара) (Яндекс-быстрый ответ)

Безнең Татарстанда икетеллелек булганлыктан,мин рус телендә дә мәгълүматлар таптым. Бу минем өчен бик тә кызыклы мәгълүмат!

**Происхождение и значение**

Зарина – старинное женское имя. Его происхождение – спорный вопрос. Многие лингвисты склонятся к славянскому варианту, согласно которому Зарина означает «заря», «красота рассвета», «звездная». Другие придерживаются среднеазиатской версии. Предводительницу древнего народа саки, который в прошлом населял территорию нынешнего Казахстана, звали Заранея или Зарния. В переводе на русский язык оно означает «золотоцветная», «золотая» и «золотоволосая». Есть у этого имени и мусульманские истоки. Полагают, что оно заимствовано из персидского языка и пошло от

однокоренного слова «зар». Его значение - «солнечный луч», «золотой», «солнцеподобный», «красное солнце».

В настоящее время имя Зарина широко популярно у народов Кавказа. В странах Западной и Восточной Европы оно встречается гораздо реже.

**Черты характера**

Тайна имени зарина – в ее непростом характере. Эта девушка ведет себя порой как избалованный ребенок, который не желает уступать и слышать других людей. Капризная и эгоистичная, она требует к себе повышенного внимания и не терпит, когда ее желаниями пренебрегают. При своей хладнокровности и заносчивости быстро находит общий язык с разными людьми, имеет живое воображение и незаурядный интеллект.

Зарина абсолютно не страшится трудностей. Какие бы сюрпризы судьбаей не подкинула, ее оптимизм и сообразительность возьмут верх над обстоятельствами. Она любит жить и действовать по заранее составленному плану. Вкладываться в установленный график ей помогает обстоятельный подход к делам, старательность и необыкновенная дальновидность.

Характеристика имени Зарина наделяет его обладательницу необыкновенным умением дружить. У нее много подруг, которыестановятся сестрами в ее глазах. Они знают ее как безотказную, честную и преданную девушку, которая стремится оказать им всестороннюю поддержку. Тесная душевная связь с друзьями не мешает ей проявлять свой бунтарский характер. Любая мелочь, которая Зарине не понравится, может разжечь громкий скандал.

Повышенная эмоциональность, гордыня и амбициозность – вот основные негативные качества Зарины. Они создают барьеры для полноценного общения с окружающими, отрицательно сказываются на личной и профессиональной стороне жизни.

**Увлечения и хобби**

В детстве Зарина – необычайно творческий ребенок. Она с охотой осваивает вышивку, бисероплетение, квиллинг или технику модульного оригами. Может часами заниматься рукоделием, пока ее подруги играют в куклы или катаются на велосипеде. Взрослая Зарина редко находит время для творчества, полностью посвящая себя чтению книг. С их помощью она отрывается от реальности и черпает жизненную мудрость. Помимо этого, ее сердце манят путешествия. Зарина любит открывать для себя новые страны, паломничать и ходить в турпоходы по родным местам. До старости ведет активную светскую жизнь, без которой она перестает чувствовать себя счастливой.

**Профессия и бизнес**

Зарина – одна из тех, для кого карьера играет весомую роль. Лидер по натуре, она с первого рабочего дня втирается в доверие начальника и становится опасным конкурентом для коллег. Трудолюбие, в сочетании с напористостью и целеустремленностью, обычно приводит ее на руководящие посты. Оказываясь в отдельном кабинете с солидным штатом подчиненных, Зарина полностью оправдывает возложенные на нее надежды. При своей справедливости, коммуникабельности и дальновидности, имеет лишь один весомый недостаток – неспособность принять критику в свой адрес. Она слишком самоуверенна, чтобы прислушиваться к тому, что говорят ей коллеги или подчиненные. Имеет все шансы, чтобы стать хорошим преподавателем, научным работником, врачом или юристом.

Личное обогащение для Зарины – не самоцель. Она может долгие годы проработать на должности с невысоким окладом и, опираясь на свою рациональность, экономность и дальновидность, жить в роскоши и комфорте. Если хватит сил и энтузиазма, может стать успешной бизнес-леди.

**Здоровье**

Здоровье Зарины находится на среднем уровне. В детстве она подвержена частым респираторным инфекциям, что причиняет близким массу беспокойств. Взрослея, она становится крепче и частота походов к врачу заметно сокращается. Гормональные перестройки организма в переходном возрасте часто выливаются в полноту. Корректировка веса требует строгой диеты, регулярных занятий спортом и постоянного наблюдения у эндокринолога.

**Любовь**

Видную и харизматичную Зарину в любом возрасте притягивают парни постарше. В отличие от своих подруг, она даже не смотрит в сторону парней-ровесников. Чтобы покорить ее сердце, избранник должен быть волевым, опытным и авторитетным в глазах окружающих. В противном случае, она не усмирит свой лидерский нрав. Слабохарактерный подкаблучник со временем устанет подчиняться, что приведет к неминуемому расставанию.

Смелая и решительная Зарина никогда не посмотрит в сторону того, кто позволит собой помыкать. Ее симпатию заслуживают немногие мужчины, с которыми она сможет почувствовать себя, как за каменной стеной. Иногда в своих требованиях перегибает палку и пытается построить отношения с сильными, но вспыльчивыми мужчинами. Такие союзы обычно не приносят ей счастья.

**Семья и брак**

Требовательная и властная Зарина редко выходит замуж раньше 30 лет. Если эта женщина берет на себя роль главы семьи, брак обречен на развод. Для поддержания гармоничных отношений в семье ее супругом должен быть не менее сильный по характеру мужчина, способный противостоять ее порывам. Атмосфера в паре во многом зависит от уступчивости обоих. Отсутствие компромиссов может превратить их дом в поле боя.

В хозяйственности, заботливости и преданности этой женщине сложно найти равных. Она с трепетом относится к детям, много сил тратит на создание уюта в доме и постоянно совершенствует свои кулинарные навыки. Не переносит, когда окружающие пытаются ее учить или указывают на ошибки. Из-за этого она никого не подпускаетк воспитанию детей или ведению быта.

**Зарина входит в ТОП-10 списков имен**

Әтием - Ренат- РЕНАТ ~ РИНАТ (лат. яки р.; неол.) 1. Латинча ренатус «яңартылган, яңадан туган» сүзеннән ясалган исем. 2. Рус телендәге «революция», «наука», «труд» сүзләреннән ясалган кыскартылма кушма исем. Татарларда утызынчы еллардан башлап шактый актив кулланылышка ия.

Әнием -Алсу- АЛСУ (т.) Алсу йөзле; күч. матур, чибәр.

**Минем укытучымның гаиләсендәге исемнәр.**

РАФИС (г.)- Рәфис. Билгеле, күренекле. Төрдәше: Рафис.

РӘМЗИЛ (г.) - Рәмзи (к.) исеменнән ясалган исем. Ф. в.: Рәмзин. Тамгалы; ишарәле; билге, үрнәк, символ. Синонимнары: Нишан, Рамиз. Исем компоненты.

РӘМЗИЯ (г.)- Билге, тамга, символ. Чаг.: Нишан.

РУЗИДӘ (ф.)- Ризык бирүче, туендыручы.

Без гап-гади, тырыш, дус-тату татар гаиләләре. Дуслык, татулыкта безнең бөтен көчебез! Шуны да онытмаска кирәк: исем кешене түгел, ә кеше исемне бизи. Эш-гамәлләре белән тарихка кергән кешеләрнең исеме мәңгегә онытылмый бит!

Гамәлең булса, күркәм зат,

Тарихка керә исем-ат –

Исемен асыл итә алган,

Чал тарихка китә алган.

Бу дөньяда шул нәрсәне,

И кешеләр, булдыралыйк,

Тарихта урын алырлык

Яхшы исем калдыралыйк!

Гомәр Саттар.

**Йомгаклау**

Укытучым белән бергәләп "Актаныш таңнары" газетасындагы иске, кызыклы исемнәрне җыйдык. Элек катлаулы исемнәр кушканнар. (Газетада өлкән яшьтәге кешеләр күберәк). Ә хәзер гадирәк исемнәр кушалар. Минем сыйныфымда гади,татар исемнәре генә кушылган диярлек.

Бу фәнни-тикшеренү эше өстендә эшләп, кешенең исеме мәгънәле икән, ул матур яңгырашлы, горурланып йөрерлек булуын һәм исемнең кеше тормышында зур роль уйнавын аңладым. Бу фикерне иптәшләремә дә җиткерергә, алар да үз исемнәренең һәм гаиләләрендәге кешеләрнең исемнәренең мәгънәләрен белсеннәр, мин бу хакта аларга аңлатырга тиеш дигән нәтиҗә ясадым.

**<u>Кулланылган әдәбият</u>:**

-Татарча-русча кеше исемнәре һәм фамилияләре сүзлеге, Татарстан китап нәшрияты, 2006 ел.

-Гомәр Саттар-Мулилле"Татар исемнәре ни сөйли?" "Раннур" нәшрияты 1998 ел.

- "Актаныш таңнары" газетасының 2021 нче елгы саннары.

- интернет ресурслар .

*Галимова Айсылу, 9 нчы сыйныф*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Муса Җәлил исемендәге «1нче гимназия» муниципаль бюджет белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчесе: Галимова Гөлфинә Салихҗан кызы, татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

## Шинельсез солдатлар

Мылтык тотып дошманга каршы атакага күтәрелмәделәр,ут эчендә үлем белән йөзгә-йөз очрашмадылар алар. Фронтка китәргә яшьләре җитмәде, сугыш чыкканда да балалар гына иде бит алар. Әмма каһәр суккан ул сугыш алар язмышына да үтеп керде: өмет-хыялларын чәлпәрәмә китерде, балачак бәхетеннән мәхрүм итте. Ут эченә кермәсәләр дә, сугыш михнәтен ай-һай нык татыдылар: көч җитмәстәй авыр хезмәттә ватылдылар, ятимлек ачысын белделәр,ач үлем белән күзгә-күз очраштылар.
Бөек Җиңүнең 75 еллыгы уңаеннан, эзләнү-тикшеренү эшемне сугыш чоры балаларына багышларга булдым. Мин чишәргә теләгән төп проблема – минем кебек яшь буынның фашист илбасарлары китергән афәтнең тирәнлеген, өлкән буынның ил азатлыгы өчен көрәштә нинди корбаннарга баруын аңлап бетермәүдә.

Дәһшәтле сугыш елларында әби-бабаларыбыз кичергән авыр язмыш беркайчан да онытылмаска тиеш һәм шул ук вакытта кабатланмасын да дибез. Сугыш тәмамланугa 77 ел вакыт узып барса да, өлкән буын вәкилләребезнең күз яше кипкәне, сугыш китергән

күңел яраларының әле дә төзәлгәне юк. Без моның шулай икәненә сугыш башланганда 5-14 яшьләрдә генә булган, бүгенге көндә 80,85, 90 яшьлек әби-бабайлар белән очрашып аралашкач аңладык.

**Без, авыз тутырып, эти дип, әйтә алмадык.**

Ил халкы белән берлектә, минем әби-бабам да җиңү көннәрен якынайту өчен сугыш вакытының катгый таләпләренә буйсынып яши. Авыр сугыш авыл халкына көн дә кара кайгы китереп тора: кемнеңдер газиз улы сугыш кырында башын салган, кемнеңдер сөлектәй ирләре һәлак булган. “Сугыштан килгән хатларны бергәләшеп укый идек. Исәннәр өчен шатланып, публик(кара кайгы хатлары) хатлары алучылар белән бергәләп кайгыра идек . Ә андый хатлар авылга күп килде, -дип искә ала әбием Гамбәрия . – Без бит, авыз тутырып, “эти” дип тә әйтә алмадык “,- ди күз яшен яшермичә.

**Шинельсез солдатлар.**

Минем әбием Салихҗанова Гамбәрия Салихҗан кызы да Бөек Җиңүгә үз өлешен керткән кеше. Ул 1934 елның 5 мартында(чынлыкта исә әбием 1933 елгы) Актаныш районы Илтимер(хәзер ул авыл юк) авылында гаиләдә икенче бала булып дөньяга килә.Сугыш башланганда, әбиемә 7 яшь була.Ул бу кара көнне менә ничек искә алды: “Сугыш башлану турында без болында ишеттек. Авылның яше –карты, бала-чагасы печән җыя иде. Бу хәбәрне ишетү белән, барысы авылга кайтты. Авылыбыз зур түгел иде,70-75 ләп кенә хуҗалык. Икенче көнне үк авылдан сугышка 5-6 кеше китте. Андагы елаш-кычкырышны, әрнүле ыңгырашуны мин беренче тапкыр шунда күрдем һәм ишеттем. Беренче партия ир-атларны озатып, 5-6 көн дә үзмады, 7-8 кешене авылыбыз белән озаттылар. Алар арасында минем әтием дә бар иде. Мин шунда әтине соңгы тапкыр күрермен дип күз алдына да китермәдем. Бәлкем, эти миңа гаиләдә бердәнбер кыз булганга, сугышка киткәндә, мине кочагына кысып, күз яшьләре битемне яндырса да, “Мин кайтканчы, зур үс,кызым,” дип әйткәч, назлы карашын, елмаюлы йөзен күргәч, кайтыр дип уйладым. Әти киткәч, мине шул елны ук мәктәпкә язып чыгып киттеләр. Абый инде өченче сыйныфта укый. Ике энем кечкенә иделәр. Көз җитү белән, безнең өйгә өч гаилә керттеләр, чөнки аларның кышка ягарга утыннары юк иде. Шулай итеп, без барысы 15 ләп кеше булдык. Әти, сугышка хәтле хезмәт көне өчен, суыртылган солы алган булган, шул солы төшеннән ботка пешереп ашап бетердек. Әни, өлкәннәр белән бергә, Җиңү көнен якынайтыр өчен көн-төн колхоз кырында, бөтен эш абый белән безгә калды. Бигрәк тә кыш көннәре үзәккә үтә иде: кияргә кием юк,ашарга бер сынык икмәккә тилмерер идек. Өстәвенә,безнең кебекләр чанага каз оясы утыртып, тавык тизәге җыярга чыга идек. Юк , ул безгә түгел, аның белән мәктәпнең мичен җылыта идек. Дәрестән соң, ял көннәрендә шул чана белән кырга тирес түгәбез. Кырда игеннәрне җыеп алгач,безнең

кебек бала-чаганы басуга башак җыярга чыгаралар. Бер башакны да алып кайтырга ярамый. Җәй көннәре җитүгә, мине абый белән фермага алып төштеләр,бозаулар карарга, көндез урак урырга барырга кирәк. Җәй көне кияргә күлмәк булмагач, әни сарык йонынннан итәк белән кофта бәйләп бирде. Көз көне мәктәпкә барырга аяк киеме юк, яланаяк чаба-чаба барасың да, аякларны тезгә кадәр бөкләп утырасың. И аның салкыннан әрнүләре!!!... Урманга барып, ботак кисү, тездән карлы суга бата-бата орлык ташу,үгез белән кырны сукалау кебек эшләр иде. Бер минут тик торырга юк,без уен уйнарга дигән сүзне белмәдек. Безнең барыбызның да уенда " Барысы да Җиңү өчен!" дигән теләк иде. Безнең кебек 8-10 яшьлекләрне чәчү орлыгы ташырга куйдылар. 25 километр җәяү барырга , орлыкны күтәреп, тагын 25 км җәяү кайтырга. Ул орлыкны алып кайткач, җирне казып, бер буш җир калдырмыйча чәчәргә. Чөнки җирне сөрергә тракторлар, атлар юк, сыерларны җигү гадәти күренешкә әйләнде. Кичләрен, сукыр лампа астында, сугышчыларга оекбаш-бияләй бәйлибез,бер пар гына түгел бит, тәүлегенә 5-6 шарны. Кирпич сугу, урман кисү, урман ташу, иң авыр хезмәтләрнең берсе-молотилкага башак көлтәсе биреп тору кебек ирләр хезмәте безнең җилкәдән төшмәде. Ә без шул авырлыкларны җиңә-җиңә, бүгенге матур тормышны күрүгә ирештек. Беркем дә рәхәт тормыш турында сорамады. Яз килүне түземсезлек белән көтә идек, чөнки бакчалардан черегән бәрәңге – кәлҗәмә җыябыз. Аннан да тәмле бәрәңге юк иде безнең өчен! Алабутадан пешерелгән икмәк – төп ризык иде. Аны чәйнәгәндә үк авызлар суелып бетә иде. Халкыбызның киләчәккә ышаныч белән каравы, туган җиренә, туган иленә булган мәхәббәте Бөек Ватан сугышында җиңүгә китергән. Әйе, бу җиңү безгә бик кыйммәткә төште." – дип хатирәләрен яңартты ул. Алар барысы да, көчләреннән килгәнчә, Җиңү көнен якынайтканнар.

89 яшьлек әбиемнең балачагы сугыш чорына туры килсә дә, әбием булдыклы, тырыш, авырлыклар алдында югалып калмый торган олы йөрәкле, сабыр һәм тыйнак кеше. Хәзер ул лаеклы ялда, гаиләбездә ихтирамга лаек кеше, тормышыбызда бик зур терәк.

Сугыш...Бик күп күз яше, кан түгелгән, озакка сузылган дүрт ел. Ул еллар әле һич узып китмәслек озын тоела. Сугыш барганда һәр йортны, һәр гаиләне кайгы, үлем сагалап йөргәндә дә, соңгы өметне өзеп, өйләргә үлем язулары килгәндә дә,кешеләр өмет белән яшәгәннәр. Безгә бу турыда онытырга ярамый, тагын сугышлар булмасын өчен бөтен көчебезне куярга тиешбез.

Күпме ир-егетен яу кырына озатудан тыш,сугыш елларында фронтны, үз авызыннан өзеп, ашлык, кием –салым белән тәэмин итеп торган авыл. Тылдагы бөтен авырлык хатын-кыз, бала-чага җилкәсенә төшә. Үзләре ачка шешенсә дә, алар һәр килограмм

ашлыкны дәүләткә озата. Сугыш чорында Татарстандагы һәр гаилә, һәр авыл әнә шулай фронт өчен дип яши.

Йомгаклап әйткәндә, әбиемнең хатирәләрен искә төшереп, аның белән аралашканнан соң, нинди генә кыенлыклар булуга карамастан, Бөек Ватан сугышы чорында халкымның фронтта да, тылда да дошманны тар-мар итүгә лаеклы өлеш кертүе белән таныштым. Бу эзләнүдән мин түбәндәге нәтиҗәләргә килдем: минем әбиемнең, яшь вакытлары сугыш чорына һәм сугыштан соң авыр торгызу елларына туры килгән. Ашаган ризыклары алабута ипие белән черегән бәрәңге кәлҗәмәсе булып та, зәмһәир суыкларда да, эссе чилләләрдә дә алар "уф алла" арбасы белән утын ташыганнар, тирес түккәннәр, печән чапканнар. Авырлыклар алдында куркып калмаганнар, гаилә корганнар. Бу сугышның кайтавазы бүген дә бик тә санаулы калган ветераннарыбызның сугыш уты көйдергән йөрәкләрендә әрни, төзәлмәс яра булып сыкрый. Безнең бурыч: мондый буыннар аралашуын, хатирәләрне туплауны киләчәк буынга җиткерү.

**Файдаланылган әдәбият**


1. Дети – герои Великой Отечественной воны. – М.Дрофа-плюс-2007

2. Дәһшәтле чор балалары.-15 томда .Т.7.-Казан: Татарстан китап нәш. 2010

3. Сугыш чоры балалар әдәбияты.-15томда.Т.4.-Казан:Татарстан китап нәш.2010

4. Герой пионерлар.-Казан:Тат.кит.нәш., 1978-320б.

5. М.Җәлил. Кечкенә дусларга:шигырьләр.-Казан:Тат.кит.нәш.,1989

6. Бабам истәлекләре. 2015

7. Вакытлы матбугат материаллары ("Ирек мәйданы", "Безнең гәҗит" газеталары , 2016-2019)



*Галимов Зиннур, Хәлимов Рәмис, 1 нче сыйныф,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «32нче гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчеләр: Мөбарәкшина Рузилә Рәшит кызы, туган теле һәм әдәбияты укытучысы, Грачева Гөлназ Таһир кызы, башлангыч сыйныфлар укытучысы*


## Татар халкында кунакчыллыкның милли-мәдәни үзенчәлекләре

Мәктәптә без һәркөнне 2 тапкыр ашханәгә барабыз. Анда күп укучылар үзләрен бик матур, әдәпле тоталар, тыйнак кына ашаганнан соң, пешекчеләргә рәхмәт әйтәләр. Аларга карап күңел сөенә. Ләкин ашханәдә үзләрен бик тәртипсез, начар тотучы укучылар да юк түгел. Аларның тавышларыннан ашханә шау-гөр килеп тора. Өйдә өстәл артында утырганда, кунакка баргач та без үзебезне әдәпле тотарга тырышабыз, тавышланмыйбыз. Нигә ашханәдә без үзебезне тота белмибез? Нигә тавышланабыз, бер-беребезне узып

кычкырып сөйләшәбез? Без бу сорауларга җавап эзләргә булдык һәм туган тел укытучыларыбызга мөрәҗәгать иттек. Укытучыларыбыз безгә ярдәм итәргә бик теләп ризалаштылар.

Хезмәтебезне татар халык авыз иҗаты әсәрләре белән танышудан башладык. Табын янында, кунакта, кунакны каршы алганда үзеңне ничек тотарга кирәклеге турында бик күп мәкаль, табышмак, әкиятләр бар икән безнең халкыбызда! Ашханәдә шау-гөр килеп утыручы дусларыбыз аларны белмиләрдер, белсәләр ул кадәр шауламаслар иде. Моны ачыклау максатыннан без анкета үткәрергә булдык. Дусларыбызны тәртипле, әдәпле булырга өндәү, ашханәдә, кунакта үзеңне тоту кагыйдәләре белән таныштыру хезмәтебезнең максаты булып тора.

**Татар халкында кунакны каршы алу традицияләре.**

Татар халкы борын – борыннан ук бик кунакчыл халык. Ул еш кунак җыю белән бергә, үзе дә кунакка йөрергә һәвәс, аның табыны мул, ризыклары да күп төрле була. Шунысы үзенчәлекле, элек татар халык табынында бизәкләп ясалган агач савыт – саба күп куелган. Мәсәлән, аш салынган зур агач табак табынның нәкъ уртасында торган. Аш өчен зур агач чүмеч, ә ботка кебек ашлар бүлү өчен зур кашык куелган;шулар белән үзеңә кирәгенчә алып бирә торган булганнар. Шул ук вакытта элек өйнең түрендәге сәке өстәл хезмәтен үтәгән. Ул да агачтан шома итеп эшләнгән, кырыйларына, кунак утырыр өчен, матур корамалардан көрпә куелган. Табынны җыеп алгач, сәкегә йоклау өчен урын җәелгән.

Элекке заманнарда, бигрәк тә авыл җирләрендә, өстәл һәм урындык кебек йорт җиһазлары бик сирәк өйләрдә генә очраган.

Өстәл янында башта ирләр утырып ашаган, аннары чират хатын – кызга җиткән. Кунак җыйганда да сәкенең бер ягына ирләр генә тезелеп уртырган. Ир белән хатынның парлап утыруы бик сирәк күзәтелгән.

Тора – бара аш – су әзерләүнең ысуллары үзгәрә, яхшыра бару белән бергә, өстәл янында утыруның рәвеше, мәгънәсе дә үзгәрә, ягъни заманча итеп һәм вакытына туры китереп оештырыла.

Кунак өстәле, өйнең зурлыгына, кунакларның санына карап, төрлечә тезелә ала. Мәсәлән, туры бер рәт кенә итеп, ягъни туры гына өстәл әзерләнә, әмма өстәл түгәрәк тә булырга мөмкин. “Т”, “П”, “Ш” хәрефләренә охшатып та тезәргә ярый. Халык: “Түгәрәк өстәлнең түре юк”, - ди. Бу сүзләрдә тирән мәгънә ята. Димәк, өстәлдә сый һәрвакыт җитәрлек,  кая утырсаң да барыбер. Бу исә өстәлнең күркәмлеген, килгән кунакларның бертигез дәрәҗәдә булуларын һәм бердәмлеген аңлата.

Шулай да, кунак табынының түре дә бар, чөнки кунаклар нинди дә булса бер вакыйга уңае белән җыела бит. Шуның өчен кунак җыюга сәбәпче кешеләр иң түргә утырырга хаклырак. Хуҗа кунакның сау – сәламәт килүен хуплап каршы ала, аягүрә торып сыйлый һәм күңелен күрә, аны хөрмәт итә.

Кунак каршылаганда чәй өстәленә чәчәкле ашъяулык җәелә. Өстәл уртасына буйдан-буйга варенье, бал, шикәр, конфет, вазалар тезеп чыгыла. Аларның ике ягына роза, кош теле, бавырсак, пәхләвә, чәкчәк, талкыш, кәләвә кебек камыр ашамлыклары куялар. Һәр кунак алдына десерт тәлинкәсе белән төрле камыр азыгы паштет, мүк җиләге бәлеше, эремчек бәлеше һәм башкаларны куярга кирәк. Тәлинкәдә өч төрле ризык буларга тиеш.

Өстәлнең берничә җиренә сай тәлинкәгә юка гына итеп телемләп лимон куярга кирәк. Кунаклар өстәл янына утырып беткәч, чәй китерәләр.Һәр чынаяк тәлинкәсенә балкашык куела. Кунаклар, үзләренә варенье салып ала алсын өчен, һәр варенье вазасында да балкашык булырга тиеш. Кунаклар күп булмаса, самоварны өстәлгә куярга мөмкин. Ул табынны бизәп торачак, чәй дә тәмлерәк тоелачак.

Чәй эчкәннән соң, өстәлне җыештырырга, махсус щетка белән тәлинкәгә ризык валчыкларын себереп алырга да, вазалар белән җиләк-җимеш – алма,груша,виноград, әфлисун һәм башкаларны чыгарырга кирәк.

Кунакларны табынга түбәндәге сүзләр ярдәмендә чакыралар:

-Табынга рәхим итегез!

-Әйдәгез, рәхим итегез!

-Тагын бер чынаяк чәй эчегез!

-Тавык итеннән авыз итегез!

-Бәлешне ашагыз әле! Һ.б.

**Татар халык авыз иҗатында, әдипләрнең әсәрләрендә кунакчыллык**

Халкыбызның авыз иҗаты әсәрләре - яшь буынга белем һәм тәрбия бирүдә кыйммәтле чыганак. Халыкның бай рухлы, кешеләрне гүзәл киләчәккә рухландыручы әкиятләре, киң колачлы җырлары, тирән фәлсәфи әйтемнәре, тапкыр һәм үткен мәкальләре, үзенчәлекле табышмаклары, яшьләргә сабак бирердәй итеп иҗат ителгән риваять, дастан, легенда һәм башка күп төрле иҗат җимешләре киләчәк буынны милләт тормышын дәвам итерлек, аны үстерүгә өлеш кертерлек итеп тәрбияләүдә зур рухи чишмә, чыганак булып тора.

Татар халкында кунакчыллыкка бәйле булган200 ләпмәкаль яшәп килә. Аларның киң таралганнары түбәндәгеләр:

Кайда коймак, шунда кунак.

Кеше ашы тәмле була.

Кеше икмәге белән мәңге торып булмый.

Тавышлы табыннан фәрештә качар.

Алдан килгән урын өчен, арттан килгән тамак өчен.

Кунак беренче көнне алтын, икенче көнне көмеш, өченче көнне бакыр, аннан ары юлы такыр.

Кунак ишегеңне ачса, син йөзеңне ач.

Кунак килсә ит пешә, ит пешмәсә бит пешә.

Кунакка барсаң, ач та барма, тук та барма.

Кунак ашы - кара-каршы.

Кунак булсаң, тыйнак бул.

Кунаклы йорт – хөрмәтле йорт.

Көтеп алган кунак кадерле була.

Халкыбызда кунакка бәйле ырымнар, ышанулар да бихисап.

Кунакның беренче көне – алтын, икенчесе – көмеш, өченчесе – бакыр, дүртенче көнең – юлың такыр.

- Өстәлдән кашык-чәнечке, пычак төшсә, кунак килә.
- Самовар җырласа, кунак чакыра.
- Мәче битен юса, кунак килә.
- Мендәр ишелсә, кунак төшә.
- Ашаган вакытта чәйгә икмәк кисәге төшсә, кунак килә.
- Чыпчык тәрәзәдән килеп чукыса, кунак көт.
- Саескан йорт-җир тирәсенә килсә, кунак чакыра.
- Чынаяк өстенә чәй чүбе калыкса, кунак килә.

Шулай ук татар халкында кунакларга бәйле табышмаклар да яшәп килә:

Урамда ул бер танышың,
Туганың яки күршең.
Чакырып, өйгә килдеме,
Ул була нинди кеше? (Кунак)

Шулай ук “Төлке белән Торна” әкиятендә дә кунакны каршылау, сыйлау турында сабак бирелә.

"Төлке белән Торна" – нәниләр өчен язылган гыйбрәтле әкият. Ул "Ни чәчсәң, шуны урырсың" мәкаленә нигезләнгән һәм балаларны тирә-яктагыларны хөрмәт итәргә, аларга игътибарлы булырга, борынгыдан килгән матур гадәтләребезне, йолаларны онытмаска, киң күңелле, ачык йөзле булырга өйрәтә.

Халкыбызның күркәм гадәте булган кунакны каршы алу, кунак булу йоласын безнең мәктәп укучылары беләләрме? Кунак булу кагыйдәләрен үтиләрме? Хезмәтебездә без әлеге сорауларга да җавап эзләдек һәм 1 нче сыйныф укучылары арасында сораштыру үткәрдек.

Сораштыруда барлыгы 54 укучы катнашты. Алар түбәндәге сорауларга җавап бирделәр:

| | |
|---|---|
| 1. | Сез кунакка еш йөрисезме? |
| 2. | Кунакларны еш чакырасызмы? |
| 3. | Кунакта үзеңне тоту кагыйдәләрен беләсезме? |
| 4. | Кунакны каршы алу йолаларын үтисезме? |
| 5. | Сезнең гаиләгезгә хас булган үзенчәлекле йолалар, традицияләр бармы? |
| 6. | Сез кунакчыллыкка бәйле татар халык авыз иҗаты әсәрләрен беләсезме? |
| 7. | Кунакны каршы алу, кунакка бару турында нинди әсәрләр беләсез? |

Сораштыру нәтиҗәләреннән күренгәнчә, укучыларның күбесе үзләре кунакка йөрергә ярата (72%), кунаклар килгәнне көтер алучы укучылар саны азрак (54%), кунакта үзеңне тоту кагыйдәләрен барлык укучылар да белеп бетерми (96%), кунакны каршы алу йолаларын белүче укучылар тагын да кимрәк (84%), халкыбызның күркәм гореф-гадәтләреннән үрнәк алып, үзләренең традицияләрен булдырган гаиләләр шактый (72%), ә менә кунакларны каршы алу, кунакта, аш табыны янында үзеңне тоту кагыйдәләренә өйрәткән, әдәпле булырга өндәгән татар халык авызы иҗаты (27%), әдипләребез әсәрләрен (16%) күп укучылар бөтенләй дә белми икән. Тикшерү нәтиҗәләреннән чыгып, укучыларның күбесе кунак итә белү, кунакта үзеңне тоту кагыйдәләрен белә һәм үти, тик шулай да барлык укучылар да әдәпле булу серләренә төшенсеннәр өчен туган тел дәресләрендә, дәрестән тыш чараларда, гаиләдә халкыбызның гореф-гадәтләренә, йолаларына игътибарны арттырырга, халык авыз иҗатын, әдипләребезнең әсәрләрен укырга, өйрәнергә кирәк дигән фикергә килдек.

Күргәнебезчә, халкыбызның йола, гореф-гадәтләрен өйрәнү зур әһәмияткә ия. Кунаклашу йоласы буыннан буынга күчеп килүче күркәм гадәтләрнең берсе. Кунакчыллык безнең тормышка шулкадәр нык үтеп керде ки, хәтта төрле халыкларның аңында ул тиешле, мәдәниятебезнең аерылгысыз бер өлеше булып кабул ителә.

Хезмәтебезнең икенче өлешендә татар халык авыз иҗатында һәм әдипләр әсәрләрендә кунаклашу йолаларының бирелешен өйрәндек, 1 нче сыйныф укучылары арасында “Кунакчыллык йолаларын беләсеңме?” дигән темага анкета үткәрдек. Сораштыру нәтиҗәләреннән шул ачыкланды: татар гаиләләрендә тәрбияләнүче укучыларның күбесе кунак итә белү, кунакта үзеңне тоту кагыйдәләрен белә һәм үти, тик

шулай да барлык укучылар да әдәпле булу серләренә төшенсеннәр өчен туган тел дәресләрендә, дәрестән тыш чараларда, гаиләдә халкыбызның гореф-гадәтләренә, йолаларына игътибарны арттырырга, халык авыз иҗатын, әдипләребезнең әсәрләрен укырга, өйрәнергә кирәк дигән фикергә килдек һәм өйрәндек тә. Шушы белемнәребезне без татар халкының борынгы гореф-гадәте булган "Кунаклашу" йоласын үткәргәндә кулланып, әти-әниләребез, укытучыларыбызны сөендердек.

Адәм баласы ана телен, динен, гореф-гадәтләрен, йолаларын ихтирам итәргә тиеш. Табигый, буыннан буынга күчә торган рухи тәҗрибә һәм йолалар вакытлар узу белән һич тә әһәмиятләрен югалтмыйлар, киресенчә, аларның кыйммәте арта гына. Моның шулай булуын без әлеге хезмәтебездә тагын бер кат исбатладык.

**Кулланылган әдәбият исемлеге**

1. Галиев Ш.Г. Шәвәли китабы: Шигырьләр. – Казан: Татар. кит. нәшр. – 2006. – 13 б.

2. Закирова К.Ф. Балачак аланы: балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм әти-әниләр өчен хрестоматия. — Казан: РИЦ. – 2011. — 560 б.

3. Нәкый Исәнбәт. Татар халык мәкальләре. 4 нче басма. — Яр Чаллы: «Идел-йорт», 2003. — 100 б.

4. Фәхретдин Р. Балаларга үгет- нәсыйхәт. – Казан: "Дом печати" нәшрияты. – 2001. – 192 б.

5. Хәйдәрова Р.З., Әхмәтҗанова Г.М., Гыйниятуллина Л.Ә. "Күңелле татар теле" 3 нче сыйныф. Казан: Татармультфильм. – 2013. – 62 б.

6. Хәйруллина В. Серле сәгать: Балалар өчен шигырьләр.- Казан: Татар. кит, нәшр. – 2013.

7. Хөсни Ф. Кырык хикәя / Ф.Хөсни.- Казан: Татар.кит.нәшр. – 1960.- 255 б.

**Интернет чыганаклар**

1. https://infourok.ru/otkritiy-urok-po-teme-shgaliev-kunaklar-klass-567012.html

2. http://nsportal.ru/shkola/rodnoy-yazyk-i-literatura/library/2015/11/18/tatar-halyk-mkallre

3. http://sabyem.ru/?p=3758

*Галиуллина Адилә, 9 нчы сыйныф,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы «7нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчеләре: Хәмизова Вафия Тимершәех кызы, Камалова Гөлназ Радик кызы*
*татар теле һәм әдәбияты укытучылары*

## Тел – бакча, сүз - чәчәк

(М.Хәбибуллинның “Сөембикә ханбикә һәм Иван Грозный”романында тел-бизәкләү чарасы буларак искергән сүзләр)

Сүз турында берничә сүз

Илебездә XX гасырның 80 – 90 нчы елларында милләтләрне, милли телләрне саклау һәм үстерү сәясәте иҗтимагый сәхнәгә менде. Моның өчен иң беренче чиратта милләтне милләт итеп саклый һәм милли мәдәниятне үстерә торган төп корал буларак, милли телне торгызу һәм үстерү кирәк иде. Бу эштә Татарстан дәүләте ышанычлы чаралар күрә башлады:

– 1990 нчы елның 30 нчы августында Татарстанның мөстәкыйльлеге турында Декларация кабул ителеп, анда татар теле рус теле белән тигез дәрәҗәдәге дәүләт теле итеп игълан ителде.

– 1992 нче елның 8 нче июлендә “Татарстан Республикасы халыклары телләре турында” Татарстан Республикасы Законы кабул ителде.

– Татар теленең рус теле белән бертигез дәрәҗәдәге дәүләт теле булуы 1992 нче елның 6 нчы ноябрендә кабул ителгән Татарстан Республикасы Конституциясендә дә беркетелде.

– 1994 нче елның 20 нче июлендә Татарстан Республикасы халыклырының телләрен, бигрәк тә татар телен саклау, өйрәнү һәм үстерүнең дәүләт планы кабул ителде.

Ләкин алтмыш ел буе милли телләрне юк итү сәясәтенең традицияләре көчле булып чыкты. Шуңа күрә татар телен торгызу, саклау һәм үстерү зур кыенлыклар белән бара. Һәрбер кеше дә телне үстерү өчен тамчы кадәр генә булса да үз өлешен кертергә тиеш. Татар телен үстерү, баету безнең бурычыбыз.

Теге яки бу телнең сүзлек составын, җирле сөйләшләрдәге сүзләр җыелмасын, теге яки бу тел остасының сүзлек байлыгын, теге яки бу кешенең
сүзләр җыелмасын, әдәби әсәрнең сүзлек составын <u>лексика</u> дип атыйлар. Лексиканы <u>лексикология</u> бүлеге өйрәнә. Димәк, лексикология сүзне тикшерә.

Сүз авазлардан тора,сүзнең төзелеше бар, сүзнең мәгънә ягы бар. Һәр сүзнең дә төп һәм күчерелмә мәгънәсен, килеп чыгышын, атама тарихын, кулланылыш үзенчәлеген, төзелешен һ.б. тасвирламаларын табып була. Ләкин хәзерге көнгә кадәр сүзгә төгәл генә, тулы гына билгеләмә бирелмәгән. Сүзләр гаҗәеп серле дә, четерекле дә. Шуңа күрә аларны тикшерү хәзерге вакытта да әһәмиятен югалтмый.

Сүзләр гасырлар үтү белән алмашынып торалар.Ниндидер вакыйгаларга бәйле рәвештә кайбер сүзләр кулланылыштан төшеп кала, ә яңалары туып тора. Менә шулай безнең лексикабыз байый, яңара.

Галимнәр сүзләр дөньясының төрле якларын өйрәнәләр.Без дә үзебезнең фәнни хезмәтебездә сүз катламнарын тикшерергә булдык. Өйрәнү-тикшерү объекты итеп искергән сүзләрне алдык.

Фәнни эшебез барышында иң беренче фәнни мәгълүмат тупладык, Мөсәгыйт Хәбибуллинның "Сөембикә ханбикә һәм Иван Грозный" романын укыдык, андагы искергән сүзләрне аерым язып алдык. Искергән сүзләрнең мәгънәләрен сүзлекләрдән карадык, мәгънә төрләре буенча классификацияләдек, кушымтада сүзлекчә бирдек.Тел турында,сүз турында атаклы кешеләрнең шигырьләрен, тирән фикерләрен, халкыбызның мәкаль-әйтемнәрен дә җыйдык. Аеруча Лена Шагыйрьҗанның көндәлегендәге язмалары күңелнең иң тирән кылларына кагылды: "Сүзләр... Сүзләр... Сез – минем мәхәббәтем... Сез – бөтенесе дә... Сез – миннән башка да яшисез, ә мин сездән башка яши алмам. Ләкин мин дә сезгә кирәк! Чөнки мин дә – сезне аклаучыларның берсе... Сезнең хакта язучылар бик үк күп түгел, ә менә сездән башка беркем дә берни дә яза алмый...

Сүзләр үзләре турында үзләре сөйләп тора, әлбәттә. Әмма аларның да бездән яшерен серләре бар. Бар гомер буе шул серләрне ачарга омтылып яшибез...

Сүзләр, мин сезне ничек яратам!.. Мин сезгә бурычлы. Минем телем дә, каләмем дә гомерем буе сезнең кануннарыгызга итагатьле булып калыр... Сез мине үз кадерегезне дә, тормыш кадерен дә аңларга өйрәттегез. Рәхмәт сезгә, сүзләр!

Дөньядагы барлык-барлык сүзләр арасында минем дә сүзләрем бар... Газизләрдән газиз Әткәм-әнкәм теле – Бөек Татар телендәге сүзләрем – Җир шары буйлап кояш нурлары кебек таралсын иде дә, җиһандагы барлык кешеләрне бары тик гүзәллеккә һәм изгелеккә генә өндәп торсыннар иде!.."

Эшебезне дә "Тел – бакча, сүз - чәчәк" дип юкка гына атамадык. Үземне мин чәчәкле бакчада йөргән кебек хис иттем. "Тел" дигән " чәчәкле бакчада" никадәр матурлылык, төрлелек, хисләр байлыгы бар. Аларны күрә, тоя, сизә белергә генә кирәк. "Чәчәкле бакчабыз"ның ямен саклыйк.

Сүзләрне өйрәнү, тикшерү бик тә мавыктыргыч! Сүзләр дөньясы шундый кызыклы! Югалган, онытылган сүзләр әледән-әле табылып тора. Хәтер сандыкларында бик озак ятып, күксеп-күгәреп беткән сүзләрне кояшлы җилгә чыгарып элсәң, алар кабаттан яңарып, сафланып һәм яшәреп китәләр. Телгә, җырга, тарихка кереп калган сүзләр барыбер үлми, юкка чыкмый...

Аларны каенсуыдай тамчылап, яисә энҗе кебек бөртекләп җыярга да җыярга кирәк... Сүзләрне тикшергәндә, безнең ата-бабаларыбызның сөйләшү үзенчәлекләренә төшенәсең, аларның нинди сүзләр кулланганын беләсең. Шуңа күрә сүзләрне киләчәктә

дә тикшерергә, өйрәнергә кирәк. Чөнки безнең үткәнебез дә, киләчәгебез дә сүзләрдән башка булмаган һәм булмаячак.

**Тел гыйлемендә телнең пассив сүзлек составы буларак искергән сүзләр**

Сүзләр яши, сүзләр калган
Җырларда, дастаннарда.
Идегәйләр белән бергә,
Җирдә - Татарстанда.
Э.Мостафин

Телнең сүзлек составы фән һәм техниканың, икътисад, мәдәният, әдәбият һәм сәнгатьнең үсүенә бәйләнешле рәвештә баеп, камилләшеп тора.

Телнең сүзлек составы үзгәрү берничә юл белән бара: искергән сүзләр төшеп кала, сүзнең аерым мәгънәләре югала, яңа мәгънәләре барлыкка килә һәм шулай ук өр-яңа сүзләр дә ясала. Бу үзгәрешләр озак вакытлар белән бәйле. Шуңа күрә иске һәм яңа сүзләр янәшә кулланылышта йөриләр.

Куллану дәрәҗәсенә карап, татар телендәге сүзләрне ике группага бүләргә мөмкин:

1.Актив сүзләр.

2.Пассив сүзләр.

Фәнни хезмәтебезнең өйрәнү объекты пассив сүзләр. Аларны 1) искергән сүзләр һәм 2) неологизмнар тәшкил итә. Искергән сүзләрне ике категориягә бүлеп йөртәләр: 1) тарихи сүзләр, 2) архаизмнар.

**Тарихи сүзләр.** Кулланылыштан төшеп калган күренеш, предметларның атамалары **тарихи сүзләр** дип атала: алпавыт, бояр, хан, ахун, морза, кантон,абак, талак, камзол, чабата, чулпы, сука, киле, торпыча, ярлык һ.б. үткән тормыштагы предметларны (күренешләрне) ниндидер кирәклек аркасында, мәсәлән, дәреслекләрдә матур әдәбиятта искә алганда, аларның шул чордагы исемнәре кулланыла, чөнки тарихи сүзләрнең хәзерге телдә синонимнары булмый.

**Архаизмнар.** Кайбер күренешләр, предметлар элекке атамасы белән түгел, бүгенгесе белән йөртелә: укытучы ( мөгаллим түгел), мәктәп ( мәдрәсә түгел), көнчыгыш ( шәрык түгел), диалект (шивә түгел) һ.б.

Димәк, әгәр тарихи сүзләр искергән, юкка чыккан күренешләрнең атамалары булса, **архаизмнар** – хәзерге көндә дә булган күренешләрнең искергән атамалары.

**Архаизмнарның типлары.** Искерү дәрәҗәсенә карап, архаизмнар 4 төрле була: 1) лексик-фонетик архаизмнар, 2) лексик-морфологик архаизмнар, 3) лексик архаизмнар, 4) семантик архаизмнар.

1)*Лексик-фонетик архаизмнар*. Хәзерге телдәге кулланылыштан үзләренең фонетик төзелешләре белән генә аерыла торган сүзләр лексик-фонетик архаизмнар дип атала: гакыл ( акыл ), тугры ( туры ), еглау ( елау ), аңгар ( аңа ), сарыг ( сары ), тугу (туу ), баг ( бау ), таг ( тау ), атгыйр ( айгыр ) , коток ( кое ), берлән ( белән ), азак ( аяк ).

2)*Лексик-морфологик архаизмнар*. Үзләренең искергән ясагыч яки төрләндергеч кушымчалары белән аерыла торган сүзләр лексик-морфологик архаизмнар дип атала: булыш*мак*лык ( булышлык ), *би*мәгънә ( мәгънәсез ), соңра (соңыннан ), баргач*тын* ( баргач ), ихлас*лы* күңел ( ихлас күңел ), бар*мага* ( барырга ), бар*аен* ( барыйм ).

3)*Лексик архаизмнар*. Тамыр килеш искереп, икенче бер сүзләр ( ягъни синонимнары ) белән алмашынган сүзләр лексик архаизмнар дип йөртелә: мәгыйшәт ( тормыш ), кярханә ( мастерская ), жиһан ( дөнья ), ислах ( реформа )
нәшер ( китап бастырып таратучы ), җәридә ( газета ), мәмләкәт ( ил ), шура ( совет ), инкыйлаб ( революция ), мантыйк ( формаль логика ). Күренә ки, лексик архаизмнар урынында татарның үз сүзләре дә, башка телләрдән кергән
сүзләр дә кулланылырга мөмкин. Моның өчен төп шарт булып сүзләрнең халыклашуы санала.

4)*Семантик архаизмнар*. Мәгънәсе искергән сүзләр семантик архаизмнар дип атала: юлдаш, иптәш, остаз, хезмәткәр, солдат, офицер, вокзал, партизан,
канун һ.б. сүзләр хәзер яңа мәгънәләрендә кулланылалар.Матур әдәбията искергән сүзләр ( архаизмнар ) төрле максатлардан чыгып файдаланылалар.

Язучы-художник үткән тормышны, реаль тарихи чынбарлыкны сурәтләгәндә иске сүзләрдән файдаланмый кала алмый. Мисал өчен Ә.Фәйзинең « Тукай », К.Нәҗминең « Язгы җилләр » романнарын карарга мөмкин.
Көлкеле, иронияле, сатирик әсәрләрдә тыңлаучыга яки укучыга тәэсир көчен арттыру максаты белән архаизмнар еш кулланылучан. Мисал өчен Г.Тукайның сатирик шигырьләрен, « Чаян » журналындагы карикатура асларын карарга мөмкин.”[1]

**Әдәбиятта тел-бизәкләү чарасы буларак искергән сүзләр**

Сүзләр күп! –
Болыт акса да,
Үлән селкенсә дә - сүз!
Р. Әхмәтҗанов

Татар теле белгечләре архаизмнарны дүрт типка бүлгән булсалар, әдәбият галиме филология фәннәре докторы Ф.М.Хатыйпов үзенең “Әдәбият белеме сүзлеге”ндә

[1] К. : Әхәтов Г. Х. Татар теленең лексикасы (Педагогия институтлары һәм колледжлары өчен кулланма ). – Казан: Татарстан кит.нәшр.. 1995. – 75-76 б.

архаизмнарны билгеле бер авазлар комплексы буларак сүзнең кулланылыштан бөтенләй төшеп калуына яки аның мәгънә эчтәлеге үзгәрүгә карап, аларны өч төргә аера.

**Лексик архаизмнар.** Аларның бер өлеше хәзерге телдә кулланыла торган сүзләрдән үзләренең фонетик төзелешләре белән аерыла. Мәсәлән, баг – бау, даг – дау, азак – аяк һ.б., ә кайберләре исә рус һ.б. телләрдән алынган сүзләр белән алышына (имла – орфография, шура – совет, нәху – синтаксис, сәясәт – политика һ.б.)

Ә беришесе телнең үз сүзләре белән алышына: диван – җыентык, мәмләкәт – ил, иҗтихад – тырышлык һ.б.

**Табигый архаизмнар -** теге яки бу әсәр иҗат ителгән вакытта халык телендә актив кулланылган сүзләр, бүгенге көн укучысы өчен искергән булып яңгырый. Сүзләр бу очракта автор ихтыярыннан башка архаизмга әйләнә.Мисал:

Бәхетле шул баладыр, кайсы дәрсенә күңел бирсә,

**Мөгаллимне** олуг күрсә, белергә кушканын белсә,

**Сабакка** калмаса соңга, борылмый барса уң-сулга,

Уенга салмаса **ихлас** – менә бәхте аның шунда. (Г.Тукай)

Бу сүзләр шигырь иҗат ителгән елда (1909) архаик булмаганнар. Әмма вакыт үзенекен иткән, алар яңа сүзләр белән алыштырылган.

**Стилистик архаизмнар** язучының иҗади максатыннан чыгып, персонажларның сөйләмендә, вакыйгаларны тасвирлаганда, сурәтли торган тарихи чор билгеләрен һәм рухын бирү өчен кулланылалар. Мисал:

Билгеле Болгар – **тораны – ханбалыкны**, Ага-базарны саклау өчен ул кораллы **чирү** калдырмый булдыра алмады. (Н.Фәттах)

Бередә тора – шәһәр, ханбалык – башкала, чирү – гаскәр.

Архаизмнар сатирик максат белән, ирониялe, көлке әсәрләр язганда да файдаланыла. Мәсәлән:

Гәүдәсе юк бер гаҗәеп **баш ирер;**

**Шәһит ирер**, ике күзе **яшь ирер.**

**Аглыйдыр** һәркем күзеннән яшь сыгып,

**Аглый** кибеттән кәләпүшләр чыгып...

Шул вакытта камчылы ишан килә,

Ул кисекбашны **тотубән** өшкерә. (Г.Тукай)

Архаизмнар тантаналы стильдә язылган әсәрләрдә дә кулланыла. Мәсәлән, Ш.Мөдәррис “Тупчы Ваһап” балладасында Архаизмнар сугыш героикасын бирү өчен, изге эштә рух күтәренкелеген күрсәтү өчен файдаланыла:

**Яд** итсен **җыр шанлы** Русса төпләренең

Урман шавын, юллар чатын, бодай кырын;
Бу **хозур** җир – көнбатыш төннәренең
Сөрем катыш сырып яткан томан-чыгын.” [2]

**М.Хәбибуллинның “ Сөембикә ханбикә һәм Иван Грозный” романында тел-бизәкләү чарасы буларак искергән сүзләр**

Сүз эзлим, сүзләр актарам,
Сүзләрдән кача-кача...
Төче сүзләр, юхаланып,
Тезләнеп, куенын ача!..
Р.Әхмәтҗанов

М.Хәбибуллинның “ Сөембикә ханбикә һәм Иван Грозный” романын укыган вакытта, без искергән сүзләрне аерым дәфтәргә яза бардык. Яза торгач, 165 сүз җыйдык. Аларны классификацияләдек, кушымтада шул сүзләрнең сүзлекчәсен бирдек (Кушымта 1, 20 – 27 б.). Сүзләрнең мәгънәләрен “Татар теленең аңлатмалы сүзлеге”ннән карадык. Мәсәлән:

1. Аксөяк – затлы, югары нәселдән булган кеше, аристократ. ТТАС I т.( 2 нче искәрмә ) 36 б.[3]
2. Каравыш – хан кызының хезмәтче кызы. ТТАС II т. ( 3 нче искәрмә ) 51 б.[4]
3. Ханбикә - хатын-кыз хан яки хан хатыны. ТТАС III т. (4 нче искәрмә ) 362 б.[5]

Кайберләренең мәгънәләрен белү өчен “Рус теленең аңлатмалы сүзлеге”нә мөрәҗәгать иттек. Мәсәлән:

1. Кенәз – гаскәрне әйдәп баручы һәм өлкә белән идарә итүче. РТАС (1 нче искәрмә ) 285 б.[6]
2. Кенәгинә – кенәзнең хатыны. РТАС 285 б.

Сүзлектә очрамаганнарына җөмләдән чыгып, үзебез аңлатма бирдек. Мәсәлән:

1. Көнтуктар – бүгенгә туктап ял итәсе урын, җир.

Үзебез җыйган сүзләрне тарихи сүзләргә һәм архаизмнарга бүлдек. Тарихи сүзләргә түбәндәгеләрне керттек: *аба, азамат, акбикә, алатлар, алтын бәлеш, бакалай,*

---

[2] К. : Ф.М. Хатыйпов. Әдәбият белеме сүзлеге.// - Казан: Татар кит.нәшр., 1990. 19-20 б.
[3] К.: Искәрмәләр 31 б.
[4] К.: Шунда ук.
[5] К.: Шунда ук.
[6] К.: Шунда ук.

*барымта, баскак, бояр, буза, бусагабаш, бусурман, вәзир, галиҗәнап, гошер, дәвалбазлар, җария, җиһангир, илбашы, казнабаш, калкан, каравылбаш, каравыш, карачы, кенәгинә, кенәз, король, көмеш бәлеш, көмеш дирһәм, күчәрбаш, магуллар, морза, мыскал, олаубаш, падишаһ, патша, сорнай, тамгачы, тархан, тәхет, тупсабаш, ук-садак, уктабан, утырма, фиргавен, хан, ханбикә, ханзадә, хансарай, ыстан, яваннар, ярлык, ясавыл, ярлык.*

Архаизмнарның үзләрен Г.Х Әхәтовның "Татар теленең лексикасы" китабындагы классификациясенә таянып, 4 төркемгә аердык:

**1.Лексик архаизмнар:** *аксөяк, аркадаш, атын, әләмнәр, әтраф, бавырчы, бакалай, бакалдак, баскак, бәгъзеләре, бәк, болак, бояр, гасага сабышкан, гасалы сүзләр, гафил, гозернамә, гөман итү, дивар, җәйләү, җәһаләт, җәһәт, җиһан, зәгъфран, зиндан, илтабарлар, кәрвансарай, кәтиб, кирмән кала, койды, койты, көнтуктар, кын, малтабар, мәдрәсә, мәҗлес, мәмләкәт, мәргән, мәркәз, мәсләк, мелла, мичәүгә җиккән, мөгаллимә, мөртәт, мөһер,*

*мөһерен сукты, назарәт, нәсара дине, нәүбәт, низам-интизам, нотыгын, олпат, олыс, оран, отраф, пайтәхет, сабак, сөаль, торык, тотанак, тылмач,*

*фиркә, халаяк, хәерхаһ, хилаф, химая итү, хирыс, чаптар, шартнамә, шәкел, шөлдер, язык, ярлык, ясак, яугир.*

**2.Лексик - морфологик архаизмнар:** ***би**нахак, гаскәр**и**, дин**дар**, ислам**ия**нең, ихлас**и**, кыл**мак**, **нә**мәгълүм, хис**сияти**.*

**3.Лексик - фонетик архаизмнар:** *абасына, баш ийде, бәһа, белдереңез, былчырак, берәүсе, гаҗәбә, гәүһәр, гелән, егълыйсың, җәтмәсе, җылан,*

*җылап, ийде, Итил, кәңәш, кәрәк, Көбән, кызыңызны, мәнем, нидәр, олуг, ошбу, сәне, утырыңыз.*

**4.Семантик архаизмнар:** *атын, углан, орышу.*

Аннан соң, кулланылыш өлкәсе буенча архаизмнарны түбәндәге төркемнәргә бүлдек.

**1.Алмашлыклар:** *бәгъзеләре, берәүсе, мәнем, ошбу, сәне.*

**2.Биләмә - территорияне аңлаткан сүзләр:** *җәйләү, кала, көнтуктар, мәмләкәт, мәркәз, олыс, отраф.*

**3.Географик атамалар:** *болак, җиһан, Итил, Көбән.*

**4.Дин өлкәсенә караган сүзләр:** *диндар, исламиянең, мәдрәсә, мелла, мөртәт, нәсара дине, язык.*

**5.Җәнлекләр:** *җылан.*

**6.Корылма, төзелмәләр:** *дивар, зиндан, кәрвансарай, кирмән кала, пайтәхет.*

**7.Көндәлек тормыш сүзләре:** *атын, бәһа, бинахак, былчырак, гасалы сүзләр, гафил, гәүһәр, җәһаләт, җәһәт, җәтмәсе, зәгъфран, кәңәш, кәрәк, назарәт, нәмәгълүм, нәүбәт, нидәр, сабак, сөаль, торык, хилаф, чаптар, шөлдер.*

**8.Медицина өлкәсенә караган сүзләр:** *тотанак.*

**9.Рәсми – сәяси өлкәгә караган сүзләр:** *гозернамә, мәҗлес, мәсләк, мөһер, мөһерен сукты, нотыгын, олпат, фиркә, шартнамә, ярлык, ясак.*

**10.Социаль катлам вәкилләре:** *аксөяк.*

**11.Тойгы белдерүче сүзләр:** *гаҗәбә , гасага сабышкан, ихласи, койты, низам-интизам, хирыс, хиссияти.*

**12.Туганлык, үзара мөнәсәбәтләрне чагылдыручы сүзләр:** *абасына, аркадаш, бәк, кызыңызны, олуг, углан, халаяк.*

**13.Хәрби өлкәгә караган сүзләр:** *әләмнәр, гаскәри, җиһангир, кын, мәргән, оран, орышу, яугир.*

**14.Һөнәрчелек сүзләре:** *бавырчы, илтабарлар, кәтиб, малтабар, мөгаллимә, тылмач.*

**15.Эш – хәрәкәтне белдерүче сүзләр:** *баш ийде, белдереңез, гөман итү, егълыйсың, җылап, ийде, кылмак, мичәүгә җиккән, утырыңыз, химая итү.*

Эзләнә торгач, кызык тарихлыларына тап булдык. Менә *ат* сүзе элекке вакытта *исем* мәгънәсендә дә йөргән, ә хәзер *атказанган, атаклы* сүзләрендә сакланып калган, кайбер вакытта танышканда "*Атың* ничек ?" дип сорыйлар. Кызганычка каршы, аның мәгънәсен күп кеше хәзер аңламый. *Фиркә* сүзен дә аерып күрсәтергә кирәк. Ул искергән сүзләр арасыннан кулланылышка кире кайтып, инде кире "искерергә" дә өлгергән. *Орышу* сүзе кайчандыр сугышуны да аңлаткан, ләкин, ул мәгънәсен югалтып, кемне дә булса әрләүне генә аңлата башлаган. Әмма без әкиятләр укыган вакытта орышу сүзен элекке мәгънәсендә бик еш очратабыз. *Углан* сүзе фонетик яктан да, семантик яктан да үзгәреш кичергән. Элек "сугышчы" мәгънәсен дә аңлаткан булса, хәзер "ул" (олан) мәгънәсендә кулланыла. Тагын *мәдрәсә, мөгаллимә* сүзләре бар. Алар урынына *мәктәп*, *укытучы* сүзләре кулланабыз. *Шура* сүзе дә кулланылыштан төшеп калган иде. Хәзер бу сүз яңадан әйләнеп кайтты. "Аксакаллар шурасы" безнең Түбән Кама шәһәрендә дә эшли.

Тел – халыкның акылын, гореф-гадәтен , дөньяга карашын, фәлсәфәсен , тарихын, кыскасы, бөтен күңел байлыгын меңеллар буена үзенә сеңдерә килеп безнең заманнарга җиткергән чиксез кадерле хәзинә. Гасырлар караңгысыннан бәреп чыккан бу гаҗәеп чишмәнең гайрәтен сүндермәү, бәлки яңа заманда телгә яңа яшәү куәте өстәү, аны халыкка тагын да баетыбрак кайтару безнең бурыч дигән фикергә килдек без фәнни хезмәтебез ахырында. Нәтиҗәне түбәндәге тармакларга бүлеп карарга мөмкин:

1. Тел – диңгез. Тиз генә аның тирәнлегенә төшенеп, киңлекләрен иңләп бетереп булмый. Шуңа күрә сүзләрне киләчәктә дә тикшерергә, өйрәнергә кирәк.

2.Искергән сүзләрне язучылар куллана.Алар үткән чор колоритын тарихи сүзләрдән башка сурәтли алмыйлар. Ул вакытта мондый сүзләр төп бизәкләү чарасы буларак кулланыла.

3.Тормышның барлык өлкәләренә дә караган сүзләр бар. Без үзебезнең хезмәтебездә кайбер өлкәләрне аерып күрсәттек.

4.Искергән сүзләр арасында кулланылышка кире кайтканнары яки кайтып, инде кире искергән сүзләр составына кергәннәре бар. Мондыйлардан *мөгаллимә, мәдрәсә, җиһан, фиркә, шура* кебек сүзләрне күрсәтергә мөмкин.

5.Кайбер искергән сүзләр мәгънә киңлекләрен киметкәннәр,кайберләре тотрыклы сүзтезмәләрдә генә сакланып калганнар. Мәсәлән, *ат, гасага сабышкан, аркадаш, орышу* сүзләре.

6.Кайбер сүзләрне кулланылышка кире кайтару мөмкинлеге зур. Алар җиңел истә калалар һәм яңгырашлары да матур. Болар, мәсәлән, *химая итү, хәерхаһ, шартнамә, җәһәт*. Алар миңа аеруча ошый.

7.Тарихи сүзләрне күбесенчә фән белгечләре тарихи хезмәтләр язу өчен кулланалар. Чөнки алардан башка үткәнне өйрәнеп булмый. Мәсәлән, тарих дәреслекләрендә без *патша, кенәз, ясак, ярлык* һ.б. сүзләрне бик еш очратабыз.

8.Чит телдән кергән сүзләрне куллануны киметергә кирәк, чөнки без татар кешеләре, безнең үз сүзләребез бар. Шулай ук һәр культуралы кешенең сөйләме саф булырга тиешлекне дә онытмыйк.

9.Әдәби телне өзлексез баетырга, аны һәрвакыт игътибар үзәгендә тотарга пассив сүзләрне активлаштырырга кирәк. Бу үзебезнең милләтебез өчен бик файдалы.

Хезмәтебез ахырында шуларны әйтәсебез килә: өйрәнсәң, эзләнсәң, лексикология бик кызыклы фән. Сүзләрне тикшерү әле файдалы да.Чөнки кешенең үз лексикасы да байый, телне дә баюга китерә. Шуңа күрә, сүзебезне йомгаклап, Р.Фәйзуллинның сүзләрен кабатлыйсы килә:

“Иренмә, син, туган, туган телнең
Асыл байлыкларын ачарга.
Без ваемсыз булсак, чит-ят сүзләр
Хәзинәңне әзер басарга!”

**Файдаланылган әдәбият**

1. Әхәтов Г.Х. Татар теленең лексикасы (Педагогия институтлары һәм колледжлары студентлары өчен кулланма)./ Г.Х. Әхәтов. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1995. – 93 б.

2. Әхмәтьянов Р.Г. Татар теленең кыскача тарихи – этимологик сүзлеге. – Казан: Тат.кит.нәшр., 2001. – 272 б.

3. Гәрәева Н.Г. Тел – белемнең ачкычы. Татар теле һәм сөйләм үстерү дәресләре: Урта махсус уку йортлары өчен д-лек/ Н.Г.Гәрәева, Н.В.Максимов, Ә.Ә.Зыятдинова. – Казан: Мәгариф, 2005. – 143 б.

4. Ожегов С.И. һәм Шведова И.Ю. Рус теленең аңлатмалы сүзлеге : 72500 сүз һәм 7500 фразеологик әйтелмә./ Россия фәннәр академиясе : Рус теле институты, Россия мәдәният фонды. – 955 б.

5. Сафиуллина Ф.С. Хәзерге татар әдәби теле: Лексикология, фразеология, фонетика, графика һәм орфография, орфоэпия, сүз ясалышы, морфология, синтаксис: Педагогия училищелары, колледжлар, гимназияләр өчен дәреслек. / Ф.С. Сафиуллина. – Казан: Мәгариф, 1994 – 21-141 б.

6. Сафиуллина Ф.С. Татар теленең лексикасы IV – VIII класслар өчен күнегүләр җыентыгы./ Ф.С. Сафиуллина.- Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1975.

7. Сафиуллина Ф.С. Хәзерге татар әдәби теле, Лексикология. Югары уку йортлары студентлары өчен./ Ф.С. Сафиуллина.- Казан: Хәтер. 1999. – 286 б.

8. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Өч томда, I том. – Казан: Татарстан китап нәшрияты. 1977. – 476 б.

9. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Өч томда, II том. –Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1979. – 726 б.

10. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Өч томда, III том. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1981. – 832 б.

11. Хатыйпов Ф.М. Әдәбият белеме сүзлеге / Ф.М.Хатыйпов. – Казан: Татар кит.нәшр., 1990. – 238 б.

12. Хатыйпов Ф.М. Әдәбият теориясе: Югары уку йортлары, педагогия училищелары, колледж студентлары өчен кулланма./ Ф.М. Хатыйпов.- Казан: Мәгариф. 2000. – 351 б.

13. Хәбибуллин М.М. Сөембикә Ханбикә һәм Иван Грозный: Тарихи роман./ М.М.Хәбибуллин. – Казан: Татар. Кит. Нәшр., 1996. – 512 б.

14. Шатлыгым. Кайгым минем... : Әдипләребез тел культурасы турында./ төзүче А.М.Вәлиева. – Казан: Мәгариф, 2003. – 175 б.

**Кушымта 1**

**Сүзлекчә**

**A**

Аба – ыру-кабиләнең нәсел башы.

Абасына – абыйсына.

Азамат – гаскәри хезмәткә иң беренче барырга тиешле таза ир кеше. ТТАС I т. 25 б.[7]

Акбикә - затлы, югары нәселдән булган хатын-кыз.

Аксөяк – затлы, югары нәселдән булган кеше, аристократ. ТТАС I т. 36 б.

Алатлар – бай катлам, рус сәясәте яклылар.

Алтын бәлеш – акча бирәмлеге.

Аркадаш – иптәш, дус. ТТАС I т. 68 б.

**Ә**

Әләмнәр – байраклар. ТТАС III т. 682 б.

Әтраф – тирә-як. ТТАС III т. 687 б.

**Б**

Бавырчы – аш пешерүче.

Бакалай – төзелмә.

Бакалдак – көймәләр туктар өчен ясалган урын.

Барымта – күчмә төрки кабиләләрдә бер-берсенең көтүләрен әйдәп кайту максаты белән ясалган талау походы. ТТАС I т. 127 б.

Баскак – Алтын Урда ханының биләмә өлкәләрдәге урынбасары, ханга ясак җыеп тапшыручы отряд башлыгы. ТТАС I т. 128 б.

Баш ийде – баш иде.

Бәгъзеләре – кайберләре.

Бәк – ирләр исеменнән соң әйтелгәндә, “әфәнде” мәгънәсен аңлаткан. ТТАС I т. 206 б.

Бәһа – бәя.

Белдереңез – белдерегез.

Берәүсе – кемдер берәү.

Бинахак – хаксызга, гаепсезгә. ТТАС I т. 165 б.

Болак – инеш. ТТАС I т. 176 б.

Бояр – Мәскәү Русенда бүләк итеп бирелә торган югары дәрәҗә; шул титулга ия кеше. ТТАС I т. 183 б.

Буза – эчемлек.

Бусагабаш – хезмәтче-йомышчы.

[7] К. : Искәрмәләр 31 б.

Бусурман – чит милләт кешесе.

Былчырак – пычрак.

**В**

Вәзир – патша яки ханның дәүләт эшләрен башкаручы иң зур дәрәҗәле вәкиле. ТТАС I т. 246 б.

**Г**

Гаҗәбә – гаҗәп.

Галиҗәнап – түрәләрне, зур дәрәҗә кешеләрен атау һәм шуларга мөрәҗәгать итү сүзе. ТТАС I т. 256 б.

Гасага сабышкан – кайгыга төшкән.

Гасалы сүзләр – кайгылы сүзләр.

Гаскәрбаш – гаскәр белән идарә итүче.

Гаскәри – гаскәргә мөнәсәбәтле.

Гафил – ваемсыз, саксыз.

Гәйшә – изге, әүлия.

Гәүһәр – җәүһәр. ТТАС I т. 283 б.

Гелән – гел.

Гозернамә - үтенеч.

Гошер – керемнең, уңышның уннан бер өлеше: мулла яки мәчет файдасына җыйнала торган җыем. ТТАС I т. 270 б.

Гөман итү – ... дип уйлау, фараз итү, күз алдына китерү. ТТАС I т. 285

**Д**

Дәвалбаз – музыка уен коралы,бәреп уйналына.

Дивар – стена.

Диндар – динле.

**Е**

Егълыйсың – елыйсың.

**Ж**

Җария – гаремнарда яшь кол хатын ТТАС III т. 753 б.

Җәйләү – җәйге тору урыны.

Җәтмәсе – ятьмәсе.

Җәһаләт – наданлык, аң-белемсезлек. ТТАС III т. 813 б.

Җәһәт – кешелеклелек, кеше сөючәнлек. ТТАС III т. 813 б.

Җиһан – дөнья. ТТАС III т. 794 б.

Җиһангир – дөньяны яулап алып үзенә буйсындыручы. ТТАС III т. 794 б.

Җылан – елан.

Җылап – елап.

**З**

Зәгъфран – үсемлектән ясалган буяу. ТТАС I т. 352 б.

Зиндан – төрмә.

**И**

Ийде – иде.

Илбашы – ил белән идарә итүче.

Илтабарлар – сатучылар.

Исламиянең – ислам динен тотучы кешеләрнең, җыелма исем.

Итил – Идел.

**К**

Казнабаш – казнага җаваплы кеше.

Калкан – борынгы гаскәриләрнең кылыч, сөңге кебек салкын кораллардан саклану өчен тактадан яки металлдан махсус эшләнгән кул сугышы коралы.

ТТАС II т. 31 б.

Каравыш – хан кызының хезмәтче кызы. ТТАС II т. 51 б.

Каравылбаш – сакчы.

Карачы – ханлык чорында дәүләт аппаратындагы югары чин. ТТАС II т. 57 б.

Катмарлана – катлаулана.

Кәтиб – язу эшләрен башкаручы, язучы – тарихчы.

Кәңәш – киңәш.

Кенәгинә – кенәзнең хатыны. РТАС 285 б.[8]

Кенәз – гаскәрне әйдәп баручы һәм өлкә белән идарә итүче. РТАС 285 б.

Кәрәк – кирәк.

Кәрвансарай – кәрван юлларында кәрван кереп куна торган йорт.

Кирмән кала – крепость.

Койды – салды.

Король – феодаль һәм буржуаз дәүләтләрендә монарх титулы. ТТАС II т. 158 б.

Койты – начар, яман.

Көбән – сулык исеме.

Көмеш бәлеш – акча берәмлеге.

Көмеш дирһәм – көмеш акча берәмлеге.

---

[8] К. : Искәрмәләр 31 б.

Көнтуктар – бүгенгә туктап ял итәсе урын, җир.

Күчәрбаш – ат йөртүче, кучер.

Кызыңызны – кызыгызны.

Кылмак – кылырга.

Кын – кылыч, хәнҗәр кебек кораллар өчен савыт, футляр. ТТАС II т. 223 б.

**М**

Магуллар – халык атамасы.

Малтабар – сату-алу белән эш итүче.

Мәдрәсә - мөселманнарда: урта һәм югары класслары булган дини уку йорты. ТТАС II т. 416 б.

Мәҗлес – диван.

Мәмләкәт – ил, дәүләт.

Мәнем – минем.

Мәркәз – идарә үзәге, башкала. ТТАС II т. 420 б.

Мәсләк – принцип, максат, тоткан юл. ТТАС II т. 421 б.

Мелла – мулла. ТТАС II т. 379 б.

Мичәүгә җиккән – кырыйга җиккән.

Морза – кайбер көнчыгыш халыкларында өстен катлау вәкиленең титулы. ТТАС II т. 405 б.

Мөгаллимә - укытучы.

Мөһер – печать.

Мөһерен сукты – печать сукты.

Мөртәт – үз диненә хыянәт иткән, башка дингә күчкән кеше. ТТАС II т. 428 б.

Мыскал – үлчәү системасына кергәнгә кадәр якынча 4,26 граммга тигез булган авырлык. ТТАС II т. 414 б.

**Н**

Назарәт – назар-караш, игътибар. ТТАС II Т. 432 б.

Нәмәгълүм – мәгълүмсез, мәгълүм түгел.

Нәсара дине – сурәткә табынучылар дине.

Нәүбәт – чират.

Нидәр – нидән.

Низам-интизам – тәртип.

**О**

Олаубаш – олау-йөкләргә җаваплы кеше, I олауда бара.

Олпат – җитди әңгәмә.

Олуг – олы.

Олыс – территориаль бүленеш.

Оран – яуга чакыру авазы. ТТАС II т. 474 б.

Орышу – сугышу.

Отраф – як.

Ошбу – бу.

**Ө**

Өстерү – кемгә дә булса каршы котырту. ТТАС III т. 710 б.

**П**

Падишаһ – патша.

Пайтәхет – башкала. ТТАС II т. 494 б.

Пакизә - чиста. ТТАС II т. 495 б.

Патша – монарх.

**С**

Сабак – берәр фәннән белем бирүгә багышланган уку вакыты. ТТАС II т. 609 б.

Сәне – сине.

Соңа – моңа.

Сорнай - өреп уйнала торган борынгы уен коралы. ТТАС II т. 661 б.

Сөаль – сорау. ТТАС II т. 713 б.

**Т**

Тамызык – аз гына.

Тархан – ханның киңәшчесе. ТТАС III т. 49 б.

Тәхет – Патша утырыр өчен куелган урын, трон.

Торык – аяк.

Тотанак - өянәк, эпилепсия. ТТАС III т. 124 б.

Тупсабаш – сакчы.

Тылмач – тәрҗемәче.. ТТАС III т. 187 б

**У**

Углан – олан.

Ук-садак – сугыш коралы.

Уктабан – җепшек карда ялтырап калган чана табаны эзе.

Утырма – хатын-кызларның дусларында озак кунак булу йоласы.ТТАС II т.323 б.

Утырыңыз – утырыгыз.

**Ү**

Үзбаш – аерым, мөстәкыйль рәвештә. ТТАС III т. 722 б.

**Ф**

Фиргавен – Борынгы Мисыр патшасы. ТТАС III т. 346 б.

Фиркә - төркем. ТТАС III т. 346 б.

**Х**

Халаяк – гади халык.

Хан – урта гасырларда феодаль идарәчегә бирелә торган дәрәҗә.

Ханбикә - хатын-кыз хан яки хан хатыны. ТТАС III т. 362 б.

Ханзадә - хан улы. ТТАС III т. 362 б.

Хансарай – дворец.

Хәерхаһ – фатыйха, ризалык.

Хилаф – ярамый торган, кире. ТТАС III т. 367 б.

Химая итү – саклау, яклау. ТТАС III т. 367 б.

Хирыс – нәфислек.

Хиссияти – хис.

**Ч**

Чаптар – ялы һәм койрыгы чал булган ат төсе турында. ТТАС III т. 309 б.

**Ш**

Шартнамә - килешү кәгазе. ТТАС III т. 494 б.

Шәкел – форма. ТТАС III т. 533б.

Шөлдер – кечкенә кыңгырау. ТТАС III т. 540 б.

**Ы**

Ыстан – биләмә.

**Я**

Яваннар – халык атамасы

Язык – гөнаһ. ТТАС III т. 624 б.

Ярлык – язма указ, грамота. ТТАС III т. 647 б.

Ясавыл – сугышчылар башлыгы.

Ясак – налог.

Яугир – сугышчы.

**Искәрмәләр**


1. Ожегов С.И. һәм Шведова И.Ю. Рус теленең аңлатмалы сүзлеге : 72500 сүз һәм 7500 фразеологик әйтелмә. / Россия фәннәр академиясе : Рус теле институты, Россия мәдәният фонды.
2. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Өч томда, I том. – Казан: Татарстан китап нәшрияты. 1977. – 476 б.

3. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Өч томда, II том. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1979. – 726 б.

4. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Өч томда, III том. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1981. – 832 б.

*Ганиева Нәзилә, 9 нче сыйныф, Татарстан Республикасы Нурлат районы Курманай төп гомуми белем бирү мәктәбе*
*Җитәкче: Гыймалетдинова Нурзия Минәхмәт кызы, татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

## «Муса Җәлилнең гражданлык батырлыгы»

### Мин ни өчен бу теманы сайладым?

Мин, Ганиева Нәзилә Рәфис кызы, Кизләү төп белем мәктәбенең 9 нчы сыйныфында укыйм. Туган авылымны, мәктәбемне бик яратам. Мәктәптә эшләп килгән "Туган якны өйрәнү " музеенда еш булам. Андагы материаллар белән танышып, авылым тарихын, халкыбызның үткәне, бүгенгесе турында өйрәнәм, материаллар туплыйм. Татар халкы - үзенең улы һәм кызында сабырлык, киң күңеллелек, кешеләргә бетмәс мәхәббәт, киләчәккә өмет тәрбияли белүче гаҗәеп зур мираска ия халык ул. Аның данын яклаган һәм күп гасырлык әдәбиятның маяклары булган Кол Гали, Тукай, Туфан, Җәлилләре генә дә тулаем халкыбызның унай кешелек сыйфатларын күрсәтеп торалар. Халкыбызның батыр уллары арасында аерым игътибарга лаек кеше бар, аның исеме каһарманлыкның, ватанпәрвәрлек, ныклыкның, тиңдәшсез шигъри набаты, үз халкына бөек батырлыкка мәңгелек чакыру булып яңгырый. Ул- патриот шагыйрь Муса Җәлил. **"Герой шагыйрь Муса Җәлилнең гражданлык батырлыгы"** темасына фәнни хезмәтебезне башкаруга да җәлилчеләрне искә алуның 77 еллыгы, аңа карата горурлану, ярату хисе этәрде. Сайланган темам бик актуаль, тиздән Бөек Җиңүнең 78 еллыгы,МусаҖәлилнең туган көне. Миндә шагыйрьнең тормыш юлын һәм иҗатын, батырлыгын тулырак өйрәнү теләге туды, шул максаттан эзләнү эшләре алып бардык.

**Эзләнү эшенең предметы:**

Муса Җәлилнең тормыш юлын, батырлыгын чагылдырган китаплар, язма истәлекләр.

Шагыйрьнең "Моабит дәфтәре" циклы.

Шагыйрь турында истәлекләр.

**Фәнни – эзләнү эшемнең максаты:** Патриот шагыйрьнең иҗади мирасын өйрәнү.Герой шагыйрь М. Җәлилнең "Моабит дәфтәрләре" иҗатының югары ноктасы булуына төшендерү.

Шагыйрьнең туган илен, халкын яратучы патриот (ватанпәрвәр ) булуын ачу.

Туган илне чиксез яратуын иҗаты, батылыгы белән раславын аңлату. Бу максатны тормышка ашыру өчен, үз алдыма түбәндәге бурычларны куйдым:

**Бурычлар:**

М.Җәлилнең милләттәшебез, татар халкының исемен дөньга таныткан шагыйрь икәнлеген аңлату.

М.Җәлилнең тормыш юлы, шигърияте һәм аның дөнья әдәбиятында, матбугатында тоткан урынын билгеләү.

Татар халкының бай рухи культурасы тарихында герой - шагыйрьнең тормыш юлын, гражданлык батырлыгын өйрәнү.

Шагыйрьнең исемен мәңгеләштергән урыннарны барлау.

**Эзләнү эшмнең гипотезасы:**

М.Җәлил - татар халкының, алай гына да түгел, илебез халыкларының да йөз аклыгы икәнлеген раслау .Үзен аямыйча, кулындагы коралы белән дә, каләме белән дә дошманга каршы көрәшкән шагыйрьнең, антына тугрылыклы ватанпәрвәр икәнлеген күрсәтү.

М.Җәлилнең милләттәшебез булуы белән чиксез горурланабыз. Ул-татар халкының исемен дөньга таныткан шагыйрь. Шуңа күрә дә бу хезмәтемдә М.Җәлилнең тормыш юлы, шигърияте һәм аның дөнья әдәбиятында, матбугатында тоткан урынын билгеләүне максат итеп куйдым. Бу фәнни эшебезне башкару барышыда Муса Җәлилнең сатлык җан түгел, ә үлеме белән үлемсезлек яулаган, җыры белән дошманны җиңгән бөек каһарман булуын ачыклау максатына ирештек. Иң элек Муса Җәлилнең балачагы, туганнары, беренче иҗат чаткылары турында материаллар тупладым. Монда архив материаллары арасында сакланучы шагыйрьнең шәхси тормышына бәйле фотосурәтләр, документ күчермәләре белән шагыйрьнең тормыш юлы һәм иҗаты турында күренекле әдибебез Рафаэль Мостафин фикерләре белән танышырга була. Үзе дә Ырынбур өлкәсеннән булган бу язучы Мусаның укытучысы Габдулла абыйның мактап сөйләвен хәтерли.

**Муса Җәлилнең тормыш юлы, иҗаты (1906—1944)**

Татар халкының бөек улы, каһарман шагыйрь Муса Җәлил 1906 елның 15 февралендә хәзерге Оренбург өлкәсенең Мостафа авылында туа. 1973 елда Мостафа абзый, гаиләсен алып, Оренбургка күчә. Монда Җәлил Тукай, Дәрдемән, Рәмиев иҗатлары белән якыннан таныша. Шулар тәэсирендә үзе дә шигырьләр яза башлый. Аның беренче шигырьләр "“Кечкенә Җәлил" имзасы белән басыла. 1922 елда Муса Казанга килә. Башта "Татарстан" газетасы редакциясендә эшли, ә 1923 елда татар рабфагында укый башлый. Шул елларда ул "Бибкәй кыз","Каз канаты" исемле пьесаларын яза. Бу пьесалар Казан, Уфа шәһәрләрендә куела, ә 1925 елда "Барабыз" исемле беренче шигырь җыентыгы (1928) Җәлилне шул заманның алдынгы шагыйрьләрерәтенә бастыра.

1927 елдан ул Мәскәүдә яши башлый. 1932 елга кадәр башта Кечкенә иптәшләр, соңыннан "Октябрь баласы" исемле балалар журналларының җаваплы редакторы була. 1927-1931 елларда Мәскәү университетының әдәбият бүлегендә укый. 1935 елда Муса Җәлил Мәскәүдә Татар опера студиясендә әдәби бүлек мөдире булып эшли башлый. Студия Татар опера театры өчен җырчылар, композиторлар әзерли. Студияне тәмамлаучылар Казанга кайткач, Татар опера һәм балет театры ачыла. Муса Җәлил дә, шул театрның әдәби бүлек мөдире булып, Казанга кайта. 1939 елда Мусаны Татарстан Язучылар берлеге җитәкчесе итеп сайлыйлар. Мәскәүдә яшәгән елларда шагыйрь "Хат ташучы" поэмасын, "Алтынчәч", "Илдар" либреттоларын яза. Композитор Нәҗип Җиһанов бу либреттоларга опералар иҗат итә.

Бөек Ватан сугышы башлангач, Муса Җәлил, беренчеләрдән булып, сугышка китә. Сугышта да ул каләмен кулыннан төшерми. 1943 елда аның "Тупчы анты" дигән җыентыгы басылып чыга. 1942 ел. Июнь. Шагыйрь Волхов фронтында. Каты сугышлар вакытында аларның часте чолганышта кала, М.Җәлил яралы хәлендә дошман кулына эләгә. Фашистларның үлем лагере. Сорау алу һәм җәзалалар. Шомлы үлем шәүләсе. Ләкин Җәлилнең рухы сынмый, ул көрәшне туктамый. Шигырьләр яза. Иптәшләренең рухын күтәрә, аларны көрәшкә өнди. Гитлерчылар әсәрләрне туган илләренә каршы сугышларга димлиләр һәм ирекле легионнар төзү белән шөгыльләнәләр. Ләкин аларның өметләре акланмый. Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләре, легионерлар арасында аңлату эшләре алып барып, немецларның коткасын фаш итә. Муса Җәлил һәм аның иптәшләре гитлерчыларга каршы коралլы восстание әзерлиләр. Ләкин араларына үтеп кергән бер хыянәтче аларның бу планнарын фашистларга ача. Мусаны һәм аның көрәштәшләрен төрмәгә ябалар. Тоткынлыкта язган шигырьләрен Җәлил 2 блокнотка туплый. Бер блокнотын Берлин төрмәсеннән Габбас Шәрипов исемле бер тоткын, ә икенчесен моабит төрмәсендә бергә утырган бельгияле Андре Тиммерманс алып чыга. 1944 елның февралендә фашистларның хәрби суды Җәлилне Һәм аның көрәштәшләрен үлем җәзасына хөкем итә. Шул елның 25 августында Плетцензее төрмәсендә унбер җәлилченең гомере өзелә. Муса Җәлилнең исемен халкыбыз мәңгеләштерде. Казандагы Татар дәүләт опера һәм балет театры Муса Җәлил исемен йөртә. Шагыйрьгә Казанда Һәйкәл куелды. "Җәлил" операсы театр сәхнәсеннән төшми. Мусага багышлап, язучылар, шагыйрьләр, драмматурглар—романнар, поэмалар, сәхнә әсәрләре; композхиторлар—җырлар, симфонияләр;рәссамнәр картиналар иҗат итәрләр.

Муса Җәлилнең тиңдәшсез батырлыгы югары бәяләнә. 1956 елның 2 нче февралендә аңа **Советлар Союзы Герое исеме** бирелә. 1957 елда "Моабит дәфтәре" **Ленин премиясе** белән бүләкләнә.

**“Моабит дәфтәре” – Җәлил иҗатының югары ноктасы**

Бу исемне телгә алуга, күз алдына ниндидер гадәттән тыш кеше килгәндәй була. Ул – ялкынлы шигырьләр язган шагыйрь дә, илнең азатлыгы өчен курку белмәс көрәшче дә, үлемне ирләрчә батыр каршылаган каһарман да. Муса Җәлил (Муса Мостафа улы Җәлилов) 1906 елда Ырынбур өлкәсе Мостафа авылында туа. Ул кече яшьтән үк зирәк һәм хыялга бай бала була. Күп укый, һәр нәрсәне белергә тырыша. Оста итеп мандолинада уйнарга өйрәнә. Рәсем ясарга ярата.

Муса Оренбургта «Хөсәения» мәдрәсәсендә укый. Җәйне туган авылында үткәрә. Табигать матурлыгы аның күңелен узенә тарта, соңыннан ул бу күзәтүләрен рәсем итеп төшерә. Муса 10-11 яшьләрендә шигырьләр дә язып карый. Ләкин алар югала. Матбугатта иң беренче булып унөч яшендә язылган «Бәхет» шигыре (1919) басыла. 1922 елда ул Казанга килә һәм 1923-1925 елларда Казан педагогия институтының рабфагында укый. 1925 елда Җәлилнең «Барабыз» исемле беренче китабы чыга. «Иптәшкә» (1929) дигән шигырь җыентыгы аның шагыйрь булып җитлегеп килүен тагын бер тапкыр раслый. Ул 1931 елда Мәскәү университетының әдәбият бүлеген тәмамлый. 1939 елда Җәлилне Татарстан Язучылар берлегенең җитәкчесе итеп сайлыйлар. Сугышка кадәрге елларда шагыйрь бик күп шигырьләр, җырлар, «Хат ташучы» поэмасын, «Алтынчәч», «Илдар» исемле опера либреттоларын яза.

Бөек Ватан сугышы башлану белән, ул үзен фронтка җибәрүләрен сорый. Аның үтенече канәгатьләндерелә. Ләкин 1942 нче елның җәендә Волхов фронтында, дошман чолганышында калып, авыр яраланган хәлдә, фашистлар кулына әсирлеккә эләгә. Әнә шулай аның лагерь тормышы башлана. Шагыйрь әсирлектә дә көрәшне туктатмый. Яшерен оешмага керә, аның җитәкчеләреннән берсе була, бик күп әсирләр белән лагерьдан качу һәм партизаннарга барып кушылу ниятен тормышка ашырырга уйлый. Бер хыянәтче аларның серләрен фашистларга хәбәр итә. Шуннан соң Җәлилне һәм аның иптәшләрен Берлиндагы Моабит төрмәсенә ябалар. Шагыйрь анда да туган иленә тугрылыклы булып кала. Искиткеч рухи ныклык күрсәтә. Үлем җәзасы көтеп торганда да, туган илгә, халыкка тирән мәхәббәт белән сугарылган, фашистларга көчле нәфрәтен белдергән шигырьләр язып, аларны үзе ясаган кечкенә дәфтәрләргә теркәп бара. Җәлилнең әсирлектә язган шигырьләре бөтен дөньяга билгеле. Татарстанга аның ике дәфтәре кайтты. Аларны бөтен дөньяда «Моабит дәфтәрләре» дигән исем белән беләләр. Беренче дәфтәренә Муса Җәлилнең алтмыш шигыре теркәлгән һәм дәфтәрнең соңгы битенә васыять язылган: *«Моны язды татарның билгеле шагыйре М. Җәлил. 1942 елны сугышка килде һәм әсир төште. Әсирлектә күп газаплар чигеп, сәяси яшерен оешмага катнашуда гаепләнеп кулга алынды, төрмәгә ябылды. Бәлкем, аны үлем җәзасына хөкем*

*итәрләр. Ул үләр. Ә аның әсирлектә һәм тоткынлыкта язган 115 шигыре бар. Ул шулар өчен кайгыра. Шуның өчен 115 енең 60 ын гына булса да күчереп калдырырга тырышты. Әгәр бу китап кулыңа төшсә, акка күчер, сакла һәм сугыштан соң, Казанга хәбәр итеп, үлгән шагыйрьнең шигырьләре итеп дөньяга чыгар. Минем васыятем шул. 1943, декабрь».* *

* Муса Җәлил.1943 нче ел, декабрь

Бу дәфтәрне 1944 елның февралендә Тегель төрмәсеннән Габбас Шарипов исемле әсир алып чыга. Аннан ул аны Нигъмәт Терегулов дигән кешегә тапшыра. 1946 елны Н. Терегулов дәфтәрне Татарстан Язучылар берлегенә китереп бирә. Икенче дәфтәрне Муса Җәлил саклар өчен Бельгия партизаны Андре Тиммерманска биргән. Әлеге намуслы кеше 1947 нче елда аларны безнең илебезгә җибәрә. Җәлилнең өченче дәфтәре дә булган дигән фикер бар. Ләкин әле ул табылмады, аны эзләү дәвам итә. 1944 елның 25 августында фашистлар М. Җәлилне һәм аның көрәштәшләрен җәзалыйлар. Җәлилчеләр соңгы сәгатьләрендә дөнья белән кулларына мөселманнарның изге китабы – Коръән тотып хушлашалар. Шагыйрьне үтерсәләр дә, фашистлар аның ялкынлы җырларын, көчле рухын юк итә алмадылар. Муса Җәлил илгә җыр булып кайтты.

Җырлап үттем данлы көрәш кырын,
Җырлап килдем тормыш языма.
Соңгы җырым палач балтасына
Башны тоткан килеш языла. A

Татарстанда Җәлил исемендәге бистә бар. Муса Җәлилгә багышлап романнар, поэмалар, опера, җырлар, сынлы сәнгать әсәрләре иҗат ителде.

Күпме кешенең чәчәктәй гомерен өзде ул. Күпме гөнаһсыз кешенең каны дәрья урынына акты. Әле хәзер дә, ул еллардан соң 60 ел үтсә дә, фашизмга ләгънәт укыйлар. Ватан өчен барган изге көрәштә татар халкының күпме бөек улы башын салды. Күпме әсәрләр, шигырьләр, күңелләрдә туып та ак кәгазь битенә төшмичә, яралгы хәлендә югалды, гаип булды. Муса Җәлилнең дә ни бары 94 шигыре генә бик бормалы юллар аша туган илгә кайтып җитә алды. Габбас Шәрипов 1944 нче елда Тегель лагерена күчерелә, дәфтәрне үзе белән алып чыга. Монда Әмир Үтәшев һәм Нигъмәт Терегулов белән таныша. Дәфтәр Н.Терелугов кулына күчә. Ул исән кайта һәм 1946 нчы елда Казанга килеп Р.Алишка тапшыра. Әкияттәге “Серле йомгак “ 1946 нчы елда сүтелә башлый. Икенче җыентык 1947 нче елда Бельгия кешесе, А.Темерманс тарафыннан Совет илчелегенә тапшырыла. Шигырьләр 1953 нче елның 25 апрелендә Мәскәүдә чыгучы “Литературная газета” битләрендә басыла. “Моабит дәфтәре” циклы тематикасы бик бай һәм жанр ягыннан төрлелеге белән аерылып тора.

- Туган илне сагыну һәм зурлау;
- Ирекле булуның зур бәхет булуы;
- Фашизмның кансызлыгын, ерткычлылыгын ачу.

“Сатлык җан” дигән тамга бетерелә.

“*Муса Җәлилнең тормышы безнең әдәбият тарихыннан аерылгысыз...*
*Минем өчен Муса Җәлил сынаулар һәм үлем каршында гражданлык һәм язучылык батырлыгы күрсәткән кешеләрнең бер үрнәге булды һәм булып кала.Ул зур шагыйрь генә түгел, бәлки көчле рухлы батыр да, безнең аңа карата рәхмәт хисе йөргән күңелебезгә нәкъ шулай булып урнашкан зур кеше дә. ...*”*

“Моабит дәфтәре” – Җәлил иҗатының югары ноктасы.

* РафаэльМостафин”Муса Җәлил турында истәлекләр” Казан Тат. Кит. Нәшр. Константин Симонов”Бер камерада”

**Яшәү хозурлыгы хөрлектә. Муса Җәлилнең гражланлык батырлыгы.** Муса Җәлил – иң беренче чиратта үзенен гаиләсен, баласын, илен яратучы. Муса Җәлил - дөньяның горурлыгы, күп милләтле әдәбиятның, бөтен прогрессив кешелек культурасының мактанычы. Аның “Моабит дәфтәре” циклы шигырьләрендә батырлык рухы һәм ихтыяр көче ташып тора. Алар Ватанга, халыкка тирән мәхәббәт, хак эшнең тантана итәчәгенә ышаныч белән сугарылганнар. Тирән мәгънәле, искиткеч нәфис, ялкынлы бу шигырьләрне укыганда, Муса Җәлилнең гражданлык батырлыгына, ватанпәрвәрлеккә, рухи сафлыгына, намуслылыгына сокланмый мөмкин түгел! Ул миллионнар өчен яшәү үрнәге булып әверелде. Муса Җәлилнең батырлыгы тирәнтен интернациональ рухта булганга күрә дә, азербайҗанлылар аны чорыбыз Фәрһады, немецлар якын дустыбыз, чехлар татар Фучигы дип атыйлар. Безнең язучыларырыбыз Муса образын чагылдырган әсәрләр – шигырьләр, поэма, драма, романнар яздылар. Композиторларыбыз җырлар, симфонияләр, опера, рәссамнарыбыз картиналар иҗат иттеләр.

Үлем карары чыгарылгач та, шагыйрь күңелен төшерми, рухын сындырмый. Төрмәнең кысан, караңгы камерасында да аның өчен иҗат йолдызы балкый. Тоткынлыкта тимер чыбыклар белән уратып алынган төрмә камерасында да ул, җырчы сабан тургаедай, һаман биеккә талпына. Татар легионында аның башка лагерьларга чыгып йөрергә, кешеләр белән аралашырга мөмкинлеге бар, ләкин аның тынгысыз җаны богаулы. Ул үз фикерен ачыктан – ачык әйтә алмый, һәр адымын үлчәп атларга мәҗбүр. Аның бер генә артык хәрәкәте дә очлы зәһәр күзләрдән читтә кала алмый. Йөрәгеннән ургып чыккан кичерешләре, фашистларга карата нәфрәт, ачу шигырьләренә күчә. Фашистларга каршы көрәшкә ул штык белән түгел, көчле каләме белән чыга. “Моабит дәфтәре” Җәлилне

җиңелмәс үлмәс рухлы итеп танытты. Көчле рух белән сугарылган бу шигырьләр күпләрнең күңелендә көчле яңгыраш тапты, җыр булып яңгырады. Мәркәзебез Казанда, Кремль каршындагы һәйкәлдә дә Җәлил горур, нык ихтиярлы, башын югары күтәреп, кулларын артка таба богаулап куелган килеш сурәтләнгән. Әгәр дә җан иңдерсәң, тимер богауларын бер талпынуда өзеп ташлар шикелле. Аның кабатланмас рухы гасырларга барып җитәр әле.

Палач балтасы астында шундый зирәк, Ватанга чиксез мәхәббәт, ә фашистларга карата җимергеч нәфрәт тулы ялкынлы юллар язу өчен тимер, сыгылмас ихтиярлы, якты акыллы, зур һәм кайнар йөрәкле кеше булырга кирзк.

Гражданин һәм шагыйрь Муса Җәлил батырлыгында тугандаш татар халкының рухи матурлыгы, көчле зур җаны, бетмәс – төкәнмәс каршы торучанлык куәте чагылды. Димәк, татарларның батырлары һәрвакыт булган, алар милләткә сүнәргә ирек бирмәгәннәр. Татарның батырлары милләтебезне саклаучы, аның яшәешен киләчәк буыннарга җиткерүче күпер хезмәтен үти, батырлар – дөнья татарларын берләштерүче көч, батырлар – иман сакчылары.

**Муса Җәлил безнең күңелләрдә...**

Казанның нәкъ уртасында (М.Горький урамы, 17 йорт) М.Җәлилнең музей—квартирасы урнашкан. 1940-41 елларда монда Татарсан Язучылар союзы идарәсенең рәисе М.Җәлил яшәгән, нәкъ менә шушыннан ул Ватанны саклау өчен сугышка киткән. Җәлил яратып җыйган, шкафка һәм этажеркага куелган китаплар, үзенең әсәрләре, үзе сайлаган фоторәсемнәрдән тупланган альбом, уен партиясе төгәлләнмәгән шахмат тактасы ята торган язу өстәле, үзе исән чакта ук ясалган бюсты, дисбесе, хуҗасының сизгер кулларын тойган һәм бу йортка килеп йөргән дусларын хәтерләгән мандолина…

Минзәлә шәһәрендәге М.Җәлил музее да бу легендар шәхес истәлеген кадерләп саклый. Ул шагыйрь исемен йөртә торган урамда урнашкан педагогия колледжы бинасында эшли. Фронтка китәр алдыннан шушы йортта Җәлил политхезмәткәрләр курсларында укыган. Монда яшәгән 56 көннең барысы да актив рәвештә иҗат итү, шигырьләрен бастырып чыгару, минзәләлеләр алдында чыгышлар ясау белән үткәнерактан калган ул елларның кабатланмас үзенчәлеген чагылдырган экспозиция, күргән—белгәннәрнең истәлекләре шулар хакында сөйли.

Балтач районның Карадуган авылындагы М.Җәлил музее зур эш алып бара. Шушы авылның укытучылары һәм мәктәпукучылары күп еллар үткәргән эзләнү эшләре нәтиҗәсендә монда М.Җәлил һәм аның якыннары, дуслары, чордашлары турында кызыклы материаллар җыелган. Ядкарьләр арасында— Җәлилнең үз кулы белән бүләк

итү сүзләре язылган "Татар әдәбияты тарихы" китабы, мәшһүр татар рәссамы Бакый Урманче таррафыннан ясалган скульптура.

Димәк, татарларның батырлары һәрвакыт булган, алар милләткә сүнәргә ирек бирмәгәннәр. Татарның батырлары милләтебезне саклаучы, аның яшәешен киләчәк буыннарга җиткерүче күпер хезмәтен үти, батырлар – дөнья татарларын берләштерүче көч, батырлар – иман сакчылары.

Тарихта чын батырларыбызның даны беркайчан да югалмыйлар, аларны тарих та җуя алмый икән. Күпме генә юк итәргә тырышсалар да, халкыбызның чын каһарманнары зинданнарны ярып чыгып, көчле җыр булып, фашизмның усал җилләренә бирешмичә исән калып, халкыбызга яңадан әйләнеп кайттылар. Китмәскә дип кайттылар! Шагыйрьләргә алдан күрү сәләте бирелә, диләр. Чынлап та, М.Җәлилнең, үз үлемсезлеген тойган кебек, әйткән сүзләре дөрес булып чыкты:

Батыр үлә, үлмәс ат алып,
Батырлыклар белән макталып.
Исмең калсын, үзең үлсәң дә,
Тарихларда укып ятларлык.

Әйтче, Муса, шундый батырлыкны
Кай җиреңдә саклап йөреттең?
Кемнән алдың мондый горурлыкны?
Нинди ялкыннарда чыныктың?
Җиңәр өчен шундый дошманнарны
Корычтан булгандыр беләгең.
Сөйләр өчен палач битенә төкереп
Куш булгандыр синең йөрәгең.
Арабыздан үзе югалса да,
Юк суытмас һични бу эзне.
Көрәштәге Муса, солдат Муса,
Йөрәктәге Муса ул безнең!

М.Җәлил- татар халкының,алай гына да түгел,илебез халыкларының да йөз аклыгы ул.Үзен аямыйча кулындагы коралы белән дә,каләме белән дә дошманга каршы көрәшкән шагыйрь беркайчан да онытылмас,аның тормыш юлын,әдәби мирасын өйрәнү эшләре буыннан буынга дәвам итәр.

Минем гипотезам расланды. Муса Җәлил – үз илен яраткан, аның азатлыгы өчен гомерен биргән чын гражданин, батыр! Гражданин һәм шагыйрь Муса Җәлил

батырлыгында тугандаш татар халкының рухи матурлыгы, көчле зур җаны, бетмәс – төкәнмәс каршы торучанлык куәте чагылды.

**Кулланылган әдәбият**


1. Муса Җәлил. “Сайланма әсәрләр”, 1955 нче ел.
2. Риза Ишморат. “Үлмәс җыр”, Казан, 1956 ел.
3. Г.Хуҗиев. “Безнең Мус”, Казан, 1957 ел.
4. Г.Кашшаф. “Муса Җәлил”, Казан, 1961 ел.
5. И.Юзеев. “Соңгы сынау”, Казан, 1963 ел.
6. А.Рошка. “Безнең Муса”, Казан, 1968 ел.
7. Х.Җәлилова. “Абыем турында”, Казан, 1969 ел.
8. Р.Мостафин. “Герой шагыйрь эзләре буйлап”, Казан, 1973 ел.
9. Ш.Маннур. “Муса”, Казан, 1975 ел.
10. “Сабантуй” газетасы, 1996 ел.

11.Рафаэль Мостафин”Муса Җәлил турында истәлекләр” Казан Тат. Кит. Нәшр. 2006нчы ел.



*Гасимова Алинә, 4 нче сыйныф, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «32 гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчеләр: Мөбарәкшина Рузилә Рәшит кызы, туган теле һәм әдәбияты укытучысы, Ачаева Чулпан Нургали кызы, башлангыч сыйныфлар укытучысы*


**Татар халык мәзәк текстларының милли-мәдәни үзенчәлекләре**

Фольклор – күпкырлы һәм бай милли иҗат. Аның милли табигате сурәтле-сәнгатьчә фикерләвендә ачык чагыла. Без әлеге хезмәтебездә татар халык иҗатының кыска жанрларыннан берсе булган мәзәк жанрын өйрәнергә булдык.

Безнең фикеребезчә, бу тема бик актуаль, чөнки, беренчедән, татар халкының милли-мәдәни үзенчәлекләре мәзәкләрдә ачык чагылыш тапкан, икенчедән, мәзәк һәрвакыт заман белән бергә атлый. Шул ягы белән ул, фольклорның башка жанрларнына караганда өлгерлек һәм җитезлек күрсәтеп килә. Хәзерге вакытта балалар мәзәкләре күбәеп бара. Аларда самимилек, риясызлык һәм дөреслек ачык бирелә.

Халкыбызның бай иҗатын тиешенчә җыйнау һәм фәнни өйрәнү хәзерге көннең иң мөһим бурычларыннан берсе булып тора.

**Татар халык авыз иҗаты системасында мәзәк жанры**

*Татар әдәбиятында жанр төре буларак мәзәк һәм аны өйрәнү тарихы*

Татар халык иҗаты әсәрләрен жанрлар ягыннан төркемләү буенча беренче тәҗрибәләр әле XIX йөзнең урталарында ук ясала. Башта бу эш практик планда, ягъни текстларны жанрларга аерып матбугатта чыгару төсендә башкарылса, К. Насыйридан башлап һәр жанрның үзенчәлекле билгеләрен ачыкларга, төркемләүне фәнни нигезгә корырга омтылу күренә.

Г. Ибраһимов халык әдәбиятын эчтәлеге ягыннан җиде төргә бүлә (бәетләр, җырлар, әкиятләр, мәкальләр, табышмаклар, такмаклар, такмазалар)[9]. Тагын Х. Бәдигый, Г. Сәгъди, Г. Рәхим тарафыннан эшләнгән төркемнәр бар[10]. Әмма боларның берсендә дә әле мәзәк жанры телгә алынмый. Бары тик 1926 елда гына М. Васильев һәм Г. Рәхим төзегән "Фольклор һәм халык әдәбиятын җыю өчен кулланма"да мәзәк беренче мәртәбә мөстәкыйль жанр итеп күрсәтелә. Аңа: "Көлкеле характердагы бик кыска хикәяләргә анекдот (ләтифа) диләр", – дигән билгеләмә дә биреп үтелә[11].

Мәзәкләр, гадәттә, мәҗлесләрдә, күмәк ял вакытларында җыелган кешеләрне бер көлдереп алу, аларның күңелен ачу максатында сөйләнәләр. "Мәзәк – күңел ачкычы" дигән гыйбарә дә жанрның әнә шундый вазифасына ишарә итә.

Татар мәзәкләрен матбугатка чыгаруда бөек мәгърифәтче Каюм Насыйри эшчәнлеге аеруча зур урын алып тора. "Җәваһирел хикәят", "Кырык бакча", "Фәвакиһелҗөләса" кебек китапларында ул дистәләрчә мәзәк текстлары урнаштыра.

Татар халкының үз мәзәкләрен системалы рәвештә җыю һәм матбугатка чыгару эше совет чорына, бигрәк тә 50 – 60 нчы елларга туры килә. Бу өлкәдә язучы Г. Бәшировның эшчәнлеге аеруча тәкъдир ителүгә лаек. Озак еллар халык арасында йөреп, шулай ук урыннардагы һәвәскәр фольклорчылар, әдәбият сөючеләр ярдәмендә ул 900 гә якын мәзәк җыйный. Мәзәкләрне җыю һәм матбугатка чыгару буенча Н. Исәнбәтнең хезмәте зур. Аның өч томлык "Татар халык мәкальләре" җыентыкларында 400 ләп мәзәк тексты китерелә.

Мәзәк текстлары төрле тематик җыентыкларда, "Чаян", "Казан утлары", "Сөембикә", "Ялкын", "Татарстан яшьләре", "Ирек мәйданы", "Мәдәни җомга" кебек журнал һәм газета битләрендә дә даими басылып киләләр.

**Татар мәзәкләренең төрләре.**

---

[9] Г. Ибраһимов. Әдәбият дәресләре. – Казан, 1916, Б. 64.

[10] Х. Габделбәдигъ. Халык әдәбияты. Мәкальләр. – Казан, 1912, Б. 5, Г. Сәгъди. Әдәбият ысуллары. – Оребург, 1912, Б. 4, Г. Рәхим. Халык әдәбиятыбызга бер караш. "Аң", 1914, 14 сан, Б. 264.

[11] Әлифба тәртибе, имла кагыйдәләре, атамалар мәгънәләре, халык әдәбиятын җыю турында инструкцияләр җыентыгы. Җыючы Г. Алпар, Казан,1926, Б. 50.

Татар халык мәзәкләренике төрле принцип нигезендә төркемләү кабул ителгән. Беренчесе – мәзәкләрне персонажлары буенча төркемләү, ягъни танылган мәзәк геройлары турындагы әсәрләрне аерым цикллар итеп туплау. Болай эшләгәндә татар фольклорында түбәндәге зуррак мәзәк цикллары булуын күрәбез:

1) Әкмәли мәзәкләре; 2) Рәхми тылмач мәзәкләре; 3) Мокыт мәзәкләре; 4) Мәнди мәзәкләре; 5) Гыйбеди мәзәкләре; 6) Әшти белән Мәшти мәзәкләре; 7) Мөҗип дивана мәзәкләре; 8) Зирәк килен Үлмәс Сылу мәзәкләре; 9) Ялкау килен Пәриха мәзәкләре; 10) Җирәнчә Чичән мәзәкләре; 11) Хуҗа Насретдин мәзәкләре һ.б.

Хуҗа Насретдин, Җирәнчә Чичәннәр татар халкының үзе тарафыннан тудырылган образлар булмаса да, алар безнең фольклорда нык үзләшеп, милли персонажлар булып киткәннәр.

Билгеле, Хуҗа турындагы мәзәкләрне татар халкы үз репертуарына иҗади үзләштереп кабул иткән. Бу мәсьәләгә кагылып, М. Васильев болай дип яза: “Безнең (ягъни татарча) текстларда төрекчә текстларны эшкәртү барыннан да элек түбәндәгеләрдә чагыла: 1) вакыйга бара торган обстановканы җирле көнкүреш шартларына яраклаштырып үзгәртүдә; 2) көлүнең тупаслыгын һәм хәрәкәтләрнең дорфалыгын йомшарта төшүдә, геройны гадиләштерүдә; 3) дингә мөнәсәбәттә ирония элементлары кертүдә”[12].

Мәзәкләрне төркемләүнең икенче ысулы – аларны идея–тематик яктан карап бүлү. Бу очракта без мәзәкләрне ике төп төркемгә аера алабыз:

1. Сыйнфый-иҗтимагый эчтәлекле мәзәкләр.
2. Көнкүреш, гаилә, әдәп-әхлак темасына караган мәзәкләр.

Беренче төркемгә керүче мәзәкләр изүче сыйныф вәкилләренең гаделсезлеген, ахмаклыгын, комсызлыгын, саранлыгын, әхлакый бозыклыгын, шулай ук хөкем-идарә, укыту-тәрбия эшләрендәге төрле җитешсезлекләрне фаш итәләр.

Мәзәкләрнең икенче тематик төркеме, әдәп-әхлак мәсьәләләрен күтәрә. Алар аерым кешеләрнең көнкүрешендә, холкында, үз-үзен тотышында очрый торган төрле җитешсезлекләрне һәм тискәре сыйфатларны (ялкаулык, наданлык, саранлык, шапшаклык, ялганчылык һ. б.) тәнкыйтьлиләр.

Мәзәк беркайчан да турыдан-туры мораль уку, үгет-нәсихәт бирү белән шөгыльләнми.

Мәзәкләрдә тискәре герой гадәттә үзенең бер сыйфаты буенча гына сурәтләнә (я ул бик ялкау, я бик саран, я бик ялганчы, я бик мактанчык һ. б.). Бу сыйфатның начарлыгын калку һәм көлке итеп сурәтләү өчен гипербола еш файдаланыла.

[12] М. Васильев. Татарские версии анекдотов Ходжи Насретдина, ИОАИЭ, т.XXXIV, вып. 1 – 2, 1928. – С. 143.

Көнкүреш мәзәкләрендә геройларны бер-беренә каршы кую алымы (тырыш – ялкау; белемле – надан; юмарт – саран һ. б.) киң кулланыла.

Димәк, мәзәк – ул борынгы заманнарда ук туып, бүгенге көндә дә актив кулланыла торган жанр. Аның төп идея-эстетик кыйммәте тормыштагы төрле тискәре күренешләрне сатира-юмор ярдәмендә фаш кылуы, әдәп-әхлак нормаларын ныгытуга, кешеләрдә, бигрәк тә яшь буында югары рухи сыйфатлар тәрбияләүгә ярдәм итүе белән билгеләнә.

**Татар мәзәк текстларының милли-мәдәни спецификасы**

*Мәзәк текстларының милли-мәдәни үзенчәлекләре*

XX гасырның соңгы яртысында мәзәк жанры тематикасының баюы, эчтәлегенең тирәнәюе һәм замана таләпләренә сизгерлеге артуы җәһәтеннән дә үзгәрә. Халыктан җыеп алган мәзәкләр татарның эчке, рухи тормышына шактый тирәнгә керә башлый. Ул игътибарны әдәп-әхлак кагыйдәләренең төп баганалары булган иманлылык, гаделлек, вәгъдәдә тору, пакълек, гомумән камиллеккә омтылу кебек асыл сыйфатларга юнәлтә.

Татар мәзәкләрендә асылда үз халкыбыз тормышы, үз гореф-гадәтләребез хакында сүз бара. Мәзәк ул, әкиятләр кебек үк, безгә бабалардан ук калган бай мирас. Ул үзендә борынгыдан бирле тупланып килгән тормыш тәҗрибәсен, гореф-гадәтне саклый. Алай гына да түгел, мәзәкләрдә сүз байлыгы, телнең үзенчәлекле борынгы матур бизәкләре дә саклана. Моңа мисал итеп “Ашыкканның авызы пешкән” дигән әйтемнең сүз ярдәмендә ясалган онытылмаслык сурәтен китерә алабыз. Кайнар аш кабып авызы пешкән кияү түшәмгә карап: “Түшәмегез бигрәк сары икән! Ниди урманнарның агачы?” – ди. Кәләше: “Уйсу җирләрнең агачы, түземсезлек җәзасы!” – дип җавап бирә. Халык сөйләменең мондый соклангыч матур бизәкләрен мәзәкләрдә күп очратырга мөмкин.

Акыллы фикерләргә байлыгы, тематикасының төрлелеге, стиленең камиллеге, теленең үткенлеге, һаман яңара баруы җәһәтеннән татар мәзәкләре башка халыклар иҗаты арасында күренекле урын тоталар.

**«Мәзәк жанрын беләсезме?»**

**(Сыйныфташлар белән сораштыру үткәрү)**

Фәнни эшебезне башкарганда сыйныфташларыбызның мәзәк жанры белән ни дәрәҗәдә кызыксынуларын белү максатыннан сораштыру үткәрергә булдык. Аларга түбәндәге сорауларны тәкъдим иттек:

1. Мәзәк нәрсә ул?

а) чынбарлыкны сәнгатьчә тасвирлауның үзенчәлекле ысулы

б) кечкенә күләмле, чәчмә формадагы көлкеле (сатирик я юмористик) эчтәлекле әсәр

2. Мәзәкләрдә еш очрый торган герой кем ул?

а) Үги кыз

б) Хуҗа Насретдин

3. Мәзәк нинди өлешләрдән тора?

а) исеме, башлам, төп өлеш, ахыры.

б) исеме, төп өлеш

4. Мәзәкнең үзенчәлеге нәрсәдә?

а) көтелмәгән чишелеш белән тәмамлануы

б) кечкенә күләмле булуы

5. Мәзәкләрне кайдан табып укыйсыз?

а) китаптан, дәреслектән, әдәби әсәрләрдән

б) интернеттан

Сораштыруда 4 нче сыйныфта укучы 30 бала катнашты. Укучыларның күбесе мәзәк жанры белән кызыксына дигән фикергә килдек. Нәтиҗәдә,мәзәкнең борынгы заманнарда ук туып, безнең көннәрдә дә актив яши һәм үсә торган жанр булуын исбатладык.

Шулай итеп, без татар мәзәк текстының жанрлык билгеләренә, идея – тематик, милли - мәдәни үзенчәлекләренә тукталып уздык.

Мәзәк – борынгы заманнарда ук туып, әле безнең көннәрдә дә актив яши һәм үсә торган жанр. Совет чорында иҗат ителгән мәзәкләрдә жанрның тематикасы һәм персонажлар составы үзгәрә баруы күзгә ташлана. Борынгы мәзәкләрдә иң еш очрый торган персонажлар патшалар, вәзирләр, байлар, казыйлар, муллалар һәм аларга капма-каршы куелучы тапкыр мужик, хәйләкәр хезмәтче яки Хуҗа Насретдин, Алдар Күсә, Әкмәли агай кебек популяр фольклор геройлары булса, яңаларына колхозчылар, агрономнар, эшчеләр, студентлар, укучы балалар һ. б. образлар килеп керә.

Иске мәзәкләрдә социаль сатира өстенлек итә. Хәзерге мәзәкләрдә зур урынны хуҗалык-көнкүреш тематикасы алып тора, аларда эшкә җавапсыз карау, ваемсызлык, ялкаулык шикелле начар сыйфатлар фаш ителә.

Мәзәк – кечкенә күләмле, чәчмә формадагы көлкеле (сатирик я юмористик) эчтәлекле әсәр. Тапкыр һәм көтелмәгән чишелеш белән тәмамлануы – жанрның үзенчәлекле билгесе.

Мәзәкләр әдәп-әхлак мәсьәләләрен күтәрә. Алар аерым кешеләрнең көнкүрешендә, холкында, үз-үзен тотышында очрый торган төрле җитешсезлекләрне һәм тискәре сыйфатларны тәнкыйтьлиләр.

Мәзәкнең төп идея - эстетик кыйммәте тормыштагы төрле тискәре күренешләрне сатира - юмор ярдәмендә фаш кылуы, әдәп - әхләк нормаларын ныгытуга, кешеләрдә, бигрәк тә яшь буында югары сыйфатлар тәрбияләүгә ярдәм итүе белән билгеләнә.

**БИБЛИОГРАФИЯ**

1**. Чыганаклар**

1. Лерон Л. Чыктым аркылы күпер: юмористик хикәяләр, пьесалар, парчалар, мәзәкләр. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2004. – 351 б.

2. Шәрәфиева Р. Мәзәкләр // Безнең мирас. – 2014. – № 5. – Б. 111.

3. 116tat.ru›p/blog-page_30.html

4. clubs.ya.ru›4611686018427390762/replies.xml…

2.**Файдаланылган әдәбият исемлеге.**

1. Заһидуллина Д.Ф., Закирҗанов Ә.М., Гыйләҗев Т.Ш., Йосыпова Н.М. Татар әдәбияты: Теория. Тарих. – Тулыл. 2 нче басма. – Казан: Мәгариф, 2006. – 319 б.

2. Урманче Ф.И. Татар халык иҗаты. – Казан: Мәгариф, 2005. Б. 351.

3.kpfu.ru›content_print?p_cid=72030

4. halik-ishati.ucoz.ru›index/m_z_kl_r/0-16

5. tt.wikipedia.org›Мәзәк

6. vk.com›id199193239

*Гатауллин Рәмис, 9 нчы сыйныф, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы “Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүче 11 нче гомуми белем бирү мәктәбе”*
*Җитәкче:Вагыйзов Фәрит Яхъя улы, татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

## «Муса Җәлилнең фронт лирикасында үзенчәлекләр»

Әдәбият белгечләре шагыйрьнең иҗатын 4 этапка бүләләр: иҗат башлангычы чоры, сугыш алды еллары, Ватан сугышы еллары, тоткынлыктагы иҗаты (“Моабит дәфтәрләре”).

Тикшерү эшебезнең максаты – М.Җәлилнең 1942 нче елда Волхов фронтында хәрби һәм иҗади эшчәнлеген өйрәнү.Шулай ук 2 нче Удар армия сугышкан урыннарда “Нефтехимик” эзләү отряды табып безнең мәктәп музеебызга тапшырган экспонатларның Кызыл Армия гаскәрләренең Волхов фронтында хәрби-героик елъязмасы белән тарихи бәйләнешен ачыклау.

Муса Җәлил Ватан азатлыгы хакына җанын биргән, язмыш сынауларына бирешмичә, үлемен батырларча кабул иткән көчле рухлы шәхес.Герой-шагыйрь үрнәге, аның яшәү мәгънәсе турындагы фикерләре бүгенге яшьләрне тәрбияләүдә бик әһәмиятле.

Муса Җәлилнең тормыш максатын һәм шул максатка ирешү юлларын ачыклау, исбатлау.

2. Шигырьләрен тирәнтен өйрәнеп, аның яшәү мәгънәсе турындагы

1. Бөек Ватан сугышы башлану белән Муса Җәлил үзен фронтка җибәрүләрен сорап Татвоенкоматка килә. 1941 нче елның 13 нче июльдә ул повестка ала һәм Кызыл Армия сафларына китә. Башта ул тупчы һөнәрен үзләштерә башлый. Аннары Курск өлкәсендәге Щигры поселогында урнашкан политруклар курсына укырга җибәрелә. Тиздән курслар Татартсанның Минзәлә шәһәренә эвакуацияләнә. Октябрь-декабрь айларында хәрби-сәяси җитәкчеләр (политруклар) әзерләүче кыска сроклы курсларны тәмамлагач, аңа «өлкән политрук» дәрәҗәсе бирелә. Шагыйрне башта Кызыл Армиянең Политуправление резервына җибәрәләр, аннары - Волхов фронтына. 1942 нче елның мартыннан ул хәрәкәттәге 2 Удар армия составында политрук булып хезмәт итә. Тиз арада аны армиянең “Отвага” газетасына хәрби корреспондент итеп күчерәләр. 2нче Удар армия бу чорда Любань юнәлешендә авыр сугышлар алып бара һәм Муса Җәлил һәрчак алгы сызыкта була.

“Отвага” газетасында аның дистәләрчә очерк һәм мәкаләләре, 30 дан артык шигырьләре басылып чыга. Әгәр дә сугышның башлангыч чорында М.Җәлил пафослы, көчле патриотик шигырьләр тудырган булса, фронтка килгәч сугышның көндәлек вакыйгалары аның лирикасына конкрет һәм төгәл тормыш сурәтләү чаралары кайтара. Аның лирик герое җанлы, тере образга әверелә (“Тел”, “Җиңү”). Ул Ватанны саклауда тормышын аямыйча, авыр хәрби язмышының барлык сынауларына әзер, бар кичерешләре хискә бай (“Һөҗүм алдыннан”, “Эз”, “Төш”) Патриотик идеяларны шагыйрь төрле поэтизмнар аша чагылдыра. Мәсәлән, язгы иртәдә госпиталь палатасына яшь шәфкать туташы керә (“Яз”). Ул үзе белән беренче чәчәкләр һәм фронттан дошманнарның чигүе турында яхшы хәбәрләр алып керә. Яшь кыз үзе дошманнардан арынган җирдә матур яз образына әйләнә. Һәм бернинди купшы сүзләрдән тыш шигырь укучыда җиңүгә ныклы ышыныч туа. Бик бай эмоциональ образлар шулай ук “Туганлык”, “Яз шатлыгы” шигырьләрендә тудырылган.

Шул ук чорда “Дан”, “Җиңү”,“Атака алдыннан” шигырьләре дөнья күрә Аның шигырьләрендә бик тирән мәгънә, йөрәк түреннән чыккан ялкынлы хис, үткен каләм көче чыгыла. Ул әйткән шигъри сүзләр бүген дә актуаль, бүген дә безнең күңелләргә үтеп керә, Ватан өчен үз гомерләрен биргән миллионнарча солдат хисләре булып, укучыларны тетрәндерә, уйга сала. «Окоптан хат», «Каска», «Госпитальдән», «Кыз үлеме», «Тел», «Европада яз», «Хуш, акыллым», «Тупчы анты»... Бу шигырьләр сугыш елъязмасы дип аталырга да хаклы. Алар аркылы солдатның яшәү рәвешен күз алдына китерәбез, кичерешләре белән танышабыз.

«Хуш, акыллым» шигыре шагыйрьнең хатыны Әминә ханымга багышланган. Монда дошман явын җиңеп кайтырга дип киткән совет солдатының вәгъдәләре бер-бер артлы

тезелә. Көрәш, үлем турында язса да, җанны өтәрлек моңсулык юк. Һәр юлда җиңүгә өмет яшеренгән шикелле. Шагыйрь-солдат ил хакына бирелгән гомер өчен дә үкенмәс кебек. «Әйдә, җырым!» шигырендә илгә олы мәхәббәт хисләре йөрткән лирик мин белән очрашабыз:

Җырым, синдә минем гәүдәләнде

Илне сөйгән йөрәк тибешем.

Монда да шул ук ант:

Яшәсәм дә,

Үлсәм дә — тик туган ил өчен!

1942 елның беренче яртысында Кызыл Армия авыр шартларда сугыш алып барса да, М.Җәлил үз иҗатында юмор-сатирик алымнар кулланып фашистлардан көлә: "Гитлер хәле", "Азимут", "Гитлерның язгы резервлары". Шул рәвешле ул кызылармиячеләрнең кәефен күтәрергә тырыша. «Отвага» фронт газетасының соңгы номеры 21нче июньдә дүрт биттә чыга. Соңгы номерны әзерләүдә М. Җәлил дә катнаша. Бу вакытта инде армия чолганышта була. Редакция составыннан бары 3 хезмәткәр фронт линиясеннән үзебезнекеләр ягына чыга: калганнар һәлак була яки хәбәрсез югалалар. Авыр яраланган хәлдә М.Җәлил фашистлар кулына әсирлеккә эләгә. Әнә шулай аның лагерь тормышы башлана. Әмма шагыйрь әсирлектә дә көрәшне туктатмый.

2. Ил өчен көрәш темасы әйдәп барган 1941-1942 еллар иҗаты Җәлил шигъриятендә аерым бер чорны тәшкил итә. Фронт лирикасына мөнәсәбәтле шигырьләр, нигездә, башланып киткән Бөек Ватан сугышына мөнәсәбәт белдереп языла. Шуңа күрә аларның күбесенчә яшәү / үлем оппозициясенә корылуы күзгә ташлана: үлемгә фәлсәфи якын килгән әдипләр моңа кадәр бетү, югалу мәгънәләрендә килгән үлемне мәңгелеккә илтүче чара дип кабул итәләр; Ватан азатлыгы өчен үлем үлемсезлеккә, үлгәннән соң яшәүгә (азатлыгы өчен үлгәннәрне Туган ил бервакытта да онытмас, халык йөрәгендә мәңге яшәр гыйбарәсе шуңа тоташа) юл алу буларак кабул ителә, нәкъ менә шул яссылыкта үлем яшәү белән тигезләшә:

Әйдә, җырым, батыр җиңү дәртен

Алып керик ялкын эченә.

Мин калмасам җирдә,син калырсың

Һәйкәл булып үлмәс эшемә. («Әйдә, җырым!», 1941).

Шагыйрьнең бу чорда иҗат ителгән шигырьләрендә җиңүгә ышаныч, илне көрәшкә өндәү, дошманга нәфрәт һәм илне саклау хакында ант бирү мотивлары әйдәп бара. Мәсәлән, «Хуш, акыллым» (1941), «Окоптан хат» (1941), «Чулпанга» (1941) кебек шигырьләр илне, якыннарны саклау турында ант бирү, җиңүгә ышаныч мотивлары белән

сугарыла. Яңа мотив буларак рус поэзиясендә киң урын алган илнең җимерелүе мотивы «Госпитальдән» (1941), «Европада яз» (1942) кебек шигырьләрендә чагылыш таба. Сугышның беренче көннәрендә язылган «Әйдә, җырым» (1941), «Дошманга каршы» (1941), «Соңгы көрәшкә» (1941), «Тупчы анты» (1941) кебек шигырьләрендә дошманга нәфрәт, илне көрәшкә өндәү мотивлары алга чыга. Ватанны, Туган илне ярату да дошманга, фашистларга көчле нәфрәт белән аерылгысыз бәйләнештә алына, көрәшче – сугышка керүче, дошман – Гитлер, фашист, талаучы кебек сурәтләр тотрыклы:

Ил!
Алдында синең мин ант итәм,
Шаһит булсын кулым ярасы:
Гитлер явын тар-мар итми торып,
Якты күрмәс күзем карасы! («Госпитальдән», 1941).

Мондый шигырьләрдә ил образы көчле бирелә. «Чын ирекнең гөрләп чәчәк аткан бакчасы» шагыйрьнең алдагы әсәрләре белән чагыштырганда үзгәреш кичерә: Туган ил — туганнар, кадерле кешеләр, тыныч туган җир образлары аша төгәлләшә һәм көрәш барган җир түгел, нәкъ менә сугышка каршы куелган тынычлык җире кебек гомумиләшә. Үлемгә мөнәсәбәт үзгәреп, сагыну, шом, кайгы хисләре якыннарыннан мәңгегә аерылышу эчтәлеге белән кушыла. Мәсәлән, «Хуш, акыллым» (1941) шигыре сөйгәненнән, туган ягыннан аерылуга газапланган лирик герой кичерешләрен үзәккә ала. Сөй-гәненнән аерылу, үлемнең янәшәдә генә йөрүе, кабат күрешергә мөмкинлекләрнең чикле булуы хис сәбәбенә әйләнә. Үлемгә мөнә-сәбәт ике яклы төс ала: батырларча үлемнең үлемсезлеккә, мәң-гелек яшәешкә юл алуын аңлаган, аны шатланып кабул иткән лирик герой «татлы йокының» сөйгәненнән мәңгегә аерачагын уйлап сагышлана, шомлана һәм: «Татлы булыр йокы... Тормышымны батырларча бирсәм ил өчен, Тормыш дустым – синең йөрәгеңдә дәвам итсә йөрәк тибешем», – дип, сөйгәне йөрәгендә «яшәячәгенә» өметләнеп юана:

Ахыр чиктә синең саф сөюең
Җиңеләйтер үлем газабын,
Илемне һәм сине сөюемне
Каным белән җиргә язармын.

Шигырьләрдә романтик (Чулпан йолдыз, җитез аргамак, таң, гөл) һәм натуралистик (кан, үч, нәфрәт, каска, штык) образлар янәшәлеге еш күзәтелә, Җәлил төп эчтәлекне бер поэтик образга җыйнап тәкъдим итә башлый. Мәсәлән, «Чулпанга» (1941) шигырендә метафора сыйфатында килгән Чулпан йолдызның күпмәгънәлелеге лирик герой хисләрен, идеяне бер үзәккә туплый. Бердән, ул татар шигърияте традициясендәгечә ялгызлыкны, сагышны чагылдырып, аерылу хәсрәтен сынландырса, икенче яктан, лирик «мин»нең

җиңүгә ышанычы, илнең матур киләчәгенә өмете булып яңгырый Үлем-шатлык кебек капма-каршы төшенчәләрнең янәшәлеге идея буларак Туган илне генә түгел, якыннарны саклап, алар азатлыгы хакына дөнья-дан китү бәхет ул дигән фикерне калкыта.Туган илгә тугрылыкны раслау мотивы ант һәм ышаныч образлары, үлем-үлемсезлек төшенчәләре белән тыгыз бәйләнештә бирелә, алар шагыйрь шәхесе белән Туган ил арасындагы мөнәсәбәтне ачуда төп чарага әверелә. Әлеге үзенчәлекләр барысы да М.Җәлил иҗатының сәяси эчтәлеккә генә сыешмавы, тар кысаларда калмавы хакында хәбәр итә. Нәтиҗәдә Җәлил шигърияте милли–шәхси эмоциональлек белән баетыла, аның тәэсир көче арта.

Безнең шәһәрнең «Нефтехимик» отряды күп еллар рәттән Новгород өлкәсенә, Мясной Бор районы тирәсендә канлы бәрелешләр узган җирләргә барды. Анда табылган ярты гасырдан артык һәлак булган сугышчыларны тантаналы рәвештә күмүдә катнашалар. Экспедицияләрдә табылган корал, хәрби амуниция һәм сугыш кирәк-яраклары безнең мәктәп музеена тапшырылып, Бөек Ватан сугышына багышланган экспозиция оештырылды. Бу экспонатлар безгә 1941-42 нче елларда Волхов фронтындагы кырыс шартларны, канлы бәрелешләр тарихын сурәтләргә ярдәм итәләр. Музей күргәзмәсендә политруклар йөрткән хәрби кыр сумкасы, ТТ пистолетының кобурасы, шартлаткычы алынган граната, каскалар бар. Вермахт солдатларының да кораллары күп – автомат-пулемет магазиннары, мина ярчыклары... Сазлыкларда табылган штык-көрәкләрне күрсәтеп, без снаряд-патроннары булмыйча, ярымач килеш 2 нче Удар армиянең сугышчыларының фашистларга каршы соңгы тамчы каннарына кадәр көрәш алып баруларын исбатлыйбыз. Шулай ук сугыш үткән урыннарада җыелган документаль материалларны, Интернеттан Германиянең хәрби командованиесе (вермахт) архивыннан алынган фотоларны видеопрезентация әзерләүдә кулланабыз. Ленинград блокадасын өзү максаты белән тиешле дәрәҗәдә әзерлексез башланган Кызыл Армиянең кышкы һөҗүме уңышсызлыкка дучар була. Яз көне сазлыклар эрегәч, безнең гаскәрләр снаряд-патроннарсыз, азык-төлексез калалалар. Фоторәсемнәрдә - ташландык хәрби техника һәм кораллар, мәетләр өеме. Бигрәк тә кеше буе биеклектә сазлык уртасындагы агачларының кәүсәләре агарып күренә: ачлыктан безнең солдатлар кайры кимергәннәр икән... Сугышның башлангыч чорында Кызыл армия солдатларының батырлыгы мәктәп музеенда саклanучы “На штурм врага” (“Дошманга һөҗүмгә”), газетларының фотокүчермәләрендә дә күп чагыла . Шушы газеталарның күчермәләрен безгә 2016 нчы елны Минзәлә педагогик колледжында урнашкан Муса Җәлил музее хезмәткәрләре бүләк иткәннәр иде. Саргаеп беткән бу басма номерларның эчтәлеге М. Җәлил эшләгән “За отвагу” дивизион газетасын белән тиң: Совинформбюро хәбәрләре, мәкаләләр, геройлар турында очерклар. Шигырьләр һәм сатирик такмаклар да бар.

Йомгаклау

Без бу кечкенә тикшерү эшендә М.Җәлилнең 1942 нче елда Волхов фронтында хәрби һәм иҗади эшчәнлегенә күзәтү ясадык. Шулай ук 2 нче Удар армия сугышкан урыннарда “Нефтехимик” эзләү отряды табып безнең мәктәп музеебызга тапшырган экспонатларның Кызыл Армия гаскәрләренең Волхов фронтында хәрби-героик елъязмасы белән тарихи бәйләнешен ачыкладык.

Муса Җәлилнең фронт шигырьләрендә эчкерсез самимилек ,тормышны ярату хисләре ярылып ята.1944 нче ел, 25 нче август. Бу дәһшәтле көнне патриот шагыйрь Муса Җәлил һәм аның унбер көрәштәшенең тормыш юлына нокта куела. Ләкин бернинди явыз үлем аны безнең арадан алып китә алмый. Муса Җәлил — үлемсез. Менә ничә еллар инде ул халык күңелендә якты бер җыр булып яши. Үзенең үлемсез шигырьләрендә яши.

Тормышым минем моңлы бер җыр иде,

Үлемем дә яңгырар җыр булып.

МусаҖәлил бүген дә тереләр белән бергә дөньяның тынычлыгы, иминлеге өчен көрәшә, яшәүгә рухландыра.

Кулланылган әдәбият:


1. Бөек Ватан сугышы чоры поэзиясе: Шигырьләр һәм поэмалар. – Казан:Татарстан республикасы “Хәтер” нәшрияты, 2005.

2. “Телсез йөрәк монологы”, Тәлгать Галимуллин, Нурфия Гафиятуллина. – Казан: Мәгариф, 2004

3. Татар әдәбияты тарихы, алты томда, 5 том, Бөек Ватан сугышы һәм сугыштан соңгы еллар әдәбияты (1941-1960). – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1989.

6.Кашшаф Г. Муса Җәлил.— Казан: Татар. кит. нәшр.2004

Электрон ресурслар:

1.Энциклопедия – URL: http://encyclopedia.mil.ru/encyclopedia/gentlemens/hero

2. Халык батырлыгы сайты(«Подвиг народа») // URL:podvignaroda.mil.ru2.

3. Сайт https://pamyat-naroda.ru/



*Гиззатуллина Мәрьям Алмаз кызы, 8нче сыйныф,*
*Фәсхетдинова Диләрә Айдар кызы, 9нчы сыйныф,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Муса Җәлил исемендәге “1 нче гимназия” муниципаль бюджет белем бирү учреждениесе*
*Җитәкче: Зартдинова Эльвира Камил кызы, инглиз теле укытучысы, Хәйруллина Гөлназ Рәшит кызы, татар теле укытучысы*


**Чәй табыны: татарча һәм инглизчә**

Һәр халыкның үзенә хас гореф-гадәт һәм йолалары бар. Шуларның иң күркәме – чәй эчү йоласы. Чәй – дөньяда киң таралган эчемлекләрнең берсе, һәм чәй эчү кайбер милләт гореф-гадәтенең бер өлеше булып тора.

Электән чәйнең туган иле Кытай дип ишеткән идем. Инглизләрнең чәйне күп эчүче милләт булуы мине гаҗәпләндерде. Кытайлар беренче унлыкка да керми икән.

Инглизләрнең озын гомерлек сере аларның күпьеллык чәй эчү традициясе белән бәйле. Аларда чәй – чын мәгънәсендә Чәй. Чәй эчү йоласын Англия Королевасы да, гади халык та бертөрле үк үти. Англиядә яшәүче 59 млн кеше көн саен 165 млн. кәсә чәй эчә. 86% өйдә эчелсә, 14% өйдән тыш кулланыла. Инглизләр белән аңлашылды, ә менә Татарстанда чәй турында, аның йолалары турында белмәүче юктыр. Ике милләтнең йолалары бертөрлеме икән?

Тикшеренү эшенең **темасы**: татарлар һәм инглизләрдә чәй йоласы: охшашлык һәм аерымлыклары.

Эшнең **актуальлеге**: һәр милләт йоласы, аерым алганда, билгеле, ә янәшә куелып тикшерелмәгән; йолаларны өйрәнеп, шул илнең, милләтнең тарихын тирәнрәк аңлыйсың.

**Гипотеза**: инглизләрдә һәм татарларда чәй эчү электән килгәч, аның аерым башкарылучы йолалары да булырга тиеш.

**Максат**: инглиз һәм татарларның чәй эчү йолаларын тикшерү.

**Бурыч**: - материал эзләп табу;

- үзенчәлекләрен билгеләү;
- аерымлыкларны ил географиясе, тарихы, халыкның менталитеты аша ачыклау.

**Тикшерену объекты**: инглиз һәм татар чәй эчү йоласы.

Методлар: 1) теоретик (материал туплау, системалаштыру, фәнни-публицистик әдәбият белән танышу)

2) практик (җәмгыять арасында сораштыру, чәй эчеп карау).

1. Чәй барлыкка килү тарихы

Чәйне, судан кала, иң киң кулланылучы әчемлек дип атап була. Аны Көнчыгышта да яраталар, Европада да өстенлек бирәләр, көнбатышта да кире какмыйлар. Аның килеп чыгышы турында төрле легендалар йөри. Көньяк-Көнбатыш Кытай, Югары Бирма, Төньяк Вьетнам чәйнең туган ягы булып санала. Аны ачуны кытай императоры – кытай медицина галиме Шень Нунга тәңгәлләштерәләр. Б.э.к. 2700 ел элек яшәгән Нун, ял иткән арада, учакта су кайнатып эчмәкле була, ләкин бер куактан төшкән яфракларны искәрми. Әлеге эчемлек аңа көч бирә, кәефен күтәрә, бөтен тәненә җылылык тарата. Шуннан соң, күп үләннәрне тикшергән галим, әлеге куак белән кызыксына башлый.

Шулай итеп, яңа төрле шифалы үлән – чәй табыла. 527 нче елда чәй  Англиядә күренә башлый, тик будда монахлары аны үз даирәсеннән чыгармый. Бары тик XIX  гасыр ахырында гына чәй киң халык массасы арасында тарала.

1.1. Татарларда чәй барлыкка килү тарихы

Татар табынында эчемлекләрнең күплеге табигый-климатик, иҗтимагый-сәнәгати шартларга, шулай ук күрше халыклар кухнясына бәйле. Чуваш, башкорт, мари, мордва, удмурт, рус, Урта Азиядән үзбәк һәм таҗиклар белән аралашу нәтиҗәсендә татарларда катык, баллы ширбәт, йөзем суы, әйрән киң кулланылган. Чәй турында ишетмәгән кеше юктыр! Аның турында күпме мәкаль, әйтем, җыр-бәет чыгарганнар?! “Татар кунакка килсә, чәй эчмичә китми”,  “Чәйне чәйнисе юк”,  “Чәй түгел бит борыч, салсаң сал бер уч”, “Чәйне сал учлап, эч тынычлап”,  “Чәй яны — гаилә җаны, “Бер чынаяк чәйнең 40 еллык хәтере бар”  һ.б.ш.  Элеккедән килгән гадәт буенча, татарларда чәй эчәргә кыстау булган. Шул исәптән, “Сыйлаганда су эч”  дигән гыйбарә сакланган.  XVIII гасыр башы – XIX гасыр азагында яшәп иҗат итүче шагыйрь, фәлсәфәче Габдерахим Утыз-Имәни әл-Болгари да чәй турында яза:

«Гүяки кәүсәрне татыр
Чәйне бер эчкән кеше,
Нәкъ матур кызлар йөзенә
Охшый ал гөлдәй төсе ...

...Син кунак булып, бу чәйне
Һич яратмасаң әгәр,
Дус янында кадер булмас
Ишәк кадере кадәр».

Татарлар арасында чәйнең таралуына мисал итеп, Каюм Насыйри түбәндәге риваятьне  китерә:  Борын-борын заманда бер суфый яшәгән. Үзенең гомерен күпчелек сәяхәттә үткәргән бу илченең юлы көннәрдән бер көнне Төркестанга алып килә. Хәлсезләнгән, ерак юл һәм эсселектән арылган юлчы Кытай чикләрендә урнашкан бер авылга хәл алырга туктый. Хуҗа кеше суфыйның хәлен тиз арада бәяли һәм аңа кайнар эчемлек бирә. Аны кабул иткәннән соң, тәнеңдә көч сизә юлчы: ару-талу бетә, аңа яңадан көч-куәт кайта. Маңгаендагы тирен сөртә-сөртә, ул эчемлеккә мәдхия укый башлый:

-Менә, ичмасам, эчемлек. Бу җәннәттәндер. Ул – Аллаһы Тәгалә бүләге!

Күп рәхмәтләр укып, юлын дәвам итә. Очраган һәр кешегә сихәтле эчемлек турында сөйли, уртаклаша. Озакламый аны хәерчеләр дә, байлар да, авырулар да, сәламәтләр дә куллаша башлый. Ул шулхәтле киң тарала ки, аннан башка беркем дә тора алмый. Алдагы

сәяхәтләрендә дә суфый дәрт-дәрман өстәүче эчемлекне үзеннән калдырмый. Аңлашылганча, бу эчемлек — галиҗәнәп чәй була.

### 1.2. Инглизләрдә чәй килеп чыгу тарихы

Англия Европада чәй кулланучылардан беренче булмый. Голландия сәяхәтчеләре һәм сәүдәгәрләренә була Англиягә 17 гасыр уртасында чәй һәм шикәр кертелә. Аны Кытай һәм Һиндстаннан алып киләләр. 19 гасырга кадәр шикәр һәм чәйне бары тик аристократлар гына куллана алган. Эчемлекнең беренчел исеме "ча" була. (Бу Кытай порты исеме белән бәйле). Сатып алу урыны үзгәргәч, Кытай порты исеме белән "тэй" [т'е] дип атала башлый. 18 гасырдан башлап, Бөекбритания чәйне иң күп куллашучы ил рәтенә керә. Тора-бара чәй аристократлар эчемлегеннән халык массалары арасына тарала. Чәй белән бергә, Кытайдан Англиягә чәй кирәк-яраклары, савыт-саба да килә. 1884нче елга чәй тагын да күбрәк кертелә башлый. Бу тимер юллар төзү белән бәйле була. 1743нче елда Челси шәһәрендә кытай савыт-сабасы сыйфатыннан килм булмаган фарфор мануфактурасы ачыла.

## 2. Инглиз һәм татар чәй эчү традицияләре

### 2. 1. Инглизчә чәй үзенчәлекләре

Инглизләрнең чәй эчүләре кабатланмас һәм мавыктыргыч. Башка халык йолаларыннан нәрсәсе белән аерылып тора соң ул? Көненә 165 млн. кәсә эчүче халык ни өчен аңа шулкадәр өстенлек бирә? 1664нче елда ост-Индия кампаниясе сәүдәгәрләре Англия короле Карл икенчегә бүләк итеп ике фунт "коры кытай яфрагы" бирә торган булалар. Король даирәсе чәйнең бөрештергеч тәме, хуш исе һәм файдалы үзленчәлекләренә тиз төшенә. Инглизлар чәй ясау барышында кәсәгә башта сөт, ә аннары гына кайнар чәй агызалар. Бу нәрсә белән бәйле була соң? Иң беренчеләрдән булып җитештерелгән фарфор бик юка була. Савыт-саба кайнардан шартламасын өчен, кәсәгә башта сөт салалар, аннары салынган кайнар су, сөт белән кушылып, юка фарфорга зыян китермәслек температурада була. Савытка баштан сөт салу гадәте шуннан калган. Чәй инглизләрнең көнкүрешенә шулкадәр үтеп керә ки, алар үзләренең эшләрен "чәй эчү арасында" планлаштыралар. Бик төгәл халык буларак, һәр нәрсәне үз вакытында башкаралар. Томанлы Альбион яшәүчеләре хәтта "Англияне Королевасыз күз алдына китереп була, ә менә чәйсез - юк", дип шаяртырга яраталар. Инглизләр чәй эчүне бер тантанага әйләндергәннәр. Аларда хәтта "чәйгә кабул итү" (чайный прием) йоласы бар. Аны үткәрү хуҗадан тора. "Чәйгә кабул итү" рәсми һәм рәсми булмаган төс алган. Рәсми булмаган чәйгә телефон челтәре аша чакыралар. Рәсми чәйгә чакыру кәгазе җибәрелә. Ул башка чакырулардан кечкенәрәк булуы белән аерылып тора. Анда чәй эчүнең өйдә булуы әйтелә һәм вакыты билгеләнә. Җитмәсә, вакытының башлану һәм тәмамлану аралыгы

күрсәтелә. Кунак үз вакыты белән, шул аралыкта килә. Чакыру кәгазендә хуҗалардан хатын-кыз исеме генә языла. Бу Европа гаиләләрендә чәй пешерү, сыйлау белән хатын-кызлар гына шөгыльләнә, шуңы күрә хуҗабикә генә чакыра ала дигән сүз.

Инглизләр көненә 6 тапкыр чәй эчәләр. Өстәвенә һәр вакытының үз чәй төре һәм йоласы бар. Иң беренче – "Инглизчә иртәнге аш" ("Английский завтрак"). Аны ике тапкыр эчәләр: беренчесе уяну белән урын-җир өстендә (бу Ангиядәге юеш һава торышы белән бәйле). Торып киенгәнче һәм юынгачы иртәнге чәй эчү Англиянең иртәнге томанлы климатын йомшарту, җылылык өстәү өчен кирәк. Икенче чәй өстәл артында эчелә. Инглизләр бик иртә яналар, һәм туклыклы ашыйлар: солы боткасы белән балык, яки бекон белән күкәй. Шулар янына сөтле чәй. Икенче иртәнге аш сәгать 12ләр тирәсендә була. Бу Королева Виктория идарәсе вакытыннан килә. Ашау бу вакытта бик төрле: ипи, сыер мае, пешерелгән йомырка, киптерелгән ипи, миндаль печеньесы, арпа кабартмасы, джем (күп очракта җиләкнеке), желе, кайнар күмәч. Шулар янында хуш исле йомшак чәй эчелә (a nice cup of tea). Англиядә төшке аш бик соң ашала. Сәгать саен чәй эчү тәнәфесе оештырыла. Җитәкчеләр моңа каршы килми, чөнки чәй эчүгә тыю эштә җитәкчелек һәм эшчеләр арасында җитди каршылык тудырырга мөмкин. Бу коры чәй эчү була, аның янына ашамлык куелмый, һәм ул "tea breaks" дип йөртелә.

Алга таба 17 һәм 18 сәгать арасында "файв-о-клок"- иң киң таралган чәй эчү вакыты. Гади эшчедән алып Королевага кадәр барысы да "ябыла", әйтерсең вакыт туктала.

Ниһаять, көне буе эшләп арганнан соң, кичке сәгать 7 белән 8 арасында инглизләр кичке ашка җыелалар. Бу ашау вакыты "югары чәй" дип атала, һәм чәй күләменә түгел, ә ашауның күп булуына ишарә итә. Көне буе эшләп арганнан соң, зур өстәл артына җыелу, җылы камин тирәсендә утыру, яңалыклар белән уртаклашу, шулар арасында тәмләп чәй эчү – болар барысы да инглизләрнең нигезле, тигез, тыныч тормыш ятратуларын күрсәтә. Шулар өстенә, балаларның уен арасындагы көлешү-сөйләшүләре өлкәннәрнең гәпләшү авазлары белән аралаша. Бу инглизләрнең гаилә җылылыгы турында сөйли.

Инглизләрнең чәй эчү йоласы билгеле бер тәртиптә оештырыла. Өстәлгә ак эскәтер җәелә, шул ук төстәге салфеткалар куела. Болардан тыш яңа җыелган чәчәк бәйләме өстәлнең уртасына урнаштырыла. Савыт-саба түбәндәгечә була: чынаяк, тәлинкә, десерт тәлинкәсе, чәй кашыгы, чәнечке, пычак, чәйнек, салкын су салынган кувшин, сөт савыты, шикәр савыты. Барлык савыт-сабаның да бер сервиздан булуы шарт. Гадәттә, әлеге сервизлар 13 предметтан тора. Чәйнек, татарларның түгәрәк чәйнегеннән аермалы буларак, биек, озынча формада. 18 гасыр башында инглизләр Кытай җитештерүчеләренә чәй кәсәсенә тоткыч ясарга тәкъдим итәләр. Кайнар чәй тамып пешермәсен яки эскәтерне

пычратмасын өчен, соңрак чәй тәлинкәсе сораталар. Шулай итеп, шәрык кәсәсеннән тоткычлы чәй чынаягы барлыкка килә.

Инглизләрнең төп кагыйдәсе: һәр тәүлек вакыты өчен үзенең чәй сорты бар. Әгәр кунак, үзенә генә бер төрле чәй эчәргә теләсә, аңа чәйне аерым кечкенә чәйнектә пешерәләр. Кагыйдә буларак, чәй яңа гына кайнап чыккан су белән пешерелми. Су әзрәк талгын булырга тиеш. Пешерелүче чәй күләме ничек исәпләнә соң? Һәр кешегә 1 чәй кашыгы исәбеннән салына, шуңа өстәп, чәйнек өчен 1 кашык өстәлә. 5 минут вакыт эчендә чәй тәмле булып пешеп чыга, үзенең файдасы һәм тәмле үзлекләрен ача. Соңгы вакытта инглизләр пакетлы чәй эчә башладылар. Ул кулланучыларның 90% тәшкил итә. Шуңа да карамастан, инглизләр чәйнектән дә баш тартмыйлар. Сөт яки каймак салынганга, инглизләр аны “ак чәй” дип йөртәләр.

Инглиз язучысы Джордж Оруэлл үзенең “Алыштыргысыз чәй” мәкаләсендә чәйгә кушылучы сөт күләмен билгеле. Аның фикеренчә, кәсәгә башта каты чәй салына, шуннан чыгып кына сөтнең күләме билгеләнә. Җитмәсә, чәй бары тик Һиндстанда җитештерелгән булырга тиеш. Шикәр салуга Оруэлл каршы. Язучы “Әгәр Россиялеләр кебек эчәсегез килсә, шикәр салыгыз”,- ди.

Шулай итеп, чәй ясалгач, этикет буенча, чәй тәлинкәсе белән чынаяк өстәлдән берьюлы алына, һәм сул кул белән тәлинкә, уң кул белән чынаяк тотыла.

Замана үзгәргән саен, гореф-гадәт һәм йолалар да үзгәрә. Шуңа да карамастан, Англиядә кыйммәтле рестораннар “чәй эчү кичәләре” уздыралар. Аларга эләгү өчен, алдан ук язылып куярга кирәк.

## 2.2. Татарча чәй эчү үзенчәлекләре

Татарларда чәй эчү йоласы инглизләрнекеннән бер дә ким түгел. “Чәй өстәле – гаилә йөрәге”, дип тә әйтергә ярата татарлар. Туй дисеңме, килен төшерүме, Сабантуймы, бала туумы – берсе дә чәйсез үтми.

Татарлар арасында чәйнең тәнне генә түгел, җанны да җылытуы турында биек яратып сөйлиләр. Әлеге халык элек-электән үзенең кунакчыллыгы белән дан тоткан. Элек өй түрендә, мич янында, күмер самавары булган. Ул һәрвакыт кайнап торган, суынмасын өчен, аңа күмер өстәп торганнар. Искәрмәстән килеп кергән кеше дә һәрвакыт кайнар чәй эчү мөмкинлегенә ия була. Хәзерге вакытта күмер самавары көнкүрештән төшеп калса да, электр самаварын әле очратып була.

Башка халыклардан аермалы булырак, татарлардан чәй өстәле артында эндәшмичә утырырга ярамый. Бу хуҗага карата хөрмәтләмәү булып санала. Шулай да сөйләшү әдәбе үтәлергә тиеш: бик кычкырып сөйләшү һәм сүгенү тыела. Чәйне электән бары тик бай татарлар гына сатып ала алган. Аның янына инҗир, хөрмә, лимон һәм башка җиләк-

җимеш тә сатып алына. Кытайдан чәй кергәнче, татарлар төрле үләннәрдән: зәңгәр мәтрүшкә, сары мәтрүшкә, бөтнек, кура җиләге яфрагы, чия һәм карлыган куагы яфрагыннан эчемлек ясаганнар. Татарларда, кайбер башка халыклардан аермалы буларак, “коры чәй эчү” дигән төшенчә юк. Табынга конфет, төрле җиләк-җимеш кайнатмалары, лимон, сөт һәм башка шундыйлар куела. Чәйне пешерү өчен фарфор чәйнек алына. Аны кайнар су белән чайкаталар, һәр кеше исәбенә 1 кечкенә кашык чәй салына, шуңа чәйнек өчен 1 калак чәй өстәлә. Кайнап чыккан суны чәйнекнең өчтән бер өлеше тулганчы коялар, 1 калак шикәр комы өстиләр һәм калын сөлге белән төреп куялар. 3-4 минуттан чәйнек тулганчы кайнар су өстиләр. Чәй пешерүнең икенче ысулы түбәндәгечә: тимер чәйнеккә 6 кечкенә кашык чәй салына, чәй күләменнән арттырмыйча төрле үләннәр кушыла. Кайнар су койганнан соң, сүрән утта чәй күпереп менгәнче кайнаталар. Әзрәк “ял иттергәч” чәй бөртекләре төпкә утыра һәм аны эчәргә мөмкин. Кунак киләсе булса, оста хуҗабикәләр чәй янына күп итеп тәм-томнар әзерлиләр, ә гадәти көнне коймак, белен яки кабартма булырга мөмкин. Күренекле табиб һәм тарихчы Карл Фукс үзенең «Казан татарлары» дип исемләнгән китабында татарларның кунакчыл халык булуын һәм бик күп чәй эчүләрен ассызыклый. «Татар халкының иң матур сыйфаты — кунакчыллык. Татарда төп сый — чәй, аны кимендә дүрт чынаяк эчәргә кирәк. Аннан табынга каймак, кура җиләгеннән как, майда кызган юка куела. Боларның барысын да, һичшиксез, ашарга кирәк, тик моның белән генә бетми. Таныш булмаган ике-өч татар кунакка чакыра. Баш тартырга ярамый. Баш тартып үпкәләтергә мөмкин».

2.3. Татарларда һәм инглизләрдә чәй эчү аерымлыклары һәм охшашлыклары

Ике милләтнең чәй эчү үзенчәлекләрен тикшереп, аермалы һәм охшаш яклары билгеләнде.

Аермалы яклары

| Татарларда | Инглизләрдә |
|---|---|
| Чәйне XXVI гасырда куллана башлыйлар | Чәйне XXVII гасырда куллана башлыйлар |
| Чәйгә аерым чакыру юк | Телефон яки хат аша чакыралар |
| Чәй эчү өчен тәүлек вакыты, чәй сорты әһәмиятле түгел | Тәүлекнең һәр вакытына үз чәй сорты каралган |
| Табын җәюгә аерым әһәмият бирелми | Табынга аерым игътибар бирелә: салфетка һәм эскәтер, савыт-саба сервисы бертөрле булырга тиеш |
| Чынаякка башта заварка, аннары кайнар су салына, соңыннан сөт өстәлә | Чынаякка башта сөт салына, аннары гына чәй һәм кайнар су өстәлә |

| | |
|---|---|
| Кайнар чәйне тәлинкәгә салып эчәләр | Чынаяк пары өстәлдән берьюлы алына: уң кул белән чынаяк, сул кул белән тәлинкә. Чәй тәлинкәгә салынмый, бары тик тамчы тамып, тап төшмәсен һәм пешү очракларын искәртү өчен генә кулланыла |

Охшаш яклары

| |
|---|
| Сөт салып эчү киң таралган |
| Чәй суынмасын өчен,  чәйнек калын сөлге белән каплана |
| Чәй янына һәрвакыт тәм-том куела |
| Кайнатма яки джем, бал, җиләк-җимеш куела |
| Тәүлегенә, ким дигәндә, 4-5 чынаяк чәй эчелә |
| Чәй карарак булып чыксын өчен, чәйнеккә шикәр комы өстәлә |
| Чәй табыны артында тыныч кына гәпләшү күркәм сыйфат санала |

Нәтиҗә күрсәткәнчә, татар һәм инглизләрдә чәй эчүнең охшаш һәм аерым яклары бар. Ни генә дисәң дә, ике милләт өчен дә  “Чәй яны- гаилә җаны”.

## Йомгаклау

Чәй эчү кешелек дөньясында һәрдаим башкарылучы йолага әйләнде дисәк тә ялгыш булмас. Тикшеренү эшенең максаты татар һәм инглизләрнең чәй эчү охшашлыкларын һәм аерымлыкларын чагыштыруга нигезләнгән иде. Географик, сәяси һәм икътисади яктан бер-берсенә якын тормаган һәм охшамаган ике милләтнең гореф-гадәтләре арасында охшашлыклар шактый булып чыкты.

Тикшеренү эше барышында укучылар, әти-әниләр арасында сораштыру үткәрелде. Кайберәүләрнең чәй эчү турында фикеренчә, инглиз һәм татар халкында чәй барлыкка килү буенча аз мәгълүматлы булулары ачыкланды. Бу эшнең актуальлеген тагын бер кат раслады. Англиянең юеш салкын һавасында да, Россиянең күпчелек татарлар яши торган эссе җәйле Идел буенда да чәй ЧӘЙ булып кала.

## Кулланылган әдәбият:

1. Школа этикета /Сост. Л.С. Лихачева. – Екатеринбург: Средне-Уральское кн. издательство, 1997.
2. Лечебные чаи, сборы, настои. //М.В. Никитина. – Москва: кн. изд. “Крылов”, 2010.
3. 5 O'clock и другие традиции Англии // А.В. Павловская – “Алисторус”, 2014.
4. Фукс, К. Ф. Ф94 Казанские татары в статистическом и этнографическом отношениях / К. Ф. Фукс: переложение на современный русский язык А. Г. Хорошавиной; науч. ред. и

предисл. И. И. Бикеева; Институт экономики, управления и права (г. Казань). – Казань: Изд-во «Познание» Института экономики, управления и права, 2013. – 108 с.

Электрон ресурслар:

1. https://zavarka.life/chajnaja-kultura
2. http://qazantatarlary.narod.ru/Fuks_statis.html

*Гыйлемханова Язилә, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы "Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүле 31 нче гомуми урта белем бирү мәктәбе"муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең 8 нче сыйныф укучысы*
*Җитәкчесе: Фокеева Елизавета Павел кызы, Ганиева Рузилә Фәвәдис кызы, татар теле һәм әдәбияты укытучылары*

**Йолаларда һәм халык авыз иҗаты әсәрләрендә саннарның вазифалары**

Мин үземнең тикшеренү эшемне "Йолаларда һәм халык авыз иҗаты әсәрләрендә саннарның вазифалары"дигән темага багышладым.Саннарның халык авыз иҗаты әсәрләренең барлык өлкәләрендә һәм йолаларда кулланылуы миндә зур кызыксыну уятты.

Шушыннан чыгып,кырык санының бигрәк тә мәкальләрдә,йолаларда кулланылыш дәрәҗәсен,өшкерүләрдә 3,7,9 саннарының тылсым көчен, табышмак-мәсьәләләрнең мавыктыргыч моментларын һәм аларда саннарның вазифаларын тикшерүне максат итеп куйдым. Куелган максатыма ирешү өчен, М.Мәһдиевнең "Кырыкның кырык мәгънәсе", Ф.С. Баязитованың "Гомернең өч туе", "Татар халкының бәйрәм һәм көнкүреш йолалары", Ф.Урманченың "Татар халык иҗаты" хезмәтләреннән файдаландым. Өч томдагы "Татар халык мәкальләре" (җыючысы һәм төзүчесе Н.Исәнбәт) җыентыгы буенча мисаллар тупладым. Кечкенәдән хәтердә калган санамышларны искә төшереп һәм башлангыч сыйныф укучыларыннан сораштырып, иң киң таралганнарын яздым.

Халык авыз иҗатында, йола-ышануларында саннарның эчтәлек һәм шигъри төзелеш ягыннан әһәмияте, тоткан урыны.

Барлык халыкларның мәкаль-әйтемнәрендә, йола-ышануларында саннар эчтәлек һәм шигъри төзелеш җәһәтеннән бик әһәмиятле урын алып торалар. Фольклорда аеруча еш кулланылган хикмәтле саннарның берсе, һичшиксез, кырык саны. Аның конкрет мәгънәләрен күзәтүгә күчкәнче, бу санның этимологиясе, ягъни ничек барлыкка килүе турындагы кайбер фикерләр белән танышып үтик.

Академик В. А. Гордлевский борынгы төрки халыкларда кырык төгәл сан белдермичә, әйберләрнең күп булуын гына күрсәткән, һәм сүз ахырындагы "к" авазы күплек кушымчасы булырга мөмкин дип карый. Аныңча, борынгы төрки шаманнар

тормышында кырык,дини сүз буларак,зур роль уйнаган һәм тора-бара, дини мәгънәсен югалтып, тик күплек төшенчәсен белдерүче булып кына калган.[3,101]

Профессор Л. Җәләй кырык-кырк-хырык сүзен кыр+ык рәвешендә ике өлешкә аерып карарга тәкъдим итә. Кырык-тамыр сүз, ә –ы-кушымча. “Кыр+ык сүзенең күплек төшенчәсендә йөргәнлеген искә алганда, -дип яза ул, -без аның тамырын хәзерге телдәге ялан мәгънәсендә йөри торган кыр “поле”, чик мәгънәсендәге кыр+ый “крайний” сүзләре белән бәйли алабыз”.[3,102]

Язучы һәм фольклорчы М.Мәһдиев тә Л.Җәләй карашын куәтли: “Кырык саны татар халкының авыз иҗатында күпчелек очракларда “бик күп”, “чиксез” мәгънәсен белдерә. Күрәсең, борынгы халыклар арифметикасының билгеле этабында кырык санау чиге булган. Шуңа барып җиткәне яки артып киткәне- исәпсез-хисапсыз, бик күп, санап бетергесез дип уйланылган. Әгәр шулай икән, ихтимал, “кыр” сүзенең дә тамыры кырык белән уртактыр. “Кыр” да бит иксез-чиксез иркен басу, ялан мәгънәсен аңлата”.[4,48]

Күплек мәгънәсен белдерүче мәкальләрдән түбәндәгеләрне күрсәтергә мөмкин. Аларның күчерелмә мәгънәләре Нәкый Исәнбәт җыелмасындабирелгән:

Кызлар күңеле - кырык карта (ягъни,кызлар күңеле күп катлы булып, сиңа бер катын гына күрсәтер, ниятләрен белеп бетерү авыр эш, дигәне);

Өйләнмәгән егет кырык кызны алыр (тегене алам, моны алам дигән хыялы күп булыр);

Кырык бала тапкан, керер капка тапмаган (күп бала үстереп тә, берсе дә кеше булмаган, игелек күрсәтмәгән була);

Кырык ач әрвахка бер бөтен икмәк каян җитсен? (варислар күп булып, мирас малы аз булганда әйтелә).

Шулай ук аз белән күп мәгънәләрен кискен төстә каршы куеп күрсәтү максатыннан кырык саны кулланылу очраклары да бар. Мәсәлән:

Кырык ел тавык булганнан бер көн этәч булганың артык;

Өйне кырык ир тутырмый, бер хатын тутыра;

Ир бер сүзле, хатын кырык сүзле;

Бер балык башын кырыкка бүлеп булмый.

Мәкальләрнең күбесендә чиктән тыш арттыру (гипербола) алымы кулланыла, һәм кырык саны әлеге алымны тагын да көчәйтеп җибәрә:

Каты агач шарт сынар, черегән агач кырык ел чыдар;

Уңган кеше кылны кырыкка ярыр.

Кырык саны татар фольклорында дини эчтәлекле текстларда да бик актив кулланыла, төрле ышануларда, ырымнарда очрый. Ул кешенең бер дөньядан икенче

дөньяга күчүе-тууы һәм үлүе дәвам иткән вакыт исәбе. Туганда кешегә җан кырык көн эчендә иңә һәм үлгәндә кырык көн эчендә китә. Кырык көнлек күчеш чорында кеше тәненә мөнәсәбәттә бик сак булырга кирәк икән.

Бала тугач та кырык көн үтмичә, төнлә ут сүндерергә, баланың үзен генә калдырырга ярамый, чөнки аны җен алыштыра, диләр (зарурлык туганда бишеккә пычак яки бүтән әйбер салып калдырырга кирәк). Бала кырык көне тулмас борын бик каты борчылса, моны йә авырый, йә исеме ошамый диләр. Бу очракта баланы өшкертеп, бөти яздырып алганнар да, шуны түшенә такканар. Аннан соң да борчылуы бетмәсә, исемен алыштырганнар. Шулай ук кырык көне тулганчы, баланың чәчен кыркырга кушалар.

Ф. С. Баязитова «Гомернең өч туе» исемле хезмәтендә балага кырык көн тулгач үткәрелә торган йолаларны кырыкламасын койу, кырыклату дип атый:

- Кырыкламасын койа балаларына, кырык кашык су белән койондыра. «Кырыкламасын койган айак йахшы айак, үземә торсын, үзем үлгәндә ул айак белән су койарсыз өстемә», - дип алып куйа кырыкламасын койган айакны.

Үлгән кешенең рухы кырык көн буена өенә килеп-китеп тора. Мәрхүмне искә алу хөрмәтеннән аның «өчесен», «җидесен», «кырыгын», «елын» укыталар. Кырыгын укытканда үткәрелә торган кайбер йолаларны галимә түбәндәгечә сурәтли:

- Кырыгына кырык күмәч пешерәбез, койаш чыкканчы хәерен бирәсен, тугисын да коймак пешереп хәер кертәсен. Табакка саласын кырык күмәчне...

- Кыркысына кырык гәрдә әвәлиләр, җәйләү-җәйләү кадәре була ул. Кырыгына ничә кеше килә, тәлинкәгә саласың инде.

Кырык саны ислам кануннарына да киң үтеп кергән. Шәригать мөлкәтнең кырыктан берен ярлыларга өләшүне хуплый. Мөхәммәд пәйгамбәр Аллаһы Тәгалә сүзен кырык яшендә ишеткән. Коръәндә «Мәетне күтәреп баручының кырык адымда кырык гөнаһы төшеп калыр» дигән сүз бар. Шуңа күрә мәет озатканда аны һәркем, кырык адым гына булса да, чирталашып күтәреп барырга тырыша.

Кырык саны кергән мәкальләр, кагыйдә буларак, җитди йола, кагыйдә, канун хөкемендә кабул ителәләр. Әлбәттә, алар арасында сатира-юмор катнашканнары, ирония, киная белән әйтелә торганнары да аз түгел:

Кырык төшнең берсе – пигамбәр төше, имеш (кырыклаган булгач, ялганның да берсе дөрескә чыкса, гаҗәп түгел дигән мәгънәдә);

Иң туры әйбер манара, аның да эче кырыкка кәкре;

Кыз егет башыннан бүреген алып кисә, кырык көнлек хатыны була, имеш (элек кичке уеннарда кайбер үткен кызлар, егетләрнең башларындагы бүрекләрен үз башларында киеп шаяргannaр).

Кырык саны “күп” дигән күчерелмә мәгънәдә бик еш кулланылса да, ул үзенең уры (дүрт унга тигез) зурлыгында “онытып бетерми”.Мәсәлән, яңгыр теләү йоласы вакытында күпер өстенә кырык чиләк су сибү тиеш саналган. Кешенең яше зурлыгы ягыннан сыйфатлаганда да төп-төгәл кырык ел турында сүз бара:

Кырык яшьнең үз яме бар;

Яшем җитте кырыкка ,эшем китте шырыкка.

Мәрхүмнәрне җирләү, аларны искә алу йолаларында да (аларга алдарак тукталып үтелде) кырыксаны үзенең реаль зурлыгында күздә тотыла: җеназаны нәкъ кырык адым күтәреп бару, вафатына кырык көн тулуны бигеләү, бу табынга кырык данә коймак пешерү һ.б.

Көнкүрештә еш кына шундый вәзгыять туып тора. Зиһенсез, онытучан, игътибарсыз кеше әле генә тоткан, үз тирәсенә генә куйган әйберен җир бетереп эзләсә дә таба алмыйча изалана. Андыйлар турында көлеп йә шелтәләп “Кырындагын кырык көн эзләгән” диләр. Ягъни, бик озак эзләгән. Ни өчен нәкъ менә кырык көн, ә биш көн, җиде көн түгел? Бу саннарның да бик озак дигән мәгънәләре бар бит. Чөнки монда доминант сүз кырындагын. Аңа эчке рифма кирәк. Ә монда иң кулай сан – кырык. Шушы ук мәкальнең “Астындагын алты ай эзләгән” дигән синонимы бар. Бу очракта рифманы алты саны тудырган. Кырын-кырын ятсаң, кырык кеше бер сәкегә сыя; кырын эш кырык елдан соң да беленер кебек мисалларда да кырык санына тукталу рифмалаштыру ихтыяҗы белән аңлатыла.

Кырык саны башка халыклар мәкальләрендә еш кулланыла, һәм ул башлыча күплек мәгънәсен белдереп килә:

Бер көн сыйлаган өчен кырык көн рәхмәт укырга кирәк (казакъ);

Бер көн талашкан кырык көнлек дошман (каракалпак);

Начарлык кырык көннән соң да беленер (кыргыз);

Арба җимерелер алдыннан кырык көн алдан шыгырдый башлый (төрекмән)һ.б.

Бүгенге көндәге кайбер ышануларны да искә алып китәсем килә: 40 яшьлек юбилейны уздырырга ярамый дигән фикер дә борынгыдан калган ышануларга барып тоташа, күрәсең.

Өшкерүләр фольклор жанрының башкаларына караганда тылсымлы көчкә ия булулары белән аерылып тора. Һәр компонентында сан булуы бу жанрны тагын да тылсымлы итә. В.Н.Топоровның “Числовой код в заговоре” дигән хезмәтендә саннарның өшкерүләрдә үзенчәлекле урын алулары турында язуы минем дә игътибарымны җәлеп итте. Мисаллар үрнәгендә боларны карап китик.

Балаларның күзенә арпа чыккач, арпа ярмасын файдаланалар. Өч тапкыр күзе кырыенда әйләндереп, өшкерүче дога укый. Аннан соң:

“И, Аллам, Раббым, мине хасталасын. Баланың күзләренә чыкмасын,” – ди.

Менә шул ук авырудан тагын бер өшкерүгә мисал китерәм. 7 бөртек арпа алалар. Өшкерүче авыруның күзенә арпаны китерә дә:

Баланың (исемен әйтә) күзенә арпа чыккан. Бердәмлексез булсын, бетсен, китсен, дөмексен.

1,2,3- очып китеп дөмексен,

1,2,3,4,5 – бетеп китсен,

1,2,3,4,5,6,7- җилдән-җилгә китсен,дөмексен,

1,2,3,4,5,6,7,8,9 – туфракка китсен,

Име-томы шул булсын, өшкерүем килешсен”.Аннары шул ук сүзләр белән кирегә санап әйтелә.

Беренче мисалдагы өч саны, В.Н. Топоров фикеренчә, тылсымлы дөньяга мөрәҗәгать итү функциясен үти. Өшкергәч терелү 3 санының әһәмиятен арттыра һәм өшкерүләрдә еш файдалануга сәбәп була. Икенче очракта бердән тугызга кадәр санау өшкерүнең йогынтысын көчәйтә, ә киресенчә киметеп санау чирне куып чыгара дип фаразлаганнар.

Куркудан өшкерү кот кою дип атала. Курыккан кешенең изүенә 7 төрле ярма салалар: бодай,арпа, солы,борчак, тары, карабодай, арыш. Куркуны бетерүне сорыйлар һәм дога укыйлар.

Куркудан өшкерүнең тагын бер үрнәге белән таныштырып китәм.Төрле үләннәр (ромашка,мәтрүшкә һ.б.) өстенә су салалар да курыккан кешене шушы савыт буена утырталар. Шул суга берәм-берәм 9кыздырылган дага салалар. Һәр даганы салганда:

“Кер котым,кер котым.

Ишектән дә кер котым,

Тишектән дә кер котым.

Үрдәк күк бакылдап кер,

Каз күк какылдап кер,” – диләр.

Санау - ул тәртип. Өшкерүдә саннарны файдалану югалтканны табарга, терелергә омтылуга туры килә.

Соңгы вакытта балалар арасында киң таралган афористик жанрларның тагын бер үзенчәлекле төре-санамышлар. Әлеге жанрның бөтен хикмәте шунда: балалар ул текстларны тулысынча яттан беләләр. Санамышлар уен вакытында “көтүчене”, төп

персонажны ачыкларга ярдәм итәләр. Мәктәбебездә башлангыч сыйныф укучылары арасында аеруча киң кулланыла торган санамышларны мисалга китерәм:

1)Бер тай, ике тай, өч тай, дүрт тай, биш тай, алты тай, җиде тай, сигез тай, тугыз тай, ун тай — чыгып тай!

2) Бер, ике, өч, дүрт, биш, алты, җиде, сигез, тугыз, ун

Байлар кия кызыл тун.

Кызыл тунның бәясе –

Йөз дә кырык сигез сум.

Санамышларның үзләренә генә хас сыйфатларына тукталып, Р. Ягъфәров болай дип яза: "Санамышларда "сәер" сүзләрнең күп булуын балалар фольклорын тикшерүчеләр жанрның борынгылыгыннан чыгып аңлаталар. Хәзерге тикшеренүчеләр исә аларның килеп чыгышын борынгы кешеләрнең "бәхетле" һәм "бәхетсез" саннарга ышануларыннан килеп чыккан дигән караштa торалар". [6,142]

Табышмакларның бер төре арифметик табышмаклар яки "табышмак-мәсьәләләр" дип атала. Бу төрнең төп үзенчәлеге – алар шактый зур күләмле булулары белән мәзәкләргә якын торалар һәм аларда төрле саннар күп кулланыла. Мәсәлән, "Агачка унике карга кунган. Аучы килеп икесен аткан. Агачта ничә карга калган?" (җавабы: берәү дә калмаган).

Әлеге үзенчәлек шигырь формасындагы табышмакларда да саклана. Мәсәлән:

1)Ике сигез – уналты,

Янә сигез, янә алты.

Ике алты, бер сигез,

Бер егерме, бер утыз. (Җавабы: йөз)

Гомумән, кайсы гына фольклор әсәрен алсак та, саннар борынгыдан кеше тормышында әһәмиятле роль уйнаганнар, һәм исәп, микъдар төшенчәләрен генә түгел, ә өстәмә мәгънә дә белдергәннәр дигән нәтиҗәгә килде

Тикшеренү эшемне башкаргач,түбәндәге нәтиҗәләргә килдем:

1) Кырык санының функцияләре күпкырлы һәм аларны өйрәнү бик мавыктыргыч,иҗади фикерләүне үстерә;

2) Элекке әби-бабаларыбызның өшкерүләрдә 3,7,9 саннарының тылсым көченә ия булуына ышануларына инандым,чөнки өшкерү йолалары бүгенге цивилизация заманында да актуальлеген югалтмый дип әйтеп була;

3) Санамышлар балалар фольклорында һәрвакыт игътибар үзәгендә;

4) Татар халык авыз ижаты әсәрләрен өйрәнгәндә, риваятьләрнең исемнәрендә үк саннарның кулланылуы игътибарымны җәлеп итте. Мәсәлән,"Җиде кыз","Унике

кыз”,“Кырык кыз”.Алга таба риваятьләрдә һәм бәетләрдә саннарның вазифаларын өйрәнү теләге туды.

Кулланылган әдәбият:

1. Баязитова Ф.С. Гомернең өч туе (Татар халкының гаилә йолалары)/ Ф.С.Баязитова. – Казан: Татар. кит.нәшр., 1992. – 295 б.

2. Баязитова Ф.С.Татар халкының бәйрәм һәм көнкүреш йолалар/Ф.С. Баязитова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1995 -158 б.

3. Мәһдиев М. Кырыкның кырык мәгънәсе/М.Мәһдиев//Сайланма әсәрләр: 5 томда/төз. Г.Хәсәнова.-Казан: Татар. кит. нәшр.- Т.5. – 2009.-  431 б.

4. Татар халык мәкальләре/Җыючысы һәм төзүчесе Н. Исәнбәт. Өч томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., Т. 1. – 1959. -913 б.; Т. 2. – 1963. - 959 б.; Т. 3. – 1967. -1013 б.

5. Урманче Ф. Татар халык ижаты/Ф.Урманче.-Казан.-:Мәгариф.-2005.-325б.

*Гыйләҗетдинова Зилә, 3 нче сыйныф, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы “27 нче гомуми урта белем бирү мәктәбе”муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчесе: Кәримова Марина Николай кызы, татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

## Мөхәммәт Мәһдиев әсәрләрендә авыл кешеләренә хас сөйләм үзенчәлекләре

**Теманың актуальлеге**. Күренекле шәхесләр иҗаты белән танышкан очрашканда, галимме ул, рәссам яки композитормы, әдип яки җәмәгать эшлеклесеме, үзеннән-үзе табигый бер сорау туа: бу олуг зат үзе эшчәнлек иткән өлкәгә нинди яңалыклар алып килгән дә, аны нинди мәгълүматлар белән баеткан?

М. Мәһдиевнең мирасы бу сорауларның барысына да уңай җавап бирер иде. Үзе кызыксынган һәр өлкәне ул эзләнүләр, ачышлар, рухи казанышлар, темалар төрлелеге, образлар белән баеткан.

М. Мәһдиевнең эстетикасы да зур бәягә, өйрәнүгә, яшь буынга бөтен тырышлыкны биреп тапшыруга лаек. Бүгенге сәяси, әхлакый каршылыклар хакимлек иткән заманда М. Мәһдиев иҗатының бу өлкәсен барлау, аны укучы яшьләргә ачып бирү мөһим бурыч булып тора. Аның кайсы гына әсәрен алма, анда матурлыкка омтылыш, һәрнәрсәдән матурлык эзләү сизелә [5, 15 б.].

Татар әдәбиятын әйдәп барган язучыларыбызның берсе Мөхәммәт абый Мәһдиевне авыл проблемасы күтәргән иң күп әсәрләр авторы дип әйтсәк тә бер дә ялгыш булмас.

Шуңа нигезләнеп, “М. Мәһдиев әсәрләрендә авыл кешеләренә хас сөйләм үзенчәлекләре” дип исемләнгән эзләнү эшбез бүгенге көндә ***бик актуаль дип әйтә алабыз.***

Хезмәтнең төп **максаты** – Мөхәммәт Мәһдиев иҗатында авыл кешеләренә хас сөйләменең бирелешен күрсәтү.

Шушы максаттан чыгып, түбәндәге **бурычларны** куйдык:

1. М. Мәһдиев иҗатына караган әдәбият белән танышу;
2. М. Мәһдиев әсәрләрен анализлау аша әдипнең иҗатына бәя бирү;
3. М. Мәһдиев әсәрләрендә авыл кешесе сөйләменә хас үзенчәлекләрне ачыклау.

Хезмәтебезнең **тикшерү предметы** – Мөхәммәт Мәһдиев иҗатында авыл кешеләренә хас сөйләм үзенчәлекләре, ә эшнең тикшерү **объекты** булып язучының “Бәхилләшү”, “Кеше китә – җыры кала” “Фронтовиклар”, әсәрләре тора.

**Фәнни эшнең яңалыгы** татар әдәбиятында авыл тормышын чагылдырган әсәрләрнең идея-эстетик һәм әдәби кыйммәтен билгеләү, аларның язылу һәм халык арасына таралу шартларын өйрәнү белән бәйле.

Без үзебезнең фәнни хезмәтебездә түбәндәге **гипотезаны** алга куябыз: Безнең фикеребезчә, язучыларның иҗатында темалар да, проблемалар да күп төрле. Шуларга бәйле төстә хәзерге матур әдәбиятыбызда туган авыл темасы бик мөһим, актуаль төс алды.

Фәнни хезмәтнең **структурасы** керештән, ике бүлектән, йомгаклау, әдәбият исемлегеннән тора.

**М. Мәһдиев иҗатында авыл тормышы**

“Туган җирне ярату М. Мәһдиев иҗатының нигезендә ята: Туган авылын сагыну хисе аңа “Кеше китә – җыры кала”, “Торналар төшкән җирдә”, “Бәхилләшү” кебек күренекле повестьларын язарга илһам чыганагы булды”, – дип язды И.Ф. Фәттахов [46, 32 б.]

Туган авыл, туган туфрак… Һәркемгә дә кадерле алар. Туган як гомер-гомергә кешеләр өчен илһам чыганагы, яшәргә көч һәм дәрт бирүче күңел маягы булган. Шуңа күрә бу орлыкларны бала күңеленә кечкенәдән үк салырга кирәк.

М. Мәһдиевне татар авылының бүгенге хәле бик борчый. Күп гасырлар дәвамында тупланган әхлак кагыйдәләренең югала баруы, матур йолаларның, гореф-гадәтләрнең онытылуы әдипнең йөрәген телгәли. Бу хакта ул “Бәхилләшү” дә ачыктан-ачык язды. “Бәхилләшү” – авылның үткәнен һәм бүгенгесен, авылның авыллыгын, татарның татарлыгын күп еллар буе бөтен нюанслары белән сурәтләп килгән популяр язучының элекке әсәрләреннән үсеп чыккан повесть [46, 51 б.].

“Бәхилләшү” – мәгълүм бер чорның, без яшәгән заманның, әле офык артында җәйге таң кебек кенә яралып килгән билгесез киләчәк белән хушлашуы ул. Автор һич

читенсенмичә: “Күрегез дә гыйбрәт алыгыз: без әнә шулай яшәдек”, – дип әйтергә тели. Тавышы моңсу да аның, сөенечле дә, үтә сагышлы да. Татар халкы күп гасырлар дәвамында чамасыз авыр сынаулар кичерде, шулай да үз йөзен, үз телен күңел бизәге булган гамен-ваемын югалтмады.

Әсәрнең төп герое, авыл басуында яшел борчак ашап үскән Фәләхетдин армия хезмәтенә алынгач Мәскәү горнизонына эләккән, шунда өч ел хезмәт иткән. Мәскәү янында бер шәһәрчектә ашханәдә эшләүче Валентина исемле рус кызы белән танышкач, бераздан аның телевизорлы квартирасына йортка кергән “окрошка” дигән суык аш ашый башлаган, “ләкин... борчак басуыннан зур шәһәргә кисәк сикереш аның баш миенә авырга туры килгән” һәм ул эти-әнисен, туган авылын, телен оныткан.

*Әмма үләр алдыннан Фәләхетдиннең дә ана теле ачылган: хәл белергә килгән туганына үз авылымның урман тирәсендәге басуында үскән бер уч яшел борчак ашыйсым килә дип саф татарча ялварган, карлы күз булганга авылдашы бу гозерне үти алмаган. “Бәхил булыгыз”, – дип җан биргән Фәләхетдин* [53, 181 б.].

“Торналар төшкән җирдә” милләтебез авыр язмыш кичергән елларда туган әсәр. Үзенең тирән сулышы, газаплы, сагышлы һәм рәхәт моңы белән, милли хисләрдән читләшә башлаган, телен саткан, моңына җирәнеп карый башлаган адәмнәрне сискәндереп дөньяга чыга бу китап.

Автор әсәрне язарга этәргеч итеп үзенең чит илләргә сәяхәтләрен саный. Бу җәһәттән аның белән килешергә дә, килешмәскә дә мөмкин. “Чит җирләрдә йөреп гыйбрәт ал” дигән җыр барлыгын да онытмыйча, “Әйдә барыйк, кызлар карыйк” бүлегенең автор әле чикләрне үтеп чыкканчы ук язылганын да искәртеп китик. Димәк, “Торналар төшкән җирдә” әсәрен язар өчен әллә кайчан, тумыштан ук әзерләнгән булган. Димәк, автор үз телебезнең, моңыбызның кадерен, газизлеген яшьтән үк тоеп үскән, чит илләрдә йөргәндә фикерен ачыклаган, фикерен өскәрәк менгергән, хатирәләре диңгезендә үз утравын тапкан.

“Торналар төшкән җирдә” – ***татар авылына гимн ул***. Анда милләтебезнең мәдәни үсеш дәрәҗәсе дөп-дөрес тотып алынган [24, 635 б.].

Тәнкыйтьче, әдәбият галиме Мөхәммәт Мәһдиев әдәбиятка “Без – кырык беренче ел балалары” (1968) повесте белән килеп керде, авыл укытучылары тормышына багышланган “Фронтовиклар” (1972) романы белән үзен җитди иҗтимагый-фәлсәфи, әхлакый мәсьәләләрне калкытып куярга инде өлгергән язучы итеп танытты.

Фронтовиклар” романын укыганда, без Акбалык мәктәбенең укучылары, укытучылары белән танышабыз. Безнең алда мәктәп тормышы, андагы кешеләр ачыла, аларның шатлык-кайгылары, борчу-мәшәкатьләре, җаннары ачыла. Роман торган саен

киңәя, тармаклана бара. Мәктәп тормышыннан авыл, колхоз хәлләренә күчәбез. Бераздан әсәргә район, республика күләмендәге вакыйгалар килеп керә. Вакыйгаларның кысалары киңәйгән саен, кешеләр арта, хәл ителергә тиешле мәсьәләләр күбәя. Бу романга авторның гомер буе җыйган күзәтүләре, аз-азлап туплаган ачышлары кергән. Монда аның тормыш, кеше гомеренең мәгънәсе турында уйланулары, теләк-омтылышлары, идеаллары, яшьлекне сагынуы чагылыш тапкан. Текстларның төзелешен ныклап өйрәнү – Мөхәммәт Мәһдиев осталыгын ачуга, заман сулышын тоярга ярдәм итә [33, 181 б.].

Димәк, тәнкыйтьче, галим, Татарстан Республикасы халык язучысы М. Мәһдиев кыска һәм нәтиҗәле гомер кичергән. Үзенең буындаш-каләмдәшләреннән ул әдәбиятка озаклабрак һәм катлаулырак юл үтүе белән аерылып тора. Ул үзенең укучысына “Без – кырык беренче ел балалары” повесте, “Каз канатлары”, “Кеше китә – җыры кала”, “Торналар төшкән җирдә”, “Мәңгелек яз”, “Бәхилләшү” кебек һәркайсы үзенчә яңгырашлы, халыкчан рухлы, ***камил телле әсәрләре*** белән таныш. Язучы үзенең әсәрләрендә туган җиргә, аның хезмәтчел һәм тыйнак кешеләренә мәхәббәт һәм хөрмәт хисләрен чагылдыруга басым ясады. Аның укучысы әлеге әсәрләрне бүгенге көндә дә яратып укый.

М. Мәһдиев әсәрләренең эчтәлеген баеткан, торган саен көчлерәк яңгыраш ала барган бер юнәлешне – аның туган авыл темасын үзәктә тоткан әсәрләре тәшкил итә. Туган авыл. Туган урман. Чыннан да, нинди зур мәгънәгә ия бу сүзләр. Чөнки һәр кешегә үз туган ягы, туган авылы, туган туфрагы кадерле. Гаҗәеп матур, искиткеч гүзәл безнең туган авылыбыз җирләре. Туган авылының төрле чәчәкләр белән бизәлгән киң болыннарына карап туя алмыйсың. Көмеш сулы елгаларының, саф һавалы урманнарына сокланмыйча мөмкинме?

Шулай итеп, язучы үзенең әсәрендә туган җиргә, аның тырыш һәм тыйнак кешеләренә мәхәббәт һәм хөрмәт хисләрен чагылдыруга аеруча басым ясады.

**М. Мәһдиев әсәрләрендә авыл кешеләренә хас сөйләм үзенчәлекләре**

Халыкның иң зур байлыгы, иң кадерле рухи хәзинәсе, һичшиксез, аның теле. Чыннан да, тел байлыгы ярдәмендә генә халык үсә, яши. Татар халкының рухи хәзинәсе бик тирән һәм хәзерге татар телебез тел-сурәтләү чараларына бай: метафора, метонимия, эпитет, синекдоха, гипербола, литота, мәкаль-әйтемнәр, синтаксик фигуралар һәм башкалар. Аларның укучы күңелендә эстетик зәвык, матурлык тойгысы, хис тудыруда әһәмияте зур [9, 25 б.].

Чыннан да, М. Мәһдиев әсәрләрендәге персонажларның теле искеткеч бай һәм үзенчәлекле. Аның әсәрләрендә чын мәгънәсендә әдәби тел дә, халык сөйләме дә, аерым диалектларда гына кулланыла торган сүзләр дә, рус теленнән кереп, авылча

татарлаштырылган яки, киресенчә, рус акценты белән әйтелгән татар сүзләре, синоним, антоним, фразеология, искиткеч үткен канатлы сүзләр – барысы да бар [9, 26 б.].

М. Мәһдиев үзенең әсәрләрендә авыл кешеләренә хас сөйләм үзенчәлекләрен чагылдыруда ***җирле сөйләм*** сүзләрен уңышлы куллана.

“Абый, *имә*, безнең класс малайлары тимер көрәкләрне кайрыйбыз дип әйтәләр” (33, 14 б.).

“Безнең авылда гына майны шулай *гөрәнкәләп* үлчиләр” (33, 16 б.).

“*Суң* менә үзең уйлап кара, – диде ул күз яшенә буылып, – ирем ярты-йорты сәламәтлеге белән әле ун-унбиш көн генә шушы чардуганны рәтләп кайтты” (33, 60 б.).

Язучының әсәрләрендә кулланылган ***мәкаль һәм әйтемнәр*** фикер үткенлеген, сөйләмнең кыскалыгына ирешергә чара булып торалар һәм эчтәлекне ачарга ярдәм итәләр.

“Бәла дигәнең агач башыннан түгел, адәм башыннан йөри бит” (33, 62 б.).

“Җитмәсә тагын аптырама, илдә чыпчык үлми” (33, 61 б.).

“Әти белән аларның борчаклары бик пешеп җитми, син күз-колак бул” (33, 59 б.).

“Юк дим, юк. Сез нәрсә, ул хәтле минем башыма тай типкән дип белдегезме?” (33, 63 б.).

М. Мәһдиев әсәрләрендә авыл кешеләренә хас сөйләм үзенчәлекләре турында сүз алып барабыз икән, ***рус теленнән кереп авылча татарчалаштырылган*** яки, киресенчә ***рус акценты белән әйтелгән татар сүзләре*** турында язмыйча һич ярамас. Бу лексиканы кулланып, язучы геройлар сөйләмендә үз максатына ирешә һәм юмористик төсмерле сүзләрне аеруча яратып куллана.

“Мин торып йөгердем, бер хат, берничә газета алып килдем, шакып бүлмәсенә кердем дә, русча ярып, аңа:

– Хәлим Фаттахович, вот *принесел* дидем. Өлкән укытучы буыла-буыла, йөткерә-йөткерә көлде” (32, 54 б.).

– “Менә безнең мөселман диненә чыкмый ул, мин сиңайтим... Бер көнне ат *духтыры* Чтапанов белән бәхәсләштек. Менә, мин әйтәм, бәхәскә китсә, дим, мин аягымны чайкыйм да эчәм... *Птамушто*, безнең мөселман тәһәрәтсез йөрми дим” (33, 62 б.).

“Зур шатлык Шәяхмәтне урамга куды.

– Һе, кара син аны, безнекен әйтәм, Гернадирмени! Икенче генә бит, ә! Мин үзем дә стройга өченче булып баса идем. Стало быйть, *паруда* шундый” (33, 75 б.).

М. Мәһдиев әсәрләрендә әдәбиятта кабатланмаган ***юмористик тезмәләр*** зур роль

уйлый.

“Миләр катып калган, аларны кыймылдатмаганга өч-дүрт ай” (33, 19 б.).

“Миләрдә ике игенә сыр бар: аларның берсе ашау, икенчесе кан койгыч сугыш турында” (33, 19 б.).

Язучының әсәрләрендә гиперболалар уңышлы кулланыла.

“Егетләрнең берсе аеруча таза, анысы Фәрит исемле иде, ул көненә дүрт-биш кило сыер ите ашап шул дәрәҗәдә тазарды ки, башын борганда арка-җилкә белән тоташтан борыла иде” (32, 55 б.).

“Бүлмә ишегеннән Шәяхмәт олы якка күз салды. Бер якта – Нәриманның дуслары – барысы да диярлек шоферлар, тракторчылар. Кара беләкле, таза егетләр. Әнә берсе – көрәшче. Иртәгә ул Ташлытауда көрәшергә тиеш. Кызып алган – унлап кеше өчен өстәлгә әзерләп куйган балыкны тәлинкәсе белән таптып китерде дә җимереп ашап бетерде” (33, 69 б.).

Сөйләмгә төгәллеккә ирешүдә, эчтәлекне ачуда ***синонимнар*** уңышлы куланыла. Әгәр мәгънәне берничә мәртәбә бер үк сүз белән кабатлый башласаң, сөйләмнең яңгырашы кими, коры чыга, сөйләмдәге матурлык югала, уңышсыз кабатланулар барлыкка килә [56, 141 б.].

Моннан котылу юлы – телдәге ***мәгънәдәш сүзләрдән*** оста файдалану. М. Мәһдиев бу хәзинәдән оста файдалана.

“Минем сезне культуралы, белемле кешеләр итеп күрәсем килә” (33, 31 б.).

“Ун минут элек кенә бу малай коридорда бөтенебезне чалып егып, изеп йөргән иде” (33, 32 б.).

“Ипи салу – хатын-кызның бер тәүлеккә сузылган эше. Бу тәүлектә йортта зур, тыныч, шатлык, тынлык, тантана” (33, 414 б.).

Әйтеп үтелгәнчә, М. Мәһдиев әсәрләрендә чагыштыру алымы белән ясалган юмор стиле хас. Чагыштырулар геройлар сөйләменә җанлылык, эмоциональлек бирә, автор хикәяләвенә төрле сүрәтле төсмерләр өсти.

“... без – егетләр, бәпкәләрен тилгәннән саклаган ата каз кебек авыл егетләренннән кызларыбызны сакладык, шулай да бер “хитрие” башта безнең егетләр белән дуслашып алды да Эльвира исемле кызыбызга ияреп кайтты” (32, 58 б.).

– Асыгыз, кисегез, мулла абзый җаным, яратмыйм шул уҗым бозавын, – дип кыз калку күкрәкләрен калтыратып елады” (33, 62 б.).

“Тәгәрәп үлсәм үләрмен, сез уҗым бозауларын рәткә салырмын” (33, 62 б.).

М. Мәһдиев теле – милли байлыгыбыз. Ләкин язучының әсәрләрендә ***рус сүзләрен кушып, сөйләм телләрен үзгәртергә маташучы геройларны*** табарга була. Әлеге геройлар татар телен рус сүзләре белән чүплиләр.

– “Мине сезнең авылга вәкил итеп җибәрделәр. Үзең уйлап кара: белергә тиешме мин монда в чем дело, или юкмы? Нинди урын бу? Ник монда карт-коры килә? Почему алай кадерле булгач аны зиратка күчермисез? Колхоз басуында бу нинди музей, понимаете ли” (33, 81 б.).

“Шул секунд эчендә Улибаева бу кара битле, зур кара күзле авыыл егетеннән үзенең җиңелгәнен сизде. Прокурор башың белән. Ул башлыгын алып киде. Тавышы калынайды.

– Ә вообще, Вәлетдинов, ужасный кеше син. Сине берни белән дә не прошибешь... Синең үз кирелегең кире. Терпеть не могу” (33, 146 б.).

***Антонимнар*** – әсәргә зур мәгънә, төгәллек һәм өстәмә яңгыраш бирәләр.

– “Юк, иптәш Улибаева, көн чәчтек, төн чәчтек, танктан башка гына” (33, 147 б.).

“Күпкә түзгәнне азга түзмичә,

Ятларга каласың”(33, 150 б.)

“Рәхмәтләр төшсен Ленинга –

Ике сыер саудырды;

Ләгънәт төшсен Сталинга –

Бер кәҗәгә калдырды”(32, 60 б.)

М. Мәһдиев әсәрләрендә геройларның күңеле моң белән тулы. Автор һәр әсәрендә дә җырны заманның сурәтләнә торган вакыйганың, персонажларның символикасы буларак куллана.

Мәсәлән “Кеше китә – җыры кала” әсәрендә, Шәкүр карак эләккән елны Заһир, русский гармунын колак янына күтәреп мехларын өзәрдәй итеп мәҗлесләрдә җырлый:

“Шәк-күр кар-рак зам маын дай

Бик күп атлар урлаган шул,

Төрмә тәр-рәз зәләрен нән

Ут-тырган дай ел-ла ган”(33, 91 б.).

Әлеге җырның көеннән, бу җыр куплетыннан без Заһирның эчке күңел дөньясын, газап-сагышлары белән очрашабыз [32, 156 б.].

Герман сугышында әсир булган, соңыннан туган җиренә кайткан Шәйхи хәлфәнең “Герман көе” сугышка яңа чыгып китүчеләрнең дә уйларына тәңгәл килә. Аларның авыл белән, туганнар белән саубуллашулары, җыр килеп кушылгангадыр, йөрәкне тетрәндерә:

Без китәбез ахырылай

Чуен юллар аркылы шу,

Өстемдәге ак күлмәгем

Кәфен булыр, ахыры (33, 170 б.).

М. Мәһдиев әсәрләрендә җырны заманның, сүрәтләнә торган вакыйганың, персонажларның ***символикасы*** буларак куллана [51, 16 б.].

Югарыда карап үтелгән мисаллардан кхренгәнчә, М. Мәһдиев әсәрләрендәге персонажларның теле искиткеч бай һәм үзенчәлекле.

Әгәр әлеге тел бизәкләрен төшереп калдырсаң, әсәр геройларының теле никадәр ярлы, эчтәлексез булыр иде.

Татар теле моңлы тел. М. Мәһдиевнең бу әсәрләрендә исә моңсу гына түгел, ул гаҗәеп дәрәҗәдә моңлы да. Автор табигатебезнең һәм кеше күңеленең бөтен үзгәрешләренә нәкъ менә киң күңелле татар кешесе булып карый ала, Мөхәммәт үз җиренең тулы хокуклы улы, җир өчен, ил изгелеге өчен җаны көя торган, күңеле сулкылдап җылый ала торган чын кеше. Бер үк вакытта ул гайрәтле сугышчы да, иманыбыз өчен бил баглап алышка да чыгарга әзер.

Шулай итеп, М. Мәһдиев халыкның күпгасырлык хәзинәсеннән белеп, оста тоемлап яза. Теле шома, җор, аңлаешлы, саф. Язучы татар теле мөмкинлекләреннән шулкадәр оста файдалана, әйтерсең лә сүзләргз тылсымлы канатлар куя.

Фәнни эшкә Мөхәммәт Мәһдиев иҗатында авыл тормышының бирелешен күзәтү максат итеп алынды.

М. Мәһдиев иҗатында авыл тормышының бирелешен, әсәрләрендә күтәрелгән тема, проблемалар, ***М. Мәһдиев әсәрләрендә авыл кешесе сөйләменә хас үзенчәлекләр яктыртылды.*** Татарстанның халык язучысы, Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе, үткен каләмле тәнкыйтьче һәм күренекле әдәбият галиме Мөхәммәт Сөнгат улы Мәһдиевнең иҗаты бай, күпкырлы. Эшебезгә куйган максатка тулырак ирешү максатыннан язучының “Кеше китә – җыры кала” повесте һәм авыл укытучылары тормышына багышланган “Фронтовиклар”, “Без – кырык беренче ел балалары” әсәре, “Бәхилләшү”, “Кеше китә – җыры кала” әсәрләренең эчтәлекләре белән якыннан таныштык.

М. Мәһдиев әсәрләрендәге ***персонажларның теле искеткеч бай*** һәм үзенчәлекле. Аның әсәрләрендә чын мәгънәсендә әдәби тел дә, халык сөйләме дә, аерым диалектларда гына кулланыла торган сүзләр дә, рус теленнән кереп, авылча татарлаштырылган яки, киресенчә, рус акценты белән әйтелгән татар сүзләре, синоним, антоним, фразеология, искиткеч үткен канатлы сүзләр – барысы да бар

Үзенең кабатланмас әсәрләрендә авыл халкының киң күңеллелеге, төшенкелеккә

бирелмәве, бер-берсенә игътибарлы һәм мәрхәмәтле булуы, ата-бабаларына ихтирамлылыгы һәм башка бик күп күркәм сыйфатларын сурәтләү аша М. Мәһдиев татар милләтенең XX гасыр уртасында сакланып калуын һәм үсешен бары тик авыл, бигрәк тә аның халкы, теле һәм мәктәбе генә тәэмин итте дигән фикерне раслый, һичшиксез, М. Мәһдиевнең моңа кадәр яратып укылган әсәрләре киләчәктә дә үз укучыларын табачак һәм матур фикерләре белән дулкынландырачак.

М. Мәһдиев әсәрләрен өйрәнү, алардагы ***тел-сурәтләү чараларына анализлау*** нәтиҗәсендә эшебезгә куелган максатка ирештек.

**Әдәбият исемлеге**


1. Әхмәтҗанова, Т.Г. Кеше китә – җыры кала / Т.Г. Әхмәтҗанова // Мәгариф. – 2004. – № 12. – 97 б.

2. Әсәдуллина, Э.М. Сөйләмдә сурәтләү чаралары / Э.М. Әсәдуллин // Мәгариф. – 1997. – № 5. – 25 б.

3. Гыйләҗев, А. Сайланып чыккан сүзләр... / А. Гыйләҗев. – Казан : Тат. кит. нәшр., 1996. – 140 б.

4. Мәһдиев, М.С. Сайланма әсәрләр : 3 томда. 3нче том. / М.С. Мәһдиев. – Казан : Тат. кит. нәшр., 1996. – 640 б.

5. Мәһдиев, М.С. Бәхилләшү: повестьлар / М.С. Мәһдиев. – Казан : Тат. кит. нәшр., 1990. – 640 б.

6. Сепперова Р.Н. М. Мәһдиев әсәрләрендә җыр символы / Р.Н. Сепперова // Мәгариф. – 2001. – № 7. – 16 б.

7. Фәттахов, И.Ф. Көлә белеп көлә иде / И.Ф. Фәттахов // Мәгариф. – 1999. – № 4. – 22 б.



*Имамиева Сәмирә, 3 нче сыйныф, Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре “54 нче гимназия”муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчесе: Шәрифҗанова Ләйсән Касыйм кызы, башлангыч сыйныф укытучысы*


**Батырлыкта – матурлык**

Без онытмыйбыз сине,
Белмәсәк вакытында кадрең,
Инде котлыйбыз сине...

**Туган илем, барлык рухым сиңа –**
**Барысы синең өчен!..**

дип язган Абдулла Алиш үзенең “Туган илгә” исемле шигырендә. Шул аңлашыла: бу сүзләрне язганда, ул үзе иҗат иткән шигырьләрне, хикәяләрне, пьесаларны, әкиятләрне күздә тоткан. Туган илне яратуын, аңа тугры булуын да әйткән. Ул беркайчан да намусына тап төшермәгән, дошманнан курыкмаган, аларга каршы яшерен көрәштә катнашкан, шигырьләр язарга да үзендә көч тапкан.

**Нигә бу кадәр сөям илемне?**
**Җырына күмеп тирбәтте мине,**

дип әйткән Абдулла Алиш үзенең “Сагынам илемне” дигән шигырендә. Шул аңлашыла: туган як, Туган ил автор өчен бик кадерле. Шуңа күрә яратуы да бик көчле. Ратканга сагына да. Шигырь юлларында әйтелгәннәр дә – шуңа дәлил.

“Абдулла Алиш һәм аның көрәштәшләре үлемне батырларча каршылыйлар. Алиш өчен иң кадерле нәрсә – Туган ил, иң бөек максат Ватанга хезмәт итү иде. “... Без соңгы сулышыбызга кадәр халкыбызга тугрылыклы булып калабыз”, – ди ул Берлин төрмәсендә язган хушлашу хатында. Җәзалап үтерер алдыннан кулларын Коръәнгә куеп, якты дөнья белән, газиз халкы белән хушлашу да шуны раслый...”

**Батырлыкка илткән юл.**

Абдулла Алиш (Габдуллаҗан) Спас районының Көек авылында 1908 нче елның 15 нче сентябрендә туган. Әтисе Габделбари өчен бик көтеп алган малай була ул. Әтисе үз улы тугач: “Нигез иясе, нәсел дәвамчысы булыр дип, Аллаһтан сорап алган ир бала ул”, – дип әйтә Габдуллаҗанның әтисе киң күңелле, белемле кеше була. Балаларын эшкә өйрәтә, аларны укытырга тырыша. Әнисе дә бик белемле, изге күңелле кеше була. Ул шигырьләр яза, бәет-мөнәҗәтләр чыгара.

Габдуллаҗан бик кечкенәдән үк китаплар ярата. Биш-алты яшьләрендә вакытта, укый-яза белмәсә дә, ул балалар өчен чыгарылган әкият китаплары
җыя башлый. Ул ике-өч тиен акчасы булса да, аны китап алырга дип саклый. Бервакыт әтисе аңа “Кызыл калфак” исемле әкият китабы алып бирә. Габдуллаҗан, бу әкиятне берничә кат олылардан укытып, хәтерендә калдыра. Соңрак, китап юлларыннан бармагын йөртеп, аны башкаларга да “укый”.

Әтисе Габдуллаҗанны хәреф танырга өйрәткәч, башта үз авылы мәктәбенә, аннан соң унбиш чакрым ераклыктагы Ямбакты авылы мәдрәсәсенә илтә. Анда әтисе ягыннан туганы Габделәхәт Алишевта укый. Монда халык авыз иҗатын өйрәнә. Шигырьләр яза. Олырак шәкертләр белән аралашып, күп нәрсәләрне аңлый башлый.

Габдуллаҗан Бураково авылындагы рус мәктәбендә дә һәм Спаста укыганда да шигырьләр яза. Ә техникумда һәм Казан дәүләт педагогия институтында укыганда,

мәкалә, шигырь, хикәяләр иҗат итә. Фатих Кәрим, Һади Такташ белән аралаша. Әдәбиятка якыная. “Бөтен иҗатымны балаларга багышларга телим,” – ди ул.

Абдулла Алиш – батыр кеше. Илсөяр Сөнкишева әйткәнчә, “батырлык үзеннән-үзе тумый ул. Кеше аңа бөтен гомере белән еллар аша килә”. Димәк, Абдулла Алишның бөтен тормышы, иҗаты – батырлыкка килү юлы ул. “Батырлыкта – матурлык”, – ди халык. Батырлык ул – авырлыкларны җиңә алу, иҗат итү, кешеләргә кирәкле сүзләрне әсәрләрдә әйтә белү, дошман алдында баш имәү...

**Язучы да Алиш, батыр да**

**“Энҗе бөртекләренә тиң” әкиятләр.**

Абдулла Алишның язучылык таланты әкият жанрында киң ачыла. Аның беренче әкияте “Капкорсак патша” “Пионер каләме” журналының 1934 нче елгы 1 нче санында басылып чыга. Әкиятне укучылардан бик күп хатлар килә. Шуларның кайберләре “Яратып укыдык”, “Китап булып чыксын” дигән исемнәр астында басылып чыга.

Абдулла Алиш әкиятләренең темасы төрле, аларда вакыйгалар бик кызыклы, шуңа күрә тиз укыла һәм истә кала.

“Яшь ленинчы” газетасының 1939 нчы елгы 1 нче февраль санында язучы “Ана әкиятләре” сериясен башлап җибәрә. Балаларга тәрбия бирүне бурыч итеп куя.

Күренекле галим һәм язучы Гази Кашшаф Алиш әкиятләренең һәрберсен “энҗе бөртекләренә” тиңләп, аларга югары бәя биреп яза: “...Абдулла Алиш та, түземлелек белән баласына тәрбия бирүче ана кебек, баланың рухын сафландыра, күңелен нурландыра торган фикерләрне әкият теленә салып бирде. Аның “Ана әкиятләре” сериясенә кергән әсәрләре шундый изге максаттан чыгып язылганнар”

“Әкиятләрдә сөйләнерлек батырлык белән тулы совет чынбарлыгы турында әкиятләр тудырасы иде. Чорыбызның фантазиясе, үткәне, киләчәге, бөек легенда булып, яңа буыннарга барып җитсен иде...” – ди Абдулла Алиш “Совет әкияте тудыру юлында” исемле мәкаләсендә.

**Абдулла Алиш – батыр язучы.**

Абдулла Алиш максатына ирешә. Әкиятләрдә сөйләнерлек батырлыкны тудырган сыйфатлар турында яза. Үз телең, динең, гореф-гадәтләрең турында сөйләргә ярамаган заманда: “Телне, динне, гореф-гадәтләрне сакларга, өйрәнергә, үстерегә кирәк”, – дигән фикерне әкиятләргә яшерә. Фикерне яшерен рәвештә әйтергә мәҗбүр булу – беренчедән, совет чынбарлыгы инде ул, икенчедән, авторның осталыгы да. Абдулла Алиш әкиятләрен укыгач, һәр кеше, вакыйгалар һәм персонажлар турында фикер йөртеп, үзе нәтиҗә ясый, нинди хәзинә яшерелүен аңлый ала.

**Хәзинә яшерелгән әкиятләр**

“Нечкәбил” әкияте: “Шашка шакмаклары төсле тезелеп киткән йортлар. Ул йортларда яшиләр кортлар,” – дип башланып китә . Матур йортларда яшәүчеләр бер телдә – үз телләрендә сөйләшәләр-аралашалар. Йорттагы бөтен эш эшче кортлар җилкәсендә: алар бал җыялар, балавыз сузалар, бала тәрбиялиләр, йорт эшен дә эшлиләр, гореф-гадәтләрне саклыйлар. Үзләре бик көчле булалар, дошманга каршы да торалар.

Эшче кортлар белән ана корт идарә итә. Балавыз төсле соры, озынча гәүдәле, кыска канатлы, бөтен ояда бердәнбер булган ана корт – Ил-йортта  патша. Ул үз илендә тынычлык, тәртип булсын өчен тырыша.

Матурлык булган җирдә ямьсезлек тә яши, кызганычка каршы. Ил-йортта да бар андый күренешләр. Әнә юан сорыкортлар, симереп, эшче кортлар ташыган балны ашап, кикереп яталар бит. Саранча, черки, кигәвен, энә карагы кебекләр дә янәшәдә генә. Бай ил-йортка кызыгучылар да әллә ни читтә йөрми икән...

“Нечкәбил” исемле әкияттән шул аңлашыла: гаилә яисә ил нык булсын өчен, бердәмлек булырга, кешеләр  эш яратырга тиеш, туган телдә аралашырга һәм әдәп сакларга кирәк. Абдулла Алиш әкиятләре менә шуларны кечкенәләр күңеленә сеңдерә, аңына сала. Болар – хәзинә, әкияткә яшерелгән хәзинә. Алай гына да түгел, без саклыйсы, киләчәк буыннарга тапшырасы хәзинә.

**“Сертотмас үрдәк”.**

Сер саклый белмәгән кешене “сертотмас үрдәк” диләр. Абдулла Алишның “Сертотмас әкиятендәге” үрдәккә охшатып инде, әлбәттә. “Ишеттеңме бер яңа хәбәр? Сиңа гына сер итеп сөйлим”, – дип башлап китә торган булган ул сүзен. Хуҗасы, урманга китәргә җыенгач: “Өйдә юклыгымны берәүгә дә белдермәс булыгыз!” – дигән. “Нигә белдермәскә кушты икән?” – дип, үрдәк йөдәп чыккан, ләкин ни өчен икәнен һич төшенә алмаган”.

Хуҗасын эзләп барганда, юлында очраган Керпе аңа: “Очраган берәүгә серләреңне сөйләмә. Сереӊ эчеңдә торса, йортың тыныч булыр, җимерелмәслек нык булыр”, – дигән. Керпенең бу акыллы киңәшенә үрдәк һич колак салмаган. Керпенең акыллы киңәше – аны йөдәткән сорауга җавап бит инде ул, югыйсә.

Тирә-юньдәгеләрнең барысы да Керпе төсле түгел бит, Куян, Аю, Бүре, Төлке кебек икейөзле, үзләрен генә кайгыртучылар да очрый, кызганычка каршы.  Роберт Миңнуллинның “Төрле кешеләр була” дигән шигырендә бу хакта әйтелгән:

Төрле кешеләр була:
Бүре кешеләр була,
Көлке кешеләр була,
Төлке кешеләр була...

“Сертотмас үрдәк” әкиятендәге үрдәк йорттагы барлык серләрне сөйләп йөрүе сәбәпле һәлак була, йортны куркыныч астына куя. Ярый әле, Хуҗа уяу кеше була, ерткычларга каршы һәр җирдә киртә куя. Вакытында кайтып кереп, йортны туздырылудан коткара.

“Сертотмас үрдәк” әкиятеннән шул аңлашыла: уяулык, сизгерлек, ил-йорт серен саклый белү – җаваплы һәм изге бурыч, намус эше. Шуңа күрә кеше үзендә матур сыйфатлар тәрбияләргә, начарларыннан арынырга тиеш. Бу – автор фикере: әкияткә яшерелгән хәзинә.

**“Кем көчле?”**

Абдулла Алиш “Кем көчле?” дигән әкият ахырында: “Кем көчле?” дигән бәхәс бетмичә калды. Сез, бәлкем, аны үзегез бетерерсез, кем көчле икәнен әйтеп бирерсез”, – дигән...

“Кышын да үзенең яшеллеген җуймый торган нарат агачы астында түмгәк сыман бер өй калкып тора, ди. Аның эчендә берничә йөз халык тора икән”. Болар – кырмыскалар. Алар яңа өйгә күчү көнен шатланып бәйрәм итәләр. Килгән кунаклар, хуҗаларны котлап, ура кычкырдылар, кул чаптылар, алкышладылар.

Хуҗа кунаклардан: “Безнең арабызда көчле бөҗәкләр кемнәр алар?” – дип сорады һәм алардан: “Билгеле, кырмыскалар, дөньяда тиңе юк батырлар алар!” – дигән җавапны көтте. Ләкин кунаклар җавап бирергә ашыкмадылар. Һәркайсы үзләренең һөнәрләрен һәм үз батырлыклары турында сөйләргә тотындылар. Чикерткә-микерткә дә, Суалчан-оялчан да, Яфрак көясе дә, Күбәләк-түгәрәк тә, Нечкәбил дә сөйләде.

Бөтен сөйләнгән сүзләргә бәя бирәчәк һәм арасында кемнең көчле һәм иң файдалы икәнен күрсәтәчәк ана кырмыска авызын ачкан килеш катып калды. Урман эчен караңгылык басты. Бөҗәкләр булачак хәлне алдан ук сизенделәр. Шуңа күрә кайсы кая посарга дип йөгерделәр. Караңгы урманны ялтыратып, яшен уйнады. Һәм кинәт кенә көчле яңгыр да коя башлады. Шул сәбәпле, бәхәс бетмичә калды...

Кунакка килгән бөҗәкләрнең һәркайсы үзенчә файдалы, әлбәттә.

“Яхшылык эшлә дә суга сал: халык күрмәсә, балык күрер”,– ди халык.

Кызганычка каршы, бөҗәкләр мактанырга ярата. Аларга тыйнаклык җитми. Алай гына да түгел, кунаклар ялагайлар, куркаклар, ялганчылар. Берсе дә кырмыскалардан күп җәфа күрүен, күпләрнең алар тарафыннан үтерелүен сөйләми. Алар хуҗаларның кәефен җибәрергә теләмиләр, шуңа дөресен сөйләмиләр...

“Кем көчле?” дигән сорау һәр кешене уйландырырга тиеш.

Аллаһы Тәгалә барлыкка китергәч, Җир ныклы булмый: селкенеп тора. Аллаһ аны таулар белән беркетә. Димәк, җирдән дә көчлерәк тау бар. Риваять ителә:

- Тау-ташлардан да көчлерәк нәрсә бар?” – дип сорыйлар. Ул:
- Тимер, – ди.
- Тимердән нәрсә көчле?
- Ут.
- Уттан нәрсә көчле?
- Су.
- Судан нәрсә көчле?
- Җил.
- Җилдән нәрсә көчле?

“Кем көчле?” дигән сорауга җавап эзләүне дәвам итсәк: күңел дөньясы бай кеше.

Начар сыйфатлар артмасын өчен, кешеләр бозылып бетмәсен өчен, динне сакларга кирәк. Бу фикер – әкияткә яшерелгән хәзинәнең берсе ул.

**“Мактанчык Чыпчык белән тыйнак Сыерчык”.**

“Мактанчык Чыпчык белән тыйнак Сыерчык” әкиятендәге вакыйгалар чынбарлыкка бик якын.

Яз кунакларын – сыерчыкларны карт Чыпчык кәефсез каршы алды, “күңелсез иде, күршеләр булды” дип, үзе эченнән бераз шатланды. “Сайраулары белән колакны тондырып бетерерләр, рәхәтләнеп йокларга да ирек бирмәсләр, туктагыз дисәң дә туктамаслар, күрше димәсләр”, – дип уйланды.

Чыннан да шулай булып чыкты: сыерчыклар көне буе сайрадылар. Алар карт Чыпчыкны хөрмәт итми кебек: берөзлексез сайрыйлар да сайрыйлар, шуңа тынычлык юк.

Чыпчыкның моңа бик ачуы килде, ямьсез тавыш белән күршеләренә җикеренде: “Бөтен тынычлыгымны боздыгыз, сайраган булып, колагымны тондырдыгыз. Ичмасам, чыпчыклар төсле сайрый алсагыз икән, алардан да уздырсагыз икән...”

Җае чыккан саен, Чыпчык мактана бирде. Имештер, үзе карчыганы җиңгән, имештер, хуҗа мәчесенең күзен чукыган... Хәтта Песинең авызына эләгүдән Сыерчык коткаргач та, Чыпчык мактанудан туктамый. Сыерчыклар аңа болай диде: “Мактану һәркемне хур итә, тыйнак булуга ни җитә!”

Минемчә, кешеләр, халыклар бер-берсенә карата түземле булырга тиеш. Һәр кешенең, һәр халыкның үз теле, үз дине, үз моңы, үз гореф-гадәтләре бар бит. Үзеңнекен дә, башкаларныкын да хөрмәт итәргә кирәк. Кеше яисә халык, без яхшырак дип, үзен башкалардан өстен куярга тиеш түгел. Тыйнак, сабыр һәм түземле булырга, бер-береңне хөрмәт итәргә кирәк. Әкияттәге хәзинә – шул фикер.

**“Ялкаулык – хурлык, тырышлык – зурлык”.**

Бу әкияттә сүз чәчәкләр патшасы үткәргән ярыш турында. Ул ярыш алдыннан чәчәкләр патшасы: “Кем дә кем бал салырга яхшы савыт әзерләсә,ул савытта бал бер дә әчемәсә, барлык чәчәктәге балны шуңа бирәчәкмен”, – дигән. Бөҗәкләр бар да тырышып эшләгәнннәр, ләкин берсе дә әйбәт савыт ясый алмаган.

Шөпшә белән Бал корты иң соңгылар булып эшкә керешкәннәр, беренчелекне алырга өмет иткәннәр.

Бал корты көне буе эшли дә эшли икән. Шөпшә бик ялкау булган. Иртән әзрәк эшли икән дә, кояш кыздыра башлагач, оясына кереп йоклый икән. Шуңа күрә бал савытын да эшли алмаган.

Ярыш көне килеп җиткән. Бал корты балавыздан эшләнгән матур күзәнәкле бал савытын күтәреп очып киткән. Шөпшә дә үзенең аннан-моннан эшләнгән кәрәзен алып килгән. Чәчәкләр патшасы беренчелекне Бал кортына биргән һәм чәчәкләрдән бал җыярга бал кортларына рөхсәт иткән.

Әкияттән шул аңлашыла: көне-төне тырышып эшләгәч, бүгенгә эш торып торсын, ял итим әле димәгәч, бар авырлыкларны да җиңеп була икән. Бәхет үзеннән-үзе килеп керми бит. Бәхетле булу өчен тырышырга кирәк. Эшне дә аннан-моннан эшләргә ярамый. Үзең ошатырлык булсын. Үзеңә ошаган нәрсә – башкаларга да ошый ул.

**“Аерылганны аю ашар, бүленгәнне бүре ашар”.**

Бик матур бер болында ат көтүе йөргән. Бу атларның көтүчеләре булмаган. Бары тик үз араларыннан иң сылу, иң йөгерек, иң җитез Җирән Кашка гына көтүче хезмәтен үти икән.

Җирән Кашка беркөнне бик арыган, шуңа ятып бераз хәл җыйнарга, йоклап алырга уйлаган. Иптәшләренең барысын бергә җыйган да әйткән:

“Аерылсагыз, айга җитмәссез, бүленсәгез, бүген бетәрсез, бергә йөрсәгез,
рәхәт көн итәрсез”, – дигән.

Атлар Җирән Кашканың сүзен оныткannar, аның файдалы киңәшен тотмаганнар. Аерылып киткәннәр, Аюга очраганнар. Әй йөгергәннәр, әй йөгергәннәр атлар. Тирән чокыр эченә егылганнар. Аякларын сындырганнар.

Бүленеп киткән өчесенең каршына Бүре килеп чыккан. Явыз бүре бер атны тотып алган. Башкалары качып котылган.

Җирән Кашка бу хакта белгәч: “Күрдегезме сүземнең дөреслеген: аерылганнар аюдан өркеп һәлак булдылар, бүленгәннәр бүрегә очрадылар”, –дигән.

Бердәмлек булмаса, атлар гына түгел, халыклар таркала, бөтен дөньяга сибелә. Дәүләтләр таркала, җир белән тигезләнә. Аю, Бүре кебек дошманнар таркаулык килеп чыгуны көтеп

кенә тора бит. Шуңа күрә бердәм булырга кирәк. Бергә булганнар бәхетле, ил-йорт нык, халкы көчле була. Бу фикерләр – әкияттән табылган хәзинә.

**7. “Койрыклар”.**

“Койрыклар” әкиятендәге ерткычлар билгеләнгән беркөнне, койрык алырга дип, карт имән янына барырга юлга чыга. Кыр куяны көчле яуган яңгырга чыдамый, оясына кире кача.

Кыр куяны аюга: “Карт имәнгә барасыңдыр, үзеңә койрык аласыңдыр. Сиңа бу зур үтенечем, алып кайтмассыңны икән миңа бер койрык”, – ди. Бүре белән, төлкегә дә шул үтенечен белдерә. Тегеләр, вәгъдә биреп, алга таба элдерә.

Кайсы алдан килеп, кайсы соңга калып, үзенә койрык сайлый. Берсе дә Куянга койрык алмый.

Куян койрык көтеп бик зарыккан була. Мескеннең күңеле тула. Күңелсезләнеп утырганда, тирә-ягын күз яше белән тутырганда ишетә куян: “Вау да вау, мырау да мырау”. Эт белән мәче ду килеп сугышалар икән. Эт:

“Минем койрык иң яхшы!” – дигән. Мәче аркылы төшкән: “Минеке ише койрык дөньяда да юк!” – дигән. Әүмәкләнә торгач, мәченең койрык очы өзелеп чыга. Өзелгән койрыкны җил, тәгәрәтеп, куян оясына илтә. Куян аны үзенә койрык итә. Мәче белән эт арасындагы бу ызгыш мәңгелеккә китә...

Куянның ялкаулыгы шул дәрәҗәдә: хәтта койрык алырга да бармый. Үз язмышына битараф ул. “Алма, пеш, өзелеп, авызыма төш”, – дигәндәй, әзерне көтеп тора. “Берәү үз күзенә кергән бүрәнәне күрмәсә дә, кеше күзенә кергән керфекне дә күрә”, – ди халык мәкале. Куян да шундый: “Бу мондый, ул тегенди”, – ди, ә үзенең ялкаулыгын күрми. Башкаларга бик үк ышанып бетми, шикләнә, шуңа күрә үтенечен бер-бер артлы өчесенә белдерә.

Аю, Бүре, Төлке вәгъдәне үтәмиләр, ышанычны акламыйлар. Аларда җаваплылык тойгысы юк. Шуңа аларга хөрмәт бетә.

Эт белән Мәче мактанчык. Акыллы: “Юл куйдым!”, ә акылсыз: “Җиңдем!”, – дияр. Эт белән Мәче бер-берсенә юл куймый: койрык өзелеп төшкәнче сугыша да гомер буе ызгыша.

Кече яшьтән кешенең ышанычын яулап, кушылган эшкә җаваплы карап, хөрмәт яулап яшәргә тырышырга кирәк. Авторның бу киңәше – әкияттән эзләп табылган хәзинә.

**8. “Каз белән аккош”**

Аккош белән Каз, күршеләр булып, тыныч күлдә яши, балалар үстерә. Җәйнең матур бер көнендә Аккош белән Каз үз балалары турында сөйләшә.

Каз баласы, үзе зур булса да, кулына кашык тотып ашамый, әнисенең ашатуын көтә икән. Аккош баласы кыстатып та тормый, кашыкны үзе тотып, азыкны кат-кат чәйни, тәмле итеп ашый икән. Вакытында йоклый, вакытында һавага чыга, уйный, шуңа күрә алма кебек кызарып, матур булып үсә икән.

Беркөнне аларның балалары: “Велосипед алыйкчы!” – дип үтенә. Әниләре ризалаша, улларын ияртеп, кибеткә бара. Велосипед алу белән, Аккошның улы йөреп китә, ә Каз бәбкәсе бер атланып карый – булдыра алмый, икенче атланырга уйлый – егыла яза, өченче тапкыр атланырга тели – егылып ук китә. Сатучы аңа: “Син, акыллым, ашны аз ашыйсың, вакытында йокламыйсың, ахры, шуңа күрә син ябык, буең да кечкенә, шуңа күрә велосипедка аягың да җитми. Хәзергә өеңә кайтып тор, зур үскәч килерсең”,ди.

Хәзер инде, велосипедка аягым җитсен дип, Каз бәбкәсе азыкны да күп ашый, вакытында йоклый да, саф һавада да уйный, ди.

Максатка ирешү өчен, сәламәтлек – рухи һәм тән сәламәтлеге кирәк. Кешеләре сәламәт булса, йорт та, ил дә нык һәм көчле була.

Йомгак ясап, шуны әйтергә мөмкин:

1. Алиш әкиятләрендәге вакыйгалар кешеләр тормышына бик якын. Аларда хайваннар, кошлар һәм бөҗәкләр дөньясы сурәтләнгән. Барысы да кешеләр кебек сөйләшә, араларында яхшылары да, начарлары да бар.
2. Абдулла Алиш әкиятләрендә фикер ачыктан-ачык әйтелмәгән.
3. Беренчедән, автор әкиятләргә үзе яшәгән чорда әйтергә ярамаган фикерләрне яшергән. Вакыйгалар һәм персонажлар турында уйланып, аларны һәркем үзе таба ала.
4. Икенчедән, Абдулла Алиш әйтергә яраган фикерләрне дә яшергән. Алар – мәкальләрдә. Әйтәсе сүзне мәкальләргә яшерү – авторның осталыгы ул.

## Йомгак

“Абдулла Алиш әкиятләренә яшерелгән хәзинә” дигән тема буенча, алдан билгеләнгән максат һәм бурычларга нигезләнеп, тикшеренү эше башкарылды. Язучының тормыш юлы һәм иҗаты өйрәнелде. Абдулла Алишның сигез әкиятенә анализ ясалды: әкиятләргә яшерелгән хәзинә, ягъни авторның яшерен әйткән фикерләре ачыкланды. Куелган максатка ирешелде.

## Тикшеренү эше нәтиҗәләре

1. Тормыш юллары күп төрле. Кеше теләгәнен сайлый ала. Абдулла Алиш халыкка хезмәт итү юлын сайлаган. Язучының тормыш юлын һәм әкиятләрен өйрәнгәч, аның тыйнак, гади һәм ярдәмчел иптәш, чын йөрәктән балаларны яратып иҗат итүче язучы булуы хәтергә кереп калды.

2. Абдулла Алиш әкият жанрын яраткан. Аның максаты – әкиятләрдә сөйләнерлек батырлык белән тулы совет чынбарлыгы турында әкиятләр тудыру. Максатына ирешкән: әкиятләрдә сөйләнерлек батырлыкны тудырган сыйфатлар, батырлыклар турында язган һәм совет чоры чынбарлыгын ачкан.

3. Абдулла Алиш әкиятләренә яшерелгән хәзинә – ул чорда әйтергә ярамаган фикер, ягъни: "Туган телне, динне, гореф-гадәтләрне сакларга, бердәм булырга кирәк", –дигән фикер ул ("Нечкәбил")

4. Абдулла Алиш әкиятләренә яшерелгән хәзинә – ул заманда әйтергә яраса да, яшереп әйтелгән фикер ул. Автор андый фикерләрне мәкальләргә яшергән:

-"Агачны яфрак бизи, кешене хезмәт бизи" ("Нечкәбил");

-"Үзен-үзе мактаган – олы ахмак" ("Кем көчле?")

-"Ачу – аю, йотсаң – бал" ("Мактанчык Чыпчык белән тыйнак Сыерчык");

- "Астыртын астан кисә, өстән ямый" ("Койрыклар");

- "Акыл – иман"("Аерылганны аю ашар, бүленгәнне бүре ашар");

- "Күлне камыш бизи, ирне намус бизи" ("Тырышлык – зурлык, ялкаулык – хурлык");

- "Сер саклаган югалмас" ("Сертотмас үрдәк");

- "Сәламәт тәндә – сәламәт акыл", "максатка ирешү өчен, сәламәтлек кирәк" ("Каз белән Аккош").

**Кулланылган әдәбият**


Алишев А. Б. Мактанчык Чыпчык белән тыйнак Сыерчык. – Казан: Мәгариф, 2004. – 16б.

Алишев А. Б. Нечкәбил. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1989. – 14б.

Алишев А. Б. Койрыклар. – Казан: Татарстан китап нәшрияты,1990. – 19б.

Ганиев А. Ганиев Ф. Әкиятләр илендә. Абдулла Алиш әсәрләре буенча татар, рус һәм инглиз телләрендә әкиятләр һәм мультфильмнар җыентыгы. – Казан: ТДИ, 2015, – 36б.

Сөнкишева. И. Әсәрләр: 1 том / Абдулла Алиш. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2008, – 302б.

Хәйри Х. Язучы да Алиш, батыр да. – Казан: Мәгариф, 2001. – 95б.



*Кәлимуллин Ильяс, 7 нче сыйныф, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы «Каенлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*

*Җитәкчесе: Гарипова Лилия Рәүф кызы, татар теле һәм әдәбияты укытучысы, Гарипов Рәсим Фәиз улы,-тарих, җәмгыять белеме укытучысы*


**Төбәк сөйләмендә кушаматлар**

Тел белеменең, ягъни лексикологиянең барлык төр ялгызлык исемнәрен өйрәнә торган махсус тармагы- ономастика дип атала. Ономастика фәне: топонимика, гидронимика, оронимика, ойконимика, микротопонимика, антропонимика, этнонимика, зоонимика, космонимика, прагнотонимика, поэтик ономастика үз эченә алган. Мин антропонимика бүлеге һәм бигрәк тә антропонимиканың бер өлеше булган кушаматлар белән кызыксына башладым һәм эзләнүләрем белән уртаклашырга булдым.

**Эшемнең темасы**: "Төбәк сөйләмендә кушаматлар"

**Проектның актуальлеге**: кушаматларның тормышта очравын күзәтеп, кушамат тагылу сәбәпләрен тикшереп, кушаматларның ясалу төрләрен өйрәнеп, кушамат тагуның начар булуын башкаларга җиткереп рухи тәрбия алуда ярдәм икәненә төшендерү.

**Хезмәтемнең максаты** – төбәгебездә кешеләргә ияргән, авыл- урамнар исемнәре белән янәшә йөри торган кушаматларны өйрәнү.

Максаттан чыгып, эшне башкарганда түбәндәге **бурычларны** чишү өстендә эшләдем:

- тормышта һәм әдәби әсәрләрдә кушаматларның ролен күзәтү;
- кушаматларның тагылу сәбәпләрен тикшерү;
- кушаматларның ясалуларын өйрәнү;
- туган ягымда - Түбән Кама районы Каенлы, Кече Җирекле, Тоба, Үчкә авылларында - кулланыла торган кушамат төрләрен барлау;
-кушаматларның шәхес тәрбияләүдә нинди өлеш алып торуына мисаллар туплау.

Максатка ирешү юлында мин эзләнү, тикшерү, анализлау **алымнары** кулландым.

**Теманың өйрәнелү дәрәҗәсе:** проект эшенә тәкъдим ителгән теманы укыгач та, минем күңелемдә бихисап фикерләр туды. Эчтәлекне төрлечә ачарга мөмкин. Тарихи китапларда, энциклопедияләрдә, интернет чараларында бу тема төрлечә яктыртылган. Туган ягым турында язылган китаплар, кулъязмалар белән таныштым. Кушамат төшенчәсен тирәнрәк аңлау өчен сүзлекләр белән эшләдем. Төбәгебезнең аксакаллары белән очрашып, кушаматларның җәмгыятьтәге ролен күзәттем.

Мин шулай ук хәзерге вакытта да кушамат тагу модасы бар икәнлекне күрдем.

Һәр телдә кешегә эндәшү, атап әйтү, мөрәҗәгать итү өчен билгеле бер антропонимик төрләр бар. Антропоним термины (грекча- " кеше") кешеләрне атау өчен хезмәт итә торган исем, отчество( әтисенең исеме), фамилия, кушамат, псевдоним төшенчәләрен аңлата һәм билгеле бер телдә кешеләрне тулаем атау системасының теге яки бу категориясенә караган конкрет атау берәмлекләрен белдерү өчен хезмәт итә.

Кушамат термины “Татар теленең аңлатмалы сүзлеге”ндә түбәндәгечә аңлатылган: “Кушамат- кешедән көлеп, мәзәк өчен яки конспирация максатларын күздә тотып бирелгән икенче исем”. [1-299б].

Кушамат, я кешенең характерындагы үзенчәлекләренә карап, я берәр кызыклы хәлләрдән соң тагыла. Кайчандыр истә калырлык эш, гамәл башкарса, кушамат тагылырга мөмкин; тышкы кыяфәт буенча да кушаматлы буласың. Шулай ук, элек авылларда кеше күп яшәгән, бертөрле исемнәр куелган. Кешеләр, бер- берсеннән аерылып тору өчен, исем янына кушамат та куйганнар.

Кушаматлар нәселдән дә күчеп йөргән. Кайберсе кош- корт, терлек- җанвар исеменнән дә ясалган. Кайчакта кушаматлар фамилия ясагыч ролен дә үтәгән. Кайбер төбәкләрдә кушаматка фамилия ясаучы кушамат өстәмичә, кушамат үзе фамилиягә әйләнгән. Рус галиме Н.В Подольская кушаматка мондый төшенчә бирә. “Кушамат- антропонимның бер төре, үзенчәлекле характерга ия, аерым бер тормыш шартларына бәйле барлыкка килгән, кешегә бирелгән өстәмә исем.” [4-115б]. Бу төр исемнәрне түбәндәгечә бүлә: коллектив кушамат- аерым бер кешеләр төркеменә, гаиләгә, нәселгә, этник төркемгә бирелгән исем; шаярту кушаматы- кешене кимсетү, көлү максатында кулланылган исем; түбәнсетү кушаматы- кешене түбәнсетү максатында, сүз белән түбәнсетү өчен бирелгән исем; мәктәп кушаматы- мәктәптә укыган чорда бирелгән кушамат. [4-116б].

Кушамат турында кызыксынгач, мин үзебезнең төбәктәге кушаматларны өйрәндәм. Сезне туган ягымда очрый торган кушаматлар белән таныштыра башлыйм.

**Каенлы авылы буенча**

Безнең якта нәселдән- нәселгә күчә торган һәм шәхси кушаматлар байтак.

**Нәселдән күчүче**

1.*Бөкәч Нурулла* сарыкларны “Бөкәч- бөкәч,” – дип чакырганга тагылып калган. Бөкәчнекеләр нәселе.

2.*Дуңгыз Нурулласы* – дуңгыз көтүе көткәнгә. Хәзер малаена Дуңгыз Раифы диләр.

3. *Чүмеч Динмөхәммәте*- Динмөхәммәт абзый кырда җир сукалаганда чүмеч табып ала, гадәт буенча өч тапкыр “чүмеч таптым ”дип кычкырган. Хуҗасы күренмәгәч, өенә алып кайта. Нәселләренең дәвамчысы Булатка да Чүмеч кушаматы ияреп йөри.

4.*Японныкылар* – Сәлах бабалары рус- япон сугышында катнашкан. Нәселләрен японныкылар дип йөртәләр.

**Шәхси кушаматлар**

1.Каенлы авылында *Тартар Харисы* бар. Кечкенә вакытта Харис абзый, үзләре янынннан агып ятучы инеш буенда уйнарга яраткан. Анда тар- тар кошлары күп булган.

Харис иптәшләре беләнуйнамыйча, шул кошларга каршы : “Тар- тар,”- дип әйтеп утырган. Шуннан аңа Тартар Харисы дип әйтә башлаганнар.

*2.<u>Баку Садыйгы</u>*- Садыйк абый Баку шәһәрендә армия сафларында хезмәт иткән. Кайткач Баку шәһәре турында кеше саен сөйләп йөргәнгә бу кушаматка ия булган.

3.*<u>Пионер Исмәгыйль</u>*- Исмәгыйль кыска балаклы чалбар киеп йөргән. Урамга чыккач, авылның бер аксакалы аңа очрап: “Пионер булдыңмы әллә?”-дип сораган.

4.Нурислам абзый фин сугышында катнаша. Әсирлеккә төшә. Берничә елдан исән-сау өенә кайткач, урамда очраган авылдашлары белән : “Исәнме, комрад,”- дип исәнләшкән. Бу сүзне еш кабатлаганга абзыйны *<u>Комрад</u>* *<u>Нурисламы</u>* дип йөртә башлаганнар.

5. Каенлы авылы тарихы белән кызыксынучы, ветеран укытучы Саимә апа истәлекләреннән : “Энем Гамиргә яшь чагында Поручик дип йөртәләр иде. Сугыштан соңгы еллар. Илдә ачлык- ялангычлык хөкем сөрә. Әти Гамиргә иләп эшкәрткән тиредән тун тегеп бирде .Җиңенең эче ак тиредән тегелгән. Энем җиңнең эчен бераз бөкләп тышка чыгарып куяр иде.Киноларда гына күрергә мөмкин булган поручикларга охшап китте. Туганымнан көнләшүчеләр *<u>Поручик</u>* дип үрти башладылар. Кушаматның гомере озын булмады”.

Кушаматлар турында авылдашыбыз Флера әби сөйләгәннәрдән. “Элегрәк кушаматлар тагу бик еш күзәтелә иде. Аның сәбәбе бертөсле исемнәрнең берничә булуындадыр. Бер авылда бишәр Саимә, җидешәр Ибраһим, әллә ничә Харис, Исмәгыйль, Мәрьямне очратырга мөмкин. Әйткән чакта ничегрәк аерырга ? Билгеле, ниндидер аеру сүзләре табарга кирәк була.”

**Кушаматлар күбрәк түбәндәге юллар белән тагылган:**

1)*сәбәп буенча:* пионер Исмәгыйль, тартар Харис;

2)*исемнең бер өлешен генә әйтү:*Ибраһим- Ибрай, Сәләхетдин- Сәләх,Шәйхетдин-Шәйхи;

3) *нәсел буенча:* Шәкүр Рәхие, судья Ибраһим;

4)*Зәгыйфьлек- кимчелекне искә алып:*сукыр Миңлевәли,аксак Харис,чулак Габдулла;

5)*характерлар буенча:* кыдрач Харис;

6) *Кош- корт я җәнлек исемнәре кушаматка әверелгәннәре дә бар*: Бүре Гөлсеме, Песнәк Гарифы, Торна Миңлебае, Чәүкә Хәсәне, Аю Вагыйзы,Тартар Харисы, Дуңгыз Раифы һ.б.

Каенлы авылында кушаматлы кешеләр генә түгел, ә **кушаматлы урамнар** да бар

1)*<u>Базар урамы.</u>* Җомга көнне оештырыла торган атаклы Базар булган монда;

2)*Җүләрләр урамы.* Бик кызу канлы кешеләр яшәгәнгә. Үзара еш сугыша торган булганнар. Урамдашлар турында "җүләрдер болар,"- дип әйткәннәр.

3)*Дию Сөләйманы урамы.* Әлеге урамга, иң беренче булып, бик күп ашарга яратуы белән даны таралган Сөләйман килеп урнашкан. Кордашлары аның турында:" Дию урынына ашый. Бер утыруда бер түшкә үгез, мичкәсе белән әче бал, миче белән ипине юк итә ,"-дигәннәр.

4)*Котылдык урамы*. Бу урамга эти- әнисеннән аерылып чыккан малайларга йорт салганнар, ягъни башка чыгарганнар. Каенана – кайнатадан "котылган" киленнәр, әлбәттә, әлеге урамга Котылдык кушаматы такканнар.

Кушаматлар хәзер дә тагыла. Соңгы елларда каенлыларга "күләгә урынына" ияргән берничә кушамат белән танышып китәбез.

Ришель исемле малайга *Француз* кушаматы менә ничек тагыла.
Малай эти-әнисе белән Урта Азия ягыннан кайткан. Авылга килеп урнашу белән Ришельнең яшьтәшләре белән танышасы килгән. Урамга чыккач малайлардан кыймыйча карап торганда, берсе килеп аңа татарча эндәшкән. Тик ул җавап бирмәгән. Икенчесе русча исәнләшкән. Өченче малай, карап- карап торган да: "Татарча да эндәшмисең, русча да белмисең, әллә син французмы?"- дип кычкырып җибәргән. Шуннан Ришельгә Француз дип әйтәләр.

*Калач* Бу кушамат нәселдән күчеп йөри. Салих абзый бик тәмле итеп калач пешерә белгән. Үзе вафат булгач, малае- Миңлегалигә, аннары Разифка, ә хәзер оныклары Айнурга да Калач дип эндәшәләр.

Венера исемле кыз, "Пташка" конфеты ярата. Нәкъ менә шуңа да кызга *Птичкин* кушаматы тагылган.

Илнар исемле егетнең берүзенә ике кушамат : 1)*Крамр* -ул тышкы кыяфәте белән рус актеры С. Краморовка охшаган. 2)Бәләкәй чакта аны *Куян* дип тә йөрткәннәр, чөнки тешләре куянныкы кебек булган.

Гомумән, Каенлы халкын *Көртлекләр* диләр, чөнки алар беркая бармыйча, беркем белән аралашмыйча яшәргә тырышалар.Төп халык авылга 20 нче гасырның 70 нче елларында килеп урнашкан кешеләрне *Килмешәкләр* дип, ә 21 гасыр башында Урта Азия якларыннан кайтып төпләнгәннәргә, милләтенә дә игътибар бирмичә,*Кыргызлар* кушаматы белән эндәшәләр.

**Кече Җирекле** авылында кушаматсыз кеше юктыр.

Кушаматларны түбәндәге төркемнәргә бүлдем:

1)*Фамилиядән татарчалаштырып ясалган.* Яковлевлар-*Җәкәүнекеләр;*

2)*Кушаматтан фамилия ясалу*: Данилов- *Даный солдат-* нәселдән күчкән. Аларның ерак бабайлары 25 еллык патша хезмәтендә булган.

Морозов Иван дәдәй рус халкының “Эй мороз, мороз!” җырын җырларга яраткан. Нәселләрен *Мороз Иванныкылар* диләр.

3)*Исемне үзгәртеп* Федосей- *Пидучи*; Ольга- *Ульгуш*; Александра- *Санук*; Семен- *Симукай.*

4)*Тышкы кыяфәт һәм характер үзенчәлекләре* буенча Ап – ак чәчле Иван дәдәй булган. Балаларына да, оныкларына да (кайберләре кара чәчле булсалар да) *Акбаш* кушаматы ияреп йөри.

Артык кызу канлы гаиләгә-*Гәрәчнекеләр*; кечкенә буйлы гаиләгә- *Маймычлар*; миңнәре күп булган Станиславка- *Миңкә* дип йөртәләр.

*Кушаматлы урам*

Бер урыс гаиләсе Җиреклегә килеп урнаша. Ул яңа урамга нигез сала. Аның артыннан килеп шул урамга урнашкан кешеләрне Урысныкылар дип атыйлар.

**Тоба авылы буенча**

***Бер төрле исемнәрне кушамат ярдәмендә аеру***

Тоба авылында Фаиз исемле кешеләр берничә. Аларны да кушамат буенча аерып була.

Шуларның берсе- *Күрәзәче Фаиз.* Фаиз абыйның олы кызы Рузилә апа:

-Минем дә алдан күрү сәләтем бар яки бераз күрәзәлек итә алам ,- ди.

*Тырт Фаиз*- шаяртуны аңламыйча, тырт итеп кеше янынннан китеп бара торган булган.

*Чучар Фаиз-* Фаиз абый бик күп сөйләшергә яраткан. Аның турында : “Су чары кебек бертуктаусыз сөйләшә,”-дигәннәр. Су чары сүзе- чучарга әверелгән.

Габдулла исемле ир-атлар да күп булган. *Кайнар Габдулласы, Шәмә Габдулласы* кушаматлары белән аларны аерганнар.

*Өргечләр*- белсәләр дә, белмәсәләр дә теләсә нәрсә сөйләп, гайбәт таратып йөриләр. Кешеләрне котыртып, талаштыручы булганнары өчен Өргеч кушаматы тагылган.

***Һөнәрләре буенча***

Салих исемле ир- атларны һөнәрләре исеменнән ясалган кушаматлар белән аерып йөрткәннәр: *Монтер Салих; Тимерче Салих; Оста Салих.*

**Тобада *тышкы кыяфәткә карап кушамат тагу*** модасы көчле.

Башы олы булганга- *Олы баш*;

Борыны зур- *Танау*;

Борын сөяге сынып формасы үзгәргәнгә- *Трамплин;*

Бик яшьтән чәче агарганга – *Акбаш*.

Бу авылда ***исемнәрне үзгәртеп ясалган кушаматлар*** да бик күп. *Мөтә-* Мөдәррис; *Мыргый* –Миргасим; *Патыйк-* Расих; *Саескан*- Фәезхан; *Пәтыйк-* Фатих; *Типкый*- Рифкать; *Учмый-* Госман; *Чекет*- Җиһанша.

***Характерга карап*** ияргән кушаматлар нәсел буенча күчә:

*Күкертнекеләр*- күкерт кебек кабынып киткәнгә;

*Сагызлар* – Мисхәт абзый әзрәк аракы эчсә, теләсә кемгә бәйләнеп, сагыз кебек ябышы торган булган;

*Пәпәләр* – Миңнулла абый телсез булган, аның балаларының теле булса да бу кушамат тагылган.

*Җоркалар* – бабалары сугыштан кайткач, үзенең исемен үзгәртеп, Җорка (Юра-Юрка) дип әйткән.

Кушаматлар хәзер дә еш кушыла икән.

1)Алда әйтеп үткән *Сагызлар* нәселе белән *Күкертләр* нәселе кушылган. Кечкенә оныклары туган. Бәбине күрергә килгән бабай оныгына күз ташлаган да:

- Сөбханалла, гел *Сагыз* булган бу!- ди икән.

Кияү югалып калмаган, бабасына болай дип җавап биргән:

- Юк , бабай, *Сагыз* түгел, Ә *Күкертле- Сагыз* безнең малаебыз!

2)*Лелин бабай-* Васил абый мәктәптә бик яхшы укыган. Бөтен нәрсәне дә белгәнгә, иптәшләре аны Ленин дип йөрткәннәр. Картая төшкәч, Лениннан Лелин бабайга әверелгән.

**Үчкә авылы буенча**

Үчкә авылында ***җәнлек- җанварлар исеменнән ясалган кушаматлар*** күп дигән нәтиҗәгә килдем.

*Бүреләр* нәселе- бүре кебек усал булганга тагылган.

*Шукә*(щука- чуртан) кушаматы тарихы да бик кызыклы. Тимербай бабай оста балыкчы булган. Аңа еш чуртан эләгә икән. Ә бабай бу балыкны ашамаган, чөнки чуртанның тамагында крестка охшаган сөяк бар икән.

*Кәҗә Җәгүре-* Егор исемле абый кәҗәләре гел кычкырып торганга, төн уртасында чыгып, кәҗәне акырта-акырта башта кыйнаган, аннары суйган.

*Пошилар* нәселе – бернәрсә белән дә кызыксынмыйча, бернәрсә өчен пошмыйча яшәгән нәселгә *Пошиныкылар* диләр.

Кайбер кешеләрнең исемнәрен беркем дә белмәгән.Исемнәре дип уйлаган атамалар кушамат булуны белгәч, шаккатканнар: *Әүри*- Мөнәвәрә, *Тикай*- Тихон.

Шулай итеп, антропонимиканың бер өлеше булган кушаматлар турында шактый гына мәгълүматлар туплап, түбәндәге нәтиҗәгә килдем: кушамат тагу һәр төбәктә булган кебек,

безнең якта да күп күзәтелә икән. Кушаматларның нәселдән- нәселгә, буыннан-буынга күчеп йөри торганнарына да, тышкы кыяфәт; эш- гамәлләр аркасында да тагылганнарына да мисаллар китердем. Әдәби әсәрләрдә дә еш очраганына инандым.

Кушамат тагу, кушаматлы булу бик куанычлы хәл түгел инде. Мөхәммәт Мәһдиевнең Әсхәдуллин исемле герое кушаматка каршы көрәш ачып:

-Кушамат әйткән баланың авызына сугарга рөхсәт итәм,- дигән.

Кушамат таккан өчен Әсхәдуллин кебек сугышырга кирәкми анысы. Шулай да, кушамат кешене кимсетергә, рәнҗетергә мөмкин. Кушамат белән эндәшсәң, дустыңны, туганыңны, якыныңны югалту куркынычы янавын онытмаска, “Авызың ни әйткәнне колагың ишетергә тиеш,”- дигән гыйбарәне истә тотып, әдәпле, әхлаклы кеше булу өчен тырышырга кирәк икәнен аңладым. Кушамат такканчы, кешенең исемен хәтерләсәң яхшы булачак. Исем турында Миргазиян Юнысның “Шәмдәлләрдә генә утлар яна” әсәрендә Сәйрин Сәләхов әйткән түбәндәге фикер белән бик килешәм: “Исем сиңа гомергә бирелгән, ул бер генә, аның чисталыгын, аның ихтирамын сакларга тиешсең. Исем ул синең үзең генә түгел бит: ул- синең йөзең, ата- анаңның, ыругыңның, нәселеңнең йөзе һәм аларның байрагы. Исем ул- синең тормыш юлыннан күтәреп барган үз байрагың”.[5-30].

**Кулланылган әдәбият**


1.Ф.Ә.Ганиев, К. С. Миннибаев “Татар теленең аңлатмалы сүзлеге”, Казан, “Матбугат йорты”, 2005 ел, 299бит

2. Ө.Г. Миңнеханов Казан, Татарстан китап нәшрияты “Авылым тарихы- халкым язмышы”, 1993

3.М. Мәһдиев Казан, Татарстан китап нәшрияты, IV том, 2009 ел,194 бит,

4.Н.В. Подольская “Словарь русской ономастической терминалогии”, Мәскәү, НЛУ,1978, 115-116 бит

5.М. Юныс “Шәмдәлләрдә генә утлар яна”, Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1984 ел

6.Ф.Ш.Шәрәфиев “Туган авылым-Каенлым”; Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2002



*Кашапова Илүзә, 11 нче сыйныф, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы “Аерым фәннәрне тирәнетен өйрәнүле 15 нче гомуми урта белем бирү мәктәбе”муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчесе: Халикова Нурсинә Дәлиф кызы, Фәтхуллина Гүзәл Фәһим кызы, татар теле һәм әдәбияты укытучылары*


***Мин Тукайның дәвамчысы***

Мин Тукайның дәвамчысы,
Үз телем, татар теле.
Яшим мин Җәлил илендә.
Йөземдә татар йөзе.
Сөям Туфан  шигырьләрен,
Такташтан үрнәк алам.
Күңелемдә әнкәм сүзләре,
“Телең онытма, балам”.
Роберт, Шәүкәт абыйларның.
Киштәмдә китаплары,
Үз телем аша ачылыр,
Бәхетнең йозаклары.
Чулманында иңләп йөзәм,
Тыңлыйм Идел тавышын,
Зөя, Зәйләр саклый серем,
Саклый күңел сагышым.
Сәйдәш көенә җыр сузам,
Җырлыйм татар көйләрен.
Биесәм татар биюен,
Алсулана йөзләрем.
Милләтемә хезмәт итәм,
Әти-әни үрнәге.
Телне, динне саклап барам,
Мин бит татар гүзәле.

***Ямьле минем туган илем***

Ямьле минем туган илем,
Ак чәчкәле туган җирем,
Бигрәк якын күңелемә,
Баштан сыйпап искән җилең.
Якын миңа туган илем,
Мине көткән туган өем.
Кайда гына яшәсәм дә
Якын хәтта карың, җилең.
Ямьле минем туган илем,
Мин бит нәни кызың синең.

Шаулап үскән урманнарың,
Йөрәгемә якын, илем!
Якын миңа туган илем,
Иркен болын, тирән күлең.
Һәрчак хәтеремдә булыр,
Ай йолдызлы, тыныч күгең!

***Әнием коймаклары***

Кызарып пешә табада,
Әнием коймаклары.
Кайнатмага манып ашыйм,
Әй тәмле коймаклары.
Әни пешергән коймакны,
Әти дә бик ярата.
“Калдырыгыз миңа” диеп,
Әнә кычкыра апа.
Улым, кызым ашасын, дип
Әни пешерә коймак.
Ярата шул безне әни,
Үстерә шулай сыйлап.
Мин дә үсеп җиткәч, әни,
Коймаклар пешерермен.
Коймакларның иң тәмлесен,
Сайлап сиңа бирермен!

***Адәмнәр***

Адәм" исемен йөрткән вәхшиләрне,
"Ерткыч", диеп дуслар, атамыйк!
Урман хуҗалары, бүреләрнең,
Исемнәрен шулай таптамыйк.
"Ерткыч" сүзе алар өчен түгел.
Хәрефләре хәтта кызганыч...
Кем дип атыйк, андый вәхшиләрне?
Табалар бит каннан юаныч!
Адәмнәрнең кылган вәхшилеген,
Эшли алмый, аю, бүреләр.
Рәнҗетмикче, мескен хайваннарны,

Алар моңа лаек түгелләр.

Бүреләр бит чүплек кырларына

Туган балаларын ташламый.

Аюлар да газиз нарасыен,

Какмый, сукмый, суга батырмый...

Газизләрен алар туйдырырга,

Азык эзли, тырыша-тырмаша.

Гаиләсен бары яклау өчен,

Дошман бугазына ябыша.

Ә адәмнәр, ничек булса шулай,

Күңел ачу ягын карыйлар.

Бер көн кырган изге нигезләрен,

Йөз чөереп, дошман саныйлар.

Ерткычларның тормышлары башка,

Дуслыкның да кадерен беләләр...

Урлап түгел, хәләл көче белән,

Үз көннәрен шулай күрәләр.

Ә адәмнәр "дуслык" төшенчәсен,

Байтактан бит инде оныткан...

Ялган, хәрәм, фәхше күңелләре,

Җылылыгын күптән суыткан.

***Күзләрнең дә яме бар***

Күзләр җитте диеп моңсуланмыйк,

Күзләрнең дә яме бар әле.

Күзләрдә дә шашып сөйгән күңел,

Дөрләп янган йөрәк бар әле.

Күзләрнең дә матур көне була,

Көнләшерлек хәтта, язлар да.

Күңелләрдә сөю исән чакта,

Ямь табасың күзге аланда...

***Бүгенге дөнья***

Дөньялары хәзер бик үзгәрде,

Түрә безне сүгә, без түрәне.

Кешелекле булу хәзер кирәк түгел.

Намус белән хезмәт кую әрәм шөгыль.

Эшләгәннәр хәзер яхшы урын алмый,
Акыл белән фикер йөртү хак саналмый...
Ялтырамый кешеләрнең кылган эше,
Ялтырасын иң мөхиме авыз теше.
Куштан белән ялагайлар дөнья тулды,
Туры сүзләр, төпле уйлар онытылды.
"Эшли" диләр, алдап, урлап көн күргәнне,
Күрмиләр шул, көне-төне бил бөккәнне.
Элек урлау, алдашулар ят საналса,
Үзебез бит юл куябыз хәзер шуңа.
Ялган белем, ризык белән туенабыз.
Үзебез дә ышанмыйча, ышанабыз...
Кешеләрнең уй-хисләрен урлый-урлый,
Бер гаепсез кешеләрне хурлый-хурлый,
Алга бару өчен, дуслар, маташабыз.
Ак-караны аермыйча саташабыз.
Һәркем белә, яманлыкның бер чиге бар.
Намуслы да, намуссыз да елыйдыр зар...
Рәнҗетелгән күңелләрдән ни көтәрсең?
Төшсә әгәр башларыңа шул каргышлар!

***Тик сугышларбулмасын!***

Тик сугышлар булмасын!
Без, балалар, шушы җирнең,
Киләчәге туган илнең.
Тик тынычлык телибез,
Бәхет өчен яшибез!
Илдә тыныч, рәхәт булсын,
Хәсрәтләр кагылмасын.
Өйдә яшәү – бәхет булсын,
Тавыш гауга булмасын!
Әти-әни өйдә торсын,
Ялгыз кеше калмасын,
Кары, салкын җиле булсын,
Тик сугышлар булмасын!

Янда якын дуслар булсын,

Шатлык җыры тынмасын.

Тышта давыл, буран булсын,

Тик сугышлар булмасын!

Балаларның бер дә юкка,

Күз яше коелмасын.

Борчу килсә ул да китсен,

Сугыш кына булмасын!

Олылары олы булсын,

Кечеләр кече булсын.

Ишеп яуган яңгыр булсын,

Тик сугышлар булмасын!

***Язлар килә***

Язлар килә,дуслар, язлар килә.

Кояш чәчә җылы нурларын.

Яз килгәнгә микән, ул да көлә,

Шатандырып каен кызларын.

Язлар килгән саен, әллә нигә,

Йөрәк ярсып-ярсып җилпенә.

Күңел көтә нидер, күңел көтә,

Мелдерәмә булып түгелә...

Язлар килгән саен бар табигать,

Кышкы йокысыннан уяна.

Шатлык белән тулган күңелләрдә,

Сандугачлар гүя, моңлана.

**Мәкер**

Борын-борын заманда түгел, әле безнең көннәрдә, гади бер бәләкәй шәһәрдә яшиләр ди өч кыз. Шундый җитез, акыллы, пөхтә кызлар икән. Эшкә тотынсалар кулларында ут уйнаталар, сөйли башласалар бар кешене авызларына карталар, аларның җырларына, биюләренә бар кеше соклана, ди. Бу кызлар әле уку алдынгылары да икән.

Шулай күңелле генә көннәр, айлар, еллар үтә. Кызлар уңганлыклары, осталыклары белән бар кешене сокландыралар. Ә иң мөхиме, аларның шулай өчәү дус һәм тату булуы бар кеше өчен дә үрнәк була.

Ләкин, бу дуслыктан көнләшүчеләр дә булмый түгел, андый хәлләр очрый. Сөйлисе сүзебез дә менә шул турыда.

Бу хәл яңа ел кичендә була. Кызлар гелдәгечә бәйрәмдә матур чыгышлары белән барысын да таң калдыралар. Айсылу, Алсу, Гөлназ бик матур киемнәр киеп, матур бию башкаралар. Бар халык кул чаба. Тик менә һәрвакыт тавыш-гауга яраткан, үзенең якын дусларын да ямьсез сүзләр белән рәҗеткән Сафия генә көнләшүле карашы белән кызларга карый. Аның башына мәкерле уй килә, ул яңа ел кичендә теләнгән теләкнең чынга ашасын белә һәм үзенең яман уен чынга ашыру өчен, чын йөрәге белән яңа елның ап-ак карын учына йомарлап "бу өчәү, мәңгегә талашсын, дуслыклары чәлпәрәмә килсен",- дип теләк теле дә, йомарлаган карны җиргә ташлый. Кар йомрысы төрле якка чәчелеп тә китә.

Бәйрәм уза, кешеләр өйләренә таралышалар. Икенче көнне яңа ел таңы ата, кызлар да йокыларыннан уяналар. Яңа елның беренче көнен алар һәрчак тау шуып уздырганга, бу юлы да чаналарын алып тауга киләләр.

Тик кызларның карашлары моңсу, йөзләре караңгы, хәтта бер-берсе белән исәнләшмиләр дә. Һәркайсы үз чанасында шуып, сөйләшми генә өйләренә таралышалар. Таудан бар бала да өч дусның мондый гамәленә аптырап карап торалар, хафаланалар. Тик Сафия генә үз эченнән, "мәкерле уем чынга ашты бит,"- дип сөенә.

Көннәр үтә, кызлар өчен ай да, кояшта сүнә. Алар шатланмыйлар, көлмиләр. Әниләре дә, сыйныфташлары да, укытучылар да сәбәбен аңлый алмыйлар. Ә Сафия читтән генә бу хәлне күзәтә. Үзе дә һаман ялгыз көннәрен үткәрә. Ничек кенә мәкере көчле булмасын, бу хәл инде аңа да кызыксыз тоела.

Менә мәктәптә кабат бәйрәм, искечә яңа ел җитә. Балалар кабат бәйрәм ясыйлар. Тик инде Айсылу, Алсу, Гөлназ бу юлы үзләренең матур чыгышлары белән башкаларны таң калдырмыйлар. Бәйрәмнең яме, кызыгы булмый. Тамашачылар да теге вакытлардагы кебек бәйрәмнән тәм табып таралышмыйлар. Ни гаҗәп, әле күптән түгел генә үзенең теләге тормышка ашканга шатланган Сафиябез дә борынын салындырган. Үзе белән ни булганын үзе дә аңламый.

Бәйрәм тәмам, кешеләр өйләренә таралышалар. Сафия яңа яуган ак кар өстеннән атлый. Кинәт аның кулына бер, ике, өч кар бөртеге төшә дә шунда ук, эреп бергә кушылалар, алар да гүя бергә елашалар.

-Нишләдем мин, ничек итеп хатамны төзәтим соң?- дип кыз үз-үзенә сорау бирә. Сафия иртән йокыдан уянуга мәктәпкә йөгерә. Айсылу, Алсу һәм Гөлназны дәресләрдән соң, тауга чакыра. Кызлар кәефсез генә булса да, ризалашалар. Менә шунда кышкы тауның, ак кары өстенә басып Сафия кызлардан гафу үтенә. Әлбәттә инде яхшылыкка шаһит булган кар бөртекләре булышмыйча калмыйлар. Кызларның татулашуларын күреп алар да биешәләр. Ләкин, хәзер кызлар "өч дус түгел" инде "дүрт дус"ка әйләнәләр.

## Ялгыз каен

Минем туган авылымның бер авылында, яшәгән ди булган ди бер малай белән бер кыз. Алар күршедә генә яшәгәннәр, бер мәктәптә, бер сыйныфта укыганнар. Малай белән кыз аерылмас дуслар булганнар. Шатлыклары булса бергә уртаклашканнар, борчу килсә бер-берсенең күңелен күргәннәр. Еллар арты еллар үткән, аларның мәктәпне тәмамлар вакытлары да килеп җиткән. Соңгы кыңгырау кичендә, алар “үзебезгә истәлек булсын”, дип, пар каен утыртканнар. Бу каеннар шундый куе, матур, зифа булып үсеп киткәннәр. Һәр таңда бергә җилдә тирбәлгәннәр, гүя яфраклары елмаешып бер-берсе белән серләшкән шикелле тоелган. Каеннарның тарихын белүчеләр таң калып, әлеге күренешне күзәткәннәр.

Егет тә кыз да үзләренә һөнәр алу өчен уку йортларына кереп белем ала башлаганнар. Менә егетнең хәрби хезмәткә китәр көннәре якынлашкан. Кыз, илне сакларга дип хәрби хезмәткә киткән дустын бик күңелсезләнеп озатып калган. Күңелсезләнүе юкка булмаган аның, шул китүдән егет туган инде башка әйләнеп кайта алмаган. Егетнең үлүе турында хәбәр кызга бик тиз килеп ирешкән.Аңа дустын югалту бик тә, бик тә авыр булган.

Каеннар белән ни булган, диярсез сез. Ни галәмәт, каеннар да шул көннән башлап кара кайгыга калганнар. Егетнең үлем хәбәре килеп җитүгә, ул утырткан каен кипкән, корыган. Көннәрдән бер көнне ул шартлап сынган, агачның төбе дә корып юкка чыккан. Кыз утырткан каен, хәзер җилдә үзе генә тирбәлә, яфракларыннан тамчы-тамчы күз яше тама, ди.

*Колмөхәммәтов Әлфис,9 нчысыйныф, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Муса Җәлил исемендәге “1 нче гимназия” муниципаль бюджет белем учреждениесе*
*Җитәкчесе: Колмөхәммәтова Зөлфия Эдуард кызы, башлангыч сыйныф укытучысы*

## Гасырлар кичкән телем

Татар теле, борынгы төрки телләрнең берсе буларак, 3 диалектка бүленә. Нурлат районы Кизләү авылы сөйләше, тел белгечләре фикере буенча, көнбатыш диалект - мишәр диалектына карый. Ул татарлар белән чуаш, рус милләтләренең телара тәэсире шартларында формалашкан һәм яши. Шуңа күрәдер, бүгенге җирле халык сөйләмендә рус алынмаларының күплеге игътибарга лаек. Сөйләшкә татарларның рус һәм чуаш халкы белән гасырлар буе аралашуы, икътисади һәм мәдәни яктан тыгыз элемтәдә яшәүләре нәтиҗәсендә үтеп кергән рус алынмаларының җирле сөйләмдә активлыгы ни дәрәҗәдә? Өлкән буын кешеләре сөйләмендә яшьтәшләрем өчен таныш булмаган яисә

аңлашылмый торган лексик берәмлекләр каян килгән? Бу сүзләр авылның тарихын өйрәнүдә әһәмияткә ияме?

Югарыдагы сорауларга җавап эзләү безне «Гасырлар кичкән телем» дигән эзләнү эше башкарырга этәрде.

Эшнең әһәмияте һәм яңалыгы: бүгенге көндә туган авылым кешеләре сөйләшендә рус алынмаларының махсус белгечләр тарафыннан өйрәнелмәве.

Эзләнү эшенең объекты - Нурлат районы Кизләү авылы, предметы - җирле сөйләм, Нурлат районы Кизләү авылы сөйләше.

Гипотезам: яшь буын әдәби телдә сөйләшүгә күчеп бара, һәм бу Кизләү авылы сөйләшендә сакланган рус алынмаларының сөйләмдәге активлыгын киметә.

Эзләнү эшенең максаты: авылдашларның сөйләм үзенчәлекләре аша кече Ватанымның тарихын өйрәнү, җирле сөйләм үзенчәлекләрен өйрәнүнең әһәмиятен ачу.

Максатка ирешү өчен, түбәндәге бурычлар хәл ителде:

-җирле сөйләмдәге рус сүзләрен туплау, эшкәртү һәм системага салу;

-бу сүзләрнең татар әдәби телендәге һәм рус телендәге эквивалентларын күзәтү барышында, мәгънәви уртак һәм аермалы якларны билгеләү;

-бүгенге авылдашларның әлеге рус алынмаларын ни дәрәҗәдә актив куллануын һәм шушы ук сүзләрне Түбән Кама шәһәре “1 нче гимназия” 10 нчы сыйныф укучылары һәм укытучыларының ни дәрәҗәдә аңлавын анкета ярдәмендә ачыклау, нәтиҗәләрен чагыштыру;

-әлеге алынмаларның халык авыз иҗатында чагылышына күзәтү ясау;

-җирле сөйләмдәге рус алынмаларының бүгенге көн Нурлат районы җирле шагыйрьләр иҗатында чагылышын тикшерү.

Эзләнү эше барышында җирле сөйләмдәге рус алынмаларын туплау, чагыштыру, күзәтү, анкета, анализ, нәтиҗәләр ясау кебек методлар актив кулланылды.

Эзләнү эше “Кереш”, “Төп өлеш”, “Йомгаклау”, “Кулланылган әдәбият”, “Кушымта” дигән структур өлешләрдән тора. “Кереш” өлешендә сайланган теманың актуальлеге ассызыклана, эзләнү эшенең максаты, бурычлары, кулланылган методлар, эшнең гипотезасы, гамәли яктан әһәмияте күрсәтелә.

“Төп өлеш”тә игътибар

-тема буенча әдәби һәм басма чыганаклар өйрәнелү;

-өлкән яшьтәге авылдашлар белән аралашу нәтиҗәсендә, җирле сөйләмдәге рус алынмалары туплану;

-“Җирле сөйләмдә сакланып калган рус сүзләре” дигән сораштыру уздырылып, нәтиҗәләр ясауга юнәлтелә.

“Йомгаклау” өлешендә эзләнү эшенең нәтиҗәләре китерелә:

-рус һәм чуаш халкы белән аралашып яшәү Нурлат районы Кизләү авылы сөйләшендә һәм көнкүрешендә тирән эз калдырган;

-рус теле җирле сөйләм лексиконын баетуда әһәмиятле урын тоткан;

-җирле сөйләмне өйрәнү бүгенге көндә әһәмиятле, чөнки тел үсеше аша җирле халыкның үткәнен, мәдәниятен һәм көнкүрешен өйрәнергә мөмкин.

Рус алынмаларының җирле халык авыз иҗатында тотрыклы сүзтезмәләрдә кулланылуы, әмма замандаш шагыйрәләр иҗатында чагылыш тапмавы безнең гипотезаның раслануын дәлилли.

“Кулланылган әдәбият” өлешендә тупланган материалны фәнни нигезләү өчен өйрәнелгән һәм файдаланган китаплар , интернет ресурслар исемлеге тәкъдим ителде. Эш барышында, бигрәк тә, энциклопедик әдәбият файдалы булды. Тупланган сүзләрне төркемләү һәм сүзлек итеп ясау алар үрнәгендә башкарылды.

“Кушымта” өлешендә эзләнүебезне башкару барышында тупланган материал, анкета нәтиҗәләре, безнең тарафтан төзелгән сүзлек урын алды.

Гомумиләштереп әйткәндә, Нурлат районы Кизләү авылында яшәүче татарлар сөйләшендә кулланылучы рус алынмалары әйтелеш, мәгънәви бөтенлек, җирле сөйләмдәге активлык, тотрыклы сүзтезмәләрдә саклану һәм җирле язучылар иҗатында кулланылу ягыннан тикшерелде. Бүгенге көндә җирле сөйләмнең татар әдәби теле һәм икътисади тормыш тәэсирендә үзгәреш кичерүе халык арасында сораштыру нәтиҗәләре белән дәлилләнде. Гипотезабыз тулысынча расланды, максатыбызга ирештек.

Тәкъдим ителгән эш гамәли яктан Нурлат районы Кизләү авылы җирлегендә тел формалашу һәм аңа тәэсир иткән күренешләрне ачарга ярдәм итүе белән әһәмиятле.

*Макаров Әмир, 3 нче сыйныф, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы “20 нче гомуми урта белем бирү мәктәбе”муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчесе: Ялалова Зөлфия Фаел кызы, татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

**Муса Җәлил**

Күпме еллар үткән, сулар аккан
Киткәнең синең бу җирдән.
Еллар сине аерса да бездән,
Сагына сине, Муса, бар галәм!
Һәркемгә дә язылмагандыр ул,

Синдәгедәй моңлы язмышлар.

Бар кеше дә, синдәй булсын иде,

Кабатланмасыннар ялгышлар.

Җырлап киттең безнең аралардан,

Илаһи бер моң, сер булып.

Синең гомерең, әйтерсеңлә, Муса,

Күктә ялтыраган бер йолдыз.

Шагыйрь булып туган соң син, Муса

Күпме шигырь, әсәр язгансың.

Туган илең, татар теленә син

Мәңге тугъры булып калгансың.

Синең гомерең, синең язмышың ул

Мирас, маяк булыр яшьләргә!

Еллар үтәр, килер алар сиңа

Һәм таяныр синең киңәшләргә.

Ышан, Муса, халкың онытмас сине!

Үзе үстергән газиз баласын.

Син кабызган утны маяк итеп,

Безгә әле озак барасы!

**Апама**

Апам минем терәгем

Апам минем яклаучым

Апам минем киңәшчем

Җил -давылдан саклаучым

Мин дә терәк булырмын

Апам сиңа һәрвакыт

Нинди генә мизгелдә дә

Табармын сиңа вакыт.

**Кыш**

Кыш җәйдән дә ямьлерәк

Күрә белсәң матурлык

Талгын гына карлар ява

Сокланып таң калырлык

Ап-ак карлы тунын киеп,

Таулар күптән көтәләр.

Чаңгы, чана шуабыз без.

Туган саен иртәләр.

Кыш бабай,  кар кызыннан

Кем генә көтми бүләк?!

Сабыйга түгел, зурга да

Теләк теләргә кирәк.

Ел да кышлар кабатлансын.

 Күңелдә булсын аклык.

Бәхет-шатлык, сәламәтлек,

Күңелдә тулсын шатлык.

**Әниемә**

Бар рәхмәтем, бар хөрмәтем,

Чиксез ярату сиңа.

Тәүге көннән багышладың,

Күңел җылыңны миңа.

Төн йокыңны йокламыйча,

Бишек җырын көйләдең.

Үсә төшкәч, әкиятләр,

Хикәяләр сөйләдең

Син һәрвакыт миңа, әни,

Карадың өмет белән

Ышанычың аклар өчен

Булган көчемне түгәм.

Өмет уты сүнгән чакта,

Маяк булдың син миңа

Бар рәхмәтем, бар хөрмәтем,

Сиңа, әнием, тик сиңа.

*Мәрданшина Әмилә, 6 нчы сыйныф, Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәренең “26 нчы гимназия” муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчесе: Сабирова Фәйрүзә Вояз кызы, югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

**Җәлил эзләре буйлап...**

**Теманың актуальлеге:** Бүгенге көндә Муса Җәлилне күргән, аның белән аралашкан кешеләр көннән көн кимеп бара. Алар белән аралашып, истәлекләрен барлап калу шагыйрь турында күбрәк белергә этәргеч бирә.

**Минем тикшеренүләр объекты:** Муса Җәлил турында язылган истәлекләр, аның шигырьләре белән танышу.

Минем тикшеренү эшемнең **максаты:** Муса Җәлилнең Минзәләдәге тормыш һәм иҗат юлын тирәнтен өйрәнү.

**Бурычлары:**

- Тарихи үткәнгә, шагыйрьнең тормыш юлына һәм иҗатына карата кызыксыну уяту, мәхәббәт хисе, патриотлык, милли горурлык хисләре тәрбияләү.
- Шагыйрь иҗаты буенча танып-белү эшчәнлеген камилләштерү.
- Сәяхәт аша шагыйрьнең тормыш юлын күзаллауны формалаштыру.

**Аннотация.**

Һәр милләттә исеме телгә алынуга ихтирам уята торган шәхесләр була. Муса Җәлил әнә шундый исемнәрнең берсе. Юк, ул исем генә түгел, бәлки тирән мәгънәле символ да. Чөнки бу исемнең синонимнары булып батырлык, кыюлык, каһарманлык, талантлылык, ватанпәрвәрлек,тугрылык кебек тирән мәгънәле сүзләр тора. Ул, чыннан да, бу сүзләрнең һәммәсенә лаек кеше. Муса Җәлил диюгә, татар халкын, ә татар халкы диюгә М.Җәлил күз алдына килә. Аның шәхесен һәм батырлыгын бөтен дөнья белә. Димәк, ул халкыбызның горурлыгы.Үзе үлсә дә, аның исеме, шигырьләре мәңгелек, ул һәрвакыт халык күңелендә яши.

**Тикшеренү эшенең әһәмияте**. Хезмәтне язу барышында тупланган материалларны татар теле һәм әдәбияты һәм башка дәресләрдә, түгәрәкләр эшендә кулланып була.

**Хезмәтнең төзелеше**. Тикшеренү эше кереш өлештән, төп өлештән, йомгаклау өлешеннән һәм файдаланылган әдәбият исемлегеннән гыйбарәт.

### 1.1 «Җәлил эзләре буйлап...»

Кышкы каникул вакытында Яңа Мәлкән мәктәбе китапханәсенә китаплар алырга бардык. Шулчак мәктәп музеена да кердек. Стенада эленеп торган картинага күзем төште (рәс. 1). Без анда Мусаны танып алдык. Ни өчен әлеге картина Мәлкән мәктәбе музеенда саклана, кем аның авторы һәм башка бик күп сораулар туды миндә.

Бу сорауларга җавап эзләү тикшеренү эшемне язарга этәргеч булды.

Әбием Калинина Мәкфия Биктимер кызы 30 елдан артык мәктәптә башангыч класс балаларына белем бирде. Ул картинаның тарихын бик яхшы хәтерли. Аны 30 елдан артык мәктәп директоры булып эшләгән Сәетов Назиф абыйга Минзәлә педагогия училищесында Муса Җәлил музеен оештыручы, җитәкчесе булган Вәсил Хәдиевич бүләк

иткән. Картинаның авторы рәссам, Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре,педагогия училищесының сынлы сәнгать укытучысы Хабибуллин Назим Нәбиуллович икәнен белдек. Ул Мусаның Дусай-Кичүдә халык белән очрашып, мәдәният йортында чыгыш ясаган вакытын сурәтләгән.

## 2.1. Муса «Кызыл Кичү» колхозында

Политкурс җитәкчеләре рөхсәте белән, партия һәм совет органнары курсантларны булышлык итү өчен колхозларга җибәрәләр. Муса «Кызыл Кичү» колхозына килә. Бу колхоз ашлык тапшыру планын үти. Ләкин, артельдә эшче көч аз булганлыктан, үстерелгән мул уңыш сугып бетерелми, кышка кала. “Муса Җәлил шушы эшләрне оештыруда безгә нык ярдәм итте. Ул вакытта партиянең район комитеты фронтка җибәрү өчен җылы кием һәм продукция хәзерләүгә бик зур игътибар бирә иде. Без бу эшләрне М.Җәлил белән берлектә, башка колхозлардан алдарак үтәп чыктык”, - дип искә ала колхозның элекке председателе Н.Ханнанов.

Муса колхоз тормышы белән ихлас күңелдән кызыксына: мәктәптә, фермада, бригадаларда була, җыелышларда катнаша, игенчеләрне фронт хәлләре белән таныштыра, шигырьләрен укый, тырыш хезмәткә рухландыра. Һәрчак: “Безнең җиңүебезгә шик юк, без җиңәрбез!” – дигән фикерне үткәрә.

Дусай-Кичү авылында Мирзаһит һәм Сабира Әхмәдиевлар гаиләсендә Җәлил бер атнадан артык тора. Сабира апа истәлекләрендә: “Муса фермага барды, колхоз хәлләре белән танышып йөрде. Куен дәфтәрен күп кенә фамилияләр һәм саннар белән тутырды. Авыл халкының эшчәнлегенә исе китеп, сугыш беткәч, безгә, Ык буена гаиләсе белән кунакка килергә теләвен белдерде.

Кичләрен Муса бик матур итеп мандолинада уйный, кайвакыт “Ком бураны”, “Ашхабад” көйләрен көйләп тә җибәрә.

Колхозыбыз турында зур очерк язып чыгармакчы иде. Әмма, кинәт китеп бару сәбәпле, ул аны бастыра алмады. “Ирекле илнең ирекле Ирего” дип улыма багышлап шигырь дә яза башлаган иде. Ләкин ул тәмамланмый калды. Шагыйрьне Минзәләгә чакырып алдылар. Китәр алдыннан йон оекбаш белән бияләй бүләк иткән идем, сөенеп алды, рәхмәтләр әйтте. Бик күңеле булып, җыелган авылдашлар белән саубуллашып, Муса китеп барды. Юлдан ике хаты килде, фронтка барып җиткәч, бер хаты килде. Фото, хатлар, улым Иреккә язган шигыре дә сакланмаган. Сугыштан соңгы еллар бик авыр булды бит, булган булса да юкка чыгарылгандыр...”, -дигән юлларны укырга була.

## 2.2. Фаина Мирзаһитовна истәлекләре

Вахитов исемендәге урта мәктәп укытучысы Фаина Мирзаһитовна хәтерендә калган кызыклы фактларны тәфсилләп сөйли. Фаина Мирзаһитовна Ганиева (Әхмәдиева) ул вакытта училищеның икенче курсында укыган, аның бу кичәдә әйткән сүзләрен озак еллар үз күңелендә йөртә: “Бәхетле сез, кызлар, бигрәк тә киләчәгегез матур. Менә сугыш бетәр. Тормыш тагын да чибәрләнер. Сугышта үлеп калырмын дип уйламыйм... Ә шулай да, белмәссең, әйләнеп кайтмасам, үтенечем шул: сугыш вакыты авырлыкларын, җиңү хакына нинди корбаннар бирелүен яшь буынга сөйләгез. Исән калсам, һичшиксез, Ык буйларын килеп күрәчәкмен”.

Икенче мәртәбә Муса Җәлилне Ф. Ганиева культура йортында, спектаклҗ куелганда күрә. Шагыйрь анда ак сакаллы карт ролен башкара. Аны дарга асарга алып баралар. Карт: “Безнекеләр килер, сездән үч алырлар, яшәсен Совет власте!” – дип кычкыра. Муса Ватаныбыз өчен үз гомерен дә шулай горур бирәчәген уйладымы икән ул вакытта?

Әлбәттә, Минзәлә чорында ил өстенә килгән куркыныч, дошманны тизрәк җиңү омтылышы, совет патриотизмы М.Җәлил иҗатының үзәген тәшкил итә. Бөек Ватан сугышы көннәрендә Минзәлә ягы кешеләренең батырлыгын күреп, тоеп яшәү дә патриотизм хисләрен җырлауга рухландырган. “Нәрсә эшләдең?” исемле шигырь аеруча характерлы. Ул 1941нче елның 25нче декабрендә иҗат ителгән.

*Тик бер бурыч хәзер ил алдында:*
*Тар-мар итеп дошман көчләрен*
*Илдән куу...*
*Иптәш, ә син бүген*
*Фронт өчен нәрсә эшләдең?*
*Күбрәк ит, икмәк, кием кирәк*
*Фронттагы сугышчыларга.*
*Чыгардыңмы... хезмәтеңнең*
*Җимешеннән өлеш шуларга?*
*Хезмәт белән тизләт син илеңнең*
*Бу сугышта җиңеп чыгуын.*
*Бөтен эшең фронт өчен булсын,*
*Шунда булыр ватанчылыгың.*

Шигырь киң халык массасын изге көрәшкә, хезмәткә өндәү авазы булып яңгырый.

Муса Җәлил Минзәләдә үзенең Татрабфакта бергә укыган сабакташларын очрата. Алар – Мәхмүдә Мәҗитова һәм Фәүзия Мөхәммәтовалар. Мәхмүдә апаның 14 яшьлек кызы Иншәр Мусаны аеруча ихтирам итә, үзләренә килгән вакытта, әнисе белән икәүләшеп, шагыйрьгә җылы мөнәсәбәт тудырырга тырышалар. Муса да җавапсыз

калмый, Иншәргә багышлап өч шигырь яза: “Бүләк”, “Иншәр сеңелгә”, “Минзәлә кызына”.

*Мин онытырмын бәлки Минзәләне,*

*Аның салкын ефәк карларын.*

*Тик онытылмас синең каш астыңнан*

*Сүзсез генә көлеп каравың...*

*Исән кайтсам, тагын күрешербез,*

*Ә кайтмасам...*

*җырым сагынсын!*

*Сине сөйгән шагыйрь абыеңны*

*Җыры белән искә алырсың.*

Муса Җәлил Минзәләдән 1942нче елның 1 гыйнваренда китеп бара.

*Хуш, Минзәлә,*

*синдә кунак булдым,*

*Бераз гына, үтеп барышлый;*

*Шуңа күрә нәни шаярулы*

*Бу җырымны сиңа багышлыйм.*

Бу китү мәңгелеккә, үлемсезлеккә китү иде.

Советлар Союзы Герое, Ленин бүләге лауреаты Муса Җәлилнең еллар үтә барган саен бөеклеге арта бара. Әйе, Минзәлә халкы бүген дә Мусаны сагынып искә ала. Минзәләдәге политкурслар Муса өчен туган илгә мәхәббәт, дошманга нәфрәт, патриот – интернационалист итеп тәрбияләү мәктәбе була. Герой буларак, ул Минзәләдә формалашкан дип уйлыйм. Ә без, үз чиратыбызда, Бөек Ватан сугышында катнашкан, кан койган, фашистларны җиңгән батырларны, бигрәк тә әдипләребезне онытырга тиеш түгелбез.

### 2.3. Ирекле илнең ирекле Ирече белән җылы очрашу.

Фәнни эшкә материал туплау барышында бүгенге көндә гаиләсе белән Мәлкән авылында тормыш кичерүче Әхмәдиев Ирек Мирзаһит улы белән очрашырга насыйп булды (рәс. 7).

Очрашуга бик теләп ризалашты. Ачык йөз белән елмаеп каршы алды Ирек абый белән Гөлсәрия апа безне. “Мин ул вакытта 4 яшьлек кечкенә бала идем. Әти фронтта, әни мәктәптә укытучы булып эшли иде. Безнең колхоз алдынгы булганлыктан Минзәләгә политкрсларга килгән Мусаны безнең авылга ял итәргә җибәргәннәр. Аны безгә кавртирага керттеләр, атнадан артык бездә торды,- дип бик канатланып сөйли башлады. Ул вакытта өебез зур иде, мичкә салам яга идек, өйнең түрендә агач карават тора иде,

шунда Муса абый белән йокладык, “Минем кызым Чулпан синең белән бер яшьтә”,-дип җилкәләренә утыртып йөрде, гел кочаклап кына торды (Чулпанны сагынуын басар өчен).

Миңа багышлап буйлы дәфтәргә “Ирекле илдә Ирек”шигырен дә язды, кечкенә булуыма карамастан мин аны ятладым, аннан оныттым. Оныттым, чөнки Муса Җәлилне халык дошманы дип игълан иттеләр, аның исемен дә атарга ярамады, әнием коммунист булганлыктан ул шигырҗ язылган кәгазь битен юкка чыгарган. Бүгенге көндә хәтер сандыгын актарып, яңадан шуны табып алырга мөмкинлек булса иде,- дип көлеп куйды.”

Әхмәдиев Ирек Мирзаһит 1937 елның 20 апрелендә  Дусай –Кичү авылында укытучы Мирзаһит (рәс. 4) һәм Сабира (рәс. 3) Әхмәдиевлар гаиләсендә туа. Башлангыч сыйныфларны Татарстан Республикасының архетиктура һәйкәлләре исемлегенә кертелгән Дусай –Кичү мәчете бинасында (рәс. 2) укыган, 5-7 сыйныфларны Мәлкэндэ, 8-9 сыйныфларны Минзәлэнең Вахитов исемендәге урта мәктәптә, 10 классны Бикбау мәктәбендә тәмамлаган. Укуын дәвам итәргә Магнитогорск шәһәренә китэ, тимер юл училищесын тэмамлый. Аннан белем алуын дәвам итәргә Чиләбе ягына китэ. 1969 елды Чаллы шәһәрендә КамАЗ төзелә башлаганны ишетеп бик теләп туган ягына әйләнеп кайта. Бугенге көндә Муса Җәлил исемен йөртуче урамда (рәс. 5), ул эз калдырган нигезне ( рәс. 6) корытмый матур гомер кичерәләр.

## III. Йомгаклау

Ык елгасының сул ярында калкулыкка тезелеп утырган Дусай – Кичү, Яңа Мәлкән, Иске Мәлкән авыллары. Алар барысы бергә “Август - Мөслим” исемендәге җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятькә берләшкән хәзер. Табигатьнең иң матур урынына урнашкан ул. Әгәр авылның тавыннан карап торсаң, күз алдында сихри гүзәллек ачыла. Биредән Чулман елгасына кадәр сузылган киңлектә йөгерек дулкыннар тирбәлә. Еракта утраулар күренеп тора. Иксез-чиксез тугайларны күзәтеп, хозурланып туя алмыйсың. Күңелеңне, хисләреңне әсир итә бу гүзәллек.

Шушы матурлыкка ямь өстәп, авыллар да яңара. Яңа хуҗалыклар да күп бу авылда. Урта мәктәп, мәдәният йорты, мәчет, һ.б. Әгәр Муса, исән – сау кайтып, бирегә кабат килгән булса, мондагы үзгәрешләрне күреп сөенер иде! Якты офыклы, таза тормышлы авыллар, матур язмышлы кешеләр ялкынлы шигырьләр һәм поэмалар язарга дәртләндерер иде аны.

## IV. Кулланылган әдәбият

1. Гайнуллина Ф. Үлемне җиңгән шагыйрь./”Мәгариф” 2006, февраль.14-16 битләр/

2. Мемориальный музей Мусы Джалиля. - Культура  г. Мензелинск. menzelinsk.ru

3. Үлемсезлек таңында: Муса Җәлил турында истәлекләр. Казан: Таткит. нәшр., 1971.-102 б.

4. Муса Җәлил. Әсәрләр . Биш томда. Шигырьләр. Казан. Татарстан китап нәшр. 2006 ел.

5. Шәмси Хамматов Муса Җәлил - партия солдаты/ Казан, Тат. кит. нәшр., 1982, 122-141 битләр.

6. Рафаэль Мустафин Муса Җәлил турында истәлекләр/ Казан, Тат. кит. нәшр., 97-103 битләр.

*Мәхмүтова Диана, 8 нче сыйныф, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы “26нчы гомуми урта белем бирү мәктәбе” муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчесе: Хәйруллина Лилия Миннефаяз кызы, татар теле әдәбияты укытучысы*

**Көз**

Алтын көзләр үтеп китте,

Җитте көзнең ахыры.

Өйгә куа ноябрьнең

Салкыннары, яңгыры.

Миләш, балан, уттай янып,

Бизәп тора дөньяны

Сәламәтлек өчен куллан,

Икесе дә файдалы.

Кайнатмаларын эзерләп

Куйдык инде кыш өчен.

Капкалап йөр, чирләмәссең,

Курерсең шунда көчен.

Беренче кар явып үтте

Кыюсыз гына булып.

Җирне дә каплый алмады,

Бетте дә китте эреп.

Җир туенды яңгырларга,

Шифасы булсын бары.

Бераз суытып җибәрсә,

Көттерми явар кары.

*Мөбәрәкшин Илгиз, 3 нче сыйныф, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы “32 нче гимназия” муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчесе: Мөбәрәкшина Рузилә Рәшит кызы, Шәрипова Алия Азамат кызы, туган тел һәм әдәбияты укытучылары*

**Әниемә**

Дөньядагы иң матур да,
иң батыр да
Ул минем әни була.
Кояш кебек иркәләп
Мине гел назлап тора.
Җимешкәем, алмам дия
Яратып мине әни.
Барысы, барысы өчен дә
Яратам сине, әни!

**Туган телем**

Әнием кебек газиз
Син миңа, туган телем.
Синең аша беләм мин
Бу дөньяның бар серен.
Татар телем, игелек
Башлангычы бит синдә.
Бишек җырыннан күчкән
Татар җаныдыр миндә.
Әдәп-әхлакка өнди
Әлифбаның һәр сүзе.
Туган телем – серле тел,
Камиллекнең син үзе!
Гөрләп, янып яшәргә
Син миңа ныклы терәк.
“Туган телем, гел яшә!”
Дип тибә минем йөрәк!

**Бабама**

Кайтырмын дип,

Җиңү яулап кайтырмын дип

Ут эченә керде бабаем.

Язмышмы тик,

Мәрхәмәтсез язмышмы тик

Адаштырды авыл малаен.

Разведкада

Төнге салкыннарда

Ачып салып дошман серләрен,

Бөтен көчен бирә бабам

Илебездән

Юк итергә фашист эзләрен.

Әти-әни, сөйгән ярың,

Өзгәләнеп сине көтteләр.

Кайтсын диеп,

Әти кайтсын диеп

Балаларың тели иделәр.

Ә беркөнне

Үзәкләрне өзеп кайгы җиле

Килеп какты безнең капканы.

Сугыш кырларына киткән җирдән

Кайтмады шул бабам, кайтмады...

**Минем бабай**

Минем бабай бик акыллы,

Минем бабаем зирәк.

Барыбыз өчен дә ул

Зур таяныч, нык терәк.

Кадак, чүкеч тотарга

Өйрәтә мине бабай.

Тәртипне дә онытмый:

“Артык шаярма, малай!

Беркайчан да чыкма, ди,

Әниең әйткән сүздән.

Минем өчен зур шатлык

Бәхетле булып үссәң”.

Бакчада да гел бергә без,

Балыкка да йөрибез.

Ишегалдын ялт иттереп

Кышын карлар көрибез.

Бабамны бик яратам мин

Тыңлыйм аның һәр сүзен.

Бабам булу бу дөньяда

Зур бәхет минем өчен!

**Энемә**

Бик бәхетле ел булды бу

Шатлык тулды күңелгә!

Әни энекәш алып кайтты

Минем туган көнемә!

Шушы көннән безнең тормыш

Матурайды, үзгәрде.

Энемнең шат авазы

Бизи безнең көннәрне.

Үзе кечкенә генә ул

Түп-түгәрәк йөзләре.

Төймә кебек уйнап тора

Аның зәңгәр күзләре.

Көннән-көн минем энемнең

Һөнәрләре күбәя.

Кечкенә генә булса да

Тәпиләргә өйрәнә.

Физзарядка ясыйбыз без

Иртән иртүк торгач та.

Энем туган хөрмәткә

Утырттык без агач та!

Энем булгач бездә хәзер

Көн дә бәйрәм шикелле.

Мине абый иткән өчен

Яратам мин энемне!

**Габдулла Тукай**

Түбәтәй кигән башына,
Каләм аның кулында.
Сөйлим әле дуслар сезгә
Тукай абый турында.
Халкымның бөек шагыйре,
Сөекле улы Тукай.
Аны укымаган, белмәгән
Бер кеше дә юк бугай.
Әнисез үскән бала ул,
Ул үксез бала булган.
Бер әбидә, бабасында,
Апаларында торган.
“Су анасы”, “Шүрәле”не
Укыйм мин кабат-кабат
“Туган тел” шигырен дә
Бетердем инде ятлап.
Тукай абый киңәшләрен
Мин дә үтим бик теләп:
Әниемнең сүзен тыңлыйм,
Алдашмыйм мин, урлашмыйм.
Әнием миңа кирәк бит,
Мин әниемә кирәк.

**Балыкта**

Яр буенда чирәмдә
Утырам тып-тын гына.
Янәшәмдә сандугач
Җыр суза моңлы гына.
Ә җирдә чикерткәләр,
Кырмыскалар кайнаша
Күбәләкләр чәчкәдә
Менә нинди тамаша!
Ә елгада балыклар

Кызыктыра күңелне

Мыштым гына торсам да,

Монда шундый күңелле!

Табигатьнең серләрен

Өйрәнәм әкрен генә.

Кармагымның чирткәнен

Күзәтәм түзем генә.

Шактый гына сынагач

Сабырлык, түземлекне

Чү, туктале, кармагым

Әнә чиртә түгелме?

Чиртә-чиртә кармагым

Аңа балык эләккән!

Тартып алсам, карап тора

Бер кечкенә кәрәкә.

*Низамова Ясминә, 5 нче сыйныф, Татарстан Республикасы Казан шәһәре Совет районы “171 нче мәктәп” муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе, “Азино” Балалар иҗат үзәге Җитәкчесе: Сафин Айдар Мөбәрәкҗан улы, Бариева Лилия Илгизәр кызы, башлангыч сыйныф укытучысы*

**Венераны терраформалаштыру һәм колонизация ысуллары**

**Проектның актуальлеге** Кайбер галимнәр элек Венерада шартлар Җирдәге шартларга охшаш булган дип исәпли. Киләчәктә Җирдә Венерадагы кебек тискәре үзгәрешләр булмасын өчен, әлеге планетаны яхшылап өйрәнергә кирәк. Хәзер бу планетаны тикшерергә җиңелрәк. Технологияләр яхшырак була башлады бит.

**Проектның максатлары**

1. Венераны терраформалаштыру һәм колонизация ысулларын белү.
2. Телескопта тикшеренүләр үткәрергә һәм фазаларны күзәтергә.

**Проектта тикшереләчәк гипотезалар**

1. Шәһәр-станцияне өслектән 50 км да төзергә кирәк. Чөнки анда шартлар яхшырак.
2. Венераны астероидлар һәм бозлы кометалары белән бомбага тотарга, үз күчәре тирәсендә әйләнүне арттыру өчен андагы көн кыскарак булачак. Һәм Венераны су белән тәэмин иту өчен астероидлар һәм комета урынынна Гиперионны кулланырга мөмкин.

3. Венераны Кояштан көзге белән капларга.

4. Венарага водородны су белән тәэмин иту һәм атмосфера басымын киметү өчен ташларга.

**Проект бурычлары**

1. Венераны төрле чыганаклардан мәгълүмат җыеп өйрәнергә.
2. Венера өслегенн телескоп аша күзәтергә.
3. Венера фазасын телескоп аша күзәтерергә.
4. Венераны терраформалаштыру һәм колонизация ысулларын өйрәнергә һәм анализларга.
5. Тикшеренү нәтиҗәләрен гомумиләштерергә һәм нәтиҗә ясарга.

**Проекта чишлә торган проблема**

Венераны терраформалаштыруның яхшарак ысулын табу.

## I. Теоретик өлеш

Венера Кояшка якынлыгы буенча икенче урында тора. Ул иң кайнар планета. Зурлыгы һәм авырлыгы буенча Венера Җирдән аерылмый. Тыгыз атмосфера парник тәэсире тудыра һәм Җир өслегенднә температура 464 градуска кадәр җылына. Бу Кояшка иң якын булган Меркурийдан да күбрәк. Венерада күкерт кислотасы яңгыры ява. Анда ел 225 җирдәге көннән тора. Ә бер көн – 243 Җир көнненән гыйбарәт. Венераның иярчене юк. Анда болытлар бик күп.



*Венера*

Венераның өйрәнү:

Б.э. к. 1600 елда Вавилон патшасы Амми-цадукиның балчык табличкаларында горизонтта 21 ел дәвамында Венера күренүе турында язмалар бар.

Б.э.к. 600-700 елда борынгы греклар иртәнге һәм кичке Венераны ике планета – Фосфор һәм Геспер дип уйлаганнар.

1519 елда Америкада Дрезден кодексы табыла. Бу – 8 гасырдагы Майя кабиләләренең текстлары копиясе. Анда Венераның күк йөзендә күренүенең төгәл таблицалары күрсәтелгән.

1610 елда Италия галиме Галилео Галилей Венераны телескоптан күзәткән һәм анда Ай фазаларына тәңгәл булган фазалар ачыклаган. Шулай ук планетаның күренә торган өлешендә үзгәрешләрне дә күзәткән.

1639 елда инглиз астрономнары Иеремия Хоррокс һәм Уильям Крабтри беренчеләрдән булып Венераның Кояш дискыннаң узуын күзәтәләр.

1761 елда Россия галиме Михаил Ломоносов Венерада тыгыз атмосфера барлыгын ачыклый.

1961 елда Калифорния обсервbooториясендә радиотелескоплар белән Венераның болытлар белән капланган өслеге өйрәнелә.

Венерага миссияләр

| | | |
|---|---|---|
| 1961 | Венера-1(СССР) | Уңышсыз |
| 1962 | Маринер-2(АКШ) | Уңышлы |
| 1965 | Венера-2(СССР) | Уңышсыз |
| 1965 | Венера-3(СССР) | Уңышсыз |
| 1967 | Венера-4(СССР) | Уңышлы |
| 1969 | Венера-5, Венера-6(СССР) | Уңышлы |
| 1970 | Венера-7(СССР) | Уңышлы |
| 1972 | Венера-8(СССР) | Уңышлы |
| 1973 | Маринер-10(АКШ) | Уңышлы |
| 1975 | Венера-9, Венера-10(СССР) | Уңышлы |
| 1978 | Пионер-Венера-1(АКШ) | Уңышлы |
| 1978 | Пионер-Венера-2(АКШ) | Уңышлы |
| 1981 | Венера-13, Венера-14(СССР) | Уңышлы |
| 1983 | Венера-15, Венера-16(СССР) | Уңышлы |
| 1984 | Вега-1, Вега-2(СССР) | Уңышлы |
| 1989 | Магелан(АКШ) | Уңышлы |
| 1989 | Галилео(АКШ) | Уңышлы |
| 1997 | Кассини-Гюйгенс(АКШ) | Уңышлы |
| 2004 | Мессенджер(АКШ) | Уңышлы |
| 2005 | Венера-Экспресс(Европа) | Уңышлы |
| 2010 | Акацуки(Япония) | Уңышсыз |


| | | |
|---|---|---|
| План | Венера-Д(Россия) | |

**II. Практик өлеш**


Галимнәр тарафыннан күрсәтелгән теорияләрдән мин 4 ысулны аерып алдым.

1. *Шәһәр-станцияләрне Венераның өслегендә төзү яхшырак булачак.* Өслектәге температура 357 градуска кадәр җитә. Ләкин югарырак температура 50-60 градуска төшә. Бу югарылыктагы басым нәкъ Җирдәге кебек - 1 атмосфера. Әлеге югарылыкта атмосфера шулай ук углекислый газдан тора. Ләкин ул башка газлардан авыррак. Шуңа күрә теләсә нинди җиңелрәк газ аэростатлар һәм дирижабльләр өчен күтәрү көчен тәэмин итә ала. Гади җир һавасы белән тулы баллон Венера атмосферасында очып йөри, ә гелий һәм водород тагын да нәтиҗәлерәк булырга мөмкин. Венерада кислород булмаганга күрә, янгын чыгудан курыкмыйча водородны кулланырга мөмкин. Атмосферада күкерт кислотасы да бар. Таркалганда ул безне су белән, ә су - кислород һәм водород белән тәэмин итә ала. Дирижабль һәм аэростатларны графеннан ясарга, ә материалны углерод күп булган атмосферадан алырга була. Минемчә, шәһәрләрне төзүнен бу ысулы бик отышлы. Вакытлыча шәһәр-станцияләрдә яшәячәк кешеләр күкерт кислотасы таркалуы нәтиҗәсендә барлыкка килгән суны куллана алалар.

2. *Венераны бозлы кометаллар һәм астероидлар белән бомбага тоту*. Әгәр дә Венераны астероидлар белән бомбага тотсаң, үз күчәре тирәсендә әйләнүе артачак. Һәм Венерада көн Җирдәге кебек булачак. Шулай ук магнит кыры да барлыкка килә ала. Венеранын үз күчәрендә әйләнеше юк, шуңа күрә анын магнит кыры көчсез. Бозлы кометалар аркасында су барлыкка килергә мөмкин. Берничә күл өчен берничә йөз комета кирәк. Комета һәм астероид урынына Сатурнның иярчене - Гиперионны кулланырга мөмкин. Ул, нигездә, боздан тора. Аны күчерү өчен кояш көзгеләрен кулланырга була. Алар кояш нурын, ул эреткән боз реактив агым барлыкка китерерлек итеп, иярченнең кирәкле урынына юнәлтәләр. Ул анын орбитасын элиптик формага кертә һәм Сатурннын икенче иярчене Титанга якынайта. Титанны Гиперионның тизләнеше өчен гравитация манёвры итеп кулланырга мөмкин. Барысын да дөрес исәпләгән вакытта Гиперион Венера белән бәрелешкәндә аны су белән тәэмин итеп кенә калмаячак, үз күчәрендә әйләнү тизлеген дә арттырачак. Минемчә бу ысул яхшы, ләкин водород ысулы бозлы кометалар белән чагыштырганда нәтиҗәлерәк була.



*Титан*



*Гиперион*

*3. Венераны кояш нурларыннан көзгеләр белән капларга.* Углекислый газ кояш нурларын бик үк яхшы йотмый. Венераның атмосферасы тулысынчы углекислый газдан торганага күрә, бу нурлар Венераның өслегенә барып җитә һәм аны җылыта. Венераның да нурланышы да бар, ләкин инфрокызыл диапазонга керә. Аны инде углекислый газ яхшы йота. Венераны Кояштан көзге белән капларга мөмкин. Углекислый газ коры бозга әвереләчәк. Аны ташларга яки Марска җибәрергә мөмкин (аны терраформалаштыру өчен). Мин бу ысулны яхшы дип уйлым. Марс та терраформалаштыру өчен ярдәм итәргә мөмкин.

*4. Венерага водород ташларга.* Водород углекислый газ белән реакциягә кереп, су һәм графит рәвешендәге углерод барлыкка китерә. Судан океаннар барлыкка килергә мөмкин. Алар Венера өслегенең 80% алачак. Шулай ук водород ысулы атмосфера басымын киметергә мөкин. Венера күктә иң якты җисем. Чөнки ул бик җылы. Мин Венераны 15 гыйнвар кичендә күзәттем. Планетаның өслеге космостан болытлар аркасында күренми. Минемчә бу ысул нәтиҗәле. Водородны гигант планеталар атмосферасыннан алырга мөмкин. Ләкин мондый сандагы водородны кеше өчен транспортировкалау бик катлаулы эш.



*Венераны күзәткән телескоп.*

## III. Йомгак

Проект башында мин Венераны терраформалаштыру ысулларын өйрәнүне, Венера фазаларын күзәтүне максат итеп куйдым. Һәм гипотезаларны тикшерергә:1) шәһәр-станция 50 км биеклектә төзү отышлырак, чөнки анда файдалырак шартлар, 2) аны су белән тәэмин иту һәм үз күчәре тирәсендә әйләнүне арттыру өчен планетаны астероидлар һәм бозлы кометалар белән бомбага тоту, 3) Венераны Кояштан капларга, 4) Венерага су барлыкка килсен өчен бик күп санда водород ташларга, шулай ук атмосфера басымын киметергә ярдәм итәчәк. Төрле чыганаклардан мәгълүмат җыеп аларны эшкәрткәннән соң, Венераны телескоп ярдәмендә күзәткәннән соң, тикшеренүләр үткәреп, мин шәһәр-станцияләрне өслектән төзүнең иң отышлы һәм тиз ысулы дип нәтиҗә ясадым.

Технологияләр дәрәҗәсен, Венера планетасының якынлыгын (яки ераклыгын) һәм аның үзенчәкләрен исәпкә алып, миңа моны 30-50 елдан соң тормышка ашырырга мөмкин кебек тоела.

## IV. Кулланылган әдәбият исемлеге


1. Большая энциклопедия космоса.Andrew Fraknoi. Эксмо
2. Астрономия. Учебное пособие / М.М. Дагаев и др. - М.: Просвещение, 2018
3. Кондратьев К.Я., Крупенин Н.Н., Селиванов А.С. «Планета Венера», Ленинград: Гидрометеоиздат, 1987
4. http://benepa.narod.ru/ - всё о венере
5. “Астрономический справочник”, А. Виноградова, Л. Сапогов; издат. Арена; Москва, 1999 год.

6. wikiпедия

*Разетдинова Рузилә, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы “32 нче гимназия” муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең 8 нче сыйныф укучысы*
*Җитәкчесе: Массалимова Мәүлия Минвәли кызы, югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

**Мамадыш районы Югары Ушмы төбәге татар авылларының кыскача тарихы һәм микротопонимиясе**

Туган авыл, Туган җир...

Йөрәккә нинди якын һәм кадерле бу сүзләр. Безнең һәрберебезнең газиз туган йорты урнашкан, челтерәп ага торган йөгерек чишмә буйлары, сокланып туймаслык тугайлары, балыклы күлләре, куе әрәмәләр белән уратылган елга үзәннәре, шаулап торган урманнары булган кадерле туган җире бар. Тәпиләп киткән, беренче тапкыр “әттә-әннә” дип әйтергә өйрәнгән вакыттан ук күңел түренә туган телебез аша кереп утырган ул кадерле урыннар.

Без әлеге фәнни-тикшеренү эшебездә авылыбызның тарихын өйрәндек, микротопонимик системасын тәшкил итүче атамаларны җыйдык һәм аларны лингвистик, лексик-семантик яктан анализладык, классификацияләдек.

Фәнни-тикшеренү эшебезнең темасын “Татарстан республикасы Мамадыш районы Югары Ушмы төбәге татар авылларының кыскача тарихы һәм микротопонимиясе” дип атадык. Бу теманы без актуаль дип саныйбыз, чөнки авылыбызның тарихы һәм микротопонимиясе фәнни югарылыкта монографик планда өйрәнелмәгән.

Эшебезнең төп максаты – Югары Ушмы авылының микротопонимикасын тәшкил итүче микротопонимнарның аталу тарихларын тикшерү, лингвистик, лексик-семантик яктан анализлау, атамаларны төркемнәргә бүлү һәм нәтиҗә чыгару. Бу максатка ирешү юлында без байтак истәлекләр, мәкаләләр белән таныштык, шул авылда яшәүче тарих укытучыларыннан, авыл картларыннан, зыялы кешеләрдән мәгълүматлар тупладык. Эшне башкарганда Г. Ф. Саттаров, Ф.Г. Гарипова, М.З. Зәкиев, К. Насыйри, Чернышев һ.б. ларның фәнни хезмәтләреннән файдаланылды. Эш барышында кулланылган методлар: эзләнү, чыганаклар анализы, күзәтү, нәтиҗә чыгару.

Фәнни-тикшеренү эшенең эчтәлегенә килгәндә, ул керештән, 2 бүлектән һәм йомгаклау өлешеннән гыйбарәт.

1.Авылым тарихы

Авыллар турында сүз алып барганда алар урнашкан мохит турында сөйләү, һичшиксез зарури.

Мамадыш районының атамасы район үзәге булып торган Мамадыш шәһәре исеменнән алынган. Мамадыш 1781 елга кадәр авыл булган, шул елны шәһәр категориясенә кергән һәм Октябрь революциясенә кадәр өяз шәһәре саналган.

Каюм Насыйри үзенең “Зөя өязе” дигән хезмәтендә барысы да бер кеше балалары тарафыннан нигезләнгән биш авыл: Мамадыш – Әкил, Тәүгелде – Мамадыш, Мамадыш – Сатылган, Бигай – Мамадыш һәм Мамадыш – Гордеевоны күрсәтә. “Ахры бу авылларның Мамадыш дип аталуына сәбәп шулдыр: Җәмәт балаларының берсе агасы янына барганда, юлда берәү очраган: “Кая барасың?” – дигән. Ул әйткән: “Мәмдәшләргә барам”, ягъни туганнарым-имчәктәшләрем катына барам, дигән икән. Шул сүздән чыккан Мәмәдәшләр авылы, ахрысы, Мамадыш авылы дигән исем алган. Бәгъзылар риваять кылалар. Бу Җәмәт дигән адәм Мамадыш каласында кадим булган Бабадыш бабаның нәселеннәндер. Иске заманда Болгарда “Мәмәдәш” дигән берәүнең ләкабе (кушаматы) булгандыр. Монда янә башка төрле риваятьләр бардыр”, - дип яза Каюм Насыйри.

Мамадыш шәһәреннән 18 км көнбатышка таба Югары Ушмы авылы урнашкан. Аңа 16 нчы гасырның беренче яртысында нигез салынган. 18 нче гасыр, 19 нчы гасырның беренче яртысында халык катламын крестьяннар тәшкил иткән. Алар җир эшкәрткән, терлек асраган.

Югары Ушмыны икенче исем белән Морза дип, шулай ук аны урысча Ярмаково дип тә атаганнар. Аннан аңлашылганча, Югары Ушмы авылын Ярмәк морза биләгән икән. Бу хакта түбәндәге риваять тә кызыклы:

“Кайчандыр бу гүзәл җир урынында зур сазлык, куе наратлык булган диләр. Бу авылга иң беренче булып Ярмөхәммәд (Ярмәк) исемле морза килеп утырган. Ул бик бай кеше була. Авыл тирәсендәге сазлык урманнарны бетереп, колларыннан көтүлек һәм чәчүлек җирләре ясаткан. Гасырлар буенча авыл әкренләп үскән, авыл халкы маллар асрап, иген игеп көн күргән. Авылны шуңа “Морза авылы” дип йөрткәннәр күрше авыллар, ә урыслар “Ярмак” дип атаганнар”.

Тора-бара “Морза” авылын, Ушмы елгасының югары агымында урнашканлыктан, Югары Ушмы дип йөртә башлаганнар.

1859 елгы мәгълүматлар буенча, авылда мәчет була. XX йөз башында авылда 2 мәчет, 2 мәктәп, 2 су тегермәне, ярма яргыч, 4 вак-төякләр кибете эшли. Авыл җәмәгатенең имана җире 824,4 дисәтинә тәшкил итә.

1920 елга кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Иске Комазан волостена керә. 1920 елдан ТАССР ның Мамадыш кантонында. 1930 елның 10 августыннан Мамадыш

районында. Хәзер Югары Ушма авыл җирлеге үзәге. 1931 елда авылда “Оборона” колхозы оештырыла (анда колхоз идарәсе урнаша). 1960 еллар башында авыл “Калинин” һәм “Доброволец” колхозлары белән “Татарстан” колхозына берләштерелә (Алкин, Акчишмә, Иске Завод, Хәсәнша, соңрак – Эшче авыллары). 1973 елда “Татарстан” колхозы – “Ушмы” совхозы, 1994 елда – “Ушма” күмәк предприятиесе, 2002–2005 елларда “Ушма” авыл хуҗалыгы җитештерү кооперативы итеп үзгәртелә. Халкы кырчылык, сөт терлекчелеге белән шөгыльләнә.

1920 елларда авылда башлангыч мәктәп ачыла (төрле биналарда урнаша; 1924 елда яңа бина төзелә), 1951–1957 елларда – җидееллык, 1961 елда сигезьеллык, 1983 елда тулы булмаган урта мәктәп (1983 елда яңа бина төзелә) итеп үзгәртелә.

1984 елда мәктәп каршында 37 нче урта һөнәри техник училище филиалы ачыла (тракторчы-машинистлар әзерләнә).

Мәктәп каршында 1996 елдан “Мирас” төбәк тарихын өйрәнү музее эшли, экспозициясе авыл, мәктәп тарихына, Бөек Ватан сугышында катнашучыларга, шул исәптән А.Матросов батырлыгын кабатлаган, 299 нчы Харьков укчылар дивизиясенең 969 нчы укчылар полкы рядовое А.Мөхәммәдиевкә багышлана (оештыручысы – Ф.Л.Хәйруллин, җитәкчесе – И.М.Вәгыйзов). Мәктәп каршындагы балалар иҗтимагый берләшмәсе Герой исемен йөртә, 1989 елда мәктәп алдында аның бюсты куела.

Бөек Ватан сугышы елларында авылда Мәскәүдән эвакуацияләнгән балалар урнаштырыла (Югары Ушмы урман пункты белән бергә 282 кеше).

Хәзер авылда мәктәп, балалар бакчасы (1977 елдан, 2008 елдан мәктәп бинасында), фельдшер-акушерлык пункты (1933 елдан медпункт, 2012 елда яңасы төзелә), мәдәният йорты (1964 елдан клуб), китапханә (1953 елда уку өе буларак нигезләнә), “Фатыйх” мәчете (1994 елдан) бар.

**Күренекле кешеләре** Ф.Г.Мөхлисов (1935 елда туган) – математик, физика-математика фәннәре докторы, профессор, ТР ның атказанган фән эшлеклесе.

## 2.Югары Ушмы авылының микротопонимиясе

Географик атамаларның җыелмасын, аларның килеп чыгышын, ясалышын, кулланылыш һәм үсеш эволюциясен, мәгънәсен, таралышын топонимика фәне өйрәнә һәм тикшерә. Микротопонимика – топонимика фәненең аерым төбәк, шул тирәлек-урын кешеләре өчен генә билгеле булган географик атамалар (микротопонимнар) җыелмасын өйрәнә торган бер бүлеге.

Билгеле булганча, бабаларыбыз елга-суларны изгеләштергәннәр, аларга табынганнар, гыйбадәт кылганнар, шәһәр һәм авылларны елга-инеш, күл, чишмә-кизләү тирәләренә торгызганнар. Халыкның тормыш-көнкүреше су белән бәйле. Су янында

урманы, тавы, аланы, изге, иске йорт  урыннары була. Югары Ушмы тәбәге татар авыллары тарихы турында мәгълүмат җыйганда, авыл тирә-юнендәге географик берәмлекләрне һәм легенда-риваятьләрне дә файдаландык, чөнки алар торак пунктларның тарихын ачыкларга булышалар.

Күренекле галимнәр, фән эшлеклеләре озак еллар дәвамында топонимиканы өйрәнү белән шөгыльләнәләр. Академик Гомәр Саттаровның “Туган җирем, туган авылым”, “Атамалар дөньясына сәяхәт”, профессор Фирдәүс Гарипованың “Авылларны сөям җаным-тәнем белән”, “Авыллар һәм калалар тарихыннан” дигән китапларында татар авылларының килеп чыгу тарихлары белән беррәттән ономастика турында бай һәм кызыклы мәгълүмат бирелгән.

Вак чишмәләрдән зур елгалар барлыкка килә, кечкенә авыллар тарихыннан олы тарихыбыз – туган илебез, Ватаныбыз тарихы туа. Кем булуыңны белү өчен туган ягыңны тарихи яктан гына өйрәнү җитми, ә географик яктан өйрәнү дә зур әһәмияткә ия.

Авылыбызның микротопинимик системасын тәшкил итүче микротопинимнар арасында бик күптәннән исемләнеп, әллә ни зур үзгәрешләр кичермичә, буыннан-буынга күчеп, ерак гасырлар аша безнең көннәргә килеп җиткәннәрен дә, әле генә атала башлаганнарын да очратырга мөмкин. Шулай да аларның күбесе борынгы атамалар. Шуларга тулырак тукталып үтик.

Географик объектларны атау өчен, Югары Ушмы халкы телендә әдәби телебездә кулланыла торган терминнар йөри: тау, үр, кыр, басу, юл, болын, алан, үзән, елга, сукмак, чокыр, яр, күл, саз һ.б. Җирле халык географик объектларны атау өчен, диалекталь сүзләрдән дә файдалана. Шундыйлардан атау, туйралык (имәнлек), чүнник кебек диалекталь географик номенклатура терминнарын күрсәтеп үтәргә мөмкин.

Югары Ушмыда таулар һәм чишмәләр бик күп. Бу авылда ике йөзләп чишмә бар. Аның кадәр чишмәле авыл, безнеңчә, беркайда да юктыр. Һәр чишмә һәм тауның үз исеме, үз тарихы бар.  Кайберләренә тулырак тукталып үтик.Мәсәлән, **“Кармыш” чишмәсе**.Бер кеше урактан кайтып килә икән. Бик каты су эчәсе килгән. Шул урында кечкенә генә чокырдан ятып су эчкәч, чишмә ясарга уйлаган. Ул бу урынны казый һәм улак куя. Кайтып барганда аңа иптәше очрый. “Кайдан кайтып киләсең?” – ди. “Урактан. Чишмә таптым. Суы бик тәмле, бик салкын. Кар шикелле. Мышный-мышный эчтем.”- дигән. Шуннан соң кар + мыштан “Кармыш” сүзе барлыкка килгән.

Еллар узган саен чишмә суын  авылга төшерүче торбалар искерә, су авылга килүдән туктый. Ә 2014 елда чишмәне яңа торбалар белән кабат авыл эченә төшерәләр.

**«Әпти» чишмәсе.**Кайчандыр, бик күптәннән бу урында куе сазлык булган. Кешеләргә су эчәргә чишмә кирәк булган. Гаптрахман исемле бер кеше бу сазлыктагы су

чыгып тора торган урыннан чишмә казып чыгара. Шул вакыттан соң бу чишмәне “Габдрахман”, “Әптери” һәм соңга таба “Әпти” чишмәсе дип йөртә башлыйлар .

**“Таллы елга” яки “Әлфинур” чишмәсе.**Кайчандыр, бик күптәннән бу урында куе таллык булган. Бу таллыкны кырып җитен чәчкәннәр. Шул урында чишмә ясалган. Шул вакытта бу чишмәгә “Таллы елга”дип исем бирелгән.

Берничә ел элек бу чишмәне бик яхшылап төзәттеләр. Аны башлап йөрүче авыл советы җирлеге рәисе Васылов Н.М. булды. Ул бу чишмәне әнисе истәлегенә аның исеме белән атады һәм “Әлфинур чишмәсе” дигән язу куйдырды. Әлфинур ханым озак еллар Югары Ушмы урта мәктәбендә балаларга рус теле һәм әдәбиятыннан белем биргән укытучы, тыл ветераны. Аның исеменә аталган чишмә өлкән буын кешеләре өчен һаман да “Таллы елга чишмәсе” булып кала.

**«Мулла» күле**. Габдрахман муллага аталган күл.

**Ушмы елгасы.**“уш”, “ош” – мари теленнән комлы су, куелык дигәнне аңлата. Элек анда баткаклы урыннар, нарат урманнары булган. Елга Мамадышта Нократ елгасына коя.

**Сәйпи түбәтәе.**Ул артык биек булмаган, ләкин бик матур фигуралы калкулык. Ул тышкы күренеше белән түбәтәйне хәтерләтә. 1890 нчы елларда бай булмаган, урта хәлле крестьянСәйфи бу калкулыкны сукалап, тырмалап анда тары чәчә. Тары калкулык битендә яхшы, ә югары күтәрелгән саен начаррак уңган булган. Ул бу калкулыкны әйләндереп алган, барлык якларын да эшкәрткән. Сәйфи үзе дә еш кына: “Минем түбәтәем” – дип сөйли торган булган. Һәм бу калкулык Сәйфи түбәтәе исемен алып калган.

**Чтапан чокыры.** Бу чокыр елга ярыннан башланып урманга барып тоташа. Урта өлешләрендә ул 3 кисәккә аерыла. Шушы өлешеннән түбәнрәк сазлык таллык. Кайчандыр бу чокырның төньяк – көнбатыш ярында Таулар дигән рус авылы урнашкан була. Көз көне Степан исемле бер кеше печәннән кайтан чакта арбасы астында кала һәм үлә. Шушы вакыйгадан соң бу чокырны Степан чокыры дип йөрткәннәр. Соңыннан Степанны татарчалаштырып, Чтапан дип йөртә башлаганнар. Берникадәр вакыттан соң бу рус авылы төрле татар байлары җәберләүләренә түзә алмыйча калдырып күчеп китәләр.

Без бу эшебездә Югары Ушма авылының микротопонимик материалын лексик – семантик – тематик яссылыкта анализладык, аны төркемнәргә бүлдек.

**1. Кеше исемнәренә һәм кушаматларына нигезләнеп ясалган микротопонимнар:** Әпти чишмәсе, Чтапан чокыры, Кадермәт үре, Сәйпи түбәтәйе, Бәһрәм аланы, Садыйк аланы, Фатыйх чүнниге, Локман аланы, Бакый елгасы, Тришкин тегермәне, Салих умарталыгы, Алексей аланы, Сарсат аланы, Демьян почмагы, Сәлимә тыгрыгы.

**2. Туганлык терминнарына һәм сословие титулларына нигезләнеп ясалган микротопонимнар:** Мулла күле, Хан юлы, Мулла тыгрыгы.

**3. Үсемлекләр дөньясы (флора) белән бәйләнешле микротопонимнар:**

Таллы елга чишмәсе.

**4. Хайваннар дөньясы (фауна) белән бәйләнешле микротопонимнар:** Бурсык үзәне, Умарта чишмәсе.

**5. Географик объектның төсенә карап аталган микротопонимнар:** Кызыл юл, Каракүл.

**6. Географик объектның зурлыгына, күләменә, формасына, санына карап аталган микротопонимнар:** Олы урам, Бәләкәй тугай, Туры үзән, Биек күпер, Биш алан, Олы тугай, Бөкереш юлы.

**7. Эш – хәрәкәт, берәр вакыйга белән бәйләнешле микротопонимнар:** Котылдык урамы, Чүмерче урамы, Янганнар аланы, Тәңкә урамы, Парник асты, Таш юл.

**8. Берәр әйбернең, билгенең табылуы, булуы белән бәйләнешле микротопонимнар:** Җиләкле алан.

**9. Октябрь революциясеннән соңгы вакыйгаларга, тормыш – көнкүрешкә бәйләнешле рәвештә барлыкка килгән микротопонимнар:** Комсомол урамы, “Татарстан” колхозы.

Без күптөрле географик объектларны очраттык. Югары Ушмы авылының микротопимик материалын лексик-семантик-тематик яссылыкта анализладык.

Елга, чишмә, тау һәм болыннарның аталу тарихын өйрәнеп, без түбәндәге нәтиҗәгә килдек: топонимик атамалар безгә борынгы әби-бабаларыбызның тормыш-көнкүреше, һөнәрләре, гореф-гадәтләре, тарихы, теле, төбәкнең табигате, географик үзенчәлекләре, авыл халкының этник составы, кәсебе турында мөһим мәгълүмат бирәләр. Һәрбер җирле атама – үзенең килеп чыгышы, барлыкка килү мәгънәсе белән чал тарих хәбәрчесеикән.

## Йомгаклау

Югарыдагы өйрәнүләрдән китерелгән мисаллардан чыгып, түбәндәге нәтиҗәләрне әйтергә мөмкин:

1. Авыллар тарихы турында сүз алып барганда алар урнашкан мохит турында сөйләү, һичшиксез зарури.

2. Авылда җыелган микротопонимик атамалар – безнең чал тарихыбыз, ата-бабаларыбыздан калган газиз мирасыбыз. Һәм аларны җыйнау – безнең изге бурычыбыз.

Эш барышында алдыбызга куйган максат һәм бурычларны чиштек. Тикшерү эшен йомгаклап, шуны әйтәсе килә: топонимик атамалар – халык иҗатының гасырлар буена җыелып килгән асыл җәүһәрләре, үзенчәлекле мирасы. Танылган язучы К. Паустовский

бик дөрес бәя биргән: “Урын-җир исемнәре халыкның үз илен шагыйранә бизәве ул. Аларда халыкның холкы, тарихы, һәвәскәрлеге һәм көнкүреш үзенчәлекләре чагылыш тапкан”.

Киләчәктә дә авыллар тарихын язу дәвам итсен, авылларның матурлыгы, кешеләрнең уңган булуы башка буыннарга барып җитсен иде. Чөнки үткәнен белмәгәннең киләчәге дә юк.

**Файдаланылган әдәбият.**

1. Бурганова Н.Б. О системе народногопраздника джиен у казанских татар./ Исследования по исторической диалектологии татарского языка. – Казань, 1982. – 47б.

2. Гарипова Ф.Г. Авыллар һәм калалар тарихыннан. - Казан, 1997. - 559б.

3. Насыйри. К. Зөя өязе авыллары. Сайланма әсәрләр. Т. II. - Казан, 1975. - 31б.

4. Золотницкий Н.И. Корневой чувашского – русский словарь. – Казань, 1875. – 261-262б.

5. И.А. Износов. Два реферата, читанные на IV Археологическом съезде в Казани в 1877г. – Казань, 1882.

6. Саттаров Г.Ф. Ни өчен шулай аталган? - Казан, 1971. - 127б.

7. Саттаров Г.Ф. Атамалар дөньясына сәяхәт. - Казан, 1992. - 240б.

8. Саттаров Г.Ф. Татар исемнәре ни сөйли? - Казан, 1998.

9. Татарстан АССР тарихы, Тат.кит.нәшр., Казан, 1957.- 61б.

10. Чернышев Е.И. Селения Казанского ханства, Сб., Вопросы этногенеза тюркоязычных народов Среднего Поволжья. - Казань, 1981.-285б.

*Сафин Алмаз, 7 нче сыйныф*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «35 нче лицей » муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчесе: Кәримова Рәсимә Габделхәй кызы, беренче категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

## М.Җәлил иҗатында кеше һәм табигать күренешләренең үзара мөнәсәбәте

Без – яңа гасыр яшьләре! Без - компьтерлар, яңа технологияләр чорында яшибез. Мин татар кешесе буларак, үз телемә гашыйк, туган җиремне, әти-әниемне, энемне яратып, кайгыртып яшим. Киләчәктә телебез, иманыбызның нык булуын телим. Киләчәктә яшьтәшләрем татар халкының тарихын, телен, әдәбиятын белеп, халкымның горур кызлары һәм уллары булып үсүен телим мин.

Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә без танылган әдипләрнең әсәрләрен яратып өйрәнәбез. Мин яраткан шагыйрьләремнән Габдулла Тукай, Муса Җәлил, Разил

Вәлиевларны санап китәр идем. Аларның иҗатында татар халкын кайгырту, туган җиргә мәхәббәт чагыла.

Бүгенге чыгышымда Муса Мостафа улы Җәлиловка тукталасым килә. Муса Җәлил – минем яраткан шагыйрьләремнең берсе. Ул – татар халкының бөек шагыйре. М. Җәлил язмышы белән безгә батырлык һәм героизм үрнәге калдырган. Безгә килеп җиткән шигырьләре Моабит төрмәсендә, үлемгә хөкем ителгәннән соң, туры мәгънәсендә «палач балтасына башны тоткан килеш» язылганнар. Бу факт үзе генә дә Муса Җәлилне бөтен дөнья халкы алдында тиңдәшсез батыр итеп таныта.

Муса Җәлилнең иҗаты күпкырлы. Аның иҗатын, тормыш юлын Гази Кашшаф, Рафаэль Мустафин кебек галимнәр өйрәнгән. Гази Кашшаф, Муса Җәлилнең 1935 нче елда язылган бер хатыннан, мондый юллар китерә:

«Мин тормышта тирән һәм ялкынлы сөя беләм. Мин табигатьне дә, кояшны да, чәчкәне дә, музыканы да һәм намуслы хезмәтне дә, ялкынлы иҗатны да, тиңдәшсез илемне дә шулай ук янып, кайнарланып сөям. Бу минем эчке тирән бер сыйфатым инде».

Чыгышымның **төп максаты** булып Муса Җәлил иҗатында кеше һәм табигать күренешләрен анализлау тора. М. Җәлилнең сугыш чорында язылган "Сандугач һәм чишмә" балладасына тукталып китәм...

**Баллада** – нинди дә булса фантастик, фольклор, риваять нигезендә төзелгән сюжетлы лиро-эпик әсәр ул.

"Сандугач һәм чишмә" балладасында җанлы табигать вәкиле – Сандугач һәм җансыз табигать вәкиле – Чишмә катнаша.

Сандугач - таң җырчысы, таң кошы, матурлык билгесе. Сандугач сөюне, мәхәббәтне, тугрылыкны гәүдәләндерә. Чишмә - сафлык, чисталык образын чагылдыра. Сандугач һәм Чишмә бер- берсе өчен нишләргә белмичә яшиләр, алар - чын "сердәшләр". Көннәрнең берсендә Сандугач үзенең сердәше янына килгәч, аны танымый...

*"Сандугач уянып*

*Канатын кагына*

*Һәм карый ашкынып*

*Тын урман ягына.*

Җанландыру күренеше чишмә образында тагын да көчлерәк тоела:

*Килде тиз сердәше*

*Чишмәгә...*

*Тик аның*

*Кайгылы моң баскан*

*Чәчәкле буйларын.*

*Чишмә тын; ул көлми,*
*Тибрәнми, селкенми;*
*Акбүз таш өстендә*
*Тамчылар сикерми.”*

Чишмә үзенең моңсулык сәбәбен сөйли. Батыр егетнең су эчәргә килүен әйтә. Сандугач - табигатьнең матурлык символы буларак тасвирлана.

*“Иркәли таң кошын*
*Зөбәрҗәт тамчылар.*
*Әйтче, бу күрнешкә*
*Сокланмый кем чыдар?!*
*Сандугач аз гына*
*Уйланып торды да*
*Җанланып эндәште*
*Чишмәгә тын гына:*
*“Кайгырма, күз нурым!*
*Ул килсә эчәргә,*
*Коткарам мин үзем,*
*Мин беләм нишләргә!”*

“Сандугач һәм Чишмә” балладасында батыр символы – үзәк символларның берсе. Батырның төп сыйфаты аның үзенең сүзләрендә ачылып килә:

*“Ул улы хөр илнең*
*Һәм бөек атаның,*
*Ялкынлы йөрәктән*
*Ул сөя Ватанын”.*

Шулай итеп, Сандугач һәм Чишмә үзләренең символик образлары белән Ватан һәм туган илне, туган якны, туган табигатьне берләштерә:

*“Яшәде ул сөеп*
*Һәм үләр бер көнне*
*Нәкъ мәгърур Сандугач*
*Һәм Чишмә шикелле”.*

Мин Муса Җәлилнең “Сандугач һәм Чишмә” поэмасында кеше һәм табигать үзенчәлекләрен күзәттем. Шагыйрьнең йөрәгеннән чыккан җырларын без киләчәктә дә яратып укырбыз, яратып җырларбыз. Татар халкының горур улы – Муса Җәлилне без һәрвакыт олылап һәм ихтирам белән искә алырбыз.

Сүземне йомгаклап, шуны әйтәсем килә: без Муса Җәлилне батырлык символы итеп беләбез. Аның фашизмга каршы көрәшен таныйбыз. Әдәбият дәресләрендә патриотик эчтәлекле әсәрләрен укып, әдипнең шигъри дөньясын, табигатькә сакчыл карашын, һәрнәрсәне яратып, хөрмәт итә белү сыйфатларын өйрәнеп , укучыларда туган илгә мәхәббәт тәрбияләнә дип уйлыйм..

**Кулланылган әдәбият**

1.Галиуллин Т. Керсез йөрәк монологы // Җәлил М. Әсәрләр. – Казан: Мәгариф, 2004. – Б. 8-9.

2.Җәлил М. Әсәрләр. Дүрт томда. 1 нче том. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1968. – 558 б.

3.Җәлил М. Әсәрләр. – Казан: Мәгариф, 2004. – 271 б.

4. Мостафин Р. Муса Җәлил эзләре буйлап (очерклар). – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1968. – 152 б.

5.Кашшаф Г. Муса Җәлил, тормыш һәм иҗаты турында очерклар. – Казан: Матур әдәбият редакциясе, 1957. – 380

*Ситдиков Булат, 4 нче сыйныф, Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре “54 нче гимназия” муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*

*Җитәкчесе: Садыкова Назлыгөл Заһир кызы, беренче категорияле башлангыч сыйныф укытучысы*

**Якын дуслар!**

1. Яннарыңда якын дуслар булу
Шундый рәхәт, якын күңелгә.
Колач җәеп сине каршы ала
Бу сагадан атлап керүгә.

2. Балачакның матур мизгелләре
Мәктәп елларына тоташа.
Уен, көлке, җыр һәм бию
Күңел дәфтәренә урнаша.

3. Вакыт узган саен шушы дәфтәр
Кат-кат итеп уйдан укыла.
Якты хатирәләр искә төшеп,
Мең кат дуслар тагын яңара.

4. Алар булган җирдә тынып тормый
Шат авазлар, сорау җаваплар.

Илләр тыныч, күкләр аяз булсын

Очрамасын юлда газаплар.

*Солтанова Эльвина, 7 нче сыйныф, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Муса Җәлил исемендәге "1 нче гимназия" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*

*Җитәкчесе: Сөнгатуллина Ләйлә Мөхәмәт кызы, югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

**Без яшь чакта**

(Хикәя)

Минем карт әбием "әй, без яшь чакта..." дип сүзен башласа, бу сөйләшүне тиз генә тәмамланыр дип уйлама. Инде җыерчыкланып какланган куллары белән яулыгын артка таба шудырып куя да тәмләп кенә сөйли башлый. Шулкадәр тәмләп сөйли белә инде, барлык булган эшләреңне калдырып, аның янына барып, "өннән чыкканыңны" сизми дә каласың. Сорау артыннан сорау яудырып, аның авызыннан чыккан һәр сүзен чүпләп утырганыңны сизми дә каласың. "Без яшь чакта кешеләр дә башка иде,"- ди. Бәләкәй чагымда бу сүзләрне колак кырыеннан гына үткәрсәм, үсә төшкәч, ул сөйләгән хәлләргә кире кайтып сөйләтәм. "Нинди иде соң алар ?"- дим. Сорау да биргәч, тагын да җанланып китә әбекәем. "Бик гади иде кешеләр, йомышлыклы, эчкерсез иде. Бер-беребез өчен үлеп тордык. Ачлык, ялангачлык галәмәтләрен бергәләп, күмәкләп җиңдек. Алабута белән черек бәрәңге оныннан пешерелгән кара икмәгең булса, бер чынаяк чәйдән өстен булмый идек. Әнә, күрше Нурaниягә кереп кара хәзер, чолан төбендә йомышыңны әйттерә дә бикләнеп кереп тә китә. Кеше кешедән курка, балакай!"-ди. Менә бит ничек, элекке кеше бүредән курыккан, аннан куркып урманга бармый тормаган, ә хәзер бер-беребездән куркабыз икән... Кызык бит!

Бер уч арпа өчен төрмәдә утырган әтисе турында сөйләгәндә, йөрәкнең иң тирән җирләре актарыла. Мондый хәл уйдырмадыр кебек тоела. Күрше авылдан кайтып барганда, юл кырыеннан учына арпа башакларын өзеп алган, бичаракай. Атта узып баручы авыл старостасы, караклыкта гаепләп, төрмәгә яптырган. "Арпа өлгердеме икән әле дип өзеп кенә карадым,"- дип күпме генә ялынса да, ишетүче булмаган. "Бәлки, бер уч түгел, бер капчык булгандыр ул, әбекәй?"- дим. Ул әйтергә өлгергәнче, җавабын үзем дә табам. Бер капчык арпа өзсәң, атып үтерә торган заманнар булган шул ул. Яңа бистәнең татар зиратына күмелгән әтисенең каберен беркайчан да күрә алмаган карт әбием. Ул күмелгән номерны да белә алмаган. Казан шәһәренә китеп урнашасы килү теләгем дә шушы хәл белән бәйле минем. Әбием миңа: "Кызым, архивлардан документларын табарсың әле,"- ди.

Әнисе Оркыяны 1933 елгы ачлык тагын бер кат бәхетсез итә. Карт әбиемнең әтисе үлгәч, әнисенә өч бала һәм үзенең тамагын туйдыру кыенлаша. Җитмәсә, җирдәге корылык  ачлык алып килә. Җан асрау өчен халык ниләр генә эшләмәгән. Урамда мәче, эт затлары калмаган заманнар. Әле аның өстенә налогны халыктан сыгып алганнар. Сарык башыннан да сөт белән май тапшыртып аптыратканнар. “Ач сыерлар бирә алмаган сөтне ничек итеп сарык бирсен инде”,- дип тагын дәвам итә әбекәем. Шундый салкын февраль иртәләренең берсендә өйләренә тентү килеп керә. Эзләгән әйберләрен тапмасалар да, кулга алалар әниләрен. Сәбәбен дә аңлатмыйча, төрмәгә ябалар ананы. Айлар буе эзәрлеклиләр әбиемнәрне, анагыз урлап яшергән онны күрсәтегез дип. Оркыя әбинең яулык очына төйнәп алып кайткан онын, әлбәттә, таба алмый тентүчеләр. Карт әбием 70 километр ераклыктагы Панаука (әбием шулай атый) төрмәсенә атна саен бара, әнисенең гаебе юклыгын расларга тели. Соңгы баруында, чирләп киткән әнисен алып кайтып китәргә кушалар аңа. Әбием ат җигеп килгәнче, әнисе үлеп тә китә. Берүзе чанага салып әнисен алып кайта, үз куллары белән кабер казып җирләргә туры килә яшь кызга. “Шундый авырлыклар кичәргә туры килде инде, балам,”- дип күзендәге энҗеләрен яулык очы белән сөртеп алырга өлгеми, тагын сөйли башлый.

“Без яшь чакта ярату, мәхәббәт дип өзгәләнүче булганын хәтерләмим мин,”- дип көлемсерәп дәвам итә карт әби. Карт бабама кияүгә чыгу тарихын елмаю аша канәгатьлек белән сөйли. Күрше авылга Сабан туена барган җирдән кияүгә калган. “Минем ике сеңлем дә бар,”- дигәч, алар да безнең белән яшәрләр дип күндергән егет. “Ну бабагыз “маладис” иде, әйткән сүзен үти торган батыр ир булып чыкты,”- дип кеткелдәп көлеп тә куя әбекәй. Үзең дә сизмәстән: “Кара әле, карт әби белән карт бабам 60 ел бергә гомер кичергәннәр. Өйләнешкәнче бер-берсен күрмәгәннәр дә бит. Бабамны искә алганда, әбекәйнең күзләре балкый,”- дип уйлап куясың.

“Әй, без яшь чакларда,”- дип тагын дәвам итә карт әби.

*Фаррахов Ислам,  4 нче сыйныф, Татарстан Республикасы  Л.Айтуганов ис. Девятерня төп гомумбелем бирү мәктәбе*
*Җитәкче: Габбасова Гүзәлия Гыез кызы, башлангыч сыйныфлар һәм туган (татар) теле укытучысы*

**Туган авылым топонимнары**

Без- төньягы татар иленең,
Бер тамчысы Бөек Иделнең.
Мин чишмәңә бүген иелдем.
Тарихларга чумдым, күмелдем.

Туган җир, туган йорт, туган авыл, Ватан! Болар - күңел түрендәге иң кадерле сүзләр. Үсә барган саен, Туган җир төшенчәсе киңәя, авыл кадере арта. Һәркемгә үз туган җире, иле кадерле. Үз тарихын, мәдәниятен, үткәнен, киләчәген, телен белгән кеше генә бәхетле була, туган илен ярата, башка халыкларга хөрмәт белән карый. Шуны истә тотып, мин туган авылым ономастикасын өлешчә өйрәнә башладым. Күршедә яшәүче әби-бабайларның, апа- абыйларның үткәннәргә кайтып, сөйләшеп утырулары да кызыксынуымны арттырды.

**Эшемнең актуальлеге:** авыл тарихын яхшы белүче өлкәннәребез саны елдан-ел кими. Әгәр эзләнү эшен башламасак, соңга калуыбыз ихтимал. Ә авылым тарихы- ил тарихының бер тамчысы.

Авылыбыз кушаматларга бик бай. Исемнәрне бозып әйтү, кушамат тагу –балалар арасында гына түгел, өлкәннәр арасында да киң таралган. Мин үзем, кешенең исемен бозмыйча, әдәби телдә кабул ителгәнчә дөрес әйтү һәм язу яклы. Бергә укыган иптәшләремнең дә моны аңлауларын телим. Кушаматларның барлыкка килү үзенчәлеге, ясалу ысуллары, кешегә тагылу сәбәбе турындагы эзләнү эше нәтиҗәсендә тупланган мәгълүматлар тәрбияви әһәмияткә ия.

**Эшемнең максаты**: эзләнү эшчәнлеге өчен кирәкле белем һәм күнекмәләр булдыру; авылыбыз ономастикасын тикшереп, татар халкы тарихын, тел үзенчәлекләрен өйрәнүгә үземнән дә өлеш кертү; кушаматларның барлыкка килү сәбәпләрен ачыклау.

**Бурычлар:** төрле бәйгеләрдә чыгыш ясау күнекмәләрен булдыру; үземдә аралашу этикетын һәм толерантлык тәрбияләү.

**Эзләнү методлары**: күзәтү, әңгәмә, төрле чыганаклар белән эшләү.

**2.1. Этнонимнар тарихыннан**

Мин үземнең туган авылымны яратам. Татар булуым белән горурланам. Үз телемдә укыйм, язам, шигырьләр иҗат итеп, балалар газета- журналларына җибәрәм. Аларның бастырылып чыгуына күңелем шатлана.

Күңелгә бер сорау килә: ни өчен безне татар диләр? Бу сорауга җавап бирү өчен, ономастиканың ыруг-кабилә, халык һәм милләт исемнәрен өйрәнә торган этнонимика бүлегенә мөрәҗәгать итәм.

Татар этнонимын, исем буларак, ике төргә бүләләр: 1) уртаклык исеменә яки 2) ялгызлык исеменә кайтарып калдыралар. Фикерләрнең күпчелеге безгә татар сүзенең төрки тамырларга кайтуын һәм “ятлар, чит кабилә кешеләре” мәгънәсен бирүе турында сөйли. “Хәзерге татар әдәбияты теле” ,”Татар грамматикасы” (1 нче том) китапларында фәнни яктан исбатлана.

Татар этнонимы ул гомуми атама да санала, чөнки аның эчендә үзатамалар: мишәр, керәшен, тубыллы, казан кешесе берләшә.

Үзатама- кабилә яки халыкның үзен-үзе атый торган исеме. Татар сүзе, үзатама булып, XX йөз башларына кадәр керми торган.

Кабилә яки халыкны башка халыклар бүтәнчә атарга мөмкин, монысы чит атама була. Мәсәлән, безне марилар суас диеп, удмуртлар бигер, казаклар ногай дип атыйлар. Болар - татарның чит атамасы.

Этнонимнар кыйммәтле тарихи мирас буларак, халык тарихын өйрәнүдә зур роль уйный. Татар- тарихта эзле халык. Бу тарихка үземнән бер тамчы өлеш кертәсем килде.

**2.2.Девятерня авылының кыскача тарихы һәм микротопонимиясе**

Топоним-грек теленнән алынган термин (topos- урын, җир; опута-исем). Топоним - урын-җир, географик исемнәр.Ул аларның килеп чыгышын, ясалышын өйрәнә һәм тикшерә. Микротопонимика- топонимика фәненең аерым төбәк, шул тирәлек кешеләре өчен билгеле булган географик атамалар җыелмасын өйрәнә торган бер бүлеге.

Микротопонимика һәрдаим барлыкка килүе белән бик кызыклы. Вакытлар үтү белән, кайбер географик атамалар онытылып, аларга яңа исем кушыла, ә күбесе исә борынгы исемнәре белән кулланышта йөри.

Авылымның микротопонимик системасын тәшкил итүче микротопонимнарга күз салсак, зур үзгәреш кичергәннәрен һәм шул килеш сакланганнарын да күрәбез. Алар арасында бик кызыклы фактлар да күзәтелә.

Девятерня топонимы. Девятерня (Мазарасты)- Иж елгасы бассейнындагы Кады суы буена утырган авыл. Әгерҗедән 80 км көньяк- көнчыгышта. Халкы- татарлар. 1722 нче елдан билгеле. Авылның элекке исеме Мазарасты була. Мазар –зират дигән сүз, димәк, зират асты дигәнне аңлата. Авылыбыз тарихы, халкы турында күп мәгълүматлар туплаган хөрмәтле кешесе, күршебез Рәис абый Әхмәтҗанов сөйләвенчә, бик каты ачлык елларында, вафат булучылар күп булгач, еракка бармыйча, кешеләрне авыл башында гына җирләгәннәр. Ә Девятерня атамасы соңрак барлыкка килгән. Безнең якны тугызбуй ягы дип йөртәләр. Якын-тирәдә тугыз авыл урнашкан: Гали, Нарат, Кадыбаш, Исәнбай, Үтәгән, Иске-Сләк, Касай, Атнагул һәм тугызынчы авыл – Девятерня. Ул тугызынчы авыл дигәнне аңлата. Бөек Октябрь Революциясеннән соң, авыл исемендә зират сүзе булмасын дип, русча девятая деревня сүзтезмәсеннән килеп чыккан. Тагын бер риваять турында искә төшерде Зөһрә әбием. Бу авыл янына тугыз торна төшә торган булган. Бу атаманың килеп чыгуын шуның белән бәйләүчеләр дә бар. Ләкин беренчесе дөресрәк дигән фикердә калам. Бу вакытта авылыбыз Сарапул өязенә карый. Документлар урысча язылa, шуңа күрә кыскартып, Девятерня дип йөртә башлыйлар.

Буыннан буынга күчеп, безнең көннәргә килеп җиткән берничә атамага тукталасым килә.

**Ком күпере.** Туган ягым урманнарга бай. Девятерня авылының көнбатыш өлешендә Ком күпере дип аталган урын бар. Пугач яулары узганда, бик сазлыклы урынга тап була. Тиз арада күп итеп ком ташып, күпер салып та куялар. Хәзер ком юылып, чокыр хасил булса да , исеме шулай ук калган.

**Кады елгасы.** Авылымның уң ягыннан агучы кечкенә елга. Ул Кадыбаш исемле авылдан агып килә. Елга кечкенә булса да, балыкка бай.

**Көтмәс елгасы**. Кады елгасы күп сулы Көтмәс елгасына коя. Ул русча Крыкмас дип атала, чөнки ул Удмуртия ягыннан агып килә. Иж елгасына кушыла. Бу елга турында, син көткәнне, ул көтмәс дип әйтә торган булганнар. Елганың агымы бик көчле булган. Аның бик тирән урыннары күп. Җәйнең эссе көннәрендә авыл халкы бу елгага су коеныргa йөри.

**Мәгаз аланы.** Элекке вакытта урман эчендә бик чиста күл булган. Бу күлгә керү юлы бер генә булган. Мәгаз исемле кеше чытырманлыкны чистартып, юл ачкан. Кызганыч, күл кибеп беткән. Ә менә исеме хәзерге көндә дә саклана. Бу урында печән чабалар, җиләк җыялар.

**Багыш-** авылның көнбатыш ягындагы урман башы. Эчкәрәк керсәң, удмурт авылларына да ерак калмый. Көнбатыш сүзеннән кыскартылып килеп чыккан. Шунысы кызыклы, әбиләр багыштан килгән болыт яңгыр алып килә, диләр. Бу чыннан да шулай, үземнең дә күзәткәнем бар.

**Шәмкә-** яңа утыртылган агачлык булганга шулай атаганнар. Рәис абый сөйләвенчә, бу 1965 еллар булган. Хәзер бу урында бик биек наратлар һәм куе чыршылык. Авылыбыз халкы шәмкәдән бихисап күп гөмбә җыя.

**Хисмәт тегермәне.** Бу Көтмәс елгасындагы су тегермәне. Анда Хисмәтулла исемле кеше эшләгән. Күрше авыллардан күп кешеләр он тартырга килә торган булган. Әле хәзер дә бу тегермән урынында баганалары утырып калган.

**2.3.Кушамат-иҗтимагый күренеш**

Авыл җирлегенә хас бер күренеш бар: кушамат тагу. Ономастиканың кешеләрне атаучы категорияләре арасында кушаматлар үзенчәлекле урын алып тора. Кешегә кушамат тагуның сәбәбе була, ул үзен йөртүче кеше белән бәйләнештә. М.Мәһдиев, А.Гыйләҗев, Ф.Хөсни әсәрләрендә телнең бу кызыклы ягы очрап тора.

Девятерня авылы да кушаматларга бай. Эзләнү барышында бик күп кушаматларның барлыкка килү тарихын ачыкладым.

Кушаматлар ничек барлыкка килә соң? Беренчесе: кешенең күзгә ташланып торган шәхси билгеләренә карап. Бүтәкә – кечкенә һәм юан, мамык – битләрендә йомшак йоннар булган, кара бәрән - бик кара , чеби – кечкенә гәүдәле, ыштыр – кулы ыштырлы (уч төпләре ярылып беткән) була.

Икенчесе фактор: кушамат иясе белән бәйле очрак яки вакыйга. Шалун Фатих- бездә маллар шалуны белән (шалун - урысчадан эшелон дигән сүз) ди торган булган. Мыш-мыш – кечкенә вакытта сакаулыгы аркасында исемен әйтә алмый торганга кушканнар. Әрмән – басуларга элек ашлыкны саклау өчен әрлән тотарга бара торган булганнар. Хәсән абый әрлән тоттым диясе урынга, әрмән тоттым дип әйткән. Өченчедән: әйләнә-тирәдәгеләрнең мөнәсәбәте. Чегән – алдакчы һәм хәйләкәр, аю –акрын йөри, бүре- усал булган өчен, генерал Рифкать – акрын, тыныч кеше .

Дүртенче фактор: исем яки фамилиягә аваздаш. Сәлтән –Салихҗан, Сибәй – Сибгатуллин, Апия – Габдулла. Бишенчесе һөнәр белән бәйле: Кәрәчин Мәгъсүм – ягулык ташучы, чүтчик Люция – фермада сөт учетын ала. Кушаматларның “гомере” озын. Ул, иясенә генә ияреп калмыйча, аның балаларына да тагылып бара. Кушаматны искелек калдыгы дип санасак та, бүгенге көндә дә кулланыштан төшми. Минем уйлавымча, һәр кешенең исеме кадерле, шуңа күрә ихтирамга, игътибарга лаек.

**Йомгаклау**

Туган як тарихын, аның ономастикасын өйрәнү, теге яки бу географик атаманың килеп чыгуы белән кызыксыну ни өчен кирәк соң ? Кайчан барлыкка килгән, ничек барлыкка килгән, нинди мәгънә белдерүләре барыбер түгелмени? Авылыбызда яшәүчеләрнең кушаматлары ничек ясалган? Мин тырышып бу сорауларга җавап эзләдем.

Эзләнү вакытында төрле материалларны анализлап, төрле буын кешеләре белән очрашып, авылымның килеп чыгышы, топонимикасы, кушаматлар килеп чыгу турында материал тупладым.

Туган ягыбызның физик-географик объектларын өйрәндем, ул урыннарда минем булганым бар. Элекке һәм хәзерге вакытлар белән чагыштырып карадым.

Туган як ономастикасын өйрәнү туган якка кагылышлы әдәби материаллар тупларга, мөстәкыйльлегемне үстерергә ярдәм итте. Алга таба эшемне дәвам итеп, Девятерня авылы микротопонимнарын лексик-семантик яктан төркемнәргә бүлеп, киңәйтеп эшлисем килә. Шуны аңладым: мине алга ачылмаган серләр, кызыклы очрашулар өнди.

Кулланылган әдәбият

1. Атлас истории Татарстана и татарского народа. Издательство ДИК, Издательский дом “Дрофа”. Казань-Москва, 1999.

2. “Әгерҗем – йөрәк җырым”. Мансур Вәли-Барҗылы. Полиграфический-издательский комплекс «Идел-пресс», 2004.
3. Татар грамматикасы. Закиев М. З. Издатели: Инсан.Фикер, 2002.
4. Хәзерге татар әдәби теле. Сафиуллина Ф.С. “Мәгариф” нәшрияте, 2002.

*Фёдорова Милена, 8 нче сыйныф, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы «16 нчы урта белем бирү мәктәбе»*
*Җитәкче:Сәгыйдуллина Раниза Зәлиф кызы, башлангыч сыйныф укытучысы, Гайнутдинова Зәлфирә Рәшид кызы,*
*татар теле укытучысы*

## Авылым язмышы-халкым язмышы

Соңгы елларда туган якны өйрәнүгә зур игътибар бирелә башлады: мәктәпләрдә,культура сарайларында туган якны өйрәнү музейлары ачыла,газета-журнал битләрендә авыллар тарихына караган язмалар басылып чыга,аерым китаплар нәшер ителә.

Минем дә киләчәк буын өчен игелекле эш башкарасым килде һәм, иң кулае дип, фәнни-эзләнү эше язуны сайладым. Илһам чыганагы, яшәргә көч һәм дәрт бирүче күңел маягы булган туган авылыбыз тарихы турында язганда баштан төрле уйлар кичте. Шуларны башкалар күңеленә дә җиткерәсем килә.

Туган төбәк тарихын өйрәнгән вакытта, мин тагын бер нәрсәне аңладым. Бары тик туган як, гаилә, урам, авыл, мәктәп, халкың тарихларын белсәң генә, Бөтендөнья һәм Ватан тарихын тиешле дәрәҗәдә үзләштерергә мөмкин. Ә безнең авыл тарихы турында белешмәләр юк дип әйтерлек.

Туган нигез, гаилә һәм төбәк тарихын өйрәнеп, андагы горурланырлык вакыйгаларны, күренешләрне җентекләп тикшереп кенә үзеңдә патриотик гражданлык хисе тәрбияләргә мөмкин дип уйлыйм.

Кулымда–каләм. Куңелем-чал тарихта.Туган авылым Үскә-Өске-Кече Аты.Үчкәнең төньягында – Тоба,көньягында – Кызыл Чапчак авыллары.Учкә авылы “Г” хәрефе формасындагы калкулыкка утырган.Авыл ике яклап зур болынлык эчендә.

Татар халкының мәңге онытылмас бөек шагыйре Габдулла Тукай үзенең “Шүрәле”әкият-поэмасында кечкенә Апуш елларын үткәргән Кырлай авылы турында болай дип язган:

“... Ул авылның,Һич онытмыйм,Һәр ягы урман иде;
Ул болын,яшел үләннәр хәтфәдән юрган иде.
-Зурмы?- дисәң, зур түгелдер,бу авыл бик кечкенә;

-Халкының эчкән суы бик кечкенә- инеш кенә...”

Бөек шагыйребезнең Кырлайга багышланган бу юллары гына түгел,ә бөтенләе белән Үчкәгә,аның табигатенә багышлап язылган диярсең.Шулай булса да сабый чактан ук каныбызга сеңеп калган “Шүрәле”нең ике генә юлы авылыбызга туры килеп бетми:

Авылыбыз ул кадәр үк кечкенә түгел. Бугенге көндә авылыбызда 100 гә якын хуҗалык.Халкыбызның эчкән суы да “Кечкенә инеш” булмаган. Ә саф,чиста тәмле сулы , Ил карталарында да урын алган Зәй елгасы.Бу елганың исеме , даны халык җырларына гына түгел,гасырларга, чал тарихка кереп калган.

Бакча артындагы күлләрдән 50-60 метр гына Зәй. Аргы ягы –әрәмәләр,Үле Зәй, Шәрә тау, колхоз чүнниге,имәнлек,чикләвеклек дистәләгән күлләр белән тау асты тулган.

Ә тарихка күз салсак, төрле риваятьләр йөри.Борынгы бабамнар Өске (Ус ка) инеше, Шия,Вятка елгалары буйлап төшеп,Кама аша чыкканнар да ,Зәй тамагына кергәннәр Һәм ерак та түгел язгы ташу басмый торган калкулыка килеп утырганнар. Бу урында берничә еллар яшәгәннән соң , тагын да матуррак , мулрак урын тапкач ,хәзерге урыннарына күчеп килгәннәр. Ә моннан 300 ел элек беренче килеп утырган урыннары,тарихи истәлек булып, халыклар күңелендә Һаман саклана.

**Документ №1.**

“ Известия общества археологии истории и этнографии при императорском Казанском университете»

(Том 18 ,вып.4-6 ,Казань 1908г. Сборник материалов по истории Казанского края в 18 веке, изданный под редакцией Д.А.Корсакова)

**УЕЗД МАМАДЫШСКИЙ**:

Стр.231.

21.Деревня Верхний Искубаш- 39 душ

24.Деревня Средняя Уська- 29 душ.

Инде күп еллардан бирле Үчкә(КечеАты)турында тагын бер “куркыныч “риваять сөйләнә. Имеш,Үчкәгә (Кече Атыга) “бөтен җинаятьчеләрне җыйганнар икән”

Монда, чынлап та ,шикләнерлек тарихи сәбәпләр дә бар:

а) Борынгы бабамнар күчеп килгән Урта Уська ясак түләүче татарлар авылы була.Һәр гаилә елына 1 сум 70 тиен көмеш яисә 17 пот ашлык түләргә тиеш булган. Шулай булгач, мондый авыр тормыш шартларында “төрле” кешеләр үсүе мөмкин.Ясак түли алмаучыларны гаепләп сөрергә карар чыгаргач,шарт куюлары да ихтимал:” я христиан динен кабул итәсез,я каторга.....”

б)Чынлап та ,авыл янәшә тирәдә генә түгел,ә бөтен Минзәлә өязендә үзенең атаклы бурлары белән дан тоткан.Әле берәр ераграк авылга барсаң:”О.знаем мы вашу деревню ,

там такие воры были...”- ди торган булганнар. Бигрәк тә иң дәрәҗәлесе –Егор Ростов булган.

Кулга эләккән әйберләрен ярлы халык белән дә “бүлешкәннәр”,ягъни ярдәмчел булганнар.

Мондый мисал:”Касса ,магазин “басмау”озаккарак сузылса,башкорт ягына “ат походыны”чыгып китә торган булганнар.( Мондый “эшләр” бигрәк тә 1921 елгы ачлыкта булган).Төнлә көтүе белән ат куып кайтып, көннәр буе ишек алдында ат суялар иде ди. Тәрәзәң ачык булса, тәрәзәдән , я бу ни шалтырады дип карасаң,өй алдына ит кисәге атып киткән булалар иде, дип сөйлиләр картлар.Халык аңлый: тагын кем сиңа яртышар ат аягы ыргытып китәр ул елларда.

**Иске олы юл-“ Пушкин юлы”**

Туган авылымның бер тарихи истәлеге күп кешеләргә ,авылларга билгеле һәм Пушкин исеме белән дә бәйле булган Иске олы юл. Үчкәнең көнбатышка караган очыннан 1000 метрлап җир үтсәң ,нәкъ борынгы Иске олы юл басулар ул урыннарда тигез булу сәбәпле , зур тракторлар заманы киткәч , аркылыга Иске лы юлда сукаланган ,күрәмсең.Ә менә Зур Аты ягында ,Чүнникләр елгасыннан башлап, әле ул Олы юл сакланган.

Бу Иске олы юлның тарихы безнең тарихи безнең Болгар бабаларыбыз яшәгән чорларга ук барып тоташа. Болгар чоры, Казан ханлыгы чоры, Рус дәүләтенең Казан ханлыгын алгач һаман көньякка таба рус илен киңәйтә баруы,Минзәлә крепосте төзелү, Оренбург крепосте төзелү һ.б.Бу Олы юл Кама аша Соколкадан чыккач, көньякка борылып ,безнең яктагы калкулыкның авыш өлешеннән Минзәлә һәм Уфа ,аннан инде Оренбургка кадәр китә торган була.

“Пушкин юлы”дип аталуында да тарихи дөреслек ята. А.С. Пушкин Пугачев восстаниесе турында материаллар җыю өчен Оренбургка барырга тиеш була. Чөнки аның бу вакытта “Капитан кызы” дигән тарихи әсәре өстендә эшли торган көннәре булган күрәмсең.Оренбургка барганда ул шушы юлдан үтә. Билгеле ,кайсы авылда булса да кунмыйча булдыра алмагандыр.

**“Сәнәклеләр”**

1920 елның февраль аенда Татарстанның Һәм Башкортстанның берничә өязендә Совет властенә каршы “сәнәклеләр восстаниясе” калкып чыга.

Ә Минзәлә өязе аның үзәгенә әверелә.Минзәлә өязенән күршеләргә – Чистай Һәм Бөгелмә өязләрендә дә тарала. 1920 елның февраль-март айларындагы «Кара бөркет восстаниесе” дип аталган бу восстаниене эсерлар , бай крестьяннар , шушы тирәдә оялап калган ак офицерлар оештыралар.Христиан һәм мөселман дин әһелләре дә берләшеп өлгергәч, халык тагын да “ ышанычлырак “ күтәрелә башлый.

Сорау туа:"Сәнәклеләр "вакытында бу тирә авыллар Һәм Үчкә авылында нинди хәлләр булды икән?

Шушы "Сәнәклеләр" белән Үчкә авылына 3 зур бәла килә! Кая карарга белмәссең ,Үчкәгә дә Һәм янәшә авылларга да төрле яклап сәнәкләр , күсәкләр, чалгылар күтәргән халык килеп тула. Бары да диярлек җәяү.Авыл гына түгел, бөтен янәшә тирә гөрләп тора.Авыл тулы кеше тавышы,эт тавышы, гел заман ахыры диеп белерсең.Һәркемнең капкалары шыр ачык.

Сәнәкле, усал йөзле ир атлар кеше саен кереп тентеп йөриләр. Өйдә булган төркем картмы ул, яшьме ул сәнәк күтәреп аларга ияргергә тиеш.Әгәр дә берәрсе каршы килә икән ,шунда ук сәнәк белән эчен актарып алганнар.

Аларның максаты:һәр авылда ул авылның үз отрядын төзү. Әгәр дә азрак булсалар ,ике авылга бер отряд төзегәннәр.

Авыл картларының сөйләвенә караганда, бигрәк тә Зәй ягыннан килеп тулганнар.Чубытлы,Имәнле,Аксар авылларыннан булганнар.

Үчкә авылында зур булмаган бер отряд төзегәннәр.Кайбер кешеләрне ,чирле килеш өйләреннән алып чыгып киткәннр.

1920 елның март аенда "сәнәклеләр" кулыннан Минзәлә өязендә меңләгән коммунист ,активистлар Һәм гаиләләре Һәлак була. Ширәмәттә – 28 кеше (барысыды бер кабердә алар)

Зур Атыда -3 кеше (Чиркәү калкулыгында күмелгәннәр алар)

**Ачлык (1921 ел)**

1920 нче елның кышында В.И. Ленин кул куйган телеграмма нигезендә Татарстан Мәскәугә Һәм Петроградка10 млн. пот икмәк озата. Шулай итеп Татарстанның бер запас икмәге дә калмый.

Ә 1921 нче елның язы һәм җәендә Идел буе регионында бик каты корылык була. Крестьяннар 1 десятинә жирдән бары тик 2-8 пот кына ашлык алалар.Бу чәчелгән бөртектән 4 мәртәбә кимрәк дигән сүз.

Иң авыры 1922 нче елның кышына һәм язына туры килгән. Кемнәр ,ни генә ашамады икән? Эт тә, мәче дә калмады,әле җитмәсә ,авыл саен кеше ашаучылар да бар икән дигән сүзләр дә таралды.Халык кырыла,тышта ачы салкын ,буранлы көннәр.Үлгән туганнарын илтеп күмәр хәлләре дә юк, дип сөйли авыл картлары.Үлгән кешене тышкагына чыгарып куеп торалар.Берничә көннән кешеләр килеп , сай гына итеп казылган кабергә итеп күмәләр.

Инде халык күпләп үлә башлагач, ике зиратка да зур чокырлар казып куялар.Йөри алганы чана белән өстерәп шул чокырга итеп ташлаган.

1921 нче елгы корылык аркасында ачлыкка дучар ителгән – Идел буеныә куп кенә халыклары белән бер үк вакытта, Татарстан халкына да чит илләрдән ярдәм ктлә башлый .Билгеле,төп ярдәм: азык- төлек! Иң зур ярдәм Америкадан килгән. “ Америка кукуруза боткалары”Шуңа күрә Татарстанның кайсы гына җирендә бу турыда кузгатсалар да, белмәгән кеше юктыр.

1996 нчы елның сентябрендә Үчкә авылы картлары белән берлектә 1921 елгы ачлыкта үлгән әрвахлар өстен тотып куйганнар.Хәзерге көндә бу урында “1921 нче елгы ачлык корбаннары” дип язып куелган.

Каберләре ике зур чокырдан гыйбарәт: берсе мөселман зиратында, икенчесе керәшен зиратында. Куп дистәләгән авылдашлар харап булган шул. Шул ук чокырларга авыл урамында егылып үлгән хәерчеләр дә ташланганнар. Чокырлар 1922 нче елның язына чыккач кына күмелгәннәр.

**Колхозлашу чоры.**

Колхозлашу елларында Үчкә авылы халкы җиргә, икмәккә бай авылларның берсенә әверелә. Эшләгән кеше инде начар ул елларны инде начар яшәмәгән.Күбесе атлы да, сыерлы да булган,әйбәт-әйбәт йорт-җирләр дә салып керә башлаганнар.Совет хөкүмәте бик авырлык белән төзелсә дә,бөтен ил җимерелү дәрәҗәсендә булса да ,авыл халкына , барыбер ярдәм итәргә тырышкан.Иң зур ярдәм шул: 1921 елгы ачлыктан соң чәчәргә симәнә биргән.

Үчкә авылындагы Рөсти карт,Гәрәй карт, Сибгат карт магазиннар ачып җибәрәләр. Тимер – томыр, кадак,буяу ише әйберләр шунда сатыла башлый.Вак-төяк азык-төлек әйберләре дә күренә башлый:чәй,шикәр,прәнек, керосин,сабын дисеңме.Халык ничек кенә итмәсен ,яшәргә тырыша.

Авылыбызның карты Вәлиулла карт сөйләвенчә:Колхоз турында бик куркыныч итеп сөйли иделәр –ди. Имеш,җирләр,мал-туар берләшә,ипине тигез бүләсең,йорт-җирләр берләшә.Башта халыкның коты алынган иде, белгән,күргән нәрсә булмагач – ди.Чөнки,”кулак итеп сөрәләр икән” дигән сүзләр дә килеп җитә башлады.Крестьяннарны гына түгел,дин әһелләрен дә озаталар икән дигән сүзләр йөри башлый.Шулай итеп,1922-30 елларда халыкның күнеле төшеп, пошаманга кала.

Ниһаять,ул көннәр килеп җитә.Бу чынлап та шомлы :байга, урта хәллегә генә түгел,ярлыга да куркыныч кебек тоела.Чөнкт ни буласын беркемдә белми.

1930 елның 30 августында берничә район оеша. Безнең бу урында Чаллы кантоныннан Шәңгәлче (Каенлы) волосте, Чистай кантоныннан Ширәмәт ,Иске Чишмә волостьларын берләштереп Ширәмәт районы төзелә.

Чынлап та,колхозда шуның башлангыч чорлары халыкка бик авыр була. Ә безнең Үчкә авылында колхозлашу – күмәкләшү ,бергәләп эшләп яшәү,ничек башланып китте икән ?

Үчкәдә бертуганнар Ризван абзый белән Рамазан абзыйларны раскулачивать итәләр.Болар, революциягә кадәр дә мулрак яшәсәләр, революциядән соң НЭП чорында тагын да ныгып китәләр.Чөнки нәселләре шундый!

Менә шул "куркыныч дошманнарны" Татарстан җиреннән 1929 елның көз айларында кулга алалар.Кайберләрен тагын 1930-31 нче елларда колхозлашу башлангач алып китәләр. Башта волостьтөрмәләрендә,аннары элекеге өяз ,ә аның соңында Казан төрмәсенә илтеп тутыралар.Ятып түгел,утырып торырга да урын юк...Алар урман кисү,барак төзү,тимер юл салу,канал казу кебек авыр эшләрбашкаралар.Бозлы сулардан бүрәнәләрне ялан кул тартып чыгаралар,аны чистартып баржаларгатөиләр.

Нәкъ шулар белән бергә ,шул газап ,тәмугы эчендә авылыбызның беренче мөәзине Миннехан абзый,авылыбызның беренче мәчетенең Имам- хатыйбы, Мортыш-Баш егете, Сабирҗан Нурмөхәммәт улы Аманаев та була.Аны"кулак" диеп озату дабер хәйлә ,сәбәп кенә була.Ул җәһәннәм газапларын үтеп,һәркемгә дә исән калырга язмаган икән шул.Чит җирләрдә-урманнарда,сазлакларда,баткакларда мәңгегәятып калалар.Туганнары, якыннары,өзелеп сөйгән балалары аларның каберләрен дә беркайчан да таба алмаячаклар.

**1932 ел.**

Бу ел "Кызыл Зәй" колзозында зур таләпләр алып килә.Ыгы-зыгы көннәре булса да,1931 нче ел өчен отчет бирмичә дә ярамый. 1931 нче елда башкарылган эшләрдән нинди нәтиҗә ясарга мөмкин?Билгеле, колхоз оештыра башлауны һәр гаилә дә шатлык белән каршы алгандыр дип әйтеп булмый.Әле авыррак тормышлы кешеләрнең дә кинәт кенә "күтәрелеп" чыгасы килмэгэннәрдер.Житмәсә төрле сүзләр дә йөри....Кем белә ,ул "колхоз" дигән нәрсәнең авыл кешесенә ниләр алып киләсен.Бәхетме? Хәерчелек кенәме? Шулай төрле фикерләр булуга да карамастан,Үчкә халкының 40-50% колхозга 1931 нче елны ук керә.

1931 нче елда җыеп алган икмәкне дә эле колхоз амбарларына түгел,ә хуҗалык амбарларына салырга туры килә.Кемнәр колхозга кереп эштә катнашкан,барына да бераз икмәк тә бүлеп бирәләр.Чөнки ул елларда кызыксындыру чаралары да мөһим бурычларның берсе булгандыр.Бәлки халыкның колхозга тиз тартылуына ул да сәбәп булгадыр.

Оешып та бетмәгән "Кызыл Зәй " колзозына кыска вакыт эчендә күп кенә сорауларны хәл итәргә туры килә.Шуңа күрә ,Үчкә авылында 1930 нчы еллардан башлап

1950 нче елларның азагына кадәр кемнәр генә председатель булып эшләмәгән.20 ел эчендә 20 председатель!

Колхоз оешкан елларда гына түгел,әле алга таба да колхозларда бернинди техника да булмый.Шуңа күрә "ир канаты-ат" булып кала. Һәм яңа оешучы колхозлар атның төп тарту көче булуын,аттан башка бернинди дә эш эшләнмәячәген беләләр.Шуңа күрә, әле 50 хуҗалыккада тулып бетмәгән колхоз членнарыннан оешкан "Кызыл Зәй" колхозы ат абзарына 5 конюх куйганнар һәм иң тәмле азыкны да -атларга биргәннәр.Бу катгый закон!

Әле колхоз төзелгәнгә 2 ел чамасы гына булса да ,һич сузарга ярамаган зур бурычларның берсе: фермаларга нигез салу(сыер, сарык, дуңгыз)

Миңкәш күле буенда бүрәнәләрдән ярып буралган дуңгыз сарае,,ике катлы чыбык-читәннән үреп,арасына салам тутырып эшләнелгән,сыерлар абзары,нәкъ сыерларныкы төчле итеп эрэмә чыбыгыннан үреп эшләнгән сарыклар абзарына нигез салына.

1937-38 нче елларда утарда сарыклар инде хайран гына күренә башлаганнар.Ләкин ,кызганычка каршы, кышкы суыкларданбик кубе үлгәннәр.

Үчкәдә тагын бер бик мөхим проблеманы хәл имичә колхозчыларга җиңеллек булмаячак кебек.Үчкәдгә үз тегермәне,үз пекарнясы кирәк!Чөнки Тоба тегермәне күп икмәкне "йота",түләп кара шул кадәр "лопатканы" "Лопатканы" гына түгел шул, колхоз икмәге тонналап китә.Шуңа күрә "Кызыл Зәй" колхозы җитәкселәре моның зур әһәмияен аңлап,көне-төне чабалар.

**1941-1945 нче еллар.**

1941 нче елнын җәй иртәсендә башланган сугыш безнең авылнын ирләрен үзенә тартып ала.1921 -1922 нче елны туганнарны сугышка алып китәләр.Авыла көне-төне эш бара. Фермаларда мөдирләр калмый,1923 елда туган ирләрне март аенда сугышка алып китәләр.

Җыеннар узгач .1924 нче елда туганнарны да сугышка алып китәләр.Тракторлар гел бетә,бөтен эш атка,кешегә кала.Ашлыкны кар яугач та ура торган булганнар.1942 елда халык хезмәт көненә эшли торган була. Ләкин бу хезмәт көненә бер килограмм ипидә,1 сум акчада ала алмыйлар.

1943 нче елның башы белән 1925 нче елда туганнарны сугышка алалар.Алар киткәч,авылда ир-ат заты бетә диярлек.Ә "Кызыл Зәй" колхозында эш бер генә көнгә дә туктап тормый. Яз башлану белән яралы солдатлар кайта башлый.Сугыш башлангач аерым хуҗалык бетә,һәркем колхозда эшли.

Халыкның сугыш вакытындагы күргән аврлыкларын язып та,сөйләп тә бетерә тоган түгел.Үчкә авылында да халык авыр яшәсә дә , ачлыктан интегүчеләр булса да ,алай ачтан үлүчеләр булмый.

Ул вакытта төптән 3-4 бәрәңге чыга торган була.Ә иң зурысы тавык күкәеннән әз генә зур була.

1943 нче елны Кама Аланы болынына бәрәңге орлыгы китерәләр. Бераз тыңгысыз кешеләр умачлык “эләктереп” калалар.”Кыюсызлары”-алабута оны саклап куя.Язга чыгу белән бакчадан черек бәрәңге җыю.Үләннәр калка башлагач кычыткан,алабута яфрагы. кузгалак,юа,. Аннан балтырган.кәҗә акалы ,көпшә,җиләк һ.б.

Икмәк җитә башлагач халык барыбер тәвәкәлли : башак уып ашыйсың,амбар тирәсендә чуаласың.Ул кесәләрне әйтәсе дә юк,малайлар берсеннән берсе киңрәк ,озынрак кесә тегәләр,ыштан бавың гына чыдасын.Әле бит ыштанның балагына да тутырып була, ә инде күлмәгең озынрак булып ,ыштаныңы кыстырп ,ныграк бау белән бәйли алсаң ,корсакка тутырасың – дип искә ала минем әти.(хәзерге көндә ул исән сау ,91 яшендә).

Зәй елгасы Үчкә халкына “бакасын”да кызганмаган.Ул үзе ракушкалар эчендә яшеренгән,шуңа күрә аны “ракушка” дип тә атыйлар.Ите бик тәмле,ләкин суан җыеп алгач,аларны ачуы бик авыр.Шуңа күрә аларн төрле юл белән ачалар:кайберәүләр әзрәк утта тотып,кайберәүләр кайнар суда тоталар.Кемнең генә ишек алдына күз төшмәсен,тау-тау булып шушы бака кабыгы ята торган булган.

Үчкә халкын ачлыктан алып калучылар:кыр җәнлекләре.Басуда,урманда,әрәмәдә ,тау буйларында куян,бурсык кебек җәнлекләрнең күп булуы.

Үчкә авылы халкын иң зур ,куркыныч бәладән –ачка үлүдән Зәй үзе ,Зәй буена урнашкан ,тибигать саклап калган!

Ә тау буе? Анданиләр генә үсми? Чия ,балан, миләш.... Ә иң изгесе- чикләвек!

Уңганнар гаиләләр чикләвекне күп итеп җыялар да ,я үзләре туенып яшиләр,я сатып он алалар .

Әле тау бенда чабаталык юкә дә биргән икән ләбаса! Авылда ул вакытта 100% кеше чабата кия. Күбрәк ясаганнары – сата, тамакка өстәмә азык.

Ә камышы! Печәне !Ни өчен Үчкә халкы салкыннан бик җәфаланмаган? Җәфаланган, ләкин җылыда яшәгән. Беренче сәбәп: һаман шул Зәй буе табигате!Һаман шул Зәй буенда гөрләп үскән тал – чыбыклары!

Тау буенда элек-электән берничә гаилә чүнник тоткан. Иң зурысы Әхмәт бабайныкы. Шул урында колхоз оешкач та “Кызыл Зәй” колхозы чүнниген оештыралар. Менә шул чүнник, калын урманны хәтерләткән,юан имәннәр эчендә урнашкан.Аерым

хуҗалык вакытта бабайлар аңа кагылмаганнар да,кагылдыртмаганнар да. Ул имәннәр җил – давылдан саклаганнар.

Менә шул умарталыкны чолгап алган бер гектарга якын имәнлекне 1941 елның декабрендә бер төн эчендә кисеп, ташып та бетергәннәр.

Сугыш болай да кыенлыклар белән генә үсә барган авыл хуҗалыгы экономикасын нигезенә кадәр какшата. Барыда фронт өчен!Ә фронт өчен кирәк булган азык – төлекне кемнәр белән әзерләргә? Аның менә төп кадагы шушы иде: әби –бабай ,хатын- кызлар, малай-шалай. Аларның да кубесе каядыр махсус эшләр белән озатылганнар: урман кисәргә,окоп казырга, торфка ,ФЗО га һ.б.Бөтен авыл хуҗалыгы эшен шул ярты-йорты кешеләр башкару бер хәл, ә иң авыры – колхозчыга бер грамм икмәк бүлмәү,яисә бүлә алмау (чөнки рөхсәт юк!)Ә ашамыйча ничек эшләргә?

Халыкның иң авыр чакларда да күз яшен йотып булса да үз дәрәҗәсен сакларга тырышуы,үз күңеленә дәва таба белгән.

Йөрәк газабыннан башка тагын ике авырлык : экономик Һәм физик. Шуңа күрә бик күп аналар ,бәлки тәүлегенә 1-2 генә сәгать ял итеп алырга мөмкинлек тугандыр.

Шулай булуга карамастан ,халык сугыш елларында да үз күңелен үзе юата алган.Гармун тавышы Үчкәдә беркайчанда сүнмәгән. Чөнки авылы шундый. Кирәк булса ,Фәхер абый иң яхшы гармунны алып кайтып бирә тоган булган.

Әле сугыш вакытында диеп тору юк. Солтан абзый өе идарә булса да , клуб булмагач, атна саен кичәләр оештыра торган булганнар.

**Җиңү бәйрәменә Һәйкәл.**

Җиңү бәйрәменең 50 еллыгына хәзерлек максаты белән, 1995 елның 11 мартында туган авылыбыз Үчкәдә сугышта Һәлак булган туганнарыбызга багышлап, “Изге аш” кичәсе уздыралар. Шул ук елны , сугышта Һәлак булганнар Һәм катнашучылар истәлегенә Һәйкәл салына башлый.Һәм ул эш тиз арада тормышка аша. Үчкә авылында куелган Һәйкәлгә 116 кеше фамилиясе язылган:55- вафат булганнар, 61 – сугышта катнашып,исән –сау кайтучылар.

**1946-1950 нче еллар.**

1946 елның авырлыкларынтагын мисаллар белән күрсәтеп була.

Эшче көчләр җитми,ир- егетләр сугыш кырларында ятып калганнар. Кайтканнары да – күбесе яралы.Тарту көчләре бик начар: атлар аз, аларның күбесе,үз тизәген ашый-ашый ,үлеп беткәннәр. Шуңа күрә, 1946 елда да гомумән, 50 нче елларга кадәр ,күбесе үгез җиккәннәр. Ат 50 еллар башында бик сирәк кенә кешегә эләгә. Үгез көлтә ташу өчен бирелгән. Тәгәрмәч ватылса да өстери,булмаса да .Үгез бирсәләр – ул кешегә бик зур бәхет. Чөнки эштән кайтканда арба төбенә салам салып кайталар,әле сукмаган көлтә дә

эләгә.Арба төбендә ашлык бөртеге торырлык такта,кабык,яисә алама чыбылдык фәлән дә булса,нәрсә кайта? Ашлык!Көн саен 1-2 кг ашлык кайтсын әле!Моннан да зур бәхет бармы?!Менә шул чакта гезгә рәхмәт укыйсың инде

Сыер фермалары ныгый башлагагандай булды.Тегермән туктап калган,пекарняларның күптән инде ишекләре урланган,мичләре җимерек,тәрәзә рамнары югалган,идән-сайгаклары да сирәкләнгән.

Урак башлануга яшь егктләрне, вак-төяк эшләрдән азат итеп ,көлтә ташырга куялар.Бер атка яисә үгезгә ике кеше :берсе ,ат белән йөрүчеөстә тора,көлтәне урнаштыра, ә икенчесе , сәнәк белән яисә кул белән “бәбкәдән” алып арбага биреп тора.

Тарих Һаман алга тәгәри.Көннәрне-көннәр, айларны-айлар,елларны- еллар алыштырып кына тора.Авырмы,җиңелме,адәм баласы шул дөнья дулкыны эчендә чайкала бирә. Шулай “тәгәри” торгач, 1949 нчы ел да килеп җитә. Тагын нинди уңышлар,борчулар,авырлыклар,мәшәкатьләр ,шатлыклар алып килер икән бу ел, минем авылыма.

Сугыш беткәнгә 4 ел үтсә дә, тормышлар бик җиңел булмаса да, кайберәүләрнең авызына икмәк, ярты ел гына булса да, эләккәли булса кирәк. Өйләре дә җылы, Һәр гаиләнең бәрәңгесе дә уңа.

Колхоз маллары гына түгел, халыкның абзарларында да хайран гына мал-туар күренә башлый.Бу бигрәк тә иртән көтү киткәндә, кич көтү кайткан вакытларда күзгә ташлана.Инде болында, казык кагып бәйләп куйган бозаулар саны арта башлый.Зәйдә,күл өсләрендә йөзгән каз төркемнәре дә елдан ел күбәйгән кебек күзгә ташланалар.Кайбер хуҗалыкларда эре,ак үрдәкләр дә үстерә башлыйлар.

“Кызыл Зәй” колхозының хуҗалыгы да хайран гына ныгый башлый: басуларда яңа тракторлар гөрли.комбайннар да элекке кебек гел ватылып ятмый,атлар саны да елдан – ел үрчи.Колхозның каралты-куралары яңара барган кебек,колхозларның да йорт-җирләре хәйран гына төзелә башлый.Көче булган кешегә, бу елларда агач алып, эш итәргә мөмкинчелек туа . Кайбер колзозчылар, якынрак туганнары ярдәме белән, йортларын яңарткалап куя башлыйлар.

Сугыш вакытында сүтелеп, ягылып беткән бакча читәннәре дә яңадан тотып алына.

Матур- матур күлмәкләр киеп, ”фразцуз”яулыклар бәйләп урамның бер очыннан,икенче очына ашка баручы-кайтучы әбиләрне дә очратасың.Еш кына Тоба авылы абыстае да,йомшак, җылы мамык шәлләрен бөркәнеп, хуш исле печән салган ат чанасына утырып,Үчкә урамнарында күренә башлый.

Каенлы,Чапчак юлларында йөрүче укучылар саны да елдан –ел арта.Димәк, Үчкә авылында яшәүче Һәркемнең күңелендә өмет чаткылары артканнан-арта,үскәннән үсә бара.

50 нче ел башларында Сәхәбетдин абзый белән Сәгыйдуллин Харис( минем иремнең әтисе)тракторга утыралар.Алардан соң Сәлмән ,Разыймнар тимер атларга атланалар.

1967 нче елның 15 нче гыйнварында "Кызыл Зәй" колхозы председателе итеп ,Каенлыда ветеринар булып эшләүче, ИбраҺимов Нурислам "сайлана"

Инде 1970 нче елның 31 нче мартыннан " Кызыл Зәй" колхозы совхоз итеп үзгәртелә. Ә совхоз директоры итеп Хайруллин Нурулла билгеләнә.

1973 нче елның мартында Кызыл Чапчак егете Әхмәтшин Габделбәр Салих улын куялар.

1992 нче елның язында ,"Кызыл Зәй" совхозыннан "Тоба" күмәк хуҗалыгы аерылып чыга: Тоба Һәм Үчкә.Җир –болыннарны бүлеп алалар.Барлык сука җире -2114 га, печәнлек – болыннар -523 га ,хуҗалык бакчалары- 278 га.Менә шушы ике авылдан торган күмәк хуҗалыкның беренче директоры итеп элекке "Кызыл Зәй" совхозында баш инженер булып эшләгән Мотыйгуллин Риян Һади улы билгеләнде.

1996 нчы елның гыйнварендә Риян Һади улы "Тоба" күмәк хуҗалыгыннан китәргә була. Аның урынына Каенлыда ветеринар булып эшләгән Фаиз Нурмөхәммәт улы Динмөхәмәтов билгеләнә. Ул вакытта Үчкә авылының зур керем бирүче бригада- яшелчә бригадасы! Аның хуҗасы – Нигъмәтҗәнов Гарифулла була.Кәбесә,помидор,кыяр,ташкабак һ,б барысыда Үчкә басуында үсә! Яше – карты,мәктәп балалары , барысыда яшелчә басуында эштә.

Түбән Кама халкына җитәрлек яшелчә белән тәэмин итеп тора.

**Йомгаклау.**

Мин –авыл баласы.Авыл –минем бишегем,түшәгем,тәүге якты сукмагым,бабамнарның гомер буразнасы,уйларымның бәреп чыккан чишмәсе. Авыл – минем гомер юлының сихри башлангычы,тере чыганагы.

Безнең бабайлар Ватан сугышын җиңеп чыкканнар,әтиләр тылда хезмәт куйганнар.Безнең буын исә авылны саклап калырга тиеш.Авылның язмышын яңартырга кирәк. ШәҺәрдә яшәсәм дә ,күңел Һаман авылга тарта.Олыгайган саен ,авылга мәхәббәтем сүрелмәде,көчәя генә бара. Тарихи төбәкне өйрәнү һәм аның тарихын язу-энә белән кое казуга тиң. Авылның үткәне турында язма чыганаклар юк диярлек, чөнки аларны язып баручы булмаган. Бердәнбер чыганак - өлкән яшьтәгеләрнең истәлекләре, буыннан – буынга сөйләнеп килгән хатирә, вакыйга, бәет, мөнәҗәт, риваятьләр. Матди чыганаклар

юкка чыгып беткән диярлек. Барлык туплаган материалларны туплап без кыскача туган як тарихын өйрәнергә тиеш. Бәлки бу тарих тулысынча да булмас, әмма кайбер архивларда сакланган материаллар, өлкәннәр сөйләме, энциклопедия материаллары безгә план нигезендә үзебезне борчыган сорауларга җавап табарга ярдәм итәчәк. Тарихи төбәкне өйрәнгәнгәндә авыл атамаларына да игътибар итмичә мөмкин түгел. Алар безгә борынгы бабаларыбызның тормыш – көнкүреше, һөнәрләре гореф – гадәтләре, тарихы, теле, төбәкнең табигате, географик үзенчәлекләре, авыл халкының этник составы , кәсебе , булып узган вакыйгалар һәм башкалар турында мөһим мәгълүматлар бирә.

Халык педагогикасына кагылышлы материаллар: авылдагы йолалар, гореф-гадәтләр, бәйрәмнәр, традицияләр, мәзәкләр киләчәктә безгә үткәнебезне ныграк аңларга ярдәм итәчәк, милләтебезнең сафлыгына, әхлагына йогынтысы тиячәк.

Киләчәктә дә мин бу тикшерү-эзләнү эшен дәвам итәргә уйлыйм, тагын да тулыландыра алырмын дип ышанып калам.

**Кулланылган әдәбият**


1. Өлфәт Миннеханов “Авылым тарихы- халкым язмышы”,Түбән Кама шәҺәре нәшрияты, 1998 ел; 506 бит;
2. Шәрәфиев Фәхри, “Каенлы авылы тарихы”,Казан: “Сүз” нәшрияты,2009 . 200 бит.
3. “Туган як” газетасы.
4. "История сел и деревень", Добров В.П., 1970г.
5. Авылда һәм авылдан читтә яшәүче өлкән буын кешеләре сөйләмнәре.



*Феткуллова Динара, 10 нчы сыйныф,Чуашстан Республикасы Батыр районы,“Шыгырдан 1 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе” муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең*
*Житәкчесе: Айзатуллова Роза Равил кызы, татар теле һәм әдәбияты укытучысы*


**Чувашстан татарлары тормышында Яңа Торын кабер ташлары**

Һәрбер җирлекнең үз халкы өчен таныш булган һәм билгеле бер исем белән аталган урыннары була. Туган авылым Шыгырданда һәм авылдан ерак түгел генә урнашкан, халык телендә “Кизләү буе”, “Мөслим”, “Цаллук буе” дип аталган урыннары бар. Алар авылның тарихи ядкаре, бик күптәннән үк авыл халкының изге урыннары. Шыгырдан тирәләрендә болгар чоры каберлекләре барлыгын галимнәр раслап тора. Авылдан биш чакрым ераклыкта гына болгар чоры шәһәрчеге урыны да сакланган. Тирә-якта шул ук чор кабер ташлары да шактый. Бик борынгы заманнардан бирле зиратлар серле һәм изге урыннар булып саналганнар.

Чуашстан татарларының республикада дистәдән артык изге урыннары бар. Элек-электән килгән йола буенча, бу урыннарга халык барып, догалар кыла. Әлеге изге урыннарның күбесендә борынгы кабер ташлары да ята. Халык, шул тирәдәге мәхәллә кешеләре аларны карап-тәрбияләп тора.

Чуашстанда борынгыдан калган изгеләштерелгән каберлекләр:

1. Шыгырданда “Мөслим” (Батыр районы).
2. Кыр Бикшиге янында “Наратлар асты” (Батыр районы).
3. Тойси һәм Тимәш авыллары арасында. (Батыр районы)
4. “Тимерле” (Кызыл Чишмә янында, Батыр районы)
5. Шыгырдан белән Тигәш авыллары арасында (Батыр районы)
6. Яңа Торында Бичура һәм мөселманнар каберлеге. (Шомыршы районы)
7. Байтирәк авылында (Шомыршы районы).
8. Табырданда гаскәр башлыгы һәм мөселманнар каберлеге. (Канаш районы)
9. Шербидә (Сюрбеево) кирпеч заводы урынында. (Комсомол районы)
10. Ишан хәзрәт Хәсән күмелгән кабер. (Шорт, Комсомол районы)
11. Таяба янында (Ялчек районы).
12. Ковалида (Урмар районы).
13. “Атлашево һәм Тутаркассида (Чабаксар районы)
14. Чуваш милли музеендагы кабер ташы.

**Яңа Торын.**

Чабаксардан Сембер шәһәренә илтә торган юл кырында, Чуаштанның көньяк өлешендә, Шомыршы районына керә торган Яңа Торын дип аталган авыл бар. Чуашлар аны Вăрманти Тăрăн, ягъни урмандагы Торын диләр, урысчасы исә Ново Буяново. Авыл зур булмыйча, 110 йортта чуашлар яши.

Бу авыл инде йөзләрчә ел буена тирә-яктагы татарлар өчен мөһим дини урын булып тора. Хикмәт шунда ки, әлеге авыл уртасында, Карлы елгасы ярында борынгы 2 кабер ташы һәм тирәсе тимерчыбык белән әйләндереп алынган зират бар. Берсендәге язуларны укырлык түгел, әмма икенчесендәге язудан тарихны чамалап була. Чуашлар аны мишәр мазары-каберлеге дип атый, ә татарлар исә "болгар бабаларыбыз яуда һәлак булган урын" дип йөри.

Бу каберлек хакында төрле сүзләр йөри. Чуаш авылы уртасындагы зиратта Болгардан куылып килгән сугышчылар һәм өч изге кыз күмелгән дип, сөйләгәннәр картлар. Башка версияләрдә әлеге кабер ташы Бикбулат морза тарафыннан Тинчура улы

Бикчурага һиҗри белән 1108 елда куелган. Һиҗри елын миладига әйләндерсәк, 1695 ел була. Халык бу урында сугыш булган дип сөйли. Риваятьләргә караганда, Бичура сугыш кырында һәлак булган. Аның гәүдәсен сугыш кырыннан елга буенча алып килеп, татар авылының каберлегенә күмгәннәр. Татар авылы хәзер юк. Шул тирәләргә Буяноводан һәм Торыннан чуашлар күчеп килеп авыл төзегәннәр. Татар авылының исемен хәтерләүчеләр юк. Бәлки ул авылның исеме Карабай булгандыр. Чөнки татар каберлегеннән ерак түгел Карабай Шомыршы авылы бар. В. Магницкий “Список татарских селений Буинского уезда в “ОАИЭ”, т. 18” дигән хезмәтендә дә Карабай исеме белән татар авылы булуын искәртә. Бу урынны тарихчылар нугай татарлары белән урыс гаскәре бәрелешкән урын булуы ихтимал дип аңлата. Бичураның нинди сугышта һәлак булуы безгә төгәл мәгълүм түгел. Казаннан килгән профессор Һ.Юсупов кабер ташларындагы язуны Бичура Тинчура улы икәнлеген укып раслый. Чуаш галимнәре кабер ташлары чуашча язылган дип аңлатырга тырыша. Әмма язу саф татар телендә.

Бу урынны җирле татарлар изге урын дип саныйлар һәм ел саен дога кылырга киләләр. Җирле тарихчылар да бу җирләрдә татар-мөселман догасы өзелмәгәнлекне яза. Тарихи чыганакларда 1908 елда Сембердән Г.Кокол дигән тарихчы Яңа Торын зиратындагы кабер ташлары хакында мәгълүмат теркәп калдырган. "Шыгырданнан килгән татарлар тезләнеп гыйбадәт кылып утыралар иде. Алар монда Казан ханлыгы вакытындагы изге затлар - сугышчылар күмелгән дип әйтәләр”, - дип язып куйган ул.

Кайсы көнне тезелеп дога кылуларын ул чакта теркәп калдырмаганнар. Бүгенге көндә Шыгырдан татарлары һәр ел май аеның соңгы көннәрендә шушы чуаш авылына килеп, гыйбадәт уздыра. Яңгыр аз булган елларны монда килеп, яңгыр намазы да укыйлар.

Авыл картлары һәм карчыкларыннан Яңа Торын турында белгән, ишеткәннәре турында да сораштырдым. “Бала чакта Яңа Торынга әниләр, әбиләр белән җәяү бара торган идек. Халык күп була иде. Әбиләр зиратның аскы ягында, Карлы елгасы ярына төшеп дога кылалар, шунда ашый-эчәләр иде. Кайбер кешеләр кунып калалар иде. Татарлар килгәнне күреп, чуашлар чәйләр кайнатып, йомыркалар пешереп безне сыйлыйлар иде. Әбиләр үзләре белән алып килгән чәйләрен пешереп, чәйләр эчәләр иде”, - дип искә төшерделәр олылар.

Яңа Торын авылы зиратына татарлар электән корылык булганда дога кылырга килә торган булганнар. Зират читендә карап торган чуаш карчыклары да, татарлар килде, димәк яңгыр була дип, ышаныч күрсәтеп калганнар. Ясин, Тәбрәк укылганнан соң, халык белән бергәләп тәүбә кылына. Моннан соң, электән килгән гадәт буенча, зираттан чыгып, яр буенда корбан ашлары ашала. Ә яңгыр теләгенең төп гыйбадәте – истиска намазы шул

ук көнне мәчетләрдә укыла. Шыгырдан, Балтай, Байтирәк, Татар Согыты авылы татарлары бу урынга ел да бер аерым көнне килеп торганнар.

Бүгенгесе көндә Яңа Торын тарихи-мәдәни кыйммәткә ия булган урын дип санала.

**Нигә бу урынны чуашлар да изге итеп кабул иткәннәр соң?**

Нигә бу урынны чуашлар да изге итеп кабул иткәннәр соң? Бу җиргә бәйле күп вакыйгаларны мисал итеп китергә була. Картлар сөйләвенә караганда, зиратның тирә-ягында койма тотылмаган була. Бер тракторчы бу җирне сөрергә тотына. Тимер сабаны моның чытырдап сына. Колхоз икенче сабан китерә, барыбер сөрә алмыйлар. Тракторчысы да вафат була. Шуннан соң изге урынның кадерен аңлый башлаганнар. Колхозлашу вакытында, бу урынны сөреп, анда кыяр утыртып караганнар. Әмма ике ел рәттән бозлы яңгыр явып, үсемлекләрне харап иткән. Зират тирәсендә бала-чага мал ашаткан. Балалар шуннан соң авырган. Ул авыру балаларны татарлардан өшкертеп торганнар. Файдаларын да күргәннәр.

Нурислам Көсәинов шушы зиратны карап торучы кеше. Туксанынчы елларда тирә-ягына яңадан койма тоттырган, бүгенгәчә тәртибен карап тора, яз-көз зират җирен җыйдырта. Бу эштә аңа җирле чуашлар ярдәм итә.

"Моңа кадәр әтиемнең әтисе бу зиратны карап торган. Халык бик күп була иде монда, өчәр көн торалар иде. Монда сугыш вакытында һәлак булган болгар бабайлар күмелгән. Элек чуашлар бу урынга салкынрак карый иде. Хәзер мөнәсәбәт башка. Чөнки алар казалар күргәләделәр. Бер җирле яшь ир зират өстендә печән чапкан, ул үлгән. Аннары әнисе сукырайган. Аңа кадәр дә бу зират белән бәйле шундый вакыйгалар булган, шуңа күрә хәзер бу җирне алар да изге итеп күрә", - ди Нурислам әфәнде.

**Йомгак.**

Безнең бабаларыбыз гаделлек, иминлек, туганлык кебек төшенчәләргә табынып яшәгәннәр, тарихка саклык белән караганнар. Без аларның теләкләрен дәвам итәргә, алар кадерләгәнне кадерләргә, саклаганны сакларга тиешбез. Алар үзләре исән чакта безне тарихыбыз, ата – бабаларыбыз рухы белән бәйләп торалар. Ә алардан соң без киләчәк буынны шуңа өйрәтергә тиешбез. Галим Тәлгать Галиуллин килер буыннар турында һәркемгә уйланырлык фикерләр әйтә: "Киләчәк буыннар үзләренең тамырларын белергә тиешләр. Башкача булганда, җәмгыятьне маңкортлар, үз тарихын белергә теләмәгән, бер көн белән яшәгән нәселсез адәмнәр явыз саранча болыты шикелле басып китәчәк", - ди ул. Үз иленең, төбәгенең, туган авылының тарихын белү кешегә үзен "Кеше" буларак таныргa ярдәм итә. Изгеләрне хөрмәтләү, ихтирам белән телгә алу безнең кешелек

сыйфатларын югалтмавыбызны, алдагы буыннар өчен күңелләребезнең тыныч булуын күрсәтә.

Тарих белән бәйләнеш булган, бар һәм киләчәктә дә булачак. Минемчә, һәр буын бу “Изге урын” нарны киләчәк буынга мирас итеп калдырачак.

**Файдаланылган әдәбият:**


1. Салихов П.М. Шыгырдан. – Ульяновск: ОАО «Областная типография «Печатный двор», 2010. – 544.
2. www.azatliq.org/a/28516338.html
3. https://islam21.ru
4. Авыл картлары белән әңгәмә.
5. Журналист Земдиханов Рәфис белән әңгәмә.



*Хәбибуллин Давид,8 нче сыйныф, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Муса Җәлил исемендәге “1 нче гимназия” муниципаль бюджет белем учреждениесе*
*Житәкчесе: Солтанов Радик Ибраһим улы, тарих һәм җәмгыять белеме укытучысы*


## XVI-XVII гасырларда Казан бистәләре. Татар бистәсе

### Казан хикәятләр белән алга баса...

Мәктәптә Россия һәм Татарстан тарихын өйрәнү барышында татар халкы тарихының Казан ханлыгы чоры, XVI гасырда Явыз Иван гаскәрләре тарафыннан аның яулап алынуы, аннан соң безнең төбәктә булган үзгәрешләр белән бәйле борылыш этабы зур кызыксыну уята.

Европа һәм Азия чикләрендә урнашкан меңъеллык Казан социаль-икътисади һәм территориаль - этник үсеш үзенчәлеге белән характерлана. Бигрәк тә мондый борылыш мизгелләре чорында. Татар халкы өчен Казан электән үк милли горурлык символы булып тора. Шәһәр тарихы Урта Идел буенда яшәүчебашка халыклар тарихы белән дә тыгыз бәйләнгән дип ассызыкларга кирәк.

Казан турында аз гына язылмаган, әмма тулаем алганда, мәсьәләнең тарихи-географик ягы өйрәнелмәгән һәм актуаль булып кала бирә.

Казан Көнчыгыш Европаның ике зур елгасы-Идел һәм Кама кушылган урында урнашкан. Башка күп кенә шәһәрләр дә шушы типта урнашып барлыкка килгән.Әкренләп Казан тирә-юньдәге бистәләр белән үсә.

Бу эштә мин шәһәрнең, аерым алганда, Татар бистәсенең барлыкка килү һәм үсеш тарихын өйрәнүне максат итеп куйдым. Бу максатка ирешү өчен тарихи һәм географик факторларны исәпкә алдым, объектларның урнашу урынын ачыклау өчен төрле

материалларны өйрәндем, Казан бистәләрендә яшәүчеләрнең шөгыльләрен, хуҗалык тормышын билгеләүнең әһәмиятен күреп эш иттем.

Тикшерүнең төп ысулы-язма һәм археология чыганакларын анализлау.

**Бистә-урта гасыр шәһәренең бер өлеше.**

Ожегов сүзлегендә "слобода" термины болай аңлатыла: 1) халкы беркетелмәгән (бәйсез) зур авыл буларак; 2) шәһәр янындагы җирлек, шәһәр яны. [1] XIV-XVI гасырларда ханлык Казаны тирәсендә берничә бистә - кураеш бистәсе(җир хуҗасы исеме белән атала), әрмән бистәсе(мондагы халык арасында 4 йортта әрмәннәр яшәгән) була. Бистә-феодализм чорында барлыкка килгән җирлек формасы. Билгеле бер җирлекләргә феодал "йомшаклык" бирә,ягъни йөкләмәләр, салымнардан азат итә, ә бистәдәгеләр аңа "бистә туплый", ягъни җир мәйданын арттыра.

Русьтә бистәләр барлыкка килүнең төп сәбәпләренең берсе – феодаль таркаулык. Бу яңа җирлекләр феодалның эшкәртелүче җирен арттырырга, бер үк вакытта башка функцияләрне - саклау, сәүдә-хуҗалык һәм башкаларны үтәргә тиеш булган.

Көнчыгыш Европа, Урта Азия һәм Якын Көнчыгыш урта гасыр шәһәрләреструктурасы формалашуының гомуми принциплары өч өлештән торган: крепость (кремль), эчке шәһәр (посад), тышкы шәһәр (бистәләр).

**Казанның рус бистәләре.**

Рус вакытындагы Казан бистәләренең барлыкка килүе шәһәрнең хәрби һәм сәүдә-сәнәгать үсеше белән тыгыз бәйләнгән. Бистәләр территориаль аерымланган җирлекләр булып торалар, табигый чикләргә ия булганнар - чокырлар, елга, күлләр, сазлык, калкулыклар. Алар посад читендә яки посад стенасы артында (Татар бистәсе) урнашкан. Уңайлы, югары коры урыннарда привилегияле бистәләр - Кызыл (Красная - иң яхшысы, матур дигәнне аңлата)- Казан феодаллары бистәсе, Петровский (изге Петр чиркәве исеме белән аталган)- архиепископ хезмәткәрләре бистәсе урнашкан.Түбәнлекләрдә, юеш, тормыш алып бару өчен кулай булмаган урыннарда хезмәт итүчеләр бистәләре - Мокрая, Подлужная, Плотничья, Сотенная һәм башкалар урнашкан.Хәрби бистәләрдәге халыкны хезмәт итүче приборлы кешеләр - стрелецлар,пушкарьлар, пищальниклар тәшкил итә. Аларның хәрби оешмасы булган, даими каравыл хезмәте алып барганнар һәм шәһәрнең билгеле бер өлешен саклау белән шөгыльләнәләр. Хуҗалык эшләренә килсәк, алар бакчаларны эшкәртү һәм һөнәрчелек белән шөгыльләнәләр. Хәрби бистәләр булмаганнарында халык үзләренә йөкләнгән билгеле бер хуҗалык функцияләрен үтәү белән шөгыльләнә, мәсәлән, төзелеш, он җитештерү һәм башкалар.

Сәүдә һәм һөнәрчелек үсеше шәһәрнең алга таба үсешенә йогынты ясый. Посад диварлары тирәсендә яңа, нигездә һөнәрчелек бистәләре: Чүлмәкчеләр (Горшечная),

кирпеччеләр (Кирпичная) үсеп чыга. Татар бистәсе янында Яңа керәшен бистәсе (Новокрещенская слобода) барлыкка килә, анда христианлыкны кабул иткән җирле халыклар күчерелә. XVII гасырның икенче яртысында, Казанканың уң ярында Кәҗә бистәсе (Козья слобода) барлыкка килә. Аның исеме 1654 елда булган чума эпидемиясе белән бәйле, ул чакта авырудан 48 меңгә якын кеше үлгән. Исән калган шәһәр кешеләре, хакимиятнең ярдәменә өметләре сүнгәч, үзләрен коткару буенча мөстәкыйль чаралар күрәләр. Татарлар, махсус билгеләнгән урында кәҗәләр суеп, корбан китерү мәрхәмәтлелеге ритуалы ясап, итне шәһәр халкына тараталар.

1565-1568 елгы язу китаплары (писцовые книги) буенча Казан халкы бистәдә яшәүчеләр белән бергә 10 меңгә якын кешегә булган, ә Татар бистәсендә 6 меңгә якын кеше яшәгән. XVII гасыр урталарында халык саны 20 меңнән артмаган.[2]

**Татар бистәсе: барлыкка килү һәм үсеш тарихы.**

Татар бистәсе үзенең формалашуы һәм үсеше буенча тарихи үзенчәлекләргә ия. Бу бистә- татар этносының үзенчәлекләре барыннан да күбрәк сакланып калган урыннарның берсе, монда халык мәдәниятының көнчыгышлыгы аның Европага омтылышы белән бергә үрелә.

Татар бистәсе Болак артында, Кабан күленең сазлыклы үзәнлегендә барлыкка килә. Аның беренче үзәге – хәзерге К.Насыйри һәм Ф. Кәрим урамнары. Бистәнең төп урамы Түбән Кабан ярының борылышы буенча барган, борынгы мөселман зиратыннан алып Печән базары урынында Плетени дигән рус авылына кадәр җиткән. Шәһәр ныгытмаларыннан читтә урнашкан бистәнең үз ныгытмасы булган -берничә капка белән агач крепость. Кешеләр яшәү өчен бу урын уңайсыз булган. Язын Идел елгасының суыбистәнең зур өлешен баскан. Урыны түбән, дымлы. Сазлык, күлләр, пычрак. Бу татарларның монда яшәргә мәҗбүр ителүе турында сөйләүче фактлар. Элек биредә җирлекләр булмаган. Риваятьләрдә болай сөйләнә: Казанны алганнан соң берничә ел узгач, казанлылар Иван Грозный патшага килеп, үзләренә яшәү урыны сорадылар. Иван IV: "Менә сезгә урын!" (“Вон там место!”) дигән . Шул место сүзеннән "бистя"сүзе килеп чыккан. Икенче риваять буенча, казанлылар "Болакның теге ягында - руслар, ә бу якта мөселманнар яшәсен" дигән үтенеч белән мөрәҗәгать иткәннәр. Рус хөкүмәте аларның үтенечен канәгатьләндергән һәм мөселманнар Болакның сул ягына, Түбән Кабан күле буенда урнашканнар. [3]Әмма бу риваятьләрнең объективлыгына ышануы кыен.

Татар бистәсе барлыкка килү вакыты буенча ике төрле караш бар:

1) бистә 1552 елда Казанны яулап алгач ук барлыкка килгән;

2) бистә 1557 елда барлыкка килгән.

Беренче версиягә ышансаң, исән калган татар халкы Кабан күле артына урнаштырылган дип фаразларга була. Аларның җирләрен русларга биреп, җиңелгәннәрне яхшы контрольда тоту өчен. Тик чыганаклар шуны сөйли: шәһәрне алганнан соң халыкның ир-атлар өлеше бөтенләй юкка чыгарылды, ә хатын-кызлар һәм балалар русларның әсирләренә әверелде һәм, нигездә, Казаннан чыгарылды. Бәлки бу җирне руслар белән союздаш татарлар алгандыр, ләкин аларга яшәү өчен уңайсыз җир бирү факты мантыйкка сыймый.

Икенче күзлектән карасак, хөкүмәт бу урынны чукынмаганнарга, әмма 1552-1557 елларда милли-азатлык хәрәкәтендә катнашмаган яки бу хәрәкәтне бастыруда катнашкан,лояль мөнәсәбәт күрсәткән татарларга калдырган. Ничек кенә булмасын, рус администрациясе җирле халыкның ярдәменә мохтаҗ булган. Казан алынганнан соң беренче елларда “служилый татарлар”га карата мөнәсәбәт хәйраняхшы булган. Тик барыбер ышанычсызлык хөкем сөргән. Татарларга шәһәрнең рус өлешенә бару тыела. XVII гасыр сәяхәтчесе Адам Олеарий "бер генә татар да үлем җәзасы куркынычы астындаКремльдәбулырга тиеш түгел" дип яза.[4]

Татар бистәсендә XVI гасыр урталарында 155 йорт- 5 рус чиновникларыныкы һәм 150 хезмәтче һәм хезмәтче булмаган татарларның йорты исәпләнә. Бистәдә хезмәт итүче татарлар билгеле привелигияләргә ия булганнар, җир биләмәләреннән файдаланганнар. Шул ук вакытта татарларның күпчелеге Казаннан 30-40 чакрым ераклыкка, шулай ук зур елгалардан 15-20 чакрым ераклыкка кысрыклана.[5]

Татар бистәсе халкының саны турында мәгълүматлар төгәл түгел. 150 йортның һәрберсендә 10 гаиләгә кадәр яшәгән, ә кайберләрендә күбрәк тә. Бу 1500 гаилә яки 6 меңнән дә ким булмаган кеше дигән сүз. Бистәдә йортлар урнашуда зур тыгызлык булган, чөнки 1500 йорттан артык хөкүмәт рөхсәт итми.

Бистәдә яшәүчеләр нигездә игенчелек һәм терлекчелек белән шөгыльләнә. Язын беренче үләннәр белән һәм беренче карга кадәр татарларның күп өлеше көтүлеккә китә һәм анда күчеп йөри. Күп кенә авылларга игенчелек белән шөгыльләнүче бистәлеләр китәләр. Бистәдә өлкән буын һәм кече балалар гына кала.

XVII гасырның беренче чирегендә бистәдә яшәүчеләрнең төп өлеше служилый новокрещенный татарлардан тора иде инде, алар вакытлар узу белән руслашалар һәм руслар белән кушылалар.

Татарларның бер өлеше сәүдә белән актив шөгыльләнә башлый, моны рус хөкүмәте хуплый. Алга таба сәүдәгәр татарлар хәтта рус сәүдәгәрләре белән чагыштырганда да билгеле бер өстенлекләргә ия булалар, чөнки алар салым түләүдән азат ителәләр. Әмма

билгеле бер өстенлекләрдән бай татарларның аз өлеше генә файдалана, бистә халкының күп өлеше хәерче булып кала һәм иң түбән статуска ия була.

Татар бистәсе мөселманнарның рухи мәдәниятен саклап калырга омтыла. Руханилар бай диндәшләрне мәчетләр төзүгә рухландыра һәм өтәрә. XVI гасырның 90 нчы елларында анда биек манаралы дүрт мәчет барлыкка килә. 1593 елда рус патшасы Казан митрополиты Гермогеннан хәвефле хат ала. Федор Иванович җавап итеп, иң реакцион чаралар кулланып, христианлаштыру сәясәтен кискен көчәйтергә - булган барлык дини биналарны җимерергә, керәшеннәрне һәм мөселманнарны күчерергә, чиркәүдән тайпылган өчен аларны каты җәзага тартырга – чылбыр кидерергә,кыйнарга һәм төрмәләргә ябаргакуша. Патшаның мондый коточкыч указына карамастан, мәчетләрне төзү легаль булмаган рәвештә җирле хакимиятләр белән килешенеп дәвам итә.

XVII гасырда бистәне киңәйтү процессы дәвам итә, аның чикләре арта. Бутатарларның арта баргансоциаль-икътисадиактивлыгыбеләнбәйлебула.

Төбәкнең социаль-икътисади һәм сәяси үсешендә Казан бистәләренең роле.

Казан бистәләренең барлыкка килүе шәһәр Идел-Урал төбәгенең эре икътисади, стратегик һәм администрация үзәге буларак үсеше процессы нәтиҗәсе булып тора. Һәр бистә шәһәр өчен билгеле бер функция башкара. Бистәдә яшәүчеләр һөнәрчелек, сәүдә, ямчылык, игенчелек белән шөгыльләнәләр, шәһәрне һәм башка бистәләрне саклыйлар. Шәһәр алдында билгеле бер функциональ бурычларын югалтучы бистәләр юкка чыга, алар урынында башка исемле һәм, әлбәттә, шәһәр өчен кирәкле башка функцияләр башкаручы бистәләр барлыкка килә.

Казан бистәләре XVIII гасырга кадәр билгеле бер дәрәҗәдә мөстәкыйль берәмлекләр булган, шәһәр халкын сословие төркемнәренә берләштергән. Посад кешесен бистәдән башка күз алдына китерү мөмкин түгел. Товар -акча мөнәсәбәтләре һәм сәүдә -һөнәрчелек үсү белән шәһәр җәмгыяте структурасы әкренләп үзгәрә. XVII гасырның соңгы чирегендә бистә статусы посад белән тигезләшә. XVIII гасыр башында шәһәр халкын милек хәле буенча бүлү принцибын кертү халыкның составы һәм шөгыльләре буенча Казанның эре сәнәгать предприятиеләренә хезмәт күрсәтүче яңа бистәләр барлыкка килүгә китергән.

Татар бистәсе социаль-сәяси һәм икътисади яктан Казан белән тыгыз бәйләнгән. 1646 елда язылган исәп алу китабы Татар бистәсен Казанның башка бистәләреннән аермый, служилыйларның йортларын руслар белән беррәттән исәпкә ала. Татар бистәсе, озак еллар дәвамында Казанда бердәнбер татар җирлеге буларак, милләтне берләштерүдә, аның үсешен активлаштыруда мөһим роль уйный. Монда татарларның хәзерге заман шәһәр мәдәниятенең тамырлары, аның чишмә башы сакланган. Татар бистәсе ярдәмендә

Казан Көнчыгыш Европаның башка шәһәрләренә охшамаган, бай тарихы һәм үзенчәлекле йөзе булган, татар һәм рус мәдәниятенең үзара бәйләнешен чагылдыручы уникаль шәһәргә әверелә.

**Әдәбият исемлеге**


1. Ожегов С. И. Рус теле сүзлеге.- Мәскәү,1986.
2. Борисов В.Л. Казан 7154 (1646) ел исәпкә алу китабы мәгълүматлары буенча.- Казан, Типо-лит. имп. ун-та, 1989.
3. Катанов Н.Ф. Казан турында хикәятләр.- Казан, ИОАИЭ, 1920.
4. Олеарий А. Мәскәүгә сәяхәт тасвирламасы.- Санкт-Петербург, 1906.
5. Исхаков Д.М. Татар халкы тарихы буенча материаллар.- Казан, 1996.



*Хайруллина Ясминә, 9 нчы сыйныф, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы "22 нче гимназия"муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчесе: Әминова Эльмира Зөфәр кызы, татар теле һәм әдәбияты укытучысы*


**Мәктәбем - белем учагы**

Кеше тормышының истәлекләргә бай, һәрвакыт сагынып сөйли торган бер мизгеле ул - мәктәп еллары. Күпме язмышларны олы тормыш юлына аяк бастырган мәктәп үзе, гүя, баласын олы юлга озаткан ана кебек, шуларны сабыр гына күзәтеп тора.

Безнең мәктәп тә бүген генә барлыкка килмәгән. Аның үткәне, тарихы бар. Һәр мәктәптә туган төбәкне өйрәнү музее бар. Музейның мәктәп тарихына багышланган бүлеге дә бар. Аны тулыландыру максатыннан чыгарылыш укучыларыннан, ветеран укытучылардан истәлекле язмалар, фотолар җыйганнар. Мине шушы күптөрле һәм эчтәлекле экспонатлар арасыннан мәктәпнең елъязма китабы кызыксындырды. Бу елъязма китабы кайчан язылган? Кем язган? Шушы сорауларга җавап табу максатыннан мин эзләнү эше башладым. Минем эзләнү эшемнең нигезендә мәктәбебезнең үткәне: укытучылар белән укучылар арасындагы буын бәйләнеше,традициягә әйләнеп киткән уку-укыту системасы, ә үткән белән хәзерге арасын тоташтыручы «күпер» булып чыгарылыш укучылары тора.

Мәктәп... Монда үткәннәр белән киләчәк тоташа. Үткәнен белмәгәннең, киләчәге караңгы, дигән бит борынгылар! Минем туган мәктәбемнең стеналары бала-чаганың күпме күңелле тавышын үз эченә сыйдырган, күпме күңел җылысы, изгелек бөркелә ул стеналардан! Кайлардан башлана микән минем мәктәп тарихы?

**Хезмәтемнең актуальлеге:**

Без, укучылар, мәктәбебезнең тарихын белергә тиеш, чөнки мәктәп һәр кешенең тормышында мөһим роль уйный. Шулай ук укучылар турында истәлекләрне, мәктәп тормышында булган кызыклы һәм әһәмиятле вакыйгаларны, укучыларның җиңүләрен һәм казанышларын сакларга тиешбез.

Проблема: мәктәп тарихының өйрәнелмәве.

Шушы проблемага бәйле рәвештә мин үз алдыма мәктәпнең тарихын өйрәнүне максат итеп куйдым. Шул максаттан чыгып бурычлар да билгеләнде:

- мәктәп тарихын өйрәнү, аның үткәне турында материаллар туплау;

- укучыларда мәктәп тарихы турында күзаллау булдыру;

- мәктәп тарихына бәйле шәхесләрне өйрәнү;

-ирешкән уңышлар турында нәтиҗәләрне барлау, яңалары белән тулыландыру;

-мәктәпнең тарихын башкаларга да сөйләү, күрсәтү, аны киләчәк буыннарга тапшыру.

Эзләнү барышында мин төрле тикшерену методларын кулландым:

-гамәли эзләнү – мәгълүматлар туплау;

-мәктәп тарихының үзгәрү динамикасын күзәтү;

-анализлау, чагыштыру, нәтиҗә чыгару;

-тупланган материалны компьютер ярдәмендә системага салу;

- мәктәп музеенда сакланган экспонатларны өйрәнеп, олы укытучыларның истәлекләрен тыңлап материал туплау, -

-чыгарылыш сыйныф укучылары белән аралашу;

-мәктәп ачылганнан бүгенге көнгә кадәр эшләүче укытучылардан интервью, сораштырулар үткәрү;

Проблеманың өйрәнелү дәрәҗәсен ачыклау максатыннан, укучылар арасында анкета сорауларына җаваплар алынды. Аның нәтиҗәләре түбәндәгечә:

76 % укучы мәктәп тарихы белән гомумән таныш түгел;

61 % укучы мәктәп тарихы белән берникадәр таныш;

96 % укучы мәктәп тарихын белергә тели;

85% укучы мәктәп тарихын белү кирәк дип саный һәм алар фикеренчә, моның белән үзләре шөгыльләнергә тиеш;

73% укучы бу эшне бик теләп башкарачагын белдерде.

## 1. Гимназиянең елъязмасы.

### 1.1. Мәктәпнең ачылу тарихы.

Мәктәп тарихын өйрәнү, минем фикеремчә, милли мирасыбызны саклауга һәм өйрәнүгә әйтеп бетергесез өлеш кертә.

1987 елның 1 сентябрендә 11 микрорайонда яңа мәктәп үз ишекләрен киң ачты. Ул беренче сыйныф укучыларын иркен сыйныфларына кунакчыл кабул итте. Мәктәпнең ачылуына балалар да, әти-әниләр дә бик шатланалар. Озак вакыт дәвамында якын-тирә йортлардагы балалар төрле мәктәпләргә күп юллар аша йөриләр. Бу мәктәпнең ачылуын алар бик көтәләр. Әле 1987 елның мартында ук төзелеп килүче мәктәпкә директор итеп Вышинский А.П  билгеләнә. Ул Түбән Кама шәһәрендә бик хөрмәтле кеше була. Шул көннән башлап Александр Павлович  мәктәптә эшләү өчен кадрлар сайлый башлый. Март аенда ук мәктәп төзелешендә педагогик хезмәт ветераннары Фаттахова Флера Таһир кызы, Фәттахов Дуфак Мансур улы, Хәсәншин Ривгать Әбрар улы һәм башка укытучылар катнаша. Укытучылар булачак укучыларның фатирларына йөреп, ата-аналар белән дә танышалар, исемлекләр төзи башлыйлар. Шуңа да 1 августта мәктәп укучыларны кабул итәргә тулысынча әзер була. Бу көнне мәктәпкә 5 класс - 1 нчеләр, 6 класс- икенчеләр, 4 класс- өченчеләр кабул ителә. 58, 60 нчы балалар бакчасында алты яшьлекләр өчен сыйныфлар ачыла. Бу көнне Түбән Кама педагогия училищесын тәмамлаган 8 укытучы үзләренең педагогик осталык үрләренә юлын башлады. Алар: Кутуева Лариса Михайловна, Петрова Ирина Николаевна, Токарева Любовь Ивановна, Сибгатуллина Зөлфия Әнвәровна, Валеева Гөлнур Индусовна, Ермошина Татьяна Аркадьевна, Прописнова Любовь Ивановна һәм Сафина Венера Харисовна. Токарева Любовь Ивановна белән  Прописнова Любовь Ивановна бүгенге көндә дә гимназиядә хөрмәтле укытучылар. Беренче көннәрдән үк башлангыч сыйныф укытучыларының методик берләшмәләре оештырыла. Беренче методик берләшмә җитәкчеләре итеп Жукова Валентина Александровна(1 класс), Прописнова Любовь Ивановна (2 класс), Садикова Альмира Назимовна (3класс) билгеләнәләр. Ә башлангыч мәктәптә бөтен эшне Баязитова Светлана Ивановна җитәкли. Методик берләшмәләрнең эше теоретик мәсьәләләрне өйрәнү белән беррәттән, укыту методикасы һәм тәҗрибә алмашу мәсьәләләрен дә карый. Коллектив укыту һәм тәрбия мәсьәләләрен хәл итә, аларны тормышка ашыра, проблемалы максатлар куя башлый. Ул вакытта ук мәктәп директоры Вышинский А.П укытучылар һәм укучыларның иҗади, фикерләүче, гадәти булмаган коллективын булдырырга тели.

### 1.2. Мәктәп җитәкчеләре.

Инглиз телен тирәнтен өйрәнүле 22 нче мәктәпнең беренче директоры - Вышинский Александр Павлович. Аны 1987 елның 2 мартында, Түбән Кама шәһәре халык депутатлары советы карары буенча, 1176 урынга исәпләнгән яңа төзелүче мәктәпкә директор итеп билгелиләр. Директор булып билгеләнгәнче, ул зур тормыш тәҗрбәсен үтә.

Вышинский Александр Павлович 1930 нчы елның 14 нче августында Минзәлә районы Кананерка авылында зкр крестьян гаиләседә туа. Гаиләдә 7 бала була.(6 малай, 1 кыз) Әтисе гомер буе колхозда эшли, сугыш вакытында колхоз председателе була.

1949-1950 нче елларда ул Минзәлә фельдшер-акушерлык мәктәбендә укый.

1950-1952 ел. Александр Павлович Кама Тамагы районы Антоновка авылында фельдшер, шул ук вакытта комсомол оешмасының секретаре була. 1952 нче елның 1 мартында аны Кама Тамагы районы комсомол оешмасының секретаре итеп билгелиләр, ә 1954 елда Казанга партия мәктәбенә укырга җибәрәләр.1953 нче елда Казан Дәүләт университетына укырга керә.1957 нче ел. Кама Тамагы районы партия комитетының җитәкче мөдире итеп билгелиләр. 1960 нчы ел. Буа шәһәре район башкарма комитетының председателе итеп билгеләнә.

1965 нче елның гыйнвар аенда Түбән Кама районы башкарма комитетының председателе итеп сайлана. Ул эшләгән еллар Түбән Кама шәһәренең һәм химия җитештерү комплексының төзелә башлаган чоры була. Бу елларда район башкарма комитеты Төзүчеләр поселыгындагы баракларның берсендә урнаша.

1967 нче елда Вышинский Александр Павлович укытучылык эшенә күчә. Гомумитехник факультетның деканы һәм философия кафедрасының өлкән укытучысы булып эшли. 1973-1987 елларда Казан химия технология институтының Түбән Кама филиалында беренче директор була. 1987 елда аны 22 нче мәктәпнең директоры итеп билгелиләр һәм пенсиягә кадәр ул шушы мәктәптә хезмәт итә. Кыска гына вакыт эчендә Александр Павлович мәктәпне яңа, заманча җиһаз белән тәэмин итә. Мәктәпнең педагогик Советы утырышларының берсендә инглиз телен тирәнтен өйрәнүле мәктәп оештыру турында Карар кабул ителә. Ике ел дәвамында программалар төзелә, уку планнары раслана, китаплар сатып алына, бу катлаулы бурычны үтәү өчен матди-техник база булдырыла. Директор урынбасарлары Кистеева В.С, Анисимова Н. В., укытучылар Латыпова А. Р., Алексеев А. Д. бу эшкә җаваплы карыйлар. 1989 елның сентябрь аенда 6а һәм 6в сыйныфларында инглиз телен тирәнтен өйрәнә башлыйлар. 1990 елның җәендә мәктәп инглиз телен тирәнтен өйрәнүле мәктәп итеп үзгәртелә һәм икенче сыйныф укучылары инглиз телен өйрәнә башлыйлар. Бу бурычны тормышка ашырганнан соң, яңа типтагы мәктәп төзү тәкъдим ителә. Мәктәп базасында лицей төзергә карар кылына. 1992 елның июнендә Татарстан Республикасы Халык мәгарифе министрлыгы коллегиясе карары белән 22 нче мәктәп-лицей итеп үзгәртелә. «Эштә яңалыкны эзләгез, Түбән Кама республиканың башка шәһәрләреннән аерылып торырга тиеш», - ди Александр Павлович. Ул бик гадел һәм башкалардан да гаделлекне таләп итә.

1992 елны мәктәп директоры итеп Толстогузов Геннадий Михайлович билгеләнә. Ул дүрт ел лицей директоры вазифаларын башкара. Бу елларда лицей лингвистик юнәлештә һәм 1-11 классларда сәләтле балаларны укытуга һәм тәрбияләүгә юнәлдерелгән була. Лицей иҗади, конкурентлыкка сәләтле шәхесне үстерү, укучыларга югары белем бирү, фәнни һәм гамәли эшчәнлекнең төрле өлкәләрендә укучыларны иҗади хезмәткә әзерләү буенча экспериментал уку планы буенча эшли. Лицей лингвистик, математик, гуманитар, эстетик, физик сәләтләрне комплексы рәвештә формалаштыруны күздә тоткан белем бирүне тәэмин итә. Лицей (9-11 сыйныфлар) төп компонент нигезендә фән нигезләрен өйрәнүне һәм, кагыйдә буларак, укучылар сайлаган фәннәрне өйрәнүне тәэмин итә:

- икенче чит тел;
- техник тәрҗемә;
- чит ил әдәбияты;
- психология нигезләре;
- иҗади шәхеснең үз-үзен үстерү;
- икътисад һәм эшмәкәрлек эшчәнлеге нигезләре;
- менеджер эшендә информатика һәм компьютер. Профилизациянең нигезе булып тел ягыннан әзерлек тора.

1997 нче елда мәктәп директоры итеп Кистеева Венера Самиковна билгеләнә. Венера Самиковна – югары квалификацияле җитәкче, Татарстан Республикасының атказанган укытучысы. Ул Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының Мактау грамотасы, 2000 ел, Татарстан Республикасы Мактау грамотасы, 2002 ел, «Түбән Кама муниципаль районы» башлыгының Мактау грамотасы, 2006 ел бүләкләнә. Түбән Кама муниципаль районы Башлыгының «Мәгарифтә Лидер» номинациясендә җиңүче, 2008 ел, «2009 елның иң яхшы белем бирү учреждениесе директоры» республика конкурсы җиңүчесе була. Венера Самиковна - актив, максатчан, иҗади эшләүче җитәкче була. Ул ТАССРның Мамадыш шәһәрендә туа. Венера Самиковна 1973 нче елда Казан дәүләт педагогия институтының физика – математика факультетын тәмамлый. Үзенең хезмәт юлын Мамадыш районы Отарка авылында математика укытучысы булып башлап җибәрә.Венера Самиковна директор итеп билгеләнгәч, коллектив үз алдына яңа бурычлар куя:

- табигать һәм җәмгыять турында системалаштырылган белемнәрне үзләштерүнең кирәкле дәрәҗәсен тәэмин итү;
- үз-үзеңә белем бирү сәләтен, камилләшүгә ихтыяҗ һәм күнекмәләрне формалаштыру;

Бу бурычлар өзлексез белем бирү шартларында мөһим, чөнки хәзерге вакытта белемнәр бик тиз искерә, белем алырга, һәрвакыт мөстәкыйль рәвештә укырга әзер булу зарур.

### 1.3 Мәктәпнең эшчәнлеге.

1997 нче елдан хәзерге көнгә кадәр мәктәп ТИСБИның «Балалар бакчасы-мәктәп - көллият – вуз» системасында эксперименталь эш программасын тормышка ашыру процессында катнаша. Системаның структурасы - күп баскычлы, эзлекле, адаптацион. Ул биш баскычтан тора, аның звеносы - инглиз телен тирәнтен өйрәнүле 22-нче номерлы мәктәп колледж-класслары. Бу программаны башлап җибәрүче фәнни-эксперименталь эш буенча директор урынбасары Хабибуллина Татьяна Анатольевна була. 1999-2000 уку елында беренче тапкыр гуманитар юнәлешнең «Халыкара мөнәсәбәтләр» белгечлеге буенча 10 нчы колледж-класс ачыла.

1999 елның 2 июленнән лицей «Инглиз телен тирәнтен өйрәнүле 22 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» исемен йөртә башлый. Билгеле булганча, мәктәп - ул икенче йорт. Биредә балалар укып кына калмыйлар, ә үзара аралашалар да. 1998 елдан мәктәптә «Содружество» балалар оешмасы эшли башлый, ул үзенең төп юнәлеше итеп балаларның иҗади активлыгын үстерүне күз алдында тота. Шулай ук традицион чаралар: Белем көне, Укытучылар көне, хокукый белемнәр декадасы, иҗади марафоннар, ачык ишекләр көне, чыгарылыш сыйныф укучыларының очрашу кичәсе, Ватанны саклаучылар көне, 8 Март, юмор көне, Җиңү Көне, Соңгы кыңгырау бәйрәме үткәрелә.

Безнең мәктәптә эзләнү, хәрәкәт рухы хөкем сөрә, чөнки анда тәвәккәл, кыю, энергияле, тынгысыз укытучылар эшли.

2005-2006 уку елында 22 нче мәктәп инновацион белем бирү программаларын актив гамәлгә ашыручы мәктәпләр арасында Россия Федерациясе гомуми белем бирү учреждениеләре конкурсында җиңүче була.

Мәктәпнең казанышлары:

-мәктәп ике тапкыр «Мәгариф милли» проекты җиңүчесе (2006,2008);

-«Татарстанның Ел укытучысы-2000» - 1 урын;

-«Татарстан мәктәпләренең иң яхшы профсоюз оешмасы-2006» - 2 урын;

- «Татарстанның иң яхшы мәктәбе-2008» - 2 урын;

-«Татарстанның иң яхшы сыйныф җитәкчесе - 2008» - 1 урын;

-«Татарстанның Ел укытучысы-2009» - 3 урын;

-«Татарстан мәктәбенең иң яхшы директоры-2009» - 1 урын;

-«Иң яхшы белем бирү учреждениесе-2010» - 2 урын;

Укытучылар коллективы инновацион укыту программаларын үзләштереп, яңа педагогик технологияләрне өйрәнеп, аларны гамәлдә кулланалар. Укытучының эш нәтиҗәсе бер генә көндә күренми.Укучыларның фән олимпиадаларында, конкурсларда, фестивальләрдә катнашулары, призлы урыннар алуы укытучының хезмәт нәтиҗәсе булып тора. 29 ел эшләү дәверендә (28 чыгарылыш) мәктәп 157 медалист чыгарган. 1993-2015 елларда мәктәпне 73 укучы алтын медальгә һәм 63 укучы көмеш медальгә тәмамлаган. 2016 нчы елдан көмеш медаль бирелми башлый. 2016-2020 елларда мәктәпне 21 укучы алтын медальгә тәмамлаган. Барлыгы 94 алтын медаль.

2013 елның 1 сентябрендә мәктәп «22 нче гимназия» исемен ала. Менә 7 ел безнең мәктәп гимназия исемен йөртә. Күп кенә педагоглар төрле дәрәҗәдәге грантлар алучылар, һөнәри конкурсларда җиңүчеләр һәм призерлар булып торалар. Белем бирү учреждениеләренең республика рейтингында гимназия ел саен олимпиада, конференцияләр һәм конкурслар нәтиҗәләре буенча иң яхшылыр арасына керә. 2017 елның ахырында Венера Самиковна лаеклы ялга китә. 2018 нче елда Шумилова Екатерина Петровна мәктәп директоры итеп билгеләнә. Ул - «Татарстанның иң яхшы сыйныф җитәкчесе - 2008» конкурсы җиңүчесе; Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Безнең иң яхшы укытучы» гранты иясе.

2001 нче елда Екатерина Петровна Алабуга дәүләт институтын тәмамлап, инглиз телен тирәнтен өйрәнүле 22 нче урта гомуми белем бирү мәктәбендә инглиз теле укытучысы булып эшли башлаган.

Бүгенге көндә мәктәптә 1033 укучы белем ала.Балаларга 67 укытучы белем бирә. Мәктәп белән Шумиова Екатерина Петровна җитәкчелек итә. Уку бүлмәләре заман таләпләренә туры китереп җиһазландырылган. Ныклы белем бирү өчен барлык шартлар да булдырылган. Мәктәпнең укытучылар коллективы барысы да югары педагогик белемле, һөнәри дәрәҗәләрен даими күтәрп торучы кадрлардан тупланган. Укытучылар балаларга төрле юнәлештә тәрбия бирәләр. Ел саен чыгарылыш сыйныф укучыларының уртача 92% ы Түбән Кама, Мәскәү, Казан, Ульяновск, Санкт-Петербург, Ижевск, Саратов, Оренбург, Түбән Новгород, Алабуга, Калининград, Чебоксар, Яр Чаллы шәһәрләрендә урнашкан югары уку йортларына укырга керәләр һәм белем алалар.

### 3.Мәктәп тарихында эз калдырган шәхесләр.

Мәктәп еллары һәркемнең күңелендә якты бер истәлек булып кала. Еллар үтү белән кеше укыган мәктәбен сагынып искә алса, мәктәп тә үзендә укып чыккан балаларын онытмый. Алар мәктәп тарихына кереп калалар. Эшләү дәверендә мәктәптә кемнәр генә укымаган. Алар һәркайсы бу тормышта үз юлларын табып, үз кыйблаларын билгеләгәннәр. Кемдер үз язмышын шәһәр белән бәйләсә, кемдер Туган ягында калуны

максат итеп куя. 22 нче мәктәпне тәмамлап, тормышта зур уңышларга ирешкән , горурланып «Алар безнең мәктәптә укыган!» – дип әйтерлек кешеләребез дә бар. Чыгарылыш сыйныф укучыларының конкурент өстенлеге-рус, татар, инглиз телләрен, ә безнең гимназиядә француз телләрен бер үк дәрәҗәдә белү.

Калимуллина Чулпан 2014 елда «FLEX» халыкара конкурсында җиңүче була һәм ел дәвамында АКШта белем ала. Төрле вакытларда барлыгы 23 учы әлеге конкурсның финалистлары булды.

Безнең чыгарылыш укучысы Алена Алехина, FLEX халыкара конкурсында җиңүче, Ак йортка чакырылган иде, анда ул АКШ Конгрессы сенаторлары белән очрашты, икенче бер чыгарылыш укучысы Татьяна Тютлина Россия Федерациясе Хөкүмәтендә Дмитрий Анатольевич Медведев белән эшли, Журба Елена СГС буенча Россия эксперты булып тора. (Химик матдәләрне классификацияләү һәм маркировкалау системасы (СГС, ингл. GHS) .

Альбина Хөсәенова нанотехнологияләр өлкәсендә Грант отты һәм Бөекбританиядә стажировка үтте, Пекин һәм Лондон олимпиадаларында волонтер булды, Казан Универсиадасы дирекциясендә эшләде, инглиз телен өйрәтү буенча English for the Universiade китабы авторы булып тора.

Мәктәп үзенең чыгарылыш укучылары белән горурлана. Чөнки алар уңышлы, социаль җайлашкан, тормышта үз урынын тапкан, үз-үзләрен күрсәтә алган. Күпләр бөтенләй төрле өлкәләрдә компетентлы белгечләр булдылар: Кондратьева Анастасия, гимназия укучысы буларак, «МАКС»авиасалонында Россия Президенты В.В. Путин белән очрашты. Хәзерге вакытта Анастасия Кытайда укый. Рөстәм Бурнашев-Мәскәү Хөкүмәте, ә Гена Алексеев-атом-төш физикасы өлкәсендә Халыкара эксперт.

Аня Шалашина МДУ, югары тәрҗемә мәктәбе факультетын тәмамлаган һәм «Три кита» кинокомпаниясендә генераль продюсер ярдәмчесе булып эшли. Маша Антонова Германия университетында укыта, Эллина Кистеева - British Airways авиакомпаниясендә идарә итүче референт Тимур Латыйпов, грант отып, Торонто университетында «Нейрохирургия» юнәлеше буенча белем ала.

Университет һәм гимназиянең тагын бер уртак проекты булып Франциядән килгән студентлар алмашу буенча халыкара программа тора.

2017 елның 24 октябрендә 22-нче номерлы гимназиядә Франциядән килгән кунакларны кабул иттеләр. Семинар программасына Фредерик Кастель - Реймс (Франция) шәһәре педагогика университетының Шомон һәм Труа шәһәрләрендәге филиаллар директоры Фредерик Кастель катнашында уза.

Әлеге укучыларыбызны мәктәпкә чакырып, һөнәр сайларга җыенган

укучыларыбыз белән очрашулар, әңгәмәләр оештырабыз. Бу – хезмәт тәрбиясенә өйрәтүнең бер формасы.

Еллар үтә, буыннар алмашынып тора. Киләчәктә тагын шундый күренекле кешеләр чыкмас дип әйтеп булмый. Һәр бала бер хәзинә, аны бары ача белергә генә кирәк. Ә моның өчен ныклы белем алу мәҗбүри.

**Йомгаклау.**

Проект эше нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора:

1. Мәктәпнең елъязма китабының авторы Хайруллина(Котляр) Динара Дамировна. Әлеге елъязма 1997 елны языла башлаган. Хәзерге көндә Динара Дамировна Түбән Кама шәһәренең 37 нче мәктәп директоры. Без, ул башлаган эшнең дәвамчылары.
2. 22 нче гимназия тарихы турында мәгълүмат артты, тупланды.
3. Мәктәп тарихы буенча материаллар җәмәгатьчелеккә тәкъдим ителде.
4. Ветеран укытучылар,чыгарылыш сыйныф укучылары белән үзара хезмәттәшлек ныгыды.
5. Нәтиҗәләр буенча елъязма китабы тулыландырды.

Әле моның белән генә эш бетми. Без бу юнәлештә дәвам итәчәкбез. Мәктәп тарихы буенча җыелган материалларны сыйныф сәгатьләрендә, төрле чараларда, тарих дәресләрендә кулланма буларак тәкъдим итәм.

Проект эшенең әһәмияте дә шунда: мәктәп тарихына кагылышлы документлар, истәлек- хатирәләр нигезендә мин аның үсеш тарихын күзәттем, мәктәп белән бәйле шәхесләрнең биографияләрен өйрәндем, укытучылар турында мәгълүмат тупладым.

Йомгаклап шуны әйтәсе килә: һәр яңа буын үзеннән килгән буынга мәктәпнең традицияләрен тапшыра, мәктәп тарихына яңа битләр өсти, анда яңа сәхифәләр ача. Димәк, бу эш дәвамлы. Тарих ул эзләнгәнне ярата.

2022 нче елның көзендә мәктәбебез ачылуга 35 ел булачак. Бу зур вакыйга. Укучыларга, укытучыларга, ветеран - укытучыларга, гомерләрен мәктәп белән бәйләгән хезмәткәрләргә рәхмәт сүзләре әйтмәү мөмкин түгел. Мәктәбебезнең алга таба да яшәвен,төрле өлкәләрдә уңышларга ирешүен телибез!

**Проект эшчәнлегендә кулланылган төп чыганаклар.**

1. «Безнең мәктәп дөньясы»- альманах, 2000 ел.

2. Ветеран укытучыларның һәм мәктәпне тәмамлаган чыгарылыш класс укучыларының истәлекләре.

3. Кистеева В.С., Садикова А.Н. «Уравление саморазвитием и самореализации личности в условиях формирования образовательной среды развивающего типа» - «Школа», Казань, 2006 год.

4. «Ленинская правда» - 10 октябрь, 1997 ел.

5. Мәктәпнең музей бүлмәсендә саклanган документлар, елъязма китабы, фотоматериаллар.

*Шәрифуллин Данир, 4 нче сыйныф, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Бакый Урманче исемендәге“2 нче гимназия” муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчесе: Мөхәмәтҗанова Чулпан Малик кызы, башлангыч сыйныф укытучысы*

## Милләтемнең энҗе бөртекләре

Фольклор – күпкырлы һәм бай милли иҗат. Аның милли табигате сурәтле-сәнгатьчә фикерләвендә ачык чагыла. Гасырлар дәвамында татарларда төрле фольклор жанрлары формалашкан. Бу система халыкның яшәешен һәм күпкырлы рухи тормышын, шәхеснең тышкы һәм эчке дөньясын иңләп алырга һәм күптөрле формаларда гәүдәләндерергә мөмкинлек биргән. Хәзерге вакытта да халык бу гүзәл хәзинәләрдән файдалана. Әдәби уку дәреслекләрендә “Халык авыз иҗаты” дигән бүлекне өйрәнү - миңа бик мавыктыргыч булып тоелды. Әлеге бүлекне йомгаклаганда укытучымның “Татар халкының милли хәзинәләре” исемле проект якларга дигән тәкъдиме - мине тирән эзләнүләргә этәрде дә инде. Фольклорның милли-этник үзенчәлекләрен, милли йөзен һәм байлыгын өйрәнәсе килү теләге туды миндә.

**Фәнни - тикшеренү эшенең темасы:** «Милләтемнең энҗе бөртекләре».

**Максат:**

- татар фольклор әсәрләре килеп чыгышын өйрәнү;
- фольклор, аның жанрлары турында кыскача бәян итү.

**Бурычлар:**

- фольклор темасына фәнни әдәбиятны өйрәнү;
- жанрларның килеп чыгышы, хәзерге көндәге ролен билгеләү;
- үземнең гаиләмдә татарфольклоры тоткан урынны ачыклау;
- замана балалары өчен татарфольклоры ролен ачыклау;
- “Татар халык авыз иҗаты” темасына лэпбук ясау.

**Тикшерү объекты** булып татар фольклор әсәрләре тора.

**Гипотеза:** хәзерге заманда яшьләр арасында татар фольклоры әсәрләренә кызыксыну кими.

Эзләнүләр барышында шундый **методлар** кулланылды :

- системалы анализ ясау;
- күзәтү;
- анкета үткәрү;
- әдәбият һәм интернет чыганакларны өйрәнү;
- килеп чыккан нәтиҗәләрне чагыштыру.

**Теманың актуальлеге:** татар фольклорында халкыбызның тарихы, тормыш-көнкүреше, йола-гадәтләре, авыз-тел һәм музыка иҗаты, бию-хореографиясе, шулай ук сурәтле-образлы фикерләве бирелгән.

Халкыбызның бай иҗатын тиешенчә җыйнау һәм фәнни өйрәнү хәзерге көннең иң мөһим бурычларыннан берсе булып тора.

## Бүлек 1. Төп өлеш. Фольклор әсәрләре тарихыннан.

### 1.1. Фольклор төшенчәсенә билгеләмә.

Фольклор сүзе (инглизчәдән *folk+lore* – халык хикмәте, халык акылы) – XIX ахырында барлыкка килеп, төрле илләрдә киң кулланышка кергән халыкара атама.

Русларда ул, башлыча, халыкның сүз сәнгатен, ягъни авыз-тел иҗатын белдерүче термин буларак кулланыла.

Татар фән дөньясында да бу терминнарның мәгънәсе һәм кулланылышы руслардагы шикелле.Аның язма әдәбияттан аермалы, үзенә хас үзенчәлекләре, асыл сыйфатлары бар:

1) телдән-телгә күчеп яшәве белән аерылып тора һәм телдән сөйләнә яки телдән башкарыла торган иҗат;

2) коллектив-күмәк иҗат та, ягъни аны тудыруда һәм эшкәртүдә күп кенә халык вәкилләре катнаша. Тыңлаучыларның күңеленә хуш килгәндә, ул телдән-телгә күчеп китә, шомара, камилләшә;

3) күп вариантылылык. Телдән-телгә күчеп йөргәндә яки төрле кешеләр авызыннан сөйләгәндә, әсәрнең ниндидер бер тотрыклы вариантта гына яшәве мөмкин түгел. Ул төрле үзгәрешләргә дучар була;

4) фольклорда сүз төп рольне уйнаса да, ул сүздән генә торган иҗат түгел, бәлки аерым жанрларда сүзне, музыканы, биюне, театраль тамашаны бергә берләштерә торган синтетик иҗат та;

5) традиционлык һәм дәвамлылык-күчемлелек. Фольклор традиция рәвешендә буыннан-буынга күчеп килә;

6) милли характерда булуы. Бу үзенчәлек анның эчтәлегендә дә, шулай ук формасында бердәй дәрәҗәдә гәүдәләнә. Татар фольклорында үзәнчәлекле милли жанрлар да бар. Бәет белән мөнәҗәт менә шундый жанрлардан.

Фольклорның милли табигате бигрәк тә халыкның сурәтле-сәнгатьчә фикерләвендә ачык күренә. Чөнки фольклор әсәрләрендә кулланыла торган образ-сурәтләр һәр халыкның мифологик традициясенә, яшәеш - мохитенә, көнкүреш үзенчәлекләренә һәм эстетик зәвыгына туры килеп тора. Моңа ышану өчен борынгыдан килгән традицион символларның кайсы халыкта нәрсә белдергәнлегенә игътибар итү дә җитә. Мәсәлән, сары төс безнең фольклорда сагышны, мариларда мәхәббәтне, кытайларда бөеклек-затлылыкны белдерә; кара төс исә бездә кайгыны яки күңелсез-тискәре нәрсәне, ә японнарда шатлык-куанычны аңлата. Яки агачлардан каенны алып карыйк. Русларда сылу гәүдәле кызны, мариларда угылны, мордваларда һәм чувашларда кәләшне, удмуртларда яшь егетне символлаштыручы бу образ татар фольклорында еш кына кайгы-хәсрәт сагышны белдерү өчен хезмәт итә.

**1.2. Фольклор төрләре.**

Фольклорда, язма әдәбияттагы кебек үк, халык иҗаты әсәрләрен тормыш-чынбарлыкны чагылдыру үзенчәлегенә карап, өч төркемгә бүлү, ягъни, фәнни термин белән әйтсәк, өч төргә (русча «род») берләштерү кабул ителгән: эпоска, лирикага һәм драмага.

Татар халык иҗатының һәм традицион классик жанрларының төрләргә мөнәсәбәттә төркемләнүе түбәндәгечә:

- эпик жанрлар: әкиятләр, риваятьләр, легендалар, мәзәкләр;
- лирик жанрлар: уен-бию җырлары, такмаклар, мөнәҗәтләр;
- лиро-эпик жанрлар: бәетләр;
- драма башлангычы белән үрелгән иҗат төрләре: йола поэзиясе, халык уеннары һәм уен-бию җырлары, балалар фольклоры.

**Мәкальләр һәм әйтемнәр.**

“Мәкаль” һәм “әйтем” дигән төшенчәләр гадәттә бергә, янәшә кулланып йөртелә.Чөнки алар арасында охшашлык, уртаклык шактый зур. Алар икесе дә иң кечкенә күләмле халык иҗаты әсәрләре. Мәкаль һәм әйтемнәрнең яшәү рәвешләре дә охшаш.

Ләкин мәкаль белән әйтем арасында шактый җитди аерма да бар. Бу аерма аларның эчтәлегендә дә, төзелешендә дә, шулай ук вазифа – функцияләрендә дә чагыла. Шуңа күрә дә алар икесе ике жанр булып исәпләнә дә.

Мәкальләрдән аермалы буларак, әйтемнәрдә фәлсәфи – дидактик хөкем чыгару, нәсыйхәт – киңәш бирү функциясе дә юк. Мәсәлән, нинди дә булса гафу итәрлек хата ясаган берәүгә карата «Дүрт аяклы ат та абына», «Кояшта да тап бар», «Үткән эшкә салават», «Беребез дә әүлия түгел» кебек әйтемнәр күңелгә килә. Ә менә теге яки бу эшне вакытында

һәм җиренә җиткереп башкарырга кирәклеген түбәндәге мәкальләр искәртеп тора: «Калган эшкә кар ява »,«Бүгенге эшне иртәгәгә калдырма», «Җиде кат үлчә, бер кат кис», «Татарның акылы төштән соң». Мәкаль һәрчак монологик сөйләмгә корыла, аерым кеше сөйләме составында гәүдәләнә.

**Табышмаклар.**

Табышмаклар текстларын төзүдә җорлык-тапкырлык һәм үткен акыллылык сорала. Бер үк вакытта әлеге жанрларның үрнәкләре, конкрет әсәрләре кечкенә күләмле булулары һәм шигырь-ритм төзелешләренең уртаклыгы буенча да бер-беренә якын торалар. Табышмак кара-каршы әйтешүне ягъни диалогик сөйләшүне һәм кимендә ике кеше (табышмак әйтүче һәм чишүче) булуын күздә тота. Табышмак ул – предмет яки күренешне читләтеп сурәтләүгә корылган һәм тыңлаучылардан шуның нәрсә булуын эзләүгә исәп ителгән башваткыч.

Табышмаклар баланың логик фикерләвен, зирәклеген, тапкырлыгын үстерүнең мөһим бер алымына әверелде. Бу инде, димәк, әлеге жанр, яңа шартларга ярашып, бүген дә яшәвен дәвам итә дигән сүз.

**Әкиятләр.**

Әкият – халык иҗатының бик борынгы жанры, шул ук вакытта әлеге жанрга карауче тылсым һәм могҗизалы уйдырмага нигезләнгән, яки маҗаралы һәм гадәттән тыш хәлләргә - вакыйгаларга корылган фантастик әсәр. Бүгенге көндә бу жанр киң кулланыла. Бала карында чакта ук хатын-кызлар туачак сабыйларына экиятләр сөйлиләр. Һәр гаиләдә балалар йоклар алдыннан экиятләр сөйләтә. Мәктәп яшендә, балалар бакчаларында экиятләрне сәхнәләштерү һаман да дәвам итә.

**Мәзәкләр.**

«Мәзәк» төшенчәсе күп кенә халыклар теленә, шул исәптән русларга грек теленнән кергән «анекдот» дигән жанр атамасына туры килә һәм хәзерге татар фольклор фәнендә нәкъ шул мәгънәдә кулланыла. Хәзерге вакытта мәзәкләр күпчелек радиода кулланыла. “Яңа гасыр” радиосында көн саен мәзәкләр ишетергә, телевизордан “Көлкеханә”, “Шаян-шоу” тапшыруларын карарга мөмкин. Заманыбызның һәм җәмгыятебезнең тискәре якларын фаш итеп, ул бүген дә социаль гаделлек, кешеләр арасында мораль-әхлакый камиллек өчен көрәшә.

**Бәетләр.**

«Бәет» атамасы гарәп телендә ике юллык строфа төрен белдерүче «бәйт» сүзеннән алынган дип исәпләнелә. Бәет жанры фаҗигале һәм героик вакыйгалар, шулай ук гыйбрәтле һәм гадәттән тыш хәлләр уңае белән чыгарылган әсәрләрне берләштерә. Аларның тексты шигъри формада була һәм телдән әйтелә яки көйләп башкарыла.

**Балалар фольклоры.**

Балалар фольклоры – шактый күләмле һәм күпкырлы иҗат. Иң тәүге һәм иң популяры, әлбәттә, бишек җырлары. Аларның төп вазифасы – баланы йоклату, йокыга талдыру. Бүгенге көндә дә әниләр бу жанрдан киң куллана. Мавыктыргычлар, юаткычлар да хәзер дә кулланыла. Балалар тормышында иярмешләр, тел көрмәкләндергечләр, эндәшләрне куллану бүген дә очрый. Балалар иҗатының тагын бер төре - хәрәкәтле уен фольклоры. Монда сүз – текст хәрәкәтле уеннар белән үзара үрелеп килә. Мәсәлән, “Почмак алыш”, “Сукыр тәкә”, “Йөзек яшереш”, “Әйлән-бәйлән” уеннары. Хәзерге көндә бу уеннарны балалар яратып уйный. Алар санамышларны бик яхшы беләләр, үз уеннарында еш файдаланалар.

**Йола фольклоры.**

Татар халык календаре, башка халыклардагы кебек, ел фасылларына һәм хуҗалыктагы эшләренә бәйле рәвештә барлыкка килгән. Шуларга бәйле рәвештә йола фольклоры да туган. Кыш көнендә уздырылган Нардуган уңаеннан нардуган җырлары башкарылган. Бу бәйрәм вакытында муллык һәм уңышлы ел килүен теләп, камыр ашлары пешергәннәр, төрлечә күрәзәлек иткәннәр, төрле уеннар уйнаганнар.

Яз көннәрендә үткәрелгән йола-бәйрәм – Нәүрүз. Бәйрәм вакытында авыл яшьләре йорттан йортка кереп, теләкләр теләгәннәр, бүләкләр җыйганнар, хуҗаларга төрле мөнәсәбәтләрен белдергәннәр.

Көзге бәйрәмдә уздырылган Сөмбелә бәйрәмендә халык мул сый-ризык әзерләп урамга чыккан, төрле уен-тамашалар уздырган.

Ә Сабан туе йолалары борын заманнан хәзергә кадәр үтәлеп килә.

Гаилә-көнкүреш йолалары, туй йолалары авыл җирендә сакланып калган. Авылларда бу йолаларга аеруча игътибар итәләр.

**2.1. Замана балалары өчен татар фольклоры роле** .

Без замана балалары - халкыбызның киләчәге безнең кулда. Ә без үзебезнең үткәнебезне беләбезме соң? Татар фольклоры турында яшьтәшләремнең белемнәрен беләсем килде. Шушы максаттан чыгып, мин тикшереүемне өч буында үткәрергә булдым. Мәктәпкәчә яшьтәгеләр, сыйныфташларым, югары уку йорты студентлары минем тикшерү объектларына әверелде. Һәр буын вәкиленә анкета сораулары тәкъдим ителде (Кушымта 1). Сорау алуларны анализлап, диаграмма төзелде. Сорау алуны энем йөри торган балалар бакчасында, гимназиянең 3 в сыйныфында, әнием эшли торган көллияттә үткәрдем. Анкета нәтиҗәләре күрсәткәнчә, мәктәпкәчә яшьтәгеләр татар фольклоры әсәрләре буларак әкиятләрне, табышмакларны әйттеләр, күпләре бу сорауга җавап бирә алмады (Кушымта 2).

Сыйныфташларымның җаваплары бераз күңелгә җылылык өстәде. Татар фольклоры әсәрләре буларак әкиятләр, табышмаклардан тыш, мәкаль һәм әйтемнәрне, такмакларны, бишек җырларын, “Сөмбелә” бәйрәмнәрен атадылар. (Кушымта 3).

Сорау алулар аша көллият студентларының татар фольклоры буенча белемнәренең бай икәненә ышандык. Алда әйтелгәннәргә өстәп, алар бәетләр, йола фольклоры, балалар фольклоры турында да әйтеп уздылар. (Кушымта 4).

Анкета нәтиҗәләре шуны күрсәтә: татар фольклоры турында белемнәре кече яшьтән үк бирергә, фольклор үрнәкләре белән балачактан таныштырырга кирәк.

**2.2. Безнең гаиләдә татар фольклоры тоткан урын .**

Милли тәрбия ул гаиләдән башлана. “Ә безнең гаиләбездә татар фольклоры әсәрләре нинди урынны алып тора икән?” - дигән сорау белән эзләнүләр үткәрдем. Мамадыш районы Түбән Сөн авылында яшәүче дәү әти һәм дәү әнием белән әңгәмәләрдән мин түбәндәгеләрне белдем: бишек җырлары белән әнием абыемны, мине һәм энемне йоклаткан. Дәү әнием үзенең кызыклы әкиятләрен сөйләп юаткан. Авыл җирендә исә, йола фольклоры зур үсешкә ия булуын аңладым. Моңа “Каз өмәсе” кичәләре, “Сабантуй” бәйрәмнәре ачык мисал булып тора.

Моңа минем күңелем сөенде, халкым өчен горурлык хисем артты. Димәк әле, авылларга кунакка кайткач, безнең буын балалары бу милли фольклор үрнәкләре белән таныша алалар дигән өмет бар.

**2.3. “Татар халык авыз иҗаты” темасына лэпбук ясау .**

Татар фольклоры турында белемнәре кече яшьтән үк бирергә, фольклор үрнәкләре белән балачактан таныштырырга кирәк. Татар телендә иҗат ителгән күрсәтмә әсбапларның аз булуын истә тотып, мин “Татар халык авыз иҗаты” темасына лэпбук ясарга булдым. Эзләнү вакытында табылган белешмәләрне бер җирдә туплау өчен бу бик уңайлы ысул булды. Әлеге хезмәтем минем балалар бакчасында тәрбияләнүчеләргә, башлангыч сыйныф укучыларына татар фольклоры әсәрләре турында белемнәрен киңәйтергә ярдәм итәр дип өметләнеп калам.

**Йомгаклау**

Хәзерге заманда яшьләр арасында татар фольклоры әсәрләренә кызыксыну кими дигән фаразлавым чынга ашмады. Фәнни-эзләнү эшем вакытында, мин шундый нәтиҗәгә килдем: шөгыльләрдә, музыка залында еш кына балалар табышмаклар әйтешә, төрле әкиятләр тыңлыйлар, татар халык уеннары уйныйлар, санамышлар, тел көрмәкләндергечләр өйрәнәләр. Сәнгать, гореф-гадәтләр, милли йолалар милләт тарихы белән тыгыз бәйләнгән.

Татар фольклорында халкыбызның тарихы, тормыш-көнкүреше, йола-гадәтләре, мифологиясе бирелгән.

Халкыбызның бай иҗатын тиешенчә җыйнау һәм фәнни өйрәнү хәзерге көннең иң мөһим бурычларыннан берсе булып тора.

Хәзерге вакытта милли йолаларга, гореф-гадәтләргә игътибар нык артты. Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә генә түгел, шулай ук башка дәресләрдә дә, милли йолаларны, татар фольклоры үрнәкләрен куллану уңай нәтиҗәләр бирә.

Без мавыгабыз, иҗат итәбез, эзләнәбез, димәк халкыбызның милли йолалары саклана әле, дигән өмет яши күңелләрдә. Шуны онытмаска кирәк: милли рух – акыл һәм гүзәллек, зәвык һәм әхлак, хезмәт һәм туган җиргә мәхәббәт тәрбияләү чарасы ул.

**Әдәбият**

1. Акберова А.Г.Мәкальләр.-Алабуга, 2003

2. Бакиров М.Х. Татар фольклоры.- Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 2008

3. Миңнуллин К.М., Кәлимуллин Җ.Х., Урманче Ф.И. Риваятьләр һәм легендалар.- Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 2001.

4. Миңнуллин К.М., Кәлимуллин Җ.Х., Урманче Ф.И. Халык афоризмнары.- Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 2002.

5. Хәбибуллина З.Н., Фәрдиева Х.Г., Хуҗиәхмәтов Ә.Н. Татар әдәбияты, 9 нчы сыйныф.- Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 2005.

6. Ярми Х.Х. Татар халкының поэтик иҗаты.-Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1967.

*Юнысова Ралия, 3 нче сыйныф, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «32 гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкче: Мөбарәкшина Рузилә Рәшит кызы, Шәрипова Алия Азамат кызы, туган теле һәм әдәбияты укытучылары*

## Иске Комазан авылы тарихы, ономастикасы, топонимикасы

Төбәк тарихын язганда архив документларына гына түгел, атамаларга да игътибар итәргә кирәк. Атамалар – тарих һәйкәлләре һәм алар безгә күп нәрсә турында сөйлиләр. Иске Комазан авылында шактый гына атамалар безнең көннәргә кадәр сакланып калган. Бу атамалар безгә туган җиребезнең дә, ата-бабаларыбызның тормышын да шактый гына күз алларга ярдәм итәләр.

Ономастика фәнендәге табышлар һәм казанышлар тел тарихын өйрәнүдә генә түгел, бәлки халыкның этник тарихын яктыртуда да зур әһәмияткә ия.

### Ономастика фәненең теоретик нигезләре

**Ономастика фәне турында гомуми төшенчә**

Ономастика (грек теленнән onomastike – исем кушу сәнгате) – тел белеменең ялгызлык исемнәрен өйрәнә торган тармагы. Шул ук вакытта бу термин белән ялгызлык исемнәре җыелмасын да атыйлар[13].Ономастика фәне үз эченә берничә тармакны ала.

1. Антропонимика – кешеләргә эндәшү өчен хезмәт итә торган исем, ата исеме (отчество), фамилия, кушамат, псевдонимнарны өйрәнә торган тармак.
2. Топонимика – ономастиканың географик объект атамаларын, аларның килеп чыгышын, төзелеш-ясалышларын өйрәнә торган тармагы.
3. Зоонимика – ономастиканың хайван, кош-корт кушаматларын өйрәнә торган тармагы.
4. Космонимика – барлык төр күк җисемнәре атамаларын өйрәнә торган тармак.
5. Теонимика – аллалар, изге затлар исемнәрен өйрәнә торган тармак.
6. Эргонимика – төрле оешма, учреждение атамасы булган ономастик берәмлекләрне өйрәнә торган тармак.
7. Прагматонимика – товар исемнәрен, маркаларын өйрәнә торган тармак.
8. Поэтик ономастика – матур әдәбиятта һәм фольклор әсәрләрендәге ялгызлык исемнәрен өйрәнә торган тармак.
9. Этнонимика – ыруг-кабилә, халык һәм милләт атамаларын өйрәнә торган тармак.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, хәзерге татар ономастикасы ялгызлык атамаларны өйрәнә торган тел гыйлеменең мөстәкыйль тармагы.

**Топонимика – ономастика фәненең бер тармагы**

Географик объектларның атамалары объектның үзе, аның тарихы һәм лингвистик табигате турында күп төрле мәгълүмат саклыйлар. Бу мәгълүматларны өйрәнү белән топонимика фәне шөгыльләнә. Һәрбер телнең, шул исәптән татар теленең дә, топонимиясе тел яшәеше хәрәкәтенең гаять катлаулы һәм үзенчәлекле иҗтимагый бер организмын тәшкил итә.

Топонимиканың су чыганаклары исемнәрен тикшерә торган бүлеге гидронимика, ландшафт-рельеф атамаларын өйрәнә торган бүлеге оронимика, торак пункт исемнәрен тикшерә торган бүлеге ойконимика, җирле зур булмаган географик объектларның атамаларын өйрәнә торган бүлеге микротопонимика, урам исемнәрен өйрәнә торган бүлеге урбанонимика дип атала. Ономастик терминнардагы -ним кушымчасы грекча

---

[13]Языкознание: Большой энцикл. слов. / Гл. ред. В. Н. Ярцева. - 2-е изд. (репр.) "Лингв. энцикл. слов. " 1990 г. - Москва: Большая рос. энцикл., 1998. – С. 347.

«исем, атама» мәгънәсендәге onoma сүзеннән килә, ягъни ойконим – ойкос «тору урыны, торак пункт» исеме, ороним – орос «тау-чокыр» исеме[14].

Топонимика фәнен «җир теле»н өйрәнүче фән дисәк дә була. Аны ниндидер аерым бер фән кысаларында гына өйрәнү дөрес һәм мөмкин эш түгел. Топонимик тикшеренүләр тел белеме, география һәм тарих, археология фәннәре казанышларын файдалану ярдәмендә генә башкарыла ала.

**Иске Комазан авылының географик атамалары килеп чыгышы тарихы**

**Иске Комазан авылы тарихы**

Иске Комазан авылы район үзәге Мамадыштан 15 чакрым ераклыкта, Мамадыш - Кукмара юлы өстендә кала. Авыл чокырда, кечкенә таучыклар арасында урнашкан. Тирә-ягын катнаш урманнар чолгап алган. (Кушымта 1)Нократ елгасына таба 7-8 чакрым ераклыкта Яңа Комазан авылы бар. Шуңа күрә, исемнәреннән чыгып, Иске Комазан авылына беренче нигез салганнар, дип уйларга була. Авылның. нигезләнү вакыты билгеле түгел. Ләкин аның исеме килеп чыгуы турында ике легенда бар.Мамадыштан Кукмарага баручылар чиста комлы урында Азан әйтеп китәләр. "Комда азан" дигәннән Комазан килеп чыккан. Элек авыл янында ком чыгару урыны булган. Бу урынны "Ком Казаны" дип йөрткәннәр. "Ком казаны" кыскарып, авыл исеме Комазан килеп чыккан[15].

**Урам исемнәренең килеп чыгу тарихы**

Морза урамы.Югары Ушмы авылында Морза исемле бай яшәгән, Ул иген җирләрен һәм Иске Комазан авылы янындагы урманнарның бер өлешен биләп торган. Аңа -Комазан халкы хезмәт иткән. Морза байның авылына чыгып китә торган урам аның исеме белән атала.

Чаллы урамы.Бу урам аша җәяүле һәм ат юлы узган. Мамадыш - Балык Бистәсе районнары чигендәге Чаллы авылына шушы урамнан узып йөргәннәр. Кайбер вакытта юлаучылар бу урамда яшәүчеләргә кереп кунгалаганнар.

Көек очы урамы. Авыл халкы Көек авылына кыска, туры юлдан бару өчен шушы урамнан чыгып киткәннәр.

Тауастыурамы.Бу урам 5-6 хуҗалыктан тора. Ул тау итәгенә терәлеп урнашкан. Шуңа күрә аны тау асты урамы дип атаганнар.(Кушымта 2)

**Чишмәләрнең, калкулыкларның аталу тарихы**

Иске Комазан авылында зур елгалар юк. Чишмәләрдән агып чыккан сулар җыелып ага торган кечкенә: Шуат, Чаллы, Морза инешләре бар. Шушы инешләр Комазаннан Нократка агучы Комазан елгасын тәшкил итәләр. Берничә кеше исеме белән атала торган чишмә бар.

---

[14]Подольская Н.В. Словарь русской ономастической терминологии. М.: Наука, 1978. – С. 103 - 136.

[15]Тыл ветераны Мөбарәкшина Газизәбикә әби сөйләвеннән

"Сәет бабай" чишмәсе. Чишмә авыл башында, су буенда, тау астыннан агып чыга. Сәет бабай матурлыкны, табигатьне яраткандыр, ул анда ике яшь каен утырткан. Бу яшь каеннар шаулап үсеп киткәннәр. Хәзер бу каеннар зур булып үскәннәр. Сәет бабай каеннар турында күршеләренә болай ди: "Менә бу каенның берсе мин, берсе минем хәләл хатыным", дигән дә, мыек астыннан гына елмаеп куйган. Чынлап та, чишмәгә карап торсаң, андагы ике каенның берсе кыз берсе егет кебек Сәет бабай чишмәсенең татлы суын эчеп үскән Гарафетдин абый да үзенеңчишмәгә карата күңелендәге хисләрен ачып салган. Аның бу шигырь юллары күңелгә якын:

Барладым барып юлларын,
Үлән юк сукмагында.
Тыңладым җанып моң-зарын,
Янында туктадым да.
Куяр җан тапмыйм бу җанны
Янәшәмдә пар каен.
Сагынам соңгы хуҗамны,
Каен шаулаган саен"[16].

Бу шигырендә Гарәфи абый үзенең табигатькә һәм чишмәләргә карата мәхәббәтен ачып салган. Зур шигъри җанлы кеше ул, шуңардырмы, күңеле канатлы атлардай матурлыкка җилкенә."Газизҗамал әби" чишмәсеЧишмәләр күбесенчә су буйларына урнашып ага. Чишмәләр бик күп, алар төрлесе-төрлечә. Онытылып, аны белгән кешеләр күптәннән дөньяда булмасалар да чишмәләрнең әкияттәй серле тарихы җәелеп ята. Һәр чишмәнең үз исеме, үз тарихы, аны төзегән кешесе була. Авылыбызның Чаллы очы су буенда бер кечкенә генә тарихлы кое бар. Аны кое дип тә, чишмә дип тә йөртәләр. Чөнки ул казылган. Кое кебек бик тирән дә түгел. Бу чишмәне Газизҗамал чишмәсе дип йөртәләр.1900 нче елларда бу чишмә янында бер Газизҗамал исемле әби торган, ире белән. Якын тирәдә чишмә булмаганлыктан, алар өйләре янына бер чишмә казып чыгаралар. Бу чишмәне Газизҗамал әби гомере өзелгәнче үзе чистартып, карап торган. Аннан соң аның Мөхәлисә, оныгы Шарифуллин Әлфир әбинең эшен дәвам иткәннәр.Хәзерге көндә дә чишмә сакланып калган.Бу чишмәдән башлап урманга кадәр 18 чишмә бар. Авылыбызның беренче чишмә төзүчесе Сәет бабай, икенчесе Газизҗамал әби.

Шулай ук авылны чолгап алган таучыклар да исемләнгән. Авылның кояш чыга торган ягында урнашкангамы авылның уң ягында урнашкан тауны Кашка тау дип йөртәләр. Икенче тау исеме - Кашшаф тавы. Тау Итәгендә элек Кашшаф исемле кеше яшәгән. Ул мал-туарын шушы тауга чыгарып, көтеп йөргән, гомеренең күп вакыты тау белән бәйләнештә узган.

---

[16]https://nsportal.ru/shkola/kraevedenie/library/2017/10/11/fnni-esh-tugan-avylym-tarihy

“Кристиән йөрәге”Авылыбызның иген басуларының берсе "Кристиән йөрәге" дип йөртелә. Ул ике ягыннан чишмә агып чыккан йөрәк формасында таучык - басу. Бу җирдә иген уңмаган. Ундырышсыз җир булганга аны крестьяннарга өләшкәннәр.

**Социаль сораштыру**

Әлеге теманы өйрәнү барышында без Иске Комазан мәктәбе укучыларының туган авыл, аның тарихы, топонимикасы буенча белемнәре белән дә кызыксындык. Социаль сораштыруүткәрергә булдык. Укучыларга 5 сорау тәкъдим иттек:

1. Нәрсә ул топоним, топонимика?

2. Сез Иске Комазан атамасының килеп чыгу тарихын беләсезме?

3. Сез үзегез яшәгән урамның исемен беләсезме? Ул нәрсәне аңлата?

4. Сез авылыбыздагы чишмәләрнең, таучыкларның исемнәрен беләсезме? Алар ни өчен шулай аталалар?

5. Үзеңнең туган ягыңның топонимнарын (урам, елга, чишмә, күл атамаларын) белү кирәкме һәм ни өчен?

Сораштыруда 1-5 нче сыйныфта укучы 20 бала катнашты. Күп кенә укучыларның топонимика, топонимнар төшенчәләрен белмәүләре ачыкланды. Җирле географик атамаларны һәм аларның килеп чыгу тарихын күп укучылар белә. Сораштыруда катнашкан барлык укучылар да туган якның географик атамаларын белергә кирәк дип саный. Ни өчен дигән сорауга күбесе түбәндәгечә җавап биргән:

-Үзеңнең туган ягыңны яхшырак белү өчен;

-Адашмас өчен;

-Белемле булыр өчен;

-Туган якның тарихын өйрәнү кызык.

Социаль сораштыруның нәтиҗәләре кушымтада бирелде. (Кушымта 3)

Топонимик атамалар тарихта гасырлар буена тупланып килгән асыл мирас ул. Аларда халкыбызның тарихи үткәне, тормыш - көнкүреше, һөнәрләре, изге, игелекле, ярдәмчел якташларыбызның исемнәре чагылыш тапкан. Иң күп микротопонимик атамаларның кеше исемнәренә нигезләнгәнен ачыкладык.

Нәтиҗә ясап шуны әйтәсе килә: атамалар, гомумән географик берәмлекләр, әби-бабаларыбыздан калган кадерле мирас. Һәр атаманы, күз карасы кебек кирәкле әйбер итеп, аңа хөрмәт белән карарга өйрәнергә кирәк. Тирә – юньгә сибелеп урнашкан вак географик берәмлек атамаларын җыеп алу, өйрәнү бик кирәкле эш.

Киләчәктә дә авылыбызның, үз төбәгебезнең атамаларын тырышып өйрәнербезен дип уйлыйм. Туган ягыбызның тарихын, атамаларын киләчәк буынга тапшыру без - яшь буынның төп бурычы.

Тикшерү эшен йомгаклап шундый нәтиҗәгә килдек:

1. Безнең төбәк топонимнары татар теленә карый.

2. Күпчелек топонимнар авылдашларыбыз хөрмәтенә багышлап аталганнар.

3. Туган авылыбыз топонимнарында тарихи вакыйгаларның эзе чагылыш тапкан.

Туган якны өйрәнү материалларының әһәмияте чиксез зур: алар Ватанга мәхәббәт, табигатькә сак караш һәм миллиүзаң тәрбияләүдә мөһим роль уйный, таныш- белү, эзләнү –өйрәнү активлыгын үстерә һәмиҗади эзләнү күнекмәләрен камилләштерә. Туган якны өйрәнү материаллары шулай ук укучыларның фактларны һәм мәгълүматларны гомумиләштерүне һәмсистемалаштыруны формалаштыра. Әлеге материаллар сыйныфтан тыш чараларда, шул исәптән таныш белү һәмкүңел ачу чараларында кулланырга мөмкин.

**Файдаланылган әдәбият исемлеге**


1. Дувалова Г.З. Чал тарихлы Комазаным. – Алабуга, 2018. – 483 б.
2. Подольская Н.В. Словарь русской ономастической терминологии. – М.: Наука, 1978. – 687 с.
3. Языкознание: Большой энцикл. слов. / Гл. ред. В. Н. Ярцева. - 2-е изд. (репр.) "Лингв. энцикл. слов. " 1990 г. - Москва: Большая рос. энцикл., 1998. – 682 с.
4. Авылдашлар, сугыш һәм тыл ветераннары сөйләвеннән: Мөбарәкшина Газизәбикә әби истәлекләре.
5. https://nsportal.ru/shkola/kraevedenie/library/2017/10/11/fnni-esh-tugan-avylym-tarihy


Кушымта 3

Социаль сораштыру нәтиҗәләре

| № | Сораулар | Дөрес җавап бирүчеләр саны | Дөрес җавап бирмәүчеләр |
|---|---|---|---|
| 1. | Нәрсә ул топоним, топонимика? | 6 кеше 30% | 14 кеше 70% |
| 2. | Сез Иске Комазан атамасының килеп чыгу тарихын беләсезме? | 18 кеше 90% | 2 кеше 10% |
| 3. | Сез үзегез яшәгән урамның исемен беләсезме? Ул нәрсәне аңлата? | 14 кеше 70% | 6 кеше 30% |
| 4. | Сез авылыбыздагы чишмәләрнең, таучыкларның исемнәрен беләсезме? Алар ни өчен шулай аталалар? | 10 кеше 50% | 10 кеше 50% |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 5. | Үзеңнең туган ягыңның топонимнарын (урам, елга, чишмә, күл атамаларын) белү кирәкме һәм ни өчен? | 20 кеше<br>100% | -<br>0% |

*Якупов Ислам, 5 нче сыйныф, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы "11 нче гомуми урта белем бирү мәктәбе"муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкче: Харисова Чулпан Сәгыйть кызы, татар теле әдәбияты укытучысы*

**Туган җирем, туган ягым!**

Без бу сүзләрне бик еш куллансак та, аның тарихын, үткәнен беләбезме? Турысын әйтик, белмибез. Дөрес, телдән-телгә, кемнәрдәндер ишеткәннәрдән чыгып,күпмедер дәрәҗәдә фараз итәбез. Ләкин аларның күпчелеге нәкъ шул кемдер сөйләгәннәргәгенә нигезләнгән. Ә тарих докуменлар булганда, фактлар раслаганда гына чын дип табыла. Шуңа күрә без бу турыда чын дөреслекне раслый торган мәгълүматларны җиткерергә бурычлыбыз. " Үз халкының тарихын белмичә яши торган адәм, нинди генә байлыкта һәм рәхәттә яшәсә дә, бу дөньяның матурлыгын күрә алмас",- дип яза атаклы шагыйрь, язучы М.Максут. Туган ягыбыз тарихын өйрәнү өстендә Халиков А.Х., Фәхретдинов Р.Г., Саттаров Г.Ф., Гарипова Ф.Г., Хаҗиев Р.И., Арсланов Л.С. һәм башкалар бик күп эшләде һәм күп кенә хезмәтләрен багышлады.

Туган ягыбыз- гаҗәеп кызыклы төбәк. Җирле географик объектларның күпчелегенең исемнәре бик борынгы заманнардан ук, ата-бабаларыбыз кушып калдырган килеш безнең чорга килеп җиткән. Алар бу атамаларны бер урынны икенчесеннән аеру ихтыяҗы туганга, бутамас өчен кушканнар. Һәр географик атама нинди дә булса гаять кыйммәтле мәгълүмат бирә, борынгы чор тарихын берникадәр күз алдына китерергә ярдәм итә. Галимнәр фикеренчә, барлык төр географик атамаларга караганда да, елга су исемнәре борынгырак. Халыкның көндәлек тормышында сакланган мондый атамаларда тарихи дөреслек бар, шуңа күрә су чыганаклары атамаларын өйрәнү актуальлеген югалтмый. Туган якның, Чулман атамасының барлыкка килү тарихын, Кама елгасы ярларында урнашкан шәһәрләрнең исемен өйрәнү максат итеп алынды. Галимнәрнең фикерләрен туплау бурычларын куйдым. Эшнең проблемасы: бүгенге мәктәп укучыларының күбесе туган якның атамаларының географик исемнәренең мәгънәсен, аларның килеп чыгышын белмиләр. Бу проблемадан гипотеза барлыкка килә: Татарстанда аларны өйрәнү өчен топонимнар җитәрлек.

Безнеӊ бабаларыбыз Изге Чулман белән ант иткәннәр. Бу елганы тикмәгә генә телгә алмаганнар, чөнки су – үзе бер тормыш. Бу тирәлектә гомер иткән халкыбызның гомере, яшәү рәвеше, сагышы, шатлыгы, күңеленеӊ чагылышы. “Эч серләреңне агым суларга сөйлә” дигән гыйбарә дә шушы заманнардан ук килә torгандыр. Биек һәм бөек тауларга яшьтәш булган елгалар -тарихның җанлы шаһитлары. Татар теленеӊ аӊлатмалыгы сүзлегендә “елга -башланган урыннан койган җиренә чаклы үзе салган үзәнлек буенча табигый рәвештә туктасыз агып торучы су” дип бирелә. Менә инде ничә гасырлар буена Идел, Чулман, Нократ кебек елгаларыбыз татар халкының, дәүләтләребезнеӊ чәчәк аткан чорын һәм шулай ук төрле илбасарларның аны һәрдаим канга батыруларын, бабаларыбызны рәнҗетүен, туган җирләреннән кубарылып туфракларын, йортларын, зияратларын ташлап төрле урыннарга күченергә мәҗбүр булуларын, илен саклау өчен башларын салуны күргән тарихи шаһитлар. Елгалар хәтерендә бик күп истәлекләр саклана. Мәсәлән, IX-XIII гасырларда Идел һәм Кама елгалары төбәгендә мәдәният, фән,архитектура өлкәләрендә алга киткән, урыс кенәзлекләре, Скандинавия илләре, Урта Азия, Кавказ, Иран Гарәп хәлифәтлекләре һ.б. илләр белән сәяси, сәүдә һәм мәдәни мөнәсәбәтләрдә яшәгән яшәгән Идел-Чулман болгарлары яшәгән. Явыз Иван Казанны яулап алганнан соң да, аның төрлечә татарларны мыскыллавын, җәберләвен бу елгалар хәтерендә саклый торгандыр. Үз ярларында рус авыллары төзелүне түгел, ә киресенчә татар авылларын күрәселәре килгәндер. Бу газаплар татар халкының дастаннарында, тарихи җырларында чагылыш тапкан.

Кама елгасы борынгы заманнарда ук Европа белән Азияне тоташтыруда әһәмиятле юл хезмәтен үтәгән, безнең төбәкләргә сәяхәтчеләрнең, сәүдәгәрләрнең килүе халкыбызның мәдәнияте, сәясәте, экономикасы үсүгә сәбәп булган, үзеннән зур өлеш керткән. Илебезгә килүчеләрнеӊ саны бихисап булган, шуңа күрә сәяхәтчеләр һәм галим – географлар язып калдырган хезмәтләрдә, сәяхәтнамәләрдә дә еш телгә алына. Мәсәлән: X йөз гарәп сәяхәтчесе Әбү-Исхак әл-Истәхри иң борынгы картаны төзи һәм “Климат китабы” дигән хезмәтен яза. Картасы бик схематик булуга карамастан, анда Идел һәм Чулман елгалары күрсәтелә.Тагы XV гасырда яшәгән венецияле монах Фра-Мауроның Россияне буенча төзегән географик картасында Идел һәм Кама елгалары, Кама тамагындагы Болгар шәһәрләре тамгаланган. Бу сәяхәтчеләр төшергән рәсемнәр татар галимнәренә өйрәнү өчен күп кенә кыйммәтле мәгълүматлар биргән.

Без зур елгаларның берсе булган, олуг елга- Кама (Чулман) елгасы ярлырында гомер итәбез. Чулман елгасы - Удмуртия Республикасы Югары Кама калкулыгыннан, сазлыктан башлана. Киров, Пермь өлкәләре айкап чыгып безнең Татарстаныбызга килеп керә. Иделнеӊ иӊ зур һәм күп сулы сул кушылдыгы. Кама Тамагы янында Куйбышев

сусаклагычына коя. Кушылдыклары: Нократ, Агыйдел, Чусовая, Вишяра, Зәй, Шушма, Иж, Мишә, Ык. Чулман елгасының гомуми озынлыгы 1805 км. Татарстан аркылы төньяк-көнчыгыштан көньяк-көнбатышка таба ага һәм Казаннан 80 чакрым түбәнрәк урында Идел белән кушыла.Татарстан территориясенә Чулман елгасының 360 чакрым озынлыгындагы иң күп сулы түбәндәге өлеше керә. Бүгенге көндә су агышы Кама, Воткинск, Түбән Кама, ГЭС плотиналары белән көйләнелә. Аның ярыларында Алабуга, Чаллы, Чистай, Менделеевск, Түбән Кама шәһәрләре җәйрәп ята. Чулман яры буйларында зурурманнар, авыллар, пристаньнар, ял йортлары урнашкан. Идел кебек үк, Чулман елгасы да гаять әһәмиятле су чыганагы. Ул Урал елгалары суы белән тулыландырыла. Идел белән икеседә тигез җирдән агуларына карамастан, Чулманның агымы тизрәк. Ә уң яры бөтен җирдә диярлек кыя, биек. Сулягысөзәк. Республикабызда Идел, Чулман кебек мәһабәт елгалардан башлап, һәр вак чишмәнең исеме бар. Һәр атама – үзе бер тарих ул, диләр галимнәребез. Кама елгасын элек Чулман иделе дип йөрткәннәр. Чулман гидронимын болгарларның ***чулматы*** дип аталган беркабиләләренә бәйләп карыйлар. Әйтик,***Чул-ы(м)-ан*** елгасы янында яши торган Чулыматылар. Чулман тирәсендә яшәгән фин-угорхалкы-мариларның бабалары Чулманны үзгәртмичә диярлек Шолман дип атаган. Марилар борынгыдан килгән әзер төрки атаманы гына кулланылышка кертеп җибәргәннәр дип уйлый алабыз, чөнки Чулман тирәләрендә төрки халыклар бик күптән яшәгәнлеген раслаучы архиологик материаллар табылып тора.

Чулман гидронимын ясалышы ягыннан тикшерсәк, ***-ан/-ән*** кушымчасы белән ясалган сүзләрнең мәгънәсен ачу бик авыр. Чөнки алар бик борынгы заманнардан ук барлыкка килгәннәр, V-VII йөзләрдән калган Орхон-Енисей язма истәлекләрендә дә ***–ан/-ән*** очрый, һәм килеп чыгышлары белән төрки телгә барып тоташа дип исәпли күп кенә галимнәр.(Казан, каран, шуран елгалары) Ә инде ***чул*** сүзенә килгәндә, елганың бара торган юл (юлым) түгелме икәнлеген гоманларга да, расларга мөмкин. Кабатлап язам, кайбер төрки халыкларда, хакаслар һәм шорларда чул, җул сүзләре-***“елга”, “су”***ны аңлата, марилар Иделне дә Юл, Ел дип атыйлар.

Кама атамасы үзенең килеп чыгышы белән фин-угыр телләренә барып тоташа, руслар тарафыннан кабул ителгән рәсми атама булып беркетелеп китә. Бу сүзнең этимологиясен күрсәтеп биргән күп кенә галимнәр бар. Аны удмурт телендәге кам-“елга” сүзе белән дә бәйләп карыйлар, камва-“көчле итеп егылып төшә торган су” сүзе белән дә аңлаталар. Хаҗиев Р.И. Кама атамасының килеп чыгышын тагын бер гипотезаны күрсәтеп уза. Татар телендә “кама” сүзенең “кыйммәтле тиреле су күсесе” дигән мәгънәсе дә бар. Мәсәлән: камчат бүрек дибез. Бу- су күсесе тиресе белән каймаланып эшләнгән баш киеме.

Чулман ярларында балкып утыручы калалар- Чаллы һәм Түбән Кама шәһәрләре. Түбән Кама атамасының ничек тууын инде әллә ниләр фаразламыйча да аңларга мөмкин.Елганың тыныч кына үз ярларыннан чыкмыйча җәйрәп яткан урынында, элекке Чәбия (удмурт сүзе, борынгы ыру) һәм Актүбә авыллары нигезенә төзелгән шәһәр.Чәбия авылы беткән,юкка чыккан, Актүбәнең язмышы бәхетлерәк – авылның бер урамы сакланып калган диярлек.Ә инде Чаллы топонимының килеп чыгышы Чуллы (чаллы) гидронимы белән мөнәсәбәтле. Бу шәһәр борынгы бабаларыбыз тарафыннан XI гасырда ук нигезләнгән торак пункт. Татарстанда Чаллы дип аталучы авыллар бик күп һәм алар республикабызның төрле районнарына сибелгән.

Чаллы гидронимының барлыкка килүен ачыклау өчен Г.Ф. Саттаров хезмәтләренә мөрәҗәгать итәбез. Болгар телендә”чал” сүзе “таш”, “чаллы”- “ташлы” мәгънәсен белдергән. Чуваш телендә чул хәзер дә “таш” дигәнне аңлата. Борынгы төрки телдә чал сүзе “***күксел ак”, “көлсу ак”, “аксыл”, “ак йөзле кешеләр”***мәгънәсендә кулланылган. Шушы төшенчәне белдерү өчен ул хәзерге татар телендә дә йөри. Мәсәлән: чал чәч, чал сакал, чал болыт. Чал сүзенә ***–лы*** сыйфат ясаучы кушымча ялгану нәтиҗәсендә барлыкка килгән чаллы сүзе “аклы” дигәнне аңлата.Ләкин без бүген чаллы күлмәк яки чаллы яулык дип сөйләшмибез. Югарыда сөйләнгәннәргә нигезләнеп, Чаллы шәһәренең исемен Чулман елгасына коючы Чаллы “Ташлы” (“ташлы елга”) исеменнән алынган дип карыйбыз.

Ф.Г.Гарипова исә “Чаллы” атамасының килеп чыгышын Сон // Сөн > Цон > Цын > Ыцын > Ыцынлы > Цынлы > Чынлы > Чаллы тәртибендә үстереп, Һун-Сөн чорындагы төрки телгә бәйли. Аның фикеренчә, челматлар – Челман яисә Чулман буйларында яшәгән кешеләр.

Болгар чорының эпиграфик ташларын һәм елга атамаларын җентекләп тикшергән тарихчы Һ.В.Йосыпов сүзлегендә шәһәр исеме булып яңгыраучы Сувар, Болгар, Тәтеш, Биләр, Төрекмән, Балимәр, Сарай, Алат атамалары арасында “Чал” атамасы да бар. Аның фикеренчә, күпләп очраучы “Чаллы” топонимын, этноним буларак, елъязмаларда искә алынган челматларга бәйләп карарга кирәк.

Борынгы топонимнарны өйрәнү белән беррәттән күптән түгел барлыкка килгән атамалар турында да онытырга ярамый. Чаллы шәһәрендә урнашкан, халык теленә Элеватор тавы дип ныклап кереп утырган торак пункт бар. Элеватор тавы- микротопоним, шәһәрнең өске,иске өлешендә урнашкан микрорайон. Тауда Элеватор урамы һәм тыкрыгы бар. Болар барысы да 1911-1916 елларда тауда төзелгән элеватор тарихы белән бәйле.

Мин бу кечкенә хезмәтемдә Чулман атамасының һәм Чаллы топонимының барлыкка килү тарихына гына тукталып үттем. Сүземне йомгаклап шуны әйтәм: Чулман

елгасы үзенең матурлыгы, чиста , мул сулары белән, үзенең ярларында төзелгән калалары, салалары белән безне сөендергән кебек киләчәк буыннарыбызны да шатландырсын. Иҗат кешеләре аларга үзләренең сәнгать әсәрләрен багышласыннар. Без телибезме, юкмы, ләкин үзебез туган,ускән җиребезнең үткәненә борылып карарга тиеш, киредән әйләнеп кайтып өйрәнергә бурычлыбыз. Һәр кеше үзе тарихта ниндидер эз, мәгълүмат калдырырга хокуклы, ләкин моны һәркем акылы белән кабул итәргә тиеш. Татар топономиясенең тарихи катламнарын ачу, серләренә төшенү һәм җентекле итеп өйрәнү татар тел белеме алдында торган бурычларның иң мөһиме дип карала. Җирле географик терминнарны, топонимнарны һәм гидронимнарны өйрәнү татар теле һәм әдәбияты, тарих, география кебек фәннәрнеөйрәнгәндә ярдәм итә. Болар- халыкның картаймас юлдашы, юанычы, тормышының матур бизәге. Авылга, әби-бабайлар янына кайткач , төрле кызыклы мәгълүматлар алып килсәк, тагы да яхшы булыр иде. Чөнки һәр авылның (ойконимның) үз атамасы, үз нәсел җебе, тау-чокырлары, кеше кушаматлары бар. Халык матур уйлаган, авылына, җиренә, суына матур исемнәр бирә белгән.

**Файдаланылганган әдәбият.**


1. Гарипова Ф.Г.Авыллар һәм калалар тарихыннан.-Казан,1997.
2. Гарипова Ф.Г. Исемнәрдә- ил тарихы.-Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1994.
3. Гарипова Ф.Г. Татарстан гидронимнары сүзлеге.-Казан,1990.
4. ЛарионовА.С. Село Соболеково и Красный Ключ.-Нижнекамск,1992.
5. Саттаров Г.Ф. Ни өчен шулай аталган.-Казан, 1971.
6. Русча-татарча география сүзлеге/ Төзүчесе:Дусаев З.С.Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1971.
7. Хаҗиев Р.И. Топонимнар ни сөйли? / Р.И. Хаҗиев // Фән һәм мәктәп. – Яр Чаллы. – 2000. – № 1-2.
8. Хаҗиев Р.И. Исемнәрдә тарих чагыла / Р.И. Хаҗиев // Фән һәм мәктәп. – Яр Чаллы. – 2000. – № 3.
9. Хаҗиев Р.И. Атамалар ни сөйли? / Р.И.Хаҗиев // Аргамак. – Яр Чаллы. – 2000. – № 2.